# Ильдар Юзеев

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

4
**ТОМ**

Стихи
рассказы
пьесы

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Илдар Юзеев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

4

**ТОМ**

Шигырьләр
хикәяләр
сәхнә әсәрләре

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ю25

Редколлегия:

*З. Р. Вәлиева, Р. М. Миңнуллин, Ф. Г. Галимуллин, Ш.Г. Галиев, Д. С. Шакиров, Х. Г. Әюпов, Р. Х. Корбанов*


**Юзеев Илдар**

Ю25 Сайланма әсәрләр. 5 томда, 4 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 592 б.

ISBN 5-298-01217-5

©Татарстан китап нәшрияты, 2002





## Төрле еллар, җырлы,
## шигырьле юллар

# Йөрәк бүлегендә туган шигырьләр (цикл)

* * *

Кузгалмыйча ятам
Йөрәк бүлегендә.
Күрдем — терелү дә,
Күрдем — үлемен дә...
Йөрәк тибешләрем —
Өстә — аппаратта.
Үз җанының хәлен
Тәнем карап ята.
Күреп торам, йөрәк
Күкрәк читен кага.
Ул ашкына Күккә —
Мәңгелеккә таба.
Әйткән кебек була:
«Син кол итеп йөрттең,
Күкрәк читлегеңне
Инде ташлап киттем.
Синнән чыккач кына,
Тойдым Ирек тәмен,
Мин Күкләргә очам,
Калсын Җирдә тәнең...»
...Ташлап китмә, җаным,
Түзик инде, чыдыйк,
Коллык читлегеннән
Бергә-бергә чыгыйк!
Барыбер бит Җирдә
Кала алмам күпкә.
Ташлап китмә йөрәк,
Ал мине дә Күккә,
Ал мине дә Күккә!

* * *

Күкрәгем эчендә
Өермә дулкыны.
Түзмәде, өзелде
Йөрәкнең бер кылы.
Әйт, йөрәк, яшисе
Ничә ай, ел калды?
Өзелми түзәрлек
Әйт, ничә кыл калды?
Бирешмә, йөрәгем,
Ярылма, сулкылда.
Өметләр бар әле
Уйнарга бер кылда...

* * *

Ял итмичә бара-бара,
Озын юлда тузган йөрәк,
Дулкынлана яна-яна,
Яшьлегеннән узган йөрәк.
Мин үзеңне кызганмадым,
Мине бераз кызган, йөрәк,
Ил хәсрәтен ала-ала,
Ут шарыдай кызган йөрәк,
Һаман исән кала-кала,
Әлегәчә сузган йөрәк,
Зинһар, тагын берничә ел
Сөен, борчыл, сызлан, йөрәк...

* * *

Ел саен, көн саен
Тибәсең көчлерәк.
Мин тыңлыйм: әйт, йөрәк,
Ни кирәк, ни кирәк?
Кайвакыт күкрәктә
Тай кебек чабасың.
Илтәсең хуҗаңны
Кайларга таба син?
Мин ардым. Картайдым.
Син — тайга иярмәм.
Иярсәм, егылып
Төшәрмен иярдән.
Ник күкрәк читлеген
Ярсынып тибәсең?
Юк, килми финишка
Иң алдан киләсем...

* * *

Чаптым. Атлап киттем. Туктап калдым.
Уйга талдым гомер үрендә.
Мин нишләрмен, әгәр әйтелмәгән
Сүзем калса йөрәк түремдә?
«Әйт! Әйт!» — диеп, бик еш тибәсеңдер,
Ашыктырып йөрәк иясен.
Иртә, диеп, һаман кичектерәм,
Сөеләсем килә, сөясем...
Син туктасаң, өлгерәлми калсам,
Шушы җырым булып кайтырмын.
«Кадереңне бер дә белмәдем шул,
Кичер, йөрәк!» — диеп әйтермен...

* * *

Юк, табиб, китмим әле мин,
Теге дөнья — миңа ят.
«Китмә, китмә, сандугач...» дип
Җырлады илһами зат.
Шулчагында мин үземне
Сандугач итеп тойдым.
Урынымнан күтәрелеп,
Очып, талпынып куйдым.
Сезнең арагызда калам,
Кумагыз, сандугачлар.
Бәлки, туң җаннар да мине
Аңлый һәм тыңлый башлар...

* * *

Ята күрше караватта,
Хәрби очучы булган.
Күктә сугышкан: дошманга
Нәфрәте-үче булган.
Кабыргалар сызлый һаман,
Булса да инде күптән,
Канатлары каерылып,
Егылып төшкән күктән.
Яраланган... Кабат күккә
Менгән ул бөркет кебек.
Әҗәл якадан тотса да,
Яшәткән хыял, өмет.
...Өмет канаты сынуын
Без монда белдек-сиздек:
Хыялдан бәреп төшергән
Чынбарлык-өметсезлек...

* * *

Сугыш гариплəре белəн ятам.
Бер үк тəртип иртə-кичен дə...
Төнен ыңгырашам, үлəм, атам,
Туңам-янам окоп эчендə.
Алар белəн разведкага барам,
Үтеп чыгам фронт чигеннəн,
Əсирлеккə төшəм, əрни ярам,
Башны түбəн иеп чигенəм.
Мин дə сугыш гариплəре ише,
Бер үк язмыш, бер үк сулышта.
Дөнья тыныч, дилəр, ник соң кеше
Ызгыш-талаш, мəңге сугышта?
Төнендə дə сугыш, өнендə дə,
Мин дə газапланам ярамнан.
Җанында да яра, тəнендə дə...
Адəм нигə шулай яралган?

* * *

Йөрәк, котырма,
Тузма, шашынма,
Ял ит утыр да,
Утыр акылга.
Түгелсең инде
Егет яшендә.
Тыңла киңәшем:
Акыл — башыңда.
Утыр да ял ит
Таулар ташында,
Син инде Җирдән
Китәр яшеңдә.
Утыр да ял ит,
Утыр акылга.
Тыңласаң аны,
Таммас яшем дә.
Булырсың һәрчак
Егет яшендә...

* * *

*Энҗе ханым Исхаковага*

Инде бу котсыз заманда
Изгелек бетте, дисәм...
Шәфкатьлек утравы сыман,
Мәрхәмәт сездә исән.
«Инде көчтем тегендә»,— дип
Алалмадым сулыш та.
«Юк, китмисең әле»,— диеп
Кайтардыгыз тормышка.
Сихәтләндем. Инде җанда
Калды бер сорау гына:
Тормыш дигән океанда
Нигә без утрау гына?

* * *

*Хастаханәдә табылган васыять*

Картлар арасында иң яше мин,
Яшьләр арасында иң карты.
Йөзгә кадәр яши идем әле:
Гомеремне яшьлек кыскартты.
Гамьсез генә, йөгереп кенә үттем
Яшьлек белән картлык арасын,
Шул чагында уйлыйсылар калган
Йөзгә кадәр яшәү чарасын.
Уйланырга вакыт тимәде шул:
Тәмәкене имдем, еш тарттым,
Эчтем... чаптым... хатыннарда яттым...
Гомеремне шактый кыскарттым.
«Әһ!» тә итми йөзгә җитә идем...
Китеп бардым бары... туксанда.
Тик, кызганыч, шулай яшәр идем,
Мөмкин булып, кабат тусам да.
Васыятем шулдыр: яшьләр, картлар,
Әйтеп китәм сезгә гозерне:
Гыйбрәт алалсагыз, бүләк итәм
Яшәлмәгән ун ел гомерне...

* * *

Бу дөньяның, түрә булырга дип,
Күптән хыялланган бер ире:
Мин, ниһаять, хәзер зур начальник:
Йөрәк бүлегенең мөдире!
Мин буйсынып йөргән чиновниклар
Кирәк тапмадылар сүземне.
Көтеп-көтеп, өскә үрләтмәгәч,
Билгеләдем үзем үземне!
Өстәгеләр белсен: бер йөрәккә
Була алмыйдыр бит мең хуҗа.
Шайтаннар да сизсен, котыртмасын,
Үз җаныма үзем — мин — хуҗа!
Боерык бирәм: ишет, көйсез йөрәк,
Мин ни кушсам — шуны тыңлыйсың,
«Бие!» дисәм, бераз тыпырдыйсың,
«Җырла!» дисәм, әз-мәз җырлыйсың!
Үз нормаңны төгәл үтәмәсәң,
Миннән рәхим-шәфкать көтмәсен,
Эшлисең дә гел-гел эшлисең син,
Ялга, пенсиягә китмисең!
Жалу белән мөдиреңә килсәң,
Катгый хуҗа итеп тоярмын,
«囗Эштә мәңге калдырырга!» диеп,
Гаризаңа язып куярмын...

* * *

Утлар-бозлар йотып сыгылсаң да,
Гомер юлын узып,
Йөрәгеңне тотып егылсаң да,—
Яшәү — барыбер кызык!
Уйна, йөрәк, бары тормыш көен,
Кылларыңны сызып,
Кичерәсе мизгелләргә сөен,—
Яшәү — барыбер кызык!
Өмет-хыялларны сүндермичә,
Еракларга узып,
Гомер узуларын сиздермичә,—
Яшәү — барыбер кызык!
Яңа туган таңны котлап киләм,
Кулларымны сузып,
Авырлыклар, сабырлыклар белән —
Яшәү — барыбер кызык!

* * *

Йөрәк турындагы җырларымны,
Тау-тау өеп, утта яндырсам,
Барсы-барсы җилгә очар иде,
Көл өеме генә калдырсам.
Йөрәк турындагы бу җырларым
Туды тетрәп, туды күкрәп тә.
Утка салмам, салкын җилгә бирмәм,—
Дөрләп-дөрләп янсын күкрәктә...

*Гыйнвар — февраль, 1995*
*Диагностика үзәге, кардиология бүлеге*

* * *

Туйдым икейөзлелектән,
Алдаудан, куштанлыктан,
Ачыктан-ачык яисә
Астыртын дошманлыктан,
Качып котылмакчы булып,
Китәм мин бу дөньядан.
Анда — сафлык һәм ихласлык,
Анда — ялган тулмаган.
Ышанмасам да мин анда
Торып калачагыма,
Хыялда гына булса да,
Китәм балачагыма.
Юк шул, күпме омтылсам да,
Кайтасы юл өзелгән.
Һич кенә качып котылып
Булмый шул үз-үзеңнән.
Мин анда кайттым бугай дип
Уйларга гына кала.
Бала булып, артист сыман
Уйнарга гына кала.
Җаннар, аңнар тупаслана,—
Шәфкатьсез тормышыбыз.
И нәниләр, балалыктан
Китмәскә тырышыгыз...

*1995*

# *Кара багана*

Кырык йортлы бу авыл янында әүвәл заманда кара багана торган. Юлчылар авылны читләтеп узганнар, ди.

## I

Чиген, юлаучы,
Кара, бак әнә:
Авыл читендә —
Кара багана!
Ачык йөз түгел,
Шом көтеп тора,
Кара багана
Куркытып тора.
Һәлакәт көтә
Шул чикне узсаң,
«Исәнме?» — диеп,
Кулларың сузсаң.
Керә аласың
Бары баш иеп:
«Шул кануннарга
Буйсынам»,— диеп.
Кара багана —
Коллык тамгасы,
Буйсынмаганга —
Хурлык тамгасы.
Шуны белеп тор
Узсаң яныннан:
Аның артында
Каты кануннар.
Кыз алып кайтса
Берәрсе читтән,
Кемдер капкасын
Карайтып киткән:
Кушмый кануннар,
Кушмый замана,
Хурлык тамгасы —
Кара багана!
Килсә бер егет
Читтән яр сөеп,
Кара ягалар

«Килмешәк» диеп.
Башка төбәктә
Янса күршеләр,
Чиләк күтәреп
Барса кешеләр,—
Кире кайтара
Канун-замана:
Янганнан кала
Кара багана...
Кемнәр токымның
Канын бозалар —
«Дуслашыйк!» — диеп,
Канун бозалар,—
Арестант булып
Моннан узалар:
Гыйбрәт ал, адәм,
Кара, бак әнә:
Себергә илтә —
Кара багана!
Кими мал, халык —
Үләт тарала:
Кара багана
Һаман карала.
Кайгы-бәлаләр
Туры юл белән
Тар сукмаклардан
Бәргән дә кергән.
Киткән кайгылар
Борылып килгән,
Янгын артыннан
Корылык килгән.
Нәсел-нәсәпләр
Карая барган,
Шәҗәрәләре
Тарая барган.
Килгән изгелек
Борылып киткән,
Кырык йорт-нигез
Кырылып беткән.
Эзсез югалган
Җир йоткан кебек.
...Бу хәлне авыл
Оныткан кебек...

## II

Замана — юлчы
Юлларда йөри,
Баганаауган
Елларда йөри,
Уйланып тора
Чорлар чигендә...
Рәхим ит, юлчы,
Кире чигенмә!
Төрле илләрдә
Кабер-зиратлар,
Читне үз итеп
Ята ир-атлар.
Авыл баласы
Ята читләрдә,
Кара багана
Ауды чикләрдә...
Дөньяга ачык
Кемнең кемлеге,
Ил иркенлеге,
Күңел киңлеге...
Бик күп чикләрдә
Агара бара,
Агара бара
Кара багана.
Ерак чүлләрдә
Ач-хәлсез бала
Авыл икмәген
Сөенеп каба.
Изге Заманны
Юлдашы иткән
Кечкенә нокта
Нинди зур икән!
Салават күперен
Бүлешү нигә?
Ни җитә күктә
Күрешүләргә!
Ил белән илләр,
Тел белән телләр
Дуслаша торган
Дәверләр-көннәр.
Дәү илгә кече,

Кечегә дәү илләр
Юл бирә торган,
Кул бирә торган
Көннәр-дәверләр...

### III

Иркен киң юлдан
Бара Замана.
Алдында ни бу?
Кара, Замана:
Кара багана!
Туктап, уйланып
Кала Замана...
Югалган авыл,
Җир йоткан кебек.
Бу хәлне дөнья
Оныткан кебек.
Шул ук багана
Борын-борыннан...
Күпме кабилә,
Ыруг кырылган,
Эзсез югалган
Милләт-халыклар,—
Хәрабәләрдә —
Археологлар...
Калыккан саен
Кара багана,
Һәлакәт көткән
Ил-җир, замана.
Онытмый еллар,
Онытмас аны:
Ут-үлем чәчкән
Свастиканы.
Онытмый еллар,
Онытмас аны:
Кара багана —
Хиросиманы!..
...Илләр чигендә
Замана тора,
Аерып-бүлеп
Багана тора,

Дәүләт-илләрне
Шикләргә тартып,
Иң-иң ахыргы
Чикләргә тартып.
Ут юк күршедә,—
Ут кертер иде...
Ут кертү түгел,
Ут төртер иде.
Кайдадыр сугыш,
Дөрли ил эче.
Үз өе тыныч —
Аның ни эше...
Тетрәсен галәм,
Җир-су чайкалсын,—
Үз куышында
Үзе сау калсын...
Олы илләр дә
Тарая икән,
Читтә багана
Карая икән,—
Зур Хакыйкатьтән
Аерылсаң әгәр,
Заман юлыннан
Каерылсаң әгәр.
Җир шары шундый
Хәлгә килмәсме:
Кара багана —
Атом гөмбәсе?!
И нурлы дөнья,
И шомлы дөнья.
Тарая күрмә,
Карая күрмә!
Күбәйсә әгәр
Кара багана,
Һич гафу итмәс
Килер Замана!
Кара багана,
Кара багана,
Замана — көзге.
Кара, бак әнә:
Кайларга таба
Бара Замана!
Баганаларны,

Чикләрне атлап
Ул уза — Заман,
Материкларга,
Континентларга
Кул суза Заман!
Чигенеп куя
Ультиматумнар,
Кодрәтен тыя
Бомба-атомнар.
Алда нурлана,
Кара, бак әнә:
Минем хыялым —
Зәңгәр багана!
Киң күңел белән
Кил шулай һаман,
Рәхим ит, юлчы —
Рәхим ит, Заман!

*1975—1977*

## Борчак белән Ядрә

Язгы көн иде.
Кеше шул чакны
Йомшак туфракка
Күмде Борчакны.
Яңгыр, яу гына,
Җилкәй, ис кенә,
Иркен кырларда
Күкрәп үс кенә.
Яңгыр мул булыр,
Коя да коя.
Борчак та үзен
Бик әйбәт тоя.
Шулай җай гына
Килгәндә шытып,
Борчуга калды
Шартлау ишетеп.
Якында гына
Нидер сикерде.
Түгәрәк үзе,
Борчак шикелле.
Артында кара
Төтен калдырып,
Үтте ул эчкә,
Җирне яндырып.
Борчак янына
Тәгәрәп килде.
— Ә-ә... Борчак?! — диеп
Масаеп көлде.
Мин монда хуҗа!
Мин монда төштем!
Югал алдымнан
Әй Борчак, мескен.
Ә мин... мин — Ядрә,
Иң көчле — җирдә,
Каршы торалмый
Миңа беркем дә.
Нәрсә ул миңа
Синең ишеләр...
Минем көчемнән
Курка кешеләр!
Әгәр теләсәм,

Дөньяның үзен
Җимерә алам,—
Беттеме сүзең?
— Мактанмыйбыз,— ди
Борчак,— көч белән,
Үсәбез җирдә
Тыныч эш белән.
Сүз белән түгел,
Эштә алышыйк.
Телисең икән,
Әйдә, ярышыйк.
— Бар дөнья белә
Мине — Ядрәне.
Җиңеп карале,
Әйдә йә әле...
Һәм ул туфракны
Тиште көч белән.
— Үсәр юлыңны
Барыбер бүләм!
Нур чәчте кояш,
Су сипте болыт,
Эре тамчылар
Килде бер булып.
Күршесен Ядрә
Кузгатып карый,
Тик тиргә бата
Һәм тәмам арый.
Нигә көч җитми,
Нигә соң авыр?
Белми ул җирдә
Тамырлар барын.
Кырдан кырларга
Борчак тарала.
Ядрәнең йөзе
Көя, карала.
Бер көнне Кеше
Җиргә иелде.
Уңышын күреп,
Шундый сөенде!
Борчакларны ул
Шатланып алды.
Ә Ядрә җирдә
Тапталып калды.

*1963*

## *Тәүге тыныч төн*

Әнә
    ветеранның
Тәрәзәсе шаулап ачылды.
Уналты ел гәүдәсендә йөрткән
                    соңгы пуля
                        җиргә очты,
                            әрнү басылды.
Тешен кысып,
                    ул барсына түзде:
Саташулы
һәм йокысыз озын төннәргә,
                менә хәзер
                    изрәп йоклап китте,
Башын куйган иде мендәргә.
Җилләр!
    Туктагыз...
        Өй янында үскән яшь топольләр,
                    сез дә йоклагыз!..
Тавыш чыкмасын!
Сугыштан соң —
                    бүген —
                        тәүге тапкыр
Карт ветеран тыныч йокласын...

*1963*

## Бер тамчы яшь тамды

Килде егет кырда ятып калган
Яудашларын искә алырга.
Ир йөрәге салкын таш түгел шул,
Ташлар... ташлар тирә-ягында.
Кабер тирәсендә гөлләр була,
Кайчан гына килмә — гел була,
Бер тамчы яшь тамды таш өстенә,—
Ир-егетнең яше бер була...
Бер тамчы яшь тамды...
Бер тамчы яшь...
Пешереп алды
Кургаш шикелле.
Пуля койсаң әгәр,
Аңардан да
Кайнар пуля булмас шикелле.

*1963*

## Сакмы йокың, Кеше!

Арулары соңгы чиккә
Җиткәндер.
Сизми калып, кинәт йоклап
Киткәндер.
Уян инде, и яшь ана,
Яшь ана.
Уйный сабый, әнисенә
Ышана.
Якынлаша караватның
Читенә.
Күтәрелә һәм очарга
Итенә.
Уяулыкны оныта торган
Чак түгел.
И яшь ана, нигә йокың
Сак түгел?
Төшә бала, төшә бара
Идәнгә.
Инде китте, инде бетте
Дигәндә...
Тойды ана. Тәмле йокы
Бүленде.
Куллар, куркып, сабыена
Үрелде.
...Беләсеңме син, яшь ана,
Сак ана:
Җир йөзендә күпме бомба
Саклана?
Әй син, Кеше, сакмы йокың,
Сакмы соң?
Кулларыңнан Җир шары ычкын-
масмы соң?

*1963*

## Тын океанда, тыныч чорларда

Бәлагә очрап, 49 көн Тын океанда, кечкенә баржада йөреп, җиңеп чыккан дүрт совет солдатын Америка авианосецы үзенең бортына алды.

*Газеталардан*

Утта янмый,
Суда батмый калып,
Мең үлемне җиңеп —
Эльбада —
Читкә куеп кызган винтовкасын,
Кулын сузган иде ул аңа.
Менә алар тагын очраштылар
Тын океанда,
Тыныч чорларда,
Бер-беренә ярдәм кулы сузып,
Магелланнар узган юлларда.
Океанга «Тын» дип исем биргән
Магелланның сүзе чын булсын,
Ерак-ерак ярлар якынайсын,
Океаннар мәңге тын булсын!

*1964*

# Ризалар

Атом-ракеталар заманында
Лирикага бирелеп йөр икән...
Спутник булып күккә менәлмәгәч,
Нигә кирәк җырың-лирикаң?..

*Бәхәсчеләр сүзе*

«Физикларммы,
әллә лирикларммы?!»
Бәхәсчеләр сүзсез калдылар...
Һава кораблары кузгалдылар.
Кемнәр?
Көтәләр...
Шулчак ишетәләр:
Галәмчеләр,
җирне урап,
җырлап үтәләр.
Туган җиребезнең матурлыгын
Шундый биеклектән күр дә син,—
Лирикага
бирелмичә ничек түзәрсең...
Иң-иң матур поэмадай булып
Ишетелә һәрбер сүзләре.
Хәтта
лириканың «дошманнары»
Җырлап җибәрмичә түзмәде.
Галәмчеләр,
батыр очучылар
Лириканы канат итәләр,
Планеталар
яңа физикларны,
яңа лирикларны көтәләр.
Фәнгә гашыйк булган очучылар
Эчтән шигырь ятлап узалар...
Бәхәс тынды...
Физиклар да,
Лириклар да инде ризалар.

*1964*

# Әйдә, аткаем!

Шаулы юлдан бара аткаем,
Чайкап-чайкап ала башкаен.
Җилбер-җилбер килә ялкаең,
Җилдән җитез барыйк, аткаем.
Әллә инде, аткай, арыйсың,—
Каерылып артка карыйсың.
Һаваларга карыйм, кырларга,
Бирелəм мин матур уйларга.
Рәхәт җилләр исә каршыга,
Машиналар алга ашыга.
Мотор тавышы белән тулган кыр,
Ишетәсеңме, аткай, тыңлап тор.
Самолетлар оча, карап кал,
Җирне әйләнәләр кораблар.
Әле без бәләкәй чакларда,
Авыр килә иде атларга:
Оныттылар, димә, аткаем,
Башың түбән имә, аткаем.
Машиналар алдан киләләр,
Зурлап юл бирәләр, күрәләр...
Күтәр башың, күтәр югары,
Нинди җитез заман юллары.
Җилбер-җилбер килсен ялкаең,
Артта калмыйк, әйдә, аткаем!

## Син яшьтәш тә, замандаш та...

«Мин коеп куйган шагыйрь генә түгел...»

*Г.Тукай*

Синең сының хәзер гөлбакчада
Бронзадан коеп куелган;
Мин бер вәкил булып килдем менә
Син күрмәгән яңа буыннан.
Нәрсә әйтим, Тукай,
Синең алда
Телем көчсез минем, сүзем аз.
Мин китергән чәчәк яз ясамас,
Үзең бакча бит син, үзең — яз.
Печән базарлары, кярханәләр...
Берсе дә юк...
Үзең дә бит күреп торасың,
Миңа һаман егерме җиде, диеп,
Син елмайган кебек буласың.
Үссәләр дә,
Синең даның өчен
Тарайдылар инде бистәләр.
Җырларыңны төрле-төрле телләр,
Ерак-ерак илләр ишетәләр.
Син калдырган язның гөлбакчасын
Бар күңелләр якын тоялар,
Сине хәзер безнең заманалар
Бронзадан коеп куялар.
Син яшьтәш тә, замандаш та булып,
Дөнья буйлап җырлап йөрисең,
Дөрес әйткәнсең шул,
Әйе, Тукай,
Коеп куйган гына түгелсең...

*1965*

## Әкияттән аерылу

Кавказ якларына килү белән,
Биек тауларына үрләдем.
Бала чакның шомлы әкиятләре...
Үзем мендем, үзем шүрләдем.
Каф тау артындагы диюләрне,
Алтын сарайдагы гүзәлне,
Аны өзелеп сөйгән шаһзадәне
Күрмиенчә күңелең түзәрме?
Кара болытларга үрләдем дә
Башым күккә тигәч шүрләдем...
Җен-пәриләр әмма күрмәдем мин,
Сарайдагы кызны күрмәдем.
...Хыял кыясына үрләгәндә,
Тормыш тауларына менгәндә,
Әкият кебек садә, беркатлы чак
Югалдымы кырыс җилләрдә?
Нигә мендем Кавказ тау башына?
Сабый җаным калды бушанып.
Бала чакның гаҗәп әкиятенә
Йөрер идем һаман ышанып.
Тау башына мендем бала булып.
Түбән таба төштем олаеп,
Каф тау артларына китеп барган
Кичке кояш кебек моңаеп...
Өлкәнлегем, реаль тауларга мен,
Тугры хыялыңнан каерылма.
Аерылсаң да серле әкияттән,
Сабыйлыктан әмма аерылма.

*1969*

## Өч авылдан чыккан өч гали җан

Өчиледән чыгып киткән Тукай,
Шигъриятнең серле йомгагын
Очын табып ерак гасырлардан,
Миллион күңелләргә чорнадың.
Сыркыдыдан чыгып киткән Такташ,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, киләчәккә илттең
Заманыңның шашкын моңнарын.
Мостафадан чыгып киткән Җәлил,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, дөнья буйлап киттең,
Үлемсезлек җырын җырладың.
Өч авылдан чыккан өч гали җан
Биеклектән карап күтәрләр:
Серле йомгак очын, югалтмыйча,
Кемнәр кая алып китәрләр?..

*1973*

# Дуска

Әгәр дә мин синең белән бергә
Эссе чүлгә китсәм,
Зар-интизар булып, комлы җиргә
Ятып, сусыз кипсәм?

Әгәр дә мин синең белән бергә
Разведкага барсам,
Дошман угы йөрәгемә тиеп,
Яраланып калсам?

Әгәр дошман алга ялган өеп,
Хәйлә, мәкер корса,
Яки дустың, яки үзең диеп,
Мылтык төбәп торса?

Әгәр безне аерып, мине — Сак,
Сине Сок итсәләр?
Мине иректә калдырып,
Сине юк итсәләр?..

Сорауларга катгый җавапларны
Сорасалар әгәр,
Әзерме без, утка-суга салып
Сынасалар әгәр?

*1970*

* * *

Йокыга талды арып кайткан
Гүзәлләр.
Тынып калды җәйрәп яткан
Үзәннәр.
Түгелерлек мөлдерәмә
Тулган Ай.
Нурлар ташый, тау-тәхеткә
Кунган Ай.
Яңа туган сабый йөзе
Диярсең.
Кулларыңа алырсың да
Сөярсең.
Мичтән чыккан икмәкмени —
Түгәрәк.
Туп шикелле төшәр таудан
Тәгәрәп.
Таулар, таулар... Зәңгәр ефәк
Шәл сыман.
Ай башына бәйләргә дә
Җәл сыман.
Нурлар ташый, тау башына
Кунган Ай.
Шагыйрь күңеле — мөлдерәмә
Тулган Ай.
Бер ташыр ул, таң калырлар
Үзәннәр.
Сикереп торыр йокыга талган
Гүзәлләр.

*1970*

# Туган җир һәм бала

*(«Таш диварлар авазы»на эскиз)*

— Туган өй. Күрәмсең үз улың кайтканны...
Кумагыз... Кертегез... Ачыгыз капканы.
— Узсаң да чикләрдән, бизсәң дә читләрдән,
Соң инде, туган өй капкасы бикләнгән.
— Әнием, онытчы күңелең ярасын,
Мин беләм: аналар кичерә баласын...
— Ил саткан балага күңелемдә урын юк.
Ул күптән югалды... югалды... улым юк.
— Чишмәкәй, сусадым. Ут йотып мин йөрим.
Бер генә тамчы су иренемә тидерим?
— Кагылма, суымны изгеләр эчтеләр,
Ил өчен утларны-суларны кичтеләр.
— Зиратым, язмышка баш игән бәндәне
Кызган, ал куеныңа гөнаһлы гәүдәне?
— Узып кит еракtан, рухыма кагылма,
Урын юк бабаңнар туфрагы янында.
— Мәрмәр таш,коткарчы, башымны бәрим дә
Югалыйм дөньядан, билге бул каберемдә?
— Мин матәм, мин һәйкәл, нигезгә куярлар,
Ил-йортны коткарган исемнәр уярлар...
— Мин тудым бу җирдә, өлешем-хакым бар,
Туган йорт, эчкән су һәм җиккән атым бар.
— Сине без тудырдык! Өметне алдадың...
Илеңә, анаңа ул була алмадың.
— Кайларга куйыйм бу бәхетсез башымны?
Алдымда бер йортның ишеге ачылды?!
— Күңелләр, капкалар, зиратлар бикләнгән.
Мин зиндан. Рәхим ит... Мин көтәм күптәннән...

*1970*

## *Толымнар*

Әй чәчләрең,
Ефәк толымнарың...
Берөзлексез карыйм аларга.
Әйдә барыйк әле киноларга,
Урамнарда сине күрсеннәр,
Толымнарың
Җилдә җилфер-җилфер килсеннәр.
Күрәм:
Һәрбер узучының хыяллары
Чәчләреңә килеп урала.
Кызлар әйтә булыр:
«Уф, Алла!..»
Читтә синнән дөнья кайгылары,
Толымнарың оста үрелгән!
Алар җилдә гамьсез җилфердиләр,
Күзләрең дә уйчан түгелләр.
Уйлар эзләп карыйм мин аларга...
Әйдә барыйк әле киноларга.
Кино күреп түгел, тормыш күреп,
Минем чәчләр бераз агарган.
Күзләремнән...
Тирән уй диңгезе карый алардан.
Толымнарың күздән югалуга,
Күп карашлар сине юксына.
Без кинода.
Ут сүнә.
...Әнә... фашист шундый матурлыкка
Вәхши кулы белән үрелгән.
«Үлем фабригы»нда, тау-тау булып,
Озын кара чәчләр өелгән.
Йомшак толымыңны кулларыңа
Алуыңны тоеп утырам.
...Җилдә җилфердәгән ул чәчләрдән
Фашист үзенә кием тукыган.
Тоям синдә нәфрәт кабынуын,
Күзләреңнең усал януын,
Сизәсеңдер:
Әле дә ул фашистның толымыңа
Үрелергә хыяллануын.

...Без кинодан чыктык.
Сөйләшмибез.
Толымнарың...
Күзләремне алмыйм һич аннан.
Алар җилдә гамьсез җилфердәми,
Алар матур,
Алар уйчаннар...

*1963*

* * *

Яшьтәшләре бар да яуга киткән:
Үзе теләп, авыру килеш тә...
Ул, ничектер, калган, табып алган
Рәхәт яши торган бер эш тә.
Сугыш узган.
Кайтмаганнар — тыныч ил алдында,
Кайтканнарның — йөзе ак кына.
Ә ул йөри,—
Ыграк басса — берәр мина фәлән
Шартлап китәр кебек сак кына.
Еллар тыныч, дәшми закон да,
Ул сөйләшми сугыш хакында...
Яшьтәшләрнең сүзсез карашлары
Ап-ак башын түбән идерә.
Сугыш кырларында тими калган
Кайнар кургаш кебек көйдерә.

*1969*

## Саумы, яшьлек!

*Казан педагогия институтының 100 еллыгына*

Саумы, яшьлек!
Озак еллардан соң
Сиңа килеп тагын баш идем...
Танымыйсың?..
Әйе, үзгәргәнмен...
Ул чакта шул мин бик яшь идем.
Бер без генә түгел, бик яшь иде
Болак буендагы юкәләр...
Без яшәгән заман тизлегедәй,
Еллар шулай бик тиз үтәләр.
Озак карап тордым Болакка мин —
Инде туктап калган тын суга...
Яшьлек белән очрашканда шулай
Күңелле дә, бераз моңсу да...
Саумы, яшьлек!
Залларыңда йөргән
Бабай-әбиләрнең яшьлеге,
Әнисенең күкрәк сөтен имгән
Бәбиләрнең килер яшьлеге!
Саумы, яшьлек!
Синнән яуга киткән,
Кайтмый калганнарның яшьлеге!
Бүген сиңа килеп,
«Саумы!» диеп
Әйтми калганнарның яшьлеге!..
Саумы, яшьлек!
Өлкән остазларның,
Безнең сөйгәннәрнең яшьлеге!
Бүген килеп,
Чал башларын иеп,
«Саумы!» дигәннәрнең яшьлеге!
Саумы, яшьлек!
Өлкән җырларымның,
Хыял-уй-хисләрем яшьлеге,
Миңе мең язмышка карап киткән
Яшьтәш, дус-ишләрем яшьлеге!
Саумы, яшьлек!

Бүген синдә йөргән
Ярсу күңелләрнең яшьлеге,
Җир балкытып, көлеп чәчәкләнгән
Эне-сеңелләрнең яшьлеге!
Саумы, яшьлек!
Синең кайнарлыгың
Йөрәк түрләрендә саклады,
Кайбер мәхәббәтләр сүнсәләр дә,—
Сиңа булган сөю саф калды.
Сөйгән ярлар безне көнләмәсен,
Беркемне дә шулай сөялмам,
Аерыласым килми, шунлыктан мин
«Саумы!» димен,
«Сау бул!» диялмам...
Саумы, яшьлек!

*1951*

## Юлларга җыенсам...

Максатка барганда
Хәл бетеп егылсам,
Юк, түзә алмыйм дип,
Кирегә борылсам,—
Күтәреп алдылар
Үземнән көчлеләр,
Юлымда очраган
Фидакяр кешеләр.
Үземне акларга
Тырышып адашсам,
Вөҗданым алдында
Аз гына алдашсам,—
Кызарта белделәр
Үземнән көчлеләр,
Юлымда очраган
Намуслы кешеләр.
Салкынга чыдамый,
Җылыга сыенсам,
Авырга бирешеп
Еларга җыенсам,—
Башымнан сыйпады
Үземнән көчлеләр,
Әтидәй, әнидәй
Ягымлы кешеләр.
Кем идем? Кем булдым?
Узылган юл сөйләр...
Юлларга җыенсам,
Шул изге кешеләр
Сорыйлар шикелле:
«Син инде көчлеме?
Юлыңда очраган
Кешеләр төслеме?»

*1970*

## Табигатем минем ерганактай...

Тау башында ул җыелып торды,
Ә беркөнне үтеп ташларны,
Тын суларны әйдәп үз артыннан,
Биек таудан аска ташланды.
Тау астында тыныч күл бар иде,
Мөмкин иде анда агарга,
Тик ерганак аны читләп үтте,
Юлын тотып шаулы ярларга.
Җил үткәрмәс тауга ышыкланып,
Күлләр генә акмый тын тора...
Табигатем минем ерганактай,
Шау-шуларга, алга омтыла.

*1972*

* * *

Аннан бирле күпме печән үсте,
Яшел җәйләр узды, ак кышлар.
Нигә, нигә хәтеремнән китми
Җыелмыйча калган покослар?
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәгемдә уелып калдылар.
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калдылар.
Чалгы тоткан куллар мылтык алды,
Печән чапты япь-яшь киленнәр...
Ир бәхетен күрә алмадым, дип
Пышылдады кайнар иреннәр...
...Картаела, ахры, туган якка
Кайтып килүләрне ешайттым.
Печән чапкан ыспай егетләрне
Мәрхүм этиләренә охшаттым.
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәкләрдә уелып калмасмы?
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калмасмы?..

*1970*

* * *

— Хушыгыз! Мин китәм еракка!
Хушыгыз!
Ишетелде бер аваз колакка:
— Хушыгыз!
— Мин китәм кайтмаска, озакка.
Хушыгыз!
Яфраклар пышылдый колакка:
— Хушыгыз!
— Анда да мондагы шикелле
Каеннар, чишмәләр табылыр...
Хушыгыз!
— Картайгач, күңелең сагыныр,
Хушыгыз!
— Мин китәм бөтенләй кайтмаска!
Хушыгыз!
Тау-ташлар, диварлар әйттеләр:
— Кайтырсың...
— Юк, кайтмам!
— Сугышта үлгәннәр кайттылар,
Йә туфрак, йә ядкәр-таш булып.
— Юк, кайтмам!
— Галәмдә үлгәннәр кайттылар
Көл булып,
Метеор шикелле ашкынып.
— Мин кайтмам, түзәрмен!
Бар тарту көчләрен өзәрмен.
Туган як җилләре тәкрарлый колакка:
— Аңларсың киткәчтен еракка...
Бабайлар туфрагы тартыр ул,
тартыр ул,
Ни белсен яшь бала... Рәнҗемик.
Барыбер кайтыр ул,
кайтыр ул...

*1971*

## *Кылганнар*

Курганнар...
Курганнар өстендә — зиратлар,
Зиратлар өстендә — кылганнар,
Туфракка әйләнгән ир-атлар —
Кайчандыр изгелек кылганнар...
Хак юлда күп булган корбаннар,—
Тик күреп торганнар кылганнар...

Курганнар...
Курганнар өстендә — зиратлар,
Зиратлар өстендә — кылганнар,
Туфракка әйләнгән ир-атлар —
Кайчандыр явызлык кылганнар,—
Илбасар яу булып килгәннәр,—
Атканнар, асканнар, кырганнар...

Курганнар...
Курганнар өстендә алышкан
Илбасар, илсөяр ир-атлар...
Туфракка әйләнгән зиратлар...
Изгелек җиңгәнне күргәннәр
Сау калган илсөяр туганнар...
Зиратлар өстендә — кылганнар...

Курганнар...
Курганнар өстендә — зиратлар,
Зиратлар өстендә — кылганнар...
Сөйләгез, шаһитлар-кылганнар!
Белсеннәр исән-сау ир-атлар,
Белсеннәр дошманнар, туганнар:
Дөньяда кемнәр ни кылганнар...

*1972*

# Эпитафияләр

**1.**

Ярты җиһан аяк аска егылды,
Аңа барсы: байлык, ләззәт, бар бәхет!
Китте дөнья... Нәтиҗәсе шул булды:
Өч аршын җир, дүрт дивар вә тар ләхет.

**2.**

Бер дә юкка җирдә яшәде,
Файда да юк аннан, зыян да...
Бер таш әрәм булды җиһанда,
Ошбу ташны язып куйганда.

**3.**

Өстендәге шушы ташка карап
Яткан чакта кызык итсәлә,
Гаеп итмәссең, шәт, мәшһүр карак,
Ядкәр ташың урлап китсәләр.

*1971*

* * *

Диңгезнең ярлары бик ерак
Булса да, утраулар, җирләр бар...
Диңгезләр артынданиләр бар?
Кемнәр бар?
Еректан-ерактан ишетәм:
Бик таныш өннәр бар.
Бу таулар бик биек булса да,
Карда да үсүче гөлләр бар.
Ә таулар артында ниләр бар?
Кемнәр бар?
Ерактан-ерактан ишетәм:
Бик таныш өннәр бар.
Күк йөзе... Мәңгелек... Чиксезлек...
Һәм бушлык... Билгесез өннәр бар.
Йолдызлар артында ниләр бар?
Кемнәр бар?

*1971*

## Гүзәллеккә — салават!

Заманча күзлек кигәнсең, сүзләрең дөрес, энем.
Мин дә шулай узган чорның тетмәсен тетәр идем...
Әйе, булды: баш әйләнү мактанудан, сүз, даннан,
Барабаннар суга-суга ерагаю вөҗданнан.
Әйе, булды районный һәм мировой ялганнар да,
Дәүләтебез миллиардларын кесәгә салганнар да.
Халыкка җавап тапмыйча, гаҗизләнү, аптырау,
Эчке яктан калтырап та, тышкы яктан ялтырау.
Иң камил тормыш төзедек, дип, буш сүзләр сиптерүләр,
Һәм дә халык хисабына банкетта типтерүләр...
Үзебезнең алдануга һәм алдауга юл кую,
Без дә кушылабыз, диеп кул күтәрү, кул кую...
Күпләр һаман аңга килми, җансыз һәм өнсез калган,
Ата-аналар хафада: баласы телсез калган.
Әйе, булды... Тукта, энем, син артык кызма әле,
Безнең узган гомерләрне тиз генә сызма әле.
Кара күзлегеңне салып, әйләнеп кара әле,
Бик күпләрнең йөрәгендә әрнү һәм яра әле.
Сүз белән сызып атсаң да безнең узган гомерне,
Сызып кара күңелләргә сеңгән Җырны, Шигырьне!
Җыр-моң саклады җаннарны авыр чакта түзәрлек,
Сәйдәш булып, Туфан булып яши бирде Гүзәллек!
Чишмәләрнең берсен генә томаласаң син тагын,
Җидегән чишмәдәй челтерәр көй булып Сара ханым.
Булмады түгел тормышта оялырлык кара як.
Сал күзлегең, Гүзәллекне аерып ал аралап.
Өмет белән әйтәмен мин Килер елларга карап:
Яманлыкка — нәфрәт! Нәләт!
Гүзәллеккә — салават!

*1980*

## Үкенечләр

Сулар акты, җилләр исте,
Тындылар күп инешләр...
Калды инде яшьлегемдә
Үкенечләр, үкенечләр.
Сөйгән юлдашын югалтып
Кычкырган күке нишләр?
Ераклардан аваз бирә
Үкенечләр, үкенечләр...
Инде кире китә алмыйм,
Чәчләрдә — ак көмешләр.
Озата барыр гомерем буе
Үкенечләр, үкенечләр...

*1975*

## КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

### *Шагыйрьләр*

Башта эшафотка мендерәләр,
Үзе үлгәч — шөһрәт таҗына...
Шагыйрьләрнең соңгы адымнары —
Йә батырлык, яки фаҗига.

### *Әйтмәссең...*

Әйтмәссең алар турында:
«Акылсыз и мәнсезләр...»
Акыллылар, исәплеләр,
Талантлы имансызлар.

### *Акушерлар һәм җәлладлар*

Акушерлар бала кабул итә,
Сөенеп: «Туа, диеп, талантлар».
Җиң сызганып, корбаннарын көтә
Кулына балта тоткан җәлладлар.

### *Гармун уйнасаң...*

Гармун уйнасаң, син уйна,—
Барча җан тынып калсын,
Гәүдәң җыр эчендә эреп,
Моң гына торып калсын.

## Нигә уйчан?

«Нигә уйчан?» диеп уйлыйсыздыр
Авыр йөкләр тарткан карт атны?
Кайбер картлар мине яшәрттеләр,
Кайбер яшьләр мине картайтты.

## Соң булса да...

Соң булса да, белә акыл, тоя йөрәк:
Дошман юктыр иске «дус»тан мәкерлерәк.

## Үземә

Дәрәҗәләр дә җитәрлек,
Исем дә — атказанган...
Булмасын иде җырларым
Халыктан отказ алган.

## Беләктә һәм йөрәктә

Яздым мин: «Әни бәгърем»,— дип,
Беләгемә энә белән кадап.
Әнкәм — юк... Инде язамын
Йөрәгемә энә белән кадап.

*1980*

## Акча янчыгына чигелгән сүзләр

1. Гел искә төшереп торсын
Шушы акча янчыгы:
Миллион тәңкәләрдән кыйммәт
Туган якның таң чыгы.

2. Тәңкәләр килер дә китәр...
Мәңгегә калыр тәңкә:
Әнкәң чәченә тагылган
Гап-гади талир тәңкә.

## Арба тәртәсенә язылган шигырь

Беркадәр гаеп булса да
Атта һәм дә тәртәдә,
«Үземдә гаеп юкмы?» дип
Уйла хет бер мәртәбә.

## Квартира ишегенә язылган шигырь

Үз шатлыгың тулы булып та,
Күршең хәсрәтен дә онытма!

## Бишеккә язылган шигырь

Бишектән табутка кадәр
Гомер дигән бер ара,
Мең сынауларын әзерләп,
Көтә сине, и бала...

## Кабер ташына язылган шигырьләр

1. Кичер, бәгъэрем, бер тапкыр да
«Сөям» диеп әйтмәдем,
«Сөям! Сөям» дип тамсыннар
Салкын ташка яшьләрем.
2. Бу дөньяда, аз булса да,
Безнең дә эзләр калды,
Боз, ташларны эретерлек
Әйтәсе сүзләр калды.

## Ни җырлар оныклар?

Меңьеллык — моң җанда,
Күзләрем — боеклар:
Меңьеллык туфракта
Ни җырлар оныклар?

*1980*

## Сибгат Хәким туган нигездә

Бер карасаң, Тукай кебек ерак,
Туфан кебек якын син безгә.
Тукай белән Туфан туганлаша
Сибгат Хәким туган нигездә.
Нәселеңдә — балта осталары:
Шундый бер йорт салдың син безгә:
Күпләр яши, шигъри җылы тоеп,
Сибгат Хәким салган нигездә.
Нәселеңдә — иген осталары,
Күңел нурың чәчтең син безгә.
Тугры Тукай, батыр Муса туар
Олы шагыйрь чәчкән нигездә.
Кол Галиләр, Кандалыйлар рухын
Саклап йөрткән ата син безгә.
Ту, шигырем, сөенечтән җырлап,
Зур осталар корган нигездә.

*Күлле Киме, 1981*

## Киләчәккә аваз

Хәзерге реактив самолетлар
тавыштан тизрәк очалар

«Сөям. Киләм»,— диеп
хәбәр бирдем дә мин,
очтым сөйгәнемә,
күккә мендем дә мин.
Төштем. Берәү дә юк,—
тавыш артта калган,
үзем — ракетада,
сүзем — атта калган.
«Сөям» дигән сүзем
килер соңга калып,
сүзсез иркәләүгә
торма гаҗәпләнеп.
...Кичер мине, заман!
Тизлек арта бара,
үзем — киләчәктә,
сүзем — атта бара.
Киләчәккә карап,
якты сагыш белән,
Узган, Бүгенгедән
аваз-тавыш бирәм.
Җыр-хәбәрем сезгә
булыр таныш, ят та.
Соң булса да, бәлки,
барып җитәр атта.

*1982*

* * *

Таныш урманнарым,
иң шәп җырны
сезгә багышларга теләдем...
«Тын кал, язма,— диде йөрәгем. —
Имәннәрнең серле пышылдавын
бик игътибар белән тыңла син...
Син җырлама, алар җырласын.
Тукта, тын кал,
яшел наратларның
ниләр сөйләшүен аңла син...
Йомшак җилдә
алар шауласын.
Агымсулар булып үзем агыйм,
үзем сөйлим әле, димә син...
Тын кал,
алар сөйләсен.
Юк, үрелмә кәгазь-каләмеңә,
иң талантлы рәссам үрелсен,
болыннарда аның могҗизалы
мең һәм миллион төсен күрерсең.
Табигатьтән өстен җырчы юк, дип,
хәйран калып карап торырсың.
Тукта, тын кал,
шулчак
Җырчы булырсың...»

*1980*

## Карт тал

Талгын җилдә сыгылып-бөгелеп
Назда үскән тал-тирәк,
Хәзер инде бөгелмисең,—
Карт буынга ял кирәк.
Хәтәр давыл алдында да
Бөгелмәссең, сынарсың,
Чал башыңны җиргә салып,
Ыңгырашмый тынарсың...

*1982*

## Бакый Урманче күргәзмәсен карагач

Бакый исеменең ни икәнен
Белеп йөресәм дә мин элек,
Әле тойдым аның чын мәгънәсен:
Мондый сәнгать бакый — МӘҢГЕЛЕК!

*1982*

## Теләк

Сине һәрчак һәр почмакта
Бәхет елмаеп көтсен,
Кысып кочаклап алсын да
Гел үзенеке итсен.
Туктап калма ярты юлда,
Гел бәхет өчен көрәш,
Үзеңнән артып калганын
Бәхетсезләргә өләш!

*1982*

## Урман кызы Гөлсәрия

Урман кызы Гөлсәрия
Бик ерак юлга чыга,
Юлларың гел җиңел булсын,
Булмаса әгәр, чыда.
Тормыш үзе — урман кебек,
Серле дә, караңгы да,
Кайчак җиләктән дә тәмле
Һәм әче баланлы да.
Яшьлек яфракларың өтеп,
Ят җилләр орынмасын,
Сандугачлы урманнардан
Читләргә борылма син...

*1982*

* * *

Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
очам,
йөзәм,
китәм
һәм кайтам...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
сагынам,
түзәм,
әрним,
югалтам...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
очмаучылар —
сәер, ят алар...
Бәлки,
мине
аңлый алмаучылар
беркөн йөрәгемә атарлар...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
егылып
төшәрмен дә
сызланып,
җан бирермен
соңгы сулышымда
очалмаганнарны кызганып...

*1982*

## Кемнәр үтәр?

Мин — мәңгелек материя,
хәзергә — җанлы адәм:
яшим,
тоям,
сөям,
елыйм,
кычкырып көлә алам...
Җиңәм,
җиңеләм,
картаям,—
яшәүдән китә барам.
Мин — мәңгелек материя,
гел җанлы булып калмам:
таш,
туфрак,
яфрак булырмын,
тик көлә генә алмам...
Мин — мәңгелек материя,
берни дә тоймас формада
җиргә кайтырмын урап...
Кемнәр үтәр өсләремнән
сагынып,
көлеп,
елап?..

*1983*

## Карадуган

Тумасам да Карадуганда,
Охшап киттең якын туганга.
Тагын ярты гасыр яшәп була
Сезнең кебек дуслар булганда!
Өлкәнәеп бераз бөгелсәм дә,
Мин сүз бирәм сезгә бүгеннән:
Карадуган кебек булырмын мин,
Кара дуга кебек бөгелмәм!
Кайчак чана кебек бөгелсәм дә,
Туктап калмам, алга шуармын,
Яңа туган сабый карамадай,
Һәр январьда кабат туармын!
Үз баласы сыман якын иткән
Балтачтагы Карадугандыр,
Мин буранлы салкын кышта туган,
Сезгә охшауларым шуңадыр.
Башны бераз җиргә иеп узсам,
Танымыйча карап калырсыз,
Яшьлек кебек моңлы, кыңгыраулы
Дәртле җырларымнан танырсыз...

*Карадуган, 3 гыйнвар, 1983*

* * *

Сибелә чәчәк,
Өзелә яфрак,
Күңелем сизенә:
Гомеремнең чәчәкләре
Һәр ел өзелә.
Һәммәсен дә йөрәк аша
Үткәрдек инде,
Күтәрәлмәс авыр йөкләр
Күтәрдек инде.
Юлларыма гел чәчәкләр
Сибелмәде шул,
Яшь гомерләр үткән-киткән:
Сизелмәде шул.
Күзләремдә кемнәр юлга
Чәчәкләр сипкән?
Хөрмәтлиләр: гомер зая
Үтмәгән икән.
Уйчан-дәртле нурлар уйный
Арган йөземдә,
Сибелә алкыш,
Сибелә чәчәк
Гомерем көзендә.
Элеккечә давылланмый,
Сибелми чәчләр,
Сибелә күз-яшь,
Өзелә үзәк,
Ни белә яшьләр...

*1985*

* * *

Әнкәемнең җылы туфрагында
басып торам.
Кулда — көрәгем.
Күкрәк читлекләрен вата күрмә,
дулама ла болай, йөрәгем...
Бу күкрәгем хәзер кышкы көндә
бушап калган салкын болын күк.
Йөрәк чаба, күкрәк читлегенә
тибә-тибә, шашкан колын күк.
Берчак өмет өзеп,
чабышларын
әкренәйтер,
чабар-чабар да,
аңлап алгач
мөмкин түгеллеген
үз әнкәсен эзләп табарга.
Ятим калганлыгын тойгач кына,
уйчанланыр.
Килер өлкәнлек.
Соңгы сулышында
кабат-кабат
ярсып тибәр:
«Әнкәм, әнкәм...» — дип...

*1985*

# Туктап уйга калу

Картаясы килми,
шулай да
картлыкка барабыз,
туктап тын алабыз,
сирәк ак чәчләрне
җилдә җилфердәтеп,
картлыкка барабыз,
узганнарны уйлап,
көрсенеп алабыз,
хәлсез башны
таянган таякка салабыз:
тирән уйга талабыз:
яшьлек артта калган,
юк кирегә китәр чарабыз,
булган — изгелекләр,
булган — яхшылыклар:
без аларны күбрәк табабыз,
кылган гөнаһларны,
ялгышларны
күкрәк читлегенә ябабыз...
Әллә яшерикме,
ачылыйкмы?
Йөрәкләрдә әрни, яна боз...
Соңгы тапкыр әйдә ачыл, йөрәк,
безнең ялгышларны
кабатламас, бәлки, балабыз!
Без, картлар,
тирән әрнү белән
артта калабыз.
Сау булыгыз, яшьләр!
Кылган яхшылыклар сездә китсә,
безне сафта диеп санагыз!
Без, картлар,
ялгышларын күкрәкләргә төяп,
авыр барабыз,
«Алга! Алга!» диеп күп кычкырдык,
хәзер,
башны түбән иеп,
газапланып,
туктап уйга калабыз...

Без, картлар,
бара-бара,
бик аз калабыз,
исәннәргә, зинһар, сак килегез:
без — төрлеләр,
заман бизмәненә салып карагыз,
яшәештә ихлас күңеллеләр —
без яшьлектә — сездә калабыз!
Авыр яуда тузган йөрәкләрне
вөҗдан үлчәвенә салабыз,—
чорга кирәк булса, ямагыз!
Йөрәкләрне ачып салабыз:
җиңелерәк картлык кичерсен, дип,
безнең хәлдә онык, балабыз...

*1987*

# «Татар бавы»

«А порой от намека слабого
Поднималась надменно бровка...
Далеко, далеко Елабуга
И татарская та веревка...»

*С.Липкин. «Зимний закат»*

Кама буйларында бау ишәләр.
Бугазымда авыр төер бар:
Бик якында гына зур шагыйрә[1]
Соңгы сулыш алган бер өй бар.
Кемдер уйлый: «Элмәк киюенә
Татар бавы, имеш, гаепле»...
Вакыт үзе әйтер хакыйкатьне!
Нахак сүзгә халык лаекмы?
Нәселем минем өзелерлек түгел,
Мең яшәгән ныклы тамырдан,
Чулман буйларында иген иккән,
Суга юкә салган, бау үргән.
Нинди ачы җилләр исмәгән дә,
Үрешләрен кемнәр кисмәгән,
Тарих бавын җигелеп бергә тарткан,
Әмма комнан аркан ишмәгән.
Упкын-чоңгыллардан үткән чакта
Өзелсә дә камыт баулары,
Ат урынына тарткан үз язмышын,
Сызылса да йөрәк майлары.
Идел-Чулман кичкән, ишкәк ишкән,
Язмышы да баудай үрелгән...
Татар җайдаклары гомум яуда
Париж урамында күренгән.
Нәселем минем күп дәһшәтләр күргән,
Баулар белән бергә җыр үргән,
Аның нинди җырлар үргәнлеген
Сорагыз сез Муса Җәлилдән!
Төрле телдә җырлап яшь аналар,
Өмет баглап, бишек асканнар,
Илбасарлар, баудан элмәк ясап,
Зояларны дарга асканнар.

---

[1] Марина Цветаева Алабуга шәһәрендә асылынып үлгән.

...Авыр бер чор, сугыш гарасаты
Маринаны монда китергән.
Хәзер кемне, кемне гаепләргә?
Сорыйк әнә Чулман, Иделдән.
Кем ишсә дә, бауның милләте юк,
Сылтамагыз аны милләткә!
Һәрбер телдә бер сүз: шәфкатьсезлек
Шагыйрәне илткән элмәккә.
Кама буйларында бау ишәләр,
Өмет баглап ага сулар да...
Мин дә кушылам: бишек бавы үрәм
Шигъри җанлы нарасыйларга.
Бугазымда авыр бер төер бар:
Калды инде фәкать сызларга...
«Бишек җыры»н көйләп, баулар үрик,
Өметсезгә ярдәм бавы сузыйк,
Бирмик аны шәфкатьсезләргә!

*1987*

# Җәяүле буранларда*

Җәяүле буранларда
Йөрим мин урамнарда.

Эзләр сүнәр,
Еллар күмәр
Без йөргән урамнарны...
Эзләр күчәр,
Кемнәр кичәр
Җәяүле буранарны?

Җәяүле буранларда
Йөрим мин урамнарда.

Серләр сөйлим,
Көйләр көйлим
Җәяүле буранларга.
Буран тынар,
Кемнәр чыгар
Без йөргән урамнарга?

Җәяүле буранларда
Йөрим мин урамнарда.

Чорлар кала,
Җырлар кала
Без йөргән урамнарда.
Кемнәр җырлар,
Кемнәр тыңлар
Җәяүле буранларда?
Чорлар кала,
Җырлар кала
Без йөргән урамнарда...

*1987*

* А.Монасыйпов музыкасы.

## Якташлар мәҗлесендә

Их, якташлар, килә, бик тә килә
Шундый бер халәткә күчәсе:
Стаканны тутырып, бергә утырып
Рәхәтләнеп килә эчәсе!
Их, эчәсе килә, эчәсе!
Зәңгәр күк гөмбәзе асларында
Үз-үземне онытып, исереп,
Үләннәргә егыласы килә,
Саф чакларны искә төшереп.
Шау яшьлегем ямансулап калган
Тау буена килә төшәсе,
Йөрәгемә чыңлап агып кергән
Чишмә суын килә эчәсе!
Стаканны тутырып, бергә утырып,
Их, эчәсе килә, эчәсе!

*1991*

* * *

Юл буена чыгып көтәр инде
Әнкәм сыман боек муел да:
«Ниләр генә булды бу балага,
Кайталмады,— диеп,— быел да...»
Башын иеп тып-тын басып торыр
Әткәм сыман сабыр карама:
«Кайтып килсә, дәва булыр иде
Сугышларда алган ярама».
Бәлки, башка кайта алмамын да...
Муел, карамалар үпкәләр...
Үзем кайталмасам, сүзем кайтыр,
Әткәм-әнкәм каберен иркәләр.
Өзгәләнгән еллар-яфракларым
Күмсәләр дә йөргән эземне,
Урамнарга сеңгән таныш моңнар
Хәтерләтер, бәлки, үземне...
Әткәм сыман сабыр карамага,
Әнкәм сыман боек муелга,
Зифа каенына Уралымның
Мин моң булып сөенеп уралырмын:
«Калам,— диеп,— Гәрә буенда...»

*1991*

## Бер кичәдә

Шәрабтандыр: бераз
Исердек...
Киң урамны искә
Төшердек.
Кочаклашып йөреп
Җырладык,
Киң урамнар юк дип
Тормадык.
Шашын әйдә, авыл
Баласы!
Таш калада ятып
Каласы...
Бездәй адашканнар
Азмы соң?
Үзең сайлап алган
Язмышың.
Агу-шәраб салып
Җаныңа,
Кайт әле бер авылың
Таңына!
Берөзлексез җырлар
Таштылар.
Урам урынына —
Таш дивар.
Җаныбызда — яшьлек
Давылы...
Киң күңелле, моңлы
Авылы.
Җырлау түгел, шашып
Кычкыру...
Бу язмыштан юктыр
Ычкыну...
Их!

*1991*

## Җырларым — шигырьләрем

Белмим дөньяда сездән дә
Изгерәк шөгыль барын,
Җырларым, шигырьләрем!

Бары сез генә белдегез
Хаклыкта шигем барын,
Җырларым, шигырьләрем!

Газапланган чакларымда
Хәсрәттән сыгылмадым,
Җырларым, шигырьләрем!

Гел-гел көйләргә омтылдым
Тормышның чыгырларын,
Җырларым, шигырьләрем!

Мусалардан соң да калган —
Хөр җанның чылбырларын,
Җырларым, шигырьләрем!

Түзә-түзә өзәрмен бер,
Сез барда — чигенмәмен,
Җырларым, шигырьләрем!

*1991*

## *Хуш, исән бул, Яңавылым!**

Мин бит синең кырларыңда
Тәгәрәп үскән бала,
Йөрәгемә суларыңның
Дулкыны күчкән бала.

Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала.
Бала чакта атлап киткән
Юлларым синдә кала.

Урамнарың, урманнарың
Шигырьләр сөйләп кала,
Өзелеп чыккан сүзләремне
Кошларым көйләп кала.

Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала.
Яшьлек сыман шаулап узган
Елларым синдә кала.

Яшьлек кала моңсуланып,
Чишмәдәй чыңлап кала,
Синдә туган көйләремне
Кырларым җырлап кала.

Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала.
Кошларыңа сердәш булсын,—
Җырларым синдә кала...

*1992*

* М.Имашев музыкасы.

## Нигә?

Бер карасаң, дөнья — нинди гүзәл, хозур!
Мәңге Кояш чыгар, балкып таңнар атар...
Ә нигә соң, нигә, ни өчен бу Җир
Тираннарга — иркен, шигъри җаннарга — тар?!
Нигә шулкадәрле хәсрәтле соң бу җыр?
Сандугачлы баглар читлек белән тулган...
Ә нигә соң, нигә, ни өчен бу Җир
Җәлладларга — сарай, шагыйрьләргә — зиндан?

*1991*

## Ачыш

Гел ашыктым, чаптым, кабаландым...
Сизмәдем дә синең барлыкны,
Бүген тойдым күкрәк читлегендә
Инде сиңа урын тарлыкны.
Танышларым нидер чамалыйдыр
Минем хәлсез, салмак адымнан.
Барлыгыңны искә төшерәсең,
Әллә инде туктау алдыннан...
Юк, туктама әле, йөрәк бәгырем,
Бу дөньяга әле кирәк бар!
Бәлки, үзе соңгы бер ачыштыр:
Күкрәгемдә минем йөрәк бар!

*1992*

## Зиратлар яныннан узганда...

Юк анда — шатлык та, нәфрәт тә,
рәхәт тә, хәсрәт тә.
Юк анда — тынлык та, тавыш та,
читләр дә, таныш та.
Юк анда кичерү, үтенеч,
ярлыкау, үкенеч.
Юк анда — вакыт та, тизлек тә,
бәхет тә, бәхетсезлек тә.
Юк анда — ширбәт тә, агу да,
хөрмәт тә, кагу да.
Юк анда — дуслар да, туган да,
ызан да, тузан да...

Дусларым, туганнар,
китәргә ашыкмыйк без анда...

*1992*

## Табиб дустым ядкәре

*Фән докторы Әсфат Абдуллин истәлегенә*

Чыныккан җан булгангадыр,
Күнеккән идең тәмам:
Кая барсаң — каршы алды,
Озатып калды Яман.
Күпмеләрне йолып алдың
Яман чир зәхмәтеннән,
Йөзеңдә нур балкыр иде
Исәннәр рәхмәтеннән.
Чигенергә мәҗбүр иттең
Куркыныч яман чирне,
Тик дәвалый алмадың шул
Шәфкатьсез яман чорны.
Син — илләрдә, син — телләрдә,
Дәрәҗә — зур, киң — күңел...
Йоклый алмый көндәшләрең:
«Ни өчен ул... мин түгел?»
Аларның хәйлә, мәкере
Үткәндер үзәгеңә.
Берәүгә дә сиздермичә,
Йөрәк ул түзә генә.
Кая барсаң ияреп йөргән
Көнчелек һәм хөсетлек...
Беркөнне без йөрәгеңнең
Ярылуын ишеттек.
Синең кебек изге затны
Инде кайлардан табыйк,
Күпләр гомерен озайткан
Кыска гомерле табиб?
Югалттык сине, авыр хис
Йөрәкне телә һаман.
Озак яшәргә ниятләп,
Озатып калды Яман...

*1992*

* * *

Сезнең якта табигать тә башка.
Бигерәк тә камил,
Юк, йокламыйк, күрми калабыз бит
Сихри төннең ямен.
Төннең сандугачын үкси-үкси
Тыңлыйсылар килә,
Шул кошларга кушылып елыйсылар,
Җырлыйсылар килә.
Сезнең якның сулары да талгын,
Суын ярга какмый,
Усал этләрегез ботны капмый,
Кортларыгыз чакмый.
Сезнең белән, җырлап, таңга каршы
Барасылар килә,
Шушы төндә җырлап, яшәп, үлеп
Каласылар килә.
Төнге урманнарга керәсе дә
Югаласы килә,
Серле Күккә ашып, Мәңгелеккә
Юл аласы килә.
Бала чакта мин бит Табигатькә
Гашыйк адәм идем...
Аһ, нигә соң ярты гомеремне
Йоклап әрәм иттем...
Саубуллашыйк, бу дөньяда, бәлки,
Очрашмабыз тиздән.
Кәккүкләргә кушылып юрыйм мин дә:
Озын гомер — бездән!

*1992*

* * *

Нигә минем баш очымнан
Узып бара бу болыт,
Каян килә, кая бара
Кызыл-кара бу болыт?
Кемнәр миңа хәбәр бирә
Сискәндереп, чаң булып,
Дөньядан шәһит киткәннәр
Йөри мәллә җан булып?
Ник килә бу кызыл болыт,
Карасына тагылып,
Яумас микән безнең башка
Кызыл-кара кар булып?
Караңгы көн, шомлы болыт,
Уем китте кагылып,
Кая барыр, кайда явар
Кызыл-кара бу болыт?..

*1993*

* * *

Фәрештәләр китте ике иңемнән,
Карлы-бозлы болыт килә Иделдән.
Күңелемдә — көпә-көндез — кара төн.
Шайтан җәйде ике кара канатын.
Йөрәгемнең ямаулары ертылды.
Әллә кая очты илһам... җыр тынды.
Башны авыр күтәрүе — Җир тарта,
Әллә язмыш, әллә инде гүр тарта.
Ярдәм сорап Күккә карар әмәл юк.
Салкын дөньям, җылы җилдән сәлам юк.
Һәр адымда һәр танышым ят сыман,
Якын иткән дусларымнан ятсынам.
Яшәвемнән гарьләнәм һәм оялам...
Аңласаң, тик син аңларсың, и Аллам!
Кире төшсен фәрештәләр яныма,
Бир сабырлык, бир җылылык җаныма!..

*1993*

* * *

Ычкынырмын акылдан дип,
Уйланудан куркам,
Газапланып йоклап китсәм,
Уянудан куркам.
Соңгы сулышымдыр, бәлки...
Тын алудан куркам,
Вөҗданым керсез булса да,
Сыналудан куркам.
Хәерлегә булмас бу, дип
Куанудан куркам,
Шырпы уты күргәндә дә,
Гел янудан куркам.
Мактап тәмам исертүдән —
Сыйланудан куркам,
Нахак сүзләр ишетүдән —
Кыйналудан куркам.
Дөреслектән читкә таба
Юл алудан куркам,
Аклау өчен сәбәп табып,
Юанудан куркам.
Куркуымнан курыкмыйм һич,—
Кылanудан куркам,
Үз юлымнан каерылып
Югалудан куркам...

*1993*

## Яшик әле...

*Фасил Әхмәткә*

Яшьлек елларыбыз — җан өшеткеч:
Җайсыз-көйсез иде,
Беребезнең — кияр киеме юк,
Беребез — өйсез иде.
Язмыш безнең баштан сыйпамады,
Үзе күргән — аңлар.
Гарипләнде — тәннәр, сүнде — шәмнәр,
Исән калды җаннар.
Җанны эшкә кушып, тешне кысып,
Горур атлап киттек,
Берәүне дә өйле итәлмәдек,
Әмма көйле иттек.
Һәр мәҗлестә аек булмасак та,
Аек булдык — җырда.
Шаккатырлык эшләр кылмасак та,
Лаек булдык чорга!
Бер көй тапкан кебек җиде нота:
До-ре-ми-фа-соль-ля-си...
Сирәк-мирәк тостлар тота-тота,
Тормыш агуларын йота-йота,
Илдар, Фасил яши.
Кайберәүләр, бәлки, «месkeннәр...» дип,
Көләләрдер бездән.
Без рух белән, дустым, көчлерәк бит
Хәтта үзебездән!
Яшик әле тормыш агуларын
Шактый киметкәнче,
Йөрәк — телгәләнеп, үзәк — өзгәләнеп,
Җанда — көй беткәнче!

*1993*

* * *

Бәла-каза арттан ияреп йөри,
Кайчак көтеп тора алда ук...
Гомер буе мин яшәгән булдым
Бәхет килер диеп алданып...
Гел ышанып, гел алданып яшәү
Газапларны бераз киметкән.
Шул чорымны кайчак сагынып куям...
Тик үзем дә белмим... нилектән?
Хәсрәтләрем бераз кимер иде
Үзем генә булсам бәхетсез,
Ничә гасыр буе көрәшеп тә
Милләттәшләр һаман тәхетсез.
Ышанмыйм да инде, алданмыйм да...
Газапларым шуңа артадыр,
Бабамнарның ватык тәхетләре
Аның саен ныграк тартадыр...

*1994*

* * *

Тормыш бит ул — боксер,
Гел йөрәккә суга.
Борчылма ла, тәкъсир,
Ул авырта шуңа.
Салкын боздай туңа
Яки яна утта.
Егылырмын бары
Соңгы нокаутта.

* * *

Әйтә алмыйм гомеремнең
Ничә елы, ае барын.
Тегендә дә сагынырмын
Казансуның каеннарын.
Кәккүкләр дә юрый алмас
Ничә көзем, язым барын.
Рәхәтләнеп суладым бер
Наратларның озоннарын.
Читкә кактым иблисләрнең
Котыртуын, азуларын,
Гомеремне озайткандыр
Илһам белән язуларым.
Әйтмәссезме: «Каен, нарат...
Кабат-кабат яза шуны...»
Мөмкин түгел ташлап китү
Бу дөньяны, Казансуны...

*1994, Крутушка*

* * *

Үзәк өзгеч моңлы тавыш
Кошларның эзләрендә,
Ниндидер бер зарлы сагыш
Атларның күзләрендә.
Кошлар, монда тусалар да,
Туган җир итәлмиләр,
Атлар, елап торсалар да,
Кошлар күк китәлмиләр.
Кошлар ничек яши түзеп?
Атлар нигә эшлиләр,
Кошларның үзәген өзеп,
Күк күкрәтеп кешниләр?..

* * *

Озак яшәгән шагыйрьнең
Шомара осталыгы,
Тарта уйның тирәнлеге,
Сүзенең кыскалыгы.
Әйтмә ләкин: «Күп яшәдем,
Шуңа күрә оста»,— дип.
Тукай, Бабич осталарның
Гомере дә кыска бит...

* * *

Гомерне булмый озайтып
Миллион алтын түләп...
Сөен, яшә рәхмәт әйтеп,
Һәрбер көнең — бер бүләк!

* * *

Бирәү — байый.
Миллион — бөлә.
Миллион — елый,
Бирәү — көлә...

*1995*

* * *

Гомеремдә күпме буш сүз
Сөйләнеп, җилгә очкан.
Бик-бик азы, орлык булып,
Шытарлык җиргә төшкән.
Авызда ботка пешермә,
Сөйләмә, телем. Тукта...
Бер бөртектән, өч бөртектән
Пешереп булмый ботка...

*1995*

* * *

*Хәсән Туфанга*

Син бит тыңлый белә идең,—
Сөйгәнне, сөймәгәнне...
Күңелеңә җыя идең
Башкалар сөйләгәнне.
Әллә тел, әллә гадәтне
Һаман да тыя алмыйм:
Сөйлим дә сөйлим, сүзләргә
Һич нокта куя алмыйм.
Тыңлау осталыгы белән
Үзеңә карат икән.
Башкаларны тыңлый белү —
Үзе бер талант икән...

*1995*

## Яши-яши аңладым...

Кеше — кодрәтле көч,
Кеше — Алла — тиңсез.
Юк, мин китмәм Җирдән,—
Дөнья нишләр минсез?

*И.Юзеев, 1965*

Ул чактагы наданлыкны
Яши-яши аңладым:
Омтылса да, берәүнең дә
Алла була алмавын.
И Илаһым кодрәтеңдә —
Галәмең, Җирең, Күгең...
Кеше — даһи да булала,
Син — даһи гына түгел.
Карап торам рәсемемә —
Яшь, дуамал җүнсезгә:
Дөнья минсез дә яшәгән,
Дөнья яшәр минсез дә...

*1995*

## Бер җырчыга

Чын җырчыга караганда
Сәхнәгә ул еш чыга,
Табигатьтән бирелмәгән
Иләмсез тавыш чыга.
Кайчагында бераз гына
Охшап куя җырчыга.
Әйе шул, чынлап еласа,
Сукыр күздән яшь чыга...

*1995*

## Син китсәң...

Кыналарың, сөмбелләрең
Коеналар су сипкәч,
Чәчәкләнгән ал гөлләрең
Боегалар син киткәч.

Алар синең үзең кебек
Тоелалар су сипкәч,
Яфраклары, саргаешып,
Коелалар син киткәч.

Көләч җылы карашыңны
Сизелерлек киметсәң,
Корырмын да, сулырмын да,
Бөтенләйгә син китсәң...

*1995*

## БАГЫШЛАУЛАР

* * *

*Нәфис сүз остасы Айрат Арсланга*

Йә кил әле, Айрат, минем янга,
Сүзсез генә бергә утырыйк,
Дөнья мәшәкатен онытыйк та,
Эчтән шигырь укып, тын торыйк.
Якташлык та, әз-мәз Такташлык та,
Тукайлык та бераз бар бездә.
Омтылыш та аларныкы кебек,
Сулыш юллары да тар бездә.
Күпме чыктың инде сәхнәләргә,
Халкың өчен янып, пошынып,
Сулыш юлларыбыз кебек, һаман
Милләтебез яши кысылып.
Олпат тавышыңны тыңлаганда,
Мин дә горурланып куямын,
Тукай, Такташ, Җәлил сулышының
Дәвамнарын синдә тоямын.
Кызыкмадык дөнья малларына,
Сәнгать, диеп гомер кыскарттык,
Ялган йолдыз булып саналганчы,
Күңелләргә керү — мең артык!
Юк,
Син — татарның Левитаны түгел,
Нәкъ безнеңчә милли Айраты,
Синдә — халкыбызның затлылыгы,
Нәфислеге, өмет, гайрәте.
Яндык, туңдык, көйдек сәнгать өчен,
Кызганмадык йөрәк җылысын,
Яшик әле, Айрат, яшик әле
Озынайтып милләт сулышын!

*1995*

# Дусларга таян, йөрәк!

*Рафаэль Сафинга*

Син миннән дә өлкәнерәк,
Акылга тирәнерәк,
Түземлеккә, сабырлыкка
Сафиннан өйрән, йөрәк!
Син миннән дә уйчанырак,
Миннән дә җитдиерәк.
Рафаэльдән үрнәк ал да,
Шаярма, җитте, йөрәк!
Син миннән дә гыйлемлерәк,
Мин артык шаянырак.
Авыр чакта Сафин кебек
Дусларга таян, йөрәк!
Мин дә бераз Сафин кебек,
Әмма син сафинырак.
Синдәй дуслар бик-бик кирәк,
Гел яшә, асыл йөрәк!

*1992*

## *Ялгышасың, Атнабай...*

*Әнгам Атнабаевка*

Уйлыйсыңдыр: «Казан минем
Ядкәремне сакламай...»
Кызлар сине онытмыйлар,
Ялгышасың, Атнабай!
Уйлыйсыңдыр: «Казан минем
Шигырьләрне ятламай...»
Бу уең да дөрес түгел,
Ялгышасың, Атнабай!
Уйлыйсыңдыр: «Пьесаларым
Сәхнәләргә атламай...»
Иң зур хатаң шушы синең,
Ялгышасың, Атнабай!
Уйлыйсыңдыр: «Казан сөйли,
Җырымны кабатламай...»
Бу — хатаңның иң олысы,
Ялгышасың, Атнабай!
Мондый олы ялгышулар
Зур шагыйрьне акламай,
Ялгышыңны төзәтергә
Вакыт инде, Атнабай!
Тамашачы һәм укучы
Ялгышыңны якламай,
Казанның да үз шагыйре,
Җырчысы син, Атнабай!
Казан да бүген шагыйрен
Түзәлми кочакламай:
Шигырьләрең — күңелгә май,
Пьесаларың — сәхнәгә җай,
Афәрин, и Атнабай!

*1988*

## *Кистеләр...*

25 август, 1944 ел — фашист җәлладлары Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең башын кистеләр.

25 август, 1935 ел — Олы Мәрәтхуҗа авылында күренекле драматург Туфан Миңнуллин туды.

Гел кистеләр безне, гел кистеләр:
Шәхси бакчаларны кистеләр,
Күкрәк көче белән эшләп тапкан
Хәләл акчаларны кистеләр.
Деннән, иманыннан язсын, диеп,
Мәчет манарасын кистеләр,
Бабаларның, ана-балаларның
Чылбыр-шәҗәрәсен кистеләр.
Идел-йортның түрләренә элгән
Сабый бишекләрен кистеләр.
«Сагынам туган илкәйне...» дип,
Моңаешып яшьләр үстеләр.
Гел кистеләр безне, гел кистеләр,
Мәктәпләрдә телне кистеләр,
Мулла бабайларның каберенә
Салыначак гөлне кистеләр.
Гел кистеләр безне, гел кистеләр;
Фән-белемгә юлны кистеләр,
Ерак илләрдәге милләттәшкә
Сузыласы кулны кистеләр.
Гел кистеләр безне, гел кистеләр:
Бабайлардан безгә күчтеләр,
Сибелсеннәр, таралсыннар, диеп,
Җандай илне-җирне кистеләр.
Уйламасын, җырламасын, диеп,
Төрмәләрдә башны кистеләр,
Болгар бабайларның нигезендә
Яткан изге ташны кистеләр.
Замананың бәла-казалары
Хәзер безнең башка күчтеләр...
Нигә, дустым, тирән уйга калдың?
«Гел кистеләр безне, кистеләр...»
Без һаман да исән, баш югары!
«Гел кистеләр безне, кистеләр!»

Уй да биек, буй да биек безнең,
Эштә — көчле, җырда — хислеләр,
Әлмәндәр һәм Туфан төслеләр!
Баш югары: уй һәм буй җитмәслек!
Гел кистеләр безне, кистеләр...

*1995*

## Картлык килсә...

*Ләбибә Ихсановага*

Иҗат тылсымнары синдә:
Син ана да, бәби дә,
Миллион балаларның дусты,
Әнкәсе син, Ләбибә!
Тәнең һәм рухың сәламәт,
Нәселең, мөгаен, нык.
Яшеренми тышка чыга
Җаныңнан мөлаемлык.
Бәбиләр дә, әбиләр дә
Ләбибә кебек булсын:
Тыйнак, сабыр, ихлас, горур —
Мировой егет булсын!
Картлык килсә: «Моны,— диеп,—
Әйләндерим әбигә»,
Язып куй син ишегеңә:
«Өйдә юк шул Ләбибә...»
Әйдәгез әле, сүз бирмик,
Картлык бүген дәшмәсен:
Әбиләрне дә яшәртеп,
Ләбибәләр яшәсен!

*1983*

# Коткар безне, Ахун!

*Гариф Ахуновка*

Тормышында иң югары нокта
Менә бүген — хәзер башлана.
Китә күрмә, зинһар, ахунлыктан,
Ярдәмеңнән безне ташлама!
Безне оялтырлык, кызартырлык
Юк шул инде Туфан, Хәкимнәр.
Указлы да булдың, вәгазь әйтеп,
Безне үгетләргә хакың бар.
Сәйдәш булып һәм Тинчурин булып,
Иңбашыңа кунган фәрештә.
Мин фәрештә була алдым, ахры,
Иҗат дигән бары бер эштә.
Без — йөгәнсез союз балаларын —
Туры юлга кертү юлында
Шайтаннарга каршы көрәштең син:
Гел-гел китап булды кулыңда.
Кайчак фәрештәләр кул селтәде,
Шайтан килеп юлдан яздырды.
Яшьрәк чибәрләргә алып китте,
Хәмер биреп кайчак аздырды.
Безне адәм иткән оешмага
«Долой союз!» диеп акырдык...
Шайтан килеп керсә, куган булдык,
Чыгып китсә, үзебез чакырдык.
Ахуныбыз безнең, хәзрәтебез,
Без гөнаһлы, әйтче, нишләргә?
Башкалар юк... мәҗбүр булырсыңдыр
Безнең белән генә эшләргә.
Хәзер дә мин бераз гына аек...
Өйгә тагын туры кайталмам.
Ахуныбыз безнең, фәрештәбез,
Коткар безне, коткар шайтаннан!

*1995*

## Генералның туган көнендә

*Гайнулла Шакировка*

Җитмеш яшькә бездән алда җиттең,
Син һаман да алда, гел алда,
«Минем арттан йөзгә җитәргә!» — дип,
Бир, генерал, безгә команда!
Их, кызганыч, хәмер эчә алмыйм,
Рәхәтләнеп тотам минерал,
Пенсионер солдатларың һаман
Синең сафта атлый, генерал!
Генералның дусты бик күп булмый.
Сиңа карап моңсу көрсенәм...
Сәлам сиңа сугыша белми торган
Солдат дусларыңның берсеннән.
Синең кебек ихлас дуслар белән
Җиңел алынадыр сулыш та.
Синең кебек генераллар булса,
Бетәр иде, бәлки, сугыш та.
Синең белән дөнья мәгънәлерәк,
Яшәмәдек гамьсез бушлыкта.
Исбат иттең бар гомерең белән:
«Бу тормышның яме — дуслыкта!»
Калган гомерне дә бергә узыйк,
Тик шул гына җанга бирер ял.
Еллар авыр, әмма синең белән
Атлаулары җиңел, генерал!
Тутырыгыз әле бокалларны,
Булса булсын, әйдә, минерал,
Честь бирмичә генә кочакларга
Рөхсәт итче, иптәш генерал!

*1995*

* * *

*Нәҗип Асанбайга*

Башкорт дуслар иллә дә бай инде:
Бикбай, Кулибай һәм Атнабай...
Син үзеңчә бик бай, беркем белән
Бутап булмай сине, Асанбай!
Синең иҗат белән Өфе яшәй,
Әсәрләрең белән Казан бай.
Кризислар сиңа һич кагылмай,
Син, Асанбай, гел-гел һаман бай.
Синең яшьтә гәүдә бик төз йөрмәй,
Беркем шулай туры басалмай.
Син — егерме яшьлек дүрт егеттәй,
Яшьлеккә дә бай син, Асанбай!

*2002*

# Кичке урам нигә тып-тын?

*Җырчы Фән Вәлиәхмәткә*

Ишек алларына чыгып,
Гармуным уйныйм әле,
Җырлап калган яшьлегемә
Кайтырга уйлыйм әле.
Авылымда, без яшь чакта,
Һәр кеше җырчы иде...
Абзыегыз тирә-якта
Иң шәп гармунчы иде.
Кичке урам нигә тып-тын?
Җырлап-биеп чыгыгыз!
Ник йоклыйсыз, уянмыйсыз?
Кайтты ич гармунчыгыз!
Ниләр булды, күңелем тулды
Очрашу шатлыгыннан.
Ничекләр итеп уятыйм
Авылымны картлыгыннан?..

*1996*

# Матурлык илчесе

«Аллаһе Тәгаләгә якынайган
саен яшен көчәя...»

*Рифкать Исрафилов*

Якыная барган саен
Аллаһе Тәгаләгә,
Сыналулар һәм сынаулар
Гел арта бара аңа.
Бирешмичә бу Җирдәге
Ваклыкка һәм Тарлыкка
Яшенле күкрәүләр аша
Бара ерак Хаклыкка.
«Коткар Матурлыкны!» диеп,
Замана ашыктыра,
Давылларда егылмыйча,
Тауларда басып тора.
Сабырлыгын, түземлеген
Үзәгенә яшергән.
Көчләр ала, хисләр ала
Күкрәүләрдән, яшеннән.
Беләбез ич, үз гомере
Берничә драмалы.
Баш имәде, язмышыннан
Мәрхәмәт сорамады.
Болай карап торышка ул —
Гади генә бер кеше.
Ә үзе бит — Матурлыкның
Илаһи бер илчесе!

*2001*

# Кем дисәгез...

*Равил Тумашевка*

Синдәй мәртәбәле режиссерлар
Бу дөньяга бик еш тумастыр,
Әнкәсенең изге һөнәренә
Тугры калган Равил Тумаштыр.
Шушы яшендә дә картаймыйча,
Япь-яшь калган башка булмастыр.
Егетләрчә атлап кем ул килә?
Соң... кем булсын? Равил Тумаштыр.
Яшьләрне дә әле яшәртергә,
Өйрәтергә йөри ул мастер.
Театрны, янып, яшәртүче,
Яшәтүче Равил Тумаштыр!
Өлкәннәргә авыр сүз әйтсәгез,
Зиһене таралмыйча тормастыр...
Театрны җыйган, таратмаган
Кем дисәгез — Равил Тумаштыр!

*1991*

# Үз тургаегыз

*Гарифҗан Мөхәммәтшинга*

Җирдән китәм-китәм дигән кебек,
Канат каккан сабан тургаен
Үзегезнең кырдан җибәрмичә,
Саклап калгансыздыр, мөгаен.
Без һәммәбез киттек калаларга,
Җирсез саргаештык бугай без.
Урманыгыз моңлы, кырларыгыз — җырлы,—
Үз җырыгыз, үз тургаегыз.
Сайраулары язда гына түгел,
Үзе туган алтын көздә дә
Ишетелә — шәһри Казандагы
Җирсез тургайларга — безгә дә...

*2001*

## Җәйгә кайту

*Якташым Рәзиләгә*

— Җылы җәйне көтеп туңдым әле,
Тәмам диваналар булдым әле.
Туган якның назлы гөлен сагынып,
Язга кадәр мин дә сулдым әле.
— Белдем, абыкаем, сиздем әле,
Җәен мәтрүшкәләр өздем әле.
Туган якның бөтен җылылыгын,
Бар дәвасын алып килдем әле.
— Көйлим: кайтам инде, кайтам инде,
Үз җырымны җырлап ятам инде.
«Мәтрүшкәләр» көен дару итеп,
Мин кышын да чәчәк атам инде!

*2002*

# Җыр дәүләтенең ханы

Илһам Шакировның туган көнендә

Сәлам сиңа, Илһам, ерак-ераклардан,
Яшьлек канат каккан чаклардан.
«Таныш моңнар», «Яшь наратлар» булып,
«Янар чәчәк» аткан чаклардан.
Җыруларың «Карурман»лы чордан
Сәлам җиле булып исәләр,
Болгар дәүләтендә тәхеттәге
Илһам ханнар искә төшәләр.
Даһи табигать тудырган
Гасырлар илһамы син,
Җыр дәүләтенең ханы син,
Халкыбызның җаны син.
Татар гел җырлап яшәде,
Алла бирсә, гел яшәр!
Җырда Илһамнар хан булса,
Җирдә ханнар Илһам булса,
Моң яшәр һәм мең яшәр!

*15 февраль, 2001*

## *Кылы өзелгәннәр көтә шуны...*

*Мирсәет Яруллинга*

Бик тә уйчан әле син бу юлы,
Йөзең сагыш, борчу белән тулы.
Өзелдеме әллә күңелеңнең
Ике йөздән — берәр нечкә кылы?
Сизәм: көннәреңнең көйсез чоры,
Клавишлар белән бүлмәң тулы.
Ватык рояль алда: төзәт шуны:
Ике йөздән артык нечкә кылы...
Бу — тормышның теткәләнгән чоры,
Күпме күрдек ору һәм ватуны.
Ватучылар белән дөнья тулы,
Күпме җаннар көтә юатуны...
Атаң рәсеме бизи диварыңны,
Өстәлендә — Фәрит абыең сыны.
Йөрәгеңә һич тә бирми тынгы
Абый көен өзгән сугыш кыры.
Көйсез әле клавишлар чыңы.
Мәшәкать — вак, ниятләрең — олы.
Басмакларда гүя абыең кулы,
Моң остасы Заһидулла улы.
Рояль — телсез, чыкмый өне — тыны,
Дөнья — ватык рояль, җый син шуны.
Төзәтәсен тели күңелеңнең
Ике йөздән артык нечкә кылы.
Клавишларда — абыеңның кулы
Һәм этиең Заһидулла кулы.
Кылы өзелгәннәр көтә шуны:
Рояль телгә килер, чыгар моңы,
Нык ышанып мин дә көтәм моны,
Мирсәет дус Заһидулла улы!..

*1998*

# Җирнең үзе кебек...

*Миргазиян Юныска*

Сынчы булмасам да, мин үземне
Бераз рәссам итеп тоямын.
Сурәтеңне агач, таштан түгел,
Шигъриятле сүздән коямын.
Болай караганда, гади бер зат:
Миргазиян гына нибары.
Үз-үзеңә бәя бирәлмисең.
Син — үзең бер дөнья — Җир шары!
Хыялларың — бер карасаң — Күкләр,
Бер карасаң — диңгез төсендә.
Бер күзеңдә — зәңгәр кара урман,
Ат шәүләсе — икенчесендә.
Йөзләреңдә тирән уелып калган
Үзең узган юллар — буразна.
Хыялыңа ирештең бит инде.
Йә, тынычлан инде беразга...
Туган илгә озак кайтмый торгач,
Таныш йөзләр ятка әйләнгән.
Атлар сабантуйның бизәгенә,
Ә кешеләр — атка әйләнгән.
Ат сагынып кайттың дөнья урап,
Карурманлы туган яклар дип.
Качып җырлыйм дисәң — карурман юк,
Кочып елыйм дисәң — атлар юк.
Җирдә, Күктә, Суда буразналар
Булып калды сызган эзләрең.
Сөйләү өчен диңгез төпләренә
Төшеп энҗе сүзләр эзләдең.
Җирнең үзе кебек, син серле дә,
Катлаулы да, кырыс, юаш та.
Иң яраткан бер юлдашы итеп,
Сөеп карый сине Кояш та.
Җирнең үзе кебек, карт та, яшь тә...
Алда гомерең — йөз-мең хыяллык.
Үз сыннарың белән үзеңне дә
Күргәзмәгә илтеп куярлык!

*2000*

# Тупчы Мәхмүт

*Мәхмүт Хөсәенгә*

Бер карыймын: син — абый,
Бер карыймын: син — сабый,
Бер карыймын: син — бабай,
Бер карыймын: син — малай,
Бер карыймын: син — акын,
Сәсәннәргә бик якын.
Запастагы артиллерист,
Һаман да туп атасың,
Дошманны да, дусларны да
Үзеңә каратасың,
Шушы яшеңә җиткәч тә,
Кызларны яратасың.
Юбилейный мактауларны
Шул урында туктатам,
Артиллерист булмасам да,
Бакчаңа бер туп атам:
Син ярату гына җитми,
Кызлар сине сөйсеннәр,
Йөз яшьтә дә япь-яшь кызлар
«Мәхмүт җаным!» дисеннәр.
Хуплар идек Такташ белән бергә
Ярым ачык калган ишектән
Бер кызыйның:
«Мәхмүт бәгърем, җибәр!..» —
Дигән тавышын да ишетсәк...

*1983*

## *СЕЗ ЮКЛЫКНЫ ТОЯМ...*

## МӘРСИЯЛӘР

### *Мәңгегә ак булып, пакь булып...*

*Хәсән Туфан ядкәре*

Тыялмай сагыну хисләрен
Җырлыйлар картлары-яшьләре:
Моңайта Казанның кичләрен
Туфанның кадерле ядкәре.
Онтылмый, ягымлы рәсемең
Җанланып җаннарда саклана,
Рәсмеңне күрсәк тә, үзеңне
Күргәндәй күңелләр сафлана.
Нәкъ үзең шикелле, җырыңнан
Сибелә мөлаем яктылык,
Калдың син, ромашка шикелле,
Мәңгегә ак булып, пакь булып.
Әле дә сибелә җилләрдә
Кылгандай сабыр, чал чәчләре...
Җыр булып тирбәлә илләрдә
Туфанның кадерле ядкәре.

*1982*

## Шагыйрьләр яткан изге урында

*Сибгат Хәким ядкәре*

Тәннәрдә кала, җаннарда кала
Синең сабырлык, синең җылылык,
Гел сагындырыр әтидәй караш,
Олуг тыйнаклык, гади олылык.
Әйткән идең бер: «Тәнем суынгач,
Китәрмен инде туган ягыма...»
Туган ягыңдай кадерле җиргә —
Киттең син Тукай, Туфан янына.
Тыныч бул, остаз, син киткән тараф,
Юнәлгән ягың — җыр юлы булыр,
Шагыйрьләр яткан изге урында
Туфрак та йомшак һәм җылы булыр...

*1986*

## Уян, Мәхмүт, уян...

*Мәхмүт Хөсәен ядкәре*

Җиде төн уртасы.
Кемдер чылтырата:
«Кайсы шагыйрь анда
Төнен йоклап ята?!
Кара тәрәзәдән:
Нәкъ шагыйрьләр төне!
Шигырь сөйлим. Тыңла...
Их, син белсәң иде!..»
«Тукта инде, Мәхмүт,
Бик тә йокым килә...»
Үпкәләми-нитми —
Трубкасын элә.
...Йоклый алмыйм. Аһ, төн!
Нәкъ шагыйрьләр төне!
Телефонга барам —
Йокламасын иде!
Теге төннәр өчен
Оят миңа, оят...
Йоклап ятканнарны
Уят, Мәхмүт, уят!
Нигә номер җыям?
Син юклыкны тоям.
Тып-тын мәңгелектән
Уян, Мәхмүт, уян...

*1995*

# Күңелләрдән китмәс инде...

*Салих Баттал ядкәре*

Халкыбызның олпат ире идең син,
Шигъриятнең баһадиры идең син.
Яманлыкка самолеттан төкердең,
Җирне сагынып парашюттан сикердең.
Курку белмәс Баттал дигән ат алдың,
Җәлилчесе иде монда татарның.
Яклатмадың, саклатмадың беркемнән,
Үзең бер көч, читтә йөрдең төркемнән.
Син саклаган туган илдән — мәрсия,
Син яклаган туган телдән — мәрсия,
Син сатмаган бар дуслардан — мәрсия,
Үзең очкан канатлардан — мәрсия,
Үзең очкан талантлардан — мәрсия,
Арабызда юк тиңдәшең, юк синең...
Күңелләрдән китмәс инде юксыну...

*1995*

## Калдың чишмә юлында...

*Эдуард Касыймов ядкәре*

Ике чиләк булган ике
Кулыңда.
Кайталмыйча калдың чишмә
Юлында.
Тулар-тулмас кына ике
Чиләгең.
Әмма әйтеп киттең иң-иң
Кирәген.
Бераз гына ялгышканбыз
Без элек.
Гомер буе кылгансың ич
Игелек!
Кемнәргәдер, бәлки, рәнҗү
Тугандыр,
Күңелең дә мөлдерәмә
Тулгандыр.
Калды синнән чишмә юлы,
Пар чиләк.
Балаларың йөри сине
Каршылап.
Әйдәгез, бер искә алып
Утырыйк.
Тулмый калган чиләкләрне
Тутырыйк.
Кайтыйк әле су юлларын
Бер урап.
Сүзе чыгар чишмә кебек
Чылтырап.

*1995*

# Яза алмый каләм...

*Кадыйр Сибгат ядкәре*

Фатиханы бездән
Алган идең, Кадыйр.
Язган идем шулчак:
«Туды,— диеп,— Шагыйрь!»
Исән чакта шагыйрь
Күрә алмый кадер:
Син үзең дә моны
Белә идең, Кадыйр.
Юк, исемең белән
Рифмалашмый «кабер»,
Җирдә җылың калыр,
Кырыс җырың калыр.
Сөйми идең төче,
Купшы сүзне, Кадыйр,
Ишетмисең хәзер
Шушы сүзне, Кадыйр.
Заман гел-гел шулай:
Күреп киттең, Кадыйр:
Үзебездән соң да
Булмас, ахры, кадер.
Төгәл рифма эзлим.
Ничек табыйм, Кадыйр?
Синең белән бары
Рифмалаша Шагыйрь.
Фатиханы бездән
Алган идең, Кадыйр.
Яза алмый каләм:
«Китте,— диеп,— шагыйрь...»

*1995*

## Акчарлак

*Рәшит Әхмәтҗан ядкәре*

Кораб китте. Тыныч йөзәр чак инде:
Гарасат юк. Җылы җилләр исәләр.
Сез әйтегез, мин ышанам: шагыйрьне
Акчарлакка әверелгән, дисәләр.
Азык эзләп очмады ул,ирекне
Алып булмый ач торып та, елап та...
Канатлары иңли инде киңлекне,
Авазлары бик якын да, ерак та...
Кораб китте. Бәлки, көтәр упкын да.
Бәлки, кемдер исән калыр... Ул кайтмас...
Бераз гына хәл алыр да дулкында
Очар һаман, кыйбласын югалтмас...

*1995*

# Безне кемнәр юксыныр?..

*Шәйхи Маннур ядкәре*

Тагын килдем әле, Шәйхи абый,
Туган Тулбаеңа.
Төнен озак-озак карап тордым
Күккә, тын Аеңа.
Күңел тулгангадыр, Тулбай ае
Хәтерләтә сине...
Синең йөзең дә бит үзе кырыс,
Үзе тулы иде.
«Ул да миңа карый иде» диеп,
Әйткән кебек ул Ай...
Без дә бер китәрбез бу дөньядан.
Шәйхи абый, шулай.
Мәңге-мәңге Күктә тын Ай йөзәр,
Агымсулар агар.
Безне сагынып һәм юксынып кемнәр
Тулган Айга карар?..

*1985*

# Син Казанда бүген, дусларыңда...

*Саҗидә Сөләйманова ядкәре*

Казандагы җан дусларың белән
Бергә яшәү иде хыялың.
Ярдәм итәлмәдек, безгә күчкән
Рәсемеңә чәчәк куямын.
«Син үлеп аңлатмагач»ны һаман,
Һәр көн кабатлыйбыз, беләбез.
Күчәр өчен фатир бирмәгәннәр —
Хәзер сиңа урам бирәбез.
Кичер инде безне, Саҗидәкәй,
Сине аңламауга түз дә — кал,
Урамыңда бергә яшик әле,
Рәнҗеп китә күрмә, бездә кал.
Күзләребез үкенечләр белән
Ядкәр рәсемеңә текәлгән.
Сине сөйгән һәрбер казанлының
Йөрәгенә син бит теркәлгән.
Урамыңа соңлап хатлар килер,
Күпләр эзләр җырың эзеннән.
Сагынычлы, юксынулы хатлар...
Җавап кына килмәс үзеңнән.
Син Казанда бүген, дусларыңда:
Хыялыңны җырда сакладың,
Сине исән тойган һәр күңелгә
Килә синең шигырь-хатларың,
Килеп торыр шигырь-хатларың...

*1 март, 1997*

## Маннурның дусларына язган васыяте

Минем уйны, хисне, омтылышны
Аңлар диеп уйлыйм күбегез,
Үлгәч, мине туган авылыма —
Тулбаема илтеп күмегез.
Авылдашлар сезгә ярдәм итәр:
Әнкәм яткан җирне табыгыз,
Өсләремә йомшак юрган итеп,
Туган туфрагымны ябыгыз.
Өлкәнәйгән саен чишмәләрнең
Челтерәүләре үзенә тарттылар,
Актык сулышымда юллар мине
Тагын сиңа алып кайттылар.
Гәүдәм калсын туган җиркәемдә:
Казан аңлар диеп беләм мин.
Бөтенләйгә, китмәскә дип кайттым,
Авылдашлар, сезнең белән мин...

*1980*

* * *

*Сонет*

Көтмәгәндә генә килде ул яз,
Кырларда да карлар аз иде.
Мәхәббәтем — кояш, күңел — аяз,
Ташып килгән иртә яз иде.

Әмма ул яз үкенечле булды:
Җылыдан соң салкын китерде.
Аерылдык, җаннарыбыз туңды,
Кырлардагы умҗым шикелле.

Күпме еллар килде язлар алып,
Күпме ташу кайтты ярына.
Күңел оча һаман канатланып
Тәүге мәхәббәте янына.

Чын мәхәббәт — иртә йә соңмы —
Сафландыра җанны — суынмый.

*1995*

* * *

Ахры, мин дә сезнең нәселдәндер,
Шуңа бигрәк якын итәмдер.
Көзен өзгәләнәм, саргаямын.
Таш өстендә үскән юкә мин.
Сездән аерса тик аерадыр
Боек йөзем, язгы ютәлем.
Кыршау миңа — өйнең дүрт дивары:
Таш өстендә үскән юкә мин.
Мин бит адәм, нигә бу җанымны
Табигатьтән мәхрүм иткәнмен?..
Башларыннан сыйпыйм, хәлен аңлап
Таш өстендә үскән юкәнең.
Әнкә-табигатьтән аерылган
Ятим бала сыман үтәмен.
Авыр кагылмагыз... Кызганмагыз!
Таш өстендә үскән юкә мин!

*1995*

## Тол ханымга бер теләк

Өермәләр юлың бүлде,
Егылмадың, афәрин!
Тол булсаң да, язмышыңа
Кол булмадың, афәрин!
Югыйсә бит нәни генә,
Нечкә җанлы бер ханым...
Йөзендә — болыт шәүләсе,
Хәлләрең ничек, җаным?
Нигәдер күзләрең дымлы.
Карашың җылы да соң...
Сөембикә язмышына
Юлларың борылмасын.
Болай тыштан караганда
Чәчәк атсаң да күкрәп,
Сизәм: җитми, башың куеп,
Үксерлек көчле күкрәк.
Тиң ярыңны эзләп табып,
Егылсаң да, афәрин!
Үзең теләп асыл ярга
Кол булсаң да, афәрин!

*1996*

## Кара каен

Каян килдең, кара каен?
Үзең әле бала каен.
Күчте мәллә кара кайгың?
Сызлый мәллә яракаең?
Күтәрелеп кара, каен,
Нихәл итим, каракаем?
Ак итәргә, пакь итәргә
Юк шул бер дә чара, каен.
Сыен әле кочагыма,
Аңлыйм сине, балакаем:
Мин үзем дә — туган җирдән
Аерылган бер бала каен...

*1996*

* * *

Тукталышны узып киткәнмен ич,
Изрәп китеп, сизми калынган.
Тиз әйләнеп кайттым үз өемә
Тукталышның теге ягыннан.
Җаным калыр, бәлки, күбәләктәй,
Болын чәчәгенә бәйләнеп.
Тик мәңгелек йокы дөньясыннан
Кире кайтып булмас әйләнеп...

*1996*

## *Соңгы кар, тәүге яңгыр...*

Урамнарда, урманнарда
Соңгы кар, тәүге яңгыр.
Кайчан, кайчан бу җаннарда
Кыш узар, яз уяныр?
Йөзгә бәреп карлар ява
Яңгыр белән аралаш.
Әллә инде кар бөртеге,
Әллә инде тама яшь...
Бозлар яна, җырлар ага,
Хәсрәтсез кем моңланыр...
Җан тартыла язга таба,
Соңгы кар, тәүге яңгыр...

*1995*

## *Роза исемле кыз*

Юк, йөрмәгез генә яннарымда,
Тасма телләләргә ышанмыйм.
Якын күргәннәргә елмайсам да,
Яман ниятлегә усал мин.
Балкып яныйм алсу иртәләрдә,
Өзмәгез сез роза чәчәген.
Янып яшим әле яшьлегемдә,
Якын килә күрмә, чәнечәмен!
Тик берәүне яратканга кадәр
Җанга сабырлык бир түзәрлек!
И малайлар, сезнең арагызда
Берәү дә юк әле өзәрлек!

* * *

Җылы якка озатып калдым
Яз кошларын.
Кошлар белән охшаш микән
Язмышларым?
Тоям җанның иркә-назга
Тартышларын.
Җылы көтеп узды гомерем,
Бар кышларым.
Очырсам да, күңелемнең
Аккошларын,
Җан җылысын көтә һаман
Яз, кышларым.
Очар идем ташлап салкын
Ак кышларын,—
Боз тавына богаулаган
Ялгышларым...

*1997*

* * *

Сәлам сезгә, нәни кызлар,
каз көтүчеләр!
Киләчәктә сөйгәненән
наз көтүчеләр!
Кем булырсыз сез, малайлар,
яз көтүчеләр,
Булмассызмы гүзәл җирне
саз итүчеләр?
Кем булсырсыз, нәни кызлар —
каз көтүчеләр?
Булмассызмы ирегезне
таз итүчеләр?
Кем булырсыз сез, малайлар —
яз көтүчеләр?
Булмассызмы күп бәхетне
аз итүчеләр?
Өметләнеп карыйм сезгә,
наз көтүчеләр,
Булырсызмы күңелләрне
яз итүчеләр?

*1997*

## Ак болытны юлдаш итәр идем...

Чит җирләргә киткән кошлар сыман,
Ак болытлар ага еракка.
Үз-үземне тыеп кына торам,
Очар идем мин дә шул якка...
Ак болытны юлдаш итәр идем,
Хәлләремне алар аңласа,
Шул болытлар белән китәр идем,
Туган-үскән җирләр калмаса.
Баш очымда ак болытлар йөри:
Яңгыр микән, әллә кар микән?
Җанны яралаучы күп дөньяда,
Җанны дәвалаучы бар микән?

*1998*

* * *

Милләтемнең шигырь бакчасында
Мин дә тибрәндем үз гөлемдә.
Минем тавышым да калыр, бәлки,
Мәңгелекнең бер мизгелендә.

## Йолдыз булма күгемдә

Сәгать теле уникегә
Җиткәндә,
Узган гомер моңсу гына
Киткәндә,—
Кил, кадерлем, бәйрәм китер
Җаныма.
Бергә керик яңа еллар
Таңына.
Төннең тыныч кочагында
Хыяллар
Киләчәккә безне илтеп
Куярлар.
Кушымта:
Ике йөрәк янсын бергә
Көчлерәк.
Янма ерак салкын йолдыз
Төслерәк.
Кушымта.
Син — хыялым, син бит үзең —
Яңа ел.
Төн йолдызы Күкләр өчен
Яна ул.
Кушымта.
Күңелемнең хыял тулы
Төнендә
Янымда бул, йолдыз булма
Күгемдә.
Кил, кадерлем, бәйрәм китер
Җаныма.
Бергә керик яңа еллар
Таңына.

*1999*

# Яңавылым*

Еракларда
Яна улың.
Йөрәкләрдә —
Яңавылым.
Сагынган күк
Ана улын,
Сагына бала
Яңавылын.
Онытма син,
Яңа буын,
Бабаң җире —
Яңавылың.
Күкрәгемдә
Яна нурың.
Бирде моңын
Яңавылым.
Елдан-елга
Яңаруың
Дәртләндерә,
Яңавылым.
Һич суынмас
Аңа юлым.
Мин синеке —
Яңавылым!
Туктаталмам
Җан давылын,
Тынычландыр,
Яңавылым.
Синеке дип
Саналуым —
Бәхеттер ул,
Яңавылым!
Сиңа булсын
Йөрәк җырым,
Йөрәк җылым,
Яңавылым!

*1999*

* Ю.Чаплин музыкасы

* * *

Сизәм ич мин: зур кайгың бар
Эчеңдә...
Тышка чыкмый, бик тирәндә
Хисең дә.
Елмайган да, шатланган да
Буласың.
Бүлмәңдәге гөлең кебек
Суласың.
Баш имисең, әмма боек
Күзләрең.
Күрәм ич мин кара хәсрәт
Эзләрен.
Шәлъяулыгың каплый боек
Яменне.
Ничек итеп җиңеләйтим
Хәлеңне?
Мин дә андый мәлне аңлау
Яшендә.
Ачыл, бәгырь, серләреңне
Яшермә.
Йөзләреңне шәлең белән
Каплама,
Газабыңны гел үзеңдә
Саклама.
Кил яныма, әйдә, болай
Килешик,
Авырлыкны икәү бергә
Бүлешик.
Җаным ачык: кеше хәлен
Тоярлык,
Газабы да, авыр сер дә
Сыярлык...

*1995*

## Сара ханым

Була шулай: кайчагында
Таштай катып кала җаным...
Эретә моң кочагында
Сара ханым, Сара ханым.

Тирәктәге асыл коштай
Очын, тибрән, сайра, җаным!
Йөрәктәге сандугачтай
Сара ханым, Сара ханым.

Күңелемдә таң ата да
Күтәреләбара җаным.
Биетә дә, җырлата да
Сара ханым, Сара ханым.

Милләтемнең бакчасында
Гөлдәй яфрак яра җаным.
Моңнарымның патшасы да
Сара ханым, Сара ханым.

*1989*

## *Без үзебез...*

Читтәгеләр,
Туган телебездән
Сез еракта — алыс тордыгыз.
Ник, нигә сез газиз әнкә телен
Чит бер телгә алыштырдыгыз?
Мондагылар,
Сез бит туган телнең
Үзәгендә генә тордыгыз.
Ник, нигә сез җанга якын телне
Башка телгә алыштырдыгыз?
Туган телнең әткә-әнкәләре...
Без ул — ерак алыс торганы.
Күреп, карап, сизеп түзеп тордык
Бала — телен алыштырганны...

*1998*

## Һәр мизгеле — бүләк

«Беттем, сүндем, артык түзә алмыйм,
Яшәү — бигрәк ямьсез, авыр бик...»
Күтәр башың, энем, кара күккә:
Күкләр нинди серле, матур бит!

Төн. Караңгы әле. Ай күренми...
Әмма Кояш барыбер калкыр бит.
Көнне каршылавы — үзе шатлык!
Таң йолдызы нинди матур бит!

Бәхет әле синнән ерак йөри,
Кайчан булса да ул балкыр бит.
Бу яшәүнең һәр мизгеле — бүләк,
Җир гөлләре бигрәк матур бит!

Юллар ярам. Бәхетемә барам.
Ул еракта, кайчак якын бик.
Җанда нәни генә өмет яна:
Яшәмәскә минем хакым юк!

Тукталабыз кайчак башны иеп:
Гомер итүләре авыр бик...
«Бу тормышны матурайтам!» диеп
Яшәүләре — үзе матур бит!

*2000*

* * *

Иң кирәкле бер сүземне
Әйтергә өлгермәдем.
Уфтанам: нигә пароход
Артыннан йөгермәдем?

Сине озаткан мизгелдә
Сулар да дулкынланды.
Киттең дә бардың тиз генә,
Ай күрде, кояш алды...

Сине көтеп узар инде
Көннәрем һәм төннәрем.
Тынарлык түгел йөрәктә
Калдырган дулкыннарың.

Кояшлар булып янам мин,
Таң җиле булып исәм.
Күңелдән укыйм догалар:
Кайта күр инде исән!

*2001*

## Алмагачлар чәчәк аткан чакларда

Бигрәк ямьле без яшәгән якларда
Алмагачлар чәчәк аткан чакларда.
Тау ягында Кояш чыга алдарак.
Алтын нурлар әйтерсең лә ал тарак.
Алмагачның чәчәкләрен җил тарый.
Безнең якны бик яратып кем карый?
Кояш карый торып бездән иртәрәк.
Бөреләрне уята ул иркәләп.
Ак чәчәкләр таң җиленә сөенә,
Тирбәләләр биеп Сәйдәш көенә.
Алма кебек кызлар да тиз өлгерер,
Чәчәкләрне җиргә сибеп җил йөрер.
Алмагачлар алтын нурда коена,
Ак күлмәген кия яшьлек туена.
Тау ягының җанга якын Кояшы
Пешерәдер татлы алма — туй ашы...

*2002*

## *Гөлләрдән килеп чыгарсың...*

Тамчылар җырлый бер көйгә,
Җәйгә тарта көннәр.
Язны ашыктырып, өйдә
Үстергәнсең гөлләр.
Син үзең дә назлы көлеп,
Күренерсең әле,
Җылы нурга, гөлең кебек,
Үрелерсең әле.
Тамчылар тып-тып тамалар,
Дәртле-моңлы көйгә.
Уйларым ташып агалар
Син яшәгән өйгә.
Күренми күпме чыдарсың,
Түзәлмәссең артык.
Гөлләрдән килеп чыгарсың
Алсу чәчәк атып...

*2002*

* * *

Хәсрәтле анадан туганмын —
Шуңадыр
Кайгыда — йөрәгем туңадыр.
Гөл сөйгән анадан туганмын —
Шуңадыр
Ул киткәч, гөлләрем суладыр.
Төн сөйгән анадан туганмын —
Шуңадыр
Җырларым төнлә дә туадыр.
Иманлы анадан туганмын —
Шуңадыр
Җырларым догалы буладыр.
Таң сөйгән анадан туганмын —
Шуңадыр
Җырларым өметле туадыр...

*2002*

## Нишләттеләр сине?

Якын күршебез Рәшит Галимуллин
Чечняда һәлак булды.

Каф тау артындагы аждаһаны
Җиңгән батыр егет турында
Мин сөйләгән кызык әкиятне
Тыңлый идең син дә, улым да.
Сугыш уты яккан зобанилар
Җибәрделәр сине яу-утка.
Илең өчен түгел, кемнәр өчен
Харап булып кайттың табутта?
Улларымның якын дусты идең,
Балам кебек идең минем дә.
Нишләттеләр сине, Рәшит энем,
Ачыласы чәчәк идең лә...
Үпкәләгән сыман рәсемеңнән
Карап тора көләч яшьлегең.
Йөгереп лә узды балачагың,
Бигрәкләр дә инде яшь идең...
Яшьлек оҗмахында яшәргә дип,
Бөреләнгәч... кайттың табутта.
Бер гөнаһсыз бала, нигә, нигә
Яндырдылар сине тәмугта?!

*2000*

* * *

Әче җил. Күкри, дөберди
Түбәдә өй калае.
Йоклый алмый газаплана
Шәһре Казан малае.
Хәлләремне аңлагандай,
Өйгә килә төн җиле:
«Юк әниең, юк әтиең,
Син — бер Казан ятиме...»
Янда гына Идел суның
Ярсулы гөрелтесе:
Бар җиһанда кызу агыш,
Йоклама, дигән төсле.
Алкын дулкыннар чакыра
Еракка — диңгезләргә:
«Әйдә, Алып бабаңнарның
Йөргән юлын эзләргә!
Кыргый кыпчак даласында
Уйнаган ком бураны...
Чыгар башыңны юрганнан,
Алтын Урда туруны!»
Йөрәкне кага дулкыннар,
Тәрәзәне җил кага:
«Аһ, кызганыч, үзең түгел,
Уйларың гына ага.
Уяныгыз, йокламагыз,
Әй Казан ятимнәре,
Бабагыз язган язмышның
Булыгыз хакимнәре!»
Бөтерә дә алып китә,
Килми йоклап каласы.
Таң алдыннан юлга чыгар
Шәһре Болгар баласы!...

*2002*

* * *

Кайчандыр әбиләр-бабайлар
Казансу — көзгегә караган.
Тын елга янына утырып,
Сылулар толымын тараган.
Тылсымлы ул нурлы көзгене
Илбасар залимнар ватканнар,
Кырганнар, асканнар, атканнар,
Су булып, ал каннар акканнар.
Казансу өсләре ал-кызыл,
Талларда җемелди алсу чык.
Татарның язмышы шикелле
Су тулы — кыйпылчык-кыйпылчык...
Шул ватык көзгене бергәләп,
Бер булып җыясы иде дә...
Көзгедә бәхетле елмаеп
Яшисе иде үз иленҗдә...

*2002*

## Тукта, җилкәй...

Гөлбакчамда яз төсләре
Кабынды.
Күкрәгемә юлчы бер җил
Кагылды.
Аңлыйм, җилкәй, көтә сине
Ерак юл.
Ял итеп ал, тукта, миндә
Кунак бул.
Җырыбызда меңәр еллап
Исәсең.
Исмәгәндә гел-гел искә
Төшәсең.
Җилсез шигырь исә алмый
Еракка.
Җилсез шагыйрь күчә алмый
Йөрәккә.
Китәрсеңме шигыремне
Җылытып,
Арганнарга, туңганнарга
Җыр илтеп?
Бармы җырым сиңа кушылып
Исәрлек,
Оныкларның йөрәгенә
Күчәрлек?..

*2002*

## *Килдем кырык чакрым ерактан...*

Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап алгач, татарларга Иделдән кырык чакрым ераклыкта гына яшәргә рөхсәт ителә.

Адәм үтәлмәслек сукмаклардан
Төнге карурманнан ат менеп,
Иделкәем,
Күрешергә килдем атлыгып.
  Тыныч агышымны будылар,
  Кырык чакрым читкә кудылар.
Кара йөрәк патша синнән аерып
Кырык якка сибеп таратты.
Иделкәем,
Акчарлагың — сыңар канатлы.
  Килдем кырык чакрым ерактан.
  Иделкәем ага йөрәктән.
Безне дә бер тирбәтерсең әле,
Агышларың калмас туктальп.
Иделкәем
Аңлагандай ага уфтанып.
  Гел-гел кара еллар булмаслар,
  Безнең агышларны бумаслар...

*2002*

# Тау башында җиләклек

Тау башында
Җиләклек,
Тау астында
Җиләклек.
Син үзең дә
Тау кашында
Тиз өлгергән
Җиләк кук.
Тау башыннан
Төш инде,
Кояш байый,
Кич инде.
Икәү бергә
Татырбыз
Җиләгеңнең
Тәмен дә.
Итәгендә
Тауларның

Мин — көтүче
Хәлендә.
Көтәм тауның
Ташында.
Бер уй гына
Башымда:
Өзелмәслек
Җиләк бул
Горур тауның
Башында.
Һай, мин бигрәк
Түзем лә...
Өзә алмыйм
Үзем дә.
Җиләк чагың
Бер генә —
Вакыт җитми
Өзелмә...

*2002*

## *Синдә генә*

Нур тараткан якты күзләр
Синдә генә,
Мин яраткан затлы сүзләр
Синдә генә.
Кузгалаклы ямьле җәйләр
Синдә генә,
Мәтрүшкәле тәмле чәйләр
Синдә генә.
Иренеңдәге ярсу тәмнәр
Синдә генә.
Чияң кебек алсу тәннәр
Синдә генә.
Дулкын-дулкын кыйгач кашлар
Синдә генә.
Тел йотарлык татлы ашлар
Синдә генә.
Тезем-тезем ширбәт йөзем
Синдә генә.
Калыр идем китми — үзем
Синдә генә...
Алданрак өлгергәне —
Синдә генә.
Җан сөйгәннең бер дигәне —
Синдә генә!..

*2002*

## Сизәләрдер...

Синең татлы-баллы икәнеңне
Шөпшәләр дә, ахры, беләләр.
Әллә нигә мине ят итәләр,
Бик яратып сиңа киләләр.
Чәчәкләрдән чәчәкләргә күчеп,
Тәмле иренеңә куналар.
Иң ләззәтле гүзәл гөлчәчәкнең
Син икәнен белә шул алар.
Сизәләрдер шәраб ачыларын,
Берни юктыр миндә — эчәрлек.
Берсе, каһәр, шундый чагып китте,—
Хәл калмады сине кочарлык...

*2002*

## Булгандыр инде...

Булгандыр инде мине дә
Үпкәләткән чакларың.
Кызып китеп авыр-авыр
Сүзләр әйткән чакларым.
Булгандыр инде, булгандыр
Соңга калып кайтканым.
«Дусларың белән яшә!» дип,
Ишегеңне япканың.
Хәзер инде бер-беребезне
«Рәхмәт» әйтеп кочарлык.
Мәхәббәтне саклап калган
Икебезнең усаллык.

*2002*

## Соңгы сорау

Туры юлда йөреп бөкерәйдем,
Турайта алмады Бәкере.
Сез аңларсыз, инде тындым диеп
Яткан җирем булса бөкере.
Сорау билгесенә охшап китәм.
Соңгы сорау белән багамын:
Бөкерәйми-кәкерәйми генә
Табарсызмы бирәр җавабын?..

*2002*

* * *

Җимерүче мәлгуньнәргә каршы
Сүзләр язган чакта, каһәрең...
Җимергәнмен нәни оныгымның
Бик тырышып корган шәһәрен...

*2002*

* * *

Туруннарым мине укысалар,
Әйтерләрме икән: Кол Юзи.
Кол Галиләр, Кол Шәрифләр кебек,
Гел изгелек кенә кыл, Юзи!
Кол Җәлилдәй кыю бул, Юзи!

*2002*

## Кызлар уены

Ике кызый гыйнвар урамында
Бер-беренә уйнап кар ата.
Минем дә бит уйнак табигатем
Йомшак җылы кышны ярата.
Җирнең өсте ап-ак болын төсле,
Яланаяк йөгереп китәсе,
Кар-чәчәктән такыялар үреп,
Шул кызларга бүләк итәсе!
Шушы көннән башлап күңелләргә
Гүя кара керләр кунмастыр,
Бер-берсенә пычрак атучылар,
Пычак атучылар булмастыр...
Язмыш җиле кая алып китәр
Табигатьнең ике аккошын?
Елый-елый сагынмаска язсын
Яшьлек болынының саф кышын.
Җирнең өсте ап-ак болын төсле,
Яланаяк йөгереп китәсе,
Кар-чәчәктән такыялар үреп,
Шул кызларга бүләк итәсе!..

*2002*

## Йорт кызлары

«Очам! Очам!» дигән өмет белән
Килеп җиткәч яшәү көзенә,
Йөрәк яргыч соңгы авазлары
Хыял күкләрендә өзелә.
Сизенәләр: казлар язмышына
Якыная инде аралар.
Алар... алар адәм аңламаган
Ярсулы җыр җырлап баралар.
«Әле дә йорт казлары булмадык» дип,
Йорт кызлары җырлый өмәдә.
Йөрәгемдә һаман шул казларның
Соңгы авазлары тирбәлә.

*2000*

* * *

Ялгышлар да, хаталар да булды.
Тик дөньяга юктыр бер кинә.
Үзем генә беләм: йөрәгемдә
Авырттырып йөри бер энә.
Гомерлеккә, ахры, кадалгандыр.
Мин бәхеткә лаек җан ласа...
Их, шул, энә, җан табибы булып,
Йөрәк яраларын ямаса...

*2000*

## Кар өстендә чәчәк

*Кырык бердә туганнарга*

Бөтен авырлыкны
Җилкәләргә салдык.
Әтисез дә калдык,
Әнисез дә калдык.
Әти — кырыс тормыш,
Әни — Ватан иде.
Өметебез — Күктән
Иңгән ал таң иде.
Бардык атны куып,
Заман армасын, дип,
Тормыш үзе бездән
Артта калмасын, дип.
Кар буйлап та бардык,
Яр буйлап та бардык,
Кыр буйлап та бардык,
Кыл буйлап та бардык.
Ачлыгын да күрдек,
Исән калдык ничек,
Чәчәк булып чыктык
Карны бозны тишеп.
Ил-көн алларында
Вөҗдан-йөз ак безнең,
Узган юлларыбыз —
Хезмәт, иҗат безнең.
Тормыш алга барсын
Өчен бирдек көчне.
Без яшәгән гомер
Түгел үкенечле.
Кырык бердә туып,
Карадык ла яшәп!
Чәчләр ап-ак инде —
Кар өстендә чәчәк.
Без барабыз һаман
Ал таңнарга таба.
Чәчне чәчәкләтеп,
Күктән ак кар ява...

*2002*

## Адашкан аккош баласы

Күрдегезме апрель кар-суына
Килеп төшкән аккош баласын?
Бик тә килә сине җылытасым,
Кайнар кочагыма аласым.
Ничек кенә сине юатыйм соң,
Нинди генә сүзләр әйтим соң?
Үз әниең белән китәлмәгәч,
Син барыбер бездә ятимсең.
Җылы якка китеп барган чакта,
Адаштыңмы очар юлыңда?
Үз әнкәең белән булалмагач,
Җылы табалмыйсың кулымда.
Азык та бар бездә, өең дә бар,
Бергә очкан кошлар юлы юк.
Ишләреңнән аерылып калгач,
Туган җирең дә дә җылы юк...

*2002*

## Таң кошларын юлдаш итәрмен

Иртә таңда мине уяталар
Табигатьнең серле көчләре.
Кәккүк булып, үзенә чакыралар
Әкияти урман эчләре.
Озын-озак гомер юрый-юрый,
Кәккүкләре рәхәт алдыйлар,
Аңлыйм инде, гомерең бигрәк кыска,
Мәңгелектә яшәп кал, диләр.
Урман эчләренә керермен дә
Таң кошларын юлдаш итәрмен.
Корган агачларны терелтерлек
Тылсымлы җыр җырлап үтәрмен.

*2002*

## Кар өстендә тәүге чәчәк

Зәңгәр күккә гел омтылып,
Кыш буена түздең ничек?
Язны тоеп, нурлар җыеп,
Салкын карны чыктың тишеп.
    Умырзая, умырзая,
    Кар өстендә тәүге чәчәк.
    Гомереңне балкытып кал
    Умырзая кебек яшәп.
Бу гомерләр бигрәк кыска,
Әйтерсең лә умырзая.
Яши белсәң кадерен белеп,
Гомерләр дә озыная.
    Умырзая, умырзая,
    Кар өстендә нурлы чәчәк.
    Гомереңне балкытып кал
    Умырзая кебек яшәп.
Җәйгә барып җитәлмичә
Чәчәкләрең коелса да,
Салкын җирне җылытып кал
Гомерең кыска тоелса да.
    Умырзая, умырзая,
    Кар өстендә моңлы чәчәк.
    Гомереңне балкытып кал
    Умырзая кебек яшәп...

*2002*

## Уйга талган чәчәк

Башны иеп көзге җилгә,
Мин дә уйланып торам.
Калды еракта язларым —
Синең балачак сыман.
Көзнең усал җилләрендә
Бер бөгеләм, бер сынам.
Калды еракта җәйләрем —
Синең яшьлегең сыман.
Сагынып чәчәк чакларымны
Мин дә уйланып торам.
Сибелә чәчләр, өзелә үзәк —
Гомерең көзләре сыман...

*2002*

* * *

Җитәрлек яшәдем, гомерем
Заяга үтте дип еламыйм.
Комсыз да түгелмен, яңадан
Шул кадәр яшәүне сорамыйм.
Берничә ел өстә, кәккүгем,
Җыр табыйм урманнар тыңларлык,
Бик иртә китте, дип, чишмәләр,
Былбыллар сагынып җырларлык.
Үзем дә, кәккүктәй моңаеп,
Карурман эчендә йөримен.
Табигать шагыйре кәккүккә
Мәңгелек гомерләр юрыймын.

*2000*

# Көз яшьләре

Узды инде айларымның
Көләчләре.
Көлми Кояш. Тып-тып тама
Көз яшьләре.
Рәхәтләнә имәннәрнең
Төз, яшьләре.
Юыладыр карт тауларның
Пеләшләре.
Нигә әче яшен түгә
Миләшләре?
«Әче!», «Әче!» дип кычкыра
Туй яшьләре.
Башка телдә үбешләре,
Сөйләшләре,
Чит кавемнән кодалары,
Кәләшләре.
Аяк аста — бабайларның
Киңәшләре.
«Болар бит, дим, милләтемнең
Үз яшьләре.
Җаннарда юк — Тукайлары,
Сәйдәшләре».

Яшьләр бии. Тама җиргә
Көз яшьләре...

*2002*

## Әнием, мин сине ташламам

Әниләр турында җырлар күп,
Монысы, мөгаен, меңенче.
Ягымлы, сабырлы, кадерле
Әнием, бу җырым — беренче!
Елмаю нурларын җаныңнан
Чәчкәнсең нәниең — елакка.
Мин юкта минут та боекма,
Әнием, китсәм дә еракка.
Мин сине гел елап уяткан,
Син мине гел җырлап юаткан.
Кочактан төштем ич, үстем ич,
Әнием, беркайчан елатмам.
Гомеремнең бәхетле мизгеле
Шат йөзең күрүдән башланган.
Борчылма, кайгырма, елама,
Әнием, мин сине ташламам...

*2002*

## Кулъяулык хәтле болыт

Озатты мине еракка
Болытсыз көннәр яме,
Яшьлектә сөйгән ярымның
Кулъяулык җилфердәве.
Узып барса күк йөзендә
Кулъяулык хәтле болыт,
Күренә миңа озатып калган
Ап-ак кулъяулык булып.
Без идек саф сөю белән
Зәңгәр күккә очынган.
Икебезне ике якка
Язмыш җиле очырган.
Яшьлегемдә җилфердәгән
Кулъяулык хәтле болыт
Иң караңгы көннәремдә
Яктыртты кояш булып.

*2001*

## Күзләремә кергәч...

Һаман салкыная барасың дип,
Юкка борчыласың, акыллым.
Суынмады яшьлек вәгъдәләрем,
Күкрәгемдә саклыйм ялкынын.
Нинди сүзләр әйтим икән диеп,
Гомерем буйларына эзләдем.
Тормыш юлларында янып-көеп,
Яшьлегебез узган — сизмәдем.
Әллә инде гамьсезлегем белән
«Яратам» дип әйтә алмадым.
Иң кадерле бер җан икәнеңне
Еллар узгач кына аңладым.
Гомер язларыбыз узган-киткән,
Күзләремә кергәч уйланам.
Язмышымнан сорыйм: миннән алда
Китә генә күрмә дөньядан...

*2000*

## Күзләрең нигә моңлы?

Менәбез дә атланабыз,
Көләбез, шатланабыз,
«Дөядә йөрдем әле!» — дип,
Дусларга мактанабыз.
Ә син үзең, дөя, нигә
Бер кызык та тапмыйсың?
Бигүк теләмичә генә,
Кар өстеннән атлыйсың.
Башың югары булса да,
Күрдем: күзләрең — моңлы.
Сагындыңмы әллә туган
Ягыңны — эссе комны?
Хәлләреңне аңлыйм да соң...
Ничекләр ярдәм итим,
Күз яшеңне киптерергә
Чүлләргә алып китим?..

*2000*

## Тукай Сәйдәшне тыңлый

Бөтен дөньясын онытып,
кечкенә Салих уйный.
Беләсе иде: Тукайның
күңеле ниләр уйлый?
Уйлагандыр: И афәрин,
бигрәк тә моңлы бала!
Без китсәк тә, бу җиһанда
Салих Сәйдәшләр кала.
Рәссамнар, көйчеләр туар,
сәнгать зур вә яшь булыр,
Салих та кечкенә булмас,
ул да зур Сәйдәш булыр!

*2001*

# Кем җиңәр, өстә калыр?

Менә кемнәр сабантуйның
Мәйданнарын киңәйтер.
Бу малайлар сынатмасмы?
Аксакаллар ни әйтер?
Үсәрме болар көрәшнең
Серен — ысулын белеп?
Боларда — безнең киләчәк,
Боларда — безнең өмет!
Төркем булып урамнарда
Йөрмәсләрме сугышып?
Яшәрләрме батырлыкка
Матурлыкны да кушып?
Иң-иң авыр көрәшләрдә
Аста калмаслар микән?
Бер-берсенә юл бирмичә,
Аяк чалмаслар микән?
Билләре дә ныгымаган.
Бу малайлар яшь әле.
Җиңгәне дә күтәрәлмәс
Иң дәү, авыр тәкәне.
Аксакаллар сынап карый:
Кем җиңәр, өстә калыр?
Кемнәр заман авырлыгын
Җилкәләренә салыр?

*2002*

## Мине кем аңлар?

Нинди күңелле
Яшәгән идек.
Бергә җырладык,
Уйнадык-көлдек.
Онытты бергә
Җырлаган көйне,
Кайтмый әтием
Сагынып өйне.
Ике канатым
Ник каерылды?
Әти һәм әни
Ник аерылды?
Бер-берсен сөеп
Ник карамыйлар?
Бер-берсен алар
Ник аңламыйлар?
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Ике йөрәкнең
Бер ярасында.
Йоклый алмыйча
Сызыла таңнар.
Нишләргә инде,
Мине кем аңлар
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Өзелеп калган
Көй арасында...

*2002*

## Ниһаять!

Революция,
Ниһаять, бездә!
Алга сикереш —
Тәрбиябездә!
Ата-аналар
Тынычлансыннар,
Бала калдырып,
Ялга барсыннар.
Бакчага бала
Йөрмәсен барып,
Дәү әниләре
Илтмәсен арып.
Кем үз постында
Борчуга төшкән —
Китә аласыз
Мөһим бу эштән.
Газапланмагыз
Процент җыеп,
Мескен балага
Икеле куеп.
Нәшрият, туктат,
Чыгарма китап.
Кино-театр,
Ишегеңне яп.
Тәрбиянең иң
Мөһим чарасы:
Табылды инде
Ата-анасы!
Ниһаять, бала
Гел өйдә ята:
Телевизор — ана,
Кампитр — ата!

*2002*

## Без — ир-атлар...

Без бик риза: хатын-кызлар
тормышны тартып бара.
Ир-егетләр, рәхәтләнеп,
арбада ятып бара.
«Ә син үзең кайда?» дисәң,
үзем дә бит мин анда,
Мультфильм карап барамын
персональный диванда.
Бик ардык ич: кабинетта,
машинада эшлибез,
Тауга таба менгәндә дә,
шул арбадан төшмибез.
Барабыз «гол!», «гол!» кычкырып,
сала-сала, туп карап,
«Әкрен барасың, хайван!» дип,
чыбыркыны суккалап.
«Мат»лы сүгенеп, әллә алга,
әллә артка барабыз.
Без — ир-атлар, төялешеп,
матриархатка барабыз.
Карап ятам: бер кинода
ат күзләре дымланды...
Бичараны кызганудан
күзләремнән яшь тамды.

*2002*

# Йола

Кичтән килгән кунак калып куна, диләр,
Борынгыдан бездә шундый йола, диләр.
Күңел төшкән кызны сынап карыйм әле:
Юлда соңлап кичен генә барыйм әле.
Ат туардым, бар хәйләне эшкә җиктем.
Җиң сызганып кыз янына кереп киттем.
«Ә» дигәнче бик тиз генә алам кочып...
Дигән идем... баскычыннан төштем очып!
Ишетеп калдым: «Бездә шундый йола! — диде,—
Мәкаләңнең мәгънәсе шул була»,— диде.
Шул көннән соң ул якларга чыкмыйм соңлап,
Ул кыз ята кочагымда — инде чынлап.
Үзе типкән урынны гел сыйпап тора:
Хәзер безнең гаиләдә шундый йола.

*2002*

## *Бүлешәләр...*

Дәүләт малын
Бүлешәләр:
Күрешәләр,
Белешәләр,
Килешәләр,
Өләшәләр,
Көлешәләр,
Үбешәләр,
Ирешәләр,
Өрешәләр...
Үлешәләр.

*1997*

## *Берләр һәм меңнәр*

«Үзем яшәгән Санкт-Петербургта битләренә пәрәнҗә япкан берничә татар кызын күрдем».

Илдар Әхмәтша,
«Азатлык» радиосы хәбәрчесе

Әдәп — аз-маз азияләшә,—
Шактый — европалаша:
Ике кыз — битен яба,
Меңләбе — артын ача.

*2001*

## Акча кирәк

Туганда да,
Туңганда да,
Уңганда да акча кирәк!
Өйләнсәң дә,
Сөйләнсәң дә,
Өй алсаң да акча кирәк!

Загска да,
Танышка да,
Бар эшкә дә акча кирәк!
Бала булса? Акча кирәк!
Өең тулса? Акча кирәк!
Хатын куса? Акча кирәк!
Еларга да,
Көләргә дә,
Үләргә дә акча кирәк!

«Акча юк!» дип сөйләнмим дә,
Еламыйм да, көлмим дә мин.
Иң яхшысы: тумыйм гына,
Өйләнмим дә, үлмим дә мин!

*1998*

# Кода белән кодагыйга

Бу дөньяда яши-яши
Кызык хәлләр булгалый:
Туганлашып утырабыз,
Кода белән кодагый.

Бер-беребезне белми идек,
Балалар якынайтты.
Үзебез таптык аларны,
Ә алар безне тапты.

Алар болай да икән,
Алар алай да икән.
Үзебез дә белми калдык:
Без әби, бабай икән!

Әгәр безне тапмасалар,
Ят булып яшәр идек.
Кода, кодагыем, диеп,
Кемнәргә дәшәр идек?

Туган-тумачалар белән
Гомер шәп уза, диләр.
Яшәсен әби, бабайлар,
Кодалар, кодагыйлар!

Инде оныклар бездән соң
Чират көтеп торалар.
Алар да тапсыннар бик шәп
Кодагыйлар, кодалар!

*2001*

## Заман егете ни җырлый?

Мин искергән җырлар яратмыймын,
Мин заманча җырлап яшәем:
«Бер алманы бишкә бүлмәем мин,
Биш алманы үзем ашаем!»

## Заман ире ни җырлый?

Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам, дуслар, застойны,
Застой белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән абыстайны.

## Имәбез!

И табигать юмартлыгы:
Акчасыз җырлый кош та.
Алтыны да, көмеше дә,
Җимеше дә... гел бушка.
Җир-Ананың күкрәк сөтен
Әрсез имеп ятабыз,
Бар байлыгын талыйбыз да
Анабызны... сатабыз.

## Замандаш портреты

Куллары — руль,
Аяк — тормоз,
Колаклар — антеннасы.
Уйда — акча. Ике күзе —
Автомобиль фарасы.

## Бер юллык шигырь

Шедевр... язасы иде бер!

## Ике юллык шигырь

Җиңел ул язу бер юллык шигырь,
Язасы иде — мең еллык шигырь!

## Өч юллык

Бер юллык язсаң — акча бирмиләр,
Мең еллык язсаң — вообще күрмиләр,
Мең юллык язсаң — басмый тиргиләр.

## Дүрт юллык

Мең юл да язмыйм,
Бер юл да язмыйм.
Бер дә язмаучыларга
Хәзер остаз мин!

*2001*

## Күчеш

Эшкә чыгып йөгергәнче,
Солы боткасы ашыйм.
Үзгәрештә яши-яши.
Шундый нәтиҗә ясыйм:
Хәзер тормыйбыз эшләргә
Гел-гел атлыгып кына:
Аттан артык эшләмибез,—
Бары ат кебек кенә.
Чыбыркы белән кумагач,
Эшләргә дә дәрт туа,
Дәүләтебез безне хәзер
Солы ашатып куа.
Рәхмәт инде хөкүмәткә,
Иркенләп сулыш алдык.
Кешегә үк әйләнмәдек,
Эш аты булып калдык.
«Маймыл» дип мине шаяртма,
Сөенеп озат, иркәм,
Маймылдан кешегә күчү,
Ай-һай, бик озак икән!
Хәзергә мин әйтә алмыйм:
Күчә-күчә нишләрбез...
Бәлки, тәмам Кеше булгач,
Аттан артык эшләрбез?..

*1996*

## Башлы редактор хикәяте

Тәҗрибә зур,
Як-ягыма карап,
Үлчәп әйтәм һәрбер сүземне.
Культ чорында башсыз кала яздым,
Харап итә яздым үземне.
Баш мәкалә үзем яза идем
Сүзләр алып «даһи ата»дан.
Һәр иртәне куркып Күккә карыйм:
«Сакла, диеп, политхатадан!»
Әллә Алла мине ишетмәде,
Әллә инде кабул итмәде,
Тик бер хәреф аркасында башым
Чак-чак кына Себер китмәде.
«Р» хәрефе төшеп калган икән
«Сталинград» дигән бер сүздә.
Почта начальнигы шалтыраткач,
Калдым телсез, сүзсез, өнсез дә...
Поезд тизлегендә чыгып чаптым,
Юк машинам минем, юк атым.
«Коткар!» диеп барып аудым аңа,
«Р» авазын шулчак югалттым.
«Шушы баш мәкалә аркасында
Баш редактор башсыз кала бит!
«Коткы тараткан!» дип, минем белән
Бергә синең баш та бара бит!»
Ул да, мин дә, алып китәрләр дип,
Өебезгә кайта алмыйбыз.
Калтырыйбыз, инде икебез дә
«Р» хәрефен әйтә алмыйбыз.
Хәреф югалтсак та, мөгаен, без
Икебезне исән калдырдык.
Баш китәрлек политхатабызны
Төне буе мичтә яндырдык.
Алфавитның башка хәрефләре
Һәммәсе дә — минем дусларым.
Ә бер хәреф — котсыз «Р» хәрефе —
Иң сөйкемсез явыз дошманым!
«Р» хәрефе кергән күп сүзләрне
Бик тә килә сызып атасым:

Революция, револьвер, рекрут...
Җитте... юк... юк, килми әйтәсем!
Әллә инде Ленин куркып калып,
«Р» хәрефен әйтә алмаган,
Әллә инде «эволюция» сүзен
«Революция» диеп аңлаган?
Культ чорының чак-чак исән калган
Мөхәррире диеп аталам.
Әле һаман куркып Күккә карыйм:
Сакла, диеп, политхатадан!...

*2002*

## Гали белән сарык

Гали бабай тәрәзәдән
Боегып карап тора.
Бик хөрмәтле аксакалга
Шунсы да ярап тора.
Янына Сарык килгән дә:
«Ярамый алай! — дигән,—
Син гел Кәҗәне сыйлыйсың,
Миңа бир давай!» — дигән.
«Бик-бик сыйлар идем дә шул —
Үземнең хәлләрем — хәл,
Карт көнемдә ялгыз калдым,
Юата бары Әҗәл.
Дөрес, анысы, якын күрә
Авыру да, каза да...
Ашатырга печән беткәч,
Килми хәзер Кәҗә дә.
Син: «Мә-ә-ә!» — дигәч, бик сөенеп
Торган булам мин көтеп...
Тыңламый да китеп бардың
Койрыгыңны селкетеп...»

*1995*

## *Кыргый базар кочагында*

Базарларда саткан булып, бушка йөрим,
Кишер саттым. Булмас, ахры, башка керем.
Янәсе дә мин — малтабар, акча көрим...
Пычак нигә? Кишер юк ич. Чыгып чаптым.
Үтмәсләнгән пычагымны тотым-саттым,
Кыргый базарның анасын сүгеп аттым.
Нервыларым тынычланды шул чагында:
Юк сатарга кишерем дә, пычагым да,
Кино карыйм «Кыргый Роза» кочагында...

*1995*

## *Бер җыр язасы килә!*

Күңелләрне тетрәтерлек,
«Гениально!» дип әйтерлек —
Бер җыр язасы килә!
Кыргый бүреләр уларлык,
Таш бәгырь ятып еларлык —
Бер җыр язасы килә!
Дошман көнләшеп үләрлек,
Дөнья алкышка күмәрлек —
Бер җыр язасы килә!
Шаккатырлык, искитәрлек,
Айныкларны исертерлек —
Бер җыр язасы килә!
Бар шагыйрьләр баш иярлек,
Иң чибәр кызлар сөярлек —
Бер җыр язасы килә!
...Ул җырны мин язар идем
Бер дә көчәнми-нитми...
Каләм дә бар, кәгазь дә бар,—
Их-х... талант кына җитми...

*1995*

## *Мин президент булсам...*

Шәхси мәнфәгатьне кайгыртмамын,
Сезнең хакта гына уйлармын,
Приемга килгән һәр кешене
Сараема чакырып сыйлармын.
Фатир-өйсез беркем торып калмас,
Һәр мохтаҗга ордер бирермен,
Әгәренки орден җитми калса,
Үпкәләсә, орден бирермен.
Алла бирсә, йөзләп мәчет төзим,
Һәр мәчеткә алтын Ай куям,
Һәр егеткә чибәр кыз ярәшәм,
Һәрбер кызга табам яшь кияү.
Тавык-чебеш базар-кибет тулыр,
Берәве дә ятмас кетәктә
Хәмер кирәк булса— үлгәнче эч!
Бер шешәсе — бары бер тәңкә!
Җаның ни теләсә — шулар булыр
Ашханәдә, кибет, хозмагта.
Курай тартып, тал төбендә ятар,
Һәрбер адәм яшәр оҗмахта.
Путевкалар — бушлай, ал икене —
Күзең төшсә — яшь бер ханымга.
Бик теләсәң — прошу ашханәгә,
Пожалысты, фәхешханәгә...
Әгәр мине, мине сайласагыз,
Кем икәнне минем күрерсез,
Симез калҗа, кара икра ашап,
Гел кикереп кенә йөрерсез.
Корсаклар тук, кайгы-хәсрәтләр — юк...
Мине генә мактап сайрарсыз,
Белеп торам, президент итеп
Сез, әлбәттә, мине сайларсыз!

*1994*

# Хатының булса депутат

Юк, сайлатмыйм мин Шурамны,
Агитация башлыйм.
Мин, мәсәлән, хатынымның
Исемен сызып ташлыйм.
«Кайчан кайтыр микән?» — диеп,
Гел көтеп ятыйммыни.
Тик телевизордан күрерсең
Өйдә үз хатыныңны.
...Каршы тавыш бирүемне
Шура үзе сизмәгән.
Миннән башка фамилиясен
Берәве дә сызмаган.
Көнләшәм: ник халык аны
Ярата да, сөя дә?
Хәзер Дәүләт Шурасына
Мин — оппозициядә...

*1995*

## Бер кыз авызыннан

Күрдем бер шәфкать туташын,
Карашы — укол кебек.
Металл да шулай ук каты
Булмастыр ул кул кебек.

Күрдем бер шәфкать егетен —
Терелдем карашыннан,
Ике кояш карап тора
Керфекләр арасыннан.

Шул шәфкатьсез туташ кереп,
Ник кагыла беләккә?
Берсе — агу, берсе — дару:
Икесе дә — йөрәккә!

*1995*

## Бераүнең изге ае

«Изге Рамазан аенда
Шайтаннар бәйдә тора»...
Нәфес, үзен тыялмыйча,
Төрле ниятләр кора.
Һич гөнаһсыз узам, дидем,
Гомеремнең бу аен.
Фәрештәмен дип уйлавым
Ялгыштыр ул, мөгаен.
Керер идем гөнаһларның
Бик тә хәтәрләренә,
Фәрештәләр язмасалар
Гамәл дәфтәрләренә.
Үзеңне аклый алмассың
«Ужымга кергән» өчен,
«Котыртты» дисәң, әйтерләр:
«Шайтан здесь ни при чем!»
Тамак гел кыткылдап тора
Хәрам ризык йотарга...
Димәк, кирәк үземне дә
Ыклап бәйдә тотарга!..

*1995*

# *И сөйкемле шәфкать туташым*

Чәчләреңә килә кагыласым,
Кулларыңны килә тотасым,
Бөтен тирә-юньне балкытасың,
И сөйкемле шәфкать туташым.
Кайчак дару итеп, уймакларга
Салып килә сине йотасым,
Комсызлыгым өчен кичер мине,
И сөйкемле шәфкать туташым!
Кайчак әкияттәге мулла кебек,—
Кәрт уенында килә отасым,
Хыялда да сине тотасым юк,
И сөйкемле шәфкать туташым.
Яшь чагымда җырлап хорда йөрдем.
«Хор кызларын юктыр онтасым»,
Дигән идем, менә оныттырдың,
И сөйкемле шәфкать туташым!
Хур кызларың белән кызыктырып,
Оҗмах, мине юкка көтәсең...
Гүзәллекне ташлап китәсем юк,
И сөйкемле шәфкать туташым!

*1985*

## Нәни генә бер явызлык

Гомер буе мине дошман күргән
Адәмнәргә юк бит үчем дә...
Тик шулай да бик тә нәни генә
Бер явызлык йөри эчемдә.
Шул явызны кая гына илтеп
Олактырыйм? Аяк тартыла:
Ямьсез карап узган капкорсакның
Тибим микән әллә артына?
Үз-үземә урын таба алмыйм,
Кул кычыта, арта көчләрем,
Күрми үткән таныш бер сәрхушнең
Койыйм микән әллә тешләрен?
Бик тә нәни генә усаллыкны
Мөмкинлек юк хәзер тыярга...
Тын урамнан китеп барган чакта
Чумып шундый татлы хыялга...
Ике-өч малай йөгереп килделәр дә
Шартлатып бер артка типтеләр.
Авызымда калган ике-өч тешне
Таш урамга коеп киттеләр.
Ыштансыз һәм тешсез кайтып киттем,
Сүгендем дә өч-дүрт авызлык.
Костюм киеп, сигаретын кабып,
Нәкъ минемчә уйлап, хыялланып,
Озатып калды «нәни» явызлык...

*1992*

# Эшкуарлар һәм җилкуарлар

Кәли дустым чөгендергә
Иртән үк эшкә куар.
Сәми дустым чөгендердән
Көн-төн көмешкә куар.
Вәли дустым-көмешкәне
Кабып алса — теш кояр.
Ул бит үзе мәгълүм табиб —
Тешсезләргә теш куяр.
Һашим дустым да эшлекле:
Читлеккә дип кош куар.
Миннән башкалар һәммәсе
Алып сатар, эшкуар.
Сәхи дустым — сәясәтче:
Ил артыннан ил куар.
Үзен дә эштән кудылар,
Сәхи хәзер — җилкуар.
Тик мин генә булалмадым
Малтабар йә эшкуар.
Хатын иртән кумый калды,
Кумый калмас — кич куар...

*1996*

## Рифма өчен язылган шигырь

Мин җитмеш елга
Бер генә туам.
Күңелем нечкә,
Булсам да юан.
Авылда туам,
Шәһәргә шуам,
Елыйсы килеп,
Күземне уам.
Күз яшем белән
Битемне юам...
Күңелем нечкә,
Булсам да юан.
Тимераякта,
Чаңгыда шуам,
Тоттырыр, бәлки,
Дөньяны куам.
Тоттырыр сиңа...
Тоттым дип юан.
Хисләрем — ташкын,
Ерылды буам.
Акыллы сүзләр
Сөйлим дә туям.
Рифма колына
Әйләнеп куям.
Рифма артыннан
Куам да куам,
Бик салмак кына
Дөньядан шуам.
Кадеремне белеп
Кал, җаным, куан:
Мин җитмеш елга
Бер генә туам.

*1994*

## Васыятьләр әйтеп тормыйм...

Васыятьләр әйтеп тормыйм...
Сездән дә шуны көтәм.
Озакламый күрешербез,
Яңа Бистәгә китәм.
Кызлар, минем белән биеп,
Назлап-сөеп калыгыз,
Әзрәк күңеле булсын, дип,
Тәнгә тиеп алыгыз.
Дошманнарым, исән чакта
Хурлап-таптап калыгыз,
Тәнкыйтьчеләр, җырларымны
Зурлап, мактап калыгыз.
Каракларым, байлыгымны,
Булса, талап калыгыз.
Ялагайлар, койрык болгап,
Кулны ялап калыгыз.
Шешәдәшләр, минем белән
Эчеп-салып калыгыз,
Акчам булса, бурычларны
Санап алып калыгыз.
Дусларым, бәхил булыгыз,
Куллар кысып калыгыз,
Минем кебек үкенмәгез:
Кызлар кочып калыгыз.
Көндәшләрем, гайбәт сөйләп,
Йолкып-чукып калыгыз,
Котылдык бу адәмнән, дип,
Дога укып калыгыз.
Юк...
Мин үләргә уйламыйм да,
Ул уй телемдә генә.
Барасы җир ерак түгел,
Әнә... тегендә генә.
Йөрәгем сәгать шикелле
«Келт» тә «келт» итеп тора.
Яңа Бистәдә, атлыгып,
Нечкәбил көтеп тора!

*1996*

## *Яшьлегем минем — җитмеш*

Яшьлегем минем бер түгел,
Яшьлегем минем — җитмеш.
Картлыкка сәлам бирмичә,
Сиксәнгә таба китмеш.
Миңа һаман килми, диеп,
Картлыгым көтә торсын.
Үзе килә күрмәсен, дип,
Яшьлегем киртә корсын.
Йоклап яткан картлыгымны
Тибеп уятмый булмас.
Әҗәл алдында уңайсыз,
Чәчне буятмый булмас.
Әҗәл белән шаярмыйлар
Икәнне күптән беләм.
Мин шаярмыйм, Әҗәл үзе
Уйный бит минем белән.
Яшьлегем минем — бер түгел,
Яшьлегем минем — җитмеш.
Картаеп яткан Әҗәлнең
Хәлен белергә китмеш...

*2002*

## Язылмаган поэма

*Дахау концлагеренда фашистлар тарафыннан крематорийда яндырылган татар шагыйре полковник Хәйретдин Мөҗәйнең язылмый калган поэмасы*

«Яктылыкны күбрәк күреп калыйм,
Баемачы, Кояш, баема.
Бу минутым минем — язылмаган,
Әмма язылачак поэма.
Күңелемдә йөргән поэмамның
Прологын әйтеп калдырам.
Син дәвам ит аны, шагыйрь иптәш,
Фашист мине утта яндыра.
Бу сүзләрне каләм белән түгел,
Аккан каным белән язамын.
Тыңла, Идел, Илем, Казаным...»

Германия.
Дахау.
Концлагерь.
Мине
Буйсынмаган өчен аттылар.
Бер минуттан, менә бер минуттан
Крематорийга озатырлар.
Мин, илемнең өлкән офицеры,
Янган утка керү алдыннан
Шигырь сөйлим.

Язмасын, дип, минем кулларымны
Имгәттеләр, каерып алдылар.
Күзләрем — кан.
Телем — телгәләнгән.
Күкрәгемә йолдыз уелган.
Тик бер минут,
Тик бер минут кына вакытым калган.
Гомерем уза минем уемнан.

«Биек-биек тауның башларына
Менәселәр безнең бар әле,— дип,—
Дөрләп-дөрләп янган ут эченә

Керәселәр безнең бар әле»,— дип,
Җырлап узган идем урамнан,—
Күңелем сизгән икән, туганнар!
Әнә алар мине көл итәргә,
Крематорий ясап куйганнар.
Авылымда яшьлек җырын җырлап,
Башлангандыр көрәш таңнарым,
Мин утларга таба горур киттем,
Мин утларга туры карадым.
Ишет, Идел, Илем, Казаным:
Бу сүзләрне көрәш утларында
Янган каным белән язамын.

Хәтерлим:
Кара-кучкыл озын чәчләремне
Сыйпап калган идең, кадерлем.
Хәтерлим...
Кадерлем,
Ап-ак чәчле кеше хәзер мин.
Бердәнберем,
Йомшак күкрәгеңнең
Кайнарлыгы һаман кочакта.
Истә:
Шулай яшь чакта,
Карурманга кереп ут кабыздык,
Сүзсез карап тордык учакка.
Ул төнне без шунда адашып йөргән
Бер юлчының юлын яктырттык.
Ул төнне без Җирдә кешеләр өчен
Янып яшәргә дип ант иттек.

Алда крематорий ялкынлана.
Илемә һәм
Сиңа биргән антым сынала.
Куй башыңны кайнар күкрәгемә...
Тик хыялда гына булса да
Куеп кал;
Гәүдәм минем көлгә әйләнгәнче,
Сине өзелеп сөйгән йөрәгемнең
Ничек тибүләрен тоеп кал.
Тоеп кал...
Кояш байый, минем йөрәгемнән

Каннар тама, таммас күз яшем.
Мин утларга керәм, Германия,
Чыксын өчен синең кояшың.
Янам шуңа:
Минем оныкларым
Сугыш дәһшәтләрен онытсын.
Аккан каным,
янган тәнем, Германия,
Салкын туфрагыңны җылытсын!
Яңа Германия калкып чыгар
Безнең көлләрдән.
Улым эзләп килсә, букет бәйлә, Германия,
Безнең көлдә үскән гөлләрдән.

Киләчәк...
Ул шундый матур булыр:
Сугышлар да булмас, дошман да...
Сез мине дә шунда искә алырсыз,
Бәлки, миңа йөз яшь тулганда,
Дуслар бергә җыелып утырганда,
Учак яккан чакта урманда...
Улым,
Эзләмә син минем каберемне,
Әткәң кала җирдә көл булып;
Көл булуың мең мәртәбә артык,
Яшәгәнче җирдә кол булып.
Табалмассыз барыбер каберемне,
Эзләп килсәгез дә эзләремнән,
Эзләгез сез мине улларымның
Тормыш дәрте янган күзләреннән...

Карт анам,
Мине тудырганга
Үкенмимсең...
Әйеме?
Әйт, анам...
Карт анам,
Төнлә
йомшак түшәгеңдә
Әйбәт төшләр күреп ят, анам.
Зинһар өчен...

Дөрләп ут янганда,
                    мине уйлаганда,
Кышкы кичтә мичкә карама.
Мичләр сүнәр,
Өй караңгы калыр,
Лампочкалар яндыр, карт анам.
Синең күңелеңә мин бары тик
Якты булып кына кайталам.

Илне сөеп типкән йөрәгемне
Крематорийга алып баралар.
Язылсы бер поэмам калды...
Терелт, шагыйрь, мине яңадан.

Алдымда — ут.
Тагын ике секунд.
Күкрәгемдә калган көч белән:
«Язып бетерәлмәгән поэмамның
Дәвамы бар!» — диеп кычкырам.
Янарбыз без якты маяк булып,
Меңнәр тормышына ямь биреп,
Мин — мәңгелек,
Мәңгелек ут...
Ә мәңгелек утка — сүнү юк!

*1964*

# Хикәяләр

## Мин сездән, авылдашлар...

Туган авылым!

Таныйсыңмы мине? Чит итмисеңме? Онытмадыңмы? Әйе, мин инде синең болыннарыңда юрга тайдай чапкан яланаяклы малай түгел. Мин сиңа дөнья күргән, сабырланган, аз сөйләп күп тыңларга өйрәнгән ир булып кайттым. Сиңа җитәр-җитмәс тау башында машинадан төштем дә, чемоданымны җиргә куеп, туктап калдым.

Кайларга гына бармадым, ниләр генә күрмәдем! Ярты дөньяны әйләнеп чыктым дип мактана алмыйм, кызганычка каршы, минем әле чит илләрдә сәяхәттә йөргәнем юк, шулай да үз илебезне аркылыга-буйга иңләдем. Казакъ дусларның тәнгә сихәтләре булган шифалы кымызын авыз иткәндә, мин синең иркен болыннарыңның хуш исле печәнен ашаган сыерның күбекләре ташып торган җылы сөтен сагындым, каракалпак дусларның су сорамасаң да ширбәт итеп биргән ал-кызыл карбызларын иреннәргә тидергәндә, мин синең йомшак тиреслегеңдә үскән кабагыңны күз алдыма китердем. Украин дусларның җылы нурларда иркәләнеп үскән алмаларын кулда тотканда, мин синең бакчаларыңда үскән бәрәңгеңне уйладым. Үз гомеремдә нинди генә тәмле-шифалы сулар эчмәдем: шәфталу соклары, кока-кола, коктейль... тагын әллә ниләр — әмма кырык градуслы салкында күршебез коесындагы чиләктән эчкән судан да тәмлерәге очрамады. Әгәр бар дөньяның иң оста-маһирлары эшләгән будильникларны тезеп куеп: «Теләсә кайсын сайла»,— дисәләр, мин, һич тә икеләнмичә: «Туган авылымда сызылып таң атканда моңлы тавыш белән кычкырып уяткан әтәчне китерегез!» — дияр идем. Сабый чакта йокы бигрәк тә тәмле була. Шуңа күрә микән, безнең авылда, без бәләкәй чакларда, йокларга гына түгел, җырларга да яраталар иде.

> Кара дуга, пар кыңгырау
> Безнең атларда гына.
> Рәхәтләнеп йоклап калдым
> Сабый чакларда гына.

Кечкенәдән калган гадәт, яшермим, бераз гына мактанырга яратам, йоклау белән мактану егетлек булмаса да, әтәчләр үзебезгә караганда маладисрак иде шул. Сөт, кабак, бәрәңге, әтәчтән башка да мактанырлык нәрсәләр

күп әле авылымда. Мактанудан киткәч, әйдә, безнең якта туган бер мәзәкне сөйләп алыйм әле. Үзегез дә беләсез, һәр кешенең үз холкы булган кебек, һәр авылның да үзенә генә хас гадәтләре, үзенчәлеге бар. Бер авыл икенчесеннән калышмаска тырышып, чемләнеп эшлиләр, берсе кәрнизләрен зәңгәргә буяса, икенчесе дә буйый, берсе дусларча көлеп мәзәк чыгарса, икенчесе дә чыгара. Безнекеләр турында күршеләр чыгарган мәзәк: «Тегеләрнең (безнең) тагын бер тапкыр мактанасылары килгән. Егермесе егерме ат җиккән. Ә итек ун пар гына икән. Һәрберсе сыңар итек кигән дә, киткән болар тарантаска утырып безнең авылга. Әй, бараләр, ди, болар. Һәммәсенең аягында ялтырап торган хром итекләр! Егерме итек! Ә итексез аяк тарантас эчендә!»

Бу хәл чынлап та кайчан да булса булгандырмы, әмма көнләшүдән чыгарганнар моны. Дөрес эшләгәннәр безнең авылдашлар, югалып калмаганнар, борыннарына чирткәннәр күршеләрнең. Ә «мактанчыклар» дип мөһер сугып кую белән һич тә килешмим. Дөрес, бар аерым кешеләр, бар мактанчыклар, бар алдакчылар, дөресен әйткәндә, алар безнең мактанычыбыз, аларсыз яшәү шактый күңелсез булыр иде. Алдакчы шөһрәте тирә-юньгә таралган Миңнияр абзый белән без хаклы рәвештә горурлана идек. Кәмитләрең, комедияләрең бер читтә торсын! Һич кенә ышанырлык түгел, әмма шулкадәр тасвирлап сөйли, әллә чынлап та шундый хәл булды микән, дип тыңлыйсың. Без бәләкәй чакта, Миңнияр абзый сугыштан кайтып төште. Аягында әлеге дә баягы шыгырдап торган хром итекләр. Буденныйныкы шикелле мәһабәт озын мыек, күкрәктә — орден-медальләр. Сугышта күргәннәре турында бер-ике сүз әйтте, ышанмадылар: «Алдакчыдан ни көтәсең, кешенекен тагып кайткан»,— диделәр. Бүтән без аның орден-медальләрен күрмәдек һәм сугыш турында сөйләвен дә ишетмәдек. Аның каравы булмаган һәм булмас хәлләрне шундый бирелеп сөйли, хәтта чын күңелдән үзе дә ышана язып кала. Сүзен башта хәйләкәр елмаеп башлаган абзый соңыннан җитдиләнә һәм соңгы җөмләсен: «Чыннан да шундый хәлләр була микәнни, егетләр?» — дип тәмамлый. Алдаша башлаудан элек, мыекларын бөтереп куяр, егет-җилән җыелган урынга килеп туктар.

— Нихәл, егетләр?

(Шул сүзен әйтү белән, авызлар ерыла башлый, борчак сибәргә тотына инде бу, янәсе...)

— Шәп, Миңнияр абзый!

— Сезнеке генә түгел, минеке дә шәп әле... күзне әйтәм... Мәсәгут безгә ничә чакрым әле?

— Ун.

— Карагыз әле Мәсәгуткә. Әнә урам уртасында, кәнсә янындагы телефон баганасын күрәсезме?

— Юк.

— Ә мин күрәм. Тагын да җунләбрәк карагыз әле.

— Карадык.

— Телефон чыбыгында бер чебен утыра, күрәсезме?

— Алдыйсың!

— Күзем сезнекеннән начар, но күрәм, егетләр, валлаһи күрәм! Ә ни өчен чебеннең йоклап утырганын беләсезме?

— Белмибез.

— Чебен очкан тавыш та ишетелмәсен, юл төзүчеләр рәхәтләнеп йокласын өчен... Киттем мин шунда юл төзүчеләрне уятырга.

Без «вәт ялганчы», «әй шыттыра» дип көлеп калабыз, ә ул үзе салган таш юлдан ун чакрымдагы чебен ягына китеп югала.

Миңнияр абзый гомере буе арттырып, ялганлап, кешеләрне көлдереп яшәде, шуңа күрә авылдашлары да аңа җитди карамадылар, Алдакчы кушаматы тактылар, ә ул үзе моңа бер дә үпкәләмичә, разый булып яшәде.

Яшәде... һәм беркөнне кинәт, йөрәге ярылып, дөньядан китеп барды. Кем дә булса вафат булса, авыл бик тирән кайгы кичерә, сөйләшмиләр, елыйлар, озаткач, авыр истәлекләр сөйлиләр. Миңнияр абзыйның үлү хәбәрен ишеткәч, ышанмыйлар, көлеп-елмаеп: «Кеше ышанмас хәбәрне чын булса да сөйләмә»,— диләр. Өйләренә баралар: Миңнияр абзый, чынлап та, мәңгегә күзләрен йомган. Йомык күзләрдә хәйләкәр бер көлемсерәү. Менә ул сикереп торыр да: «Чынлап та шундый хәл була микәнни, егетләр?» — дип сөйли башлар сыман. Тәнен туфрак белән күмгәч тә, күңелдә ниндидер салкын-авыр тойгы калмый, халык аны кызыклы яклары белән генә искә ала.

Берникадәр вакыт узгач, авыл халкы сизә: нидер җитми, нидер юк. Урамнарда дәртле көлү тавышлары азая, егетләр төркеме дә моңаеп кала. Моның сәбәбен соң гына аңлыйлар: ун чакрымнан чебен күрүче, эчләр катканчы көлдерүче, иң усал кешеләрне дә тәмле теле белән эшләтә белүче ялганчы Миңнияр абзый җитми икән. Җитми, и вәссәлам! «Чынлап та шундый хәл була микәнни, егет-

ләр?» Соңгы кайтуда Миңнияр абзыйның кабер ташындагы рәсеме белән генә очраштым. Шул ук сәер тойгы! Күңелдә авырлык юк, аның сабыйларча хәйләкәр-мөлаем йөзенә карап, тагын нинди хикмәт әйтер икән бу, дип көтәсең. Миңнияр абзый дәшми. Ә авылның аны яшәтәсе килә. Инде аның үзен кире кайтарып булмый. Халык аның образын терелтә, мәзәкләр чыгара, исемен телдән төшерми. Бездә генә түгел, тирә-юньдә дә «Миңнияр абзый әйткәндәй» дигән сүзләрне еш ишетәсең. Мәзәкләрдән берсе. Монысын укытучы, мыегын Миңнияр абзыйныкына охшатып үстергән Шаһинур сөйләде: «Валлаһи, чын мәзәк түгел, үз күзләрем белән күрдем»,— ди.

— Миңнияр белән без бик дус идек. Ни күзем белән күрим, беркөнне ул кемгәдер ачуланып килеп керде: мыеклары селкенә. «Председатель юл төзүчеләргә печән бирми!» — ди. Әйдә, мин әйтәм, председатель булып уйныйбыз. Башта син председатель бул! Миңнияр абзыйның ачуы сүрелде, мыекларын бөтерде дә тотынды уйнарга. Ишек шакып кердем. «Иптәш председатель,— мин әйтәм,— печән бир әле».— «Әнә алыгыз,— ди ул, рольгә кереп.— Мүксаздан мәктәпкә кадәр печәнлек сезгә — укытучыларга!»

Хәзер инде мин председатель урынында. Керә теге ишекне шакып. «Печән бир әле безгә — юл төзүчеләргә, иптәш председатель!» — «Сезгә! Юл төзүчеләргәме? Рәхим итеп алыгыз, таш юлда үскән печән — сезнеке!» — дим.

Миңнияр рольгә керүебезне онытты, уенга чын күңелдән ышанып: «Мин сезгә печән бирдем бит, нигә безгә бирмисең?» — дип ачуланып, ярсып чыгып китте.

Монысы — чын. Инде мәзәк итеп сөйлиләр. Беркатлы, ихлас күңелле, сабый җанлы кешене сагынып. Ул сагыну көннән-көн, елдан-ел арта, һәм Миңнияр абзый үз авылының легендар героена әверелә бара. Халык тудырган мәзәкләрнең берсе:

— Үзегезгә мәгълүм, Миңнияр мәрхүм, үзе исән чакта, борчак сибәргә ярата иде. Үләренә бер-ике көн калгач, мәрхүмкәй, мактана икән: «Гомерем буе җыйган акчамны Йөгәмәш тавындагы карт карама төбенә күмдем, исән-сау яшәп, мин бу дөньядан ычкынгач, казып алыгыз».

Үзен күмдек бит инде. Хуш. Моны тыңлап торган берничә егет, тиз генә баеп китү нияте белән, тотыналар карама төбен казырга. Казыйлар-казыйлар да бер капчык табалар. Капчык эченнән язу килеп чыга: «Тот капчыгыңны, авызын түбән таба куеп...»

Менә шулай, Миңнияр әле дә булса телдә, күңелдә яши.

Бәләкәй чакта без, аннан көлеп, такмак әйтеп кала торган идек:

Миңнияр,
Икебезгә бер кыяр,
Син турый тор, мин ашыем,
Кайсыбыз алдан туяр...

Үпкәләүнең ни икәнен белми торган Миңнияр, без күпме генә артыннан йөгереп такмакласак та ачуланмый, үзеннән көлеп чыгарылган такмакны, туктап, елмаеп, рәхәтләнеп тыңлый иде. Мин беләм, валлаһи-билләһи, бу такмак бары тик безнең авылда гына туган, андый Миңнияр кызыклы Миңнияр бары бездә генә, беркайда юк һәм булмас та! Ә нигә Миңнияр безгә ачуланмый? Без, калай әтәчләргә, исемеңне кертеп, такмак әйтеп кара, без шундук сугышырга тотынабыз. Миңниярның ни өчен үпкәләмәвен яши-яши аңладым. Дүрт юлда — Миңниярның кеше буларак сыйфаты, характеры, образы. Син бит шундый дөнья бәясе кеше, хәтта кыяр турасаң да, үзең ашамыйча, кешеләргә бирәсең, үзең ач калсаң каласың, әмма җаның — канәгать... Алай ук беркатлы булма инде, Миңнияр, дөньяда төрле адәмнәр бар, син тураганны эләктерергә генә торган комсызлар бар, үзең турында да кайгырт инде син бераз... Әгәр дә Миңнияр:

Мин турыем, син ашый тор,
Кайсыбыз алдан туяр,—

дип җырлаган булсак, ул безгә әйләнеп тә карамас иде. Шушы дүрт юлда — Ватан сугышының беренче көненнән иң соңгы көненә кадәр — дүрт ел фронтта йөргән кавалерист Миңнияр, икмәгенең соңгы валчыгын яралы дустына биргән Миңнияр, шат табигатьле, иң авыр минутларда дусларының рухын күтәрүче, авылдашларына юллар, күперләр салып калдыручы көчле җанлы Миңнияр. Әгәр дә мин аның шундый кеше икәнен белсәм, бәләкәй чакта малайлар белән аның бакчасына кереп кыярын урламаган һәм, качып, кыяр турый-турый:

Миңнияр,
Икебезгә бер кыяр,
Мин ашыйм, син үстерә тор,
Кайсыбыз алдан туяр,—

дип такмакламаган булыр идем.

Миңнияр салып калдырган таш юллардан, күперләрдән узам, фронт документларын, фоторәсемнәрен карыйм: юк, Миңниярның төп сыйфаты алдашу түгел. Чынында исә ялганлап сөйләве аның дөньяны көнкүреш ваклыкларыннан күтәребрәк карарга теләвеннән, матуррак, калкурак күрергә теләвеннән килә. Әдәбият теориясе телендә моны художестволы арттыру, диләр бугай. Димәк, Миңниярда язучыга кирәк сыйфатның берсе — юмарт фантазия булган. Тагын башка бик күп сыйфатлар да өстәлсә, ул, һичшиксез, язучы һөнәренә ирешер иде, тик бер генә нәрсә: язу сәләте генә җитми калган. Тел белән тегермән тартырга оста иде дә соң, кул белән тегермән тарту ягы чамалы иде шул авылдашымның. Миңнияр турындагы такмакларны әнә шул «тел тегермәне» әйләндереп чыгарган да инде. Бу язмаларымны укучы авылдашларым, бәлки: «Бездә Миңнияр исемле кеше юк, әмма тач шуңа охшаган кеше бар иде, язучыбыз да алдакчы булып чыкты»,— дип уйласалар, мин һич тә үпкәләмим. Чыннан да, мин фантазиягә ирек куеп арттырам, исемнәрне дә үзгәртәм, әмма тормыш дөреслегенә хыянәт итмим. Миңниярлардан күчкән бу сыйфат миңа әдәбиятка кыюрак керергә, характер тудырганда, сюжет корганда, чынбарлыкны тагын да калкурак, көчәйтебрәк күрсәтү максаты белән, чиксез хыялны җигәргә ярдәм итте.

Һәр авылның бер тилесе була. Бездә дә бар иде берәү! Сезнең авылныкы, бәлки, шыр тиледер, әмма мактана алам: безнең тилебез дә үзләрен акыллы санап йөрүче кайберәүләрдән акыллырак иде! Миңниярның ялганлавы мөлаем, күңелле, җанга рәхәт. Безнең тиленең теленә эләктеңме — мәрхәмәт көтмә, бер көлүдә бөтен мир алдында мәсхәрәгә калдыра. Ул өйдәнөйгә кереп йөри, акча бирсәләр ала, бирмәсәләр — сорамый, шулай да керү белән һәр күршегә характеристика бирә.

— Күрше Садрыйга кердеңме?

— Кердем. Әле шуннан чыктым.

— Нишләп яткан булалар? Акча бирделәрме?

— Бирер сиңа Садрый, тот! Этнең койрык астына сукыр бер тиен таксаң, Йөгәмәш тавының башына менгәнче йөгерер!

Шушы бер җөмлә белән Садрый бетте, комсызлык билгесе аңа шушы сатирик сүзләр белән мәңгегә чәпәлде. Садрый? Садрый? Кайсы Садрый? Теге, эт койрыгы асты-

на тагылган сукыр бер тиен артыннан Йөгәмәш тау башына кадәр чапкан Садрыймы?

Бер җөмләдә — комсызның тулы портреты. Аны ишеткәнгә утыз еллап вакыт узды, күпме китаплар укылды, күпме мәгънәле сүзләр онытылды, ә бу җөмлә әлегә кадәр хәтердә саклана. Образлы әйтелгән, усал әйтелгән. Кайчакта төнлә уянып китәм дә шул күренешне күз алдыма китерәм!

Койрык астына сукыр бер тиен (!) тагылган эт Йөгәмәш тавына чабып менә. Ә тау биек, текә, йөгереп менәрлек түгел. Ә Садрый, мышный-мышный, телен салындырып, бары тик алдында ялтыраган сукыр бер тиенгә карап, чаба да чаба. Бәлки, ыштаны да төшеп каладыр әле, аңа да карамый, йөгерүен белә. Чөнки аңа акча кирәк, акча!

Шуларны уйлап, җиде төн уртасында, кычкырып көләргә тотынам. Их, мин әйтәм, моннан мультфильм эшләргә! Шигем юк, башкалар да көләр иде!

Чыннан да, Садрый үтә карун, саран кеше иде шул. Егермегә якын корт умартасы тота. Аңа ярарга тырышып, «Бал бабай» дип дәшсәләр дә, бал тәтеми иде шул. Бал суыртканда, ишекне бикләп куя, тәрәзәләрнең пәрдәсен төшерә. Пәрдә төшүнең ни икәнен сизенеп алган күршесе Габдуллаҗан күпме генә өй тирәли әйләнеп йөрсә дә, ишекне ачмый.

— Кузгалалмыйм шул, Габдуллаҗан, өянәгем кузгалды,— дип кенә җибәрә.

Үз туганнары килгәндә дә чәй өстәленә табак белән куймый, тәлинкә төбенә күренер-күренмәс кенә бер калак бал сала. Ел саен зарлана:

— Уңмадым кортлардан, каһәр суккырлары,— ди. Безнең белән уйнаган улы Нәсим бер телем икмәккә бал сылап чыкса, без, тәмле телләнеп, аңа сарылабыз:

— Нәсим, әз генә бир әле!

— Бер генә тешлим инде!

— Кылтайма, бир!

— Ипи шүрлегеңә менгәнче, биреп кал!

Нәсим ашавын белә, безгә бал бабай сүзләре белән генә җавап бирә:

— Юк, бирмим! Сез кешегә биреп әрәм итәсез!

«Кешегә бирсәң — әрәм була». Бу — комсыз кешенең төп яшәү рәвеше, тормыш фәлсәфәсе. Бары үзеңә генә, үзеңә генә, кешегә биреп әрәм итә күрмә! Кайда нәрсә күрәсең — әләктер, җый, кирәге чыгар, кешегә генә бирмә!

Безнең акыллы тилебез (ай-һай, тиле булды микән ул, мөгаен, кылангандыр гына) бер җөмлә белән Садрыйның портретын койган да куйган. Аның телгә осталыгына безнекеләр дә бәя биргәннәр, хикмәтле сүз сөйләүчегә: «Телеңә тиле төкергәндер синең»,— диләр. Тиле болай карауга үзе усалга охшамаган, дөнья мазаларыннан хәбәре булмагандай, гел елмаеп кына йөри. Каян килгән аңа усаллык?

Бал суыртып ятканда, Садрый ялгыш ишеген ачып чыккан да, тиле килеп кергән. Табигый инде, теге бал сораган. Бал бабай авыз иттермәгәч, тиле, утырып, муллалар шикелле килештереп, теләк теләгән һәм ахырын болай тәмамлаган:

— Рәхмәт, Садрый, бал ашатуыңа. Ходай Тәгаләнең рәхмәте ява-ява түбәңне тишеп бетерсен! Аллаһе әкбәр!

Бал бабай да, изге теләген әйтә-әйтә, тилене куып чыгара.

— Телеңне корт чаккыры нәрсәкәй! — дигән сүзләрен күрше-тирә дә ишетеп кала.

Ни хикмәттер, тиленең теләге тормышка ашмый. Садрый, күршеләрнең аерган кортларын тубалга җыйганда, агачтан егылып төшә төшүен, әмма ләкин башы тишелми. Киресенчә, Садрыйның теләге кабул килә: урамнан узып барганда, Бал бабайның корты тиленең телен чага. Ул: «Ай!» — дип кычкырып җибәрә һәм шуннан соң бер ай ләм-мим бер сүз дәшми. Садрый, моны ишетеп, куанычыннан нишләргә дә белми, бу хәбәрне әйтергә кергән малайны бер калак бал белән сыйлый: «Аллага шөкер, котылдым шул тиленең теленнән»,— ди.

Бер ай узганнан соң, тиле авызын ачкан һәм һәммәгезгә мәгълүм теге җөмләне әйткән.

«Тән ярасы — бер ай, тел ярасы — гомерлек»,— дигән сүзләрнең хаклыгын мин әнә шунда аңладым. Тиленең шешкән теле бер айдан төзәлде, ә Садрыйга ябышкан «комсызлык» мөһере гомергә калды. Безнең тилебез гади генә сүзләргә тирән мәгънә бирде, канат куйды, һәм алар, телдән телгә, өйдән өйгә күчә-күчә, күрше авылларга да очтылар. Мин бу җөмләне безнең хакта мәзәк чыгарган күршеләрдә дә ишеттем. Димәк, комсызлар сездә дә бар, бездә генә түгел!

Әдәби әсәр иҗат иткәндә, образлылыкка, кыскалыкка, канатлы тапкыр җөмлә табарга, усаллыкка мин үзе-

безнең авылның тилесеннән дә өйрәндем һәм өйрәнәм. Менә тагын җае килгәндә мактанып алдым әле.

Күршеләр безне мактанчыклыкта гаепли икән, әйдә, мәзәген дә чыгара бирсеннәр, безнең моңа бер дә исебез китми, мактанырлык кешеләребез юкмы әллә?! Бик ачу килсә, күршеләр урамыннан егерме хром итек киеп узган авылдашлар белән дә мактана алабыз. Итексез аякны күрсәтми тарантас эченә тыгып бару, беләсегез килсә, һич тә масаюдан түгел, башкалар алдында сер бирергә, сынатырга теләмәүдән генә. Авылдашлар, дус күршеләр алдында гына түгел, дошман алдында да сынатмадылар. Күрше авыл, сиңа әйтәм, тыңла... Исеңдәме, тарантастан солдат итеген салындырып, урамнардан Сәлимҗан уза иде. Чиләкләп яңгыр яуганда да, күз ачкысыз кышкы буранда да ул район үзәгеннән почта ташый иде. Хәтерләдеңме? Сул аягында итеге булмаганга күрсәтми узгандыр әле, сезнең гадәтне беләм инде, дисезме? Юк, безнең гадәтне белеп бетермисез икән шул... Сәлимҗан, унҗиде яшьтән үзе теләп, Ватан сугышына китеп, авылга аяксыз кайтып керде. Яраланмаган җире юк. Тән яралары өстенә — йөрәк ярасы: сөйгән кызы башкага кияүгә чыккан. Тешләрен сугып сындырсалар да, дошманы алдында кан түкерергә өйрәнмәгән егет сыгылып төшмәде, ул һаман шул: кичләрен дус-ишләре белән кочаклашып урамнан җырлап уза, хәтта мин аның кичке уенда бер аяксыз килеш биегәнен күреп шаккаттым. Туракланган гәүдә һаман шул элекке ритмын югалтмаган. Бер генә үзгәреш сиздем: Сәлимҗан абый элек биегәндәге кебек зәһәр итеп, колакларны ярып керерлек сызгырмый һәм: «Их, егетләр!» — дип кычкырмый иде... Мин аның сәбәбен соңыннан гына аңладым. Җәй көне чоланга йокларга ятам. Төн уртасында сузып-ярсып, өзелеп-өзелеп көйләгән җыр ишетәм. Беренче тапкыр түгел инде. Сүзләрен дә ятлап бетердем.

Алма, диеп алган идем,
Йомарланган кар булды.
Сынар өчен сөйгән идем,
Эч өзәрлек яр булды.

Аңламассың бу олыларны... Нигә шуны кеше көлдереп, бала-чагаларны уятып, җырлап йөрергә? Беренче ике юлы әле кызык. Сәлимҗан абый, алма ашыйсы килеп, агачка үреләә, алма дигәне бер йомарлам кар булып чыга...

Соңгы юллары бөтенләй адәм көлкесе, кеше аңламаслык! Йөрисең дә инде, Сәлимҗан абый, таң әтәчләрен, тавыкларны көлдереп!..

Икенче төнне ул акрын гына, мин генә ишетерлек итеп, тагын җырлап уза:

Бөреләнеп чәчәк аттым,
Атмаган булыр идем.
Болай көтәреңне белсәм,
Кайтмаган булыр идем.

Аның иркә-йомшак тавышы мине иркәли, тагын йокыга талам. Һәм төшемдә ап-ак чәчәк аткан алмагач күрәм: мин, сокланып, аңа үреләм, тик буем җитми...

Өлкәннәрнең мөнәсәбәтләрен аңларга тырышып, төштә алмагачларга үрелсәм дә, берни дә төшенмәгәнмен икән ул чакта... Сәлимҗан абый күршебез Сәкинә апаны яраткан, җырларын аның өчен җырлаган икән, иртән торгач, Сәкинә апаның күзләрендә яшьләр күрсәм дә, игътибар итмәгәнмен икән. Яратканмы Сәкинә апа Сәлимҗан абыйны, әллә кызганып кына елаганмы,— монысы минем өчен табышмак иде. Сәлимҗан абый көндезен районнан почта ташып йөрде дә бердәнбер көнне авылдан китеп югалды. «Бөтенләй кайтмыйм»,— дип киткән. Төннәрен чоланда йоклыйм. Юк, йокламыйча, төн уртасы җиткәнне һәм, сизелер-сизелмәс кенә, бер аягы белән атлап, Сәлимҗан абыйның килүен һәм ипләп кенә, ягымлы тавыш белән җыр башлаганын көтәм. Ләкин ул килми, җырламый... Үзем дә сизмәстән, авыз эчемнән генә, әллә кая еракка киткән, күкрәгендә саф мәхәббәт йөрткән моңлы абыйның җырын көйлим:

Алма диеп алган идем,
Йомарланган кар булды...

Хәзер инде мин бу сүзләрнең мәгънәсен, үзәк өзгеч хисен аңлыйм... Сәлимҗан абый артыннан барасы: «Мин сине аңлыйм, абый, әйдә, кайтабыз, авылга кайтып дөрес эшләгәнсең»,— дип әйтәсе килә.

Әмма ул киткән юлларда карлы җилләр генә сызгыра...

Әгәр минем әсәрләремдә лирик моң, тыштан әллә ни кычкырып тормый торган эчке бер өзгәләнү, янулы сагыш бар икән, барысы да авылдашым Сәлимҗаннардан...

Чын матурлыкны аңлый башлавым да авылым белән бәйләнгән.

Бала чакта колхозның яшелчә бакчасына кыяр урларга бардык.

Бакча каравылчысы без көлеп йөргән, ямьсез генә, күрер күзгә күрексез генә тол хатын. Хәтта исемен дә белмибез: «Закир хатыны»,— дип кенә йөртәбез.

Кыяр түтәлләренә Гәрә елгасы аркылы кердек. Корсакларга, күлмәкләргә тутырдык. Шул вакыт Закир хатыны килеп чыкты да, кычкырып, безнең арттан куа башлады. Без, эре кыяфәт белән, аннан көлә-көлә (барыбер тота алмый!) әкрен генә йөгерәбез, елга аша чыгабыз да теге як ярда ятып, тел күрсәтеп үчеклибез: янәсе, тотып кара! Шулчак Закир хатыны яр буена килде, суга керде... су тирәнәя, ул... күлмәк итәген күтәрә, су тирәнәя бара, ул тагын күлмәген күтәрә төшә... Менә ул... күлмәген бөтенләй салды. Без телсез-өнсез катып калдык... Алдыбызда... кем? Искиткеч гүзәл кыз сыны басып тора иде. Ул һаман килә. Без, аңга килә алмыйча, һуштан калып, аның ап-ак, түгәрәк алма кебек тыгыз күкрәкләренә, кечке эңгер-меңгердә кара-кучкыл булып күренгән, сихерләп алган тез тирәсенә карыйбыз. Курку катыш оялудан тән сизелер-сизелмәс дерелдәп куя. Без, кадакланган кебек, ярга ябышып катканбыз: качу, йөгерү уебызда да юк. Алдыбыздагы шәрә могҗиза үзе дә оялутартынуны оныткан, ул һаман без яткан ярга таба якынлаша иде. Менә ул кинәт реаль тормышка кайтты булса кирәк, үзе дә, ни эшләгәнен сизеп, айныды, оятыннан кызарып (битен бик якыннан күрмәсәк тә, шулай тоелды), тиз генә күлмәген киярգә тотынды. Ул нишләптер үзе дә ни өчен бу якка чыкканын онытты, башын түбән иде дә, елга буйлап, әкрен генә кояш баеган якка, кичке эңгергә кереп югалды...

Беребез дә дәшми. Күз алдыбызда һаман гүзәл сын. Әллә нишләтте ул безне. Кинәт без дөньяның яшерен, олыларга гына билгеле ягын күреп калдык шикелле, шунлыктан күңелдә егетләргә генә хас татлы-кайнар җилкенү дә, балачакның иң тәмле, яшерен бер сере ачылганнан соң була торган билгесез бер бушану хисе дә туды.

Әкрен генә, башны түбән иеп, кузгалабыз. Кая барабыз, үзебез дә белмибез. Кая ул бер-беребезне үчекләп кычкырулар, төртешүләр, көтмәгәндә кызык ясап аяк чалулар, исемне бозып эндәшүләр... Бик авыр, хәл итә алмаслык сорау алдында калган сыман, салмак, эре адым-

нар белән атлап барабыз. Соңыннан гына аңладым: балачак белән моңсу саубуллашу булган икән бу серле кич...

Икенче көнне дә, өченче көнне дә, аннан соң да без бу хакта бер-беребез белән сөйләшмәдек. Исәнләшкәндә дә, элекке кебек, корсакка төртеп түгел: «Сәлам, яшьтәш!» — дип кенә очрашабыз. Күзләрдә — үзебез дә белмәгән, беркем дә аңлата алмаган серле моң... Төнлә, клубтан кайтканда, бөтен урамны уятырлык тавыш белән кычкырып түгел, үзем дә сизмәстән, йөрәк белән серләшеп, үзем белән сөйләшеп, Сәлимҗан абый кебек җырлап кайтам. Хәзер безнең өчен Закир хатыныннан да гүзәл кыз юк. Үзебез аның белән очрашудан оялабыз, куркабыз, үзебезнең тизрәк аны күрәсебез килә...

Башка без бер тапкыр да кыяр урларга бармадык. Беребез, физкультура укытучысы Гамил абыйның өенә баргач, китап эченә яшереп куйган немец «трофее» — шәрә кыз рәсемен чәлдереп кайтты. Аннан соң без, берничә елдан, унҗиде яшькә җитеп, кыяр кебек өлгергәч, колхоз айгырына салып, Закир хатынының үз кызын — Гөлзифаны дустыбыз Фәндүскә «урлап» кайттык. Күрер күзгә әллә ни чибәр булмаса да, дустыбыз аны сайлады. Ни өчендер (үзара килешеп эшләгәнне белгәндер, бәлки) Закир хатыны сизсә дә, куа чыкмады. Соңыннан әйттеләр, капка төбенә чыгып, кызы киткән якларга бик озак карап торган да, елыйсы урынга, җырлап җибәргән:

Үзәкләрем өзеләдер
Таң белән җырласалар.
Нихәлләр итеп түзәрсең,
Бәхетеңне урласалар?..

Бу җырның мәгънәсен мин үсә төшкәч, кайгы-хәсрәттән күбрәк авыз иткәч кенә белдем: Закир хатынының бәхетен сугыш урлаган, аның ире Закир сугышта һәлак булып, ул кызы белән генә тол калган, аннан соң беркемгә дә кияүгә чыкмыйча картайган икән...

Аннан соң мин илебезнең төрле музейларында, галереяларында дөньяның мәшһүр рәссамнары иҗат иткән бик күп гүзәл кыз рәсемнәрен, су коенучы чибәрләрне, шәрә алиһәләрне күрдем. Шул вакытта һәрчак минем күз алдыма үзебезнең авылның мадоннасы — Закир хатыны килеп баса, һәм, матурлык турында әсәр язганда, тышкы һәм эчке балкышы белән, героиняларымны тудыруда катнаша...

*1974—1982*

# Сагыну булган икән...

Бишенче классны тәмамлагач, безне, әйбәт укыган өч малайны, пионер лагерена җибәрделәр. 1945 елның җәе. Сугыш яңа гына тәмамланган айлар. Кайберләребезнең этиләре әле өйләренә кайтмаган да. Өйдә ашаганыбыз: черек бәрәңге «күмәче», бәрәңге һәм сирәк-мирәк кенә эләккән умач. Менә хәзер ул елларны искә төшерәм дә, әле халкыбыз сугыш авырлыкларыннан арынып өлгермәгән вакытта, пионерлар өчен лагерь ачарга ничек хәлләреннән килде икән, дип уйлап куям. Лагерь Ямады авылыннан кырык биш чакрым ераклыкта: Ташлы Елга дигән авылда. Анда барып җиткәнче әле Яңавылга кырык чакрым барасы. Безне, печән салынган атлы арбага утыртып, Зиннәт бабай алып китте. Ул, арык атны куа-куа, безгә борылып карамый гына: «Саубуллашыгыз туган җирегез белән, озакка китәсез бит...» — ди. Ә безгә ни... Ямадыны ташлап китү сөенеченнән башлар күккә тигән. Тәмам туеп беткән идек Мүксазыннан да, Тәкә төбәгеннән дә, Гәрә суыннан да, әрәмәсеннән дә. Урман-нарын күрәсе дә килми, утынга барсаң — каравылчы чанаңны чапкалап, балтаңны алып кала. Әй, безнең авылның аның сандугачлары да бака кебек сайрый, чишмәсе дә Ханнан исемле генә... Бездәге кебек тәмсез кузгалакны дөнья бетереп эзләсәң дә табалмассың... Гәрәсен әйтер идем, үрдәк чумарлык та суы юк. Шулай инде, Зиннәт бабай, саубуллашмыйбыз без Ямады белән... «Кайсы авылдан?» — дип сорасалар, әйтергә оят: Ямады... Җисеме дә исеменә туры килеп тора. Юк, саубуллашмыйбыз без, Зиннәт бабай!

«Рәүф, сине анаң әнә тегендә, Тәкә төбәктә, арыш урган җирендә тапты...» Зиннәт бабайның бу җөмләсенә дә без артык игътибар итмибез, Рәүф хәтта «шулаймыни?» дип тә сорамый... «Тәкә төбәктә туган нәрсә» дип, теңкәгә тиярләр инде болар, дип уйлыйдыр инде. Их, әниләр, әниләр, берәр җүнлерәк урын тапмадыгызмыни соң безне дөньяга китererлек?.. Шундый да ятышсыз җирдә тудыргансыз безне, «туган җир» дип әйтәсе дә килми.

Без бу уйларны кычкырып әйтмибез. Зиннәт бабай да бездән җавап көтми, әкрен генә ат юырткан уңайга үз уйларына бирелеп, талгын гына көйләп барган була:

Ераклардан күренә, диләр,
Ысперлау дигән кала.
Илен ташлап читкә китә
Мени бәхетле бала...

Свердловскины әйтәдер инде «Ысперлау» дип, алып китүче булса, ераклардан гына күренеп торган әллә кайдагы калаларга китәр иек әле, бездән дә бәхетле кеше булмас ие...

Атны ял иттерә-иттерә, ашата-ашата, көне буе барсак бардык, кояш баерга өлгергәнче килеп җиттек Ташлы Елгага. Ташлы Елга! Һәй, булса да булыр икән табигатьнең асыл почмагы! Яр буйлары таш та ком гына. Ә сулары!.. Монда инде аптыраган үрдәк кебек, «чумыйм микән, чуммыйм микән» дип икеләнеп тормыйсың, туп-туры яр башыннан йөгереп килеп, зәңгәр тирәнлеккә сикерәсең... Бакалар монда бөтенләй юк, ә сандугачлары, валлаһи дип әйтәм, зурнәй әйтмешли, «оҗмах кошларың бер як читтә торсын!» Монда инде Ямадының сәләмә җилендә дә бөгелергә әзер торган кәтүк җебе нечкәлегендәге мескен зирекләр юк та юк, бездәге әче кузгалак урынына тугайлардан кочагың белән юа умырасың. Монысы әле юмарт табигать үзе биргән бүләк-ризыклар... Без, дүрт ел буе черек бәрәңге кәлҗемәсе кимерергә мәҗбүр малайлар, монда — лагерьда көненә өч тапкыр, Ямады ишетсен өчен кабатлап әйтәм, көненә өч тапкыр ботка ашыйбыз!

Шундый рәхәтлектә өч көн узды, бер атна узды... Унынчы көн дигәндә, без бер-беребездән ояла-ояла гына, Ямадыны искә төшердек. Анда да исеме белән атамыйбыз: «Тегендә, дибез, нишлиләр икән?» «Тегендә бу вакытта Гәрәдә коеналар микән, әллә Җырка урманында җиләк җыялар микән?» Унберенче көнне беребез, кыюланып: «Ямадыда хәзер нишләп яткан булалар икән?» — дип тә җиффәрде. Уникенче көнне мин Рәүфнең күзләрендә олыларга гына хас бер мөлдерәү, түгелер-түгелмәс мөлдерәү тойдым, «Тәкә төбәккә торналар төшкәндер инде»,— дигәндә, аның тирән күзләрендәге йөгерек дулкыннарыннан бер тамчы чайпалып түгелде дә сыман...

Тәкә төбәге... Зиннәт бабайның ата-бабаларыннан ишетеп сөйләвенә караганда, борын-борын заманда кыр тәкәләре сугышырга шунда җыела торган булганнар... Тәкәләрнең дә шушы төбәктә туып-үскәннәре... Үлә икән — үзенең туган җирендә җан бирә.

Унөченче көнне мин һәрвакыт авыз ерып көлеп йөргән Зинирның, бездән качып, ямьсез тавыш белән җырга охшаган авазлар чыгаруын ишеттем:

Илен ташлап читкә китә
Мени бәхетле бала...

Ә мин үзем... Мин үземме? Бишенче көнне үк, йоклап китәр-китмәс, үзебезнең ишегалдындагы ямь-яшел чирәмне төштә күрдем. Төш микән әле бу, әллә күңелдәуйда туган хыялмы? Әнкәй күпереп торган йомшак чирәмне аска ястык итеп җәйгән, ә безнең өй өстендәге мамык-мамык болытларны юрган урынына япкан... Җанны иркәләгән бу җылылык әллә әнкәйнең кулларыннан, әллә чирәм-ястыктан, әллә мамык-болыттан?.. Салкыннан җиңелчә генә калтырап уянып китсәм, бар рәхәтлек шул мизгелдә үк югалды. Өстемдәге ачылып киткән одеялга төренсәм дә, кабат йоклап шул рәхәтлеккә кайтырга теләп, күпме генә күзләремне йомсам да, барыбер төне буе йоклый алмадым. Нигә соң әле, нигә шулкадәр дә гүзәл күренгән Ташлы елга буйларында йөргәндә, ярларында тал-тирәктән башка берни дә үсмәгән Гәрә елгасы күз алдына килә? Әллә инде хыялыйланам, зурнәй әйтмешли, Алла сакласын... Нигә әле мин, күзләремне йомсам, үләннәр арасында күмелер-күмелмәс яткан Ханнан чишмәсенең челтерәүләрен ишетәм. Һич тә арттырып әйтмим, бакчадагы көнбагышны каргадан саклау өчен куйган карачкыга кадәр ягымлы, хәтта шул без куып интеккән каргаларга кадәр матур тоела башлады түгелме соң? Тора-бара мондагы ботканың тәме кимеде, тегендәге үзебезнең «кәлҗәмә» белән умач берни белән дә алыштыргысыз икән ич! Ә киртә буенда үскән япь яшь, ямь-яшел кычытканнан пешерелгән аш — телең йотарлык бит. Мондагы урам тулы бозаулар бигрәк кыяфәтсез инде, менә безнең бозау, әнкәсенең көтүдән кайтканын көтеп, бер мөгрәсә, түзәлмичә бу якның барлык сыерлары чабып килерлек!

Ташлы Елганың һәрбер сандугачы, каены, чишмәсе котсыз булып күренә башлаган, Ямадының беренче очраган карачкысын кочаклап еларга җитешкән өч малайга ни кала соң? Бергә очрашырга да, күз яшьләренә, җебегәнлеккә бирелмичә генә, егетләрчә: «Туган җирне сагындым!» — дип әйтеп салырга! Юк, әйтмибез!

Мин аны бүген, илле яшьлек ир булып, туган җирнең,

сагынуның ни икәнен аңлагач әйтәм. Ул вакытта әле без, беренче тапкыр туган авылыннан аерылган өч бала, бу халәтебезнең сагыну дип аталуын күңелебез белән тойсак та, бөтен тирәнлеге белән аңламаганбыз. Юк, дөрес әйтмәдем, без аны әле балаларча тагын да, бүгенгедән дә тирәнрәк, авыррак тоймадык микән әле?

Башта кем әйтте безгә качып китү турында? Өчебез дә берьюлы әйтмәдек микән әле. Әйе, без, кайтып китәргә ике генә көн калгач, лагерьдан Ямадыга.. качып китәргә ниятләдек. Кыю планны тормышка ашыру өчен, таң беленер-беленмәс эңгер-меңгер вакытны сайладык. Уяна алмаудан куркып, чиратлап йокларга сүз куешкан идек, беребез дә йокламаган... Тотып алсалар? Арттан эзләп килсәләр? Авылга хәбәр итеп, кире китерсәләр? Әмма качу нияте күңелебезгә шулкадәр тирән урнашкан,— безне бу омтылыштан бернинди көч тә туктата алмас иде.

Тәрәзәне ипләп кенә ачып, бер-бер артлы сикереп төштек тә алны-артны карамыйча йөгердек. Иң алдан, мышный-мышный, физкультура дәресләрендә йөгергәндә иң арттан килә торган Рәүф чаба. Алга да чыкмыйча, артка да калмыйча, бераз батыраеп, бераз куркып уртадан йөгергәне — мин. Озын сыйракларын минем табаннарыма үк тидереп баручы Зинирның еш-еш сулыш алуын ишетеп барам. Әйтерсең без пионер лагереннан түгел, дошман әсирлегеннән, концлагерьдан качып барабыз. Кинодагы шикелле, менә хәзер безне этләр белән куа чыгарлар, тизрәк, кызурак, малайлар, туктамагыз! Этләр өстерсәләр, куркып калмагыз... Ташлы елгага керәбез дә су эченнән барабыз: овчаркалар суда кеше исен югалта. Әгәр куучылар су эченнән дә табарлар дип шүрләсәгез, авызга камыш кабабыз да, алар узганчы су төбендә сулап ятабыз...

Чаба торгач, Тәкә төбәктә туган нәрсә — Рәүф нәрсәгәдер абынып егылган икән, мин аның өстенә, Зинир минем өскә килеп өелештек. Кузгалырга кыймыйча, лагерь ягына колак салабыз... Тып-тын... Лагерь тирәсе тирән йокыга талган. Безне беркем дә кумый иде. Бераз гына күңелсез булып китсә дә, үзебезне: «Әле сизмәгәннәрдер, менә бераздан куа чыгарлар»,— дип тынычландырдык та, таш-комны шыгырдатып, кайтыр юлга ашыктык. Шул вакыт Рәүф, борынын мышкылдата-мышкылдата, әйтеп салмасынмы: «Малайлар, мин бит ыштанны онытып калдырганмын!» Колаклар үрә торды:

менә сиңа мә! Әңгер-меңгердә күзләребезне ачыбрак карасак: чыннан да, алдыбызда таңгы салкыннан дерелдәп ярым-шәрә Рәүф басып тора иде. Ерык авыз Зинир шаркылдап көләргә тотынган иде,— тиз туктаттым: «Уен эш түгел, бу кыяфәтсез авылга ыштансыз кайтып керсә, ояты безгә дә!» Нишләргә, моны хәзер ташлап китүе дә кызганыч, кырык биш чакрым бу ыштансыз карачкы белән кайту да күңелсез хәл! Ә? Карачкы? Бәладән котылдык, малайлар! Берәрсенең бакчасындагы карачкыдан ыштанын йолкып алабыз да Рәүфне шунда чумдырабыз. Шулай эшләдек тә: беренче очраган карачкының ыштанын салдырып, Рәүфкә кидердек. Гомере буе биюнең ни икәнен белмәгән малай, сөенечтән, биеп җибәрде. Читтән караганда Рәүф каргалар гына түгел, карачкылар үзләре куркып йөрәге ярылырлык кыяфәттә иде. Без юлны дәвам иттек.

«Яңавылга үзебез генә бер әләксәк, рәхәтләнеп, туйганчы карап йөрер идек» дип хыялланган малайлар, без, районыбызның мәшһүр үзәгенә әйләнеп тә карамыйча, тугач ук кендегебез бәйләнгән үзебезнең үзәккә элдертәбез. Кояш рәхимсез башны-битне пешерә,— барабыз, олы юлның тузаны тир катыш йөзләргә-күзләргә сылана,— барабыз, инде хәл дә калмады,— аяклар кыек-мыек атлыйлар,— барабыз... Беребез дә башлап: «Туктап ял итәбезме әллә?» — дип авыз ачмый. Бер елганы уздык,— туктамадык, юлда очраган авылның коесын карап киттек,— туктамадык, аннан арырак буралап куйган чишмә очрады,— туктамадык... Әлсерәдек, сусадык,— суларга чуммыйча, салкын чишмәләргә иреннәрне тидермичә, йөгерә-атлый, ава-түнә үзебезнең авылкаебызга кайтабыз.

Әз генә салкынча рәхәт җил исеп, тирләрне сөрткәндәй итте,— артка борылып карасак,— инде кояш, Зиннәт бабайның арбасындагы кылдый-былдый барган тәгәрмәч сыман, йокымсырап кына, без качып киткән чит якларга тәгәри икән ләбаса. Артка борылдык та, туктадык та... Зиннәт бабай дигәннән... Шул вакыт, кай урындадыр, тирәндә, башта сизелер-сизелмәс кенә, аннан бөтен тәнгә-җанга таралып, таныш бер көй тирбәлә башлады. Нинди көй бу, кайда ишеттем мин аны? Сандугачлы-кәккүкле Мүксаз буйларындамы, йөгерек дулкыннарында тирбәткән Кәшти тугайдамы? Әллә иркә куллары белән бишек тирбәткән әнкәемнәнме? Әллә Ханнан чишмәсенең чел-

терәвендә ишеттемме мин бу көйне? «Малайлар, туктагыз! Туктагыз!» Мин бу сүзләрне кычкырмыйча, яңа гына туып килгән көйне югалтудан курка-курка гына әйтәм. «Малайлар, Зиннәт бабай нинди көйне җырлады әле?» Шулчак мин бөтен барлыгыма әнә шул көйнең таралуын, үзәкләр өзгеч таныш дулкыннар агышыннан тәннең рәхәт сулкылдап куюын, күзләргә ихтыярсыз ачы да, татлы да кайнар яшьләр килүен тоям. «Малайлар, Зиннәт бабай нинди көй җырлый иде әле?» Көйнең беренче авазын-сүзен башларга да өлгермәдем, малайларым бер булып көйне күтәреп тә алдылар.

Ераклардан күренә, диләр
Ысперлау дигән кала...

Беребез дә элеккечә тамак төбе белән кычкырмый, әйтерсең лә без Гәрә буенда йокыга талган еламсар талларны уятудан куркабыз, беребез дә күзләрдән тамган тамчылардан оялмый,— әйтерсең лә без бер-беребезне күрмибез, беребез дә, олылар сәхнәдән озын көйләр суузганда кыланганча, авызын зур ачып, элеккечә иснәми, киресенчә, безнең авызлар шундый да көйле, күңел тирбәнешләренә тәңгәл килеп ачылалар. Җырның икенче өлешен малайларым үзләре башлыйлар:

Илен ташлап читкә китә
Мени бәхетле бала...

Ничек соң без моңа кадәр җырның сүзләренә игътибар итмәгәнбез? Якташларыбызның элек-электән бәхет эзләп Свердловск ягына киткәннәрен, күбесенең шунда калуларын да белә идек түгелме? Хәтеремдә: берсе, авылга кунакка кайткач, тальян гармунга кушылып, әче тавыш белән шушы көйне җырлады. Кызык өчен, кеше көлдерү өчен генә шашып-өзелеп җырламаган икән ул абзый. Димәк, без әле бәхетлеләр, без әле кечкенә генә инеше, чишмәсе булган, һәр төбәге үз исеме белән аталган үз илебезгә кайтып барабыз.

Зиннәт бабай да, безне илтә барганда, эче пошканнан гына көйләмәгәндер бу җырны. Ул бер дә үзе турында сөйләргә яратмый, шулай да аның турында: «Элекке герман сугышында немецларда әсирлектә интеккән»,— дип сөйләгәннәрен ишеткәнебез бар. Аның бердәнбер улы Хәбир сугышның беренче көннәрендә үк һәлак булган. Бәлки, ул да соңгы сулышларында безнең Тәкә төбәкне,

Ханнан чишмәсен, Кәшти тугайларын күз алдына китергәндер, өзелеп-өзелеп, әтисеннән ишеткән шушы җырны көйләгәндер...

Таныш көйне җырлап алуга, буй-сыннарыбыз тураеп, тәннәребез җиңеләеп китте, без, адымнарыбызны тагын да тизләтеп, йөгерә-атлый, юлыбызны дәвам иттек. Анда, авылыбызда, безнекеләр нихәлдә яталар икән? Әнкәй авырып егылмаганмы? Әткәй фронттан кайтып кермәгәнме? Акмуен, бозау, мескенкәем, мине югалтып мөгридер инде! Их, менә ишегалдындагы яшел чирәмгә ятып тәгәрәп-тәгәрәп ауныйсы иде! Ә авылдашлар? Бездән башка ничек яшәп маташкан булалар икән? Кемнәр сугыштан кайткан, кемнәр кайтмаган?.. Ә безнең турыда уйлыйлармы, искә төшерәләр микән авылдашлар? Бездән башка тагын да авырдыр тормыш йөген сөйрәгән әнкәйләргә, кибән куючы әби-бабайларга? Кирәк бит уттай кызу эш өстендә печән чабуны бөкрәеп беткән карткорыга, хатын-кызга, инвалид солдатларга ташлап, лагерьга китәргә? Малайлар хәзер, сызгыра-сызгыра, чыбыркыларын селти-селти, ат өстендә чүмәлә тарттыралардыр, эштән кайтканда, аттан төшмичә генә, Кәшти тугайга чабалардыр...

Иң алда тузан туздырып баручы Зинир уйны бүлдерде: «Әйдәгез, өйгә таң атканда, беренче әтәч кычкырганда гына кайтып керәбез!» Безнең әтәчләнгәнне, «юк! юк!» дип каршы әйткәнне дә көтмичә, аңлатып та бирде: «Анда безне лагерьга кире җибәрергә ат җигеп торалардыр. Ичмасам, туйганчы бер Ямадыны карап китәрбез!» Дөрес сүзгә җавап юк. Килештек.

Авылга якынлашкан саен, күкрәк эчендә «чыгарга мөмкинме?» дигән сыман, нәрсәдер, нидер күкрәк читлеген кага, әнкәй дә, еш кына кәефе киткән чакта: «Уф, йөрәгем!» — дип, барган җиреннән туктап кала. Йөрәк дигәне әнә шул тирәдәдер инде...

Үзебезнең Тәкә төбәккә җитәрәк, Зинир, әллә ни күргән кебек, кычкырып җибәрде: «Карагыз Тәкә төбәкнең каенын!» Әйтүе булды, әллә хәлсезләнеп, әллә аягы таеп, юл читенә ауды. Үзе һаман, беренче тапкыр күргән кебек, калкулык өстендә авылыбыз ягыннан искән кичке тын җилдә җилфердәгән ялгыз каенга йотылып карый. Карале, безнең Тәкә төбәкнең каены бармыни? Күпме шуннан узып, шунда уйнап, күзләребез күрмәгәнме, әллә күреп тә, ныклап карамаганбызмы? Баеп

барган кояш нурларында карт каенның җыерчыклары күренде инде әллә... Текәлебрәк карасам: шул ак каен, нәкъ әнкәем шикелле, түбәнгә таба мине эзләп төшеп килә: «Балам, кайттыңмыни, эзли-эзли арып беттем бит»,— ди. Озын чәчләрен туздырып бара-бара да тагын туктап кала: «Әй, бала, бала...» — дип, кулы белән сул күкрәгенә тотына. «Әнкәй!» — дип кычкырып җибәрәсе килә, әмма, хыял белән чынбарлык арасында икеләнеп, бу омтылыштан тыелып калам. Шулай да мин, шул хистән арына алмыйча, безне каршы алырга чыккан ак каеныбызга таба йөгердем...

Еллар узып, авылга кайткач, өчебез шуларны искә төшереп утырдык. Ул чакта ак каенны алар һәрберсе үзенчә күргән.

Зинир: «Мин, әллә ни күргән кебек, кычкырып җибәрдем: «Карагыз Тәкә төбәкнең каенын!» Адаштырылган эт өенә кайтып хәлсезләнеп егылган сыман, юл читендәге чирәмгә аудым да, Аккаенга карап, хәйран-вәйран калдым. Әллә саташам, әллә күзләрем, әлҗе-мөлҗе килеп, ялгыш күрәләрме? Бу бит минем әти! Тач үзе. Иртәгә сугышка китәргә дигән көнне безне әнә шул каен янына алып барды. Шаярып-көлеп бераз утыргач, футлярыннан скрипкасын алды да, Такташныкы кебек озын, таралган чәчләрен баш түбәсенә сыпырып куйды да смычогын сызып җибәрде. Озын, бик озын көй уйнады әти, әмма ул чакта мин көйне аңлап җиткермәгәнмен. Аккаен түгел бит бу, минем әти! Башын чайкый-чайкый, чәчләрен җилдә туздырып, «Карурман» көен өздерә.

(Күптән түгел мин Казанда рәссам Зинир Гариповның шәхси күргәзмәсен карадым. «Минем әти» исемле портретта ул үзенең скрипка уйнаучы әтисен Аккаенга охшатып ясаган.)

Рәүф: «Тәкә төбәктәге Аккаенны күргәч, сезнең арттан мин дә юл читенә егылдым. Әнкәй гомерем буе: «Мин сине Тәкә төбәктә таптым»,— дип тукыса да, сүзләрен колак яныннан уздыра торган идем. «Юньле бала шунда тумыни?» — дип кимсендем дә әле. Ә хәзер... Тәкә төбәкне, аның Аккаенын алыштырып куйганнармыни? Әткәй лобогрейкада арыш урган, әнкәй көлтә бәйләгән кырлар... Аккаен миңа шул чакта әнкәй урагы белән учламнарны җыеп, иелә-иелә көлтә бәйләгән шикелле тоелды. Гүяки мин менә хәзер генә шушы әнкәйдән өзелеп төшкәнмен,

әле урак белән көндегемне дә кисеп өлгермәгәннәр. Менә хәзер, хәзер кендек әби килә дә... Мин кычкырып елап җибәрәм...»

(Моннан берничә ел элек яшьлек дустым илле еллык юбилеена Ямадыга чакырды. Гомере буе туган җирендә иген үстергән агроном Рәүф хөрмәтенә һәм аның кайтмый калган әтисе хөрмәтенә, әле дә исән әнисе хөрмәтенә тостлар күтәрдек.)

Тукта әле, мин балачакта күргән Аккаен турында сөйли идем ич... Әйе, Аккаеныбызга таба йөгердек... Аккаен төбендә шундый да җайлы, шундый да җылы. Бу инде үзебезнең өй, үзебезнең җир. Тынычланып, көне буе уйнап арыган сабый баладай изрәп йокыга талабыз. Уяулы-йокылы, Каенның җил уңаена ипле генә тирбәлүен, әнкәебезнең баштан иркәләвен, бишегемне тирбәтүен тоеп ятам...

Әллә төш, әллә өн... «Балам, тор, таң ата...» — дип, әнкәй минем тузанланып беткән чәчләремне, битләремне сыйпый. Күзләремне ачам,— әнкәй түгел икән, таңгы җилдә яшел яфраклары белән иелеп, Аккаен мине уяткан. «Малайлар, торыгыз, Ямадыда таң ата!»

Әллә соң адашып чит җиргә килеп чыктыкмы? Алай дисәң, әнә һәрбер сукмагы безгә таныш Мүксаз буе урманнары. Саз һәм мүктән гыйбарәт бу урыннар хәзер әкияттәгедәй сихри гүзәл манзараны хәтерләтеп күренәләр. Әйтерсең лә илаһи бер даһи рәссам Мүксаз буйларын без кайтуга исәпсез-хисапсыз төрле төсләргә буяп куйган. Ә Гәрә елгасы, «гомер буе күрмәсәм дә үкенмәс идем» дип, без төкереп киткән Гәрә елгасы, адәм карамаслык котсыз кыз биленә алып такса гүзәл булып күренерлек тасмамыни... Ә Ямады үзе... Әнә шулай тасмасыз да, илаһи рәссам өстәгән буяусыз да, бары тик шул килеш, сызылып-сызылып төтен чыгып торган морҗалары, тубыл башында чайкалган карга оялары, казык башына эленгән чүлмәкләре, җилкәсенә чыбыркы элгән көтүчесе, таңны хәбәр итеп сөрән салган әтәчләре белән, бары тик шул килеш, табигый килеш алдыбызда балкый.

Без, туган җиребезгә кайткан бәхетле балалар, дөнья тулы сөенечтән шашынып, йөгерә-чаба, хәзер инде кочаклап еларлык Ямадыбыз кочагына, бакалары да сандугач кебек сайраган Мүксазыбызга, диңгез кебек олыланган Гәрәбезгә, безне таларга көтеп торган ата каз,

күркәләребезгә, алардан да бигрәк, ишегалдының яшел чирәменә ташландык.

Ә безне, качакларны, кочак җәеп каршыламадылар. Мәктәптә дә, өйдә дә, урамда да тиргәделәр. Рәүфнең әнисе әле җитмәсә «оҗмах»тан качып кайткан баласын талчыбыгы белән сыйлаган да. Зинир белән мине, җәза урынына, арыш басуына билчән утарга җибәрделәр. Монысына гына түзәбез инде!

Зинир әтисенең үлү хәбәре килгән. Ә Рәүфнең әтисе тагын да катлаулырак язмышка очраган,— без анысын озак еллардан соң гына белдек: яраланган килеш фашист әсирлегенә эләккән. Концлагерьдан качкан. Сугыш ахырында, каты яраланып, госпитальгә кергән. Үлем алдыннан үзен туган авылына кайтарып күмүләрен сораган. Туган җиренә кайткан батыр солдатны бөтен авыл хөрмәт белән күмде.

Кайтканның икенче көнендә Зиннәт бабайны соңгы юлга озаттык. Аның кабер туфрагы да суынмаган иде әле,— орден-медальләр белән күкрәкләре тулган улы, хәбәрсез югалган Хәбир кайтып төште.

Без юкта Гарифулла бабайларның тәкәсе югалган. Күрше районның мәшһүр бер карагы урлап киткән икән, дип тә сөйләделәр. Бөтен әйләнә-тирәне, урман-тугайкырларны бетереп эзләдек, таба алмадык. Юкка гына анды исем бирмәгәннәрдер дип, Тәкә төбәген дә айкадык... Югалып кырык көн, кырык төн торганнан соң, таң атканда көч-хәл белән бәәлди-бәәлди, тузан-пычракларга буялып, тигәнәк-сырланнарга уралып, танырлык та төсе калмаган тәкәбез ишегалларына кайтып егылды. Атларның йөзәр чакрымнардан кайтуларын ишеткән бар иде: «аңгыра сарык» дип даны чыккан токым вәкиленең мондый каһарманлыгы кайбер абзыйларны гаҗәпкә калдырды. Ә безнең өчен бу бөтенләй гадәти хәл иде.

Менә шул вакыйгалардан соң без өчебез дә, сүз берләшкән кебек, язларын кыр казлары каңгылдашып, торналар торкылдашып кайтканда, һәр елны аларны каршы алырга йөгереп чыгабыз. Туган җир дип аталган изге туфрагы булган һәр бәхетле җан иясенең үз Әнкәсе, үз Аккаены, үз Төбәге бар бит!

*1984*

# Ачылмаган бер чәчәк

Аның турында язармын дип һич тә уйламаган идем. Беренчедән, ул миңа якыннан таныш түгел, икенчедән, кем әле ул шулкадәр телгә алып сөйләрлек: гап-гади артистка. Аның да әле шөһрәт казанмаганы, сәхнәгә кереп-чыгып йөри торганы гына. Үзләре телендә андыйларны эпизодик рольләрдә уйнаучы дип атыйлар бугай. Хәтерем ялгышмаса, бер тапкыр ул «Беренче театр»да ни акыллы, ни тиле асрау Биби ролендә күренде, анда да әллә ни хәтердә калмаган,— уенында тормышчанлык, табигыйлек җитмәгәндер, ахрысы... Шунысын гына әйтә алам, сүзсез рольләрне күп уйнады, әле «Галиябану»да, әле «Зәңгәр шәл»дә йөзе чалынды шикелле. Нишлисең, табигать сәләтне тамчылап кына тамыза шул... Роль бирмиләр дип, режиссерларны да гаепләргә ашыкмыйк. Ул үз хәлен үзе дә чамалаган булса кирәк, кайберәүләр сыман, төп рольләр таләп итеп, режиссерларның бугазыннан алмаган. Шулай да... шулай да... имеш-мимешләр ишеткәнем бар: янәсе, шул артистка грек трагедиясендә Ана образын уйнау турында хыяллана... Әй, андый буш хыяллар кемнәргә килеп кемнәрдән китмәгән...

Минем исә Шифа Таймасова белән танышлыгым урамда очрашканда баш кагып исәнләшеп китүдән узмый иде. Шифа апа белән якыннанрак, һич тә көтмәгәндә, больницада танышырга туры килде. Бер палатада ятучы иптәшләрем: «Күрше палатада артистка Таймасова ята»,— диделәр. Янына килеп йөргән берничә таныш артистны күреп, сөйләшеп тордым,— әллә ни танышлык булмагач, Шифа апага керергә җөрьәт итмәдем. Ә үзе ни өчендер бөтенләй күренми, ашханәгә дә йөрмәгәч, хәле бик шәптән түгелдер инде бичараның. Шәфкать туташларының берсеннән сорап карадым, кырыс кына: «Ята!» — дип кенә әйтеп куйды. Әллә ни каты авырмаган сырхау кызыксынучанлыгы белән аның палатасындагы хатыннарга сүз кушып карадым. «Артистка! Кыланып ята шунда! — диде диабет белән җәфаланган шактый юан хатын.— Улын көтә. Аңа ышансаң, беркеме дә юктыр әле...» Икенчесе, күрер күзгә мөлаем гына, кыска гына ханым кулын селтәде: хәле мөшкел, янәсе, сорап та тормагыз...

Якшәмбе көнне тәм-томнар, ризыклар күтәреп, авы-

руларның туган-тумачалары, дус-иптәшләре палаталарга кереп тула. Күреп-сорашып торам: ни өчендер Шифа апага хәл белергә беркем дә килми. Якыннары, бергә эшләгән ахирәтләре кайда соң, моңа кадәр күренгәлиләр иде ич... Хатыннар аша ачыкладым: артистлар гастрольгә киткәннәр. Ярый, алар китте дә ди. Гаиләсеннән берәр кешесе, һич тә булмаса, туганы юк микәнни мескеннең? Тегеләр аркылы белешеп торам: бар икән, бердәнбер улы бар икән. Ни өчен килә алмый? Командировкага киткән. Андый хәлләр дә була, әйе, кайтыр улы командировкадан, беркөнне килеп җитәр. Ялгыз кешене ташларга ярамый, авыру хатынның күңелен күрергә иде, тәм-томнар ашатырга иде... Ташламаганнар, чит итмәгәннәр, палатадашлары әллә ниләр биреп караганнар,— Шифа апабыз алмаган: «Минем берни дә кабасым килми, рәхмәт, борчылмагыз»,— ди икән.

Беркөнне коридорда, юк сүзне бар итеп, гәпләшеп утырганда, каршыбызга мәһабәт гәүдәле бер ханымның килгәнен күрдек. Гадәттә, үз дәрәҗәсен белеп кенә атлаган андый хатын-кыз очраса, ир-егетләр генә түгел, өлкән яшьтәге ханымнар да ихтирам белән юл бирүчән һәм артыннан карап калучан булалар. Кызыл бәрхет озын халаттан, билбавын биленең әле дә нечкәлеген белендереп торырлык кына кысып бәйләгән, аякларында — бизәкле йомшак чүәкләр, кыска кара чәчләрен шома итеп тараган, иреннәренә, битләренә шәфәкъ нуры сыман алсулык йөгергән, уйчан күзләренең куе каралыгы дулкын-дулкын кашларына да күчкән кебек. Әкрен сөйләшә, горур-килешле кыяфәте мәшһүр картинадагы Ермолованы хәтерләтә, әмма тормышчанрак, садәрәк, табигыйрәк. Якыннанрак карагач сизәсең: карашында ниндидер олы фаҗига кичергән кешенең серләре, газаплары яшеренгән... Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр. Шифа апага килүче берәр атказанган артисткадыр дисәң, нигә халат, чүәклердән... Яныбызга килеп җиткәч кенә ышандым: бу — Шифа апаның үзе иде. Без аның белән баш иеп исәнләштек, ул мине танып, бераз гына туктап торды: «Сезнең монда ятуыгызны белә идем, хәлегез ничек?» — дип сорады. Кемдер телефонга чакырган,— юлыннан бүлмәдем, артыннан гаҗәпләнеп-сокланып карап калдым. Кем әйтер аңа алтмышның теге ягындагы ханым дип? Аңарда авыруның әзе дә юк, киресенчә, бу юлы ул миндә

сәхнәдәгедән көчлерәк тәэсир калдырды. Кире әйләнеп килгәндә, ул, туктап, командировкадагы улы белән сөйләшүен, аның тиздән кайтачагын хәбәр итте, йөзенең тагын да кайнарланып-кызарып китүеннән мин аның сөенүен тойдым шикелле.

Болницада ятучы кешенең хәл-әхвәлләрен белсәгез иде сез! Озын төннәр буе йоклый алмыйча, тормышында кичергән иң татлы мизгелләрне күз алдына китерәсең, мәгънәсез-гамьсез үткән айларны-елларны кызганасың, шул чакта фәлән кешене ник рәнҗеттем икән дип, үз-үзеңне тиргисең, сине дошман күргән адәмнәр белән бәхәскә керәсең, гомернең аяусыз кыскалыгы турында уйланасың, газаплар-бәлаләр күрсәтсә дә, якты дөньяда яшисе килү хисе тагын да көчәя... Мөгаен, Шифа апа да, керфек какмыйча, газаплы да, тәмле дә уйларга чумып ятадыр, бердәнбер улы белән сөйләшүне хыялында дәвам итәдер...

Шуннан соң ул коридорда күренмәде. «Йөрәге нык авырып, стенага карап хәрәкәтсез ята»,— диделәр. Палатадашларым аның тагын бер тапкыр телефоннан сөйләшүен, тагын берничә көннән, коридорга чыгып, «улым күчтәнәче» дип, алмалар өләшеп йөргәнен күргәннәр. Мин үзем ул вакытта, температурам күтәрелеп, урын өстендә ятып калдым. Хәлем аруланып, дару эчәргә барганда, Шифа апаның артистларча ачык дикция белән, бөтен коридорга ишетелерлек итеп, телефон аша сөйләшкән чагына туры килдем.

— Улым! Дачадан мин яраткан гладиолус чәчәкләрен алып килә күр... ачылмаган булсалар да... Чәчәкләрнең ачылганын үз күзләрем белән күрәсем килә...

Шифа апа тагын нәрсәдер әйтергә теләсә дә, өлгермәде, яшь кенә шәфкать туташы аны палатасына алып китте:

— Күпме әйттем сезгә йөрергә ярамый дип... Хәзер кереп ятыгыз!

Караватыма мин дә кереп яттым. Сагындым, мин дә сагындым бакчабызның иркә гөл-чәчәкләрен. Күзләремне йомам: алдымда бер балкып, бер югалып, ал-кызыл гладиолуслар тирбәлә. Палатасыннан чыгып безгә каршы килгәндә, Шифа апаның төсе-кыяфәте, йөзе-иреннәре, халаты көзнең соңгы чәчәкләренә охшап яналар иде. Һәр кешенең үзенең сөйгән төсләре, яраткан чәчәкләре. Ни өчен ул гладиолус чәчәкләрен сорый? Нигә башка чәчәкләрне түгел? Мөгаен, моның ул үзе генә белгән берәр сере бардыр...

Бер атнадан артык чыкмагач, Шифа апаның хәлен белергә үзем кердем. Ул ятып тора, ачык кара күзләре түшәмгә караганнар. Тумбочка өстендәге вазада — ачылыр-ачылмас гладиолуслар... Шунда ук — ачылып куелган китап. Күзләрем, элеккеге профессиональ журналист үткенлеге белән, андагы хәрефләрне абайлап алды: грек трагедиясе...

Шифа апа мине тавышымнан таныды да торып утырырга теләде, көче җитмәгәнне аңлагач, күкрәк тавышы белән әйтте:

— Улымның командировкасын тагын озайтканнар... Әнә... чәчәкләр җибәргән... Тиздән үзе дә кайтып җитәр...

Без артыгын сөйләшеп тормадык,— шәфкать туташы, әдәплелек күрсәтеп тормыйча гына, чыгып китүемне таләп итте. Тыңламый хәлең юк,— Шифа апага исәнлек-саулык теләп, башны иеп, әмергә буйсынырга туры килде.

Хәзер өннәремдә, төшләремдә — гладиолус чәчәкләре... Таң атканда аларның ал таҗларында саф чыклар җемелди. Үзем дә сизмәстән, мин ул чәчәкләргә гашыйк була барам. Алар әле ачылып кына киләләр, алар әле, ачыла-ачыла, барлык яшерен төсләре белән балкырлар. Минем өчен хәзер Шифа апа үзе — ачылмаган бер чәчәк. Хәзер мин төшләремдә шул чәчәкләр арасында ниндидер үзем генә тапкан бер көйгә җырлап йөрим:

Бакчамдагы ал гөлләрем
Сиңа дип тартылганнар,
Зифа буеңны эзлиләр,
Сиңа дип ачылганнар.
Нәкъ үзеңә охшаганы
Һаман ачылмый әле,
Йөрәгемнең ярсулары
Шунсыз басылмый әле.
Син үзең дә минем өчен
Ачылмаган бер чәчәк,
Син ачылсаң, бар тирәмә —
Дөньяма нур сибәчәк.

Озаграк утырып бер сөйләшергә дигән ният белән, икенче көнне Шифа апа палатасына килеп кердем. Ни аяныч... Койкасы буш. Башка палатага күчергәннәрме, әллә... үзе больницаны ташлап качканмы? Шулай гына булсачы... Әллә күрше палатага кергәнме? Әнә бит гла-

диолус чәчәкләре, нинди хуш булып, тулышып ачылганнар да тәрәзәдән төшкән кояш нурына авышканнар. Әйтегезче, гладиолуслар, сезне яраткан, ачылуыгызны өзелеп көткән Шифа апагыз кайда?

Таң беленер-беленмәс, бернинди тавыш бирмичә, сызланмыйча, ярдәмгә беркемне дә чакырмыйча, ачылып килгән гладиолусларга карап, Шифа апа күзләрен мәңгегә йомган. Үлем алдыннан озын-озын монологлар сөйләгән, «Балалар... балам...» дигән сүзләрне еш кабатлаган...

Шул көнне кичен төсе-бите качкан, сакал-мыек баскан, күп эчүдән шешенгән утыз яшьләрдәге бер адәм коридор буйлап шаулап узды:

— Таймасова кайда монда?!

Бу — Шифа апаның баласы Рамус иде.

Бүлмәдәге хатыннарның әйтүенә караганда, Рамус беркая да командировкага китмәгән, шәһәрдә юлдан язып йөргән, бераз айный төшкәч кенә, дөньяда әнисе барлыгын исенә төшергән һәм... больницага әнисеннән акча сорарга килгән. Ана буларак Шифа апа барысын да эченә йоткан, кешеләрдән яшерергә тырышкан, «Улым командировкада», «Балам алмалар җибәргән», «Улым белән сөйләштем» дип ялганларга мәҗбүр булган һәм көн саен, өметләнеп, баласының килүен көткән...

Кайгы-хәсрәтен, фаҗигасен тышка чыгармаган артистканың соңгы сәгатьләрендә трагедиядәге Ана булып саташуын аңларга тырышам. Әле дә күз алдымда коридордан горур кыяфәттә, хатын-кыз дәрәҗәсен саклап, башын югары күтәреп үтүләре... Юк, Ермолованы хәтерләтмәгән ул... нәкъ үзе... артистка Таймасова. Аның үз холкы, үз фаҗигасе трагедия героинясы белән аера алмаслык булып кушылган. Шушы образны тудыру уе белән озак еллар янган Шифа апаның үзе хыялланган образын уйнарга иң өлгергән, иң тулышкан чагы... Режиссерлар да, башкалар да, минем уйлавымча, аның шушы илаһи халәтен тоймаганнар... «Кызганыч!» дип әйтергә телем әйләнми. Шифа Таймасова горур ханым һәм үзе хыялланган төп ролен уйнап киткән талантлы артистка булып күңелемә урнашып калды...

*1985*

# Алларыңа тезәр идем...

Туган якка туйга чакырганнар. Кайттым. Туй район үзәгендә буласы иде. Моннан безнең авылга кырык чакрым гына. Керергә туры килмәс, дип юкка курыкканмын, икенче көнне туй анда дәвам итәсе икән. Минем кебек, ерак шәһәрдән үз машинасында килгән Заһир авылдаш бигрәк тә шатланды:

— Болай булгач, бигрәк тә әйбәт, мин барыбер барасы идем. Менә кара...— Ул, «Москвич» ишеген ачып, чәчәк бәйләмен күрсәтте.— Әнигә... Иртәнгә кадәр сулмасыннар дип, суга салып куйдым...

— Гайния апа һаман авылдамыни?

Сорауны ник биргәнемә шунда ук үкенергә туры килде.

— Былтыр җирләдем бит...

— Шулаймыни?..— дип гаҗәпләнүдән артык сүз әйтүнең кирәге юк иде.

Әйе, Гайния апа да дөньядан киткән икән... Авыр туфрагы җиңел булсын. Әниебез сыман якын күрә идек без аны. Без дигәнем, сугыш чорында бәләкәй арба тартып утынга, саламга йөргән, печән вакытында чүмәлә тарттырган, урак өстендә ат белән эскерт өйгән чәкүшкә кадәр генә малай-шалайлар. Эт булып арып кайтабыз да, корсакны бәрәңге шулпасы белән тутырып, Гайния апага — аулак өйгә, кич утырырга йөгерәбез. Нигә Гайния апага дисәгез, ул һич тә ачулана белми, ачулану гынамы, үзе безне чакыра. Кечкенә чакта ук, әниләр кая булса да кунакка-мазарга кунарга китсәләр, безне Гайния апада калдыралар иде. Бер сөенеч иде анда бер кич кунулары! Ни өчен дисәгез, Гайния апа үзенең малае Заһирга тальян алып бирде, дөресрәге, башмак үстереп, аны тальянга алыштырды. Сугышта һәлак булган ире Бәхти гармунчы булгангамы, әллә инде үзе тыңларга яраткангамы, Гайния апа улы Заһирның да гармунчы булуын бик тели иде. Теләү белән генә түгел икән шул, Заһир, күпме генә көчәнсә дә, бер генә көй дә чыгара алмады. Ә менә мин... мин... миңа шул гына кирәк иде дә, кочаклыйм да гармунны, тартып җибәрәм күрүкне, үзеннән-үзе Гайния апа өйрәткән җыр агыла башлый.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,  
Алларыңа тезәм мин...

Үзем уйныйм, үзем талгын гына җил искәндә иркен болында уйлана-уйлана, иелә-иелә аллы-гөлле чәчәк җыеп йөрүче Гайния апаны күз алдыма китерәм. (Чәчәкләр ярата иде ул.)

Бик сагындым сине, бик сагындым,
Әле дә ничек түзәм мин...

Берчак бу гармунны мин түгелдер, Бәхти абзый үзе уйныйдыр кебек тоела... Ул да әнә шулай, ярсып тальян күрүген тарта-тарта, сугышка киткәндә соңгы тапкыр урам әйләнгән, диләр. Моң дулкыннарында тирбәлә-тирбәлә, Гайния апага карап куям, ул, күзләрен ярым йомган хәлдә, күкрәгенең иң тирән урыннарыннан әллә нинди серле авазлар чыгарып, җырлый-җырлый...

Гөл чәчәкләрен өзәм мин...

...Уйларымнан арынам. Капка төбенә каршыларга чыгабыз. Кияү белән кыз загстан язылышып кайталар. Бер-бер артлы автобус, аның артыннан җиңел машиналар тезелгән. Килен төшә! «Волга»дан туп-туры мендәргә сикереп төшә. Аннары кияүнең кулларында өйгә керә. Әйе, бөтенләй башка киленнәр, бөтенләй башка йолалар, ризыклар... Өй алдында мичкә-мичкә сыралар ачыла, ризык-шәрабның чиге юк. Нәкъ әкияттәге кебек, мыегым булмаса да, мин дә мыекны чылаттым, башкалар кебек, яшь чакны искә төшереп, минем дә ярсып-ярсып гармун уйныйсым, өзелеп-өзелеп җырлыйсым килеп китте. Бирегез әле, егетләр-кызлар, сандугач кадәр генә әнә теге бәләкәй гармунны!

Ихтирам билгесеннән генә, ультразаман көйләреннән тынып, яшьләр мине тыңлаган булалар.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин...

Элеккеге кебек үк шәптән булмаса да, ихлас күңелдән уйныйм-җырлыйм... Үзем күз кырые белән генә Заһирга карап куям: аңласа, ул аңлар, кушылса, ул кушылыр миңа...

Кушылучы юк. Күрәсең, Заһир күңелендә истәлекләр уятмады бу көй. Әллә, истәлекләргә бирелеп, йомшап китүдән, күңелле шау-шуны бозудан курыктымы...

— Әйдә, җибәр әле, яшьтәш, бию көен!

Теләр-теләмәс кенә бию көенә күчүгә, ул, әллә туган якка кайту тәэсиреннән, әллә шәраб шаукымыннан, ярсып биергә тотынды. Заман кешесе, хисләрен яшерә За-

һир, минем сыман беркатлы түгел... Дөрес эшли... Китте бию, ялгыз бию, парлап бию, кочаклашып-күмәкләп бию, сызгырып бию, кычкырып бию! Әйе, туй булгач туй булсын, гомергә сөйләрлек булсын! Мин дә, ниһаять, күңелле бәйрәм стихиясенә бирелеп, биючеләр ташкынына кереп югалдым. Төне буе шаштык, төне буе тост күтәрдек, килен белән кияү дә, көмеш, алтын туйлар, балалар, оныклар өчен дә. Без биемәгән бию, без җырламаган җыр калмагандыр...

Йоклап та тормыйча, икенче көнне, кияү белән кыз утырган машина артыннан кыр казлары кебек тезелеп, туйны килен өендә дәвам итәргә — безнең авылга киттек. Юлдагы маҗараларны, яңгыр явып тору сәбәпле, тайгак юлдан барган алдагы машинаның тайпылып юл читенә төшүен, куркырга да өлгерми калуыбызны, соңгы елларда бу якларда туган яңа гадәт артыннан куып, «бер яртысыз җибәрү юк!» дип, безнең колоннага аркылы төшкән тракторчы егетләрнең әрсезләнүен сөйләп тормыйм. Әмма һаман шулай тостлар әйтешә-әйтешә, төн уртасында бик күпләрнең ястык та сорап тормыйча түнүләреннән соң, Заһир белән икебезнең авыл кочагына ташлануыбызны сөйләмичә һич тә түзә алмыйм.

Һәр елны, авылыма кайткан саен, мин җиде төн уртасында, сыздырып гармун уйный-уйный, урам әйләнәм. Мондый гадәтемне авылдашларым да беләләр, минем уйнауны әллә каян таныйлар, уяна-уяна, тәмле төшләр күрә-күрә дә тыңлыйлар, икенче көнне: «Кем кайтып киткәнне ишеттегезме»,— дип, бер-берсеннән сорашалар икән. Гармунны әллә кайларда, әллә нинди хәлләрдә дә уйнаганым бар, әмма беркайчан да туган авылым урамнарында төнлә уйнап узган кебек уйналмыйдыр. Син монда үзеңне әнкәң бишегендә тирбәлгән кебек, саф челтерәү тавышын тыңлап чишмә янында утырган кебек тоясың. Үзең дә беләсең: сине әбиләр дә, бәбиләр дә, бабайлар да, малайлар да тыңлыйлар. Әйе, йокласалар да, күңелләре сизгер аларның, тыңлыйлар... Сине балачагың йөгереп узган урамнар, беренче мәхәббәтең кабынган тугайлар тыңлый, япаялгыз Ай, исәпсез йолдызлар тыңлый. Һәммәсе синең тылсымлы көеңә буйсыналар, уйна, уйна, тарт гармуныңның күрүген өзелгәнче, син монда — моңнар патшасы!

Минем янәшәмдә генә барган Заһир тыңлый-тыңлый да, түзә алмыйча, көйгә бик үк туры килмәгән тавышы белән, җырлап җибәрергә маташа:

Тар урамнарны киң итеп
Йөргән чаклар бар иде...

Гармунны туктатам, Заһирга инәлеп карыйм: зинһар өчен, кушылма, тын гына тыңлап бар... Тыңлый Заһир, җырламый. Аларның өй урынына җиткәч, гармун да, без дә туктадык. Кайчандыр безне Гайния апа күңел канаты астына җыйган аулак өй... Йөрәктә беренче тапкыр гармун авазы булып моң туган җылы бер урын. Бармаклар үзләреннән-үзләре гармунның иң кирәкле, иң үзәк өзгеч телләрен эзләп табалар һәм сабый чакта ук үз булган көйне уйныйлар:

Гөл чәчәкләрен өзәм мин...
Алларыңа тезәм мин...

Мин гармун уйнаудан аз гына туктап торган арада, Заһирның иреннәре миңа ишетелерлек итеп кенә пышылдыйлар:

— Иртән уяну белән зиратка барам... Ул чәчәкләр ярата иде...

«Мин дә синең белән барам, Заһир»,— дип әйтәсе килә, әмма төн шулкадәр тын, шулкадәр моңлы-сагышлы, шулкадәр шагыйранә, аны көйсез аваз чыгарып бозасы килми иде.

Күңелләр бушанганчы әнә шулай йөрдек-йөрдек тә, төн авышкач, янә дә туй табынына кайтып утырдык. Китте яңадан күңел ачу, шау-шу, бию, әйлән-бәйлән, шаян сүз, баян, оркестр... Үзебезнең урамда йөргәндә бераз йомшаклыкка бирелүебездән оялып, «заман кешеләре»нә әйләндек, бер-беребезгә ирләрчә тупасрак сүзләр әйтештек: «Мине ихтирам итәсеңме?» — дип, бер-беребезнең җилкәләренә суктык, ишегалдына чыгып көч сынашырга, чирәмдә тәгәрәргә тотындык.

Шул арада көн дә яктырган, безгә, кунакларга, тизелешеп кайтып китәргә дә вакыт җиткән. Һәм киттек тә. Бәйрәмнәрдән, мактаулардан баш әйләнгән, кәефләр бик тә күтәренке, җырлый-җырлый чыгып та барабыз кайчандыр без туган авылдан. Гаеп итмәгез, авылдашлар, көндез күрешеп тә булмый, без бит туйга — кунакка бер генә кичкә кайткан кешеләр...

Кияү яшәгән йортка кайтып, кәеф-сафаны тагын дәвам итә-итә, сәгатькә карыйбыз: инде шәһәргә — өйгә кайтып китәргә дә вакыт җиткән ич...

Заһирны машинасына озата барам. Кочаклашабыз. «Онытма, яшьтәш», «Хуш, авылдаш»...

Ул кабинасын ачып җибәрүгә, мин чәчәк бәйләмнәрен күреп калам һәм сораулы күзләр белән аңа карыйм.

— Заһир?..

Бераз гына сула төшкән ал чәчәкләрне күреп, Заһир башын чайкап куйды:

— Их, онытылган... зиратка барып килергә...

— Заһир, әле соң түгел бит... Машинаң белән генә барасың да киләсең...

— Юк шул, эшкә соңга калам... Ну ярый инде, икенче кайтканда...— Заһир, үзен озатырга килгән кияү егетне күреп, сөенгәндәй итте.— Карале, дус кеше, менә әнинең туфрагына салырмын дип, чәчәкләр алып килгән идем, туй белән мавыгып онытылган... Зинһар өчен, авырсынмый гына берәрсе илтеп салсын инде... Эшкә соңга калам...

Чәчәкләр калды. Заһирның машинасы, ярсып, тузан туздырып, кузгалды да, тиздән күздән дә югалды. Кияү егет, аптырап, әле кулындагы шиңгән чәчәкләргә, әле миңа карап тора...

...Ул чәчәкләр ярата иде...

Туйдан кайтуга инде күпме айлар узды... Мәҗлесләрдә сөйләгән акыллы һәм буш бихисап сүзләрне, ике төн буе җырланган чамасыз җырларны инде онытып бетердем. Әмма шушы бер җөмлә күңелемнең иң түрендәге бер почмагында урнашып калды. Ялгыз калган чакларымда мин кулыма гармун алам һәм туган авылымда өйрәнгән көйне уйныйм. Уйныйм һәм гармуныма кушылып карыйм:

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Алларыңа тезәм мин...

Ул чакны чәчәкләр турында Заһирның исенә төшермәүдә үземне дә гаепле саныйм. Нишләдек без, нишләдек без, егетләр?! Нигә, нигә бармадык без җырлы, моңлы яшәргә өйрәтеп калдырган Гайния апа янына?.. Ул безне, менә хәзер килерләр, менә хәзер килерләр... дип көткәндер, көткәндер дә, без исәнләшмичә дә китеп баргач, өметен өзгәндер...

...Ул чәчәкләр ярата иде...

Җәй көне авылыма кайту белән, мин болыннан ул яраткан чәчәкләрне өзәргә һәм аның алларына тезәргә уйлыйм...

Кайтам... Заһир кайтмаса да...

*1980*



# Сәхнә әсәрләре

# *Моңлы бала түгел идем...*

*Музыкалы водевиль*

КАТНАШАЛАР:

З и л ә й л ү к — студентка.
М и ң г о л — студент.
М и ң з и ф а — гармун фабрикасы директоры урынбасары.
М ө б ә р ә к — ире.
М и р з а — уллары.
Т у т а й — урынбасарның урынбасары.
Н ә ф и с ә, Ф и р д ә в е с, А й д а р, Г а з и н у р — студентлар.

Вакыйга безнең көннәрдә май аенда бара.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

### 1

Миңзифа һәм Мөбәрәк Аюхановлар квартиры. Иртә. М ө б ә р ә к, җырлый-җырлый, сакал кыра.

М ө б ә р ә к. Миңзифа! Тор! Сиңа әйтәм! (*Йокы бүлмәсенә барып.*) Миңзифа, уян, соңга каласың!

М и ң з и ф а (*күзләрен уа-уа чыга*). Ник кычкырасың, ни булды?

М ө б ә р ә к. Эшеңә соңга каласың, дим...

М и ң з и ф а. Төн буе керфек какмадым. Әле генә йоклап киткән идем.

М ө б ә р ә к. Син кайчан кайттың соң?

М и ң з и ф а. Мин кайтканда телевизор алдында йоклап утыра идең. Ярый әле янгын чыгармагансың.

М ө б ә р ә к. Синең һаман шул җыелыштыр инде?

М и ң з и ф а. Синең дүрт ягың кыйбла. Фабрика яна!

М ө б ә р ә к. Пожарниклар...

М и ң з и ф а. Банкротка әйләнәбез! Продукция үтми!

М ө б ә р ә к. Барсы да яна, син генәмени...

Миңзифа. Дөньяны менә синең кебек янмас-пошмас адәмнәр басты. Мирза кайда? Йоклыймы?

Мөбәрәк. Әллә... Кичә кайттымени ул?

Миңзифа. Ләх булып кайтты да караватка ауды.

Мөбәрәк. Әллә чынлап сала башлады инде?

Миңзифа. Укуын да ташлаган.

Мөбәрәк. Укыйм дигән була ич.

Миңзифа. Үзе әйтте, ник миңа баш катырып йөрергә, ди. Галимнәр — урам себерә, наданнар — тәхеткә менә, ди.

Миңзифа. Бар, уят үзен. Айнык баштан сөйләшеп карыйк.

Мөбәрәк. Мин аны!

Миңзифа. Хәчтерүш!

Мөбәрәк (*бүлмәгә кереп чыга*). Юк. Чыгып ычкынган.

Миңзифа. Бар! Эзлә! Тап!

Мөбәрәк. Табарсың печән кибәнендә энәне!

Миңзифа. Йөрәккә энә булып кадалды бу бала. Нигә генә таптырдың...

Мөбәрәк. Син таптың ич, мин түгел.

Миңзифа. Шул бала дип бармак та кыймылдатмадың. Харап була бит...

Мөбәрәк. Кыланмаган калмады. Университетка керттем...

Миңзифа. Керткәч чыгармаска иде.

Мөбәрәк. Мавыгып китмәсме дип, гитара алып бирдем, сез эшләгән гармунны да биреп карадым, әйләнеп тә карамады...

Миңзифа. Таптың продукция! Безнеке — юк инде ул... Син булдыклы ир булсаң, машина алып бир!

Мөбәрәк. Кара, гармун кая киткән? Менә монда иде. Юк. Берәрсе чәлдергәнме?

Миңзифа. Кемгә кирәге бар аның...

Мөбәрәк. Кичә генә күрдем: менә шушында иде. Әллә Мирза алып китте микән?

Миңзифа. Ниемә алсын ул аны. Уйный белми бит. Нерваларда гына уйный... Әллә югалтабыз инде баланы? Күздән югалтмаска иде... Бар, эзлә, тап!

Мөбәрәк. Күздән югалтмаска дисеңме? Менә шуны күз алдында тотып, мин бер нәрсә алып кайттым.

Миңзифа. Нәрсә ул?

Мөбәрәк. Хәзер күрсәтәм. (*Бүлмәдән бинокль алып чыга.*) Менә!

Миңзифа. Фотоаппарат?

Мөбәрәк. Юк.
Миңзифа. Пистолет?
Мөбәрәк. Алла сакласын!
Миңзифа. Аласы машинага радиоалгыч?
Мөбәрәк. Булмаганны әйтмә!
Миңзифа. Портмонет?
Мөбәрәк. Булмаган һәм булмаячак акчагамы?
Миңзифа. Кинокамера?
Мөбәрәк. Буй җитми.
Миңзифа. Әйтсәң әйт, әйтмәсәң...
Мөбәрәк. Бу аңа түгел, үзебезгә. Малайны күздән ычкындырмас өчен...
Миңзифа. Бинокль?
Мөбәрәк. Нәкъ үзе! Мирза әллә ни еракка китми, шушы тирәдә — студентлар йорты янында әйләнә. Тотабыз да нишләп йөргәнен бинокльдән күзәтәбез.
Миңзифа. Кая әле, кая... (*Бинокльне тартып ала да карый.*) Урамда лилипутлар йөри. Нәрсә алдың?!
Мөбәрәк. Теге ягыннан кара.
Миңзифа. Ой! Зурайдылар. Кара, әллә Мирза басып тора инде?
Мөбәрәк. Нәкъ үзе!
Миңзифа. Күздән ычкындырмыйк, карыйк...

## 2

Бинокль аша күренеш. Мирза ялгызы гармун янында басып тора.

Мирза. Әй! Тукта! Гармун сатам! Аласыңмы? Һей, абзый! Гармун ал! Гармунны очсызга сатам! Бәясе — бер ярты! Кемгә гармун кирәк?.. Алыгыз! Сәлам дә бирмиләр... Йә, кемгә кирәк инде бу бабайлар гармушкасы? (*Гармун өстенә утыра. Зиләйлүк узып барганны йотылып күзәтә.*) Әй, гүзәл, кил әле монда!
Зиләйлүк. Ни кирәк, абзый кеше?
Мирза. Мин кеше, но абый түгел. Сез минем сакалга карамагыз. Бу мода гына.
Зиләйлүк. Карт кеше дип торам. Сез, чыннан да, яшь егет икән.
Мирза (*гаҗәпләнеп, сокланып карый*). Әйе, туташ, мин яшь.
Зиләйлүк. Әллә сез гармун уйныйсызмы? Ачуланмагыз, сезгә бирергә бер тиен дә акчам юк. Стипендия бирмәделәр әле.

Мирза (*уңайсызланып*). Мин хәерче түгел.

Зиләйлүк. Алай булса, сез гармунчы? Уйнагыз әле бер көй. Мин гармунны яратам.

Мирза (*каушап*). Сез... яратам дидегез.

Зиләйлүк. Лекциягә ашыксам да, берәр көй тыңлап китәр идем.

Мирза. Их туташ, мин гармунчы түгел шул...

Зиләйлүк. Алайса, сез аны сатасыз?

Мирза. Сатарга уйлаган идем дә. Кирәк булса, мин аны сезгә бушлай бирәм. Алыгыз...

Зиләйлүк. Юк... юк. Минем үземә кирәкми. Минем бер дустым бар. Ул әйбәт гармун эзли. Әмма ул студент, аның да акчасы юк. Әнә ул үзе дә килә. Миңгол!

Миңгол. Зиләйлүк!

Зиләйлүк. Мин сине төне буе борчылып көттем. Кайда югалдың?

Миңгол. Төне буе пристаньда йөк бушаттым. Киттекме?

Зиләйлүк. Менә... гармун сата.

Миңгол. Кая, карап карыйк әле.

Мирза (*күзләрен Зиләйлүктән алмыйча*). Гармуны әлләни түгел. Үзебезнең Казан фабригының хромкасы гына.

Миңгол (*гармунны ала, уйнап карый*). Зиләйлүк, синең тавышыңа туры килсә, алам.

Зиләйлүк. «Иртән җырлаган кеше бәхетсез була». Дәү әни сүзләре.

Миңгол. Моңлы була дип әйтергә теләгәндер ул. Әйдә, җырла инде мин әйткәч. Ашыкма, вакыт бар әле...

Зиләйлүк (*җырлый*).

Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Гомерем җилләр кебек искәнгә.
Җаннарымда сайрар сандугачым
Исләремә килеп төшкәнгә.

Миңгол. Күпме сорыйсың?

Мирза (*әллә нишләгән, аңламый тора*). Нәрсәгә күпме сорыйм?

Миңгол. Гармунга.

Мирза. Әллә әйбәт гармун?

Миңгол. Шәп. Мин аны алам. Әйт бәясен.

Зиләйлүк. Миңгол, синең акчаң юк ич...

Миңгол. Гармунга җитәрлек эшләдем. Нигә телсез калдың?

Мирза. Мин аны сезгә бушлай бирәм. Алыгыз.

Миңгол (*кесәсеннән акча чыгарып*). Азсынмыйсыңмы?

Мирза. Юк, кирәкми...

Миңгол (*аның кесәсәнә салып*). Сагынмассыңмы гармуныңны?

Мирза. Гармунны сагынмам. Әмма...

Зиләйлүк. Сау булыгыз.

Миңгол. Рәхмәт.

**Китәләр.**

Мирза. Зиләйлүк...

## 3

**Гармун фабрикасының ишегалды. Уртада — табут. Директор урынбасары Миңзифа һәм гармун ясау осталары.**

Миңзифа (*кәгазьдән укый*). Таваришши, иптәшләр, әфәнделәр, ханым-туташларым, гомер буе гармун ясаган осталарым минем! Мин сезне бүгенгесе көндә җыйдым шуңа ки, директорыбызның хәле фабрикабызныкы шикелле неважный — йөрәгендә кризис. Әлегесе вакытта больницада. Рәхмәт. (*Тутайга.*) Тутай, син нәрсә бутыйсың мине? Шуңа карамастан без яшәргә тырышабыз. Тырышабыз гына түгел, аяк сузасы урында шактый уңышка ирештек дип уйлыйм. Мин моны директор урынбасары буларак әйтәм. Кыска сүзнең озыны шул: без мөшкел хәлдән чыгу өчен, гармун ясауны туктатып, бүгенге көндә иң актуаль проблемага әйләнгән продукция чыгаруга күчәбез. Сынатмадык, иптәшләр! (*Кул чаба.*) Оркестр! Халкыбызның аңы, тамагы тук булмаса да, соңгы айларда бик үсте. Ишеттегезме оркестрны? Кемгә кирәге бар гармунның — социализм калдыгы ул! Ә табутсыз бер адәм баласы да яши алмый һәм дә яшәмәскә тиеш! Фабрикабызның беренче продукциясен чыгару приз... приз... Тутай, нәрсә яздың син? Нинди приз?..

Тутай. Призентация. Рәхмәт.

Миңзифа. Призентациясен ачам. Оркестр! Кем сөйли?

Тутай. Рәхмәт. Бирегез сүз миңа!

Миңзифа. Яңа гына билгеләнгән урынбасарым Тутай Бурундуков сүз сорый. Озынырак сөйлә!

Т у т а й. Рәхмәт. Кимчелегем бар бердәнбер: сөйли алмыйм озын. (*Укый.*) Без осталары гармун теленең, түгел телнеке. Рәхмәт. Сүләрмен аз һәм дә эшлекле сүзләр. Беренче: котлап куярга кирәк урынбасарыбыз Миңзифа Касыймовнаны директор вазифаларын алып баруы белән... вакытлыча булса да... әлегә... Шулай ук үземне дә минем. Рәхмәт. Нигә дисәгез, яңа хуҗа килү белән бу постка, уйлый башлады кризиска крес сугу турында. Хәлбуки үзебез почти ярты ел алмасак та хезмәт хакын. Безнең илебездә бар күрмәүчеләр акчаның төсен почти өчәр ел и күбрәк тә. Рәхмәт аларга! Акчасыз яшәгәнне, гармунсыз яшәрбез, Алла бирсә — табутка, чират торучы картлар әйтмешли. Хуҗабикәбез әйтте бик тә төгәл-конкрет — табутсыз яшәү бүгенгесе көндә яшәү түгел ул! Эшенә карагыз безнең осталарның, кемдер әйтмешли, гармуныңның анасын орып бирә. Гафу итегез, Миңзифа Касыймовна. Тагын бер карагыз: «Мине ал!» да «Мине ал!»— дип кычкырып тора. Хәзер үк исән чакта ук шул үзебезнең продукция эченә кереп ятасы килә.

Т а в ы ш л а р. Ят, Тутай, ят!

Т у т а й. Вакыты җиткәч, ятарбыз да, Алла бирсә, безнең табутны дүрт күз белән көтеп торучы картларыбыз әйтмешли. Үлеп-нитеп китсәң, рәхим ит, табарга икән каян дип, дөнья бетереп эзләсе юк. Рәхим ит. Яшәсен безнең табут!

М и ң з и ф а. Фәнни яктан да аңлату сорала, Хәйбулов!

Х е з м ә т к ә р. Статистика мәгълүматларын әйтәм: узган ел туучыларга караганда, теге дөньяга китүчеләрнең саны арткан.

М и ң з и ф а. Гармун уйнаучыларның саны?

Х е з м ә т к ә р. Әлегә төгәл мәгълүматлар юк, әмма безнең гармунны сорау кимеде. Яшьләргә гармун кирәкми, картларның бармаклары каткан, алар табут көтәләр хәзер. Гармун заманы үткән: магнитофон, телевизор, дискотека...

М и ң з и ф а. Синтезатор, плейер... Радио-телевидение, газеталарга рекламалар бирегез. Реклама! Музыка. Үзебезнең шагыйребез Шайбәк!

«Ш а г ы й р ь».

Һәркем дә белә: Әҗәлгә
Булмыйдыр дару табып
Йөрисең-йөрисең дә берчак
Бик кирәк була табут!

Йөргән буласың да әз-мәз
Хәмер-валидол кабып...
Егыласың... Табут эзләп
Йөрмәгез инде чабып!

Т у т а й. Аля фуршит! (*Шампан шәрабы коялар.*)

М и ң з и ф а. Яшьләр, кыланыгыз үзегезчә! Музыка!

Т у т а й. (*«Шагыйрь» янына барып, аннан кәгазь алып килә, Миңзифа каршына килеп, яшьләрнең бию фонында тост әйтә.*)

Күтәрмимен бу тостымны
Башсызлар өчен,
Күтәрмимен бу тостымны
Баш сызлар өчен,
Күтәрмимен бу тостымны
Җансызлар өчен,
Күтәрмимен бу тостымны
Җан сызлар өчен,
Күтәрмимен бу тостымны
Йөз һәм мең зифа өчен...
Күтәрәм мин бу тостымны
Башлы, аңлы,
Эштә җанлы
Хуҗа Миңзифа өчен! Рәхмәт!

М и ң з и ф а. Яшәсен беренче продукциябез!

О с т а. Туктагыз, җәмәгать, миңа да сүз бирегез әле!

М и ң з и ф а. Сарманов, син исемлектә юк.

О с т а. Мин исемлексез генә әйтәм.

Т а в ы ш л а р. Әйтсен, әйтсен!

О с т а. Беләсегез килсә, минем ярты гомерем шушы фабрикада узды. Белдегезме? Пенсиягә китмәдем, иеме, ташлыйсым килмәде, әйе, шулай. Тоттык та: шалт Мөхәммәтҗан, әйе, шулай, заманга яраксыз дип, иеме, гармунның артына типтек, иеме? Рәхмәт әйтү юк, нитү юк, әйе, шулай. Нишләп әле аны оныттык, әйе, шулай.

Т а в ы ш. Дөрес! Гармунныбыз белән кешеләрчә бәхилләшик, рәнҗеп китмәсен!

М и ң з и ф а. Тутай, кайда без чыгарган иң соңгы продукция?

Т у т а й. Момент! (*Гармунны алып бирә.*) Барсы да уйланылган. Рәхим итегез.

М и ң з и ф а. Куй аны табут өстенә. (*Тутай куя.*) Җә-

мәгатьләр, мәрхүмне соңгы юлга озату тантанасын ачык дип белдерәм. Беренче һәм соңгы сүзне Тутай әфәндебез әйтер. Музыка! (*Матәм уйнала.*)

Тутай. Нәрсә әйтәсең монда. Гармун әйткән соңгы сүзен үзе. Шулай тормыш, беләсез, аралышып-кочаклашып йөри шатлык белән кайгы. Нишләтәсең, адәм баласы кебек, картайдың син дә, дөресен әйткәндә, үлдең. Кеше булсаң, озатыр идек пенсиягә. Рәнҗемә, ит гафу, орган-суккан, мат белән сүгенгән чакларыбыз да булгандыр, рәхмәт. Туйдыра алмавыңа карамастан безнең тамакны, без сине, әйбәтләнсә хәлләр, онытмаска тырышырбыз. Бәхил бул, җиңел булсын авыр туфрагың. Борчылма, күмәбез фабрика исәбенә.

Миңзифа. Бу беренче продукциябезгә салынган беренче мәрхүмебез. Символик күмү дип уйлагыз. Мәрхүм белән бәхилләшегез. (*«Мәрхүм»гә карый-карый, табут тирәли әйләнәләр.*) Тутай, табут капкачын ач, сал табутка!

Миңгол (*залдан*). Туктагыз, ашыкмагыз! (*Сәхнәгә сикереп менә.*) Сәйдәш бит Сакай маршын гармунны күмү өчен язмаган.

Миңзифа. Сезгә табут кирәкме? Бу — беренче. Сатылмый әлегә.

Миңгол. Миңа табут кирәкми.

Миңзифа. Нигә мендең монда? Безнең гармунны күмүдә синең нинди катнашың бар? Син кем?

Миңгол. Студент. Миңгол Вәлиев.

Миңзифа. Эш эзләп килдеңме? Үзебезнең эшчеләргә дә юк. Тутай, сал гармунны табутка! (*Тутай табут капкачын ача.*)

Миңгол (*гармунга тотына*). Бир әле гармунны.

Миңзифа. Кагылма мәрхүмгә.

Тутай (*үзенә тартып*). Кагылма! Хулиганство!

Миңгол. Бәлки, ул әле үлмәгәндер. Карыйк.

Тавышлар. Карасын! Карасын!

Миңзифа. Мәрхүмнең өстеннән көләргә рөхсәт итмим!

Миңгол. Мин көлмим. Мин дә бәхилләшәм... кочаклап... Гадәттә иң соңгы минутларда мәрхүмнең иң якын дуслары кала. Ул минем иң якын дустым иде.

Бик ямансу чакларымда
Син идең кочакларымда,
гармуным,

Көйсез чакта көйләүчем дә,
Телсез чакта сөйләүчем дә,
гармуным.
Дәртсез калган чакларымда
Син идең кочакларымда,
гармуным,
Гамьсез чакта уятучым,
Кайгы барда юатучым,
гармуным.
Хуш-бәхил бул, якын дустым...
Соңгы тапкыр сине кочтым,
гармуным.
Күмелмә, сүнмә, сүрелмә...
Юк, бирмим сине үлемгә,
гармуным!

(*Гармун телләренә баса. Гармун ыңгырашып аваз бирә.*)

Тутай. Маташма, беркемгә кирәге юк аның.

Миңгол (*күриген тартып карый*). Ул әле сулыш ала. Аңа ашыгыч ярдәм кирәк. (*Әкрен-әкрен генә көй чыгара.*) Ул үлмәгән! Сез аны харап итмәгез. Бирегез миңа, мин аны терелтәм. (*Искиткеч бер моң белән «Озату» көен уйный-уйный, сәхнәдән залга төшә. Тегеләр гаҗәпләнеп, яшьләр үз биюләрен дәвам итеп калалар.*)

## 4

**Миңзифа һәм Мөбәрәк Аюхановлар квартиры. Зур экранлы телевизор. Телефон. Уртада — тәрәзә. Өстәлдә — бинокль.**

Миңзифа. Ничекләр генә юлга кертергә бу шалапайны? Тәмам ычкынып бара. Кая олагыр икән тагын? (*Өстәлдәге бинокльне ала.*) Кызларны күзәткән. Шунда гына китсә ярар ие... (*Карый.*) Зиләйлүк! Әбәү лә матур килештереп китап укып утыра! Яшьлегемдә мин дә шул чама идем. Һай биле, нечкә билкәйләре! Студентлар шашадыр инде, мескенкәйләр! Безнекеләр — Аюхановлар килене бу! Зиләйлүк... Бер генә күз сирпеп бу якка карачы. Сиңа булачак каенанаң Миңзифа карап тора... яратып, өмет белән. Каенаналарның зәһәр дигән яманаты чыккан, ышанма, үзләре зәһәр киленнәр сүзе! Без синең белән чүкелдәшеп кенә яшәрбез, Зиләйлүккәем! Без мужик нәселеннән түгел лә... Китап укыган була, и матурым ла, сизенәм, күңелең бүтәндә, кемнедер көтәсең. Мин дә шулай көтә

идем кайчандыр. Көтә-көтә идем дә, килмәгәч, үзем эзләп китә идем. Мөбәрәгем-түгәрәгемне. Кемдер килә түгелме? Нишләр икән! Кабул итәрме, юкмы! Мирза?! Ул! Зиләйлүк янына килгән! Ма-ла-дис! Беренче тапкыр әйтәм бу сүзне үзеңә! Син дә мамаң уйлаганны уйлап йөрисең икән ич! Ә мин сине «болван!» дип тиргим гел. Акылыңа килгәндә, мамаңа охшап куясың шул, балакай.

Мөбәрәк (*кайтып керә*). Миңзифа! Кемне карыйсың анда?

Миңзифа. Кил әле, кил... Карале...

Мөбәрәк. Карамыйм, оялам... Тагын чишенгәннәрме... Ну бу студентлар, яз җиткәч бигрәк котыралар...

Миңзифа. Бу юлы алай түгел. Безнең киләчәк бәхетебез — бинокльдә.

Мөбәрәк. Ай-яй ерак икән бәхетебез. Бәләкәй генә кыз кисәген күрәм.

Миңзифа. Кире ягыннан карыйсың. Әйләндереп кара!

Мөбәрәк. О! О! Нигә миңа япь-яшь студентка күрсәтәсең. Тоттым да өйләндем булыр.

Миңзифа. Өйләнерлекме?

Мөбәрәк. Рөхсәт итсәң...

Миңзифа (*йодрыгын тегенең борын төбенә куеп*). Менә! Өйләнерлек кенә түгел, бал кашыгына салып йотарлык. Асылмы?

Мөбәрәк. Ярый инде шунда...

Миңзифа. Ныклабрак кара, бигрәк тә биленә игътибар ит.

Мөбәрәк. Синең билең тагын да нечкәрәк иде... егерме ел элек.

Миңзифа. Кешенең нечкә җиренә кагылма. Хәзер кара аның янында басып торган егеткә.

Мөбәрәк. Карадым. Егете әллә ни түгел.

Миңзифа. Сиңа охшаганмы?

Мөбәрәк. Кем белән чагыштырасың? Мин шәбрәк. Кем соң бу?

Миңзифа. Күзле бүкән. Мирза!

Мөбәрәк. Минем малаймы?

Миңзифа. Минем малай! Шул кыз янына килгән. Ниһаять! Күпме көттем мин бу минутларны! Шушы кыз — Зиләйлүк, Аюханов әфәнде, безнеке булачак!

Мөбәрәк. Ягъни мәсәлән?

Миңзифа. Мирзаныкы булачак! Ул сине «әтием!», мине «әнием!» диячәк.

Мөбәрәк. Хәл ителгәнме?

Миңзифа. Әнә улың хәл итеп ята. Шул Зиләйлүккә өйләнеп куйса, акылга утырмас микән дигән өмет бар. Сизденме, Аю әфәнде, эшләр кая тәгәри?

Мөбәрәк. Кыз ничегерәк соң? Җүнлеме? Хәзерге студентларның шактые — эчкече, наркоман; торакларында — бардак... Барысы да күз алдында. Мирзабыз үзеннән дә яманга килеп капса? Күрсәтер күрмәгәнеңне...

Миңзифа. Миңзифаның сыналган разведкасы эшли. Тутайны күндердем. «Дело» ачтым. (*Кәгазьләр актарып.*) Исеме Зиләйлүк. Фамилиясе... Акчурина! Сизденме? Акчурина! Татар дөньясына таралган морзалар нәселеннән! Синең аю фамилиясе белән йөргәч тә, син Миңзифаның үз фамилиясен онытма! Карачурина! Бай, зыялы морзалар токымы! Совет властеннан өркеп үз фамилиямне ташлагач та, синең кебек мужикка кушылгач та, ак сөяк икәнемне оныткан дисеңме әллә?

Мөбәрәк. Юк, юк, оныттырмыйсың.

Миңзифа. Тутай аркылы бу белешмәләрне алдым да Мирзабызны Зиләйлүк белән кавыштырырга ниятләдем. Ә ул, ни акыллы, ни дурак диеп йөрсәм, тоткан да Зиләйлүк янына үзе килгән. Токым каны уйный! Иш ишен барыбер эзләп таба икән. Их, Мөбәрәк, нишләп сөенмисең, минем яшь чакларым искә төште әле, җырлыйсы-биисе килеп китте...

Мөбәрәк. Минем дә!

Миңзифа. Сөюеңне син ничек әйттең әле?

Мөбәрәк. Җырлап шикелле.

Мөбәрәк.

Ягып яшьлек учакларын,
Башладык бит без юл башын.
Гомерлеккә кочакладым,
Җан юлдашым, җан юлдашым.

Миңзифа.

Син кабызган ут булмаса,
Нишләр идем ялгыз башым.
Куллар кулга сузылмаса,
Җан юлдашым, җан юлдашым.

Бергә.

Такыялар бергә үрик,
Кайнар яшьлек озата барсын.
Ни күрсәк тә бергә күрик,
Җан юлдашым, җан юлдашым.

Миңзифа. Малаебыз җан юлдашын кочаклыймы икән? (*Бинокльдән карый.*)

Мөбәрәк. Үбешсәләр — карама.

Миңзифа. Мирза, бичара, Зиләйлүк белән сөйләшергә тели, ә ул... китте дә барды. Үпкәләде бугай...

Мөбәрәк. Үпкәләтмәү өчен бераз ирененнән үпкәләү кирәк.

Миңзифа. Ничек кенә ярдәм итәргә балакаема? (*Шул вакыт гармун тавышы ишетелә.*) Ниндидер таныш музыка... (*Телевизор экранын ача. Анда — гармун уйнаучы Миңгол.*)

Диктор. Миңгол, сине гармунчылар фестивалендә беренче урынны алуың белән котлыйбыз. Бу гармунның бик гади күренә. Әмма син уйнаганда, җырлыйсы да, елыйсы да килә. Әллә телләре алтынмы?

Миңгол. Безнең калабыздагы фабриканың соңгы гармуны бу. Банкротка әйләнмәс өчен фабрика табут ясауга күчә. Мин аны үлемнән саклап калдым. Телләре алтын булмаса да, сайрап тора. (*Уйный.*)

Диктор. Миңгол, син үзәккә үтәрлек җырлыйсың да. Ник син бигрәк моңлы бала булдың?

Миңгол (*уйнап җырлый*).

Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Сандугачлы талда үскәнгә.
Язмыш агачында тирбәләм дип,
Канатларым сынып төшкәнгә.
Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Җилгә каршы ишкәк ишкәнгә.
Тормыш көймәсендә йөзә-йөзә,
Хәсрәт дәрьялары эчкәнгә.
Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Гомерем җилләр кебек искәнгә.
Җаннарымда сайрар сандугачым
Исләремә килеп төшкәнгә.

Миңзифа (*телевизорны сүндерә, ишек-түрле йөреп*). Безобразие! Син елап утырасың түгелме?

Мөбәрәк. Күңел тулып китте.

Миңзифа. Минем производство яну алдында! Син кемнеңдер гармун кычкыртуына балавыз сыгып утырасың!

Мөбәрәк. Ни булды?

Миңзифа. Күрмәдеңмени, безнең яңа продукциянең яманатын сата, үлгән гармунны күккә күтәрә.

Мөбәрәк. Шәп җырлый...

Миңзифа. Аяк чала бу безгә! Табутка — антиреклама!

Мөбәрәк. Минемчә, бу егет гашыйк булган.

Миңзифа. Яңа туган балабызга — табутка реклама ясыйсы урында... Пычаксыз суйды!

Мөбәрәк. Кызма, утыр, тынычлан... (*Утыра.*)

Миңзифа. Директор авыр хәлдә ята. Белеп булмый, ычкыныл-нитеп китсә дип, беренче продукцияне аның үзенә багышладык. Икенчесен урынбасарына — миңа әзерләмәкче буласызмы? Юк! Гармунга! Йә мин, йә гармун! Әгәренки җиңелсәм, хурлыгымнан үз табутыма үзем кереп ятам, Алла сакласын!

Тутай (*ашыгып керә*). Эшләр хөрти!

Миңзифа. Фабрика янамы?

Тутай. Юк.

Миңзифа. Кассаны бастылармы?

Тутай. Басарлык касса бармы?

Миңзифа. Мирза?!

Тутай. Әйе.

Мөбәрәк. Исәнме?

Тутай. Исәнмесез, остаз!

Миңзифа. Мирза исәнме? Бәла-казага юлыктымы әллә?

Тутай. Бәламе, казамы, булмый алдан ук әйтеп.

Мөбәрәк. Телеңә салынма. Ни булды?

Тутай. Разведка. Мөһим мәгълүматлар. (*Тәрәзәгә күрсәтеп.*) Карагыз анда ниләр булып ята...

(*Миңзифа белән Мөбәрәк бинокльдән карыйлар.*)

## 5

Бинокльдән күренеш.
Сул яктан — студентларның тулай торагы. Кызлар заман көенә бииләр.

Зиләйлүк. Һай кызлар, арыдым биеп. Әйдәгез керәбез, иртәгә — семинар.

Фирдәвес. Көтик инде егетләрне. Кичә дә шушы вакытта килделәр. (*Туктап, биеп сөйләшәләр.*)

Нәфисә. Әй, бүген килмәсләр инде. Кичә Зиләйлүк эшне бозды, ишекне бикләде дә куйды. Айдар да китеп барды башка кызлары янына.

Ф и р д ә в е с. Зиләйлүк, нигә шулай иттең, ә? Газинур белән тагын үбешәлмичә калдым.

З и л ә й л ү к. Миңголдан да аракы исе килә иде. Кердем дә бикләндем. Икенче эчеп килмәсеннәр! Тагын шулай килсәләр, ачмыйбыз ишекне!

Ф и р д ә в е с. Һай харап икән: аракы исе килгән. Әзмәз капмагач та — студентмени ул. Бик исең киткән, туры килгәндә, үзем дә тост күтәрәм мәхәббәт өчен! Айдар әйтмешли, ирекле мәхәббәт өчен!

Н ә ф и с ә. Минем Айдарга кагылма! Ул әллә ни эчми...

Ф и р д ә в е с. Газинурга «эчмә!» дип әйтеп кара, әллә кая җибәрә. Эчсен, тартсын рәхәтләнеп, минем янга да килгәләсен шунда... Онытканда бер булса да...

Н ә ф и с ә. Минем Айдар... минеке түгел шул, егылганчы эчми дә, тартмый да... үзем белеп торам, беркөнне берничә кыз белән очраша. Барыбер яратам шул Дон Жуанны!

Ф и р д ә в е с. Фу, тартмаган егет егетмени ул! Төнге барга чакырсалар, каиф өчен үзем дә тарткалыйм. Газинурга ярарга тырышам. Ул ни әйтә, мин тыңлыйм. Тыңламый кара!

Н ә ф и с ә. Ят дисә, ятар идең дәме әллә?

Ф и р д ә в е с. Анысын үзебез генә беләбез! Зиләйлүк, килсәләр, ишекне бикләмә инде... Газинур белән рәхәтләнеп үбешәсем килә...

З и л ә й л ү к. Бераз ялындырыйк, кызлар, бер сызгыруга йөгереп чыккан кызлардан егетләр тиз бизәләр. Мин сезгә ачкычны бирмәгән булырмын.

Ф и р д ә в е с. Кара аны, озак интектермә!

З и л ә й л ү к. Мин сезнең егетләрне кумыйм ич, кызлар.

Н ә ф и с ә. Айдар Миңголга иярә дә китә.

Ф и р д ә в е с. Газинур да.

Н ә ф и с ә. Әллә син Миңголны яратмыйсыңмы?

Ф и р д ә в е с. Яратмасаң, миңа бир. Газинурга ышаныч юк.

З и л ә й л ү к. Үзенә «яратам» дип беркайчан да әйтмим.

Ф и р д ә в е с. Миңолның бер дә исе китмәс, артык ялындырсаң, ташлар да китәр.

Н ә ф и с ә. Гармунчының бармаклары саен мәхәббәт аның. Артыннан йөз кыз йөридер әле.

З и л ә й л ү к. Чынлап яратмый икән... йөрмәсен йөрәкне яндырып...

Н ә ф и с ә. Зиләйлүк, ялгышмыйсыңмы, Миңгол кебек егетне син дөнья бетереп эзләсәң дә табалмыйсың. Тәкәбберләнмә.

Ф и р д ә в е с. Морзалар токымыннан шул син. Бу холкың белән безнең заманда ир-егет төсе күрми картаерсың.

Н ә ф и с ә. Мин беләм: Миңгол ярата аны!

Ф и р д ә в е с. Ә син? Дөресен әйт, чынлап яратасыңмы аны?

З и л ә й л ү к.

Мәхәббәтнең ни икәнен
Белмәгән гамьсез бала
Йөрәгендә көтмәгәндә
Серле бер хис кузгала.
Җанын аның давыллады,
Биләде бер моң гына,
Ияртте дә алып китте
Нәни бер гармун гына.
Аның белән очрашуны
Минутлап саныйм инде.
Шул гармунның чакыруын
Ерактан таныйм инде. (*Шигырь сөйләгәндә ерактан гармун тавышы ишетелә.*) Ул килә!

Ф и р д ә в е с. Газинур да килә!

Н ә ф и с ә. Айдар да!

З и л ә й л ү к. Әйдәгез, кызлар, кереп бикләник!

Кызларны кулларыннан тартып алып китә. Тегеләр: «Кермик! Бикләнмик!»— дия-дия, аңа буйсыналар. М и ң г о л, А й д а р һәм Г а з и н у р керәләр. Миңголның кулында — гармун. Айдар белән Газинур баскыч тотканнар, шунда гармун уйнап килүче Миңголны утыртканнар.

М и ң г о л (*баскычтан төшеп, тәрәзәгә карый*). Егетләр, тәрәзәне томалап ук куйганнар. Өмет юк.

А й д а р (*баскычка ымлап*). Без алмаган крепость юк!

Г а з и н у р. Әйдәгез, кыюлык өчен бераз салып килик!

М и ң г о л. Шуның өчен үпкәләттек ич инде.

Г а з и н у р. Фирдәвес үпкәләмәде.

А й д а р. Шул синең морза кызы аркасында без дә ялынырга тиеш.

М и ң г о л. Сез теләсә нишләгез, мин бүгеннән ул гадәтне ташлыйм!

Г а з и н у р. Синең шул булыр инде.

А й д а р. Әллә өйдә юклармы? Хәрәкәт сизелми.

Г а з и н у р. Әнә! Берсе карап тора. Фирдәвеснең башы!
А й д а р. Каян таныдың?
Г а з и н у р. Мин аны мичкә керсә... башыннан таныйм.
А й д а р. Әһә, мин дә Нәфисәнең кул изәвен күрдем.

Чакыра.

М и ң г о л. Җырламасак... йөгереп чыкмаслар.
А й д а р. Шәһәрчә кыланалар авыл кызлары! Алар белән гармун телендә сөйләшергә кирәк.
Г а з и н у р. Миңгол, тарт гармуныңны! Өз күриген! Җырсыз тартып чыгарып булмас аларны.
М и ң г о л. Анысын була. Без консерваторлар... (*Гармун уйный. Өчәү җырлыйлар.*)

Их кызлар, кызлар, шулкадәр
Нигә сагындырасыз,
Үзегез дә сагынасыз,
Нигә ялындырасыз?

Ф и р д ә в е с т а в ы ш ы. Мин ялындырмыйм!
Г а з и н у р.

Их кызлар, кызлар, шулкадәр
Борыныгыз югары.
Сездәй тәкәббер кызларны
Күргәнебез юк әле!— дигән булыйк.

А й д а р (*җырлый*).

Сөйгәнемнең балконына
Сөяп куйдым баскычны.
Йөрәккәеңне ачарга
Биреп торчы ачкычны.

Ялындырсаң, китәм дә барам!
Н ә ф и с ә т а в ы ш ы. Ачкыч Зиләйлүктә! Ачмый!
А й д а р.

Шикләнмә, сөеклем,
Бикләнмә, сөеклем,
Елмаеп та көлеп, биеп чык.

Г а з и н у р.

Чык, иркәм, балконга,
Карама салкынга,
Җылытырмын, толып киеп чык!
Баскыч куегыз, баскыч! (*Баскыч куялар.*)

Фирдәвескәй!
Ф и р д ә в е с. Әү!

Газинур. Кара күзкәй!
Фирдәвес. Әү!
Газинур. Ач!
Фирдәвес. Ач булсаң, туеп кил!
Газинур. Тәрәзәне ач! Мин Исмәгыйль түгел.
Фирдәвес. Мин дә Галиябану түгел. (*Тәрәзәне ача.*)

Нечкә билләремнән кочып,
Тәрәзәдән тартып ал.
Тагын да нык яратырмын,
Газинуркай, зәңгәр күзкәй,
Мороженый сатып ал!

Газинур. Сикер кочагыма! Ашыкма, үзем менеп алам! (*Менә башлый. Фирдәвес, көтеп тә тормыйча, баскычтан йөгереп төшә һәм Газинурны кочаклый.*)

Фирдәвес. Сагындырдың, Газинурка! (*Үбеп тә ала.*) Кая алып барасың? Уңгамы, сулгамы?

Газинур. Сулга, бары тик сулга! Бүлмә буш, киттек безгә!

Фирдәвес(*кесәсеннән сигарет ала*). Зажигалка! Киттек!

Газинур. Без киттек оҗмахка! Кызганам мин сезне... (*Кочаклашып чыгалар.*)

Миңгол (*Айдарга*). Чират синеке, Айдар!

Айдар. Нәфисә! Кил кочагыма! (*Баскычтан менә.*)

Син каен булалмадың,
Мин чыршы булалмадым.
Көйгә салып әйтеп тормыйм,
Мин җырчы булалмадым.

Нәфисә.

Син Сәйдәш булалмадың,
Җәлил дә булалмадың,
Галиябану булыр идем,
Айдар җаным, Дон Жуаным,
Син Хәлил булалмадың.

Айдар. Бир кулыңны! (*Тәрәзәдән алып тартып төшерә.*)

Нәфисә. Тирә-якта козгыннар юкмы, җаным?

Айдар. Ачык авыз каргалардан башка беркем дә күренми. Үбим әле!

Нәфисә. Ашыкма, чыпчыгым. Әйдә, ярар инде. (*Үптерә.*) Кая алып барасың? Парк? Дискотека?

Айдар. Төнге клуб! Стриптиз!

Нәфисә. Болар белән күңелсез! Киттек! (*Чыгалар.*)

Миңгол (*баскычтан әкрен генә менә дә туктала*). Зиләйлүк... Нигә тәрәзәне яптың? Ач инде... Өч кенә сүзем бар. (*Тәрәзәне ачмакчы була, кечкенә пыяла төшеп ватыла.*) Бәхеткә булсын... Борчылма, пыяланы үзем куярмын. Зиләйлүк, өч кенә сүз әйтәм дә китәм. Ярый, сау бул, пыяла алып киләм. (*Төшә, скамейкага утыра. Җырлый.*)

Сиңа гына әйтеләсе серем
Яшеренгән йөрәк түремдә.
Әйтә алмый йөргән өч сүземне
Алып китәм гармун телендә.

Җыр вакытында Зиләйлүк ишектән чыгып әкрен генә Миңголга таба бара.

Зиләйлүк. Миңгол, әйт шул өч сүзеңне.

Миңгол. Зиләйлүк, мин сине яратам.

Зиләйлүк. Ә минем сиңа дүрт сүз әйтәсем бар.

Миңгол. Әйт шуны!

Зиләйлүк. Мин синең гармуныңны яратам. (*Якынаялар.*)

## 6

Тутай (*бинокльдән карап*). Күрдегезме, сиздегезме?

Миңзифа (*кулъяулыгы белән яшьләрен сөртүче Мөбәрәккә*). Синдә дә җан әсәре бар икән: аңладың Мирзаның ни көткәнен.

Тутай. Драмасын.

Миңзифа. Трагедиясен. Күз яшьләреңне шуңа агызасыңдыр бит, папасы?

Мөбәрәк. Яшьлектә синең белән очрашкан чаклар искә төште.

Миңзифа. Кара инде моны. Баласының язмышын күз алдына китереп кайгыга калган дисәң, барлы-юклы яшь чагын уйлап утыра икән. Әллә нәрсә әйтер идем, килешмәс. Бу бит Мексика фильмы түгел!

Тутай. Мексика фильмын бәреп ега.

Миңзифа. Син караган тамашаның төп герое кем булып чыкты инде, белдеңме?

Мөбәрәк. Гармунчы инде...

Миңзифа. Әнә шул гармунчы мут егет фабриканың гына түгел, безнең шәхси дошманыбыз да булып чыкты.

Тутай. Шул малай төште миңа да аркылы. Консерватория оркестры тиеш барырга Парижга фестивальгә.

Пләмәнник тә минеке шунда маташа. Хәзер бу конкурент. Дошманым минеке дә, димәк.

Мөбәрәк. Нишләп ул миңа дошман булсын?

Миңзифа. Тутай, кара инде, менә шушының белән яшь гомеремне бәйләгән мин — җүләр. Дөресме?

Тутай. Әйтәсез дөрес. Рәхмәт.

Миңзифа. Балабызның киләчәгенә киртә ул — менә нигә дошман! Мәхәббәт корбаны булып үзенә кул салмаса ярый, балакай... (*Бинокльдән карый.*) Юк ул анда. (*Ишектә Мирза күренә. Аны бинокльнең ерагайтып күрсәтә торган ягыннан күрә дә.*) Син кайда, Мирза? Нигә син бик еракта? Әй лә, икенче ягыннан караганмын икән. Балам...

Мирза. Мин кайттым, мама.

Миңзифа. Хәлләрең ничек, улыкаем?

Мирза. Минем хәлләр коточкыч, мама. Әллә нишләдем мин. Күкләргә ашасы, шашасы килә! Минем бүген сандугач булып сайрыйсым, әллә кайларга барып бүре булып улыйсым килә!

Миңзифа. Йа Алла... (*Мөбәрәккә.*) Тегендә шалтырат.

Мөбәрәк. Мирза, егет бул, бирешмә.

Миңзифа. Ни булды? Башыңа типтеләрме әллә?

Мирза. Башка гына типсәләр, әйбәтрәк булыр иде... Йөрәккә, йөрәккә, мама!

Миңзифа. Милиция!

Мирза. Милия дә, доктор да... беркем дә минем хәлне төзәтә алмый...

Миңзифа. Исердеңме? Наркотик?..

Мирза. Наркотиклар да мине айныта алмый хәзер... Гомеремдә беренче тапкыр шомырт чәчәкләренең исенә исердем. Зәңгәр урманнарга барып, чәчәкле болыннарга күмелеп, үксеп-үксеп җырлыйсым килә!

Мөбәрәк (*улының бу халәтен аңлап, якын итеп*). Мирза, әйдә, бергә йөреп керик.

Мирза. Юк, папа, минем берүзем генә калып, таңга кадәр йолдызлар белән генә сөйләшеп йөрисем килә.

Миңзифа. Улым, төнлә ялгызың йөри күрмә, урам фахишәләренә эләгеп, харап булырсың. СПИД эләктерерсең, Алла сакласын...

Мирза. Их мама, мама, хәзер мин беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмыйм. Үтерсәләр дә...

Мөбәрәк. Бар, бар, Мирза, үзең генә йөреп кер.

Миңзифа. Папасы, ни сөйлисең? Югалтабыз баланы!

Мирза. Мине югалтмагыз. Әгәр югалтсагыз, йолдызлардан эзләгез! (*Чыга.*)

Миңзифа. Нишләп аны кара төн уртасында берүзен чыгарып җибәрдең? Тәмам ычкынган бала... Нишлибез?

Мөбәрәк. Моңа сөенергә генә кирәк.

Миңзифа. Кит аннан! Шул да булдымы папа.

Мөбәрәк. Адәм юлына керергә аңа күкләр ярдәмгә килгән.

Миңзифа. Син үзең дә ычкына башладыңмы әллә?

Мөбәрәк. Ул яшьлекнең моңа кадәр тоймаган күгенә менгән.

Миңзифа. Шашуы аның мәхәббәттән. Отказ алды бит балакай. Коткарыйк без аны һәлакәттән. Күпме балалар мәхәббәтнең корбаны булып һәлак булдылар.

Мөбәрәк. Комачаулама син аңа.

Миңзифа. Мин синең белән сөйләшмим дә. Тутай, син минем урынбасарым, тәкъдимеңне әйт!

Тутай. Мәхәббәт фронтында дошманнарына Мирзаның тәкъдим итәм оештырырга контр һөҗүм!

Миңзифа. Конкрет?

Тутай. Келлер? Рәхмәт.

Миңзифа. Батмый. Статья!

Мөбәрәк. Баш ватмагыз. Аны дәвалар...

Миңзифа. Кем? Экстросенс?

Мөбәрәк. Вакыт.

Миңзифа. Синнән җүнле сүз ишетеп булмас. Их сез, ирләр, икегезгә бер баш юк. Эштәге шикелле үк җитәкчелекне үз кулыма алырга туры килә. Сездә булмаган акыл белән мин шундый карарга килдем. Күреп торасыз, Мирзабыз гүзәл кыз Зиләйлүккә гашыйк. Шул нигездә шактый җиңеләйгән. Аның өчен мамасы уйларга тиеш. Чөнки папасыннан он да юк, җон да юк. Ничек итеп Зиләйлүкне Мирзага каратырга? Бу олы операцияне башкарып чыгуда да син, Тутай, урынбасарым булырсың.

Тутай. Теләсә нинди заданиегезне үтәргә әзермен, Миңзифа Касыймовна!

Миңзифа. Морза нәселе Зиләйлүк безнеке булыр! (*Бинокльдән карап.*) Мирзаныкы булыр! Зиләйлүк килен, каенанаңнан сәлам!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ АКТ

Миңзифа белән Мөбәрәк бинокльдән күзәтәләр.

Миңзифа. Мә бинокльне. Бераздан анда мине дә, малаеңны да күрерсең. (*Китә.*)

Мөбәрәк. Хәерле булсын.

### Бинокльдән күренгән тамаша

Тутай техника урнаштырып йөри.

Тутай.

Болай читтән караганда,
Озын түгел, кыска мин.
Тутай кем дип сорасагыз,
Һәрбер эшкә оста мин.
Мәсьәләгә якыннан һәм
Ерактан карый беләм.
Тагын бер уңай сыйфатым:
Һәркемгә ярый беләм.
Тутай кем дип сорасагыз,
Маклер, жокей, аучы да...
Кирәк икән — аеручы,
Кирәк икән — яучы да.

Әле мин нишләдем? Юк иде җырлаганым, юк иде биегәнем. Тыпырдап тора аяклар музыкага. Операцияне башладык! Булсын хәерле! (*Югала. Ул көйләгән магнитофоннан таныш гармун тавышы ишетелә. Бу — Миңголның язмасы*).

Зиләйлүк (*тәрәзәне ачып*). Миңгол килә! (*Өчесе дә йөгереп чыгалар.*)

Фирдәвес. Газинур килә!

Нәфисә. Айдар!

Тутай тавышы.

И гүзәл кыз, күңелең кошын
Яулаучы аучы килә.
Төннәр буе йокламыйча,
Син көткән яучы килә!

Фирдәвес. Яучы килә! Газинурдан булмас. Ул аның ни икәнен дә белми.

Нәфисә. Айдардан да булмас. Гомергә өйләнми ди.

Зиләйлүк. Миңгол әйткән иде яучы җибәрермен

дип. Шаярган дип уйладым. Әллә чынлап әйткән инде...

Нәфисә. Шаяруы да чынлап аның.

Фирдәвес. Миңгол әйтмәдемени, әтисе авылда мулла икән.

Нәфисә. Мулла килене буласың алай булгач.

Зиләйлүк. Шаяртмагыз әле, кызлар, кем әле кияүгә чыгарга уйлый...

Тутай (*керә*). Исәнмесез, саумысез, матурлары дөньяның? (*Җавап бирәләр.*) Асылларның асылы, гүзәлләрнең гүзәле, һәрбер егет үлеп гашыйк булырлык, йотарлык бер кашык су белән, тотарлык уч төбендә генә... килдем мин бик изге миссия белән...

Фирдәвес. Миңамы?

Нәфисә. Миңамы?

Тутай. Гыйззәтле һәм кыйммәтле Зиләйлүк туташ. Җибәрде мине яучы итеп шул егет, кайсыдыр ки яна-көя синең өчен. Туды синең өчен махсус дөньяга, яши түлке синең өчен. Симез булган егет кайчандыр күргәннән бирле сине ни аракы эчми, ни җүнләп ашамый, калды почти сөяккә. Ике пачка тарткан егет тарта хәзер түлке көнгә ике-өч сигарет. Ябыкты хәзер, инде шәм кебек төз, ыспай, биле нечкә аның да, точно синеке кебек. Килгәндә папасына, мулла кебек тәүфыйк иясе, эчкән иде бер тапкыр үлгәнче, но үлмәде, ташлады аракы эчүне совсем, кайчакта коньяк кына капкалый, анда да үзе сатып алып түгел, кешеләр сыйласа. Кыз белән пар килгәнсез бик. Булмаса уңай җавап сезнең яктан, асыл егет асылынырга да риза...

Зиләйлүк. Юк... юк...

Тутай. Асылынырга да өлгерә асыл кызга — сиңа, Зиләйлүк. Бир кулыңны...

Зиләйлүк. Юк... юк.

Тутай. Асылынырга да өлгерә асыл кызга — сиңа, Зиләйлүк. Бир кулыңны...

Зиләйлүк. Юк... юк.

Тутай. Яучыга. (*Музыка. Зиләйлүкне уртага алып чыга*).

### Дуэт

Тутай. Егетеңне төшләреңдә күрдеңме?

Зиләйлүк. Күрмәдем.

Тутай. Асыл туташ, мин киләсен белдеңме?

Зиләйлүк. Белмәдем.

Тутай. Егете дә затлы нәсел,
Асылдан.
Зиләйлүк. Чынлапмы?
Тутай. Сине уйлап яза инде
Акылдан.
Зиләйлүк. Чынлапмы?
Тутай. Ул егеттә матурлык бар,
Бар моң да.
Зиләйлүк. Шулай шул!
Тутай. Аның кебек уйнаучы юк гармунда.
Зиләйлүк. Шулай шул!
Тутай. Ул бик кыю, ә син, туташ,
Иркәрәк.
Зиләйлүк. Шулаймы?
Тутай. Гомереңбуе яшәр сине
Иркәләп.
Чык кияүгә шул асылга!
Зиләйлүк. Иртәрәк!
Тутай. Гомерең буе яшәр сине
Иркәләп.
Зиләйлүк. Иртәрәк... (*Югала. Тутай да чыга.*)

Тутай тавышы. Каршы алыгыз! Булачак кайнана! (*Кызлар керәләр. Алар алдында морзабикә кебек затлы киенгән Миңзифа пәйда була.*)

Миңзифа (*дәрәҗәле адымнар белән кызлар каршына килеп туктый*). Зиләйлүк! Кызым? Кайсыгыз сезнең Зиләйлүк?

Фирдәвес. Кайсыбыз килен булырлык —
Үзең эзләп тап!
Нәфисә. Асыл кошны танып була кайда да,
Шул асылга булсаң иде каенана!

Миңзифа (*Зиләйлүк алдына килеп туктый*). Бисмилла рахман рахим. Зиләйлүк!

Зиләйлүк. Әйе, апа, мин Зиләйлүк. Каян таныдыгыз?

Миңзифа. Мин аксөяк нәселне гәүдәсенең горур торышыннан. Күзләренең сокланггыч горур карашыннан тоям.

Зиләйлүк. Сез аның әнисеме?

Миңзифа. Күңелең белән син дә таныдың. Әйе, мин аның мамасы, шулай ук морза нәселеннән. Улым ялгышмаган, тфү-тфү, күз тимәсен, фәрештәнең «Амин!» дигән чагына туры килсен, токымнарыбыз кушылсын, йөрәкләрегез бергә типсен!

Н ә ф и с ә. Атасы кем соң!

М и ң з и ф а. Морза нәселеннән булмаса да, тәртибен тикшереп карасагыз, мулладан ким түгел, артык булмаса әле? Мужик нәселеннән булса да, нигә кияүгә чыктың дип сорарсыз инде. Яраттым шул шадра шайтанны! Зиләйлүк, үзең беләсең, малаебызның сиңа күзе төшкән, әллә нишләде, алышынды, күзләре куе зәңгәрләнде, тавышы да, күңеле дә нечкәрде. Нишләргә дә белми, бичара...

Ф и р д ә в е с. Без бердәнбер Зиләйлүкне бичарага бирмибез.

М и ң з и ф а. Бичара дигәч тә. Мәхәббәт шаукымы инде. Тәмам авыруга сабышты.

Н ә ф и с ә. Без кызыбызны авыруга бирмибез.

М и ң з и ф а. Авыру дигәч тә... мәхәббәт авыруы гына ул...

З и л ә й л ү к. Ярар инде, кызлар.

Н ә ф и с ә. Машинасы бармы?

М и ң з и ф а. Алла бирсә, бар, булачак, үзеңне машинадан да чыгармас.

Ф и р д ә в е с. Мал-мөлкәт ягы ничек? Без кызны ярлы адәмгә дип үстермәдек.

М и ң з и ф а. Минем бабамның бабасының ярты губерняны чиста тоткан сабын ясау фабрикасы, хәзерге байларның өч катлы коттеджларын бәреп ега торган биш сарае булган.

Н ә ф и с ә. Ә малаегызның ние бар?

М и ң з и ф а. Башында мие бар, өе бар, гармунда ратып уйный торган көе бар.

Ф и р д ә в е с. Көйнең исеме ничек?

М и ң з и ф а. «Зиләйлүк». Гармунын тота да шуны уйный.

Н ә ф и с ә. Бию көен уйный беләме?

М и ң з и ф а. Анысын, Алла бирсә, туйда уйнар.

Ф и р д ә в е с. Апа, син морза кызлары биюен беләсеңме соң?

М и ң з и ф а. Кая инде безгә бию? Кырганнар бөтен нәсел-нәсәпне...

Ф и р д ә в е с. Биеп күрсәтикме? Әйдәгез, кызлар, иртәгәге концертка репетиция булыр. (*Музыка. Өчәүләп морза кызлары биюен башкаралар. Миңзифа үзе дә аларга кушылып китә.*)

М и ң з и ф а (*сокланып*). Морза кызы морза кызы шул инде. Сез яшьләр ничек тә үзегез аңлашыгыз инде. Хушыгыз, матуркайлар! (*Чыга.*)

Н ә ф и с ә. Каенанаңны да күрдек.

Ф и р д ә в е с. Туй күлмәге әзерлә.

З и л ә й л ү к. Нинди туй, нинди каенана? Ул чакта уйлаганым да юк.

Н ә ф и с ә. Миңгол килер дә, «әйдә, өйләнешик!» дияр. Ата-аналары хәл иткән.

З и л ә й л ү к. Ул турыда бер сүз дә башламадык. Миңголның бик җаваплы вакыты: оркестр белән Берлинга җыена.

Н ә ф и с ә. Өйләнешү өчен вакыт кирәкмени.

Ф и р д ә в е с. Миңа берәр егет тәкъдим ясасамы, үзем кулыннан сөйрәп загска алып китәр идем.

З и л ә й л ү к. Вакыт җитми чәчәк атмый бакчадагы гөлләр дә.

Ф и р д ә в е с. Синең урынында булсаммы?

Тизрәк чыгып калыйм әле
Алучысы барында,—

дип җырлар идем.

Н ә ф и с ә. Минем Дон-Жуаным өйләнүнең ни икәнен дә белми, башкаларны коча да минем янга килә. Нинди бәхетле син, Зиләйлүк! Сине чын күңелдән сөйгән кеше бар!

Ф и р д ә в е с. Миңа тәтеми андый бәхет. Беркем дә алмас инде мине. (*Сигарет каба*). Йә алса да, икенче көнне үк куып чыгарыр. Әй, чыгарса соң...

Н ә ф и с ә. Исемемне, уйламыйча, Нәфисә куйганнар. Карагыз, минме Нәфисә? Гүзәл булып тумаганга минме гаепле? Егетләр бары да синең кебек сылуларга гашыйк. Бизәнеп тә, чәчләремне буяп та карыйм — ноль внимания! И шуннан соң яныңа кем килә — шуңа риза буласың. Ә егетләр капшау, сыйпау ягын гына карыйлар. Күрәсем килми берсен дә! Мәхәббәт дигән буласыз. Юк ул мәхәббәт! Егетләр хаклы. Нигә карасын алар безгә? Үзебезнең телдә сөйләшкән булсак та, без бит татар кызлары түгел.

Ф и р д ә в е с. Урыс кызлары да түгелбез...

Н ә ф и с ә. Авыл кызлары да, шәһәр кызлары да түгел. Кем карасын безгә. Чын күңелдән кем сөйсен безне?! Шуңа күрә аның мәхәббәте дә янар-янмас, сүнәр-сүнмәс. Без яшәгән заманда сөю була алмый. Булса да, вакытлыча мавыгу гына...

З и л ә й л ү к. Кызлар, ялгышасыз, бар ул сөю, бар ул сөелү. Сез аның белән очрашмагансыз гына. Килер ул сезгә кайчан булса да, соңга калып булса да. Ул килер, килер!

Н ә ф и с ә. Синеке килер, Зиләйлүк.

Ф и р д ә в е с. Килсә дә, анысы да болай гына йөри. Чынлап булса, тәрәзә пыяласын ватып китмәс иде. Алар шулай — ватарга гына торалар. Көтмә, яшьлегеңне зерәгә уздырма. Синдәге данныйлар булса, мин ун егет белән берьюлы сиптерер идем. Әйдә, Нәфисә, үзебез эзләп китәбез.Бар! Коктейль!

Н ә ф и с ә. Юк, мин бүлмәгә керәм. Бер солдаттан хат алган идем, шуңа җавап язам. (*Кереп китә.*)

Ф и р д ә в е с (*җырлап чыга*). Үпкәләсәң, әйдә, үп, Коля!

З и л ә й л ү к (*ялгызы кала. Җырлый.*)

Яшьлегемне бер давыллар өчен,
Тәрәзәмне килеп кактыңмы?
Әллә инде болай уйнап кына,
Күңелем пыяласын ваттыңмы?
Күзләремне алмыйм тәрәзәдән,
Күтәрәм дә карыйм пәрдәсен.
Кызык өчен шаярырга гына
Килдең микән миңа әллә син?
Тәрәзәмә кунган күгәрченнән
Сөенечле хәбәр көтәм мин.
Син килерсең, бергә очар өчен
Җырларыңны канат итәм мин.

(*Миңгол уйнаган гармун тавышы.*) Миңгол! Ул килә! (*Миңголныкы кебек гармун тоткан, Миңголныкы кебек үк күлмәк кигән Мирза керә.*)

З и л ә й л ү к. Килдеңме? Мин сине шундый көттем.

М и р з а. Тагын бер генә әйт шул сүзләреңне. Син моны чынлап әйтәсеңме? Син мине көттеңме? (*Якыная.*)

З и л ә й л ү к. Ой! Мин сезне Миңгол диеп торам!

М и р з а. Миннән курыкмагыз, туташ.

З и л ә й л ү к. Мин керим инде.

М и р з а. Бер генә минутка мине тыңлагыз, зинһар...

З и л ә й л ү к. Кичерегез... миңа килергә тиеш...

М и р з а. Беләм, кемнең киләсен дә беләм. Аны яратканыңны да беләм. Беләм, мине яратмаганыңны да беләм. Әмма мин сезнең арагызга кара елан булып ятмам. Мин Исмәгыйль түгел.

З и л ә й л ү к. Сез ни сөйлисез?

М и р з а. Сөйгәнеңне дә атмам. Мин бары тик сезгә бәхет теләргә килдем. Утырып тыңлагыз мине.

З и л ә й л ү к. Юк, мин ашыгам... (*Шулай да утыра.*) Тиз генә әйтегез...

Мирза. Сез мине әллә нишләттегез, Зиләйлүк. Сезне беренче тапкыр күргәннән соң төссез булып күренгән дөнья үзгәрде дә куйды. Ничек мин моңа кадәр күрмәгәнмен шомырт чәчәкләренең баш әйләндергеч аклыгын, ничек мин сизмәгәнмен Айның горур ялгызлыгын, ничек мин тоймаганмын. Күктәге йолдызларның серле җемелдәүләрен. Миннән көлмәгез, Зиләйлүк. Сез дә яратасызмы?

Зиләйлүк. Яратам.

Мирза. Нинди бәхетле Сездән бу сүзне ишеткән кеше!

Зиләйлүк. Тынычланыгыз... (*Кузгала.*)

Мирза. Тагын бер генә сүз... Сезне күргәннән бирле мин тынычлыгымны югалттым. Моңа кадәр Көнбатышның джаз, рок музыкасын гына таныган адәм — мин — милләт моңын йөрәгем белән тойдым. Бар икән татарда йөрәк өзгеч моң! Аның өчен гашыйк булырга кирәк икән...

Зиләйлүк. Мин китим инде...

Мирза. Сез мине гамьсез-уйсыз адәмнән хыялыйга әйләндердегез. Өй тулы инструментларны тотып та карамаган, хәсрәтнең ни икәнен дә белмәгән егет гармунда көй чыгара башлады. Әллә инде Күкләр ярдәме, үзем дә белмим, күкрәгемдә ургылып бер җыр туды. (*Гармун уйнарга җыенгач, магнитофонда Миңголның уйнавы ишетелә. Мирза моның Тутай эше икәнне аңлап ала.*) Тутай, комачаулама. Мин үзем дә уйный беләм. Тагын бер генә минут. Шул көемне җырлап, Сезнең белән мәңгегә бәхилләшәм.

Ул да ялгыз, бәлки, аңлар диеп,
Күзәттем мин төннең тын Аен.
Синең белән бергә кавышуны
Насыйп итмәгәндер Ходаем.
Бәхетле бул сөйгән ярың белән,
Мине яратмыйсың, беләм бит.
Синең белән башка очрашмабыз,
Хуш, бәхил бул, бәгърем Зиләйлүк.

Чыга. Зиләйлүк тә кереп китә. Миңзифа белән Тутай керәләр.

Миңзифа. Тутай, ни булды аңа, нишләде ул?

Тутай. Әйтте ул: мин сине яратам, яратмыйсың мине син, хуш, бәхил бул, дескать, багерем Зиләйлүк!

Миңзифа. Ул бата! Суга бата!

Тутай. Монда юк совсем су.

Миңзифа. Үз-үзен ата!

Тутай. Юк пистолет.

Миңзифа. Поезд астына!
Тутай. Поезд юк.
Миңзифа. Машина астына!
Тутай. Булса теләк — анысы табыла.
Миңзифа. Тутай, хәрәкәт ит!
Тутай. Табут?
Миңзифа. Нинди табут? Әйдә артыннан барыйк, коткарыйк.
Тутай. Ташланмаса әгәр... булмасмы йөгерү зря?
Миңзифа. Киттек!

Тутайны кулыннан тартып алып китә. Айдар, Газинур һәм Фирдәвес керәләр.

Фирдәвес. Зиләйлүк! Харап булды! Бәла!
Айдар. Кычкырма, йөрәген ярырсың.
Газинур. Әллә әйтми торабызмы?
Зиләйлүк (*чыга*). Ни булды?!
Фирдәвес. Миңголны?
Зиләйлүк. Нишләттеләр?
Фирдәвес. Әй лә... берни дә эшләтмәделәр.
Айдар. Аны...
Газинур. Алып киттеләр.
Зиләйлүк. Кая алып киттеләр?
Фирдәвес. Кая булсын... төрмәгә!
Зиләйлүк. Төрмәгә? Кемнәр?
Фирдәвес. Милиция.
Газинур. Арттырма. Төрмәгә үк түгел.
Фирдәвес. Әлегә.
Айдар. Ерунда! Курыкмагыз.
Зиләйлүк. Нигә алып киттеләр?
Айдар. Чепуха!
Фирдәвес. Булыр сиңа чепуха! Фабриканың соңгы гармунын урлаган!
Айдар. Һәм сезнең бүлмә тәрәзәсен ваткан өчен... янәсе.
Зиләйлүк. Пыяланы шундук куйды ич...
Газинур. Берни дә булмас, борчылма, Зиләйлүк.
Фирдәвес. Шаһитлар кул куйган. Тутай диме шунда...
Зиләйлүк. Ышанмыйм. Аның гаебе юк!
Фирдәвес. Әйттем мин сиңа: берсенә дә ышаныч юк дип...
Газинур. Телеңне тый!
Зиләйлүк. Әйдәгез, барып коткарыйк, гаепсез икәнен әйтик!

Фирдәвес. Кем ышана безгә? Кайгырма, уйларсың-уйларсың да онытырсың.

Зиләйлүк. Мин аның янына барам. Мин дә гаепле, мине дә кулга алсыннар.

Фирдәвес. Җүләр!

Зиләйлүк. Алып барыгыз мине анда...

Айдар. Мин барам.

Нәфисә (*тәрәзәдән*). Мин дә барам!

Фирдәвес. Юкка йөрисез. Барыбер коткарып булмый! (*Чыгалар.*)

## 7

Авансценадан Мирза уйнап-җырлап уза.

Бер җырлармын моңлы исемеңне
Уярмын да кыя ташына.
Һич тә үпкәләмимм язмышыма,
Татлы хәсрәт төште башыма.

Пәрдә күтәрелә. Миңзифалар квартиры.

Тутай (*керә*). Хәерле ял көне, Миңзифа Касыймовна!

Миңзифа. Хәерле көн, Тутай. Нинди уйларда йөрисең?

Тутай. Башка килә төрле уйлар. Әйткән идегез иске бабайлар мәкаләсен: «Әнисенә карап, дескать, кызын коч! Шуны хәзер карап ситуациягә әйтергә кирәк башкача: «Әбисенә карап малаен коч!»

Миңзифа. Уйларың зур икән. Афәрин, Тутай әфәнде! Башың да, акылың да бар синең.

Тутай. Остазым Мөбәрәк әфәнде шәкерте ведь. Математика. Техучилище.

Миңзифа. Ниләр бар? Табутка сорау бармы?

Тутай. Юк дәрәҗәсендә. Язга килеп чыккан халык үлә әзрәк. Рәхмәт аларга. Гармунга сорау килә күп. Аңлашылмый.

Миңзифа. Теге гармунчы малай рекламасы! Социализмга кайту юк! Гармун — узылган этап.

Тутай. Утырттым ведь тәки ул малайны, ә? Сезнең өчен...

Миңзифа. Мирза өчен.

Тутай. Операция чыкты — во!

Миңзифа. Мирзаны коткару өчен әллә ниләр эшләдек, Алла булса, кабул итсен инде.

Т у т а й. Кабул итә. Күр дә тор, онытачак Зиләйлүк тюремщикны.

М и ң з и ф а. Онытыр микән? Мирзага борылырмы?

Т у т а й. Йөз градуска борыла! Беләбез кызларны: «Чыгам генералга!» Тәтеми генерал, әйтәләр соңыннан: «Солдат булса да ярар иде» ... Рәхмәт.

М и ң з и ф а. Тутай, сыйлыйм әле бер үзеңне керткән өлешең өчен. (*Шампан куя.*)

Т у т а й. Кертергә өлеш әзермен һәрвакыт!

М ө б ә р ә к (*кайтып керә*). Минем өлешне дә онытмагыз. Миңзифа, ал, кадерлем! (*Роза чәчәкләрен бирә.*)

М и ң з и ф а. Роза чәчәкләре. Миңамы?

М ө б ә р ә к. Сиңа, Миңзифа.

М и ң з и ф а. Миңзифа дип исем белән дәштең...

Т у т а й. Рәхмәт.

М и ң з и ф а. Рәхмәт, Мөбәрәгем.

М ө б ә р ә к. Бүгенге бәйрәм котлы булсын, Миңзифа?

М и ң з и ф а. Әле иртәрәк. Нинди бәйрәм?

М ө б ә р ә к. Хәтерлә әле, шомырт чәчәк атканда без кая бардык?

М и ң з и ф а. Загста язылыштык түгелме?

Т у т а й (*шампанны ачып касәләргә сала*). Бул исән!

М ө б ә р ә к. Бүген бергә яши башлауга нәкъ егерме ел!

Т у т а й. Остазым, тост!

М ө б ә р ә к.

Мин гашыйкмын, юллардагы
Карларга гашыйк,
Язлар килсә, елгадагы
Ярларга гашыйк,
Яр буенда дулкынланган
Талларга гашыйк,
Салмак агып, уйга салган
Салларга гашыйк,
Салларга карап калучы
Ярларга гашыйк.
Шушында бәхет табучы
Парларга гашыйк,
Сүнгән дәртне уятучы
Таңнарга гашыйк,
Егерме ел яратучы
Бер кызга гашыйк!

Т у т а й. Браво, остаз! Егерме ел тагын бергә яшәгез!

Миңзифа. Нишләдегез сез? Монысы да авышканмалае артыннан! Каян таптың шундый сүзләрне? Гомер буе шигырь укымаган математик...

Мөбәрәк. Мирза өйгә шигырь китаплары ташый.

Миңзифа. Әллә соң син дә берәр кызга гашыйкмы? Алла сакласын.

Тутай. Укыганда мәктәптә мине дә шигырь ятларга иттеләр мәҗбүр.

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, совсем оныта алмамын...
Белмим... И белмәдем.

Чәпәде укытучы двойка! Опять двойка! Мөбәрәк абый да куйды двойканы күп. Борып карады колакны да. Әзрәк типте артка да. Рәхмәт аңа! И кеше итте.

Мөбәрәк. Колагың борылып җитмәгән.

Тутай. Тостның икенчесе: Мирзаның Зиләйлүкле булуы өчен!

Миңзифа. Күз генә тимәсен. Үзе генә акылын ташламасын инде. Аллага шөкер, авышса да, эчми башлады.

Тутай. Эчмичә исерә. Рәхмәт. Сузмыйча озак үткәрү өчен икесенең презентациясен!

Мирза (*кереп тыңлап тора да өстәл янына килә. Тынып калалар. Мирза үзенә дә шәраб сала*). Бер-берсен яратучы Зиләйлүк белән Миңгол өчен! (*Уртлап куя.*) Нигә күтәрмисез?

Миңзифа. Без сине югалттык, Мирза. Киткән чакта әйтеп кит: сине каян эзләргә?

Мирза.

Уттан-судан мине эзләмәгез,
Юлда булырмын,
Серле күңелемне ниләр тарта —
Шунда булырмын.
Кошлар кебек мин бик ярсулы да,
Тын да булырмын,
Кайда сайрау, кайда челтерәүләр,—
Шунда булырмын.
Кирәк икән гармун телләре дә,
Кыл да булырмын,
Кайда шатлык, кайда тирән хәсрәт,—
Шунда булырмын.
Мин югалсам, сулга каерылмам,

Уңда булырмын,
Җаным тынганда да аерылмам,—
Монда булырмын.

Миңзифа. Балам, югала күрмә. Без барысын да беләбез, яшермә. Синең өчен барысын да эшләдек.

Тутай. Рөхсәтме? Рәхмәт. (*Миңзифа башын селки.*) Мирза энекәш, син бел: булды минем остазым өч: тормыш — беренчесе, Мирза абый икенчесе, мине ул өйрәтте уйларга монументально! Өченчесе — синең мама! Миңзифа Касыймовна опять итте кеше. Үтәп шул бурычны үземнең талантны куйдым көйләргә синең язмышны. И көйләдем. Рәхмәт! Зиләйлүккә бардым яучы булып, син очрашуга барган участокны чолгап алдым аудио-видеомагнитофон белән... Шулар өстенә синең көндәшеңне аттым. Курыкмагыз, читкә аттым. Исмәгыйль кебек атмадым пистолет белән. Чакырдым милицияне и акт төзетеп олактырдым... кая дисез — читлеккә... алган өчен сорамыйча гармунын фабриканың и Зиләйлүкнең ваткан өчен тәрәзәсен... Рәхмәт миңа...

Миңзифа. Тутай сине бәхетле итү өчен барысын да эшләде.

Тутай. Зиләйлүк — синеке!

Мирза. Тутай әфәнде, үз гомереңдә синең берәр гашыйк булганың бармы?

Тутай. Гашыйк? Хи-хи-хи... Минем өчен бу несерьезно. Мин — акыл кешесе.

Мирза. Синең читлеккә ябылган сандугачны күргәнең бармы? Сары сандугачны?

Тутай. Хәтерләмимим.

Мирза. Иректә калган парының нигә саргайганын беләсеңме?

Тутай. Нигә ул миңа кирәк?

Мирза. Тутай, син — киллер!

Тутай. Киллер?! Минме? Рәхмәт. Тотканым юк кулга пистолет.

Мирза. Син — мәхәббәт киллеры!

Тутай. Миңзифа Касыймовна... Мин беркемне дә атмадым. Таянып нәрсәгә әйтәсең?

Мирза. Син яучы түгел, аучы — пар сандугачларның йөрәкләренә аткансың!

Тутай. Мин түгел «Галиябану»дагы Исмәгыйль. Мин атмадым.

Мирза. Исмәгыйль атуыннан да яман бу. Хәлил бик

тиз җан биргән. Син аткан сандугачлар бик озак газап чигәргә дучар ителгәннәр. Парсыз калган сандугачлар саргаеп үләләр. (*Тезен тезгә куеп утырган Тутайга.*) Тутай! Бас! Син хәзер минем белән барасың!

Т у т а й (*тора*). Кая?

М и р з а. Милиция бүлегенә.

Т у т а й. Нигә?

М и р з а. Үзең биргән мәгълүматларның ялган икәнен әйтеп, шушы кулың белән куйган имзаңны кире аласың. Киттек!

Т у т а й. Миңзифа Касыймовна... әйтегез аңа... үзем куштым дип... Рәхмәт.

М и ң з и ф а. Мирза...

М и р з а. Мама, без синең үзең белән генә сөйләшербез. (*Тутайга.*) Үз аягың белән барасыңмы, әллә милиция машинасы чакыртыйммы?

Т у т а й (*кызганыч кыяфәт белән Миңзифага карый, ул «бар» дип ымлагач*). Рәхмәт, рәхмәт. (*Чыгалар.*)

М ө б ә р ә к. Миңзифа, чыннан да Миңголны кулга алуда синең катнашың бармы?

М и ң з и ф а. Барысы да Мирза өчен. Үзе теләгән кызга — Зиләйлүккә өйләндереп, акылга утыртмакчы булдым.

М ө б ә р ә к. Шуның өчен Миңголны утырту кирәк идеме?

М и ң з и ф а. Мирзаның бәхеткә бару юлында Миңгол тора. Аны алып ташлау кирәк.

М ө б ә р ә к. Акылга утырдымы соң Мирза?

М и ң з и ф а. Утыру гына түгел, ычкынды.

М ө б ә р ә к. Яшьлек өчен табигый хәл, гашыйк булганнарның халәте. Мәхәббәт аның тупасланган хисләрен уяткан, сафландырган. Кире җавап алгач та ул Зиләйлүкне тагын да бәхетлерәк итәргә тели. Их Миңзифа, яши-яши оныттык без яшьлекнең сафлыгын. Оныттыңмыни минем дә сине яратып шашып йөргәннәрне... Син дә Зиләйлүк кебек горур, нәзакәтле идең. (*Музыка.*) Оныттыңмыни үзеңнең дә борын күтәреп йөргәннәреңне?

М и ң з и ф а. Онытылган.

М ө б ә р ә к. Исеңдәме?

Д у э т

М ө б ә р ә к. Мин сине яратам, гүзәл!

М и ң з и ф а. Ни өчен?

Мөбәрәк. Үзем дә белмим ни өчен.
Әллә борын очындагы
Бәләкәй генә миң өчен.
Мин сине яратам, гүзәл.
Миңзифа. Ни өчен?
Мөбәрәк. Инде тоттым дигәндә,
Ычкынуың өчен.
Миңзифа. Мин сине яратмыйм.
Мөбәрәк. Мин сине яратам!
Миңзифа. Ни өчен?
Мөбәрәк. Тоттым дигәндә, «Каравыл!»
Кычкыруың өчен.
Мин сине яратам, гүзәл!
Миңзифа. Ни өчен?
Мөбәрәк. Мине өзелеп яратып та,
Сиздермәвең өчен.
Миңзифа. Мин сине яратмыйм.
Мөбәрәк. Мин сине яратам, гүзәл!
Миңзифа. Ни өчен?
Мөбәрәк. Әнә шул сиздермәү белән
Биздермәвең өчен.
Мөбәрәк. Мин сине яратам, гүзәл!
Миңзифа. Ни өчен?
Мөбәрәк. Үзем дә белмим ни өчен.
Күпме мине газапладың,
Ни ачуым, ни үчем.
Мин сине яратам, гүзәл!
Миңзифа. Ни өчен?

Мөбәрәк. Үзем дә белмим ни өчен! (*Миңзифаны кулыннан тотып диванга утырта.*) Мин сине яратам, гүзәл...

Миңзифа. Минме гүзәл? Син мине чынлап яратасыңмы?

Мөбәрәк. Мин сине үзеңне морза кызы кебек тоткан чагыңны яратам. Нәрсәнедер югалттык без, Миңзифа...

Миңзифа. Нәрсәне югалттым соң мин?

Мөбәрәк. Яшьлек моңын югалттык. Аны миндә Мирза кабат уятты.

Миңзифа. Үземә дә әллә ничек булып китте әле...

Мөбәрәк. Әйдә, сандугачларны саргайтмыйк, без дә кавышырга ярдәм итик...

## 8

Мирза бинокльдән күзәтә.

З и л ә й л ү к. Миңгол!
М и ң г о л (*керә*). Зиләйлүк!
З и л ә й л ү к. Чыгардылармы?
М и ң г о л. Чыгардылар.
З и л ә й л ү к. Акладылармы?
М и ң г о л. Акладылар. Гафу үтенделәр.
З и л ә й л ү к. Әллә ниләр уйлап бетердем. Син чыкмыйча ишек төбеннән китмәдем. Кермәгән бүлмә калмады.
М и ң г о л. Мин белеп, тоеп тордым, Зиләйлүк. Борчылма, моннан соң гел бергә булырбыз. Парижга фестивальгә барып кайтыйм да...
З и л ә й л ү к. Китәсеңдәмени? Кайчан?
М и ң г о л. Иртәгә үк.
З и л ә й л ү к. Кавышырга да өлгермәдек, аерылабыз дамыни, Миңгол?
М и ң г о л. Мин анда озак тормам. Барыбыз да дулкынланабыз. Европага татар моңнарын алып барабыз бит.
З и л ә й л ү к. Французлар безнең моңны аңлар микән, Миңгол? Үзебезнең халыкта да үз моңыннан мәрхүмнәр бик күп ич. Читләргә бигрәк тә ят бит инде ул...
М и ң г о л. Үзебездә дә бераз шик бар, әмма ышаныч, өмет көчлерәк, Зиләйлүк.
З и л ә й л ү к. Йөргән юлларыгызда фәрештәләр юлдаш булсын!
М и ң г о л. Фәрештәм син ул, Зиләйлүк!

Күрешеп тә өлгермәдек,
Китәргә туры килә,
Кавышуның минутларын
Көтәргә туры килә.
Асыл кошым Зиләйлүк,
Әйтер сүзем бигрәк күп.

З и л ә й л ү к.

«Сөям» дигән күкрәк сүзең
Оялады йөрәккә.
Чит илләрдә сак була күр,
Читлекләргә эләкмә.
Хуш-исән бул, Миңголым,
Хәерле юл, былбылым!

Миңгол. Мин синең яныңа очып кайтырмын!

Зиләйлүк. Кайтыр юлларыңнан күзем алмый көтәрмен. Мин сине көтәрмен!

## 9

Фабрика янындагы мәйдан. Беренче күренештәге кешеләр җыелган.

Миңзифа. Товаришши-иптәшләр, җәмәгать-әфәнделәр, ханым-туташлар. Мин сезне җыйдым шуның өчен: үзегез беләсез, фабрикабыз һаман аякка басалмый тора. Кризистан котылу максатыннан без икенче төр продукция чыгарып карадык — табут! Бүгенгесе көндә хәл үзгәрер, бәлки: директор да аякка басты, тиздән кайтыр, бәлки... Әмма табут безне коткармас, ахры. Чөнкиме? Чөнки үлгән кешенең табут алырлык акчасы юк. Шуның өстенә үзебезнең гармунга ни өчендер сорау артты.

Берәү. Телевизордан Миңгол уйнап күрсәтте бит!

Миңзифа. Бәлки, рекламаның да файдасы булгандыр. Мәсьәләне хәзергә ачык калдырам. Дөресен әйткәндә, миндә шик бар. Безгә дөнья базарына чыгарлык продукция җитештерү дөрес булыр. Безнең гармун белән Казаннан ерак китеп булмый. Чит илгә чыгуны әйткән дә юк. Уйладык-уйладык, киңәштек-киңәштек тә без ярты дөнья мохтаҗ булган тагын бер мөһим продукция чыгарырга ниятләдек. Ул... Тутай, ач! (*Ябылган материяне ачалар.*) Сабыйлар арбасы! Беренче продукциянең приз... приз...

Тутай. Призентация!

Миңзифа. Призентациясен ачык дип белдерәм! Хәзер безне котларга бөтен дөньяга танылган мәшһүр артист киләчәк. Үзебезнең яшьләр чакырган.

Тавышлар. Әнә үзе килә!

Миңзифа. Каршылагыз! Музыка!

Кулына гармун тоткан Миңгол һәм аны озата килүче Зиләйлүк, Нәфисә, Фирдәвес, Айдар, Газинур керәләр.

Миңгол (*Сәйдәш көенә җырлый*).

Дусларым, сөенеп кайттым.
Дусларым, ерак илләрдән.
Уйнадым Сәйдәш көйләрен.
Чит булсалар да, ят булсалар да,

Ят итмәделәр гармун телләрен.
Аңлады ятлар, милли көйләргә
Йөрәк моңына читләр юк икән.
Тойдым үзем дә, дөнья йөзендә
Ихлас хисләргә чикләр юк икән.

Кушымтаны барысы да күтәреп ала. Җыр вакытында Тутай Миңзифага нәрсәдер барып әйтә, Миңзифа аны тыңламый, кулын гына селки.

Айдар. Кадерле моңдашларыбыз! Сез чакырган Миңгол Вәлиев оркестр солисты булып Парижда музыка фестивалендә катнашты. Алар иң югары бүләк — Гран-при алып кайттылар. (*Кул чабулар.*)

Хор

Миңгол, Миңгол кайткан,
Бүләк алып кайткан,
Безнең хәлне каян.
Каян сизгән наян!

Миңзифа. Үзебезнең гармун осталары исеменнән, шул эштә йөрәк пристубы алган һәм терелеп килүче директорыбыз исеменнән...

Тутай. Исеменнән Миңзифа Касыймовнаның. Факт!

Миңзифа (*аны бүлеп*). Кысылма! Мин дә чын күңелемнән котлыйм!

Берәү. Гран-при алып кайтучыга бер сорау бар иде?

Миңзифа. Рөхсәт.

Берәү. Миңгол Вәлиев әйтмәсме, Европаны таң калдырып, ул нинди гармунда уйнады икән?

Миңзифа. Әлбәттә, безнеке түгел инде!

Тутай. Рәхмәт. Әйттегез «во!»

Миңзифа. Менә шундый мировой товар эшләргә кирәк иде безгә дә!

Тутай. Әйттегез масштабно!

Миңзифа. Рәхим итегез, Миңгол...

Тутай. Әфәнде!

Миңзифа. Миңгол Вәлиев!

Миңгол. Бу гармун — сезнең фабрика иҗаты.

Миңзифа. Шаяртасыз.

Тутай. Критика — безнең адреска. Рәхмәт.

Миңгол. Мин шаярмыйм. Чынлап әйтәм. Күмәргә җыенгач, мин алып калган сезнең гармун бу.

Миңзифа. Юк, бу — безнең продукция түгел.Безнекендә мондый матур бизәкләр юк.

Миңгол. Мин аны үзем матурладым. Тавышына тәңгәл килсен дип...

Миңзифа. Юк, ышанмыйм.

Миңгол. Үзебезнең татар көен Европага алып чыккан бу гармунга һәм аны иҗат итүче осталарга — мең рәхмәт! Алдыгызда түбәнчелек белән баш иям, осталар! Ярты дөньяны әйләнеп кайткан бу кадерле гармунны сезнең үзегезгә кайтарып бирәм. (*Миңзифага тапшыра.*) Музеегызга куярсыз.

Миңзифа. Чынлап та безнең гармунмы бу? (*Тутайга.*) Кара әле!

Тутай (*карап*). Бик шикле. Факт.

Газинур. Акт?

Тутай. Рәхмәт. Искә төшермәгез.

Миңзифа. Осталар, соңгы сүз сезнеке!

Осталар.— Үзебезнең гармун!
— Төсе үзгәргән.
— Матурайган!
— Танырлык та түгел!

Миңзифа. Бу факт, иптәшләр, яңача уйларга мәҗбүр итә. Без бинокльнең кире ягыннан караганбыз. Турысын әйтик, без үзебезнең продукциянең кадерен белмәгәнбез.

Арадан берәү. Кадрларның дә кадерен белмәдегез, осталар китәләр.

Миңзифа. Килешми. Бабайларның акыллы ике мәкале дә безгә карый. Беренчесе: кадрларның кадерен бел, икенчесе: үлгәннәрнең каберен бел. Ике мәкаль өстендә без җиң сызганып эшләргә тиеш!

Миңгол. Безнең чыгыштан соң минем янга бик күп чит ил гражданнары килде. «Бу гармунны каян, ничек алдырырга?» дип кызыксындылар. Мин сезнең адресны бирдем. Бергә яулап алынган җиңү белән сезнең фабриканы да котлыйм!

Миңзифа. Ситуация үзгәрүне искә алып, мин бу кадерле һәм кыйммәтле гармуныбызны мәшһүр гармунчыбыз Миңгол Вәлиевкә бүләк итәм! Үз кулым белән... Шуңа өстәп тагын бер бүләгебез, чөнки без машина да, ат та бирәлмибез, иң беренче продукциябез — сабыйлар арбасы! (*Гармунны арбага салып, Зиләйлүк алдына килеп туктала.*) Сезгә, Зиләйлүк, Миңгол...

З и л ә й л ү к. Безгә иртәрәк әле...

М и ң з и ф а. Каенанаңа сәлам әйт.

Т у т а й. Беренче продукция презинтациясенә чакырыгыз. Рәхмәт.

М и ң г о л (*җыр башлый, башкалар кушылалар*).

Сөенечтән генә тамсын
Татлы күз яшьләрегез.
Ничә яшьтә булсагыз да,
Яшәрегез, яшәрегез!
Олы хиснең — Мәхәббәтнең
Баласы, яшьләре без.
Йөрәкләрдә сөю саклап,
Яшәрегез, яшәрегез!
Йөз яшьләргә җиткәндә дә
Әйтегез: «Яшь әле без!»
Сөю утын сүндермәгез,
Яшәрегез, яшәрегез!
Күңелләрдә яшьлек булса,
Агармас чәчләрегез,
Уңай барыр эшләрегез —
Яшәрегез, яшәрегез!

Миңгол белән Зиләйлүк арбадагы сабыйны — гармунны Киләчәккә алып китәләр. Миңзифа, моңсуланып, аларга карап кала. Аның янына Мирза да килеп баса. Аларны Мирзаның үзәк өзгеч җыры озата.

П ә р д ә.

*1999*

# Гашыйклар тавы*

*Повесть-поэма*

Элекке дәверләрдә Гашыйклар тавында түгәрәк тирән күл булган, диләр. Туган җирләрен сагынып, тезелешеп, язларын киек кошлар кайтканнар. Көннәрдән бер көнне шул якның сунарчысы, нәни балалары белән күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да, пешереп ашарга ниятләп, ут өстендәге казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, Серле үрдәк казаннан күтәрелеп, зәңгәр һавага очкан...

Шул көннән соң, Гашыйклар тавының матурлыгы күзгә күренеп сулган, күле корыган...

*Борынгы риваять*

## 1

Бу юлы командировкам мине Себергә, Юрга каласына китерде. Себер дигәч тә, табигатьнең бездән әллә ни аермасы юк: нәкъ бездәге шикелле яшькелт-сары яфракларын кояр-коймас утыручы ак каеннар, бакчаларда — күз явын алырлык август чәчәкләре... «Анда суыктыр» дип алган җылы курткамны салып кулга тотарга туры килде. Каршы алырга төшүче өлкән яшьтәге Хәнәфи ага мине кунак йортына урнаштырды да үзенә алып китте. Хатыны Сәлимә апа бик җылы каршылады. Икесенең дә туган ягы шушында. Хәнәфи ага шуннан сугышка киткән, яраланган, тагын үз заводына эшкә кайткан: «Туган туфрак үзенә тарта, шунда тудым, шунда үләрмен дә инде»,— ди. Сәлимә апа яратып, шаяртып кына, кул селтәгән була:

— Әй, картлач, әллә ничә тапкыр үлдең инде... Хәзер чынлап үлсәң дә ышанмыйм.

Чыннан да, Сәлимә апа ике тапкыр «Ирегез Хәнәфи Вафин геройларча һәлак булды» дигән хәбәр алган, өметен өзмичә көткән.

Мин, шәһәр советы тарафыннан рәсми чакырылганлыктан, кичен халык белән очрашуга бардым. Язучы

* 1992 елда Чаллы татар дәүләт яшьләр театрында куелды.

буларак, үземнең әсәрләремне укыганнан соң, күп кенә сорауларга җаваплар бирергә дә туры килде. Әмма иң кызыгы алда иде әле. Шушында, Татарстаннан бик ерак Себер шәһәрендә, татар яшьләре бергә җыелып, ансамбль оештырганнар: алар бергәләп сөенәләр, бәйрәм итәләр. Үзара кайгыларын уртаклашканда да җырлыйлар, үз моңнарын кичен мәдәният сараенда халык белән дә уртаклашалар. Хәнәфи ага исә үзе җитәкче, үзе — менә дигән конферансье. Ансамбльнең исеме дә җанга ятышлы — «Сагыну». Әллә кайчаннан таныш безнең як көйләре биредә бигрәк тә ягымлы ишетелә икән. Тукта... Ә монысы нинди җыр? Мин ишетмәгән-белмәгән, безнең якларда җырланмаган көй. Озын кара толымлы, кара күзле кыз җырлый:

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн — ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман,
Кайтыр юлларымны югалттым.
«Туган якларыңа кайт! Кайт!» диеп,
Киек кошлар тезелеп киткәндер...
«Кайта!» диеп өзелеп көткәндер дә,
Көтә-көтә түземе беткәндер.
Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр...
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Кичә тәмамланды. Ансамбль яшьләре мине кунак йортына озата киттеләр. Мондый җылы август төнендә җәяү йөрүгә ни җитә,— трамвайга да утырмадык. Алар, шул җырны җырлап, төнге урамнар буйлап баралар:

Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын,
Кош тавышы белән кычкырган...

Хәнәфи агадан ипләп кенә сорыйм:

— Нинди җыр бу? Кем язган?

— Аның исеме юк иде. Без аны «Яралы кош» дип атадык. Авторы — шушы ансамбльне оештыручы. Мин аның шәкерте генә.

— Үзе кайда соң? Исәнме?

— Исәнлеген исән... Килә алмый...

Мине кунак йортына кадәр китерделәр дә яшьләр,

тыныч йокы теләп, өйләренә таралдылар. Икәүдән-икәү генә калгач, Хәнәфи ага башлаган сүзен дәвам итте:

— Казаннан икәнегезне белгәч, җырның авторы Сезне бик күрәсе килүен әйтте. Сез иртәгә ничек тә вакыт табыгыз инде, үзем илтеп куярмын. Хәерле төн!

Бу төнне бик озак йоклый алмый яттым. Нинди сере бар бу җырның? Көен дә, сүзен дә үзе чыгарган, диләр. Мондый җыр нindидер авыр хәлләр кичергән кешенең йөрәгендә генә туа ала. Нинди язмыш аны туган җиреннән аерган икән?

Икенче көнне Хәнәфи ага, машинасына утыртып, мине Юрга урамнары буйлап алып китте. Шәһәр әллә ни зур түгел, халык берән-сәрән генә күренә. Урамнар иркен, шоферга мондый юлларда йөрү рәхәттер. Биш катлы өй янында машинасын туктаткач, Хәнәфи ага мине икенче каттагы квартирага алып менде. Звонок шалтыратты, ишекне ачып, өй эченә атлады, ымлап, мине дә артыннан ияртте. Хуҗаның үзен күргәч, мин аның: «Керегез!» — дигән карлыккан тавышын ишеттем. Ак күлмәк, кара чалбар кигән, кыска буйлы, ябык чырайлы кеше колясkада утыра иде. Сүзсез генә чишендек. Сул кулы белән коляска тәгәрмәчен тәгәрәтеп, хуҗа түргә юнәлде:

— Узыгыз!

Хәнәфи ага, ымлап, креслога күрсәтте дә:

— Берәр сәгатьтән килеп алырмын,— дип китеп тә барды. Сүзне нидән башларга белмичә, икебез дә аптырабрак тордык. Бүлмә тулы ал гөлләр: тәрәзә төпләрендә дә, өстәлдә дә, стенадагы асылмалы чүлмәкләрдә дә... Бер кырыйда — вак балыклар йөзеп йөргән аквариум. Эчендә — камыш сабаклары... Хуҗаның игътибар белән күзәтүен тоеп, мин уңайсызланып киттем. Ниһаять, ул, телгә килеп:

— Мин Сезне көттем,— диде. Шул вакыт авызының бик авыр ачылуын шәйләп, бу сөйләшүнең аңа җиңел түгеллеген абайладым. Аның ярты гәүдәсе хәрәкәтсез иде...

— Сез Татарстаннан бит, шулаймы?

— Әйе. Тумышым белән Башкортостаннан. Ул коляскасын миңа якынрак тәгәрәтте.

— Шулаймыни? Кемнәрегез бар анда?

— Әни. Әти.

— Димәк, кайткалыйсыз?

— Сагынган саен. Моннан кайтышлый да кереп чыгарга исәп.

— Таллыкүл авылын белмисезме?

— Белмим шул.

— Гашыйклар тавы турында ишеткәнегез бармы?

— Гашыйклар тавы? Безгә әлләни ерак түгел ул. Аның легендасын безнең тирәдә дә сөйлиләр. Җиде көн казанда кайнагач очкан кыр үрдәге...

— Әйе... Әйе! Ул легенда... чындыр, бәлки... Ул, зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, миңа карады:

— Таллыкүл авылы Гашыйклар тавына терәлеп тора. Әгәр мин әманәт тапшырсам... Сез анда бара алмассызмы?

— Нинди әманәт бит?

— Сез кичә «Яралы кош»ны тыңладыгызмы?

— Әйе. Аны Сез чыгарган, диләр, дөресме?

— Дөрес.— Ул, башын иеп, арыган кәяфәттә, бераз дәшми торды.— Әманәтем шул: «Яралы кош»...

— Кемгә тапшырырга?

— Таллыкүл: Мөнирә Идрисовага.

— Ничек?

— Менә сезгә — магнитофон. Тасмасында — «Яралы кош». Үземнең тавыш. Мөнирә җырны ишетсен иде. Кем икәнне әйтмәсәгез дә, җырымнан мине — Сәет Зилаеровны танып алыр...

— Аңладым. Тасмасын гына бирегез. Үз магнитофоным бар.

— Рәхмәт, якташ.

— Белергә яраса, кем соң ул Мөнирә?

— Сөйләве авыр...

Сәет ага үзенең коляскасын читкәрәк тәгәрәтте, аквариум янында туктап, эчендәге балыкларның кагылуыннан талгын гына тирбәлеп-тирбәлеп куйган камышларга текәлде.

— Сез мине аңларга тырышыгыз... Беренче тапкыр мин аны урманда күрдем. Их, безнең Таллыкүл урманнары! Ярты дөньяны әйләндем, дигәндәй, юк андый урманнар беркайда! Урманчы әтием үлгәч, Таллыкүл участогына мине, унтугыз яшьлек егетне, куйдылар. Киләм берзаман шулай урман буйлап, үз уйларыма бирелеп, кош-

лар тавышын тыңлап... Шулчак, колакка ялгыш ишетеләме дисәм, юк, чыннан да кемдер нечкә генә, көйле генә тавыш белән аваз бирә:

— Ау-у-у!

Андый хәлләрне күргәнем бар, кемдер адашкандыр. Ун чакрымга ишетелерлек тавыш белән җавап бирәм:

— Э-һе-й-й!

Сез мине аңларга тырышыгыз: урманда туган баланың колагы сак: кошлар әнә шулай бер-берсен эзлиләр. Барып чыктым йөгерә-йөгерә Түгәрәк болынга, күрәм: кәрзин тоткан, зәңгәр күлмәк кигән, яланбашлы кыз каен төбенә утырган.

— Нишлисең син монда?

— Күрмәйсеңмени ния, адаштым ич...

Безнең якта шулайрак, көйләбрәк сөйләшәләр. Сез аңларга тырышыгыз, кызның җыр кебек сүзләре, беленер-беленмәс кенә тибрәлгән йомры күкрәкләре, яндырып алган коңгырт күзләре әллә нишләтте дә куйды...

— Кем кызы соң син?

— Кара, танымайсыңмыни, Сәет абый, түбән оч Мөнирә ич мин.

— Сафа абзый кызымы?

Ул, таныганга сөенеп, сикереп үк торды:

— Әйе. Тугызынчы класс укучысы Мөнирә Идрисова. Бу сүзләре белән кыз минем дөрләгән хисләремә бозлы су сиптемени: иреннәре җиләктән алсурак тоелган сөйкемле кыз — укучы бала гына икән.

— Әйдә, өеңә кайтарып куям.

Нәни генә, йомшак кына кулларына кагылгач, йөрәгем сулкылдап, тәнем дерелдәп китте. Ул, куркынып, кулларын тартып алды да, поши баласы сыман, читкә ыргылды:

— Тотмагыз! Үзем дә кайта беләм!..

Һәм китте... китте урман сукмагыннан. Беркем дә белмәгән, үзе генә йөргән сукмаклардан. Мин, тукталмакчы булдым, юк, мөмкин түгел, үземнән-үзем аның каен җилендә җилфердәгән зәңгәр күлмәгенә тартылам, иярәм.

— Мөнирә... тукта, сеңелем...

Туктады Сафа кызы Мөнирә. Кинәт кенә борылды да мин генә ишетелерлек итеп пышылдады:

— Мин... адашмадым...

— Кара урманда ялгызың нишләп йөрисең соң болай, сеңелкәш?

Ул, кызарып, башын түбән иде дә:

— Мин сезне яратам, Сәет абый,— диде. Шуннан йөзен куллары белән каплады да урман эченә кереп югалды. Сез аңларга тырышыгыз, якташ, минем нинди хәлдә калганны. Уналты яшьлек кыз сиңа мәхәббәтен ачыктан-ачык белдерсен әле... Юк, балалыктан күчү чорының хыялый бер җилпенүедер бу, дип, үземне тынычландырам. Әмма зәңгәр күлмәген тибрәндереп, күз алдыма Мөнирә килеп баса. Әллә инде үзем дә гашыйкмы? «Юк, ярамый, син олырак кеше, тыел!» — ди акылым. Ә йөрәк буйсынмый: «Кызның яшьлек тилерүе генә булмаса ярар иде»,— ди. Үземне тиргим, аны онытырга тырышам. Әмма хыялымда — Мөнирә. Ул узган сукмакларда, болыннарда йөрим, иреннәрем: «Мөнирә, Мөнирә»,— дип кабатлыйлар. Тагын килеп чыкмасмы дигән өмет мине шул кадерле урыннарга китерә. Таллыкүл урамнарыннан, мәктәп яннарыннан урыйм, ул яшәгән өй яныннан узам. Тәрәзә төпләрендәге ал гөлләре арасыннан зәңгәр чәчәгемне күрермен дип хыялланам. Аңлыйм: хәзер ул үз хисләреннән, мәхәббәтеннән качып йөридер.

Икенче тапкыр мин аны клубта укучылар концертында күрдем. Араларында гармунчы булмаганлыктан, мине чакырдылар:

— Бер укучы кызыбызны җырлат, зинһар, коткар,— дигәч, әлбәттә инде, ризалаштым.

— Концертыбызның чираттагы номерында Таллыкүл яшьләренең яраткан җыры —«Җиләккә бармам инде». Җырлый Мөнирә Идрисова. Гармунда — Сәет Зилаеров!

Гармунымны күтәреп, сәхнәгә чыгам. Әллә инде тез буыннарым калтырый, үз хәлемне үзем генә беләм. Янында гына ап-ак күлмәк кигән, аккош сыман озын ак муенлы Мөнирә. Ул бит минем белән җырлыйсын белмәде. Нишләр? Оялып, сәхнә артына кереп качмасмы? Көйне ахырынача җырларга үзендә көч табармы? Гармун телләренә башта курка-курка гына кагылам, аннан, әллә гармуннан, әллә тирәннән — күңел түреннән сихри авазлар агылуын тоеп кыюланам, үзем дә көй дулкынында тирбәләм.

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, сүзсез калдым,
Адаштым дип алдаштым.
Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде;
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.
Җиләклеккә бармам инде,
Бармам инде, адашмам,
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашмам...

Җыр тәмамлануга, без сәхнәнең ике ягына ташландык. Әйе, ташландык. Мин, шашкан адәм кебек, әллә сөенечтән, әллә көенечтән туп-туры урманыма чумдым. Хәзер мине аңласа, бары тик караңгы урман гына аңлый. Үземнең кайдалыгымны таң аткач кына белдем: күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәкләренә карап утырам икән, үзем һаман җырлыйм...

Өлгергән ич димәгез,
Җиләкләргә тимәгез.
Миндәй дивана булырсыз:
Яшь кызларны сөймәгез!

Сез су эчә-эчә тыңлагыз, якташ...

(Сәет ага өстәл янына тәгәрәп килде, сусавын тоеп, тустаганына су салдым.)

Аннан соң... мин салкыннан калтыранган тәнем белән янда гына Мөнирәнең кайнар сулышын сиздем.

— Сәет абый... беләм... Сез мине яратмыйсыз... мине бала дип уйлыйсыз... Сау булыгыз... мин башка килмәм...

Аны әллә кулларым, әллә тыннарым белән тартып алдым, әллә ул кочагыма үзе килеп керде, әллә ике омтылыш бергә туры килде, хәтерләмим, шулай да ул, тыпырчынып, кочагымнан ычкынганчы, әйтеп өлгердем:

— Мөнирәм... яратам...

Сез мине аңларга тырышыгыз, якташ, шундый сафлык, пакьлек, гөнаһсыз сак хәрәкәтләр...

Гөнаһ шомлыгына, Сафа абзый, нидәндер шикләнеп, кызы артыннан күзәтеп, эзләп килгән икән. Мин аның ямьсез тавыш белән:

— Эт сөйрәгере кыз! Менә син нишләп йөрисең икән! — дип акыруыннан айнып киттем һәм Мөниранең урман эченә кереп качуын күреп калдым.

Аңласагыз иде, якташ, хәлләремне... Мине, балигъ булмаган кызны ялгыш юлга юнәлтүдә гаепләп, комсомол секретаре вазифасыннан азат иттеләр. Ярый, анысы түзәрлек. Мөниранe каты куллы атасы чыбыркы белән кыйнаган, әнисе якламаса, тагын да яманрак буласы икән. Әмма бернинди чаралар да безне аерырлык түгел иде инде. Без бик сирәк кенә, яшеренеп кенә, урман сукмакларында очрашуларны дәвам иттек. Их, якташ, нигә соң мин шагыйрь булып тумаганмын, язып бирер идем мин сезгә... тел юк... тел!

Сугыш башланган айны аңа унсигез яшь тулды. Яуга киту хәбәрен көз көне алдым. Ни өчендер Таллыкүлнең киек кошлары киткәч кире әйләнеп кайттылар. Мөниранең күзләрендә — шом.

— Сәет абый, кошларның кире әйләнеп кайтуы хәерлегә булыр микән... әллә нинди уйлар килә... Шома чәчләреннән сыйпап юатам:

— Бер дә борчылма! Юлларында ни дә булса очрагандыр... Сугыш, афәт!

— Юлларың уң булса ярар иде, Сәет абый...

— Безнең сәгать сукты, Мөнирә, әйдә, Гашыйклар тавына!

Мин сезгә Гашыйклар тавы турында сөйләмәдем бит әле. Авылның югары очыннан, күл яныннан күтәреләсең. Элек-электән килгән гадәт: гашыйклар шул тау башына менеп, туган җиргә карап, бер-берсен ташламаска, мәңге тугры булырга, шушы урында кабат очрашырга вәгъдә бирешәләр. Кем дә кем антын боза, күр дә тор, аңа нинди дә булса бәла-каза килә: йә авырый, йә үлә, йә бәхетсез язмышка дучар була... Ай-һай, белмим, риваять кенә микән?.. Без дә, ике гашыйк, таңны каршыларга дип, Гашыйклар тавына күтәрелдек. Аста, бихисап төсләр белән таң нурында җемелдәп, Таллыкүл ялтырап ята. Анда — юллары бүленгән, китәлми калган киек кошлар... Ул, кочагыма сыенып, үзендә шаярырлык көч таба.

М ө н и р ә. Кара аны, үлеп-нитеп калсаң, өйгә кайтып керәсе булма!

Сәет. Синең янга кайтмыйлармыни, Мөнирә! Яз җиткәч, кошлар белән кайтып җитәрмен.

Мөнирә. Вәгъдәме?

Сәет. Вәгъдә, кадерлем. Менә син шушы яшьлегең, чибәрлегең белән ятларга карамассыңмы, көтәрсеңме мине?

Мөнирә. Көтәрмен, Сәет абый, кайта гына күр. Юлларың бүленеп, озаграк кайталмый торсаң да, гел-гел көтәрмен.

Сәет. Көт, Мөнирәм, көтсәң, мин үлмәм, һичшиксез, кайтырмын!

Мөнирә. Безне бернинди дошман да, сугыш та аера алмас, Сәет абый...

Сәет. Мөнирәм, әйтмичә китә алмыйм. Мин кичә кыр үрдәген аттым...

Мөнирә. Аттың? Кыр үрдәген? Сәет абый, нишләдең? Нигә? Ни өчен?

Сәет. Мин урманчы гына түгел, аучы да... Кыр үрдәге белән сыйланып, төне буе Гашыйклар тавында синең белән утыру иде исәбем...

Мөнирә. Хараплар иткәнсең, Сәет абыкаем... Үтердеңме?

Сәет. Үлмәде бугай. Күлгә килеп төшкәч, эзләгән идем, табалмадым. Мөгаен, яраланган гынадыр... Ана үрдәк булды бугай... Балалары...

Мөнирә. Риваятьне оныттыңмы әллә, Сәет абый?

Сәет. Әй, ышанма иске йолаларга... Берни дә булмас!

Мөнирә. Хәерлегә юрыйк... Нигәләр аттың, Сәет абый! Үзең кошлар белән кайтып җитәрмен дисең...

Сәет. Кайгырма, Мөнирә, бер үрдәген югалтканнан Таллыкүл корымас. Без язмыштан өстен яңа чор кешеләре! Оныт... Кара минем күзләремә... Сөясеңме мине, әйт Таллыкүл буйлары ишетерлек итеп!

Мөнирә. Сөям, Сәет абый, мин — мәңгегә синеке!

Сәет. Алайса, сөюебезне җыр белән раслыйк!

Әкрен генә гармунымны сыздырып җибәрдем — без икәүләп, әтиләр-әниләр телендә дә тибрәлгән таныш көйне җырладык:

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында;
Онытыйк шомнарны,

Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.

Без — тауның башында,
Мәңгелек каршында —
Гашыйклар очрашкан урында.
Җанда — Ай нурлары,
Хисләр — саф, югары:
Биектә — Киек Каз Юлында.

Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге җир алдында:
Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

Ул төн җыр булып күңелдә уелып калды. Икенче көнне без авыл советына барып язылыштык. Бер атнадан мин фронтка киттем.

Аннан соңмы? Аннан соң мәхшәр, кыямәт... Сугыш, чигенү, окоп, үлеш, кырылыш... Соңыннан гына белдем: бер һөҗүмнән соң, өйгә «үлде» дигән хәбәр җибәргәннәр. Шулай да мин, инде үлдем дигәндә дә, Мөнирәне уйлап, исән кала килдем. Дошман тылында йөрдем, үлекләр өстеннән шуыштым, чәнечтем, үтердем! Бер ел, ике, өч ел ут-боз эчендә. Гүзәл кыз Мөнирә, Гашыйклар тавы яшьлекнең хыялый мизгеле булып кына калды. Өстеңә бомбалар коелганда, һәр адымда үлем сагалаганда, яшьлек хатирәләре күмелә икән, якташ... Сез мине аңларга тырышыгыз. Камалышта калып, күпме ач йөрдем, яраландым, әсирлеккә эләктем, качтым, партизан булып сугыштым, тагын үзебезнең якка чыктым. Өйдәгеләр өчен мин — батырларча һәлак булган кеше... Ниһаять, яраланып, госпитальгә эләктем. Әллә ни авыр яра түгел, тәмугтан котылган безнең ише солдатка — санаторий инде. Сугыш бетәргә инде күп калмаган, күкрәктә орден-медальләр ялтырый-чылтырый. Кулда — немец аккордеоны...

Атландым атның биленә,
Киттем герман иленә;

Герман җире-яшел үлән,
Йә кайтам да йә үләм!

Яшәп калырга кирәк, аз булса да! Шнапс чөмерәбез, типтерәбез, кызларга күз төшерәбез! Шундагы Ләлә исемле шәфкать туташына иләште куйды Сәет абзагыз! Көн саен очрашабыз, тәмам ир белән хатынга әйләндек. Рәхәт тормышны үзебез сугышып алдык, исән калдык, кадерен белеп кенә яшисе хәзер! Тотарга да Ләләнең туган җиренә — Себергә ычкынырга! Фашистның муенын борган бездәй ир-егетләргә кайда да бер — Себер дә үзебезнеке! Кем көтә анда яшьли һәлак булган солдатны? Мөнирә? Ул инде, хәбәр алу белән, онытып, кияүгә чыккандыр... Бетте сугыш... калдым мин исән, киттек без Ләлә белән бергәләп Себергә! Менә шулай уйлады ул чак егерме биш яшьлек Сәет Зилаеров...

Еллар узды, якташ, җилләр исте үзебезнең Таллыкүлне искә төшереп, сулар акты тын гына тирбәлеп, атылган үрдәкне, юллары бүленгән киек кошларны хәтерләтеп... Тауга менгәндә, тын кысыла башлады... яшь чакларны, Гашыйклар тавын сагындырып... Мин түгелме саф җанлы табигать баласы Мөнирәгә: «Кайтырмын, көт!» — дигән егет? Ничек тә аңларга тырыш, якташ, гомеремнең соңгы еллары — тоташ газап... Ник кайтмадым Таллыкүлгә, мин бит вәгъдәләр бирдем Мөнирәгә. Гөнаһсыз, чиста күңелле кыз, бәлки, мине көткәндер тилмереп... «Ниләр генә булса да, көтәм,— диде,— мин сиңа ышанам»,— диде. Әллә ничә тапкыр кайтырга, үлгәнче Мөнирәдән бәхиллек сорарга, гафу үтенергә ниятләп карадым, дүрт ел үлем белән көрәшеп җиңеп кайткан гвардеецның шуңа батырлыгы җитмәде. Менә хәзер, бик теләсәм дә, кайта алмыйм. Вәгъдәгә хыянәт... Риваятьнең дәвамы. Хорафатларга ышанмасам да, кайчак шикләнеп куям: әллә, мин әйтәм, Таллыкүл үрдәген аткан өчен язмыш үземне каһәрлиме? Кирәк бит: нәкъ кыр үрдәген аткан уң кулымны паралич сукты. Исемдә: мәчет манарасын кискән авылдашымның кулы корыган дип сөйләгәннәр иде. Юк, бу — дин файдасына түгел, бары тик киеренке кичерешләргә бәйләнгән: кеше гомере буе шул гөнаһы өчен газаплана, гел шуның турында уйлый, шул ырым дөрестер, дип, куркып яши һәм тәннең иң көчсез шул урыны хәрәкәтсез кала. Инде бөтен өмет сездә, якташ... Зинһар, «Яра-

лы кош»ны аңа җиткерегез. Кияүгә чыгып, балалары булса да... Бары тик үзенә генә. Башка бер сүз дә әйтмәгез. Җырдан ул барысын да үзе аңлар: минем әлегә исәнлекне, газапларымны, хыянәтемне, мәхәббәтемне...

— Хатыныгыз? Ләлә?

— Ул барысын да белә. Яшермәдем. Сез киләсен белгәч, уңайсызламас өчен чыгып китте. Ул үзе болай әйбәт хатын, әмма бәхетсез. Мин үзем дә бәхетсез инде, фактически. Балалар да булмады, ичмасам...

Сәет ага арыган, сүнә барган күзләре белән ялварып карады:

— Әманәтне тапшырырсызмы?

— Ышана аласыз. Таллыкүлгә барырмын. Мөнирәне эзләп табармын.

Җырны тагын бер тапкыр искә төшерергә теләптер, ахры, ул сул кулы белән өстәлдәге магнитофонны көйләде, аннан Сәет аганың өзгәләнгән тавышы ишетелде:

Хәзер үзем яралы кош сыман,
Кайтыр юлларымны югалттым...

Билгеләнгән вакыт җитеп, мине алырга Хәнәфи ага килгәндә, без инде саубуллаша идек. Сәет ага, оясыннан чыга алмаган, канатлары каерылган кош кебек, талпынып куйды:

— Сез бәхетле: Таллыкүлне, аны күрәсез... Сәлам барысына да... Таллыкүл камышларына... Гашыйклар тавына... Зинһар, андагы хәлләрне сөйләп миңа хат языгыз яки Хәнәфигә шалтыратыгыз. Көтәрмен...

## 2

Мин утырган поезд, Себер карурманнарын, үзәннәрен, тау-елгаларын артта калдырып, ярсулы тавыш белән таныш урыннарын сәламли-сәламли, алга чаба. Тәгәрмәчләр бары мин үзем генә тойган көйгә тәгәриләр. «Әйләнеп кайтам, әйләнеп кайтам» дип кабатлыйлар шикелле. Тышта җылы, кояшлы сентябрь, әле табигать саргаерга өлгермәгән. Мин башта үземнең туган районыма — Яңавылга туктарга, аннан Таллыкүлгә барып килергә уйладым.

Туган як!

Шаян колындай уйнап, яшел болыннардан яланаяк чапкан балачагың, татлы сөю газаплары белән яндырып акылдан шаштырган хыялый яшьлегең ак томаннар, күксел таулар артына китеп ерагайган саен,— үзең торган, күнегелгән җиреңдә гаилә корып, дус-ишләр тапсаң да, бәхетле чагыңда да, иң авыр минутларыңда да гел сиңа, сиңа тартыласың. Эре-эре җиләкләрең, әчкелтем-төчкелтем кузгалакларың, тәмле балтырганнарың белән сыйлаган кунакчыл урманнарың, өздереп сайраулары белән дәрт-дәрман уяткан кошларың,— төнлә төшеңә керсәләр дә, чиксез рәхәтлек кичерәсең. Һәркемнең үз ягы, үз төбәге — үзенчә кадерле, үзенчә газиз.

Мин язмыш зилзиләсе туган ягыннан аерган кешенең әманәтен алып, ул яшәгән, үскән, гыйшкы кабынган җирләргә барам. Яңавыл станциясенә иртә-таң белән төшеп, әти-әниләрне сөендердем дә, кайтышлый тагын керергә сүз бирдем һәм, Таллыкүл ягына юнәлгән автобуска утырып киттем. Миңа ничек тә Мөнирә Идрисованы табарга кирәк. Ике сәгать чамасы асфальт юлдан баргач, шофер машинаны туктатты:

— Таллыкүл! Сулга китегез!

Плащымны кулга алып, кыр буйлап сузылган юлга каерылдым. Басулар бушап, салам эскертләре генә өелеп калган. Барам-барам да, туктап, алга карыйм: бер генә җан иясе дә күренми — мондый вакытта олысы-кечесе — бәрәңгедәдер. Тимер канатларын җилпеп утыручы нефть скважиналары тирәсендә дә кешеләр юк. Борылмалы юлдан атлый торгач, тагын асфальт юлга чыктым. Сәет ага сөйләгән Гашыйклар тавы кайда соң? Киек кошлар йөзәрлек күл кайда? Җиләккә барсаң адашырлык куе урманнар кайда? Ниһаять, алда әллә ни зур булмаган тау күренде, аннан да ерактарак күгелҗем-карачкыл урман төсмерләнде. Мөгаен, Таллыкүл буйлары шулдыр. Выжылдап «Москвич» узып китте — туктатмадым, җәяүлеләр очрар әле. Авылга килеп кердем. Бу — үзәк урам, ахры. Сул якта — зур гына кибет, аннан ары — өр-яңа мәдәният сарае. Туктадым, кызыл хәрефләр белән язылган белдерүгә игътибар иттем: «Бүген яшьләрне озату кичәсе! Гашыйклар тавында кичке сигездә көтәбез!» Таштан салынган ике катлы колхоз идарәсе. Хәзер мине аякларым түгел, уйларым алып бара: берән-сәрән оч-

раштырган кешеләрдән дә сораштырмыйм, авыл белән үзем танышасым килә. Монысы — бакча. Эчендә — түрдә Ватан сугышы корбаннарына һәйкәл. Ташка уелган йөзләгән исемнәр... Тукта, ни бу? «Зилаеров Сәет»... Бу — мин күргән, миңа әманәтен биргән Сәетме әллә? Бәлки, исем-фамилиясе туры гына килгәндер...

Урамга чыккач, беренче очраган кыздан сорадым:

— Әйтегез әле, сеңелем, бу — кайсы авыл?

— Зирекле.

— Зирекле? Мин ялгыш килдем микәнни?

— Сезгә нинди авыл кирәк, абзый?

— Таллыкүл, Гашыйклар тавы.

— Ә-ә-ә... шулай диләр аны. Нәмә сразы әйтмәй торасыз... Әнә Гашыйклар тавы... күренеп тора.

— Сеңелем, сез Таллыкүлдән Мөнирә Идрисованы белмисезме?

— Әллә, белмәем,— диде дә кыз, ашыгып, идарәгә кереп китте. Ә миңа рәсми йортка керү кирәк түгел,— эшем бик тә шәхси, бик тә нечкә... Мин — әманәт иясе, язмышлар илчесе.

Зирекленең озын киң урамын үтеп, авыл читенә чыгуга, як-ягында сирәк-мирәк агачлар үскән, нефть скважиналары тирәсендәге бормалы юлга һәм алдымда пәйда булган тауга игътибарым юнәлде.

Гашыйклар тавы, мөгаен, шулдыр. Таллыкүл авылы кайда соң? Тау артындамы? Тирә-якта каен, чыршы, юкә агачлары күренгәли. Урман дип һич тә әйтерлек түгел. Керсәң, адашырлык калын кара урманга кайчан җитәрмен? Сәет ага урманны Таллыкүлгә терәлеп тора дигән иде югыйсә... Көз җылы килүгә карамастан, агачлар җәйге киемнәрен салалар, яшькелт-сары яфракларын кияләр. Әнә якында гына — берничә яңа өй. Аларның артында гел иске йортлар бугай.

Шулчак ерак та түгел, каеннар ешлыгыннан таныш җыр ишетеп, сагаеп, туктап калдым. Әллә Мөнирәме?

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым,
Сине күргәч, сүзсез калдым,
Адаштым дип алдаштым.
Әй-й-й!

Сөенечтән нишләргә дә белмичә, җыр ишетелгән якка талпынырга да өлгермәдем, икенче яктан мотоцикл дөбердәве, бераздан мотор тавышы тынып, бер егетнең җыры ишетелде:

Җиләклеккә барма инде,
Барма инде, адашма,
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашма!
Әһе-й-й-й!

Җыр авазлары тынуга, мотор тагын кабынды. Урман юлыннан джинсы чалбар кигән егет белән кыз утырган мотоцикл килеп чыкты. Мин хыялда тудырган табигать баласы Мөнирә түгел, бөтенләй башка, ят кыз иде ул. Күрәсең, мин һаман да әле Сәет агай хисләреннән аерылмаганмын... Мөнирә хәзер алтмыш яшьләр тирәсендәге, Сәет ага күрсә, үзе дә танымаслык ханымдыр...

Егет мотоциклын бик оста гына борды, кыз нидер әйтте дә, егетне кочаклап, артка утырды, һәм шул ук мизгелдә алардан җилләр исте. Димәк, аларның да тоткан юлы — Таллыкүл. Димәк, бу көйне яшьләр дә онытмаган. Сәет аганың сөйләп, көйләп бирүеннән мин Мөнирәнең җырында — оялчанлык та, тирәнгә яшеренгән мөлдерәмә зәңгәр сагыш та сизгән идем. Ул кыз да, егет тә сагыш-моңны күтәренке рух һәм шаянлык белән алыштырганнар... Шул ук көй, бөтенләй башка яңгыраш... Охшашлык тик яшьлектә... кайнарлыкта.

Әкрен генә атлап, мотоциклга кунаклаган яшьлек артыннан иярдем.

## 3

Яшьлек! Әллә син хыялый бер әкият кенәме? Яшь Сәет Зилаеровның күзләрендә мәңгегә шәүләсе калган зәңгәр урманнар кайда? Ыгы-зыгылы бертөрле көндәлек тормышка ямь биреп йөзүче, дулкыннар таратып уйнаучы кыр үрдәкләре кайда? Нигә сез туган күлегезгә кайтмадыгыз, юлларыгызны өермәләр бүлдеме әллә? Менә минем очар канатларым да юк, мин кайттым, Сәет Зилаеровның хыялы булып кайттым. Сәлам сиңа, киек кошларсыз боегып калган Таллыкүл! Сәлам сиңа, яшьлек

төсмерен җуйган, тешләре коелган карт сыман, серлелеген югалткан гап-гади урман! Әллә минем күзләремә генә шулай күренәсезме? Сәлам сиңа, Мөнирә ханым, янар яшьлегеңнән! Мин сине үзем эзлим, күрәсем дә килә, олыгайган, урман-күл шикелле, күркәмлеген югалткан хәлдә күрсәм, күңелдә авыр хис калудан куркам да... Исәнме, Гашыйклар тавы! Сәет аганың сөйләвенә караганда, син бик мәһабәт, биек булып ерактан ук балкырга тиеш идең... Барлык гашыйкларны әсир иткән, үзенә тарткан-чакырган зәңгәр ераклыгың, якын яшеллегең кайда?

Бөтенләй диярлек Сәет Зилаеровка әверелеп, мин Таллыкүл авылына керәм. Әмма алдымда хәрабәләргә әйләнгән нигезләр, тәмам картаеп, янтайган-егылган өянкеләр, тупыллар күрәм. Йөри-йөри аңладым: кешеләр, яшәгән нигезләрен калдырып, каядыр киткәннәр, күченгәннәр. Адәмнәрнең шат авазлары урынына — каргаларның хәсрәтле, ялыктыргыч, карлыккан бертөрле тавышы... Яшьлегеңнән бер аваз бирсәнә, Таллыкүл! Әллә мин эзләгән Мөнирәне дә узган яшьлегендә калдырдыңмы?

Ташландык нигезләр яныннан уза торгач, алдымда заманча салынган таш йорт күренде. Өр-яңа рәшәткәләр белән уратылган өйнең тимер капкасын ачып, ишегалдына кердем, йортта беркем дә юк. Шул вакыт якында гына, бакча ягыннан ягымлы бер көй ишетеп, сискәнеп киттем.

Тавышы — нәкъ Сәет Зилаеровныкы! Җыр иясен бакчада эзләп таптым. Ул, әкрен генә көйләп-көйләп, алмагач төбе йомшарта. Мәһабәт гәүдәле, кара чәчле, кара мыеклы ир-егет төсе-кыяфәте белән дә Сәет агага тарткан иде. Мин, мөгаен, дөрес килгәнмендер. Җыр изге юлга озатты, җыр каршы ала...

— Исәнмесез?

— Исәнмесез! Сезгә кем кирәк?

— Мин Мөнирә Идрисованы эзлим.

— Сез кем буласыз соң?

— Язучы.

— Сезгә нигә кирәк ул?

— Мине аның язмышы кызыксындыра. Аның өе шушымы?

— Әйе.
— Сез аның улымы әллә?
— Әйе. Өмет Зилаеров.
— Әниегез өйдәме?
— Юк.
— Ул тиз кайтырмы?
— Кайтмас.
— Өмет, Сез мине аның янына алып бара алмассызмы? Миңа аны ничек тә күрергә иде.
— Әйдәгез. Алып барам.

Сабыр табигатьле, аз сүзле Өмет артыннан киттем. Икебез дә дәшмибез. Мин сабырсызланам, тынычсызланам, үзем генә сизәм: йөрәгем еш-еш тибәргә тотынды. Аның белән ничегрәк сөйләшергә, ниләр әйтергә, ниндирәк сүзләр табарга? Сәет аганың исәнлеген белгәч, йөрәгенә авыр алмасмы? Өмет алдында әйтергәме, әллә... үзенә генәме? Бәлки, ул башка берәүгә кияүгә чыккандыр, Сәет аганы бөтенләй онытткандыр?..

Тукта, син мине кая алып барасың, Өмет? Зиратка кербез түгелме соң? Өмет белән бергә мин ал гөлләр уратып алган (Сәет аганың өендә дә нәкъ шундый гөлләр иде) кабер алдында басып торам һәм ташка уеп язылган үзәк өзгеч сүзләрне укыйм:

***Идрисова Мөнирә Сафа кызы***

***1923—1986***

*Сәет!*
*Кайтырсың, шушында табарсың,*
*Өзмимен өметне... мин көтәм.*

Мәрмәр ташның икенче ягында рәсем: якты дөньяга елмаеп караучы Мөнирә...

Авыр хәсрәт тынлыгыннан аерып, Өмет иплəп кенә иңнәремә кагыла:
— Киттек...

Өмет артыннан күпме барганымны да, кая кергәнемне дә белмим... Кулларымда ниндидер бер дәфтәр күргәч кенә башымны күтәрдем.
— Әнкәйнең көндәлек... Шигырь белән язган, мәрхүмә...

## Мөнирә Идрисованың күңел дәфтәреннән өзекләр

### 1942 ел

Йөзләрдә хәсрәте күренер,
Күзләрдә тамчылар күренмәс;
Кошларның юллары бүленер,
Ярымның юллары бүленмәс.
Толымым билемә уралыр,
Өметем кайгыга уралмас;
Киек кош юлларда югалыр,
Сөйгәнем яуларда югалмас!

### 1943 ел

Көйләмә син миңа, авылым,
Яуларда үлгәннәр бәетен,—
Туктатып сугышлар давылын,
Барыбер кайтыр ул — Сәетем!

### 1945 ел

Баламны күкрәккә кысам мин:
Ул сиңа охшаган шулкадәр!
Әйтмәгез! Тыңламыйм, ышанмыйм:
«Үлде!» дип килсә дә йөз хәбәр.

### 1950 ел

Сөюем хакына түзәм мин:
Йөрәк бит нечкәрәк кылдан да...
Буранда маяклар тезәм мин:
Күз алмыйм син кайтыр юллардан.

### 1952 ел

Очалмый төшкәндер — яралы...
Таллыкүл суында киек кош.
Хәбәр бу — юллары ураулы,—
Көтәрмен унар җәй, унар кыш...

### 1960 ел

Нинди уй бу газиз башымда:
Берсе дә аңламый иделәр.

«Өметең унсигез яшендә,
Әллә син хыялый»,— диделәр.

## 1970 ел

Кыен ул йокысыз төннәрдә
Җилләр дә тәрәзә чиртмәсә...
Хәсрәтем сөйләргә кемнәргә?
Өметем — балам да читләшә.

## 1980 ел

Авылдан шәһәргә күчәләр.
Өмет тә күченә. Мин калам.
Берсе дә аңламый ич алар:
Юлларга чыгам да тукталам.
Язмышым нигезен калдырып,
Юк, китә алмыйм мин авылдан;
Сәетем, югалтып, каңгырып,
Эзләсә Гашыйклар тавыннан?..
Өнемдә, эшемдә, төшемдә,
Аңымда, җанымда, хисемдә...
Яуларга озаткан кичемдә
Бирелгән вәгъдәләр исемдә.

## 1982 ел

Үрдәкләр төшмичә китәләр.
Таллыкүл чалт аяз... юк томан.
Минутлар, сәгатьләр үтәләр
Кавышалмый Сак белән Сок сыман.
Күзәтәм киек кош эзләрен...
Китәрдәй булам ла кушылып.
Уянып язларын, көзләрен
Күңелем җилпенә кош булып...

## 1986 ел

Гашыйклар тавына карарсың...
Иң соңгы җырым бу... мин китәм.
Кайтырсың... шушында табарсың...
Өзмимен өметне. Мин көтәм.

### Күңел дәфтәренең дәвамы

Мин — баласы, Өмет Зилаеров...
Моңнан ерак адәм... нишләдем:
Әнкәемнең күңел дәфтәренә
Шигырь булып тама хисләрем.
Таллыкүлдә керләр чайкаганда,
Әнкәемнең гомере өзелгән.
Һәрбер хәрәкәте, һәр сүзеннән
Мәгънә табып йөрим эзеннән.
Без, балалар, нинди өметсезләр,
Без, балалар, нинди гамьсезләр...
Әнкәй җир йөзеннән киткәч кенә,
Үкенечтән әрнеп җан сызлар.
И хәзерге акылларым булса,
Табар идем чара-дәваны...
Инде беләм: әнкәй үзе бит ул —
Риваятьнең җанлы дәвамы.
Без, малайлар, Гашыйклар тавыннан
Бер үрдәккә аттык ук белән.
Мин әнкәйгә моны сиздермәдем
Борчылмасын диеп юк белән.
Кем белсен соң: изге имәннәрне
Турый-турый учак якканбыз;
Без ул чакта әнкәй йөрәгенә,
Әнкәй өметенә атканбыз.
«Үрдәк» диеп атадылар безне,
Әллә күлдә оста чумганга...
Бик үртәлә идем: әнкәем дә,
Мин үзем дә «үрдәк» булганга...
Таллыкүлгә берәр үрдәк кайтса,
Өметләнеп көтәм... ни көтәм?
Гел Гашыйклар тавы ягыннан мин
Сагынылган тавыш ишетәм.

Мөнирә. Өмет, балам, ни эшләдең, сугыштыңмы әллә?

Өмет. Сугыштым ла...

Мөнирә. Нигә?

Өмет. Үрдәк дип мыскылламасыннар...

Мөнирә. Шуңа ачуландыңмы?

Өмет. Тагын бер генә әйтеп карасыннар...

Мөнирә. «Үрдәк» дигәнгә бер дә үпкәләмә, балам. Безнең нәселнең мәңгегә чәпәлгән кушаматы ул. Шәҗәрәбездә җиденче бабабыз да, аннан элгәреләре дә — үрдәкләр... Иң әүвәлге әнкәбез — Гашыйклар тавындагы Серле үрдәк. Явыз бәндәләр Серле үрдәкне атканнар да җиргә төшергәннәр. Яраланган, канатлары сынган кош җирдә тормыш итә башлаган. Барыбер мәңге-мәңге сагышланып зәңгәр һавага караган... үрдәкләр без...

Өмет. Минем үрдәк буласым килми!

Мөнирә. Буласың киләме, юкмы, син дә үрдәк, балам.

Өмет. Безне мәктәптә кешене маймылдан килеп чыккан дип өйрәтәләр.

Мөнирә. Каршы килмим. Кайбер адәмнәр, бәлкем, чыннан да маймылдан яралгандыр. Без — Таллыкүлleләр, кошлар нәселеннән...

Өмет. Каян алып әйтәсең моны, әнкәй?

Мөнирә. Төшемдә гел канатланып кош булып очам. Әби-бабаларымның дәрте уянадыр, мөгаен, маймылдан яралган булсам, мин төштә агач башына үрмәләүдән узмас идем... Нигә соң мин биеккә, кошлар югарылыгына күтәреләм дә, уяна-уяна гына җиргә килеп төшәм?..

Үзем саклыйм хәзер Таллыкүлнең
Изге тавын, кошын, урманын;
Әнкәй генә белми Өметенең
«Сәет кебек лесник» булганын.
Ә ул чакта, әти юклыктандыр,
Балалыкны иртә югалттым.
Ни аяныч... Дәү-дәү ир булгач та,
Йөрәгенә күпме ук аттым.
Әйе, кара алтын — ил байлыгы,
Таллыкүлдә белеп тапканбыз;
Туган җир йөзенә, кабаланып,
Кайчак бетмәс кара якканбыз,
Тиңсез матурлыкны югалтканбыз...

Күлләр кипкәч, карурманнар сулгач,
Айныганбыз, әмма... соң булган.
Туган җиргә — Ана йөрәгенә
Ук атканбыз икән,
шул булган.

...Начальнигым дәшеп алды мине.
Башлык сүзеннән соң кем узган?
«Изге тауның маен суырабыз,—
Иртәгә үк шунда! Җиң сызган!»
Аны-моны һич тә уйламыйча,
Киттем тауга таңда туп-туры.
Бульдозерга каршы кемнәр килә:
— Тукта! Тукта! Каһәр суккыры!

Мөнирә. «Тукта!» диләр сиңа! Сүндер моторыңны!

Өмет. Ни кирәк сезгә?

Мөнирә. Гашыйклар тавын мәсхәрәләргә без рөхсәт итмибез!

Өмет. Рөхсәт итмисез?! Сез? Безгә? Монда бораулау эшләре башлана! Приказ!

Мөнирә. Ә без ул приказны дөрес түгел дип табабыз!

Өмет. Китегез юлдан!

Мөнирә. Тапта! Үткәрмибез!

Өмет. Дәүләт планын өзгән өчен җавап бирерсез! (*Бульдозердан төшә.*) Ән-кәй?! Син?

Мөнирә. Өмет?.. Өздең өметләремне... Җир ярылса, кереп китәр идем... Ник шуңа ризалаштың?..

Өмет. Мин кушканны үтим... Туктале, ник юктан тавыш куптарасың? Котыртып, нефтьчеләрне дә ияртткәнсең...

Тавышлар. Дөрес әйтә әниең, хак әйтә!

Мөнирә. Беләсең ич Гашыйклар тавының изге җир икәнен. Анда борынгы бабаларыбыз-әбиләребез, этиләре-без-әниләребез бер-берсен ташламаска, яратырга ант биргәннәр, вәгъдәләшкәннәр. Ул тау — Таллыкүлнең иманы.

Өмет. Изге... иман... Үзең дәүләт кешесе, авыл советында секретарь... Син нәрсә, әнкәй, муллалар сүзен сөйлисең?

Мөнирә. Мәңге искерми торган йолалар бар. Гашыйклар тавы...

Өмет. Җитте! Монда дини картлар бүгенге көндә дә корбан чалалар. Димәк, бу урын, начальнигым әйткәнчә, искелек калдыгы... Без аны тар-мар итеп, хәрабәләрендә яңа тормыш корабыз.

М ө н и р ә. Өмет, балам, аңла: Гашыйклар тавында — нефть юк!

Ө м е т. Син беләсеңме, безме?

М ө н и р ә. Тау астында су агып ята...

Ө м е т. Нәрсәгә таянып, шулкадәр ышанып раслыйсың?

М ө н и р ә. Риваятькә ышанып. Үрдәк киткәннән соң, аның күле тау астына качкан.

Ө м е т. Дин әкиятләре!

М ө н и р ә. Борынгылар хак әйткәндер: Гашыйклар тавын ташлап киткән үрдәк менә шуңа күрә кайтмый бит инде...

Ө м е т. Хыял!.. Гомереңбуе кайтмаган иреңне көтеп картайдың. Җүләр син, әнкәй! Без — эш кешеләре! Эш! Эш! Эш! Йолаларга килгәндә, аңла, әнкәй: чор башка, җыр — башка, машина булмаса, яшьләр тауга күтәрелергә иренәләр... Кайда туры килә... шунда...

М ө н и р ә. Оятсыз! Менә сиңа! (*Өметнең яңагына суга.*)

Т а в ы ш л а р.

— Менә монысы — артык!

— Өметтә дә хаклык бар!

— Кул селтик тә үткәрик!

— Өмет, син әнкәңне рәнҗеттең, гафу үтен!

— Кире борыл! Барыбер үткәрмибез!

Изге тауга менми чигендек без:
Бораулауның башка юлы бар:
«Дин яклаучы!» диеп, әнкәемне
Авыл советыннан кудылар.
Озак кына баш ваттылар әле:
«Моңа нинди җәза табарга?»
«Әһ» тә итми, сөенә-сөенә китте
Көне-төне сыер саварга.
Тыныч калдырмыйча, изге тауның
Тикшерделәр катлам-ташларын,
Нәтиҗә шул:
аста — бары тик су!
Әнкәй «күрәзә»се расланды!..
«Килер язмышымны юра» диеп,
Яше-карты аңа бәйләнде.
Юрамады... Әмма... ояты ни:
Әнкәй «абыстай»га әйләнде.

Күз яшьләрен яшереп кешеләрдән,
Үксегәндер ул чак... Кем дәшкән...
Төшен юрый иде... Димәк, һәр төн
Әткәй рухы белән сөйләшкән.
Төннәр буе йокламаган, димәк,
Каян көч тапкандыр чыдарлык.
Күргән төшләре дә изге иде:
Әллә хыял, әллә чынбарлык...

## Мөнирәнең төше

Мөнирә. Сә-е-ет!

Сәет. Әү-ү!

Мөнирә. Син кайда?

Сәет. Әллә кайларда!

Мөнирә. Тавышың кайтты, үзең — юк!

Сәет. Кичер, Мөнирә, мин әлегә кайталмыйм!

Мөнирә. Сине шундый күрәсем килә, Сәет...

Сәет. Мөнирәм, көт!

Мөнирә. Исән генә бул, Сәетем, сабыр канатларым сынганчы көтәрмен. Шуны гына әйт, яз кайтырсыңмы, көзме?

Сәет. Мин Серле үрдәк белән бергә кайтырмын!

Мөнирә. Син әле үзең киткәч, туган улың Өметне дә күрмәдең. Ул инде ир-егет, шулкадәр үзеңә охшаган...

Сәет. Өмет?.. Балам?.. Күзләре нинди? Чәче?

Мөнирә. Тач үзең инде...

Сәет. Өмет... Өмет... Каян алдың шулкадәр ягымлы исемне?

Мөнирә. Әллә... үзеннән-үзе... ихластан.

Сәет. Белсәң иде, Мөнирә, шулкадәр гармунымны сагындым. Аңа тузан кунып, телләре күгәреп беткәндер инде.

Мөнирә. Сайраплар тора. Оныгың уйный.

Сәет. Кит аннан!.. Оныгым да бармыни? Исеме ничек?

Мөнирә. Сәет.

Сәет. Ничек Сәет?

Мөнирә. Мин аңа тугач ук, Сәет дип дәштем. Башка исем юк.

Сәет. Их, Мөнирәм, гармунда уйнап, сине җырлатып, Таллыкүл урманнарында адашырга!..

Мөнирә. Әйдә, адашыйк соң... (*Җырлыйлар.*)
Карурманга барган идем,
Юри генә адаштым.
Сәет. Мине күргәч, телсез калдың,
Адаштым дип, алдаштың.
Мөнирә. Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде...

Сәет, элекке кебек җырла...

Сәет. Тырышам бит...

Мөнирә. Без элек тырышып җырламадык, үзеннән-үзе...

Сәет. Ничек җырлый идек соң, онытылган?..

Мөнирә. Дәртле, сөенечле, өметле иде җырыбыз. Хәзер — авыр хәсрәт тавышында. Әйдә, элеккечә җырлыйк!

Сәет (*сүз белән*). Җиләкләргә барма инде,
Барма инде, адашма...

(*Тавышы еракта.*)

Мөнирә. Сә-ет! Ау-у-у! Кайда син?

## Күңел дәфтәреннән

Шул чагында, башкаларга кушылып,
Җанын аңламыйча, нигә мин:
«Онытырга вакыт, күпме генә
Көтсәң дә ул кайтмас»,— дигәнмен.
Үзен югалткач тик аңладым мин,
Бары берәүдән ул наз көткән,
Гомере буе көткән...
Шул ихлас хис
Сүнгән рухын аның балкыткан.

Мөнирә. Ничек килдең, балам, күз ачкысыз буранда?

Өмет. Сине кар күмеп китмәдеме икән дип... Әйдә киттек! Машинамны Зирекледә калдырдым.

Мөнирә. Зирекләгә кадәр юл йөрерлекме?

Өмет. Йөрерлек. Киттек, әнкәй!

Мөнирә. Рәхмәт төшкерләре, юлны ачканнар икән!

Өмет. Бикләә ишегеңне!

Мөнирә. Юк инде, балам, китмим. Көчләмә! Бер йомышым гына бар барын...

Өмет. Әйт!

Мөнирә. Зирекледән Таллыкүлгә юлны чистартсыннар, әйт әле нефтьче дусларыңа...

Өмет. Монысы нигә тагын?

Мөнирә. Әткәң кайтканда юлда адашыр...

Өмет. Их, әнкәй, саташасың түгелме?

Мөнирә. Бер дә саташмыйм, балам, әткәң юлга чыгарга җыена...

Өмет. Каян синдә шундый уй?

Мөнирә. Бүген төшемдә Гашыйклар тавындагы күлне күрдем. Теге үрдәк, төшәргә ниятләп, күл өстендә әйләнә, имеш... Бер канаты каерылса да, кайткан, җанаш... Кайта болай булгач әткәң, әзерлән!

Өмет. Бичара... Төшкә ышанасың...

Мөнирә. Төш ул — өннең дәвамы, балам. Ул исән! Күңелем тоя: кайтырга әзерләнә...

Өмет. Әнкәй, уян!

### Күңел дәфтәреннән

Туфрагыңа хәзер таш куйсам да,
Баш куйсам да, күңел сызлана.
Юк, сиздермим аңа,
Җир астыннан
Әйткән кебек була: «Түз, бала»...
Кырык биш ел тоташ көткән әнкәм,
Бер хәбәр юк өмет итәрлек,
Каян килгән аңа бу ышаныч?
Әткәм булган, димәк, көтәрлек!

### Мөнирәнең төше

Мөнирә. Сәет, зинһар, төшемдә булса да, биш минутка гына кайт. Соңгы тапкыр сорыйм!

Сәет. Исәнме, матурым!

Мөнирә. Әлегә исән... «Матурым» дидең. Сине көтә-көтә картайдым, ямьсезләндем, Сәет. Матурлыгым, исәнлегем улыма, онытыма көчте, ахры. Әйдә, аларда калсын...

Сәет. Карт көнеңдә нигезеңдә ялгызың калгансың түгелме соң? Балаларыбыз — Өмет, Сәет кайдалар?

М ө н и р ә. Киттеләр. Барысы да киттеләр... Таллыкүлдә — бер үзем.

С ә е т. Әллә бөтенләй ташладылармы үзеңне?

М ө н и р ә. Яңа калага күчтеләр. Өмет күпме ялынды, ялварды, ачуланды — күчмәдем. Рәнҗемим. Атна саен кайтып, хәлемне белеп, ярдәм итеп китә.

С ә е т. Хәлең ничек, Мөнирә?

М ө н и р ә. Минем хәлем ярыйсы ла ул... Таллыкүл өчен җаным әрни. Яшьләр Таллыкүлне ташладылар, бабаларыбыз калдырган юлдан каерылдылар, риваятькә, изге җиргә хыянәт иттеләр, матурлыгын файдаландылар да, картайтып, ямьсезләтеп, алыр нәрсәсе калмагач, ташлап киттеләр. Ничек сызланмыйсың: борын-борыннан сыналган иң асыл гадәтләрне, мең еллап сабыйлар бишеген тирбәткән моңны-телне ташларга ниятлиләр...

С ә е т. Чыннан да, Таллыкүлгә ни булган? Танырлык та түгел. Кыр үрдәкләре кайткан вакыт. Берәү дә күренми... Әллә мин гаеплеме соң? Теге вакытта әнкә үрдәккә аттым бит...

М ө н и р ә. Без барыбыз да гаепле Әнкәбез — Табигать алдында!

С ә е т. Нигәләр генә аттым?! Ник аттым?!

М ө н и р ә. Синең вөҗданың сау, димәк... газапланасың... Кайтып керсәң, җаннарың тетрәр... Явыз адәмнәр киек кош, җәнлекләрне вертолеттан атып, кырып бетерделәр, күлдәге балыкларны динамитлар белән шартлатып, үзен сазга әйләндерделәр, керсәң адашырлык карурман җырда гына калды. Табигатьнең кадерен белә торган шәфкатьле җаннар яудан кайтмадылар шул...

С ә е т. Нинди хозур иде Таллыкүл буйлары!..

М ө н и р ә. Байлыкны арттырдык, матурлыкны кимettек... Шулай да мин өметне өзмим. Өметем кала, Сәетем кала, тагын бер Сәетем кала... Сау бул, Сәет, мин китәм...

С ә е т. Тукта! Китмә! (*Мылтык шартлаган тавыш.*)

М ө н и р ә. Их, харап иттең!.. Нигә аттың?

С ә е т. Мин үрдәккә аттым...

М ө н и р ә. Үрдәк мин бит инде, Сәет!

С ә е т. Янымда гына җан бирергә яткан яралы үрдәк... Синме, Мөнирә?

М ө н и р ә. Мин, Сәет... Барыбер мин бәхетле, сине күреп, кайнар кулларыңда, туган җиремдә җан бирәм...

Сәет. Мөнирә, кичермә мине, бәхилләмә, каргап кит!.. Юк, ташлама мине, мәңге көтәргә дип, Гашыйклар тавында вәгъдә бирдең...

Мөнирә. Ә син елама... Вәгъдәгә тугры калам, Сәет, көттем, көтәрмен анда да! Сау булыгыз, исән булыгыз, ике Сәетем, исән бул, Өмет!

Сау булыгыз, туган-үскән җирләр,
Матур тормыш сезгә миннән соң!

**Күңел дәфтәреннән**

Заман үзгәрүне таләп итә:
Нәкъ әнкәйчә яшәү — шарт түгел...
Әмма тарта мине — югарыда,
Кош юлында калган саф күңел!

## 6

Без, Өмет белән икебез, иске өйнең баскычында утырабыз.

— Әнкәй бу баскычта, уң кулын каш өстенә куеп, күзләрен юлларга текәп утырырга ярата иде. Менә әле дә аның тавышын ишетәм сыман:

«Таллыкүлнең гүзәллеген күрергә теләп, әллә кайлардан, Казан, Уфалардан, ерак Себер якларыннан килгәннәр, туганнар сабан туйларында җыелганнар. Беренче тапкыр аяк баскан һәрбер кеше, әкиятләрдә күрелмәгән манзарага таң калып, «аһ» иткән, тәүге күрүдә үк гашыйк булган. Сылу табигать кешеләр җанына да мәрхәмәт, шәфкать, нәфислек иңдергән. Шунлыктандыр инде, кызлары да бер күрүдә һуштан язарлык чибәр, егетләре Таллыкүлдәге имән кебек күркәм, ыспай, чыдамлы; балалары — өлгергән алма кебек түгәрәк, таза булганнар»... Әнкәй нәкъ менә шулай сөйли иде.

Таллыкүлне саклау урманына әйләндерү турында сүз йөргән. Сугыш башлангач аның кайгысымы? Аннан соңгы тарихын сөйлисе килми.

Минем өчен иң авыры шул — Таллыкүлне мәсхәрәләүдә катнашкан адәмнәрнең берсе — мин үзем! Янәсе, табигатьне яулап алу көрәшендә без җиңгәнбез! Янәсе,

мин — новатор, заман кешесе, ул — борынгылыкка, артка тарта. Юк, кемнәрдер әйткәнчә, әнкәй кара алтынга дошманлык белән карамады, туган якларда нефть табылуга куанды гына. Ә без, рекорд артыннан рекорд куеп, табигатьнең иң нечкә, иң нәфис, иң илаһи җиренә бәреп кергәнбез. Нәтиҗәсе — күз алдында... Табигать шәрәләнеп калганнан соң, кешеләрнең җаны ярлыланган, тупасланган, үзара мәхәббәтләре сүрәнләнгән, туган җиреннән суынган. Авылдашларымның күбесе, тапкан байлыкларын нишләтергә белмичә, хәмер колына әйләнделәр. Гашыйклар тавын оныттык: кая анда менеп вәгъдәләр биреп тору,— без инде аның серлелеген бетергән идек. Нигә сөйләп торырга, шул хәмер аркасында, яраткан хатыным китте. Элек-электән нәселе белән игенчеләр, кырларын ташлап, шәһәрдә күңелләре тартмаган теләсә нинди эшкә тотындылар. Борынгыдан мирас булып күчкән табигатьне, риваятьне, гасырлар буена сыналган гадәтләрне, ырымнарны, китапларны, мәчетләрне, дин белән бәйләп, барысын да: яманын да, асылын да — машина астына салып таптаганбыз ласа! Кыр үрдәге турындагы риваятьне чыгаручылар үзләре калдырган гүзәллекне рәнҗетсәң, нинди фаҗига киләсен алдан искәрткәннәр!

Әнә шулай Таллыкүлне таркаттык... Нигезендә бер әнкәй торып калды. Вәгъдәсенә тугры булып, көтеп... Хәзер ул — юк. Әткәйне мин көтәм. Кайтмасын да беләм, барыбер көтәм... Уң кулымны каш өстенә куеп... баскычка утырып...

Әнкәйне соңгы юлга озаткач кына аңга килдем, айныдым: нишләдек без, нишләттек үзебезнең туган җиребезне?

Басмага карасам: әнкәем һаман керләр чайкый кебек. Шул кыяфәттә төшләремә килеп керә... Авыр чакта ярдәм итә, күз яшьләремне сөртә. «Әнкәй, син исән чакта бер тапкыр да күзеңнән яшь чыгармадың?» «Мин еламыйм бит, балам, каты күңеллелектән дә түгел, безнең нәселнең гадәте: елаудан тыелабыз. Шуңадыр инде, елый башласак, туктый алмыйбыз»... Төшемдә әнкәй яраткан шушы басмага керләр чайкарга төшкәнмен, имеш...

### Өметнең төше

Т а в ы ш. Өмет, балам, бир, керләреңне үзем чайкап бирим...

Ө м е т. Әнкәй, кайттыңмыни?

Т а в ы ш. Мин әле кайтмадым, керләреңне чайкашырга бик азга гына килдем.

Ө м е т. Кайда соң син? Тавышың бар — үзең юк!

Т а в ы ш. Бәй, улым, танымыйсыңмыни, алдыңда торам ласа...

Ө м е т. Алдымда — үрдәк... син — юк...

Т а в ы ш. Шул үрдәк мин булам инде, балам.

Ө м е т. Серле үрдәк... син?

Т а в ы ш. Нигә гаҗәпләндең? Керләреңне бир әле, балам, анда юма, пычратасың ич. Менә монда су чистарак...

Ө м е т. Рәхмәт, әнкәй... Якынрак кил, башыңнан бер сыйпап кына алыйм инде. Исән чакта бер генә дә иркәли алмадым.

Т а в ы ш. Юк, килмим. Мин адәмнәрдән куркам, балам...

Ө м е т. Нигә куркасың, әнкәй?

Т а в ы ш. Адәм балаларының борынгы риваятьтәге явыз аучыдан аермалары юк.

Ө м е т. Без сиңа тимәбез. Серле үрдәк — әнкәм... Кайчан кайтырсың соң?

Т а в ы ш. Гашыйклар тавындагы күлне үз урынында күрмичә, Таллыкүл урманнары шауламыйча, кешеләрнең җанына шәфкать иңмичә, кайта алмыйбыз!

К а й т а в а з. Кайта алмыйбыз! Кайта алмыйбыз!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ө м е т. Яңа калада төшләр күрә-күрә, әнкәм белән сөйләшә-сөйләшә, яттым-яттым да, Таллыкүлгә кире кайтып, әнкәй нигезендә йорт кордым. Таллыкүл әле үлмәгән, исән, хәлсезләнгән, авырган, картайган, сулыш өрергә, терелтергә генә кирәк. Әнкәй өен сүтәргә дә кул бармый, торсын, әйдә, рухын саклап...

Гашыйклар тавында җыр ишетәсезме? Бүген анда яшьләр җыела. Әкренләп кайталар... Шунда таңны каршылаячаклар. Барабызмы без дә? Киттек!

## 7

Мин Өмет артыннан кайчандыр Мөнирә белән Сәет вәгъдәләр алышкан Гашыйклар тавына күтәреләм. Кояш,

сүрән нурларын Таллыкүлдә саран гына җемелдәтеп, баерга җыена.

— Күрәсезме? Риваятьтә сөйләнгән элекке күл урыны.— Өмет тау башындагы зур түгәрәк чокырны күрсәтте.— Әллә инде үзем дә әнкәйгә әйләнеп барам: башымда тәвәккәл уй йөри: нигә күл төбен бораулап карамаска, бәлки, чынлап та, тау астына качкан күл ургылып кире чыгар... Әнкәй әйтмешли, үзләренең туган күлен танып, киек кошлар да кайтыр, кайлардадыр тилмереп йөрмәсләр...

«Киек кошлар» сүзен ишетү белән, йөрәгемдә бер җыр тибә башлый. Ул җыр, яралы җыр, дөньялар әйләнеп, чиксез күп бәлаләр кичереп, авыр юлларда адашып, магнитофон тасмасына уралып кайтты. Ул җыр, тынгылык бирмичә, кабаланып, әйтеп бетергесез бер ярсыну белән күкрәк читлегеннән чыгуны, Таллыкүл табигатенә кушылуны таләп итә. Янәшәмдә генә Сәет аганың карлыккан тавышын ишетәм сыман: «Бөтен өмет сездә, якташ, зинһар, җырымны Мөнирәгә җиткерегез. Шуннан ул барысын да аңлар: минем исәнлекне, газапларымны, мәхәббәтемне...

Хәзер үзем яралы кош сыман,
Кайтыр юлларымны югалттым...»

Яшеренгән ул җырны чыгармыйча, бөтен көчем белән тыеп торам. Мин аны, әманәт итеп, Мөнирәгә, бары Мөнирәгә генә тапшырырга алындым. Ул үзе озак еллар буе көткән әрнүле, серле бу җырны ишетүдән мәхрүм.

Артыбызда ишетелгән мотор гөрелтесе уйларымны бүлде. Шул арада тау битендәге бормалы юлдан мотоцикл килеп чыкты һәм чытырдап-пошкырып, тау өстенә ыргылды. Алдындагы егетне кочаклап, артта утырган кызның кичке җилдә җилфердәп калган чәчләреннән танырга өлгердем: болар бит — Таллыкүлгә килгәндә очраган гашыйклар!

— Их, яшьләр! Күпме тукыдым монда машина белән йөрү тыела дип... Минем улым Сәет үзенең сөйгән кызы Алсу белән. Үзе иртәгә хәрби училищега китә. Һе! Мотоциклда үкереп менәләр! Гашыйклар тавының элекке серлелеген саклыйсы иде...

Тау башына менеп җитүгә, кояш баеп, караңгыланды. Шуңа карамастан, анда күзләрне чагылдырырлык

якты иде. Яшьләрнең ни өчен мотоциклда килүләрен төшенгәч, Өмет тә аларга ачуланып торуны кирәк тапмады,— без, берничә фаралар нурында күңел ачучы кызларны-егетләрне күреп, шулар төркеменә кушылдык. Гитараларга кушылып җырлаучы, биюче яшьләр, Өметне күргәч, күңел ачудан тыелып калдылар.

— Малайлар, туктап торыгыз!

— Өмет абый килде!

— Башларга вакыт!

— Өмет абый, сөйләшкәнчә, кичәне Сез алып барыгыз инде...

Өмет, миннән аерылып, түгәрәк уртасына чыгып басты, Гашыйклар тавы бер мәлгә тынып калды, һәрбер сүзне күңелемә язып барырга тырышам,— түкми-чәчми боларның һәммәсен шушы кадерле җирдән хат-хәбәр көтүче Сәет агага юллармын...

— Кадерле дуслар, якташлар!.. Яшьләрне озату кичәсен бу юлы Гашыйклар тавында үткәрергә ниятләдек. Менә шушы без басып торган җирдә борынгы нәселдәшләребез сөйгән ярларын, дусларын, эти-әниләрен, туган якларын онытмаска вәгъдә биргәннәр. Язмыш юллары катлаулы булып, сөйгәннәре озак вакыт кайталмый торсалар, антларына тугрылык саклап, көткәннәр. Безнең «Таң» колхозыннан биш йөз ир-егетне шушы тауда озатканнар. Шуларның ике йөзе каһарманнарча яу кырында ятып калды. Минем этием Сәетнең исеме дә һәйкәл ташына уеп язылган... Таллыкүл үзенең балаларын гомер бакый озата килгән. Сөенечле каршылауларга караганда, сагышлы озатулар күбрәк... Бүгенге озату киләчәктә шатлыклы очрашулар белән тәмамланыр дип ышанабыз! Чөнки сез игелекле йолаларны терелтеп, таң атканда Гашыйклар тавында вәгъдә бирәсез... Үтәр еллар, без дә бервакыт кемнәрдер өчен борынгыларга әйләнербез. Киләчәктәге яңа дәвер кешеләре безне сагынып яд итәрләрме, әллә үзләре өчен генә яшәгәннәр, хәрабәләр генә калдырганнар дип рәнҗеп, каһәрләп искә төшерерләрме? Бездән ни калыр: яңа Тукай, Сәйдәшләрме, әллә «заман өчен искергән» дип, үз халкының рухыннан ваз кичкән нәсел-нәсәпсезләрме? Бүген сезне Гашыйклар тавында күргәч, өмет уяна.

Хәерле юл сезгә, армия сафларына, хәрби училище-

ларга китүче яшьләребез! Язмышыгыз кайларга гына илтсә дә, әнкәгез кебек мәрхәмәтле Таллыкүлне онытмагыз, аны яшәртергә, элекке хәленә кайтарырга ярдәм итегез!

Концертыбызны Гашыйклар тавына багышланган җыр белән башлыйбыз. Бу җырны минем әнием Мөнирә дә яратып җырлый иде. Сезнең алда — Сәет Зилаеров һәм Алсу Сафина. Минем әтием, ягъни Сәетнең бабасы Сәет Зилаеров шушы гармунда уйнаган.

Фара балкышында икесе дә ап-ак кофта, зәңгәр джинсы чалбар кигән Сәет белән Алсу күренде.

Бәләкәй Сәет, гармунын тотып, уртада калгач, бераз каушап, тамагын кырып алды, аннан, аккорд биреп, таныш көйне сыздырып җибәрде. Алсу гармунчыга өздереп карап алды да дәртле көр тавыш белән аңа иярде. Икенче аккордтан соң, Сәет җырны үзе дәвам итте. Яшьләр дә аларга кушылып, җырны бөтен Таллыкүл буйларына тараттылар:

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында...
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында...

**8**

Без таңны, яшьләргә әллә ни күренмичә генә, Гашыйклар тавында каршыладык. Өмет, озак кына уйланып барабара да, тукталып, көрсенеп куя:

— Сез миңа нидер әйтергә телисез, әмма яшерәсез кебек...

— Нигә?

— Шулай тоела...

— Юк, Өмет, болай гына... Яшь чаклар искә төшә дә, кемнедер юксынып куям...

— Рөхсәт итсәгез, Сезне берничә сәгатькә ялгыз калдырам. Участокны карап килергә кирәк.

— Барыгыз, Өмет, мин йөрим әле...

Димәк, Өмет тә сизенә.

Күкрәгемдә минем бер җыр йөри. Мин аны Мөнирәгә,

бары тик Мөниргә генә тапшырырга тиеш идем. Ул — юк. Әйе, мин Өметне берничә тапкыр туктатып, ул үзе дә эчке тоемлавы белән сизенгән әрнүле серне ачарга омтылып, кабат-кабат уемнан кире кайттым.

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр,
Мин язмыштан инде ычкынмам...

Ерак Себердә коляскада хәбәр көтеп утыручы Сәет ага, нигә әле сиңа Таллыкүлгә, улыңа, оныгыңа кайтмаска? Ачыктан-ачык сөйләп бирсәң, сине барысы да аңларлар, гафу итәрләр. Кайт, Сәет ага, әле соң түгел... Туган җиргә кайтып җан бирү картлыгыңдагы авыр хәсрәтләреңне җиңеләйтер...

Шул вакыт таң җиле ике яшьнең әкрен генә сөйләшүләрен китерде:

Сәет. Алсу, мине көтәрсеңме?

Алсу. Көтәрмен! Ә син кайтырсыңмы?

Сәет. Кайтырмын! Әйдә, сүз бирик!

Алсу. Безне хыялыбызга, мәхәббәт үрләренә үрләткән, яшьлек утларында дөрләткән...

Сәет. ... безне таныштырган, кавыштырган...

Алсу. }
Сәет. } Гашыйклар тавы!..

Сәет. Аерылышу таңында... сиңа

Алсу. Сүз бирәбез!

Сәет. Сүз бирәбез!

Алсу. Мин сине көтәрмен, Сәет!

Сәет. Мин сиңа кайтырмын, Алсу!

Алсу. Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге җир алдында:

Сәет. Аерылган көннәрдә,
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

## 9

Сәет аганы авылына кайтырга чакыру өчен, мин Юрга белән телефоннан сөйләшергә карар кылдым. Мөнирәнең һәм Өметнең шулкадәр көтүләрен белгән адәм, нинди генә хәлләрдә дә, кайтмыйча түзә алмас... Хәнәфи аганың өендә телефон бар. Сәет аганы, бәлки, ул озатып

куяр. Әгәр инде кайталмаса, исәбем — аның белән киңәшергә: улына әтисенең дөньяда яшәвен ачаргамы, юкмы?

Зирекле почта бүлегендәге кыз мине Юрга белән бик тиз тоташтырды:

— Һалло! Юрга! Хәнәфи ага, сезме? Исәнмесез? Мин Таллыкүлдән. Миннән хәбәр көткән иптәшкә тапшырыгыз: Мөнирә Идрисова — вафат. Аларның, ягъни икесенең улы һәм оныгы бар. Аны Таллыкүлдә һаман көтәләр. Ул хәзер үк кайтсын. Берәрегез озата барсагыз... Әле соң түгел...

— Без аны озаттык...

— Кая? Таллыкүлгәме?

— Соңгы юлга... Кичә генә...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Таллыкүл буйларына чыгарга теләп, магнитофон эчендә һәм минем йөрәгемдә яралы кош сыман, бер җыр канат кагына. Соңгы чиккә кадәр тыелып-тыелып килдем дә, канатлары каерылган, туфрагыннан аерылган ул сагышлы җырны туган җиренә очырдым. Сәет аганың җәрәхәтләнгән, үзеннән бәхетлерәк җыры Таллыкүлгә кайтып егылды:

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр,
Мин язмыштан инде ычкынмам...
Танырсыңмы, юкмы: мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Йөрәгемне кысып, басып интектергән авыр йөк ычкынып, әрнү, газаптан бераз гына бушанып киттем. Әмма җыр белән бергә очалмаган сер калды. Нишләргә? Ул серне гомерем буе үземдә саклап йөртергәме? Өметкә барысын да дөресен генә сөйләп бирсәм? Юк, әнкәсеннән күчкән мәңгелек ышанычын, өметен, хыялын сүндерергә, югалтырга ярамый. Ә шулай да... Кайчан булса да аяусыз, кырыс дөреслек калкып чыгарга тиештер бит? Нишләргә? Сөйләргәме, юкмы?

Мин, әманәтен тапшыра алмаган мәхәббәт илчесе, Зирекледән кабат Таллыкүлгә барам. Күлне дулкынландырып, су өстендә кыр үрдәкләре тирбәлә түгелме? Әйе, чыннан да, Мөнирә өзелеп көткән киек кошлар төшкән ич. Менә алар, кинәт миннән курыккан сыман, кычкыра-кычкыра, дәррәү кубып күтәрелделәр, туган төбәкләре белән хушлашкандай, «бак, бак», «кайт, кайт!» диган

ярсулы авазлар чыгарып, күлне бер әйләнделәр дә кояшлы зәңгәр һава диңгезенә кереп югалдылар. Араларыннан берсе, бердәм чылбырдан ычкынып, күлгә кире килде дә, нидер эзли-эзли, тагын бер әйләнде һәм төркем артыннан иярде. Өзгәләнеп кычкыруыннан, канат җилпүләреннән ул миңа киек кошка — чын асылына әверелгән, Серле үрдәкне табып, Гашыйклар тавына кайтару өметен югалтмаган Мөнирә кебек тоелды.

Сөйгән күлләренә яңадан кайта алырлармы, Таллыкүл буйларын кабат күрерләрме алар? Исән-сау йөреп кайтыгыз, үрдәкләр! Очар юлларыгызда Серле үрдәкне эзләп тапсагыз, туган җиренә юл күрсәтегез!

Серле үрдәкнең риваять икәнен дә, аның беркайчан кайтмасын да акылым белән беләм. Әмма Таллыкүлдә Мөнирә кебек затларның рухы яшәсә, Гашыйклар тавындагы күлнең дә, үрдәкнең дә кайчан булса да бер кайтуына өмет бар!

Кызгандыруны ялварган, бераз гына горурлык, бераз гына мескенлек тә чагылган җырдан бушаган йөрәгем үзен юатучы, дәрт-дәрман уятучы, заманында Мөнирәне рухландырган, өметләндергән, Гашыйклар тавына күтәргән Җыр көтә. Һәм җанны сафландыра, илһамландыра, баета торган ул Җыр озак көттерми, Гашыйклар тавыннан туптуры минем күңелемә, Таллыкүл буйларына ага...

Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге җир алдында:
Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

*1985—1986*

# *Ерактагы кәккүк авазы**

*Либретто ике актта, дүрт күренештә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Д а м и р — прологта һәм эпилогта реставратор.
Т а м и р — оста.
Г ө л н а з — прологта һәм эпилогта Дамирның сөйгәне.
А л к и з — Тамирның сөйгәне.
Р и м а н — прологта һәм эпилогта студент.
А л т ы н б ә к — хан баласы.
Т и м е р х а н — хан.
Б а й н а з а р — Алтынбәкнең дусты.
Л ә й с ә н— студентка.
А к ы л и я с е А к с а к а л,
Х а л ы к, х а н х е з м ә т ч е л ә р е, с т у д е н т л а р...

Вакыйга Болгар чорында, безнең көннәрдә һәм фаҗигане күргәннән соң уйланмасаң, киләчәктә дә булуы ихтимал...

## Пролог

Кереш музыка.

Яктылык нуры караңгылык, тынлык хөкем сөргән борынгы ташларны ача.

Реставратор Дамир Болгар хәрабәләрендә, илһамланып, бабаларыннан торып калган ташларны яңарта. Ул җаны-тәне белән изге эшенә бирелгән, тормыш ваклыклары, дөнья ыгы-зыгылары аның өчен юк кебек.

...Идел ага, юлын-агышларын үзгәртә, мәңгелек белән чагыштырганда мизгел генә булган гомерләр уза, еллар, заманалар алышына. Кемнәрдер кайчандыр тормыш корганнар, Җирне, Кешене гүзәл итү нияте белән илһамланып төзегәннәр, иҗат иткәннәр. Кемнәрдер җимергәннәр, Кешенең матур ниятләрен хәрабәләргә әйләндергәннәр...

Гасырлар, чорлар ага, атылган йолдызлар, гомерләр туа да сүнә. Әмма кешелек хәтере мәңгелек. Хәтер-узганнарның ядкәре эзсез калмый...

Ташлар эченнән, ерактан онытыла барган борынгы көй ишетелә.

---

* Либреттога композитор Рәшит Кәлимуллин опера иҗат итте. Спектакль беренче тапкыр 1989 елны Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелды.

Дөньяви уйларга салучы җырчы-Акыл иясе Аксакал үзе дә күренә һәм серле караңгылыкта югала.

Таң нурлары серле караңгылыкны яктырта.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дамир оста — ташлар арасында.

Дамир

Моннан мең ел элек борынгылар
яшәп киткән җир бу,
ата-бабалар җире.

Студентларны ияртеп, Гөлназ керә.

Гөлназ

Туктагыз, без килеп җиттек инде
мин әйткән изге урыннарга.

Ләйсән

Болгар хәрабәләренәме?

Гөлназ

Әйе, әйе, бик дөрес.

Риман

Гел дөрес әйтәсең син, Ләйсән:
Болгар хәрабәләре!
(*Тавышын үзгәртеп.*)
Дөрес әйтәсең син, кызым.

Ләйсән

Ник көләсең син һаман?

Гөлназ

Карагыз Идел буйларына:
берзаманны монда
мәшһүр дәүләт булган...

Ләйсән

Ата-бабалар яшәп киткән җирме бу?

Риман

Ләйсән, Ләйсән, Ләйсән,
җиде бабаңны сызгырып уятыргамы?
Сәлам әбиләреңә!
Ха-ха-ха!

Гөлназ

Моннан мең ел элек борынгылар

Студентлар

Борынгылар, борынгылар

Гөлназ

Яшәп киткән, яшәп киткән,
ата-бабалар яшәп киткән җир бу...

Риман

Ата-бабалар торган җирләр, имеш...
Хи-хи-хи!

Гөлназ

Сез бара торыгыз. Мин куып җитәрмен.

Студентлар ташлар арасында йөриләр. Гөлназ Дамир янына килә.

Мең ел элек борынгылар яккан
учак сүнгән урын
тынгылык бирми сиңа...
Гомереңне шуңа багышлап,
оныттың хәзер мине дә...
Борынгылар сиңа кадерлерәк,
ят итүне сизә йөрәк.

Дамир

Юк, юк, мин суынмадым.
Юк, юк, Гөлназ, ялгышасың син.

Гөлназ

Юк, башка түзәр хәлем юк минем.
Сиңа ташлар гына кирәк.

Дамир
Сине чын күңелдән сөям.
Аңла син мине.

Гөлназ
Бергә булу уеңда юк кебек...

Дамир
Бергә булыйк, бергә булыйк!

Гөлназ
Күпме яшәрбез Сак белән Сок кебек?

Дамир
Бергә булыйк, бергә булыйк!

Гөлназ
Бары сине күрү өчен генә...

Дуэт
Дамир. Бары сине,
Гөлназ. Бары сине,
Дамир. Тели табигатем;
Гөлназ. Сине күрү өчен
монда алып килдем яшьләрне;
Дамир. Бары сине ихлас...
Гөлназ. Ләкин син мине...
Дамир. Яратам!
Гөлназ. Мине аңламыйсың!
Дамир. Төшләремә кереп сагындырасың...

Гөлназны үзенә таба тарта, аны үбәргә омтыла, әмма Гөлназ, үзен җиңеп, Дамирның кочагыннан ычкына.

Гөлназ
Дамир, кайнар сүзләреңне
күп ишеттем инде...
Әйткәннәрең җилгә оча бара.
Без барыбер бергә булмабыз...

Дамир
Гөлназ, Гөлназ,
син хаклы түгел!

Ни булды соң сиңа?
Юкка гына кызасың син...

Гөлназ

Юк, юк, юк,
башка түзәр хәлем юк!
Синең ташларың саташтырып,
кабер булып төшләремә керә.
Юк, юк, юк,
башка түзәр хәлем юк!
Йә мин, яки ташларың...

Студентлар әйләнеп керә.

Беренче студент

Ни булды?

Икенче студент

Нәрсә булды?

Риман

Ник тиясең аңа?

Гөлназ

Әйт син миңа:
бу ташлар кемгә кирәк?
Ни файда бар артка борылуда?
Узганнарны яңартырга, имеш...
Кемдер ваткан,
күпме гасыр яткан...
Менә монысы, бәлки, зиндандыр...

Студентлар

Бәлки, зиндандыр.

Риман

Адәм котын алып торгандыр!

Студентлар

Алып торгандыр!

Риман

Ятсын шунда тузан-таш булып!

Ник казыну тарих чүплегендә?!
Хәрабәләр кемгә кирәк?
Ятсын шунда тузан-таш булып!

Хәрабәләр өстендә гамьсез-мыскыллы бию башлана.

Дамир

Туктагыз!.. Туктагыз!..
(*Тыелгысыз рок музыка аның тавышын күмә.*)
Туктагыз, диләр сезгә!
(*Ишетмәскә тырышып, колакларын томалый.*)
Туктагыз... Туктагыз!.. Туктагыз!..
(*Хәрабәләр астыннан сүзсез хор авазы килә. Кулларын колагыннан алу белән, янә шашкын рок музыка калкып чыга. Яңадан колакларын томалый.*)
Хәрабәләр, ишетәсезме?
Ник дәшмисез?
Күрмисезме ни кыланганнарын?
Нигә тын ятасыз?!
Җавап бирегез!

Ташлар арасында Акыл иясе Аксакал күренә.

Акыл иясе Аксакал

Узганнарны онытсагыз — корырсыз.
Тамырларсыз Җирдә ничек торырсыз?
Үзегез дә онытылырсыз!..

...Хәрабәләр эченнән борынгылар рухын гәүдәләндергән Кыз белән Егет күтәрелә. Алар яшьләрнең, мыскыллы хәрәкәтләреннән сыкрап, рәнҗүләрен белдерәләр. Кыз белән Егет яшьләрне борынгы заманга чакыралар, хәрабәләр астында калган Болгарны җанландыралар...

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Сүзсез хор фонында вакыйга Болгар чорына күчә. Дамир — Тамирга, Гөлназ — Алкизгә әверелә.
Урман иле. Кечкенә таудагы улак аркылы чишмә агып чыга. Чишмә тирәсе таш сыннар, агач фигуралар белән бизәлгән. Бу— Тамир останың иҗаты.
Уң якта изге каберлекнең ташлары.

Алкиз

Җырлый таулар, җырлый чишмәләр,

Җанга рәхәт җилләр исәләр.
Урманның да бардыр язмышы,
Уйга сала кәккүк тавышы.
Кәккүк, әйтче, синең кемең бар?
Үзәк өзгеч нинди серең бар?
Ерактагы изге кошым син,
Йөрәктәге сердәш дусым син.
Кәккүк, кәккүк, тынып калсаң,
Сине мин сагынам,
Табигатькә, сиңа табынам.
Чыгам урман серен тыңларга,
Гашыйк булып карыйм урманга.

Тамир (*Ташлар арасыннан пәйда була.*)

Кәккүк! Кәккүк!
Иртә таңнан сайрап уяттың.
Алкиз, ошыймы сиңа минем ташларым?
Әйтче миңа, Алкиз, әйтче миңа!

Алкиз

Тамир, син аларга гашыйк,
хыялыңда ташлар гына.
Әллә инде суынасың,
шикле уйлар туа күңелемдә...

Дуэт

Тамир. Шикләнмә, Алкиз, борчылма,
Алкиз. Шикләнәм, Тамир, борчылам.
Тамир. Син бит ташка йөрәгемнән күчкән.
Алкиз. Йөрәк җылың ташларыңа күчкән.
Тамир. Син — серле зат, урман кошы кебек,
Алкиз. Мин гади зат — урман кошы кебек,
Тамир. Табигатьнең сабый баласы;
синең белән чишмә сыман челтерәп
Алкиз. Синең белән чишмә сыман челтерәп
Тамир. Мәңгелеккә килә агасы
Алкиз. Мәңгелеккә килә агасы.
Тамир. Без китәрбез, ә табигать калыр,
Җирдә яңа хәят башланыр.
Алкиз. Башланыр...
Тамир. Безнең шулай янып сөюләрне
киләчәккә илтсен ташларым.

Эшкә тотына. Алкиз аның үзенә, ташларына сокланып карап тора да китә. Тамир аны күз карашлары белән озатып кала. Алтынбәк белән Байназар керә. Алар аучылар киемендә.

Алтынбәк

Ни бу? Нәрсә бу? Без кайда?

Байназар

Урман илендә без, углан.
Монда бу чишмәне изге күреп табынганнар.
Бабаларның йолаларын сакламакчы болар...

Алтынбәк (*Адәм сынын күреп.*)

Монысы да изге ташмы? Ни күрәм мин?

Байназар

Ха-ха-ха!
Кем адәмне ташка әйләндергән?
Әнә «гали оста» үзе!

Алтынбәк

Әй, син!

Байназар

Ишетәсеңме, сиңа әйтәләр!

Алтынбәк

Ташларыңны юлдан алып ат!

Байназар (*Ташларга тибеп.*)

Ташларыңны алып ат!

Алтынбәк

Юкса без аларны

Байназар

Туздырырбыз!

Тамир

Сезгә ни кирәк? Юлыгызда булыгыз!

Алтынбәк (*Текәлеп карап тора да, танып.*)
Ташчы... Тамир?!

Тамир

Эзгә төштең, углан?..

Алтынбәк

Качып котылдым, дип уйладыңмы?
Җир астыннан эзләп табам!

Байназар

Табарбыз! Табарбыз!

Алтынбәк

Бөек ханың өчен ташпулатлар
һәм сарайлар салган Тамир оста...
Мескен хәлгә хәзер төштеңме?

Байназар

Хәрабәләрдә көн күрәсең?

Тамир

Явыз узгынчылар
мәсхәрәләп киткән ташларны
яңарту ул — табигатькә хөрмәт, табигатькә!

Алтынбәк

Әйт син миңа:
кемгә кирәк болар?!

Алтынбәк, Байназар

Кемгә кирәк синең ташларың?!

Алтынбәк

Киләчәккә ядкәр имеш...
Ташлар бизи, ташлар кыра...
Мәңгелектә барсы бетә:
ташлар сына, кабер тына,
иелмәгән башлар тына...
Дөньялыкта, Җирдә, Күктә
үзгәрмәслек бер канун сакланган:

кемдә — алтын, кемдә — кылыч, кемдә —
тәхет... —
буыннан буынга кодрәтле дан калган.
Боерам: тотыгыз качкынны!

Хезмәтчеләр Тамирны тотмакчы булалар, ул каршылык күрсәтә һәм, ычкынып, чыгып кача. Аны куып китәләр.

Әмеремне үтәмәсәләр —
рәхим-шәфкать көтмәсеннәр!

Алтынбәкнең юлдашлары Алкизне алып керәләр. Аны ташка утырталар.

Кайда югалдыгыз?

Байназар

Юлларыгыз уңган икән!

Беренче аучы

Асыл кошны эләктердек!

Бергә

Асыл кошны!

Беренче аучы

Олуг ханга бүләк итәрсең!

Алтынбәк

Үземнән артмас — асыл кош булса...
Күрсәтегез!

Байназар

Карап карыйк!

Алтынбәк

Ишетәсезме, аңгыралар? Күрсәтегез!

Алтынбәк, Байназар

Карап карыйк! Ха-ха-ха!

Алкизнең йөзен ачалар. Мондый гүзәллекне күрермен дип уйламаган Алтынбәк, хәйран калып, аңа текәлә.

Алтынбәк

Мондый гүзәл кызны күргәнем юк иде...
Зифа буйларыңны яшермә син миннән,
нурлы йөзләреңне яшермә.
Сылу кыз, үзең — күркәм, йөзең — камил,
сылу кыз, кем баласы, кем буласың?
Сылу кыз, исемеңне әйтче миңа?

Байназар

Бәлки, берәр теләгең бардыр. Әйтеп кал!

Алкиз

Кәккүк белән саубуллашыйм...

Байназар

Ха-ха-ха!
Әгәр теләсәң, урманың белән дә бәхилләш!

Алкиз

Кәккүк! Кәккүк! (*Якында гына кәккүк җавап бирә.*)
Кәккүк безгә кыска гомер юрый...
Язмыштан узмыш юк...

Алтынбәк

Боерам: атып төшерегез,
үтерегез аны!
Мин язган язмыштан узмыш юк!

Алкиз

Туктагыз... туктагыз!..

Алтынбәк, аңа ияреп, башкалар, җәяләрен киереп, ук аталар. Кәккүкнең җансыз гәүдәсен Алтынбәк алдына китереп салалар.

Алтынбәк

Сиңа, сылу, озын гомер бирәм!
Кыз — ирекле!

Алкиз

(*Үтерелгән кошны, күтәреп ала, тыннары белән җылытып, терелтмәкче була.*)

Кәккүк... изге кош...
Кәккүк җаным, зинһар кичер мине...

Сүзсез хор. Аңа Акыл иясе Аксакал кушыла.

Урман илен кара болыт басты,
җансыз калган урман тын калды,
кошлар-киекләре куркып качты,
сулар агышыннан тукталды...

Алтынбәк

Белмәдем...
Яман ниятләрем юк иде...

Акыл иясе Аксакал

Хәерлеге түгел,
табигатьне бәла-шом көтә...

Алтынбәк

Болай буласын һич белмәдем.
Урман кызы, нишләргә соң миңа?

Акыл иясе Аксакал

Килер язмышыбыз куркыта...
Ниләр көтә безне, ни көтә?

## ИКЕНЧЕ АКТ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хан сараенда Алтынбәк бүлмәсе. Ат тояклары тавышы. Әле генә иярдән төшкән Алтынбәк ау киемендә кайтып керә дә, ярсып, бер якка җәясен, икенче якка камчысын атып бәрә.

Алтынбәк

Нишләдем мин, нишләдем мин?
Минем өскә нәләт, нәләт ява...
Гөнаһсыз адәмнәрне рәнҗеттем.

Ария

Күз алдымда — кара урман,
ташлар үкси, таулар ава.
Нишләдем мин, нишләдем мин?

Өскә нәләт, каргыш ява.
Йөрәгемдә, йөрәгемдә
үкенеч яралды,
аткан угым, агу булып,
үземә кадалды.
Нигә мин, Урман иле, сиңа бардым?
Алкиз, сине күргәч, каушап калдым...
Күз алларымнан китми буй-сыннарың,
бер күрүдә мине тылсымладың.
Моңарчы беркемгә дә буйсынмадым.
Күз алларымнан китми буй-сыннарың,
бер күрүдә мине тылсымладың.
Моңарчы мин беркемгә дә баш имәдем,
моңарчы мин беркемгә дә буйсынмадым.
Күз алларымнан китми толымнарың,
нур сибеп йөргән болыннарың.
Моңарчы мин беркемгә дә баш имәдем,
моңарчы беркемне дә шулай сөймәдем.
Алкиз! Алкиз!

Тимерхан (*Керә.*)

Углан, ник кайгылы йөзең?
Ник дәшмисең?
Мин борчылам.
Кайда йөрдең?
Кайтмадың озак...

Алтынбәк

Без адаштык Урман илендә.

Тимерхан

Сизеп торам: нидер яшерәсең.
Әйтче, углым, ач сереңне.
Мин бит атаң, бәлки, ярдәм итәрмен.

Алтынбәк

Атай, анда калды мин үтергән Кәккүк...

Тимерхан

Тыңлыйм сине, ач сереңне, әйтче миңа...
Изге кошы Урман иленең. Афәрин! Хуплыйм!

Алтынбәк

Атай, анда калды үксеп бер чибәр...
Алкиз атлы чибәр газап чигәр...

Тимерхан

Углан, син гашыйкмы әллә?

Алтынбәк

Язмыш серен аңа кем сөйләр?

Тимерхан

Гашыйкмы?

Алтынбәк

Ул илаһи бер зат. Табигатьнең
үзе кебек гади, гүзәл...

Тимерхан

Хан баласы! Син... каралар беләнме?
Оныт! Эзләреңне суыт!

Алтынбәк

Анысын онытыр да идем...
Ул сөя шул Тамир останы...

Тимерхан

Ташчы Тамир?! Урман илендә?!
Нишли ул анда?

Алтынбәк

Борынгылар изге дип табынган
урынны яңарта.
Анда, хәрефләре җуелган ташлар астында,
изгеләр ята...

Тимерхан

Кемгәдер изге. Ә кемгәдер ул —
куркыныч урын.

Алтынбәк

Ни сөйлисең? Төшенмим мин, атай...

Тимерхан

Анда... зиратта минем токымның
тәхеткә килү серләре күмелгән.
Хәзер үк Урман иленә алай[1] җибәрегез!

Хезмәтче керә, баш иеп чыга.

Иблис җирен ватарга, җимерергә!

Алтынбәк

Атай... атай!
Андый ниятеңне кыла күрмә!
Сиңа ышанып, мин җанымны ачтым.
Көчсез адәмнәргә кылыч белән
барырсың дип уйламаган идем...

Тимерхан

Хан әмере кире алынмый!
Башы иелгәнне — кылыч сөя.
Кылганнарым әгәр ошамаса,
күз алдымнан югал!
Нәрсә карап торасың?!
Кит моннан!

Алтынбәк

Атай, мине дә тыңла!
Әмер-фәрманыңны үтәсәң, —
мин сиңа — углан, син миңа — атай түгел!
(*Чыга.*)

Тимерхан

Улым, улым, тукта, китмә!..
Тукта, диләр сиңа!
Нәрсә булды миңа?
Җанга тынгылык юк.
Күңелем сизә: бәла булмагае...
Юк! Юк! Юк!
Урман иле аны харап итәр...
Ул һәлакәт эзләп анда китте!
Коткарырга аны үзем барам!
Һәй! Тизрәк!

[1] *Алай* — гаскәри төркем, отряд.

Ишетәсезме, аңгыралар?!
Акбүзатны бирегез!
Коткарырга аны үзем барам!

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

**Урман иле.**

Алкиз (*Ария.*)

Ярсу дулкындай таштым мин,
кайларга таба агам?
Кайныйм, янам, дулкынланам,
ике ярны да кагам,
мин кайсы ярга барам?
Синең газаплы карашың
Китми күңелемнән һаман,
хәтәр агымга ияреп,
мин кайсы ярга барам,
кайларга таба агам?
Хәсрәт дәрьясын табам...
Ярлар кушылмас мәңгегә,
агымнан туктап калам;
кайныйм, янам, үз-үземне
аккан язмышка салам,
упкынга кереп барам,
калмады башка чарам.
Нишлим соң инде,
нишлим соң инде?
Күңел тоя: хәерлегә түгел...
Ни булыр безгә, ни булыр?
Язмыш, бирмә бәлаләрне,
коткар безне, кичер!

**Тамир керер, аның янына тезләнә.**

Тамир

Язмыш, бирмә!
Тәңрем, коткар
бер гөнаһсыз,

Алкиз, Тамир

Бер гөнаһсыз балаларыңны!

Алкиз

Тамир, әйт син миңа,<br>нишләргә соң?<br>Кем коткарыр безне<br>бу бәладән?

Тамир

Тынычлан, Алкиз, тынычлан:<br>Кәккүкне мин таштан ясармын.<br>Ул чын Кәккүк кебек аваз бирер.<br>Табигать, бәлки, кичерер...

Алкиз

Юк, юк, Тамир, мин аңламыйм сине!<br>Салкын ташларың җанлы кош булалмый!<br>Тамир, Тәңрем безне мәңге кичермәс!<br>(*Яшенле-күкрәүле урманга таба китә.*)

Тамир

Алкиз, тукта, аңлашыйк әле...<br>(*Аның артыннан югала.*)

Акыл иясе Аксакал (*ерактан күренә.*)

Табигатьнең балалары көткән<br>мәрхәмәтләр һаман юк.<br>Көтелмәгән бәла булып кайта<br>адәм кылган һәрбер яманлык.

Караңгылана. Балет номеры. Куркыныч килгәнне тоеп, борынгылар рухы — Кыз белән Егет ташлар арасыннан атылып чыгалар. Алар кайда качып котылырга белмичә, ташлар арасында хәрәкәтләнәләр. Кача-поса Тимерхан өере керә. Алар изге урынны, ташларны, чишмә янындагы корылмаларны ваталар, чишмә улагын җимерәләр. Бу күренеш балет белән башкарыла һәм беренче күренештәге мыскыллы биюне хәтерләтә. Алар тарафыннан Кыз белән Егет тә, мәсхәрәләнеп, аяк асла3 рына салына.

Өер башлыгы

Ватыгыз! Җимерегез!

Өер

Ват! Җимер! Ват! Җимер!

Тавышларны ишетеп, Т а м и р керә, бу хәлне күреп, тегеләргә каршы ташлана.

Т а м и р

Мәлгуньнәр, туктагыз! Нишлисез сез?!
Коткарыгыз! Коткарыгыз!
Изге җирне мәсхәрәлиләр!

Җимерүчеләр Тамирга һөҗүм итәләр. Тамир кулына эләккән күсәк белән саклана. Урман ягыннан якынлашкан тавышларны ишетеп, җимерүчеләр качалар. Арадан берсе (өер башлыгы) таш артына яшеренә. Тамир берьялгызы, тузган чәчле башын иеп, кулына күсәк тоткан килеш, җимерелгән хәрабәләр янында басып тора.

Көннәр-төннәр дәртле уйлар белән,
өмет белән яшәдем мин, яндым.
Тынып калган,
онытыла барган
бабам җырын,
бабам җирен
уятам дип хыялландым.
Күкрәкне кагып,
хәсрәткә салып,
сыкрый бабам җыры.
Мәсхәрәләнгән
минем изге җирем, бабам җире,
бабам җыры
дәшә...
Алларымда — җансыз ташлар,
кабер сыман ята алар.
Ник мине дә салкын гүргә тарта алар...
Юк, юк! Гүр иясе итәлмәссез мине!
Җаным минем, исән чакта, таш астына кереп ятмас!
Нәләт сезгә! Нәләт сезгә!

Төрле яктан х а л ы к  т ө р к е м е җыела.

Нәләт! Нәләт! Нәләт!
(*Башын күтәрә, алдындагы адәмнәрне күреп.*)
Нәләт сезгә! Нәләт!

Акылыннан шашкан сыман, үз-үзен тыя алмыйча, хәрабәгә әйләнгән таш калдыкларын вата-җимерә башлый.

Өер башлыгы (*Яшеренгән җиреннән чыгып.*)

Ул шашкан! Тилергән!
Газиз җирне мәсхәрәли!

Төркем

— Ул шашкан!
— Тилергән!
— Газиз җирне мәсхәрәли!

Тамир

Хөкем сезнең кулда...

Кулындагы күсәген җиргә ыргыта. Өер башлыгы шунда ук күсәкне эләктереп ала.

Төркем

— Имансыз!
— Тотыгыз аны!
— Җәза бирик!
— Үлем! Үлем!

Алтынбәк (*Керә дә, аңлап алып.*)

Туктагыз! Җибәрегез аны!
Ул гаепле түгел!
Мине хөкем итегез!

Өер башлыгы

Үлем! Үтерергә аны!

Төркем Алтынбәк сүзләренә игътибар итми: аны читкә этеп, чиксез ачу белән Тамирга ташлана. Алда күсәк тоткан Өер башлыгы бара. Түгәрәк кысылганнан-кысыла. Бераздан аңсыз өер, тыела төшеп, читенә. Факеллар яктысында — Тамирның җансыз гәүдәсе. Төркем башлыгы кача.

Алкиз керә, Тамирның хәрәкәтсез гәүдәсенә ташлана.

Алкиз

Тамир! Тамир!
Ни булды?
Кемнәр харап итте сине?!
Тамир... Тамир...

Беренче тавыш

Имансыз! Ул изге ташларны мәсхәрәләде!

Икенче тавыш

Шул кирәк аңа! Тиешле җәзасын алды!

Алтынбәк

Юк, юк, ул гаепле түгел...
Барысы да миннән башланды...
Кичер мине, Алкиз...

Тимерхан (*Тән сакчылары, вәзирләре белән керә.*)

Алтынбәк?! Исән-аман!
Кылган догаларым кабул булды!
Әйдә, улым... әйдә, киттек моннан.
Улым, ник дәшмисең?

Алтынбәк

Син... син... син үтерткән гаепсез җан бу.
Ә син үзең, берни булмагандай,
тыныч, канәгать...

Тимерхан

Тыңла син, углан!
Башын игәннәргә — кылыч тими.
Димәк, ул үзе гаепле!

Алтынбәк

Аңга килеп, бик соң аңладым мин...
Нигә, нигә синең кара ниятеңне белмәдем мин?

Тимерхан

Ни булды соң сиңа,
ни сөйлисең, углан?

Алтынбәк

Мин ышандым,
мин ышандым сиңа...

Тимерхан

Булды! Җитте! Тукта!
Аңга кил син, ахмак!

Алтынбәк

Мондый явызлыкка барырсың дип
уйламаган идем...
Көтелмәгән бәла булып кайта
адәм кылган һәрбер яманлык...
(*Сүзсез хор.*)

Тимерхан

Минем углан, миннән туган
бала атасына — ханга каршы бара!

Тимерхан һәм хор

Аңга кил! Аңга кил!
Юлдан яздырганнар сине!

Тимерхан

Котырткannar сине.
Җеннәр тынгы бирми сиңа!

Тимерхан һәм хор

Тәүбә ит! Тәүбә ит!

Тимерхан

Барсына да шушы кыз гаепле!
Нәрсә карап торасыз!
Кулга алыгыз аны!

**Тимерхан үзе Алкизне үз арасына алган халык төркеменә каршы бара. Ике арада бәрелеш, буталыш китә.**

Тимерхан (*Җәясендәге укны тартып.*)

Мин язган язмыштан узмыш юк!
Минем уктан узмыш — юк!

**Ук җәядән ычкынып китә. Шул вакыт Алтынбәк Алкизне үзенең гәүдәсе белән каплый. Ук туп-туры аның күкрәгенә кадала.**

Алтынбәк (*Егыла.*)

Атай... атай...

Тимерхан (*Баласы өстенә ава.*)

Балам... Алтынбәк...
Ни кылдым мин?

Сиңа бәхет кенә теләгән идем...
Кичер... кичер мине...
Балам...

Ук-җәясен атып бәрә. Кая барганын, нишләгәнен дә белмичә, хәрабәләр арасыннан карурман ягына китеп югала.

Алкиз

Дөнья — адәмнәрнең зур оясы
Минем өчен салкын, буш инде;
оям да юк, мин үзем дә хәзер
канатлары каерылган җансыз кош инде...

Ташлар арасыннан чыккан борынгылар рухы — Кыз белән Егет уйчан, салмак хәрәкәтләр белән җимерелгән ташларны күтәрергә омтылалар, әмма аларның моңа көче җитми...

## ЭПИЛОГ

Вакыйга беренче күренештәге Болгар хәрабәләре белән алышына. Тамир — Дамирга, Алкиз — Гөлназга, Алтынбәк — Риманга әверелә.
Ерактан, үзәкләрне өзеп, фаҗигале борынгы көй ишетелә. Моны хәрабәләр арасыннан күренгән Акыл иясе Аксакал җырлый.

Акыл иясе Аксакал

Бәхетле булып дөньяда
гамьле яшәү өчен яралдык,
хәят гел, мәңге тар булыр
өстенлек итсә яманлык...

Көйгә заманча сүзләр тезелә. Аңа узган вакыйгалардан тетрәнеп җыелынган, җанланган ташлар да, Дамир да кушыла.

Дамир

Моннан мең ел элек
борынгылар яшәп киткән җир бу...
Газиз җирдән узган чакта
тукталып уйга кал,
узганнарга кайтып, гыйбрәт ал!..

Пәрдә.

*1988—1990*

# Соңгы төн*

*Трагедия-легенда*

Муса Җәлил үлем җәзасы алдыннан
В. Гётеның «Фауст»ын кабат укыган.

ФАҖИГА ГЕРОЙЛАРЫ:

Шагыйрь.
Тиран.
Мефистофель.
Гаскәр башлыгы.
Төрмә хуҗасы.
Баш җәллад.
Бәндә.
Кыз.
Шагыйрьнең сөйгәне.
Шагыйрьнең ике дусты.
Шагыйрьнең әнисе.
Кеше.
Робот.
«Җир хуҗасы».
Мәзәкчеләр, сакчылар,
җәлладлар, кызлар...

XX гасырның 40 нчы елларында төнге сәгать уникедән иртәнге алтыга кадәр булган вакыйга.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

Зур сәгать фонында — зиндан. Тиздән унике тула.

Шагыйрь

Җирдә — сугыш. Бөтен җиһан тетри-күкри,
Дәһшәт, үлем — без барасы юл өстендә.
Узды Тиран шомга салып... Шулай укмы
Кешелекнең киләчәге кыл өстендә?
Корал белән көчле идем — аердылар,
Куллар белән көчле идем — каердылар.
Күкрәгемдә, пычракларда тапталса да,
Тапланмаган бары җырым-җаным калды,

* 1982 елда Минзәлә татар дәүләт драма театрында куелды

Тип, йөрәгем, тип, йөрәгем, сана, сана:
Тагын ничә төнем калды, таңым калды?
Хөкем көтәм. Тәнем, туфрак-җир булырсың.
Табаннарым соң мәртәбә җир җылысын
Тояр... Кояш соңгы сәлам-нурын кояр.
Күпме газап, интегүләр күрде бу тән.
Һәммәсен дә үзем белән алып китәм.
(*Тәрәзәгә карап.*)
Тагын шул кыз... Кулларында — ап-ак чәчәк.
Һәр төн зарыгып көтеп алдым килгәнеңне.
Кемне шулай көтәсең син, төн гүзәле,
Хәтерләтеп яшьлегемдә сөйгәнемне?
Өч төн Тиран сорау алды — мин дәшмәдем.
Газапладեы — күрсәтмәдем күз яшьләрен.
Соңгы төнем... Шулай укмы залим Тиран
Җанымны да тәнем белән бергә күмәр?
Үлем килә: иң ахыргы сүзен әйтеп...
Булса иде гомеремне тик бер көнгә,
Тик бер генә көнгә бары озынайтып...

Сәгать төнге уникене суга. Дәһшәтле аяк тавышлары. Шагыйрь акрын гына күтәрелә.
Т и р а н кабинеты. Ул — глобус алдында.

Т и р а н

Җиргә яңа дәвер китерү өчен
Яратылган бөек милләтем
Өмет белән миңа карап тора,
Үрә катып һәрбер сүземә.
Күпме илләр инде башын иде
Минем тиңсез көчем алдында.
Әмма минем олуг ахыр максат
Үтәлмәгән әле.
Тумыштан ук Тәңрем шулай язган.
Һәм мин — хаким — хаклык-иманымны
Бар җиһанга икърар итәрмен.
Хак кылычым җирдә ялтырар,
Дөнья тетрәр, күкләр калтырар!
Ах, дөньям,
Син — минеке...
Бары тик минеке!
Тулы килеш, чистартылган килеш,

Кабул итеп алам мин сине,
Шунсыз җаным тынычлана алмас,
Күзләр йокы күрмәс...
Ә мин беләм: моңа ирешермен,
Аллам миңа юлдаш булганда,
Аның кодрәтенә таянып мин
Әйтә алам:
Җирдә минем каным,
Минем нәселем генә калачак!
Күк астында калган һәрбер бәндә
Тик минемчә уйлар,
Тик минемчә сөйләшер!
Әйе! Киләчәктән мәхрүм булган
Телләр, хәрабәләр өстендә
Бөек дәүләт, милләт, мәдәният
Күтәрелер, күккә үрләр!
(*Өстәл янына килә, кәгазь алып.*)
Яу кырыннан һаман яман хәбәр...
Шанлы гаскәрләрем туктап калды.
Зур-зур югалтулар.
Дошман көч туплаган.
Гаскәр башлыгы!

Гаскәр башлыгы (*Керә.*)

Дөнья хакименә шан һәм шөһрәт!

Тиран

Әйт! Ни булды?

Гаскәр башлыгы

Ярты гаскәрләрен кырып салдык.
Әмма үтәлмәдек...

Тиран

Сәбәп?

Гаскәр башлыгы

Алар безгә караганда азрак иде...
Бөтен көчне шунда юнәлттек...
Әмма...

Тиран

Әмма?!

Гаскәр башлыгы

Алга китәлмәдек...

Тиран

Югал, йолкыш!

Гаскәр башлыгы чыга. Тиран, үзен тынычландыру өчен, глобусны әйләндерә.

Тиран

Нинди ил бу? Нинди адәмнәр?
Төрмәдә дә буйсынмыйлар.
Әллә инде ул халыкта
Мин белмәгән серле көч бармы?
Ни булды соң миңа?
Әллә инде көчем кими бара?
Шикләнәм мин: әллә һәммәсе дә
Миңа хыянәтчел тозак кора?
Таянычым — Баш җәлладка ышаныч аз!
Кем башын киссә дә — аңа барыбер!
Төрмә хуҗасы да — шул ук!
Төрмә хуҗасын!

Төрмә хуҗасы (*Керә.*)

Дөнья хакименә шан һәм шөһрәт!

Тиран

Ниләр бар анда?

Төрмә хуҗасы

Буйсынганга — богау, үзсүзлене
Олактырам теге дөньяга!

Тиран

Фетнә куркынычы бетте, димәк?

Төрмә хуҗасы

Сезгә мәгълүм: фетнә башлыгы
Шагыйрь иде... Хәзер — тындылар.
Үзе шунда һаман — таш капчыкта
Хөкем көтә.

Тиран

Сугыш хәлләреннән хәбәрдармы?
Безнең тукталуны белмиме?

Төрмә хуҗасы

Адәм түгел — җен дә үтә алмас!

Тиран

Шагыйрь әзерме?

Төрмә хуҗасы

Әзер!

Тиран

Баш җәлладны!

Баш җәллад (*Керә.*)

Дөнья хакименә шан һәм шөһрәт!

Тиран

Телгә килдеме?

Баш җәллад

Кулланмаган җәза калмады.
Дәшми.

Тиран

Син — шул эшнең мәшһүр остасы.
Кара аны: мин канәгать түгел!
Онытма: кем идең —
Минем дәүләтемдә кем булдың?

Баш җәллад

Мәңге онытмам, хуҗам!

Тиран

Өч тапкыр бит миңа алып килдең...

Баш җәллад

Дүртенче төн күз йомган юк,
Эштән эт шикелле арып кайтам.

Тиран (*Баш җәлладка.*)

Чыгып тор! (*Җәллад чыга.*)
Баш докторның фәнни эшләреннән
Файда бармы?

Төрмә хуҗасы

Зинданнар— фәнни лаборатория!
Юк булуга дучар ителгән
Түбән расаларның токымнарын,
Нәселен корытуга юнәлгән
Тәҗрибәләр үзен аклый, хуҗам!
Баш докторның яңа ачышы да
Сезнең фатиханы көтә.

Тиран

Ни ачты ул?

Төрмә хуҗасы

Сезнең даһи тәгълиматтан чыгып,
Кол-бәндәнең яңа төрен ачты.

Тиран

Ягъни?

Төрмә хуҗасы

Мигә, органнарга физик тәэсир,
Һәм бәндә — әзер!
Күрсәтергә рөхсәт итегез!

Тиран

Рөхсәт! (*Утыра.*)

Төрмә хуҗасы

Бәндәне кертегез!

Ике яктан ике гаскәри Бәндәне алып керәләр. Ул униформадан.

Менә үзе! (*Әсирнең папкасын ачып.*) № 56026.

Тиран

Гаебе?

Төрмә хуҗасы

Сезнең бөек тәгълиматка каршы юнәлештә
уйларга җөрьәт иткән.

Тиран

Гаебен таныдымы?

Төрмә хуҗасы

Барлык җәзаларны үтте. Әмма үз сүзендә калды.
Шуннан Баш докторга мин тапшырдым аны.
Менә — нәтиҗә!
Бәндә, үрә кат! (*Бәндә «смирно»га баса.*)
Хәзер аңа нинди әмер бирсәң — шуны үти.
Шулай өйрәтелгән. Бәндә, мин кем?

Бәндә

Сез — кеше, галиҗәнап!

Төрмә хуҗасы

Син кем?

Бәндә

Мин бәндә, галиҗәнап!

Төрмә хуҗасы

Бәндә, төрмә сиңа ошыймы?

Бәндә

Төрмә миңа ошый, галиҗәнап!

Төрмә хуҗасы

Бәндә, кемгә каршы сугышасың?

Бәндә

Кемгә каршы җибәрсәгез — шуңа каршы!

Төрмә хуҗасы

Бөек хуҗа өчен үләргә дә ризасыңмы?

Бәндә

Риза!

Төрмә хуҗасы

Бөек хуҗаңа ничә ел гомер телисең?

Бәндә

Мең ел!

Тиран

Алыгыз! Чакырганны көтсен! (*Бәндәне алып чыгалар.*)

Төрмә хуҗасы

Сезгә тугрылыклы солдат артты!

Тиран

Бары бер солдат? Йөз мең!

Төрмә хуҗасы

Бу — беренче данә. Сездән — рөхсәт?

Тиран

Вакыт көтми. Бик тиз!

Төрмә хуҗасы

Бер ел?

Тиран

Бер атна!
Кешеме ул, җенме, бәндәме —
Миңа солдат, солдат, солдат кирәк!

Төрмә хуҗасы

Булыр, хуҗам!

Тиран

Шагыйрьне!

Шагыйрьне кертәләр. Тынлык.

Утырыгыз. (*Шагыйрь кузгалмый.*)
Кәефегез ничек? (*Тынлык.*)
Анда эшләү өчен шартлар бармы? (*Тынлык.*)
Сез, бәлки, җәнлекләр яратасыздыр?

Әллә читлектәге кошларнымы?
Мин үзем балыкларның йөзеп йөрүләрен
карап торырга яратам.
Теләсәгез, мин аквариум куярга боерырмын.
Бәндәне!

Бәндә керә һәм Тиран алдында, үрә каткан кыяфәттә, туктап кала.

Шагыйрь

(*Бәндәгә таба омтылып.*) Яшьтәш!
(*Бәндә калтыранып куя, әмма дәшми.*)
Танымыйсыңмы әллә? Мин — шагыйрь...
(*Тынлык.*)
Исеңдәме, бер чишмәдән сулар эчтек,
Кайгыларны, газапларны бергә кичтек.
Әсирлектә бергә кочаклашып,
Туган җирне сагынып җырлаган төн
Исеңдәме? (*Җырлый.*)
Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам, дуслар, илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам.
Яшьли сөйгән иркәмне.
Оныттыңдамыни? Ник дәшмисең?
*(Бәндә дәшми, Шагыйрьгә карамаска тырыша.)*
Мин дә озак дәшмәдем. Хәзер безгә дәшмичә
ярамый!

Тиран

Ялгышасың, ул сөйләшә. (*Бәндәгә.*)
Үрә кат! Син кем?

Бәндә

Бәндә, бөек хуҗам!

Тиран

Хуҗаңа ничә ел гомер телисең?

Бәндә

Бөек хуҗама — мең ел гомер!

Шагыйрь

Сатлык җан!

Тиран

Борыл! Ычкын! (*Бәндәне алып китәләр.*)
Дустың белән очрашуга мин бик шат.

Шагыйрь

Ул дус түгел.
Ул оныткан Туган ил җырын.
Хәзер ул — кол!

Тиран

Ул — ирекле. Ул төрмәдә түгел.

Шагыйрь

Илдән башка ирек — ирекме?
Төрмәдә мин — мең кат ирекле.

Тиран

Бу дустың да шулай сайрый иде. Ә хәзер ул —
тугрылыклы минем солдатым.
Дус-ишләрең бары да миңа күчте.
Син ялгызың, кемең бар тагын?

Шагыйрь

Тормыш һәм җыр биргән газиз әнкәм.

Тиран

Сөйгән кызың да бармы?

Шагыйрь

Ул да көтә мине.

Тиран

Хәзер генә хәбәр китерделәр:
Уртаклашам авыр кайгыңны...
Әниең дә, сөйгән кызың да һәлак булган.

Шагыйрь

Ялган!

Тиран

Берьялгызың калдың — кемең бар?

Ш а г ы й р ь

Туган илем бар!

Т и р а н

Хәзер синең илең дә юк.

Ш а г ы й р ь

Андагы елгалар гел шаулап агарлар,
Туктата алмассың,
Сандугач, тургайлар гел канат кагарлар,
юк, ата алмассың,
Чишмәләр юлларын диңгезгә борырлар,
Туктата алмассың,
Изге саф сулары тирәндә булырлар,
гел җырлап торырлар,
юк, йота алмассың!

Т и р а н

Шәраб! (*Касә белән шәраб китерәләр.*)
Аңа бирегез!

Т ө р м ә х у җ а с ы

Бик-бик теләсә дә, ул эчәлми.
Аның ике кулы хәрәкәтсез:
Каләм һәм дә мылтык тотмаслык...

Т и р а н

Эчерегез!
(*Касәне Шагыйрьнең авызына китерәләр.*) Эч!
(*Авызына коялар.*) Ни эчкәнеңне беләсеңме?

Ш а г ы й р ь

Туган җирем йөземеннән...

Т и р а н

Туган җирең инде минем кулда.
Ышандыңмы?

Ш а г ы й р ь

Туган җирне булмый тартып алып...
Катламнарның иң-иң тирәнендә,

Тамырланган күпләр йөрәгендә —
Менә монда!

Тиран

Бу касәнең нидән ясалганын беләсеңме?

Шагыйрь

Акыл иясенең баш сөягеннән.

Тиран (*Аптырап.*)

Әйе... Син — кол-әсир.
Язмышыңа — мин хуҗа!
Һәрбер минутыңа— мин хуҗа!
Бер хәрәкәт, бер сүзем...

Шагыйрь

Төрмәләргә, колларыңа хуҗа,
Ә җаныма хуҗа — мин үзем!
Шагыйрь беркайчан да кол булмас,
Кол шагыйрьдән моңлы җыр тумас.

Тиран

Йөрәгеңдә әгәр көч-дәрт булса,
Берәр шигырь чыгар.
Тик көләрлек булсын рәхәтләнеп...
Хөкем чыгарганда искә алам. Яле...

Шагыйрь

Җир шарын яулап алам, дип,
Дөньяга чаң каккан, ди,
Үзе төрткән ут берзаман
Үз артына капкан, ди.
Гаскәрен артта калдырып,
Әй, кирегә чапкан, ди,
Дөньядан колак каккан, ди,
Өч аршин җир тапкан, ди.
(*Тиранга карап кычкырып көлә.*)
Ха-ха-ха!

Тиран (*Төрмә хуҗасына.*)

Ул нигә көлә?

Төрмә хуҗасы

Ул акылдан шашкан!

Тиран

Туктатыгыз аны көлүдән!

Шагыйрьнең авызын томалыйлар.

Соңгы тапкыр көлгән адәм генә миннән көләргә җөрьәт итә. Син шуны беләсеңме?

Шагыйрь

Беләм.

Тиран

Үзең белән бергә юк булачак бу көлүең.

Шагыйрь

Ялгышасың, тиран, көлү калыр.
Бу шигырьне яу кырында һәрбер солдат белә.
Зиндандагы һәрбер әсир белә.
Әнә теге яктан көлү куа килә.
Бар гаскәрләр, бар төрмәләр көлә,
Ачу-нәфрәт, каргыш белән көлә:
Аяк астың яна, җир селкенә,—
Йөгерергә вакыт җитеп килә!..

Тиран

Әйдә, бергә уйлыйк:
Нинди үлем сиңа мәгъкуль булыр?
Ату?

Шагыйрь

Газапланмый гына җиңел үлем...

Тиран

Асу?

Шагыйрь

Бик искергән ысул.
Гасыр өчен заманчарак үлем
уйлап кара.

Т и р а н

Җәлладны!

Өч җ ә л л а д керә. Уртада — Б а ш  җ ә л л а д.

Баш җәллад, сиңа — эш: Шагыйрь!

Б а ш  җ ә л л а д

О, Шагыйрь? Яшь, ахмак чагымда мин дә кәгазь пычратып карадым.

Т и р а н

Шагыйрь булсаң, ә?

Б а ш  җ ә л л а д

Сезнең бөек тәгълиматка табынгач, мин шагыйрь башының киселү өчен муенда йөргәнен тиз аңладым. Дөнья шагыйрьдән башка яши ала, җәлладтан башка таркала, һәлак була.

Ш а г ы й р ь

Җырсыз дөнья — җансыз дөнья.

Т и р а н

Соңгы сүзең бармы?

Ш а г ы й р ь

Соңгы сүзем калыр җырларымда!

Т и р а н

Җырыңны да күмәбез!

Ш а г ы й р ь

Күмәлмәссең!
Тираннар омтыла — тәхеткә,
Шагыйрьләр омтыла — бәхеткә.
Тиранның кулында — ак кылыч,
Шагыйрьнең кулында — хак кылыч.
Тиранның юлында — кан кала,
Шагыйрьнең юлында — җан кала.
Тиранның эзендә — җир яна,
Шагыйрьнең эзендә — җыр яна.

Тиранның каберендә — җил исәр,
Шагыйрьнең каберендә — гөл үсәр.
Шагыйрьнең сүзләре — ук булыр,
Тиранның эзләре — юк булыр!

Тиран

Тыңлагыз хөкем карарын!
Минем тарафтан Җир йөзендә урнаштырылган
яңа тәртипкә каршылык күрсәткәне өчен, мин
Шагыйрьне үлем җәзасына хөкем иттем!
Гильотинада башын чабарга!

Баш җәллад

Кайчан башкарырга боерасыз?

Тиран

Хәзер үк! (*Шагыйрьгә.*)
Соңгы үтенечең?

Шагыйрь

Син үзеңне хөкем иттең бүген,
Көчсез икәнеңне расладың.
Мәсхәрәле үлем көтә сезне!
Соңгы үтенечең бармы, Тиран?
Соңгы үтенечең бармы, Җәллад?

Тиран

Алыгыз!

**Шагыйрьне алып китәләр. Тиран, үзен кая куярга белмичә, бүлмә буйлап йөри.**

Ниндидер бер мөнәҗәтче бәндә
Миннән көлсен, имеш...
Шагыйрь... Батыр булып үлә, имеш...
Юкка гына! Аның иленә
Хәбәр китте: анда Шагыйрьне
Беләчәкләр сатлык җан итеп...
(*Төрмә хуҗасына.*) Тыңла, үтә!
Кәгазь пычратучы шагыйрьләрнең,
Галимнәрнең башын кисәргә!
Алар җирдә исән йөргән чакта,
Йоклый алмам.

Мөмкин китәргә!.. Тукта!
Барчасыннан бәндә ясарга!
Буйсынмыйлар икән — асарга!

Төрмә хуҗасы

Тыңлыйм, хуҗам! (*Китә.*)

Тиран

Шулай да ул минем алдымда
Тетрәнмәде. Чын солдатча
Каршы алды үлем карарын.
Каян анда ул көч?
Ә мин... көчсез булып калдым.
Ул халыкның көчен сындырырга
Нинди чара табыйм?
Әллә ялгышаммы?
Юк! Каршы бер көч җирдә кимеде.
Бетте Шагыйрь, китте дөньядан...

Бүлмәнең бер почмагына бара. Кинәт аннан Шагыйрь көлүе ишетелә. Тиран, гаҗәпләнеп, чигенә. Бүлмәнең икенче ягына барса, аннан Мефистофель көлүе яңгырый. Ул, аптырап-куркып, артка чигенә.

Мефистофель тавышы

Синең төп ялгышың шунда булды...

Тиран (*Каушап, күккә карап.*)

Минме? Кем ялгышты?

Тавыш

Әйе, син ялгыштың.

Тиран

Әйт дөресен, мине ни көтә?

Тавыш

Җиңелү.

Тиран

Юк, ышанмыйм!

Мефистофель (*Пәйда булып.*)
Бөтен рухым белән ант итәм!

Тиран
Син кем?

Мефистофель
Син үзеңне өстен көч исәпләп ялгышасың.

Тиран
Син кем?

Мефистофель
Өстен көч.

Тиран
Кемнән өстен?

Мефистофель
Синнән, кешедән, табигатьтән.

Тиран
Син әллә теге дөньяданмы?

Мефистофель
Тегесеннән дә, бусыннан да.

Тиран
Сакчылар!

Мефистофель
Килсәләр — юк булам — вәссәлам!

Тиран
Ниятең изгеме, явызмы?

Мефистофель
Изгелек, явызлык — бер миңа,
Өстен мин барыннан.

Тиран
Кем соң син, нәрсә син?

Мефистофель

Мефистофель. Доктор Фаустның мин Җанын
алган рухмын*.

Тиран

Шайтан, рухлар миңа юлдаш түгел.

Мефистофель

Синең төп ялгышың шунда булды...

Тиран

Нидә?

Мефистофель

Йомшаклыгың синең — тупас көчтә.
Хәтерлимсең, синнән галимнәрең,
Акыл-рухлар качты. Калганнарын
Юкка чыгардың син. Китапларын
Утка салдың. Йә әйт, шуның белән
Нишләмәкче булдың?

Тиран

Дөньядагы барлык адәмнәрнең
Тик минемчә генә уйлауларын,
Тик минемчә генә яшәүләрен,
Тик минемчә генә сөйләүләрен,
Бары миңа гына буйсынуын
Теләдем мин! Телим! Һәм булыр!

Мефистофель

Ләкин адәмнәрнең акыл-җанын
Җиңү мөмкин түгел җәзалап!

Тиран

Җиңеп була бары көч белән,
Кырып, сытып, таптап, җимереп!

---

* Немец халкының доктор Фауст турындагы легендаларында табигатьне, яшәешне таныл белә алмаудан өметсезлеккә бирелгән Фаустның, явызлык рухы Мефистофель белән килешүе турында сөйләнә, Килешү буенча ул җирдәге барлык рәхәтне татыганчы яшәячәк, әмма моның бәрабәренә җанын сатарга тиеш була.

Мефистофель

Ә Шагыйрьне җиңә алдыңмы соң?

Тиран

Бетте! Юк ителде!

Мефистофель

Шагыйрь башын кисү — көчсезлек бит.
Тираннар...
Сез нинди вак, түбән бәндәләр!
Бер үк хаталарны кабатлыйсыз.
Моңа кадәр әле берегез дә
Шагыйрь рухын җиңә алмады.
Дөрес көлде сездән Шагыйрегез.

Тиран

Йә, синеңчә, нидә ялгыштым мин?

Мефистофель

Дошманыңны үтерүдән элек,
Акылын, җанын яулап ал аның
Һәм үзенә каршы юнәлтә бел.
Ә син шуны аңлый алмадың.

Тиран

Үз сүземдә калам. Хаклы икәнеңне
Раслап күрсәт.

Мефистофель

Мөмкин расларга!
Тик ашыкма Шагыйрь башын кисәргә.

Тиран

Мин ни отам?

Мефистофель

Мәшһүр шагыйрь җыры — ирек өчен
Көрәшченең рухи юлдашы.
Шагыйрь үзе исә — юл башы.
Җырын үзләренә каршы борсаң,
Сине яу кырында уңыш көтә...

Тиран

Уңыш?

Мефистофель

Мин ишеттем: Шагыйрь мәсхәрәле
Шигырь атты синең йөзеңә.
Мин теләсәм әгәр — Шагыйрь үзе
Уч төбемә салыр үз җанын.

Тиран

Ә син моңа ничек ирешәсең?

Мефистофель

Анысы — сер, минем эш!

Тиран

Бу — кызык. Тик ышанып бетмим.

Мефистофель

Каты токым. Беләм. Тиз бирелмәс.
Бөтен рухым белән ант итәм:
Соңгы адымда
Шагыйрегез юха елан кебек
Шуышып йөрер минем алдымда.

Тиран

Минем алдымда...

Мефистофель

Синең алдыңда да.

Тиран

Тәкъдимең?

Мефистофель

Вакыт бир.

Тиран

Күпме?

Мефистофель

Иртәнге алтыга кадәр.

Җәзалауны туктат. Әмер бир!

Тиран

Сакчылар!

Сакчы керә.

Шагыйрьне алып киттеләрме?

Сакчы

Алар юлда!

Тиран

Бар, хәбәр ит тизрәк! Җәзалауны туктатырга!

Сакчы чыга.

Мефистофель

Килештек! Иртәнге алтыда төрмәгә кил!

Тиран

Килештек! Хәерле юл!

Караңгылана. Мефистофель сәхнә алдына чыга.

Мефистофель

Җир белән Күк арасында йөреп,
Ваклыклардан туеп, бермәлне
Күреп алдым көчле бер җанны.
Мин үземнең тиңсез рухым белән
Тәңре коллыгыннан ычкындым.
Шагыйрь тираннардан өстен калды...
Шигъри җаннар Җирдә канат җәйсә?
Ярыймы соң моңа юл кую!
Бу, әйтергә ярый, карап торып,
Җиңелүгә үзең кул кую.
Соңгы минут, соңгы сәгатьтә
Адәм, гадәттә,
Җаны белән ялгыз торып кала,
Яки рухлар белән сөйләшә.
Яки гакылыннан яза.
Чөнки алда — җәза, соңгы төн.

Карыйк: адәм ничек каршы алыр
Иң кадерле актык минутын.
Мин Тиран да һәм Алла да түгел,—
Тираннардан өстен, югары!
Миңа буйсынмаган, бирелмәгән
Адәм заты җирдә юк әле!
Аның көче:
Җәза-кыйнауларга
Түзә ала — чыдам, батыр, нык.
Йомшак ягы: яшәү, ирек сөя,
Ә иманы исә — матурлык.
Адәм газапларга чыдый ала,
Ә рәхәткә... юк... юк... түзәлми.
Коллык чылбырларын өзәлсә дә,
Ләззәт чылбырларын өзәлми.
(*Төрмә алдындагы почмакта*
*чәчәк тоткан кызны күреп.*)
Яшь кыз... бик тиз гашыйк булырлык.
Күп кирәкме әллә адәмгә?

Кыз

Чәчәк сатам! Алыгыз! Иң саф чәчәкләр!

Мефистофель

Чәчәк кенә микән... кем белә?
Чәчәгеңне төнлә кем күрә?

Кыз

Күрдегез ич!
Ялгыз, төнлә, нишләп йөрисез?

Мефистофель

Бәхетсезгә бәхет бүләк итәм.

Кыз

Миңа булса иде ул!

Мефистофель

Бәхет бушлай бирелми, кызый.

Кыз

Ак чәчәкләр — бөтен байлыгым!

Мефистофель

Тулган ай шикелле ике күкрәк,
Төнне балкытучы ике күз...
Һуштан яздырырлык ике сүз,—
Моннан да зур байлык ник кирәк?
(*Кызның күкрәгенә кыйммәтле җәүһәрләр тага.*)

Кыз

Бу — серле төш булып тоела... (*Кире биреп.*)
Юк, түли алмам гомерем буена.

Мефистофель

Миңа күп кирәкми.
Менә бу төрмәгә кара!

Кыз

Карадым.

Мефистофель

Тәрәзәдәге утны күрәсеңме?

Кыз

Күрәм.

Мефистофель

Анда — Шагыйрь.

Кыз

О, Шагыйрь? Төрмәдә?

Мефистофель

Тиран белән килешүгә бармый.
Башын кисәчәкләр!

Кыз

Ой!

Мефистофель

Коткарырга кирәк ничек тә...

Кыз
Өйрәт!

Мефистофель
Син аны үзеңә әсир ит!

Кыз
Бу эштә мин инде сыналган.

Мефистофель
Синнән күз дә алмас ул,
Өздереп бер карарсың!

Кыз
Өздереп бер карармын!

Мефистофель
Сихри кара күзләреңә
Иярмичә калмас ул!

Кыз
Иярмичә калмас ул!

Мефистофель
Тылсымнарың белән тәэсир ит,
Буй-сыннарың белән әсир ит.

Кыз
Тылсымнарым тәэсир итәрләр,
Буй-сыннарым әсир итәрләр.

Мефистофель
Үз эшеңне оста башкаралсаң,
Хакын икеләтә алырсың.

Кыз
Ничек кушсаң — шулай булыр, хуҗам!

Мефистофель
Әгәр шуны үти алмасаң —
Мәңгелек кол!

Чакырырмын, шунда йөреп тор! (*Югала.*)

Кыз

Тыңлыйм, хуҗам!
Әллә нинди шомлы куркыныч төн...
Кем бу? Җенме? Әллә адәмме?

Төрмә. Үлем камерасы.

Шагыйрь

Өстәлемдә китап. Кемдер куйган.
«Фауст». Бәлки, пастор килгәндер,
Бәхилләшкән чакта бу адәмгә
Бер изгелек кылыйм, дигәндер.
Теләсәм дә, бик-бик теләсәм дә,
Ача алмам барлык битләрен,
Геройлары белән бәхәсләшеп,
Бәхилләшеп җирдән китәрмен.
Үлememне салкын кан белән мин
Каршылармын. Беләм. Тик менә
Җаным әрни. Соңгы язмышымны
Беркем белмәс,— дошман яшерер.
Күңелемдәге соңгы җырларымны
Кемгә, кемгә китим калдырып?
Изге әманәтне Туган илгә
Тапшырырлык бер зат юкмыни?
Юк шул, юк шул... Тормыш йомгагы
Сүтелеп бетә... Гомер кыскара.
Ахыр сулышымда ышанып бер
Сүз кушарлык ихлас җан булса...

Тавыш

Бар андый җан.

Шагыйрь

Кем син?

Мефистофель

(*Кинәт стена ачылып, пәйда була.*)
Син күрәсе килгән изге бер җан.

Шагыйрь
Бу китапны син китердең, димәк?

Мефистофель
Әлбәттә.

Шагыйрь
Ничек үттең төнге сак аша?

Мефистофель
Мин һәркемнең күңеленә керәм
Кырык йозак, җиде ят аша.

Шагыйрь
Кем дип дәшим сиңа, исемең ничек?

Мефистофель
Өстәлеңдә — «Фауст». Син дә җирнең
Мәгънә эзләүче бер Фаусты.

Шагыйрь
Димәк, «Фауст» үзенең иярчене
Мефистофель белән кавышты?

Мефистофель
Таныдың?

Шагыйрь
Мин сөйләшер идем Фауст белән...

Мефистофель
Үзең шаһит: Тиран тарафыннан юк ителде
Җирдә хаклык, мәгънә эзләүчеләр.
Бу төрмәнең соңгы Фаусты — син.

Шагыйрь
Нигә килдең?

Мефистофель
Шагыйрьләрнең җанын хөрмәт итәм.

Шагыйрь

Ниятең?

Мефистофель

Сиңа ярдәм итү.

Шагыйрь

Соңга калдың.

Мефистофель

Нәкъ вакытлы килеп өлгердем.

Шагыйрь

Максатың ни?

Мефистофель

Сине Тиран коллыгыннан азат итү.

Шагыйрь

Мин үлемгә хөкем ителгән.
Гильотина көтәм.

Йоклыйлар дусларым, белмиләр.
Йоклагыз, дусларым белмәгез!
Соң тапкыр йоклагыз төш күреп,
Тик җәллад балтасын күрмәгез...

Хыялый-шатлыклы музыка. Караңгылы-яктылы күренеш: үлемнән котылып кайткан кеше һәм аның сөйгәне бер-берсенә тартылалар, әмма кушыла алмыйлар.

**Үлемгә хөкем ителгәннәр төше**

Мин хөкем ителдем йөз яшькә
Кадәре картаймый яшәргә.
Мин кайттым, кадерлем, кил, кочыйм,
Карама чал төшкән чәчләргә.
Дөньяда коллар юк, төрмә юк.
Онытылган золымнар, газаплар.
Мин кайттым, кадерлем, кил, кочыйм,
Колларым богаудан азатлар.
Төрмәнең нигезен актарып,

Ал гөлләр чәчегез, сеңелләр!
Мин кайттым, кадерлем, кил, кочыйм,
Кулларым богаулы түгелләр.
Карт дөнья иркенләп тын ала.
Толымың муеныма урала.
Мин кайттым, кадерлем, кил кочыйм,
Елама, керфегең чылана...
Елама...

Хыял-төш югала.

Шагыйрь

Гильотина көтәм.

Мефистофель

Юрамыйм да төшне, әйе, чынлап,
Мин яшәүгә сине хөкем итәм.

Шагыйрь

Чыннан дамы бу төш өн булыр?

Мефистофель

Бу — гаҗәеп серле төн булыр!
Әйе, төшең — өн булыр.
Мин гомереңне синең озайтам.

Шагыйрь

Күпмегә?

Мефистофель

Үзең теләгән кадәр. Бер көн... бер ел...
Бик телисең икән... хәтта йөз ел...

Шагыйрь

Ничек?

Мефистофель

Син, әлбәттә, тиеш түләргә.
Килешкәндә шунсыз булмый, дустым.

Шагыйрь

Син бит моңа кыйммәт сорарсың...
Байлыгым юк, күреп торасың.

Мефистофель

Синең әле рухың, җаның бар.
Мин яшәтәм сине теләгән кадәр,—
Син... җаныңны миңа бирәсең...

Шагыйрь

Менә нинди икән синең максат...
Минем сатыла торган җаным юк! Юк!

Мефистофель

Реаль кара, дустым, мәсьәләгә,
Язмышыңны минут хәл итә.
Икенең берсе: яки гильотина,
Яки гамьсез рәхәт озын гомер...
Дөнья кайгысыннан азат тормыш.
Ирек. Байлык. Хөрмәт. Дан. Дәрәҗә.
Ләззәт. Рәхәт. Бәхет. Сәгадәт.
Яки үлем шушы минутта ук!

Шагыйрь

Җаның сатып йөз ел яшәгәнче,
Хөр җан белән үлү — мең артык!

Мефистофель

Бер караудa син хаклы да кебек,
«Афәрин!» дип әйтәм моңа тик.
Буйсынмаганнарны хөрмәт итәм.
Мин үзем дә шундый бер затмын.
Мондый чакта килеп, минем кебек,
Ярдәм кулын сузмас беркем дә.
Уйла, дустым:
Калган бик аз гына гомереңне
Яшәп кара минем иркемдә.
Мәрхәмәтсез вакыт бик кысса да,
Дөнья белән бәхилләшергә...

Шагыйрь

Ә мин риза соңгы минуткача
Синең белән бәхәсләшергә.

Мефистофель

Син бит шагыйрь, нечкә күңелеңә
Төрле уйлар киләчәк, беләм.
Әмма шуңа кадәр, дускай, сине
Очраштырам киләчәк белән.
Тиран китә... килә икенчесе...
Үзгәрә тик бары формасы.
Явызлык ул, дускай, адәмнәрнең
Юлдашы һәм яшәү нормасы.
Ерак-ерак киләчәккә кара:
Тел йотылган, халкың онтылган...
Күр, таныш бул, әнә яңа хуҗа
Җир-тәхеткә менеп утырган.

Мефистофель хыялы: Җир-тәхеттә — «Җир хуҗасы». Өч җәллад Шагыйрьне кертәләр.

«Җир хуҗасы»

Кем бу?

Баш җәллад

Үз халкының соңгы Шагыйре.

«Җир хуҗасы»

Аңа ни калган?

Баш җәллад

Әрем генә үскән далаларда
Берьялгызы йөри «халкым» дип...
Ахры, акылдан шашкан.

«Җир хуҗасы»

Минем җирдә сиңа ни кирәк?

Шагыйрь

Җанга якын телдә сөйли торган,
Минем җырларымны көйли торган,
Әнкәм булып җиргә тудыручы,
Җан бирүче, моңлы җыр бирүче,
Назлы бишегендә үстерүче,
Авыр минутларда көч бирүче —
Халкым кайда минем?

«Җир хуҗасы»

Андый халыкны мин белмим!
Җирдә тик бер генә халык бар —
Минем халкым! Минем нәселем!
Җиһан өчен барган тиңсез яуда
Микро-халык, микро-нокталарны
Юк иттем мин. Куплэп үрчетергә
Лаек булган затлы бер нәсел —
Минем токым калды Җир йөзендә!

Шагыйрь

Юк, синеңчә булмас!
Кеше акылы моңа юл куймас!
Тарих, вакытлыча чигенсә дә,
Синең ихтыярга буйсынмас!

Баш җәллад

Даһи хуҗам, Шагыйрь җәза көтә.
Асу? Ату? Гильотина?

«Җир хуҗасы»

Менә шушы хөкем карары:
Ул ирекле.
Җибәрегез үзен!

Баш җәллад

Һич аңламыйм... Шагыйрьне?!

«Җир хуҗасы»

Иң коточкыч җәза — аны исән калдыру!

Баш җәллад

Төшенмим, хуҗам.

«Җир хуҗасы»

Хәзер ул безгә куркыныч түгел,
Халкыннан, теленнән башка — Шагыйрь юк!
Хөкем карарын үтә!

Баш җәллад

Син ирекле!

Далага җибәрегез үзен!
Кайчандыр үз халкы яшәгән далага!

«Җир хуҗасы» һәм җәлладлар югалалар.

Шагыйрь

Кирәк түгел миңа мондый ирек!
Халкым кайда минем, туган телем?!

Шагыйрь зур авырлык белән Мефистофельнең рухи коллыгыннан ычкынып, авансценага килә.

Шагыйрь

Юк!
Басып кергән яулардан
Болгар дигән ил янган,
Җимерелгән, тапталган.
Болгар дигән ил янган,—
Халык калган, тел калган,—
Уклар — ата алмаган,
Туплар — вата алмаган.
Гөлне киссәң — гөл кала,
Телне киссәң — тел кала,
Башны киссәң — ил кала,
Илдә туган тел кала.
Юк!
Кеше мәгърур! Үз куллары белән
Коллык чылбырларын өзәр дә
Җиң сызганып башлар тираннарсыз,
Сугышларсыз тормыш төзәргә.
Кеше узар. Үлем кораллары
Җир астында калыр тапталып,
Планета тыныч сулыш алыр,
Аек акыл итәр патшалык!

Мефистофель

Тынычлан...

Кул хәрәкәте: җиңел музыка. Ике мәзәкче пантомимасы. Алар бармак очларында Җир шары формасындагы шарны йөртәләр. Шар, төшеп китте дигәндә, әле берсе, әле икенчесе тотып ала. Музыка тизләнә, шар өчен талаша башлыйлар. Музыка туктала — шар шартлый! Мәзәкчеләр шаркылдап көләләр дә югалалар.

Әйе, шагыйрьләрнең хәле авыр...
Киләчәккә карап торам да,
Хаклык синдә, мин дә хуплыйм сине -
Берчак Җирдә калмас Тиран да...
Кеше...
Берсен-берсе таптап, сытып узар,
Берсен-берсе кырып бетерер,
Һәм Җир шарын беркөн, сугыша-сугыша,
Яшәмәслек хәлгә китерер.
Фараз кылыйк: Кеше, Галәм урап,
Җирне сагынып очып кайтты, ди...

Мефистофель хыялы.

К е ш е

Саумы сез, кешеләр?!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Беркем юк.
Кайда сез?!
Ау-у! Әни! Әти! Бабам! Балалар!
Кайда сез, кешеләр?!

Тавышы кайтаваз булып кире кайта. Алда Р о б о т пәйда була.

Р о б о т

Кешеләр? Ха-ха-ха!
Эзләмә! Тапмассың! Юк алар!
Җирдә мин... Мин торам!

К е ш е

Кем соң син?

Р о б о т

Мин — кеше иҗаты! Адәмнең акылы.

К е ш е

Балалар, оныклар соң... кая киттеләр?

Р о б о т

Кешеләр? Һәммәсе кырылып беттеләр.
Богаулар, чылбырлар чылбырга бәйләнде,
Кешенең акылы тимергә әйләнде.
Акылын алдым да акылдан шаштым мин,

Шаштым да автомат төймәгә бастым мин.
Коточкыч шартлаудан тетрәде бөтен җир.
Бер мизгел. Һәлакәт. Хәрабә. Төтен. Җил.
Кит, Кеше өрәге, кабереңә яшерен.
Юк инде бу җирдә туганың, нәселең!

Кеше

Җир бәгърем, нишләдең? Мәгънәсез,
Куркыныч — Кешедән башка син!..
(*Караңгылыкта югалалар.*)

Мефистофель

Юк файда, юк өмет
Киләчәк көтүдән...
Син ардың, дускаем,
Кит гамьнән, кит уйдан.
Мәзәкчеләр!

Ике мәзәкче кереп, икесе ике якка басалар.

Беренче мәзәкче

Җир балалары, Җир шары белән уйный торгач, аны шартлаталар. Хәрабәләре Кариус планетасына килеп төшә. «Җир, кулларыңны күтәр! Бирел!» — дип кычкыра Кариус. «Кулларымны күтәрә алмыйм, сындырдым...» — дип җавап бирә мескен Җир-ана, ыңгырашып.

Икенче мәзәкче

Ахырзаман алдыннан Алла, түземе бетеп, Җир балаларын, гөнаһлары өчен, тәмуг утында яндырырга уйлаган, ди. Бөтен ягулыгын ягып бетергән,— адәмнәр һаман янмыйлар, ди. Караса: тегеләр тимергә әйләнеп беткән, ди, имеш... Ха-ха-ха!

Мефистофель

Оныт күрәчәкне, узганыңны,
Гел хисләрдә яшә, уйлама...
Шагыйранә бер төн бүләк итәм:
Йә, рәхим ит минем дөньяма!

Кул хәрәкәте ясауга, төрмә стенасы ачылып китә. Алда — искиткеч гүзәл айлы-йолдызлы күк манзарасы.

Ш а г ы й р ь (*Хәйран калып.*)

Һава! Хөрлек! Иркенлек!

## ИКЕНЧЕ АКТ

М е ф и с т о ф е л ь һәм Ш а г ы й р ь.

М е ф и с т о ф е л ь

Монда юк — богаулар,
Бәлаләр-казалар,
Монда юк — авыр уй,
Гамь, хәсрәт, җәзалар.
Син — шагыйрь, син — иркә
Табигать баласы.
Рәхәтлек илендә
Мәңгегә каласы.

Ш а г ы й р ь

Мин яраткан һава, күлләр, гөлләр,
Җанны иркәләүче тәм-исләр!..
Ерактагы таң йолдызы булып,
Төшләремә кергән тын кичләр!
Әллә нинди сихри көчләр мине
Сезгә, сезгә тартып китерде.
Карыйм әле, өзелеп карыйм әле
Беренче кат күргән шикелле.

М е ф и с т о ф е л ь

Җаныңа ни кирәк —
Алырсың һәммәсен.
Ачам мин гомереңнең
Киләчәк пәрдәсен.

Кул хәрәкәте: пәрдә ачыла. Йолдызлы төн. Серле-хыялый музыка. Өстәл өстендә — ризык, шәраб, җимеш... М ә з ә к ч е л ә р керә. Беренче мәзәкче үзенә таба очып килгән тәлинкәне тотып ала.

И к е н ч е м ә з ә к ч е

Әһә, таптым! Бир минем тәлинкәне!

Б е р е н ч е м ә з ә к ч е

Бирмим! Минеке!

Икенче мәзәкче

Минеке!

Беренче мәзәкче

Кем син?

Икенче мәзәкче

Мин — Кариус планетасының мәзәкчесе. Орион планетасындагы дустым белән тәлинкә очырып уйнаганда, тәлинкәм ялгыш Җиргә очып китте.

Беренче мәзәкче

Ә без квартирда хатын белән талашып киттек.

Икенче мәзәкче

Нәрсә ул «хатын», нәрсә ул «талашу»,
нәрсә ул «квартир»?

Беренче мәзәкче

Соңга калып кайткан өчен, хатын миңа тәлинкәне шундый көч-нәфрәт белән ыргытты ки — тәлинкә, Җирнең тарту көченнән ычкынып, йолдызларга очты. Бир миңа тәлинкәне, ул миңа хатынга кире ыргыту өчен, әгәр ачуы басылса, алдында тәлинкә тоту өчен кирәк! (*Тәлинкәне тартып ала.*)

Икенче мәзәкче

Ул миңа уйнарга кирәк!
(*Тарткалаша-тарткалаша чыгалар.*)

Мефистофель

Син юмор сөясең,
Ахрысы, ошаттың —
Ниһаять, елмайдың,
Афәрин, бик шатмын!
Мә көзге, тузгыган
Чәчеңне ал тарап,
Елмаю, шатлыклар —
Алдарак, алдарак... (*Бокал күтәреп.*)
Шигъри төн өчен!

Ш а г ы й р ь

Туар көн өчен!

Сихри моңга тирбәлеп бии-бии, т ө н  к ы з л а р ы керә. Уртада — К ы з. Аның җырына башкалар кушыла.

К ы з  җ ы р ы

Син кал, Шагыйрь, безнең янда,
Оныт дөнья михнәтләрен.
Татып кал кыска гомернең
Ләззәтләрен, хикмәтләрен.
Син кал, шагыйрь, безнең янда,
Яшәрерсең шул чагында,
Йом күзеңне, иркәлән син
Назлы моңнар кочагында...

Ш а г ы й р ь

Шул! Ак чәчәк тоткан кыз!

К ы з

Син кал, Шагыйрь, безнең янда...

Шагыйрьгә якынлашып, нәзакәтле хәрәкәтләр белән, Кыз аны биергә чакыра. Шагыйрь, рәхәтлектән исереп, биергә тартыла.

Ш а г ы й р ь

Әйтче, гүзәл, син кем?

К ы з

Гади бер кыз.

Ш а г ы й р ь

Тәрәзәдән сине күрә идем...
Кемне көттең шулай өзелеп?

К ы з

Йөрәгемдә калсын сер булып...

Ш а г ы й р ь

Ул килдеме?

К ы з

Юк шул... килмәде...

Ш а г ы й р ь

Бәхетле җан... аны көтәләр...
Ник килмәде икән?

К ы з

Бәлки, ул килергә теләсә дә,
Килә алмагандыр...

Ш а г ы й р ь

Килсә, ул егетне ни көтә?

К ы з

Ул килсәме?
Дөньядагы иң зур бүләк көтә.

Ш а г ы й р ь

Нинди бүләк? Әйтче, йөрәк көтә...

К ы з

Ул кыз аңа яшәү бүләк итә!

Ш а г ы й р ь

Син үзең дә яшәү кебек гүзәл!

М е ф и с т о ф е л ь күренә. Кул хәрәкәте: биюле-җырлы гүзәллек өзелә.

К ы з т а в ы ш ы

Мин сине көтәрмен!..

Ш а г ы й р ь

(*Кыз артыннан омтылып, Мефистофельгә.*)
Сорыйм синнән: тагын бер минут...

М е ф и с т о ф е л ь

Очрашырсың ныграк сагынгач.
Узган төндә төш күрдеңме? Сөйлә...

Шагыйрь

Иңнәремә кунды сандугач.

Мефистофель

(*Кул хәрәкәте белән чакыра.*
*Мәзәкчеләр, кереп, табынга утыралар.*)

Сандугачлар күргән төшендә...

Беренче мәзәкче

Бер патша иртә таң белән уяна да үзенең вәзирен чакырып ала: «Төшемдә ике җилкәмә ике сандугач килеп кунды, ни көтә мине, юра»,— ди. Вәзир әйтә: «Кызганыч, синең ике улың да үзеңнән иртәрәк үләрләр»,— ди. Ачуы килгән патша вәзирнең башын кисәргә боера.

Икенче мәзәкче

Патша икенче вәзирен чакыра: «Төшемдә ике җилкәмә ике сандугач килеп кунды, юра»,— ди. Вәзир әйтә: «Ике улыңнан да озаграк яшәрсең»,— ди. Кәефе килгән патша, бу вәзирен бүләкли. (*Мәзәкчеләр югала.*)

Шагыйрь

Мефистофель, тизрәк очраштыр...

Мефистофель

Егет хәлен аңлыйм, төшенәм,
Гашыйк чакны искә төшерәм.

Җиңел музыка. Якында гына Кыз җыры ишетелә.

Шагыйрь

Ул?

Мефистофель

Ул... сине көтә! (*Хәйләкәр елмаеп чыга.*)

Кыз җыры

Таң җилләре чәчләремне
Уйнап сүтәләр,
Тын дулкыннар йөрәгемне

Назлап үтәләр.
Уйларымны белгән сыман,
Җилләр исәләр,
Алар минем җилкәнемне
Сиңа илтәләр.
Таң җилләре алдан барып
Җаның иркәләр,
Өзелеп сөю сәламнәрен
Хәбәр итәрләр.
Серле көчләр җилкәнемне
Сиңа илтәләр,
Төнбоеклар сөенечле
Таңны көтәләр.
Җылы нурлар төнбоекның
Яшен сөртәләр,
Сөю бәхетенә тусын
Таңнар-иртәләр... *

Шагыйрь алдында ак каен һәм Кыз пәйда була.

Шагыйрь

Таң кызы!..

Кыз

Төн егете...
(*Таралып төшкән толымнарын таң нурында үрә.*)

Шагыйрь

Син нинди гүзәл!

Кыз

Син нинди шагыйранә!

Шагыйрь

Карап торам сиңа еракларда
Калган зәңгәр таңым аткандай,
Яшьлегемдә өзелеп гашыйк булган
Сөйгән ярым кире кайткандай.

---

* М.Яруллин музыкасы.

К ы з

Тәүге җырындагы Таң кызы мин...
Гөлләр, күлләр дә шул, таң да шул,
Сөю-сөелү, гамьсез яшьлек өчен
Яратылган иркә җан да шул...

Ш а г ы й р ь

Таңым минем...

К ы з

Җаным минем...

Ш а г ы й р ь

Аһ, кулларың аккош канатыдай,
Карашыңда сөйкем-наз гына.

К ы з

Оныт дөнья зарын, кайгыларын...

Ш а г ы й р ь

Тик беразга гына, аз гына,
Карыйм әле күзем талганчы...
Таңнар атып, бар йолдызлар сүнеп,
Җирдә тик син генә калганчы...

К ы з (*Чәчләрен үреп.*)

Син яраткан көмеш чәчләремне
Синең өчен генә үрәмдер...

Ш а г ы й р ь

Карыйм әле күзем талганчы,
Бәлки, соңгы тапкыр күрәмдер...

Сәгать суга. Дәһшәтле аяк тавышлары.

К ы з (*Шагыйрьне кочаклап.*)

Юк... юк...
Сине беркем миннән аера алмас,
Әҗәл атлый алмас адым да...
Ул чигенер минем сиңа булган
Кайнар мәхәббәтем алдында.
(*Аяк тавышлары тына. Күкрәкләрен ачып.*)

Сөясеңме мине?

Шагыйрь

Син — гүзәл!

Кыз (*Үбеп.*)

Сөясеңме мине?

Шагыйрь

Син — сылу...

Кыз

Сөясеңме мине, шигъри күңел?

Шагыйрь

Матурлыкны сөйми мөмкин түгел!

Кыз

Сөюләрең әгәр ихлас булса,
Син кал бездә...

«Син кал бездә» җырын кызлар хоры күтәреп ала. Кинәт Мефистофель күренә. Җыр тына. Кыз югала.

Шагыйрь

Тукта, китмә!

Мефистофель

Вакыт ашыктыра!

Шагыйрь

Туктат сәгатьне!

Мефистофель

Туктатырга вакыт-сәгатьне
Син бары тик үзең сәләтле.

Шагыйрь

Табигатькә, таңга гашыйк җанның
Хакы юкмы әллә яшәргә?

Мефистофель

Хакы бар!

Шагыйрь

Җирдә һәр хәшәрәт
Теләгәнчә яши, һава сулый.
Гүзәллекне сөйгән иркә җанның
Таң нурларын каршы алырга
Хакы юкмы?!

Мефистофель

Хакы бар!

Шагыйрь

Әйтче, әйт, акыл?
Акыл — каршы!

Мефистофель

Ә йөрәгең?

Шагыйрь

«Хакың бар!» дип тибә! Хакым бар!

Мефистофель

Икенең берсен сайла!

Шагыйрь

Мин... калам... (*Көчсезләнеп каенга тотына.*)

Мефистофель (*Тантана итеп.*)

Сөенеч, шатлыкка
Әзер бул син тагын,
Көт, дустым, әзерлим
Күңелле зур табын... (*Югала.*)

Шагыйрь

Юк, юк, артык түзә алмыйм... Калам,
Калам Мефистофель иләндә,

Яшьлегемнең кадерләрен белеп,
Бик яшисем килә минем дә. (*Егыла.*)
Нигә табигатем кабул итми
Мондый сәер гамьсез тынлыкны?
Бу ни бу? Җанымда җыр сүнә, моң тына...
Таң йолдызы — сөйгән ярым төсле...
Чал болытлар әнкәм чәче төсле...
(*Сикереп тора.*)

Мефистофель (*Керә.*)

Берәр шигең бармы әллә?

Шагыйрь

Ул ни яна шундый шомлы булып,
Җирне ялкын-төтен чорнаган?

Мефистофель

Син яраткан алсу шәфәкъ төсе.

Шагыйрь

Юк... Мичтә яндырылган иптәшләрем
Төтен булып чыга торбадан!
Җир астыннан тавыш-өн килә?..

Мефистофель

«Хур кызлары» анда гөр килә.

Шагыйрь

Юк... Шулай үзәк өзгеч тавыш белән
Терелләй күмелгәннәр җан бирә.
Үз илемдә — кан-яшь... Мин — рәхәттә...
Илем, әнкәм, ярым, дусларым...

Мефистофель

Алар барысы сиңа нәләт укый:
Дус-ишләрең, анаң, сөйгән ярың...
Юл өзелгән сиңа илеңә таба...
Анда кайтсаң — төрмә, үз тираның:
Карар әзер — үлем җәзасы!
Тиранда да, илеңдә дә — үлем!

Ә мин сине ике үлемнән дә
Йолып калып, рәхәт гомер бирәм.
Җаның нәрсә тели, сора, дустым...
Ни кирәк тагын да? (*Үзалдына.*)
Соңыннан соң булыр, сорап кал
Җаның бар чагында.

Шагыйрь

Мине алар белән очраштыр...

Мефистофель

Йә, күр, кара, алар синең алда...

Кул хәрәкәте: Шагыйрьнең сөйгәне пәйда була.

Шагыйрь (*Омтылып.*)

Кадерлем!

Шагыйрьнең сөйгәне

Синең белән йөргән иртә-кичләр,
Сиңа дип саклаган иркә хисләр,
Сине өзелеп сөю-яратулар,
Исемеңне ядлап таң атулар,
Күзләремә тутырып карауларың,
Кәккүк кычкыруын санауларың,
«Көт, кайтырмын!» диеп китүләрең,
Йөрәгемдә сине йөртүләрем,
Синең белән тәүге үбешкән төн,
Синең белән соңгы күрешкән көн...—
Хәрам булсын! Хәрам!

Шагыйрь

Юк, ышанма, бәгърем, юк, ышанма!

Мефистофель

Дусларың да сине көтми хәзер...

Шагыйрь

Дуслар аңлар мине!

Хәрби киемдә Шагыйрьнең дусты күренә.

Дустым!

Мефистофель

Бу кешене син дустың дип таныйсыңмы?

Беренче дус

Минем якын дустым Шагыйрь иде.
Бу — ул түгел!

Шагыйрь

Исеңә төшер, яшьтәш, бу — мин... бу — мин!
Хәтерендәме: бергә антлар бирдек...

Беренче дус

Барлык дусларым да яу кырында,
Хыянәтче безнең арада
Битлек киеп кенә йөргән икән,—
Рәхим-шәфкать булмас аңарга!
Нәләт! Нәләт!

Шагыйрь

Ышан: мин хыянәт итмәдем!

Беренче дус

Нәләт! Нәләт! Нәләт! (*Югала.*)

Мефистофель

Икенче бер дустың...
(*Тоткын киемендә Икенче дус күренә.*)

Шагыйрь

Каләмдәшем?!
Ялгышаммы?
Син дә тоткында?!

Икенче дус

Ышанмыйлар... Яуга җибәрмиләр —
Янар идем сугыш утында...
Барлык күргән газапларың белән

Бездән бәхетлерәк син анда.
Ә мин үз илемдә, «дошман» булып,
Бер гаепсез утырам зинданда...

Мефистофель

Соңгы ышанычың — газиз әнкәң...

«Бишек җыры»н көйләп, Ана пәйда була.

Ана

Йокла, балам, күз нурым,
Кояш батты, төн булыр,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Йөрәк парәм кем булыр?

Шагыйрь

Әнкәй!

Ана

Туган җирнең гамен,
Күкрәк сөтемнең тәмен,
Яшел чирәмнәрдән атлап киткән көнен,
Һәрнәрсәдән изге туган телен,
Моңнар, җырлар биргән туган өен,
Кәккүкләрнең аваз-тавышларын,
Ятимнәрнең кайгы-сагышларын,
Җирнең ыңгырашып зар елавын,
Көчсезләрнең шәфкать соравын,
Яраларның сызлау-әрнүләрен,
Сабыйларның күз-яшь түгүләрен,
Аналарның өмет итүләрен,
Кайтырмы дип, һәр көн көтүләрен,
Яуга киткән чакта биргән антын,
Ил баласы дигән изге атын
　　онытса ул әгәр —
　　мәңге бәхиллегем юк!

Шагыйрь (*Куллары белән башын тотып.*)

Әнкәм, ышан... Юк, юк, онытмадым,
Тап төшермәм изге антыма!

Мефистофель

Илдә — нәләт, ана каргышы.
Син әйләнеп кара артыңа —
Гильотина!

Шагыйрь

Әнкәм минем, рәхмәт хисе беләң
Син рөхсәт ит рухың кочарга.
Сау-бәхил бул, әнкәм, гомерем буе,
Мин тырыштым сиңа охшарга.

Ана тавышы

Мәңге бәхиллегем юк! (*Шагыйрь чигенә.*)

Мефистофель

Менә шулай хәлләр. Дөньяның бар
Үзгәрмәслек катгый кануны,
Телисеңме, теләмисеңме —
Мәҗбүр итә берчак тануны:
Язмыштан — узмыш юк!
Бер юл да юк бүтән.

Шагыйрь

О, явыз җан, син хаклыдыр, бәлки..

Мефистофель

Котылгысыз финал.

Шагыйрь

Бер минут бир миңа уйланырга...

Мефистофель

Бары бер минут! (*Югала.*)

Шагыйрь тирән уйда. Кыз керә.

Кыз

Баш тарта илең дә,
Анаң да, ярың да...
Барсын да онытырсың,

Кал минем янымда.
(*Иркәләмәкче булып.*)
Кадерлем, бер генәм, өметем...

Шагыйрь

Кит! Югал!

Кыз

Кума мине, Шагыйрь...

Шагыйрь

Күз алдымнан югал!

Кыз

Баш тартсаң иманың
Һәм туган илеңнән,
Котылып калырсың
Рәхимсез үлемнән.
Яшь килеш үлгәнче,
Йөз яшә — кил аңга...
Шарты да бик җиңел —
Ярдәм ит Тиранга!

Шагыйрь

Таларга, ватарга,
Атарга, асарга,
Җир шарын хәрабә,
Каберлек ясарга?
Ирексез итәргә
Көчсез һәр адәмне?
Тиранга ярдәмме?
Тиранга ярдәмме?!
Мең нәләт — назыңа
Бирелгән мизгелгә!
Мең нәләт — йөзеңә!
Мең нәләт — үземә!
Син — елан!

Кыз

Юк!

Шагыйрь

Акчага сатылган кол-бәндә!
Һәрбер сүзең синең, хәрәкәтең
Хуҗаң теләгенә буйсынган... Сөйрәлчек!

Кыз

(*Шагыйрьнең аяк астына ташланып, аның тезләрен кочаклап елый.*)
Сафлыгың алдында баш иям!
Сине исән калдырырга теләп,
Мин эләктем иблис ятьмәсенә.
Хуҗам боерыгы үтәлмәсә...

Шагыйрь

Сине ни көтә?

Кыз

Мин — мәңгелек кол!

Шагыйрь (*Аны күтәреп торгыза.*)

Бәхетсез кол-бәндә...
Син нинди түбәндә, түбәндә.
Тор, сеңелем, күтәрел,
Күтәрел, Кеше бул!
Хуҗаңа әйт: Тиран килсен. Мин әзер.

Кыз (*Сөенеп.*)

Син азат, котылдың үлемнән?!

Шагыйрь

Мин барам үлемгә!

Кыз

Юк! Юк!

Шагыйрь

Синең кебек күпләр — бәхетсезләр —
Ирек, Бәхет таңын көтәдер.
Кеше булу гына җитми әле,

Көрәшче бул, сеңелем, күтәрел!
Бәхил бул...

К ы з

Мәңгелек кол булып яшәгәнче,
Үлем артык... Мин дә синең белән!
(*Муенындагы җәүһәрләрне салып ыргыта.*)

Ш а г ы й р ь

Син кал Җирдә моңсу җырым булып.
Тик син шаһит, тик син генә күрдең
Гомеремнең соңгы сәгатен...

К ы з

Бармы васыятең-аманәтең?

Ш а г ы й р ь

Җаныма иң соңгы
Җырымны яшердем.
Ул сүнсә — мин сүнәм,
Яшәсә — мин яшим.
Әгәр ул мондагы
Дусларым аркылы
Илемә, Анама,
Ярыма ирешсә —
Бәхет дип санармын
Гомеремнең азагын.
Көләрмен үлемнән.
Туймам җан газабын.
Мин сиңа ышанам.
Менә ул җыр:

Тор, күтәрел, Кеше!
Түбәнлектән, коллык, хурлыктан
Син менәргә тиеш үрләргә!
Тор, күтәрел, Кеше!
Туганнарча, кулга-кул тотышып,
«Азатлык!» дип, төрле телләрдә!
Тор, күтәрел, Кеше!

К ы з (*Кабатлап.*)

Тыныч бул, кадерлем!
Сүзеңне аклармын,
Йөрәгем түрендә
Җырыңны саклармын,—
Дусларга илткәнче.
Бәхил бул мәңгегә,
Беренче һәм соңгы
Мәхәббәт, бәхил бул!.. (*Шагыйрьгә ташланып, кочаклап үбә дә чыгып йөгерә.*)

Ш а г ы й р ь

Бәхил бул мәңгегә,
Өметем һәм таңым...
Мефистофель!

М е ф и с т о ф е л ь пәйда була.

Мин мәңгелектә калырга карар иттем!
(*Хәзер ул язмышын хәл иткән, шуңлыктан — тыныч.*)

М е ф и с т о ф е л ь

Котлыйм! Афәрин!

Ш а г ы й р ь

Елмаясым килә, көләсем!

М е ф и с т о ф е л ь

Андый чакта юмор — табигый хәл —
Үзең беләсең.

Кул күтәрүгә, и к е м ә з ә к ч е керә.

Иң озын гомерле шагыйрьнең
Елмаясы килә, шаяннар!

Ш а г ы й р ь

Бу юлы мин сезгә үзем мәзәк сөйләргә булдым.
Хуҗа Насретдинның актык сүзен беләсезме?

Мәзәкчеләр

Юк! Белмибез!

Шагыйрь

Җәлладлар Хуҗаны сөйрәп асарга алып килгәннәр.
— Актык сүзеңне әйтеп кал,— дигән хан.
— Актык сүзем юк, бик кечкенә үтенечем бар.
— Нинди үтенеч? — дигән хан.
— Муеныма кагылсалар, кытыгым килә, билемнән ассыннар,— дигән Хуҗа.

Бу юлы мәзәкчеләр чынлап көләләр. Кинәт сәгать суга.

Мин әзер, Мефистофель!

Мефистофель

Үз урыныңа!

Шагыйрь зиндан булган урынга килә.

Шәт, аңладың булыр...
Дөнья — төрмә. Кеше шул төрмәгә
Мәңге богауланып куелган.
Маңгаена — акыл тирәсенә:
«Син — кол» дигән сүзләр уелган.
Җан иясе һава сулау өчен
Җиргә яратылган. Ирекка
Ул омтылып карый, нәтиҗәдә,
Килеп керә тимер читлеккә.

Кул хәрәкәте: Шагыйрь дүрт дивар эчендә кала.

Ә ирекне, ай-һай, сөясең син...
Дөнья — дүрт капкалы. Шартлатып,
Өч капкасын ябып куйсалар да,
Берсе ачык кала — аңла тик!

Кул селтәү белән, алдагы стена ачыла.

Язмышыңны үзең хәл ит хәзер.

Шомлы аяк тавышлары. Сәгать алтыны сукканда, Баш җәллад һәм ике сакчы уртасында Тиран керә.

Тиран

Мефистофель?

Мефистофель

Нәкъ сөйләшкәнчә!

Тиран

Ул...

Мефистофель

Синеке!

Баш җәллад

Гильотина әзер, хуҗам! (*Җиңнәрен сызгана.*)

Тиран (*Ачу белән.*)

Узынма! (*Мефистофельгә.*)
Җәза урынына...

Мефистофель

Тантана!

Тиран

Хуҗа бүген бөек сәясәттә
Борылыш ясый: артка чигенә?
Артка чигенә дә алга китә?

Мефистофель

Тәмамланды минем миссиям.
Хәзер үзең дәвам ит.
Кирәк була калсам — мин әзер! (*Югала.*)

Тиран (*Шагыйрь алдына килеп, хөрмәтләп.*)

Җирнең иң атаклы Шагыйренә
Хөрмәт һәм ихтирам!
Шәраб! Шагыйрьгә дә!

Ш а г ы й р ь

Нидән әле һич тә көтмәгәндә
Лаек булдым шундый хөрмәткә?

Т и р а н

Бездән бик зур хата китә язган.
Тарих үзгәргәндә корбаннарсыз
Мөмкин түгел һич тә... беләсез.
Гаепсез дә кайчак кереп китә
Дөнья куласасы астына.

Ш а г ы й р ь

Мең-миллионнар... Бик кечкенә ялгыш!

Т и р а н

Мин бит тарих ясыйм. Ә тарих ул —
Адәмнәрдән көчле!

Ш а г ы й р ь

Ә мин уйлыйм: бөек ул тарихны
Халык иҗат итә.

Т и р а н

Зур хата.
Ялгыш шул фикергә инанганнар
Җир астында ята. (*Чәкәшеп.*)
Шагыйрь хөрмәтенә! Җиңү өчен!

Ш а г ы й р ь

Җиңүебез өчен! (*Эчмичә касәне кире бирә.*)

Т и р а н

Ярый әле Сезне вакытында
Тартып алдым.
Соң әйттеләр сезнең мәшһүрлекне.

Ш а г ы й р ь (*Ирония белән.*)

Мин бурычлы!

Тиран

Шундый тонда сөйләшүләр ошый.
Башла миссияңне!

Шагыйрь

Мин әзер!

Тиран

Барча тоткын минем якка чыксын!
Барысы — Туган илен онытсын!
Барысы — кулларына корал тотсын!
Минем солдат булып сугышсын!

Шагыйрь

Тоткыннарны җый!

Тиран

Тоткыннарны җыярга! Коралландырырга!
Кил, Шагыйрем, син — ирекле хәзер.
Минем коллар синең сүзне көтә!

Шагыйрь зинданнан чыгып, Тиран янына килә. Тиранның бер ягында — Баш җәллад, икенче ягында — Шагыйрь. Шау-шу.

Үрә кат! Тыңла!
Сезгә мәгълүм — тоткындагы Шагыйрь
Минем якка чыкты!
Аның сезгә әйтер сүзе бар!
(*Тавышлар: кычкыру, сызгыру.*)
Рәхим ит, Шагыйрем!

Шагыйрь

Дуслар! Туганнар! Илдәшләр!

Туган илнең тын бакчасын сөйдем,
Җир җиләген, каен, имәнен,
Һәр чәчәккә туктап башны идем,
Тик дошманга башны имәдем.
Лачын коштай күккә күтәрелдем,
Яраланып төштем түбәнгә.
Ләкин түбәнлеккә төшмәдем мин,

Күз алдыма үлем килгәндә...
(*Тиран, сискәнеп, сикереп тора.*)
Җирне юк итәргә хыялланган
Тираннарның уен өзәргә,—
Тор, күтәрел, Кеше!
Җирне ирекләләр яши торган
Бәхет йорты итеп төзәргә,
Тор, күтәрел, Кеше!
Күп газаплар күргән Җиребезне
Көл итмичә, гөлләр итәргә,—
Тор, күтәрел, Кеше!
Тираннардан азат булып, Җирдә
Хуҗа булып көннәр итәргә,—
Тор, күтәрел, Кеше!

Тиран

Гильотинага! Башын кисәргә!

**Мефистофель пәйда була. Җәлладлар Шагыйрьне җәзага алып китәләр. Шагыйрь тавышын ишетеп күтәрелгән коллар тавышы.**

Төрмә хуҗасы (*Керә.*)

Коллар — баш күтәрде! Кыямәт!

Тиран

Хыянәт!

Гаскәр башлыгы (*Керә.*)

Коралланган коллар... безгә каршы...

Тиран

Кем гаепле?!

Төрмә хуҗасы

Шагыйрь җыры!

Мефистофель

Шагыйрь җыры?!

Төрмә хуҗасы

Шагыйрь аны ниндидер бер кызга биргән һәм ул кулдан-кулга, колдан-колга күчкән.

Мефистофель

Анда — Шагыйрьнең җаны!

Тиран

Алдандык... (*Мефистофельгә.*) Син...

Мефистофель

Вакытлыча чигенү... Көрәш — алда!

Баш җәллад (*Керә.*)

Үлде.

Мефистофель

Әмма... җанын бирмәде.
(*Караңгылыкка китеп югала.*)

Шагыйрь тавышы

Җирдән китәм тугрылыклы хәлдә
Ил-анама биргән антыма,
Күкрәгемнән беркем ала алмас,
Мин җанымны бирәм халкыма!

*1968—1972*

# *Бәгырь*

*Трагедия*

Егерменче гасырның 30 нчы елларында булган хәлләр...

КАТНАШАЛАР:

Салих Сәйдәшев.
Кәрим Тинчурин.
Сәйяр.
Гөлнара.
Заһидә.
Яңа дус.
Төн кешеләре.

Композитор Салих Сәйдәшевнең иҗат бүлмәсе. Ул пианино янында утыра.

Салих

Комедия тәмам. Тамашачы
Кул чапты да китте йокларга.
Ә мин кайттым ялгыз, дускай, сине
Туган көнең белән котларга.
Гел-гел бергә төн үткәрә идек,
Үзең юк шул бүген янымда.
Беркем хәзер җөрьәт итә алмый
Исемеңне телгә алырга.
Син яшәгән урам тирәкләре
Кайтуыңны көтеп саргая.
Йөргән юлларыңда җилләр уйный.
Беркем белми... киттең син кая?
Сагынырга калды гомеремнең
Синең белән булган чакларын.
Юк итмәдем синең рәсемеңне:
Төсең итеп яшереп сакладым.

Пианино эченә яшерелгән рәсемне алып, алдына куя.

Туган көнең бүген — сүзең юк,
Көем көтә сине, үзең — юк.
Ник дәшмисең, Кәрим,

Йөрәгемнең
Әрнүләрен ничек тыярга?
Без икебез бер җыр, бер көй идек.
Мин тудырам сине хыялда.

Сагышлы бер көй агышында К ә р и м Т и н ч у р и н пәйда була. Ул әкрен генә килеп, Салихның уйнаганын тыңлап тора да кулларын аның җилкәсенә куя.

С а л и х (*Уйнаудан туктап.*) Кәрим!..

К ә р и м

Уйна, Салих, уйна, туктама.
Кара урман...
Кошлар сайравыннан
Күңелләргә җылы чык тама.
«Кара урман» көен уйныйсың син.
Булат җыры ничек?
Премьерага бик аз вакыт калды.

С а л и х

Урман шавын, качкыннарның җырын
Таба алмый газапланган чагым.

К ә р и м

Әллә сүзләр көйгә ятмыйлармы?

С а л и х

Бик шәп җырың, сүзең.
Булдыралмыйм үзем.

К ә р и м

Әйдә, киттек, Салих, карурманга,
Сүзнең көе шунда табылыр.

С а л и х

Соң бит инде.

К ә р и м

Качкыннарның өе — төнге урман.
Булат, ярын көтеп, шалаш корган...

С а л и х (*Көй эзләп.*)

Кара урман...

К ә р и м (*Пианинога күрсәтеп.*)
Алабызмы әллә моны да?

С ә й д ә ш
Калсын әйдә...

К ә р и м
Син — дирижер. Урман — оркестр.

С а л и х
Урман шавы —
Безгә алкыштыр.

**Манзара алышына. Төнге кара урман. С а л и х белән К ә р и м шалаш корганнар, учак якканнар.**

К ә р и м
Мин үземне ыгы-зыгылардан
Киткән качкын итеп хис итәм.

С а л и х
Ә мин кара урман эчләреннән
Булатларның көен ишетәм.
Кара урман...

К ә р и м
Сизәсеңме, төн серләрен сөйләп,
Әллә нинди сихри җил исте.

С а л и х
Кара пәрәнҗәсен капладымы,
Шомлы булып калды җир өсте.
Кара урман...

К ә р и м
Тыңлыйк әле кара урман шавын.
Алар ирек өчен ашкынган.
Җирне җылы зәңгәр шәлгә төреп,
Килеп чыгар кебек качкыннар.

С а л и х
Кара урман шаулый,
Ирек даулый...

Кәрим

Икебез дә булыйк хыялый.

Салих

Ирек сөйгән өйсез хыялыйлар
Карурманга килеп оялый.

Кәрим

Таң атканда туган яңа көең
Янар йөрәкләргә сыялмый.
Тоям: йөрәгеңә моң тула,
Мин теләгән ярсу җыр туа.
Җил дә тынды... тыныч таң ата.
Иҗат ялгызлыкны ярата.

Салихны ялгыз калдырып чыгып китә.

Салих

Кайчак ярсыйм, кайчак тынып калам,—
Табигатем минем — карурман.
Хәсрәтем дә, дәртле көйләрем дә
Синдә туган, синдә кабынган.
  Тормыш серләрен,
  Көйләрен таптым.
  Кара урманда
  Мин үзем качкын.

Көй туа, ул Күктән дә, Җирдән дә ишетелә сыман.

Сәйяр (*Керә.*)

Хәерле төн телим, Сәйдәш абый!

Салих

Хәерле төн телим сезгә дә.

Сәйяр

Сезне күрү иде минем хыял.

Салих

Сез кем? Нигә ялгыз урманда?

Сәйяр

Әнә шалаш. Сөйгән кызым анда.

Сөю бәхетеннән куанып без,
Карурманга килеп сыендык.
Монда икегезне бергә күргәч,
Шундый сөендек!
«Ә үзләрен бармы күргәнең?» дип,
Сорый танышларның барсы да.
Сез кабызган утка карап килсәк,—
Алда — Сәйдәш белән Тинчура!

Салих

Сез кем? Таныш булыйк, егетем?

Сәйяр

Сынчы Сәйяр. Сәнгать баскычыннан
Атлау иде хыял-өметем.
Рөхсәтегез булса, икегезнең
Сынын ясау иде ниятем.
Тагын икебезнең үтенеч...
Гөлнара!

Гөлнара керә.

Салих (*Алдында гүзәл кыз пәйда булгач, хәрәкәтсез кала.*)
Бишбалта?..

Гөлнара

Биш-алты... (*Елмая.*)

Сәйяр

Сез танышлар инде әллә?

Гөлнара

Әйе, мин гашыйкмын «Зәңгәр шәл»гә.

Салих

Нинди үтенечең, әйтеп кара.

Сәйяр

Балерина минем Гөлнарам.
Һәрбер чыгышына гел барам.

Гөлнара

Сезне бик тә хөрмәт итәбез.
Сездән яңа балет көтәбез.

Сәйяр

Бии балерина Гөлнара!
Сәйдәш балетына кем бара?

Салих

Белмим шул... Тинчурин ни әйтер?
Сез танышмы?

Сәйяр

Сәхнә аша таныш үзе дә,
Уендагы һәрбер сүзе дә.

Салих

Килә үзе дә.

Кәрим керә.

Таныш бул.
Ул да безнең кебек төн егете.

Сәйяр

Таң сәламе сезгә, мәшһүр остаз!

Салих

Төн үткәргән гүзәл кыз белән.

Кәрим

Сыз моннан!

Салих

Иҗат эше аның — син һәм мин.

Кәрим

Ычкын! Сыз моннан!

Салих

Аңламадым...

Сәйяр

Кичерегез, мин дә төшенмим.

Кәрим

Беләм анның «иҗат» эшен мин.
Бик күп күрдем андый бәндәләрне —
Йөри алар кызлар озатып.
Ә чынында, моның нияте бер:
Йөри сине, мине күзәтеп.
Бар, кит, энем... бул сау-сәламәт.
Теге-буга миннән сәлам әйт!

Гөлнара

Юк, юк, Сәйяр андый егет түгел!

Кәрим

Моңа кадәр ялгышмады күңел.

Сәйяр

Ялгышасыз, остаз:
Ниятем саф,
Мин бары тик сезгә баш июче,
Икегезне бер җан диюче.
Бер раслармын сезгә тугрылыкны,
Раслармын.

Гөлнара

Зинһар өчен, кичерегез безне...

Кәрим

Кичерермен әгәр ялгышсам.

Яшьләр китәләр.

Салих (*Гөлнараның артыннан карап кала.*)

Бәхетле бул, гүзәл... (*Кәримгә.*)
Ни өчендер кәефең юк, сизәм.

Кәрим

Мин төш күрдем. Имеш, якты төндә
Зәңгәр күк астында йөрибез.

Салих

Бик матур төш. Хәерлегә булыр.
Әйдә — юрыйбыз.

Кәрим

Берәү дә юк. Бар да изрәп йоклый.
Син дә мин һәм тулган Ай гына,
Табигатьне тыныч дәртләндереп,
Синең көең агыла җай гына.
Йолдызларга карап барган чакта,
Караңгылык басты Җир йөзен.
Давыл купты.
Бар йолдызлар сүнде.
Аерылып калдым берүзем.
Кулларыңны эзлим тотынырга.
Әллә кая барам... ычкынам.
Телсез калган, шашкан адәм кебек:
«Сәйдәш! Сәйдәш!» — диеп кычкырам.
Ә син ишетмисең, сине миннән
Көчләп аерганнар икән ич,
Янар йолдызларны сүндерергә
Ил йөзенә Дәҗҗал* килгән ич.

Салих

«Зар» дип исемләнгән әсәреңне
Төштә булса да син куйгансың.
Премьераң, бәгырь, котлы булсын,
Инде тамашачы уйлансын.
Әйдә, аерылмаска без ант бирик.

Кәрим

Әйдә, ике җанны бер итик!

Салих

Безне аерырлык көч юк, булмас!
Антыбызны
Яңа көем белән беркетик! (*Җыр башлый, Кәрим сөенеп кушыла.*)
Кара урман шаулый, ирек даулый,

---

* Дәҗҗал — К.Тинчуринның 1924 елда басылган «Зар» исемле шигъри трагедиясе каһарманы.

Ирек даулый качкын егетләргә.
Кара урман төсле шаулый-шаулый
Дошманнарның көнен төн итәргә.
Кара урман шаулый,
Йөрәкләр ярсый
Тоткын җәнлектәй,
Кара урман шаулый,
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный,
Кайда син, бибкәй?

Дирижер таягы тоткан Сәйдәш күренә. «Зәңгәр шәл»дән оркестрның соңгы аккордлары, «Афәрин! Авторны!», «Режиссерны!» дигән авазлар, көчле кул чабулар ишетелә. Кәрим Тинчурин сәхнәгә күтәрелеп баш ия. Кул хәрәкәте белән алкышларны туктата.

Кәрим

Композитор-дирижерны
Күрмисезме әллә сез?
Бу әсәрем тумас иде
Салих дустым Сәйдәшсез.
Бар күңелләрне балкыта
Сәйдәш көенең нуры.
Без — бербөтен,
«Зәңгәр шәл»нең
Ул — икенче авторы.
Сәйдәшебез театрга
Табигать бүләгедер.
Драматург, аңы булса,
Аһәңсаз — йөрәгедер.
Сәйдәш яңа чорыбызның
Моңын һәм көен тапты.
Театрны тамашачы
Җанына якынайтты.
Ялгышмаганмын Салихны
Чакырып Ырынбурдан,
Мин бәхетле: «Дус булыйк!» — дип,
Талантлы кулын биргән...

«Тинчурин — Сәйдәш!», «Сәйдәш — Тинчурин!» дигән тавышлар. Салих сәхнәгә менә. Бер-берсен премьера белән котлап кочаклашалар. Бүлмәдә Кәрим, Салих һәм Заһидә. Таң аткан.

Заһидә

«Зәңгәр шәл»гә киләчәктә

Бик озын гомер телим,
Әсәрне үзем язгандай —
Күкләрдә очып йөрим.

К ә р и м

Бу бәхет булмас вакытлы...
Шатлыклар әле алда.

З а һ и д ә

Ярты сәгать алкышлады
Тамашачылар залда.

К ә р и м

Көйдән башка — мин көчсез.

С а л и х

Сүздән башка — мин көчсез.

З а һ и д ә

Сүз белән көйне кушканда —
Баһадир икән ич сез!

К ә р и м

Миндә илһам ташып тора!

С а л и х

Минем дә шундый чагым.
Синең дәртле сүзләреңне
Мин көтеп торам, бәгырь.

З а һ и д ә

Күңелдә — Мәйсәрә җыры,
Күздә — шатлык яшьләре.

К ә р и м

Бүләгебез сиңа булсын...

С а л и х

Премьера ядкәре.

Ө ч е с е   б е р г ә

Зәңгәр шәл! (*Кәрим Заһидәнең иңенә зәңгәр шәл сала.*)

З а һ и д ә

Мин дә бер җырлармын әле:
«Үткән гомерем җәл түгел».
Сезнең сүз, көйләр яшәсә,
Гел янармын, сүрелмәм!

К ә р и м (*Шәраблы бокал тотып.*)

Премьера котлы булсын!

С а л и х

«Зәңгәр шәл» котлы булсын!

З а һ и д ә

Ике талант, ике йөрәк
Гел янар утлы булсын!

Салих үз бүлмәсендә ялгызы. Пианинода уйный. Күрәзәле хыялы дәвам итә.

С а л и х

Сүзең белән күңелләрне нурлап,
Йөз, меңнәрне үзеңә караттың,
Беркем әйтми хәзер исемеңне,
Кинәт йотты сине кара төн.
Дус-ишләр дә барысы телен йоткан,—
«Ул кайда?» дип сорыйм кемнәрдән?
Эзлим бергә йөргән урамнардан,
Сине алып киткән төннәрдән.
Туган көнең белән котлыйм диеп,
Тәрәзәдә шәүләң эзләдем,
Черек күлгә килдем башым иеп,
Мондадыр дип, бәлки, эзләрең.
Хыялымда — исән, төшкә керә.
Хәерлегә булсын дип юрыйм.
Әйтегезче, төрмә диварлары! —
Исән-саумы Кәрим Тинчурин?
Күпләр хәзер монда — тоткынлыкта:
Иҗаттагы дус-иш, танышым...
Дивар аша тоям, ишетәм сыман
Кәримнең саф, тансык тавышын.

Күз алдында тоткыннар киемендә К ә р и м һәм б а ш к а л а р пәйда була.

Тоткыннар хоры

Булат, Булат кайткан,
Бүләк алып кайткан,
Сабан җилен каян,
Каян сизгән, наян!

Барысы да

Зәңгәр шәл!

Булат

Анда юк урак, анда юк сабан.
Анда икмәкне алалар сатып,
Эшчеләр санын, номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда.

Салих

Кем син? Булатмы? Кәримме?
Таный алмыйм.
Бик күпләр сез... берәү, икәү...
Саный алмыйм.

Кәрим-Булат

Бер бүлмәдә — йөзләп тоткын,
Сыеп булмый.
Бу җыр катгый тыелса да,
Тыеп булмый!

Салих

Кайда син, бәгырь?

Кәрим

Монда юк уен, монда юк сәхнә.
Салкын бүлмәдә тоталар ябып.
Тоткыннар санын, номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар монда.

Салих

Нигә син анда?
Нигә мин монда?

Кәрим

Зәңгәр шәлгә кара яктылар.
Гаепсезгә монда яптылар.

Салихның дүрт ягында кара пәрдә — дүрт дивар пәйда була.

Заһидә (*Кара пәрдә алдында.*)
Очып кына узган киек казлар,
Әйтсәгез лә Булатымның
Абау, дуслар, хәлләрен.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл.

Салих
Заһидә, саумы?

Заһидә
Килмә якын...

Салих
Мин дә сизәм: Кәрим якын бик.

Заһидә
Килмә янга, Салих.

Салих
Нидән шул кадәре салкынлык?

Заһидә
Кая гына барсам — караңгы йөз.
«Баш тарт аннан, дошман ул»,— диләр.
Эштән чыгардылар,
Өйдән кудылар.
Төсе булып зәңгәр шәле калды,—
Авыр чакта шуны кочам мин,
Нинди генә гаеп таксалар да,
Ышанмыйм.
Син кит, Салих...

Салих
Әллә инде миннән шикләнәсең,
Баш тарткан дип якын дусыннан.
Җырларыбыз гына түгел,— аңла:
Җаннарыбыз бергә кушылган.
Әйдә, киттек безгә...

Заһидә
Рәхмәт, Салих!

Сиңа ышанам мин.
Әмма килмә янга, үтенәм!
Очрашканда, миңа сәлам бирмә,
Белмәгәнгә салынып үт кенә.
Үзеңне дә дошман итәрләр,
Әнә шунда алып китәрләр.
Хуш, исән бул,
Салих, син кирәксең,
Сирәгәя бара сафлар да.
Син дә юкка чыксаң, өмет сүнәр,
Ә өметне кирәк сакларга.
Хуш, исән бул, Салих... (*Караңгыда югала.*)

Салих

Тукта, китмә, Заһидә...

Манзара алышына. Шомлы музыка. Кемнәрдер кулларына факеллар тотып, ут төртеп йөриләр. Ут яктысында пианино янындагы Сәйдәш күренеп кала. Шау-шу тына. Бер читтәрәк учак уты гына торып кала. Анда кемнеңдер шәүләсе шәйләнә.

Эчтә яна шомлы утлар.
Кемгә сөйлим хәлемне?
Ялгызы... учак янында
Кем ул? Әллә Кәримме? (*Утка таба атлый.*)
Ул, бәлки, дустын көтәдер.
Утка карап уйлана...

Яңа дус (*Күренә.*)

Дөрес, бәгырь, дуссыз яшәү
Бик авыр бу дөньяда.

Салих

Ялгышканмын. Ул дигәнем —
Булды билгесез өрәк.

Яңа дус

Кайчагында яңа дуслар
Искедән кадерлерәк.

Салих

Җылыталмый күңелемне
Иң көчле учаклар да...

Яңа дус

Дус — дошманга, дошман — дуска
Әйләнгән бу чакларда.
Күрәсеңме ниләр яна? —
Йөрәгең сызлар янә...
Салих (*Янып бетмәгән кәгазь кисәкләрен карап.*) «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе»,
«Сүнгән йолдызлар» яна!

Яңа дус

Дустыңның утлы сүзләре
Көйләреңне яндыра.
Яндыра һәм көйләреңнән
Көлләр генә калдыра.

Салих

Учакны кемнәр якты?
Утларга кемнәр атты?

Яңа дус

Сез үзегез ут яктыгыз.
Яндыручы мин түгел.
Шикләнмә һич, сине дуссыз
Калдыручы мин түгел.
Аның йөрәгенә мәкер,
Хыянәт поскан булган.
Сине утларга салучы...
Ул... сиңа дошман булган.
Ул чагында сәхнә сиңа
Уен булып тоелган,
Хәзер аның сүзләренә
Көйләрең дә тыелган.
Инде сезнең — авторларның
Фаҗигасен язалар.
Чын тормышта көтә сезне
Физик, рухи җәзалар...

Салих

Озын гомер юраса да,
Моң кәккүге Габәши,
Ник шагыйрьләр иртә китә,
Аһәңсазлар аз яши?

Я ң а д у с

Тәхет янына кирәксез
Шагыйрь-әдип һәм дә сез,
Ярдәмче булып бармасаң,—
Калдырачак ярдәмсез.

С а л и х

Ни өчен сүз осталарын
Тоталар зинданнарда?
Иҗат эше җинаятьме?
Ни гаеп бар аларда?

Я ң а д у с

Шагыйрь иректә йөргәндә —
Тәхет өчен куркыныч.
Телен һәм кулын бәйләсәң,—
Хуҗа-юлбашчы тыныч.

С а л и х

Бер гаебе булмаса да...

Я ң а д у с (*Бүлдерә.*)

Яуга дәшәр халыкны,
Тәхеткә каршы котыртыр —
Һәрбер шагыйрь гаепле!
Кем әйтер, шагыйрь — сүз шаһы —
Гавамны котыртмас дип,
Карурман качкыны булып,
Тәхеткә ут төртмәс дип?
Бу — минем карашым түгел,—
Илбашлар шулай уйлый.
Мин моны яклап сөйләмим,
Әмма килешми булмый.

С а л и х

Барлык дус-ишләр зинданда...
Ник мин дә түгел анда?
Әллә кемнәр урап алган,—
Ник алар монда калган?

Я ң а д у с

Ачуланма: «Дусларыңны
Сайлый белмәдең»,— дисәм.

Көйләрең сине саклады,
Сөен, бәгырь, син — исән.
Алар да җырны ярата,
Уйлама — башка алар,
Синең көйне юлдаш итеп,
Эшләрен башкаралар.
«Минем катнашым юк»,— диеп,
Уйлыйсыңмы әллә син?
Күрәзәмне дәвам итеп,
Ачам Сарай пәрдәсен.

Пәрдә күтәрелә. Халык алдында — Юлбашчының Уң кулы.

Уң кул (*Сәгатенә карап.*)

Бу сәгать тарих битендә
Лаеклы урын алыр,
Дошманнарны тар-мар иткән
Бер дәвер булып калыр.
Юлбашчыбыз сезне — ягъни
Җиңүчеләрне котлый,
Бик күп дошманны фаш иткән
Иптәшләрне онытмый.
Йөз дошманның йөзен ачкан
Чып-чын патриот икән —
Галин!
Исемем язылган
Сәгатьне бүләк итәм!

Сәйдәш маршы яңгырый.

Бер дошман каршы килалмас
Тантаналы барышка,
Алга, гел алга, иптәшләр,
Бердәм атлап маршта!

Сәйдәш маршы уйнала.

Биргән планны арттырып
Үтәгән Казан халкы
Бөек җиңү хөрмәтенә
Бәйрәм итәргә хаклы!
Дошманнарга үлем!

Гавам

— Җәзаларга!

— Юк итәргә!
— Бары бер генә таләп!
— Ил дошманнарына үлем!
— Нәләт! Нәләт! Нәләт!

Бәйрәм башлана. Уң кул каршында кызлар Сәйдәш музыкасына бию башкаралар. Анда Г ө л н а р а да бар.

Я ң а  д у с

Болар сиңа танышлардыр —
Бар мәйданны тутырган,
Сезнең уңышка кул чабып,
«Зәңгәр шәл»дә утырган.

С а л и х

Туктат, туктат күрәзәңне,
Яп сарайлар пәрдәсен!

Я ң а  д у с

«Минем катнашым юк»,— диеп,
Уйлыйсыңмы әллә син?
Мин беләм: синең кулда да
Ул бүләк иткән сәгать.

С а л и х

Мин аны югалттым инде,
Караклар калды талап.

Я ң а  д у с

Кем икәнеңне белгәч,
«Сәйдәш» дигән сүз җитә.
Кире биргәннәр.
Син — мәшһүр,—
Бандитлар да үз итә.
Синең хакта легендалар...

С а л и х

Мәзәкләр...

Я ң а  д у с

Сөйлә Бишбалта кызын.
Сәгать төнге ике. Төн озын.

С а л и х

Илһамсыз һәм кәефсез чак.

Йөрәк әйләнгән ташка.
Җан эреде күзем төшкәч,
Бик гүзәл бер туташка.
Үземне күрдем шикелле
Күзләре карасында.
Әйтте ул: «Әйдә, очрашыйк
Бишбалта арасында».
Көттем.
Ә ул күренмәде
Бишбалта тарафында.
Ә ул әйткән булган икән:
«Биш-алты арасында».
Мәзәк түгел,— булган хәл,
Очрашмадык, бигрәк җәл...
Мин һаман да аны онытa алмыйм.
Бишбалтага күңелем гел бара.
Кайчан да бер хыял-балет булып,
Сәхнәләргә менәр Гөлнара.

Гөлнараның сөйгәне белән биюен күз алдына китерә.

Яңа дус

Их, аһәңсаз...
Мәхәббәтең талларына кунып,
Сайрый алмадың.
Кызларны да, дусларны да
Сайлый алмадың.
Бу кадәре көйсезлекләр
Җанга ничек сыя, әйт?
Улың үлде. Хатыныңнан
Көтә сине хыянәт.
Нечкә күңелеңә оя корып,
«Җан дустым син» дигән булдылар,
Антлар биреп, гел-гел алдадылар
Һәм хыянәт сиңа кылдылар.

Салих

Без күргәнне кемнәр язар?
Кемнәр сәхнәдә уйнар?
Тормышта башка күрергә
Язмасын диеп уйлар?
Һәм, гомумән, туарлармы
Шагыйрьләр, аһәңсазлар?

Куркыныч юлга басарга
Җөрьәт итәр бик азлар

Я ңа дус

Сезнең фаҗигане белүчеләр
Сүзгә, көйгә килмәс, бел шуны.
Хәтерлисең булыр карурманда
Сезнең янга килгән сынчыны.
Сезне җан дуслар дип ялгышты.
Яшь шул әле, белми тормышны.

Сынчы Сәйяр бүлмәсе. Ул үзенең «Җан дуслар» дигән эшен дәвам итә.

Сәйяр (*Көйли.*)

Кара урман шаулый.
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный,
Кайда син, бибкәй?

Гөлнара (*Бүлмәдән чыга.*)

Төн уртасы, Сәйяр, йокла инде,
Ул тыелган җырны көйләмә.

Сәйяр

Инде эшнең ахырына барам, Гөлнарам.

Гөлнара

Тинчурин да кулга алынган...
Тагын әлләниләр сөйлиләр.
Никтер Сәйдәшевкә тимиләр.

Сәйяр

Татар дөньясында алар аз.
Исән була күрсен аһәңсаз.

Гөлнара

Сак була күр, шушы авыр чорны
Без тиешбез исән үтәргә.

Сәйяр

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.
Оныттыңмы әллә Черек күлдә

Сине сөйгән кеше барлыгын?
Безгә кагылмаслар...

Гөлнара

Шаярма ла...
Өзелеп сөйгән ярым —
Бер Сәйярем генә бар минем!

## Төн кешеләрендә

Төн кешесе

Сез халык дошманы белән
Очрашырга баргансыз —
Һәм аңардан — Тинчуриннан —
Күрсәтмәләр алгансыз!

Сәйяр

Әйе, мине карурманга
Искиткеч бер көй тартты.
Яктырды күңел офыгым,
Иҗатым таңы атты.

Төн кешесе

Даһи иҗатың шушымы?
Сәйдәш — Тинчурин сыны?
Анда ниләр сөйләштегез?
Оешмада кемнәр бар?

Сәйяр

Мин бәхетле, гомеремдә
Әнә шундый төннәр бар!
Йөрәгем белән тойдым мин
Сүз һәм көй кушылуын,
Бергә типкән ике җанның
Бу төндә куш булуын.
Әйе, бу — минем иҗатым,
«Җан дуслар» дип атадым.

Төн кешесе

Беләмсең кая илткәнен
Бу сәяси хатаның?
Ал балтаңны, Сәйдәшевне
Дошманыннан аер син.

Ал кулыңа, тот балтаңны!
Бәлки, исән калырсың.

Төн кешеләре

Ал кулыңа, тот балтаңны!

Сәйяр

Чын иҗатчы беркайчан да
Явызлык кыла алмый,
Җанда туган уй-хисенең
Җәллады була алмый!

Төн кешеләре

Ал кулыңа, тот балтаңны!

Сәйяр

Балтам минем иҗат итә
Сүз һәм көйнең берлеген.
Сирәк туган талантларның
Көйче һәм шагыйрьлеген.

Төн кешесе

Ал кулыңа, тот балтаңны!
Сәйдәшевне аер син!
Тинчуринны чабып ыргыт —
Бәлки, исән калырсың.

Сәйяр

Юк! Юк! Юк!

Гөлнара

Ал кулыңа, тот балтаңны...
Башыңны югалтасың...

Төн кешесе

Аерыгыз! Каерыгыз!
Алыгыз үз балтасын!

Балтасын алып, агач сынны вата-аера башлыйлар.

Сәйдәшне калдырыгыз!
Тегесен яндырыгыз!

Салих

Ни гаебе бар аларның?
Харап була балалар...

Яңа дус

Синең дустың аркасында
Килде шушы бәлаләр.
Тәхет иясе ышанмый
Сүзләргә һәм балтага.
Ирек бирсәң, икесе дә
Тәхетен вата ала.
Башсызлыгы аркасында
Бәхетен вата бала...

**Төн кешеләре**

Зинданнар түрәсе

Юлбашчының сул кулыннан кайттым,—
Ул канәгать түгел һич кенә.
Тоткыннарның санын арттырырга!

Зиндан башлыгы

Алар — миллион,
Зиндан — кечкенә.
Тоткын өстендә — тоткын...

Түрә

Мөмкин тиз бушатырга
Өчлек хөкем итеп тора.
Кирәк күбрәк атарга!
Адәмнәрне котыртучы затлар:
Каләм ияләре, артистлар...
Төп ударны әнә шунда юнәлт:
Тынсын сәхнә, сүнсен алкышлар!
Йә, Тинчурин, ничек?

Зиндан башлыгы

Кул куймады, «гаеп юк!» янәсе.
Үзе кыйналган эт хәлендә.
«Кара йөрәк — патша!» дип җырлыйлар...
Коточкыч бит — «Зәңгәр шәл»ендә!
Шул да җиткән. Ибраһимов яткан
Ялтага да барган...

Түрә

Өстәгез!
Режиссер да, дирижер да — үзебез!
Без — сәхнәдә хәзер, өстә — без!

Зиндан башлыгы

Ә монысы... (*Җырлый.*)
«Туган илләреннән аерылып,
Киек-җәнлек кебек боегып,
Гомерләре сүнә качкыннарның
Кара урманнарга сыенып.
(*Икәүләп.*)
Без качкыннар, киек-арысланнар,
Урман — безнең Ватаныбыз, илебез.
Зур калалар безгә кара урман,
Ташпулатлар — безгә киң ялан.
Аргамаклар, йон түшәкләр,
Кама бүрек, пустау камзул — кирәкми,
Падишаның сенаторы, Үрәтниге,
Прокуроры кирәкми!»

**Чын күңелдән җырланган көйгә шәүләләре күренгән тоткыннар да кушыла. Әйтерсең лә бөтен зиндан җырлый.**

Түрә (*Куркып.*)

Тс-с-с! Яп авызыңны! Бу бит — анти! Бу бит — контр!

Зиндан башлыгы

Авторны! Авторны!

Түрә

Нинди хөкем чыгарсаң да —
Аз аларга!
Җәзаларга!

Зиндан башлыгы

Носилкага төяп чыгардылар.
Түзсә, түзәр тагын бер атна.
Тиздән атыласы исемлектә.

Түрә

Бик аз гына торсын чиратта.
Атылганны хәбәр итмәскә.
Хатлар килмәс ерак киткәч тә...

Зиндан башлыгы

Сәйдәшевне кайчан китерәсез?

Түрә

Әз-мәз яшәп калсын дан белән.
Әллә кая ерак китә алмас
Ярты җан белән.
Сәйдәш ул — татарның бәгыре бит...
Җәза өлкәсендә без — мастер.
Халык санын алу — авыр түгел,
Җанын алу...
ай-һай, булмастыр.
Аның үзен оста файдаланыйк.
Тими торыйк. Аннан күз күрер.
Һәр адымы — безнең күзәтүдә.
Карап карыйк,
кемне үз күрер...

Салих пианино янында. «Зәңгәр шәл»дән Мәйсәрә җырын уйный. Спектакльдән бер өзек күз алдына килә.

Мәйсәрә

Күрдегезме аны, кошкайларым,
Әллә үләннәр басканмы,
Абау, җаныем, каберен.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.
Базарларда сатыла торган
Маллар кебек безнең хәл.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.

Заһирә

Мәйсәрә!

Мәйсәрә

Син кем?

Заһирә

Акрын, Мәйсәрә, хәбәр китердем.

Мәйсәрә

Тукта, саташаммы юкса мин? Заһирә җаным, ничек киләсе булдың?

З а һ и р ә

Абыйдан хәбәр алдым.

М ә й с ә р ә

Булат бәгырем исән? Йә, йә, тизрәк-тизрәк сөйлә, кайда, ни эшли?

З а һ и р ә

Ул хәзер казна урманында икән.

М ә й с ә р ә

Үзе генәме? Ай, мескен!

З а һ и р ә

Алар анда күпләр, ди.

М ә й с ә р ә

Йә, йә, миңа ачуланмыймы, минем хәлне ишеткәнме? Заһирә бәгырем, тиз бул, сөйлә, сөйлә.

З а һ и р ә

Ишеткән, язган хаты синең турыңда.

М ә й с ә р ә

Йә, йә, кая хаты?

З а һ и р ә

Хәзер. Бу хатны алганыбызга ике атна булып узды.

М ә й с ә р ә

Ике атна!.. Үзе китердеме?

З а һ и р ә

Юк. Хәерче булып сакаллар куйган иптәше китерде.

Салих пианино янында.

З а һ и д ә (*Керә.*)

Салих...

Салих

Син кем?

Заһидә

Акрын, Салих, хәбәр китердем.

Салих

Заһидә?!
Нинди хәбәр? Көттем шулкадәр.
Ул исәнме?

Заһидә

Исән... әлегә.
Кайларга гына бармадым,
Беркем керми хәленә.

Салих

Әйт тизрәк.

Заһидә

Бары берничә сүз:
«Заһидәкәй. Түз...
Сәйдәш саклансын...»
Карурманда сине көтмиләр,
Килүеңне өмет итмиләр.

Салих

Аның үзен саклый алмадым шул —
Үзәкләрем өзелә шулкадәр.

Заһидә

Тагын бер хәбәр:
Шушы төндә тентү ясарлар.
Аның белән бәйле бер әйбер дә
Тапмасыннар.
Ходай Тәгалә һәм үз көйләрең
Сакласыннар... (*Югала.*)

Салих

Заһидә, тукта... (*Ялгыз калып, пианино эченә яшерелгән кәгазьләрне, рәсемнәрне актара.*)
Бик кадерле истәлекләр...
Ядкәрләр... калдырыйммы?

Әллә икәү яккан утта
Үзем үк яндырыйммы?

Я ң а  д у с

Мөмкин үлемне сайларга.
Була исән калып та.
Ниятеңдә яшәү булса,
Икеләнмә, сал утка!
Ычкынырга тырыш, дускай,
Сәхнәдәге уеннан.
Чыгар аны хәтереңнән,
Хыялыңнан, уеңнан.
Дус дип уйлаганнарың да
«Саклан!» дип торган чакта,
Мә, шырпы, юк ит барын да,
Үзеңне-үзең сакла!

С а л и х

Юк, мин моны эшли алмыйм.
Кул тартмый.

Я ң а  д у с

Алар килә!
Алдан ук язып куелган:
Коточкыч карар килә!
Аңлыйм халәтеңне, дускай,
Китер, үзем яндырам.
Моң даһиен киләчәккә
Исән-имин кадырам! (*Ут төртә, рәсем яна башлый.*)

С а л и х

Тукта, сүндер утларыңны!
Җанга якын ич алар...
Яңа дус
Әнә, кара: җантимерләр
Машинадан төшәләр... (*Югала.*)

Дәһшәтле аяк тавышлары якыная. Т ө н  к е ш е л ә р е керә.

Т ө н  к е ш е с е (*Документларын күрсәтеп.*)

Тентү!
Иптәш Сәйдәшев... син әлегә иптәш.
(*Салихка каршы утыра. Тегеләргә.*) Башлагыз!

(*Өйне тенти башлыйлар.*)
Синдә тентү эше башкарырбыз.
Ә сез безгә бер көй башкарыгыз!
Шундый көй кирәк —
Бу өй — сәхнә булып тоелсын!
Ял да итсен бераз башларыбыз.
Тик көй булсын, сүзе — кирәкми!

Бер сүз дәшмәгән Салих әкрен генә уйнарга тотына. Тегеләр шул музыкага тентиләр. Төн кешесе, башын иеп, уйга талган. Ярсулы клавишлар, соңгы аккордны алып тына.

Беренче төн кешесе

Безгә кирәк берни табылмады!

Төн кешесе (*Пианинога күрсәтеп.*)

Ачып карагыз!

Беренче төн кешесе ача һәм анда Тинчуринның рәсемен күрә, әмма берни әйтмичә, урынына кире куя. Берни дә юк. Бары бер таяк!

Төн кешесе

Ни бу, маэстро?

Салих

Дирижер таягы.

Төн кешесе (*Кире бирә.*)

Үзеңә калсын.
Сине тыңлап,
Җырлап утырасы иде бер.
Инде аңладыңмы —
Кем тыңлаучы,
Ә кем дирижер? (*Китәләр.*)

Салих

Күзәтәләр,
Сүз аталар,
Төз аталар йөрәккә.
Үз-үземнән куркып йөрим,
Әйләнәмме өрәккә?
Өемне дә,
Киемне дә,

Көемне дә тентиләр.
«Сүзләреңнән аерылгач,
Даһига тиң син!» — диләр.
Аердылар,
Каердылар,
Беләлмимен хәлеңне.
Мин төш күрдем. Шушы төнне
Нишләтерләр Кәримне?

Я ң а  д у с

Синең тоемың да чынга аша.
Финал мизгелләре якынлаша.
Башын имәгәннәр, горур җаннар
Төрмә упкынында юк булыр.
Тик, бары тик гүзәл Гөлнарабыз
Мәңге юк булудан котылыр.
(*Төн кешесе кабинеты. Өстәле затлы ризык, шәраб белән бизәлгән.*)

Т ө н  к е ш е с е

Гөлнараны! (*Кертәләр.*)
Гөлнара? Исәнме, җаным?
Синең өчен бу табын.
Утыр, аша җимешләрне...
Җаның ни тели тагын?

Г ө л н а р а

Сәйяр кайда? Аны нишләттегез?

Т ө н  к е ш е с е

Син ялгыштың китеп Сәйяр белән,
Күңелең язмыш белән шаярды.

Г ө л н а р а

Мин яратам бары Сәйярне!

Т ө н  к е ш е с е

Син — яшь, чибәр, киләчәгең — алда,
Бәхетеңә каршы кем бара?
Нинди генә хәлдә калсаң да син,
Мин яратам сине, Гөлнара!

Г ө л н а р а

Су эчәсем килә...

Т ө н к е ш е с е

Беләм, синең сөйләшәсең килә...
Кап шәрабны, җитеш йөземеннән,
Янә нурлар балкыр йөзеңнән.
Онгыта алмыйм сүзсез биюеңне...
Гомерем — газап соңгы вакытта.
Йөрим бары сине күрү өчен
Син катнашкан һәрбер балетка.
Тормышыңда тирән ялгышыңны
Уйлыйм: хәзер аңлагансыңдыр дип,
Тик уйламыйм яшьлек хаталарын
Төзәтергә инде соңдыр дип...

Г ө л н а р а

Сәйяр кайда? Ул исәнме, юкмы?
Яшермә, әйт миңа дөресен.

Т ө н к е ш е с е

Таң атканда, чынын белерсең.
Баштан сыйпамаслар, үзем өчен
Бик куркыныч юлга мин барам.
Сөюемне раслап, сине, сине
Исән калдырырга бар чарам,
Гөлнарам!
Ул Сәйярне таңда атачаклар.

Г ө л н а р а

Атачаклар?!
Юк, юк, ышанмыйм!

Т ө н к е ш е с е

Әгәр бер шартыма риза булсаң,
Атмаска дип, үзем кушармын.
Минеке бул!
Башка токтыннарның
Төшенә дә бу хәл кермәгән.
Минеке бул... шулчак —
Сәйяр — исән,
Син дә котыласың төрмәдән.
Сәйдәш көен тыңлап,

Биеп-җырлап,
Шушы төнне бергә уткәрик.
Кил, Гөлнарам, тулы шәрабны без
Син һәм минем өчен күтәрик!

Сәйдәшнең күңелле музыкасы. Төн кешеләре, ике яктан тотып, кыйналган Кәримне төрмә диварына сөяп куялар. Аның янына Сәйярне дә китерәләр. Сәйяр егылган Кәримне күтәреп ала.

Сәйяр

Кәрим ага, сезме?

Кәрим

Син үзең кем?

Сәйяр

Сезгә — карурманга баручы —
Мәңге тугры булып калучы —
Сынчы Сәйяр.

Төн кешесе

Разговоры!

Кәрим

Кичер, энем...

Төн кешесе тавышы

101 нче номерлы тоткын Сәлимов Сәйяр Әхмәт улы Советка каршы җинаятьчел эшчәнлеге өчен атарга хөкем ителде. Хөкем карарын җиренә җиткерергә!

Сәйяр

Онытмагыз Сәйдәш-Тинчуринны!
Сау-бәхил бул, Гөлнарам...

Ату тавышы. Сәйяр егыла. Салихның күз алдына балет күренеше килә. Төн кешесе көч һәм хәйлә белән Гөлнараны үзенә буйсындырган. Төн кешесе бит аңа Сәйярне исән калдырырга сүз бирде. Гөлнара һаман да Сәйярне яратуын тәкрарлый. Сәйярне оныттыру өчен, Төн кешесе чынбарлыкны әйтә: «Сәйярне шул төнне үк аттылар!» Алданган Гөлнара күкрәгенә хәнҗәр яшереп килә һәм Төн кешесен үтермәкче була. Төн кешесе хәнҗәрне алып, Гөлнараның үзенә кадый.

Төн кешесе тавышы

102 нче номерлы тоткын Кәрим Гали улы Тинчурин Со-

ветка каршы җинаятьчел эшчәнлеге өчен атарга хөкем ителде. Хөкем карарын җиренә җиткерергә!

Кәрим

Салих Сәйдәшевне саклагыз!
Татарлар, татарны атмагыз!

Ату тавышы. Кәрим егыла. Төн кешеләре, казна эшен башкарып, Сәйдәш һәм Тинчурин җырын көйләп китеп баралар. Салих пианино янында. Ул үз күрәзәсе-фаразыннан шашып калган.

Салих

Иҗатчыны юк итәргә
Бармы сезнең хакыгыз?!
Тинчуринның ярты җанын —
Сәйдәшне дә атыгыз!
Гаепсезгә кеше ату...
Бу бит, бу бит — вәхшилек.

Яңа дус

Алар сиңа караганда
Рәхәт, тыныч яши бит.
Рухың изгән бу зинданнан
Ireккә чыгу өчен
Бер генә юл: тулысынча
Алар ягына күчү!

Салих

Талантың чәчәк атканда,
Җан дустым, булдың һәлак.
(*Матәм маршы.*)
Сине яндырткан мизгелгә,
Дәшми яшәүгә — нәләт!
Сүнә илһам... сүрелә җан...
Күңелем — өнсез калган.
Клавишлар үксеп елый:
Сүзсез һәм телсез калган.
Як-ягымда һәм янымда
Атучы, сатучылар...
Кайда сез, саф хыялларым,
Юлга озатучылар.
(*«Кара урман» көен уйный. Салихта элекке дәртле моң уяна.*)

Онытма һәм оныттырма —
Дөньяда өмет барын.
«Сүнгән йолдызлар» кабыныр,
Сүнмәгез, хыялларым!

Яңа дус

Алар үлде дә котылды.
Синдә калды газабы.
Үкенечле тәмамланыр
Гомереңнең азагы.
Рухи зинданыңда калып,
Бер чиккә җиткерерләр:
Сөйгән эшеңнән дә куып,
Әкренләп үтерерләр.
Яман авыру алып китәр
Яшь көенчә үзеңне.

Салих

Тормышым көйсез булса да,
Әйтеп калыйм сүземне.
Кәримнән башка — ярты җан.

Яңа дус

Бер киңәш мин дә әйтим,
Аңардан башка син — даһи!

Салих

Аннан башка — мин ятим.

Яңа дус

Табигать биргән талантның
Рәхәтен күрү өчен —
Бер генә юл: бөтенләйгә
Алар ягына күчү!
Шунда гына син үзеңне
Ирекле дип сизәрсең.
Онытырсың газапларны,
Диңгезләрдә йөзәрсең.
Яшәрсең тын сарайларда,
Мәдхияләр язарсың.
Яшәрерсең, бик теләсәң —
Алар кебек азарсың.
Үзеннән-үзе килерләр

Орденнар, дәрәҗәләр...
Кош сайраган бакчаларга
Ачылыр тәрәзәләр.

Салих

Ирекле кош сына торган
Юан талга куналмас.
Нечкә талларда тирбәлер,
Карурманда югалмас.
Бар нәрсәдән артык миңа
Сүз һәм көйнең берлеге.
Шул — яшәвемнең мәгънәсе
Һәм җанымның хөрлеге!
Үтерүче көчләрнең мин
Колы була алмыймын,
Шул бәйрәмдә уйнаучының
Кылы була алмыймын.
Мин таныдым:
Син бит — Дәҗҗал,
Явызлыкның символы.
Һәр җирдәге яманлыкның
Уң кулы һәм сул кулы.
Сайрамаган кош булмас,
Былбыл-козгын куш булмас.
Тинчуринның ярты җаны
Козгын белән дус булмас!

Яңа дус

Үзеңнең дә, халкыңның да
Киләчәге караңгы...

Салих

Йөрәгендә ут сүнмәгән
Исән дуслар бар әле!

Яңа дус

Күрәзәче булып әйтәм:
Сезне һәлакәт көтә.
Сезнекеләр беркайчан да
Менә алмас тәхеткә! (*Югала.*)

Салих

Яшәсә дә вакытлыча
Тинчуриннарсыз калып,

Моңнарыңнан аерылмасын,
Телсез калмасын халык!
Кара урман әчләреннән
Кайтыгыз, качкыннарым!
Белсен тәхет ияләре
Җаннарда ялкын барын!
Сездә — якты хыялларым,
Дәртем һәм өметләрем.
Сүзне-Моңны югалтмагыз,
Кызларым, егетләрем!

**Дирижер таягын ала. Барысы да сәхнәгә чыга. «Зәңгәр шәл»дән Булат җыры һәм хор яңгырый.**

Булат

Дусларым, каңгырып кайттым.
Дусларым, ерак иլләрдән,
Тоткыннар — батыр егетләр,
Дусларым сәлам әйттеләр:
Матур кызларга, якын дусларга,
Син дә, кодача, өлешсез калма.
Анда юк — уен, анда юк — сәхнә,
Салкын бүлмәдә тоталар ябып.
Тоткыннар санын, номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда.

Хор

Булат, Булат кайткан,
Бүләк алып кайткан.
Сабан җилен каян,
Каян сизгән, наян!
Сабан таңда, сабан,
Бүләкләр дә алган,
Сабан җилен каян,
Каян сизгән наян.

Барысы да

Зәңгәр шәл!

**Булат Заһидәнең иңенә зәңгәр шәл сала. Кара пәрдә зәңгәрләнә, кара урман яктыра.**

*1995—2001*

# *Янар чәчәк**

*Комедия 3 пәрдәдә, 5 күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Фәнәви.
Фәүзия.
Лира.
Җидегән.
Юлдаш.
Рамазан.
Нәгыйм.
Дускаев.
Миңнулла.
Җәмәй.
Яшьләр.

Вакыйга 50—60 нчы елларда колхоз авылында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### I КҮРЕНЕШ

Сәхнә караңгы. Ерактан-ерактан әкрен генә рояль моңнары ишетелә. Моңнар көчәю белән, сәхнә яктыра төшә. Ашкынып-ашкынып уйнаучы пианистның шәүләсе күренә. Музыкаль авазлар тагын да көчәя. Сәхнә яктыра. Шәүлә югала... Колхоз клубының яки уку йортының эче. Стеналарда — лозунглар, плакатлар. Уртада — өстәл. Лира, Фәүзия, Нәгыйм, берничә яшь егет һәм кыз өстәл тирәли утырганнар. Юлдаш өстәл янында, дәфтәр тоткан килеш, басып тора. Ул үзе язган пьесаны укып бетергән.

Пәрдә ачылганда, гомуми көлү.

Юлдаш. Йә, җәмәгать, комедия ошадымы?

Лира. Искиткеч! Коточкыч язгансың, Юлдаш.

Нәгыйм. Көлә-көлә эчләр катып бетте...

Фәүзия. Юлдаш, син моны үзең уйлап чыгардыңмы, әллә?..

Юлдаш. Күчердеңме, дисеңме? Әйе, күчереп яздым. Үзебезнең колхоз кешеләреннән...

Нәгыйм. Теге егет Юлдаш үзе түгелме соң?..

Лира. Син бит ул, Юлдаш?..

* 1961 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды.

Юлдаш. Абзагыз үзе...

Нәгыйм. Миңнулла минем күрше ич!

Фәүзия. Бәй, теге... әкәмәт, Рамазан абый түгелме соң?

Тавышлар.

— Шул үзе...

— Җәмәй дә эләккән кармакка!

— Бер тамчы су кебек...

— Суйган да каплаган!

Фәүзия. Әй эттә генәсе... Ә теге «принципиально» дип йөргәне ни бит... (*Юлдаш, әйтмә, дип ишарәли.*) Ни бит... иптәш Дускаев! (*Фәүзия үзе дә сизеп алып уңайсызлана.*) Әй лә... Ул түгел икән...

Лира (*уңайсызланып, Юлдашка карый.*) Минем эти түгелдер? Булмас.

Юлдаш (*аска карап*). Мин, Лира, анысын үзем уйлап таптым. Баш белән.

Фәүзия. Ә теге кыз... син, Лира апа.

Нәгыйм. Җидегән абый да бар...

Лира. Ә теге... ферма кызы син ич, Фәүзия.

Көлеп җибәрәләр.

Фәүзия. Мин?! Чынлапмы, Юлдаш?

Юлдаш. Бер-берегезне эзләп таптыгызмы, шулай була ул!

Бер егет. Болай булгач, син бездән китәрсең инде, Юлдаш...

Юлдаш. Ничек булгач?..

Бер кыз. Язучы булгач. Йә чакыру кәгазе җибәрерләр әле.

Юлдаш. Очырмасалар, ычкынырга исәп юк.

Нәгыйм. Лира апа, ник уйга баттың? Нишлибез? Куябызмы?

Юлдаш. Әллә Лирага ошамады инде?..

Лира. Пьеса ошавын ошады. Коточкыч! Тик менә... Уңайсызрак булмасмы икән, дим. Бигрәк тозлап-борычлап язылган... ияләре ачуланмасмы?

Юлдаш. Мин аны шуның өчен яздым.

Бер егет. Лира апа, тагын нәрсә кирәк? Дөрес сүз таш яра.

Лира. Тавыш-гауга купмасмы?

Юлдаш. Тавыш түгел, давыл купсын!

Тавышлар.

— Тавыш куба...

— Купсын!
— Гыйбрәт булсын!
— Башка пьеса беткәнмени?
— Үзебезнең малай язган ич...
Лира (*яшьләргә*). Йә, куябызмы, юкмы?
Яшьләр.
— Куябыз!
— Хәзерләнә башлыйк...
— Бүген үк...
— Хәзер үк...
Нәгыйм. Куябыз! Куябыз!
Лира. Ни булса, шул булыр. Куябыз! Фәүзия, кем булып уйныйсың?.. Әйдә, ферма кызын...
Фәүзия. Мин... белмим... Әллә нишләп киттем... Ә уйныйсым килә. Ул кызда минем хыялларым, хисләрем бар төсле.
Юлдаш. Тәнкыйтькә эләккән кешеләрне премьера көнне чакыру билеты белән, иң хөрмәтле кунак итеп, иң беренче рәткә утыртабыз.
Нәгыйм. Ихтирамны аңлап килсәләр ярый ла... (*Көлә.*)
Лира. Шулай да Рамазан абзыйга пьесаны укытырга кирәк.
Тавышлар.
— Укысын!
— Укыдымы — бәхилләш инде пьесаң белән...
— Укымасын!
Юлдаш. Тукта әле, кем-кем — ул инде пьесаны аңлый торган кеше. Мин аңа пьесаны укырга бирдем. Ул бүген монда фикере белән киләчәк.
Бер егет. Ишкәнсең ишәк чумарын!
Нәгыйм. Миңнулланы үзем уйныйм. Лира апа, декорацияне үзем ясыйм. Фонда — яңа авыл. Безнең авыл. Пейзаж — ... чишмә... электр баганалары... еракта Агыйдел дулкынлана...
Лира. Декоратор да үзебезнеке! Читтән чакырасы юк.
Нәгыйм. Музыканы үзең яз, Лира апа. Ул шундый музыка булсын...

Рамазан Җәләев керә.

Рамазан. Сәлам авыл интеллигентларына!

Юлдаш, дирижер кебек, таяк белән селтәнә.

Яшьләр (*барысы бергә*). Исәнмесез, иптәш Җәләев!

Рамазан (*Юлдашка*). Бир кулыңны, иптәш Юлдаш! Колхоз идарәсе исеменнән тәбрик итәм.

Юлдаш. Аңламыйм, Рамазан абый...

Рамазан. Дөрес! Шулай тыйнак булырга кирәк. (*Кулындагы дәфтәрне югары күтәреп.*) Пьесаңны укыдым.

Лира.
Юлдаш. } Йә, ничек, Рамазан абый?

Рамазан. Мондый пьесаның булганы да юк, булмас та, башка кеше язса, кирәге дә юк.

Лира. Димәк, пьеса сезгә ошады, Рамазан абый?

Рамазан. Ошау гына дисеңме! Кәмит! (*Юлдашка.*) Бик башлы кеше булып чыктың әле син, иптәш Юлдаш. Атаң мәрхүм дөнья ялкавы иде. Алма да агачыннан ерак тәгәри икән. Котлыйм, котлыйм. Ун ел мәктәптә шар сугып йөрмәгәнсең.

Лира. Сез каршы түгел алай булгач, Рамазан абый?

Рамазан. Һич кичекмәстән куярга кирәк!

Юлдаш. Иптәш Җәләев, пьесага, вакытыгыз тыгыз булмаса, пичәтегезне сугып куйсагыз, күңел тынычланыр ие.

Рамазан. Анысы кечкенә мәсьәлә, рәхәтләнеп сугабыз аны. (*Дәфтәргә печать суга.*) Куярга! Бүгеннән үк репетиция башларга! Дөнья шаулатыгыз!

Юлдаш. Пьесадагы председательгә сез ничек карыйсыз, иптәш Җәләев?

Рамазан. Бик уңай карыйм. Акыллы кеше булып чыктың, иптәш Юлдаш. Аңладым. Мине язгансың. Исемфамилияне генә башка кешенекен куйгансың. Әллә, исемне халыктан яшермичә, дөресен язасыңмы?

Лира. Автор риза булса...

Юлдаш. Сәнгатьне яратучы председатель өчен андый гына үзгәртүләргә риза булырга туры килә.

Рамазан. Ни өчен дигәндә, халыкның аңламый калуы бар, төрле кеше бар.

Лира. Рамазан абый, пьесада кимчелекләр юкмы соң?

Рамазан. Тегеләй дә уйлап карадым, болай да. Кимчелек юк кына бит, әй. Бүгенге колхозда нинди кимчелек булсын, ди, адәм көлкесе. Колхоз бай... халык көр күңелле. Ни өчен дигәндә, коммунизм төзибез.

Юлдаш. Бәлки, пьесага киметүләр яки өстәүләр кирәктер, иптәш Җәләев?

Рамазан. Киметүләр кирәк булмас, энем. Өстәүләргә килгәндә, анысын уйлап кара. Әйтик, мәсәлән, автоматлашкан тавык фермасы...

Л и р а. Анысын автор үзе уйлап карар. Рамазан абый, иртәгә өченче бригадага концерт белән бара идек. Анда, клубны яптырып, бәрәңге тутыргансыз икән.

Р а м а з а н. Техника заманасында нигә барып йөрергә? Рәхим ит. Юлдаш радиоузелына кер дә җырлый бир. Тыңласыннар.

Ю л д а ш. Безнең программада бию, физкультномерлар, балеттан өзекләр дә бар, Рамазан абый.

Р а м а з а н. Кайгырма, берничә елдан безнең колхозда да телестудия булыр.

Л и р а. Аңа кадәр биеми торсыннармы?

Ю л д а ш. Рамазан абыйга тегене сайрап бирәбезме әллә, Лира?

Л и р а. Тыңлагыз, Рамазан абый.

Р а м а з а н (*сәгатенә карап*). Йә, йә... нәрсәне?

Л и р а. Җанлы газетаның беренче бите. «3 нче бригада зары». Редакторы Юлдаш Хәйдәров. Башладык. (*Рамазанны уратып җырлыйлар.*)

Безнең авылның утлары
Гөлт итеп янып тора,
Утлары янып торса да,
Клубы ябык тора.

Авылларның арасы
Ерак, ничек барасы.
Арып-талып кайтып җитсәң,
Эшкә соңга каласы...

Ерак юлны якын итеп,
Культура килер микән.
Әллә кайбер кешеләрнең
Йөрәге тимер микән?..

Р а м а з а н. Хикмәт. Аны, кешеләр шикелле, җырламыйча гына әйтеп булмыймыни?

Ю л д а ш. Операда да җырлап сөйләшәләр ич, Рамазан абый.

Р а м а з а н. Бервакыт шулай республика активында опера тыңларга мәҗбүр иткәннәр иде. Барысы бергә кычкыра бирә, берсенең җырын икенчесе тыңламый, тәнәфестә чак качып котылдым.

Л и р а. Берзаманны опера безнең авылда да булыр...

Р а м а з а н. Андый күңелсез сүзләр сөйләмә, Лира.

Лира. Әллә, Рамазан абый, пьесада үзегез дә уйныйсызмы?

Юлдаш. Чынлап, иптәш Җәләев.

Рамазан. Мин үзем дә бик теләп уйнарга риза, әмма ләкин минем эшнең колачын үзегез беләсез. Ә уйнаган чаклар бар иде, кәмит! Сәхнәне селкетә идек. Колакларны сүгә идек. Җырлый, бии, ярата һәм шуңа охшашлы башка эшләр эшләп йөри идек. Ул чакларда кызлар, минем бөдрә чәчләремә карап:

Талдин билләрең нечкә,
Талдин нечкә билләреңә
Кул салдым үкенечкә,—

дип сайрап торалар иде. Ә хәзер, дәрт бар, дәрман юк... Шуңа карамастан, җир селкетеп йөрибез әле. (*Сәгатенә карый.*) Хуш, башка сөйләүчеләр юкмы?.. Булмаса, ябык дип игълан итәм.

Лира. Рәхмәт, Рамазан абый, яшьләр йөрәген аңладыгыз.

Юлдаш (*салам кыстырып*). Иптәш Җәләевнең йөрәге яшь шул аның.

Рамазан. Мактама, мактама... Хуш, киттем, миннән полный рөхсәт! (*Чыгарга бара. Юлдашка ымлап.*) Әйтергә оныткаммын, иптәш Юлдаш, мин синең должностьны күтәрү турында уйладым әле. Гомер буе радиоузелда попугай кебек игълан укып утырмассың, шәт. Миңа синең шикелле акыллы кадрлар муеннан кирәк. Мин сине акрынлап иң югары постка — председатель урынбасарына кадәр күтәрермен! (*Чыгып китә.*)

Юлдаш. Күрдегезме?! Ә сез аны сүккән буласыз.

Лира. Бернәрсә дә төшенмим. Бик серле. Рамазан абый әллә пьесаны укымаганмы?

Юлдаш (*хәйләкәр елмаеп*). Җаен белсәң, май кебек ул Рамазан абыең...

**Фәнәви килеп керә. Эш киеменнән. Ул, бер сүз дә әйтмичә, яшьләр арасыннан Фәүзияне эзли.**

Фәнәви. Фәүзия кайда?

Юлдаш. Айда. Ракетага утыртып, Айга очырдык.

Фәнәви (*Юлдашка*). Ат дагалаганда, бака ботын кыстырган да үлгән, ди... Лира апа, кайда Фәүзия?

Фәүзия (*алга чыгып*). Дөнья җимерелдеме әллә, Фәнәви?

Ф ә н ә в и. Дөнья җимерелмәгән, йортның асты өскә килгән. Хуҗасыз өй шикелле. Ә син монда, дөнья мәшәкатен онытып, кәмит уйнап йөрисең. Кайт тизрәк өйгә!

Л и р а. Фәнәви, монда репетиция!

Ф ә н ә в и. Семьяны бозып бетерәсез инде шул репетициягез белән. (*Фәүзиягә.*) Сиңа әйтәләр, әйдә өйгә!

Ф ә ү з и я. Фәнәви, нишлисең халык алдында?!

Ю л д а ш (*Фәнәвинең алдына чыгып*). Репетиция бетмичә, Фәүзия өйгә кайтмый!

Ф ә н ә в и. Кара, кара бу шарлатанны. Күзләреңне пичәтләндереп карама. Шартлап чыгар. Үз хатыны кебек сөйләшә, җитмәсә.

Ю л д а ш. Фәүзия синеке генә түгел, безнеке дә.

Ф ә ү з и я. Фәнәви, кешедән оял!

Ф ә н ә в и. Фәүзия сезнеке? ЗАГС кенәгәгезне күрсәтеп сөйләшегез. Ул минем хатынмы, әллә сезнең хатынмы? Син тагын, өйгә басып кереп, бу өй минеке, бу кәҗә минеке, диярсең.

Ю л д а ш. Коммунизмда синең кәҗәң дә минеке булачак.

Ф ә н ә в и. Башыңда шөрепләр ычкынгандыр синең. Коммунизмда минем хатын да сиңа булачакмы? Әй, Юлдаш, Юлдаш... Айгыр кебек гәүдәң белән адәм көлдереп йөрим диген, ә? Йорт-җиреңне карар иең ичмасам.

Ю л д а ш. Йорт-йорт дип, мещанлык сазлыгына батуыңны белмисең...

Ф ә н ә в и. Батсам, ярдәмгә сезне чакырмам, курыкмагыз, үзем чыгармын. Киттек, Фәүзия!

Ф ә ү з и я. Репетиция бетмәде ич. (*Лирага карый.*)

Л и р а. Фәүзия бер сәгатьтән бушый, Фәнәви.

Ф ә н ә в и. Ярый, син адәм көлдереп йөр алайса. Идәнне дә үзем себерермен, тавыкларны да үзем ашатырмын, сыерны да үзем савармын... Кал алайса. (*Чыгып китә.*)

Тынлык. Фәүзия, нишләргә дә белмичә, сәхнә уртасында басып кала.

Ю л д а ш. Фәүзия, син хаклы!

Л и р а. Уңайсызрак килеп чыкты бу...

Ф ә ү з и я (*бер ноктага карап торганнан соң*). Фәнәви! (*Чыгып йөгерә.*)

Л и р а. Фәүзиясез дә калдык. Нишлибез?

Ю л д а ш. Фәүзия иртәгә барыбер киләчәк. Репетицияне башлыйк, Лира.

Л и р а. Юк, Фәүзиясез булмый... Күрәсең ич.

Яшьләр.
— Әйдәгез, киттек болынга!
— Тарт, Рәис, баяныңны!
— Киттек!

**Җырлап чыгалар. Лира, Юлдаш, Нәгыйм генә торып кала. Уңайсыз тынлык.**

Юлдаш. Беренче көнне үк уңышсыз башладыгыз, Лира. Йомшаклык күрсәттегез.

Нәгыйм. Язучы булдым дигәч тә... син Лира апага каты сүз әйтмә.

Юлдаш. Бар, Нәгыйм, әниеңнең җылы кочагына кайт. (*Чыга.*)

Лира. Өздем. Таркаттым...

Нәгыйм. Лира апа... (*Күккә карап.*) Нигә бүген һавада йолдызлар янмый икән? (*Лира эндәшми.*) Ә йөрәк яна... их!.. (*Чыга.*)

**Ерактан яшьләрнең җыр тавышлары ишетелә.**

**Пәрдә.**

## II КҮРЕНЕШ

**Сәхнәнең уң ягында Фәнәвиләр өе. Ул биек койма белән уратып алынган. Койманың бер тактасы каерылган. Теге яктан кадак каккан тавыш ишетелеп тора. Сул якта яңа салынган йорт. Аңа «Гостиница» дип язылган. Гостиницаның тәрәзәсе ачык. Тәрәзәдән ут күренә, тәрәзә янында гына карт нарат. Пәрдә ачылганда, бер як читтә — Нәгыйм. Ул, бик бирелеп, пумала белән рәсем ясый. Еш-еш тәрәзәгә карап ала. Гостиница ишегеннән Лира этисен озата чыга.**

Дускаев. Шулай, кызым, минем бу эштә калу-калмау мәсьәләсе тора.

Лира. Ни өчен соң, эти? Үзең гаепләме?

Дускаев. Минме гаепле?! Һич юк. Кино күрсәтү планын үтәп барам. Ни кирәк? Чыга да бер яшь-җилкенчәк район активында әйтеп сала: Дускаев, янәсе, заман сулышын сизми. Кино күрсәтүдән башканы белми... Минме сизмим, минме белмим?.. Йә, әйт...

Лира. Мин сине сәнгать кешесе дип беләм, эти!

Дускаев. Шул шул. Шуның сөйләве буенча чакырып алдылар да райкомга, категорически куялар: йә яңача эшлисең, йә бөтенләй эшләмисең. Кара әле, ул малай сезнең авылдан бугай. Фамилиясе хәтердән чыккан.

Л и р а. Кем икән ул? Нәгыйм, Юлдаш...

Д у с к а е в. Әллә кем булсын. Әтиеңнең тормышына сукмакчы. Йөрәк тә уйнап тора бу арада. Шуннан соң тагын начарайды.

Л и р а. Кем икән ул юньсез малай?.. Кайгырма, әти.

Д у с к а е в. Иртәгә үк кайт, кызым. Оясыз кош кебек тилмереп, гостиницада ятма. Әниең дә шулай ди.

Л и р а. Килүемә нибары бер ай бит. Кайтмыйм.

Д у с к а е в. Эх, кызым. Нишләмәкче буласың син монда? Талантыңны һәлак итәсең. Шартлар кайда монда талант өчен? Оркестр кая? Пианино? Авыл шартларын мин биш бармагым кебек беләм...

Л и р а. Ә без, әти, аларны үзебез булдырырбыз. Сез ярдәм итсәгез, әлбәттә.

Д у с к а е в. Минем сәнгатьне яратуны син яхшы беләсең. Ләкин... беренчедән, син ялгызың нишләмәкче буласың? Икенчедән, безнең ярдәмме?.. Пианино, режиссер, оркестр, картиналар галереясымы? Район органнары хуҗалык белән мәшгуль.

Л и р а. Ә колхозчының рухи дөньясы? Ул кино, лекция, радио белән генә канәгатьләнергә тиешме? Юк, аңа «Галиябану» да, «Евгений Онегин» операсы да, «Шүрәле» балеты да кирәк.

Д у с к а е в. Тормыш тәҗрибәсе юк синдә, Лира, вакыты җитәр. Киләчәктә шулай булыр да. Ә бүгенге кешеләрдә хәзерлек юк... Мин сәнгатьне яратсам да, романтик түгел, ә практик. Сыер савучы кызның «Куда, куда вы удалились...» дигән мәшһүр арияне түземе җитеп тыңлап утыруына шигем зур.

Л и р а. Ә без аны өйрәтергә тиешбез. Әйе, мин инде өйрәтә дә башладым. Драма һәм музыка түгәрәкләре оештырдым. Шундый талантлы яшьләр...

Д у с к а е в. Ник кешеләр өчен үзеңнең талантыңны харап итәсең, Лира? Институт тәмамлап бит! Әниең дә шулай ди. Без синең бөтенсоюз масштабында танылган артистка булуыңны өмет иттек.

Л и р а. Һәркемгә дә артистка булырга димәгән. Ә менә минем режиссер буласым килә.

Д у с к а е в. Ишетсен колагың, синең урының монда түгел, һич югында, район масштабында артистка бул. Әниең дә шулай ди.

Л и р а. Юк инде, мин авыл масштабында гына калыйм.

Д у с к а е в. Яшьлек... Үкенерсең...

Лира. Һич үкенмәм.

Дускаев. Их, Лира, Лира. Канатсыз тургай.

Лира. Минем канатлар әле яңа гына чыгып килә.

Дускаев. Димәк, үз сүзеңдә каласың? Принципиально! Киттем. Кайтсаң — ачык йөз.

Лира. Клуб, уку йорты белән танышмыйсыңмыни, эти?

Дускаев. Башка вакытта. Махсус сиңа гына килгән идем. Хуш!

Лира. Хуш, эти. Әнигә сәлам!

Дускаев. Әниең дә шулай ди... (*Чыга.*)

**Лира, Нәгыймне күрмичә, кереп бара. Нәгыймниндидер көй сызгыра.**

Лира (*күреп*). Нәгыйм, син нишлисең монда?

Нәгыйм. Декорациянең эскизларын сызам, Лира апа.

Лира. Төнлә... Шундый караңгыда?

Нәгыйм. Электр төнлә яшьләр өчен яна, Лира апа. Аннан соң... Гомумән, миңа якты. Аннан соң... Лира апа.

Лира. Берәр сүз әйтәсең бармы әллә, Нәгыйм?

Нәгыйм. Бар шул... Әй, юк... юк!

Лира. Монда уңайсыздыр бит сиңа?

Нәгыйм. Киресенчә, миңа монда уңайлы, Лира апа... Аннан соң...

Лира (*эскизга карап*). Натурадан эшлисең? Гостиница... Ә монысы... Фәнәвиләр капкасы...

Нәгыйм. Бу — сәхнәнең планы. Нәкъ натурадан булачак. Мин сезгә комачауламыйммы, Лира апа?

Лира. Һич юк. (*Пауза.*) Нәгыйм, син рәсем ясау белән күптән мавыгасыңмы?

Нәгыйм. Бала чактан. Менә минем кайбер эшләрем. (*Бирә.*)

Лира (*рәсемнәрне карап*). Матур... Су буе... Таулар... Урман... Шишкинны хәтерләтә...

Нәгыйм. Лира апа, рәсемнәрнең кай ягыдыр килешеп җитми шикелле, үзем белмим. Киңәш сорарга беркем юк. Мәктәптә аннан-моннан гына өйрәттеләр. Казаннан берәр художник та килеп чыкмый.

Лира. Укыйсың киләме синең, Нәгыйм? Сәнгать училищесында?

Нәгыйм. Кая инде анда эләгергә безгә...

Лира. Әйдә иртәгә үк синең рәсемеңне Казанга училищега җибәрәбез. Сине укырга алырлар...

Нәгыйм. Шәп булыр иде, Лира апа! Укып чыксам,

яңадан сезнең янга кайтыр идем! (*Пауза.*) Ә син монда каласыңмы, Лира апа?

Лира. Нигә алай дидең, Нәгыйм?

Нәгыйм. Болай гына.

Лира. Бик яратасыңмы рәсем ясарга?

Нәгыйм. Үзем станокта деталь кырам, ә күз алдымда — төрле төстәге буяулар... Шишкин урманнары. Колак төбендә, Лира апа, сез өйрәтә башлаган музыкаль авазлар яңгырап тора. До, ре, ми, фа, соль, ля, си... Әгәр дә мин музыкант булсам, беләсезме, нишләр идем, Лира апа?

Лира. Йә?

Нәгыйм. Тагын ике музыкаль аваз өстәр идем...

Лира. Нинди авазлар?

Нәгыйм. Ли-ра.

Лира (*көлә*). Димәк, кирәк тапмаганнар.

Нәгыйм (*рәсемнәрне җыеп*). Лира апа, сезгә бер серем бар.

Лира. Әйт, Нәгыйм.

Нәгыйм (*пышылдап*). Мин Марска очарга уйлап йөрим бит.

Лира (*шаярып*). Мине дә үзең белән алырсыңмы?

Нәгыйм. Сезгә ярамый, Лира апа. Сез җирдә калыгыз.

Лира. Тагын безгә кайтырсыңмы соң?

Нәгыйм. Бәлки, кайтырмын да... Лира апа, сагынырсызмы мине?

Лира. Сагынырмын, сагынырмын...

Нәгыйм. Сер итеп кенә әйтәм: беркемгә дә әйтмәгез, яме? Җибәрмәсәләр — бөтен халык көләр.

Лира. Ярый, Нәгыйм. Иртәгә рәсемнәреңне алып кил, җибәрербез.

Нәгыйм. Рәхмәт, тыныч йокы, Лира апа!

Чыга.

Лира. Гаҗәп егет. (*Пауза. Мотоцикл тавышы.*) Ул!

Гостиницага керә. Пианист шәүләсе. Бераздан ачык тәрәзәдән Лираның җыры ишетелә.

Лира җыры*.

Карт наратлар сорый: «Төн йокламый,
Ни уйлыйсың болай, сеңелем?»

---

* Пьесадагы җырларның көйләрен композитор Мирсәет Яруллин язды.

Мин үзем дә белмим,
Нәрсә булды,
Ниләр уйлый минем күңелем.
Карт наратлар әйтә: «Җидегән йолдыз
Сүнәр инде, йокла, сеңелем...»
Минем өчен яңа йолдыз балкыр,
Юк, сүрелмәс минем күңелем.
Карт наратлар тына: «Без йоклыйбыз,
Хәерле төн сиңа, сеңелем...»
Шикләнүләр, уфтанулар белән
Үз йолдызын көтә күңелем...

**Җырның соңгы яртысында Җидегән керә, тәрәзәгә карап тыңлап тора. Җыр тәмамлангач, акрын гына тәрәзәгә чиртә.**

Лира (*тәрәзәдән башын тыгып*). Мин хәзер, Җидегән. (*Чыга.*) Тагын мотоциклың ватылдымы?

Җидегән. Нәкъ сезнең янга җиткәч, бензин бетте. Чынлап әйтәм.

Лира. Ә бездә бензин юк...

Җидегән. Кирәге дә юк... Бераз ял итим дә сөйрәп кайтырмын.

Лира. Кулыгызда тагын чүп үләннәре... Сезне юкка гына чүп үләннәре докторы дип атамыйлар икән.

Җидегән. Доктор? Чынлап. Мин туфракка операция ясамакчы булам.

Лира. Ничек туймыйсыз шулардан? Сезне бөтен бүлмәсен чүп үләннәре белән тутырган, диләр, шулаймы, Җидегән? Сез чүп үләннәренә гашыйк булдыгызмы әллә?

Җидегән. Юк, мин культура үсемлекләренә гашыйк. Чынлап. Аларны паразит чүп үләннәреннән коткарасым килә минем. Ә беләсеңме нишлиләр чүп үләннәре? Алар яктылыкка, матурлыкка омтылган үсемлекнең азык матдәсен талап алалар, кояш нурларын ышыклап, күләгә ясыйлар. Чынлап. Тыңлыйсыңмы мине? Менә кара... Менә алар... билчән, надырбаш, сарут, сырлан, бакра... тигәнәк... Чүп үләннәре булмаса, без уңышны гектарыннан 4—5 центнер артык алыр идек. Лира, син көләсең?

Лира. Әй, Җидегән... сез чүп үләннәре турында шундый илһамланып сөйлисез, әйтерсең дөньяда чәчәкләр юк...

Җидегән. Чәчәкләр! Бактерияләр, вируслар чәчәккә дә һөҗүм итәләр. Тыңлыйсыңмы? Чынлап. Аларга ирек кенә бир, аларга каршы көрәшмә генә — бөтен кырны тутыралар. Валлаһи.

**Лира.** Ә мин чәчәкләр яратам. Чәчәкләр һәм билчәннәр! Аралары нинди ерак!

**Җидегән.** Бактерияләрне, вирусларны бетергәч, мин сиңа иң саф, иң пакь, иң гүзәл чәчәкләр алып килермен.

**Лира.** Нинди озак! Миңа хәзер үк кирәк. Чәчәкләрне бик яратам.

**Җидегән.** Чүп үләннәре белән мавыгып, чәчәкләрне онытканмын. Чынлап.

**Лира.** Сез, авыл хуҗалыгы белгече булгач, сәнгатьтән дә ерак торасыздыр инде?.. Гафу итегез.

**Җидегән.** Ерак, бик ерак... Әнә... йолдызларераклыгында...

**Лира.** Ә исемегез нинди матур...

**Җидегән.** Үзем ямьсез булганга ул... Үз исемемнән үзем оялып йөрим... Нинди Җидегән инде мин...

**Лира.** Бәлки, сез пьесада уйнарсыз? Безгә бер кеше җитми.

**Җидегән.** Табигать мине бар нәрсәдән мәхрүм иткән... Ни җырлый белмим, ни бии... Студент чакта «бак-бак» дип кычкырып торырга хорга алганнар иде алуын...

**Лира.** Кызганыч.

**Җидегән.** Үзем сәләтсез булсам да, мин матур булган һәрнәрсәне яратам. Шулай мотоцикл белән кыр буйлап барам да туктап калам. Тургайлар сайрый. Рәхәт тә, сагышлы да. Чынлап! Аңлату өчен композитор булу кирәк. Ачуланмагыз, Лира, җырыгызны тыңладым. Тургай сайравын хәтерләтте.

**Лира.** Әти мине Лира-тургай дип йөртә иде.

**Җидегән.** Лира-тургай... Көтмәгәндә ничек килдегез сез монда? Ничек шәһәрдә калмадыгыз?

**Лира.** Шәһәрдә минем кебекләр буа буарлык. Әллә инде табигатьне яратканга, авылда яшисем килә минем. Ялга кайтканда һәрвакыт йөрәгем әрнеп китә иде... Авылда никадәр талантлы сәнгать көчләре! Ә алар ярдәмсезләр. Канатлары бар, ә оча алмыйлар. Без дә очарга өйрәтмәгәч, кем өйрәтсен аларны!

**Җидегән.** Син авылга лира алып килгән тургай, Лира.

**Лира.** Ни өчен сәнгать кешеләре авылда туалар да, барысы да шәһәргә китәләр икән. Ә шәһәрләшеп алгач, авылны сагынып җырлыйлар?

Җидегән. Хәзергә әле, Лира, культура үзәге — калада. Килер бер көн, аңа инде ерак түгел, безнең колхоз артистлары үзебезнең колхоз композиторы язган яңа балетны сәхнәдә күрсәтерләр.

Лира. Мин мондый сүзләрне күп ишеттем. Сүзләр әйтелә дә бетә. Ә менә ярдәм юк...

Җидегән. Активта мин бу турыда сөйләгән идем. Культура бүлегендә бер булдыксыз кеше утыра.

Лира (*кинәт*). Булдыксыз?!

Җидегән. Артта калган... Яңа күренешләрне күрә белми.

Лира (*уңайсыз хәлдә калып*). Белми?..

Җидегән. Культураның «К» хәрефен генә белә...

Лира (*усал*). Ә сез үзегез нәрсә беләсез соң?!

Җидегән (*аптырап кала*). Сез шулай усал да була беләсезмени?

Лира. Сезнең ул буш сүзләрегездән кемгә файда? Йөрәк авырулы, сәнгать өчен үлеп торган Дускаевкамы? Матурлыкка омтылган, ләкин койма уратып алган Фәүзиягәме?

Җидегән. Сез кызып киттегез. Ләкин мин сезне...

Лира. Чүп үләннәренә гашыйк агрономның йөрәкләргә, чәчәкләргә ерак булуында шигем юк!

Җидегән. Сез... сез... Хушыгыз. Мотоциклның бензины дөнья уралык!

Чыга. Мотоцикл тавышы.

Лира (*ялгыз кала. Ул Җидегән киткән якка омтылыш ясый. Башын тота*). Нәрсә әйттем мин?! Нишләдем?! (*Бер читкә барып утыра.*)

Нәгыйм керә.

Нәгыйм (*кинәт килеп кереп, акрын гына*). Лира апа, сез Җидегән абыйны яратасызмыни? (*Лира ишетми.*) Димәк, чынлап. (*Кычкырып.*) Лира апа!

Лира (*күтәрелеп*). Нәгыйм? Рәсемнәрне китердең дәмени?

Нәгыйм. Рәсемнәрне дә китермим, училищега да бармыйм, пьесага да катнашмыйм... Сез мине Айлардан эзләсәгез дә таба алмассыз. Бәхил булыгыз! (*Чыга.*)

Лира (*сикереп торып*). Нәгыйм, тукта!

Капканы ачып, Фәнәви чыга. Кулында чүкеч.

Ф ә н ә в и. Сез болай акыллы күренәсез, ир хатынын котыртмагыз, Лира апа.

Л и р а. Уйлап сөйлә, Фәнәви, уйнап сөйләмә.

Ф ә н ә в и. Уйларлык кына баш бар бездә анысы... Сезнең Фәүзиягез һаман юк...

Л и р а. Ул репетициядән соң, дуңгызлары янына китте. Хәзер кайтып җитәр.

Ф ә н ә в и. Нинди дуңгызлар белән йөридер, кем белә...

Л и р а. Фәүзиягез яңадан репетициягә йөрмәс! (*Гостиницага кереп китә. Фәнәви койма төзәтә башлый.*)

Ф ә н ә в и. Беләбез без сезнең нинди театр куеп йөрүегезне. (*Якында гына яшьләрнең җыр тавышлары.*) Һаман юк теге... Хатынсыз калдыралар инде болар бу пьесалары белән.

М и ң н у л л а керә.

М и ң н у л л а. Исән-саулыкмы, энем Фәнәви?

Ф ә н ә в и. Сине генә көтеп тора идем.

М и ң н у л л а. Миңнулланың кирәк тә булып куюы бар.

Ф ә н ә в и. Потың бер тиен.

М и ң н у л л а. Поты бер тиен генә булмас булуын, кыйммәтрәк булыр.

Ф ә н ә в и. Нәрсәнең?

М и ң н у л л а. Бодайның...

Ф ә н ә в и. Кирәкме әллә?

М и ң н у л л а. Кирәк. Түлке акчалата түгел...

Ф ә н ә в и. Нәрсә бирәсең?

М и ң н у л л а. Баллата.

Ф ә н ә в и. Бал күп синең, төн карачкысы, ә? Сатасың да сатасың? Бездән бай яшисең. Оештыр миңа бер биш оя корт.

М и ң н у л л а. Миңа нәрсә?

Ф ә н ә в и. Бодай.

М и ң н у л л а (*башын кашып*). Уйлап карарбыз.

Ф ә н ә в и. Уйлап-нитеп торасы юк. Мә бишне!

М и ң н у л л а. Кәнкрит сөйләшербез.

Ф ә н ә в и. Хатын кайтканчы тиз бул. Уйлап баш катырма. Мә бишне! (*Кыса.*)

М и ң н у л л а. Ун булсын!

Ф ә н ә в и. Иртәгә килерсең.

М и ң н у л л а (*куеныннан капчык чыгарып*). Миңа бир инде бераз хәзер үк. Өйдә кеше көтеп тора.

Ф ә н ә в и. Кем?

Миңнулла. Беткәнмени дөньяда әрәмтамак.

Фәнәви. Бетмәгән шул менә. Бир капчыгыңны! Сөял коймага! (*Кереп китә.*)

Миңнулла (*сөяләә*). Кәкре каенга сөямәсен бу... Бүген үк кәнкрит сүләшеп, ташып куярга кирәк. (*Эт өрә башлый.*) Чәбә, чәбә, тәмуг кисәве. Чабудан тартырга гына торалар.

Фәнәви (*ярты капчык бодай күтәреп чыга*). Китер җилкәңне...

Миңнулла (*күтәреп*). Пачаму аз салдың?

Фәнәви. Моны да күтәрәлмәссең дигән идем. Эшкә булса, бил сызлый дисең...

Миңнулла (*авыр күтәргән булып*). Авыр икән шул... Хуш. Умарталарны бүген китерә башлармын. Кайгырма. Үзем. Җәмәйгә яртыны гына утыртам.

Фәнәви. Тукта әле. Нишләтәсең бу бодайны?

Миңнулла. Син нишләттең, мин дә шулай эшләтәм, Алла бирсә.

Фәнәви. Сатасың... Менә сиңа мулла...

Миңнулла. Хәзерге заман мулласына килешә ул, энем... (*Чыга башлый.*)

Фәнәви (*ачулы*). Килешә! (*Капка төзәтә.*)

Фәүзия керә. Кулында дәфтәр. Миңнулла белән бәрелешә.

Фәүзия. Әбәү, мәхәббәтсез.

Миңнулла. Әбәү, мәхәббәтле... (*Чыга.*)

Фәүзия. Фәнәви, нәрсә күтәргән ул?

Фәнәви эндәшми.

Фәнәви, капка ватылдымыни?

Фәнәви. Капка ватылуы бернәрсә дә түгел, ә менә йөрәк ватылса... (*Кинәт әйләнеп.*) Кайда йөрдең?

Фәүзия. Репетициядә...

Фәнәви. Репетиция бетүгә бишбылтыр... Лира апа да әллә кайчан кайтты.

Фәүзия. Аннан соң дуңгызларны карап килдем.

Фәнәви (*җыр тавышы килгән якка күрсәтеп*). Әллә син әллә кемнәр белән үбешеп йөргәнсең, кем белә.

Фәүзия. Кит аннан, Фәнәви, нәрсә сөйлисең...

Фәнәви. Сөйләмәссең монда... Сыер кайтты — син юк. Сарыклар бәәлдәп йөри — син юк. Ярый, ашарга пешереп куйгансың... Күңелең әллә кайда, өйдә түгел. Кеше

печән әзерли, корт карый... син чикерткә шикелле бушка биеп йөрисең. Сукыр бер тиен дә бирмиләр үзләре...

Фәүзия. Кара, нишләвең бу, Фәнәви? Сыерны да саумый калдырганым, малларны да карамый калганым юк. Фермада көн буе чабам. Тик торганым бармы?..

Фәнәви. Синең сүзгә карап, әти-әнидән аерылып чыктым.

Фәүзия. Бозалар бит алар сине... Алар кубызына бии башладың. Эх, синме бу, Фәнәви?

Фәнәви. Шулай була ул. Юлдашлар белән юлдан язып йөрсәң, иреңне дә танымыйсың... Тот агачның башыннан. Әллә... лә. Шундый вакытта чүкече дә дошманга әйләнә... Ул Юлдашыгызның йөзендә иман нуры юк. Күзләре «Бер чиләк су белән йотам» дип тора. Йортның астын-өскә китереп бетерәбез инде. Юньле кешеләр әнә корт карыйлар. Егерме башлап умарталары бар.

Фәүзия (*ачуына чыдаша алмыйча, агачны читкә этәрә*). Мә агачыңны... тотмыйм.

Фәнәви (*үзгәреп*). Фәүзия... Фәүзия...

Фәүзия. Йорт, сыер, бакча дип, дөньяны онытабыз инде.

Фәнәви. Тагын нәрсә кирәк сиңа. Сыеры да, балы да, акчасы да күңелле киләчәк өчен...

Фәүзия. Мине мондый киләчәк кызыктырмый. Минем хыялым бар. Минем артистка буласым килә. Минем укыйсым килә.

Фәнәви. Шул гына калган ди тагын. Дуңгыз каравыңны бел. Мәктәптә шуңа өйрәттеләр.

Фәүзия. Берәү дә, гомер буе урта белемле булып кал, дип закон язмаган. Ике ел әйбәт кенә эшләдем. Яренгә театр институтына китәм!

Фәнәви. Ә мин?

Фәүзия. Соң... бергә китик. Син бит кайчандыр хыяллана белә идең. Исеңдәме, инженер-техник булам, дигәнең? Әнә колхозга инженер көтәләр.

Фәнәви. Китәргә? Йорт-җирне ташлапмы? Тәрәзәне кадаклапмы?

Фәүзия. Кош та оясына кире кайта. Мин артистка булып, үзебезнең театрга, ә син механик булып колхозга кайтырбыз.

Фәнәви. Артистка булмыйсың. Бетте-китте! Кем эләгә шуның белән үбешкәнеңне карап утырыргамы? Чегән кебек авылдан авылга күчеп йөрергәме? Йортны ташлап...

Артистка да булдымы эш! Техника заманасы. Мин әйтмим, Рамазан абый әйтә...

Ф ә ү з и я (*агач төбенә утыра*). Шайтан котыртамы әллә, Фәнәви, болай түгел иең. Бар ие гөрләп торган чаклар! Исеңдәме клубтагы бер кичә... син өзелеп-өзелеп гармун уйнадың... мин җырладым. (*Рояль авазлары ишетелә.*) Кичәдән соң без икәү генә, ояла-ояла, болынга чыгып киттек...

Сәхнә акрын гына караңгылана. Күренеш үзгәрә. Урман. Таулар. Чишмә буе. Ф ә н ә в и белән Ф ә ү з и я керәләр.

Ф ә н ә в и.

Китик,
Кулга-кул тотышып,
Еракларга китик, Фәүзия,
Таң-таң атсын,
Яшьлек таңнарын да
Бергә-бергә үтик, Фәүзия.

Ф ә ү з и я.

Бар табигать бүген җырлый кебек,
Тирәкләрдә кошлар уяна.
Унҗидедә канатланган яшьлек
Килер матурлыгын уйлана.
Хыял якын,
Хыял шундый якын,
Ул сиңа да таныш хис микән?
Киләчәкнең, шушы чишмә кебек,
Чылтырап килүләрен ишетәм.

Ф ә н ә в и.

Без бүгеннән башлап ирекле ләр,
Классларда калды балачак,
Синең исемең хәзер балачактан
Яшьлегемә күчеп калачак.
Күпме йөрдек, бергә укысак та,
Хатлар белән генә сөйләшеп.
Мин беренче тапкыр,
Хатсыз гына
Әйтәм,— «Фәүзиякәй, сөям», дип.

Ф ә ү з и я (*яулыгы белән күзләрен каплый*).

Ә мин... Әйтә алмыйм...
Фәнәви...

Ә мин... юк, юк...
Әйтә алмыйм... оялам...

**Фәнәви.**

Беркем дә юк...
Ай да,
Сизгән кебек,
Тау артына китеп югалган.

**Фәүзия.**

Тал-тирәктә әнә бер кош сайрый,
Минем хисне ул кош сөйләсен.

**Фәнәви.**

Фәүзиякәй, кайчак куркып куям,
Сине башка берәү сөймәсен...
Син минеке...
Мәңге минеке бул,
Ят карашлар «сөям» димәсен.

**Фәүзия.**

Үзем әйтәм... Кошлар аңлаталмас,
Кош кош инде, сайрый, сөйләми...
Нигә ятлар миңа, табигатем
Синнән башкаларны теләми.

**Фәнәви** (*кесәсеннән дәфтәр алып*).

Мин шагыйрь дә һәм рәссам да түгел,
Ал, Фәүзия,
Бу дәфтәрем — сиңа истәлек.
Җырлар... чәчәк... гөлләр,
Яшьлек булсын
Җырлы-гөлле юлдан үтәрлек.

(*Җирдән ут чәчәген өзеп алып.*)

Менә чәчәк...
Шушы чәчәк кебек
Балкып, янып торсын киләчәк.

**Фәүзия.**

Янар чәчәк!..

(*Дәфтәрнең беренче битен укый.*)

Бар матурлык белән яшьлек килә,
Алып килә,

Сөю-сөелү,
сагыну,
сынаулар.
Яратулар,
бүгенгедәй таң атулар булыр,
Ләкин булмас салкын кыраулар.
Рәхмәт, Фәнәви...
Авырлыклар булса, тормышымда
Алырмын да яшьлек дәфтәрен,
Әйткән сүзләреңне искә төшереп,
«Фәнәви!» дип сиңа дәшәрмен.
Син ризамы?

Фәнәви.

Риза!
Китик,
Кулга-кул тотышып,
Тауга каршы китик, Фәүзия.
Таң-таң атсын,
Яшьлек таңнарын да
Бергә-бергә үтик, Фәүзия.

Тауларга таба китеп югалалар. Караңгы. Рояль уйный. Сәхнә яктыра. Фәнәви башын иеп уйга калган.

Фәүзия. Менә без тауларга килеп җиттек. Ә син шул тауларга менә башлагач кына нинди үзгәрдең, Фәнәви. Өйне коймалар белән уратып алдың. Барысы да сиңа гына, үзеңә генә... Өйдән үзеңне трактор белән дә сөйрәп алып чыгып булмый. Кайда ул янар чәчәк?! Кайда ул гармун моңнары?

Фәнәви (*әсәрләнеп*). Артыгын сөйләмә, Фәүзия. Мин бит синең өчен тырышам. Мин сине әүвәлгечә яратам. Сине бәхетле итәсем килә. Сине әллә кем тартып алыр сыман. Шуңа көнләшәм. Дусларымнан да көнләшәм. (*Фәүзиянең чәченнән сыйпап.*) Бар, бар, Фәүзия, тынычлан, сыерны сау. Койманы үзем төзәтермен.

Фәүзия. Җүләр, җүләр... Әйбәт кенә яшәр чак инде. (*Өйгә кереп чыга.*) Репетициягә бергә барыйк, яме, Фәнәви...

Фәнәви. Ярар, карарбыз.

Фәүзия. Кинога да барырбыз, яме, Фәнәвикәем.

Фәнәви. Болай булгач, бармый булмас инде.

Фәүзия. Репетициягә дә бергә барабыз, яме, Фәнәвикәем.

Ф ә н ә в и. Нишлисең — хәлең юк...
Ф ә ү з и я. Мин сыер савам, Фәнәви.

Йөгереп кереп китә. Бераз тынлык.

М и ң н у л л а т а в ы ш ы. Умарталарны чыгып ал!
Ф ә ү з и я (*чыгып*). Кем ул төн уртасында сөрән сала?
М и ң н у л л а т а в ы ш ы. Умарталарны чыгып ал!
Ф ә н ә в и. Умарталар? Әйдә, чыктык!
Ф ә ү з и я. Кайда? Нигә?
Ф ә н ә в и. Бер план бар, Фәүзия.
Ф ә ү з и я. Нинди план ул тагын?
Ф ә н ә в и. Тагын да, тагын да баерак яшәү планы. Әнә бакча, анда җиләк-җимеш утыртабыз. Син ап-ак күлмәгеңне киеп, җырлый-җырлый җиләк җыясың. Ишегалдында хайванның, кош-кортның хисабы юк... Сыер, ат, сарык, дуңгыз, күркә... һ.б., һ.б. Ә мин битлек кигәнмен. Кортлар карыйм. Берзаман кортлар аера башлый, ун баш, егерме баш, утыз... Миллионлаган кортлар сиңа, миңа чәчәкләрдән бал җыеп түгел, акча җыеп йөриләр. Җиләк җыела, бал суыртыла. Без «Москвич»ка утырып базарга китәбез... Син дә, мин дә бәхетлеләр. Башкалар безнең бәхеттән көнләшәләр... Әнә инде безгә бәхет үзе кычкырып тора...
М и ң н у л л а т а в ы ш ы. Фәнәви!.. Умарталарны чыгып ал!
Ф ә н ә в и. Әйдә, Фәүзия, умарталарны урнаштырыйк.
Ф ә ү з и я (*катгый*). Юк! Мин чыкмыйм. Мин мондый бәхеттән риза түгел.
Ф ә н ә в и. Чыкмыйсың, риза түгелсең? Юк, риза булырсың, син минем хатыным.
Ф ә ү з и я. Минем бәхетсез ирнең бәхетсез хатыны буласым килми.
Ф ә н ә в и. Ә, шулаймы?! Буласың килмиме? Бар алай булса, күземә күренмә! Бар Юлдашларың янына! Кайтып керәсе булма! Үзем дә яшәрмен!
Ф ә ү з и я. Фәнәви, ач күзеңне!
М и ң н у л л а т а в ы ш ы. Чыгып ал!
Ф ә н ә в и. Үзем дә яшәрмен... Мә, дәфтәреңне дә алып кит!..

Истәлек дәфтәрен ыргыта да тавыш килгән якка китә.

Ф ә ү з и я (*дәфтәргә карый. Дәфтәр өстендә кипкән*

*чәчәк ята. Дәфтәрне һәм чәчәкне алып*). Чәчәк... кипкән... Сау бул, Фәнәви... Лира апа... (*Лираның тәрәзәсе янына килә. Аннан ишетелгән музыканы тыңлап тора.*)

Лира җыры.

Карт наратлар сорый: «Төн йокламый
Ни уйлыйсың болай, сеңелем?»
Мин үзем дә белмим, нәрсә булды,
Ниләр уйлый минем күңелем.

Фәүзия (*тәрәзәгә чиртә*). Лира апа!
Лира (*тәрәзәне ачып*). Ни булды, Фәүзия?
Фәүзия. Гостиницада миңа да урын бармы?
Лира. Әйдә, Фәүзия, (*Фәүзия кереп югала.*)

Фәнәви керә. Караңгы. Фәүзияне эзли.

Фәнәви. Фәүзия! Фәүзия дим! (*Капканы ачып керә.*) Фәүзия!..

Миңнулла белән Җәмәй керә.

Миңнулла. Бәхеткә каршы, лампочкасы да сүнгән.
Җәмәй. Бер яртыны тондырсаң яктыра ул. Давай, чыгар мөгәричне, мин сиңа Миңнулла булганың өчен ат бирмәдем, Фәнәви өчен...
Миңнулла. Ашыкма, эшне бетерик әле. Бодайны ташып куйыйк.
Җәмәй. Юк инде, башта куеп сөйләш.Ату шаг та атламыйм.
Миңнулла. Куярмын, җаным, куярмын. Тагын беразга түз. (*Капканы ачарга маташа. Эт өрә.*) Чалбар төбен генә умырмаса ярар иде, ләгънәт!
Җәмәй. Умыра бирсен. Сиңа нәрсә, чалбар төбе булды ни, булмады ни.
Миңнулла. Бәтәриең юкмы? Кабыз әле.
Җәмәй. Менә тәмәке кабыздым.
Миңнулла. Кая соң үзе... Фәнәви...
Фәнәви (*капканы ачып*). Фәүзия?!
Миңнулла. Без әле бу, җаным.
Җәмәй. Мин дә монда, Фәнәви дус!
Фәнәви. Нәрсә кирәк?
Миңнулла. Кара, кара... оныттыңмы әллә? Бодай кирәк. Менә капчыклар да үземнеке...

Җ ә м ә й. Давай мәгәричне, күп сайрама.

Ф ә н ә в и. Сызыгыз моннан исән чакта!

М и ң н у л л а. Шаярып маташма инде.

Ф ә н ә в и (*аның кулыннан капчыкларны тартып алып бәргәләп чыгара*). Күземә күренмә! Умарталарың белән чәнчелеп кит!

М и ң н у л л а (*чыгып кача*). Каравыл, талыйлар!

Җ ә м ә й (*кычкырып көлеп тора*). Ну шәп бирдең, Фәнәви!

Ф ә н ә в и. Сиңа ни калды монда? Нигә килдең?

Җ ә м ә й. Мин Миңнуллага түгел, атны сиңа дип бирдем.

Ф ә н ә в и. Кирәкми миңа бернәрсә дә... (*Җәмәйне куалап чыгара.*) Миңа Фәүзия кирәк! (*Кычкыра.*) Фәүзия!!!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### III КҮРЕНЕШ

**Колхоз председателе бүлмәсе. Ю л д а ш председатель өстәленә микрофон куеп йөри. Җ ә м ә й кереп, стена буена чүгәли, папирос кабыза.**

Җ ә м ә й. Кая теге?

Ю л д а ш. Һа! Кызлар начальнигы! Монда чүгәләргә һәм тартырга ярамый. (*Язуны күрсәтә.*)

Җ ә м ә й. Һай! Тиле әйткәндәй, нәрсә генә язмыйлар! Менә син дә, Юлдаш, кәгазь әрәм итеп йөрисең... Минем сурәтне гәзиткә күпме төшердең... Һич төзәлергә исәп юк, тиле әйтмешли. Тире калын, тире! Үтми! Алты тапкыр рәсемне стенага сыладыгыз, алты! (*Кеткелди.*)

Ю л д а ш. Алты кат тиреңә җиттек, җиде кат тиреңә җиткәч, үтәр!

Җ ә м ә й. Күз йомып алдыйсың, парень. Мине сәнәк белән ике яктан терәтеп куеп төшергәнсең... Алай булмады, парень. Болай булды... Салдым, егылганмын; кызлар, җаннарым, аккош канаты кебек куллары белән күтәреп алганнар да ике дуңгыз арасына терәтеп куйганнар. Ә син алдама!

Ю л д а ш. Җиденчесендә дөресен язарбыз.

Җ ә м ә й. Аннан килеп... мине ялкау, дисез инде... Кемнән ким? Хезмәт көне барамы, бара. Җәмәй саламы,

сала! Нигә сала? Шуның өчен — хезмәт көненә акча бирәләр. Аннан килеп, ялкау булмый хәлең юк... Кызлар җимертеп эшли! Кызлар — муеннан; Җәмәй — берәү! Теге әйтмешли (*өстәленә күрсәтеп*), атом заманасы! Элек тәмәкене үзебез бакчада үстерәдер иек. Хәзер, пажалысты, төреп тә торасы юк... Ал да кап авызыңа! Кайда соң теге?

Юлдаш. Техника дип җенләнеп йөри.

Җәмәй. Дөрес итә! Мин дә шуңа килгән ием. Туры айгырдан котылырга кирәк. Нигә? Авызында әзрәк хәмер исе сиздеме, дулый да чокырга илтеп тондыра, хайван! Бозылуның ар ягына чыкты. Фермага бер машина кирәк, парень! Фермага бит! Бирер микән?

Юлдаш. Ник бирмәскә? Тик сиңа самосвал бирергә кирәк.

Җәмәй. Анысына да риза. Ә нигә?

Юлдаш. Кайвакытта өеңә кайтып җитәлмисең. Андый чакта сине самосвалга саласың да хатыныңның кайнар кочагына илтеп аударасың...

Җәмәй. Алай булгач, миңа монысы кирәкми, тегесе кирәк... Машиналы булсам, Фәнәвине шофер итеп алам. Күренмәдеме үзе? Әйткән нәзерен түләп бетерми. «Фәүзияле булсам, үлгәнче бер сыйлыйм»,— дигән сүзе бар егетнең. Сыйлады, кәнишне, үлгәнче түгел. Син дә килгәлә фермага, парень... Айдагы Зөһрәдән дә чибәррәк берәрсен тоттырып җибәрермен.

Юлдаш. Миңа дигән кыз әнә... (*Тәрәзәгә күрсәтә.*)

Җәмәй. Кайда? (*Карый.*)

Юлдаш. Айда.

Җәмәй (*ктткелди*). Буең җитмәгән җиргә үреләсең. Миңа кил син... Бер сызгыра гына Җәмәй, пажалысты, җаның кемне тели...

Фәүзия (*йөгереп керә*). Юлдаш, Рамазан абый күренмәдеме?

Юлдаш. Юк, Фәнәви дә күренмәде. Бүген репетиция, Фәүзия!

Фәүзия. Аның кайгысымыни, ут йотып йөрим...

Җәмәй. Андый чакта, тиле әйтмешли, су йотарга кирәк. (*Фәүзия Җәмәйгә усал караш ташлый.*) Бетте... бетте, Фәүзиякәем... Хәзер китәм. Тәмәке тартырга гына кергән идем. Фәүзия, кичә сезгә умарта китергән иек. Фәнәви куып чыгарды. Сиңа сөйләнмәдеме, минем муен тамырына чынлап эләктерде микән, әллә ялгыш кынамы?

Ф ә ү з и я (*шатланып*). Сөйләде.

Җ ә м ә й. Юри генә диме?

Ф ә ү з и я. Чынлап, ди, әле әзрәк эләкте, ди. Очрасын гына, ди. (*Чыга.*)

Н ә г ы й м керә.

Н ә г ы й м. Җәләев абый кайда?

Ю л д а ш. Басуда. Ә Лира район үзәгеннән кайтып җитмәде.

Н ә г ы й м. Лира апа?..

Ю л д а ш. Бүген репетиция, Нәгыйм.

Н ә г ы й м. Репетиция кайгысымыни...

Ю л д а ш. Гашыйк булдыңмы әллә?

Н ә г ы й м. Юк ла... каян беләсең?

Җ ә м ә й (*бармагын төртеп*). Әһә... тотылды.

Н ә г ы й м (*кулын йодрыклап*). Тәрәзәдән тондырам!

Җ ә м ә й. Юк, юк, тотылмадың, Нәгыймкәем...

Н ә г ы й м. Монда Ай тотылырга тора, ә сез... сез җансызлар.

Җ и д е г ә н керә. Кулында ут чәчәге.

Җ и д е г ә н. Лира юкмы монда?

Җ ә м ә й. Бетте... бетте... китәм, хәзер. (*Ычкына.*)

Н ә г ы й м. Миңа ул түгел, председатель кирәк! (*Чыга.*)

Ю л д а ш. О! Ни күрәм... Чүп үләннәре урынына чәчәк! Кызык!

Җ и д е г ә н. Кызык түгел шул, Юлдаш...

Ю л д а ш. Ә нинди чәчәк бу?

Җ и д е г ә н. Ут чәчәге...

Ю л д а ш. Ут кебек янып тора!

Җ и д е г ә н. Әгәр аны суга куйсаң, ул тагын да кызарып яначак. (*Председатель өстәленә стаканга куя.*)

Ю л д а ш.

Сулар сипсәң дә басылмый
Янган йөрәк ялкыны...

Җ и д е г ә н. Чүп үләннәре докторына кая инде аны аңларга? (*Чыга.*)

Ю л д а ш. Нишләгәннәр болар? Корт иле аерганмыни...

Р а м а з а н ашыгып кайтып керә. Чәчәкне күрә.

Р а м а з а н. Кем эше бу? (*Төрле яктан карый.*) Син куйдыңмы?

Ю л д а ш. Аны мин куймадым.

Р а м а з а н. Бу нинди тәртипсезлек!

Ю л д а ш. Мин үзем дә абайламый калдым, борылып карадым — зәп-зәңгәр яулыкның һәм шул чәчәк шикелле кызыл күлмәкнең җилфердәвен генә күреп калдым.

Р а м а з а н. Йә, микрофон әзерме?

Ю л д а ш. Микрофоны бераз искергән, иптәш Җәләев. Шулай да наряд бирергә генә була.

Р а м а з а н. Ә син тап, әкәмәт! Яңаны куй!

Ю л д а ш. Иске бүлмәгә иске микрофон да ярап торыр.

Р а м а з а н (*төрттерүне аңлап алып*). Син шәйләп сөйлә. (*Пауза.*) Иптәш Юлдаш, соңгы вакытта башка төрле уйлар килә башлады. Хуш, колхоз автоматлаша бара. Ни өчен дигәндә, алга барабыз. Автоматны без кешенең хезмәтен җиңеләйтү өчен кертәбез. Мин колхозга техника кертү өчен күпме көч түктем. Минем эшнең авырлыгын үзең беләсең. Ә нигә председательнең эшен җиңеләйтү турында уйламаска!

Ю л д а ш. Үзем дә соңгы төннәрдә гел шуны уйлап йоклыйм.

Р а м а з а н. Йоклау дигәннән, бүген төнлә бер төш күрдем әле. Якын кил.

Ю л д а ш. Йә, йә, иптәш Җәләев.

Р а м а з а н. Коммунизмга җиткәнмен, имеш. Беркем сукми, беркем тиргәми. Үзем председатель, үзем өйдә наряд биреп кенә ятам, әкәмәт. Ни өчен дигәндә, өстәлдә телевизор утыра. Бөтен кыр уч төбендәге кебек, имеш. Кнопкага басам: тракторлар үзләре җир сөреп йөри. Синең әлеге дә баягы шушы микрофоның да өстәлгә килгән. Телевизордан карыйм да кычкырам микрофонга, 1 нче бригада фәлән эшкә, 3 нче бригада тегән эшкә. Телевизорны фермага күчерәм, әкәмәтство! «Җәмәй, син нәрсә анда дуңгыз кебек хырылдап ятасың, тор!» Уянып китсәм, әкәмәт, телевизор да, микрофон да юк, янымда Мәһирә апаң гырылдап ята... (*Көлә.*) Адәм көлкесе!

Ю л д а ш. Бүген йоклаганда шул төшнең дәвамы керсә, телевизордан ныклабрак кара әле, иптәш Җәләев, фермада культура эшләре ничек икән?

Р а м а з а н. Шаян кеше булып чыктың син, әкәмәт. Ферма дигәннән, кичә ферма турында сүз булды. Бу яңа секретарь ошыймы сиңа, Юлдаш, әйт әле.

Ю л д а ш. Әллә ни кырганы юк әле.

Р а м а з а н. Шул шул. Иске секретарь шәп иде. Каршы бер сүз әйтмәс иде, мин нәрсә әйтсәм дә, «әйе, шулай, дөрес» дип җөпләп кенә торыр иде. Баш бармак кебек иде!

Ю л д а ш. Берәү, итеге тишелеп, итекчегә барган икән. Итекче әйткән: «Иртәгә килеп алырсың, итегең баш бармак кебек булыр»,— дигән. Килгән бу мескен иртәгесен. Алган итекне дә киткән киеп. Бераз гына барган икән —итектән баш бармагы килгән дә чыккан. (*Рамазан көлә-көлә тыңлый.*) Менә шуның кебек булды инде синең үз кешең...

Р а м а з а н. Син шәйләп, әкәмәт! Шулай да син миңа бик ошап киттең әле, Юлдаш. Пьеса яздым диген, ә? Мине халык массасына күрсәтәм диген... Молодец, энекәш! Күтәрәм мин сине, иң почетлы эшкә күтәрәм...

Ю л д а ш (*микрофонны тотып*). Искергән бу. Кайбер винтикларны алмаштырмыйча булмый. Ярый, мин радиоузелга чыгам. (*Чыга.*)

Л и р а керә, аның кулында картиналар.

Р а м а з а н (*бик җылы каршы, алып*). О! Лира. Рәхим ит. Бик сирәк күренәсең Рамазан абыеңа.

Л и р а. Район үзәгеннән кайтып килешем. (*Чәчәкне күреп.*) Чәчәк! Ут кебек яна!

Р а м а з а н. Ял итә-итә эшләргә кирәк, Лира. Нигә кушмаган эш артыннан чабарга.

Л и р а. Картиналар алып кайттым. Галерея оештырырга художниклар союзы да ярдәм итәргә уйлый. Менә алардан хат алдым.

Р а м а з а н. Коллекция җыям диген, ә? Яшь чакта була торган хәл. Гостиница стенасын бизәргә уйлыйсыңмы?

Л и р а. Үзем өчен түгел. Менә карагыз, Рамазан абый... Репин, Суриков, Перов, Крамской, Айвазовский.

Р а м а з а н. Әкәмәт икән... Колхозчыларгамыни бу?

Л и р а. Үз колхозчыларыгызны начар беләсез, Рамазан абый... Сезнең колхозыгызда менә дигән талантлар бар!

Р а м а з а н. Талантлар эш белән мәшгуль, аларның вакытлары юк, Лира сеңелем! Икенче мәсьәлә — техника. Техника, автоматизация өчен җанымны бирәм. Нигә дигәндә, атом заманасы...

Л и р а. Атом заманасында һәрберебезнең гомуми культурасы булырга тиеш. Карагыз бу картиналарга, Рамазан абый. Кешелек дөньясы нинди генә җәүһәрләр иҗат

итмәгән! Юк, сез җентекләп, рухланып карагыз. Менә табигать җырчысы Левитан... «Март». Кешенең күңелендә нинди гүзәл тойгылар уята ул! Яз... Ишегалдында җигүле ат... Картинада кеше юк, ә ул — табигатьнең хуҗасы, сизелеп тора.

Р а м а з а н. Бүгенге тормыштан артта калган художник икән, әкәмәт. Ни өчен ат? Ни өчен машина түгел?

Л и р а. Рамазан абый, Левитан XIX гасырда яшәгән.

Р а м а з а н. Шулай булгач, нигә баш катырасың? Бүгенге көн турында кем уйлар?

Л и р а. Браво, Рамазан абый. Икенче баруда, әгәр тагын акча бирсәгез, мин бүгенге көн художникларының әсәрләрен алып кайтырмын.

Р а м а з а н. Акча?! Менә кәмит! Мин сиңа рәсем алырга акча бирмәдем.

Л и р а. Мин аны концерт куеп алган акчаларга алдым. Җитмәгәч, үзем өстәдем.

Р а м а з а н. Йә, әйт, нинди кеше син? Болай булмый. Юк өчен үз акчаңны түлисең... Әтиең эшләсен әнә, әтиең уйласын!

Л и р а. Ә мин сездән акча сорарга килгән идем. Оркестр оештырырга уйлыйбыз. Музыкаль инструментлар... Рояль...

Р а м а з а н. Ниятегез яхшы. Кирәктер. Ләкин колхозның төп эше — хуҗалык, техника. Сельсоветтан сорагыз.

Л и р а. Авыл советы сезгә җибәрде.

Р а м а з а н. Кая ыргыласың син, Лира? Ну, ярый, күрсәт кино. Ни өчен районда башкалар эшләмәгәнне куптарырга. Сәнгать ул, Лира, колхозда синең өчен генә сәнгать... Без — материалистлар.

Л и р а. Материалистлар сәнгатькә зур ихтирам белән карыйлар!

Р а м а з а н. Шәһәр өчен ул...

Л и р а. Рамазан абый, Рамазан абый... Ә мин сезгә бүләк алып кайткан булам тагы...

Р а м а з а н. Нинди бүләк ул?

Л и р а. Мин сезгә, сәнгатьне аңлаучы кеше дип, менә нәрсә алып кайткан идем. (*Венера Милосская статуэткасын өстәлгә куя.*)

Р а м а з а н (*чигенеп*). Син нәрсә, мине мыскыл итәсең?..

Л и р а. Ничек? Мыскыл итәм?

Р а м а з а н. Әтиеңә әйтәм, әкәмәт. Ничек оялмыйсың?

Л и р а. Сез... Сез...

Р а м а з а н. Ялангач хатын-кыз сыны... Кеше күрмәсен. Адәм көлкесенә калдырырсың...

Л и р а. Мин аны колхозчыларга күрсәтү өчен алып кайттым.

Р а м а з а н. Кәмит! Клубка куясыңмы шуны! Бөтен дөнья кубар.

Л и р а. Мин аны сезнең өстәлегезгә куям!

Р а м а з а н. Зинһар, шундый күңелсезлек эшләмә, Лира. Бала булма. Җитмәсә, син аның кайтканда кулларын сындыргансың.

Л и р а (*көлә*). Елыйсы урында көләсе килә... Дөнья сәнгатенең шедевры Венера Милосская статуясы бу, Рамазан абый. Безнең эрага кадәр үк антик культура иҗат иткән әсәр. Ә аны узган гасырда гына җир астыннан тапканнар. Табылганда ук куллары булмаган аның, Рамазан абый. Карагыз сез аның гүзәллегенә! Скульптор ташны җанландырган. Ул сулыш алып тора кебек. Кешенең гүзәллегенә, сафлыгына, гадилегенә дан җырлый ул! Сездә шундый хис тумыймы, Рамазан абый...

Р а м а з а н. Һич тумый, әкәмәт. Монда колхозчыда хатын-кыз гәүдәсе белән кызыксыну һәм башка шуңа охшашлы хисләр уянуы ихтимал.

Л и р а. Мин аны кайткач яшьләргә күрсәттем. Яныннан китмичә сокланып карап тордылар. Бигрәк тә Фәүзия, Нәгыйм...

Р а м а з а н. Менә әйттем бит. Бозма яшьләрне, Лира! Әтиеңә әйтәм. Миннән, әтиең кебек кешедән көлмә!

Л и р а. Йә, нишләргә соң инде миңа?

Р а м а з а н. Бу... кемне, Венераңны, калдырып тор. Мин ялгыз калгач уйлап карармын... Ә син, Лира, әтиеңнең дусты буларак әйтәм, әллә кайда, әллә кайчан табылган гарип таш курчакны күтәреп йөрмә. Югыйсә «бу кеше акыллы микән» дигән һәм шуңа охшашлы башка хисләр уянуы ихтимал.

Л и р а. Сез дә, хуҗа кеше дә, аңламагач, нишләргә инде миңа?! (*Яшьләрен сөртә.*)

Р а м а з а н. Чү! Елый күрмә! Лира... Авызыңа су кап. (*Су бирә.*)

Ж и д е г ә н (*керә*). Исәнмесез? (*Лираны күреп.*) Ни булды?

Р а м а з а н. Вак-төяк, әкәмәт. Миндә гаеп юк. (*Статуэтканы яшерә.*) Ул... бу... ни.

Л и р а. Мин эшли алмыйм... Булмый...

Р а м а з а н. Шулай диген...

Лира. Минем хыялларым чыннан да җимерелдемени соң? Хәтта эти дә ярдәм итми... (*Йөгереп чыгып китә.*)

Рамазан. Адәм көлкесе!

Җидегән. Лирага ни булган?

Рамазан. Акылдан язган дип әйтимме, әкәмәт. Уттай кызу эш өстендә, кеше техника, техника дип ах килеп йөргәндә, ул рәсем, ташкурчак һәм шуңа охшашлы вак-төякләр белән баш катырып йөри. Ярый, пьесасын куярга рөхсәт! Ә оркестр! Галерея, диме? Тагын нәрсәләр...

Җидегән. Әйтегез әле, ни өчен байыйбыз без?

Рамазан. Бу соравыңны минем беренче класстагы малаема бир!

Җидегән. Колхозчылар экономиканы күтәрү өчен нигә көрәшәләр? Яхшы ашау, яхшы киенү өчен генәме? Юк, алар матур яшәргә омтылалар. Яшьләр музыка, диләр, сәнгать диләр...

Рамазан. Җырлап-биеп яшәргә мин дә яратамдыр, бәлки? Әмма дә ләкин комбайнчы да, савымчы да клубта таңга кадәр биеп йөрсәләр, колхозда кем эшләр? Ә? Болай да яшьләр шәһәргә таярга гына торалар. Хезмәтне ярату дигән кодрәт кенә тота аларны. Яшь күңелне җыр-музыка белән эштән биздерү — бик җиңел. «Мин талантлы» дип, китте-барды шәһәргә... Башта берсе, аннан икенчесе... Менә сиңа — оркестр! Колхоз сәнгать кадрлары әзерләми, безгә саф механизаторлар, техник прогресс турында уйлаучы яшьләр кирәк! Игътибар — шуларга!

Җидегән. Берьяклы юнәлештә генә үссәк, яшьләр шәһәргә китә бирерләр, китмәгәннәре — ял вакытларында эчәргә тотынырлар... Рухи тормышка игътибарны киметсәк, бу — производство күрсәткечләренә дә сугачак. Безгә яшьләрнең таләпләренә төкереп карарга ярамый!

Рамазан. Чамалап сөйләшегез.

Җидегән. Моны ничек, кисәтү дип аңларгамы?

Рамазан. Ни өчен дисәң, башың яшь... Мине бүрек белән бәреп егып булмый. Кичә дә җыелышта сез ул сүзне еш кулландыгыз. Бераз культуралы була белергә кирәк. Нәрсә, сезгә председатель урынына Габдулла Тукайны яки Пушкинны утыртып куярга кирәкме?

Җидегән. Һич кирәкми. Безгә киләчәкнең Пушкиннарын, Тукайларын аңларга һәм аларга ярдәм итәргә генә кирәк. Әйтергә оят, Каен авылындагы клубны ябып, бәрәңге базына әйләндергәнсез.

Р а м а з а н. Нәрсә син, колхозчыны, бәрәңге ашатмыйча, клубта биетеп тотар идеңмени! Тукай әйтмешли, «Әй бәрәңге, вай бәрәңге, һай бәрәңге җанашым!..»

Җ и д е г ә н. Сез бүгенге колхозчыга тамак күзләгеннән генә чыгып карамагыз. Колхозга белемле яшьләр килде.

Р а м а з а н. Сез нәрсә, мине булдыксыз җитәкче димәкче буласызмы?

Җ и д е г ә н. Сез әйбәт җитәкче, яхшы оештыручы... техниканы беләсез, яратасыз. Ләкин яшьләрнең инициативасын...

Р а м а з а н. Җитте! Туйдым... Кайчан туктыйсыз инде... Бу хакта указание булганы юк... Син минем политик комиссарым, колхоз хуҗалыгы турында борчылу урынына бәетләр һәм шуңа охшашлы башка нәрсәләр сөйлисең...

Җ и д е г ә н. Ярый, бу мәсьәләне ачык калдырып, фермага күчик... ферманы эчкече кулына тапшыргансыз.

Р а м а з а н. Бу темага сөйләшергә була. Дөрес. Җәмәйне әйтәсеңме? Ул үзе бик булдыклы кеше... Эчмәгән чагында... Тик эчмәгән көне юк, каһәр суккыры...

Җ и д е г ә н. Бүген үк эшеннән бушатырга!

Р а м а з а н. Боерык?!

Ж и д е г ә н. Әйе, партбюро боерыгы. Фермага үзем алынам.

Р а м а з а н. Бик әйбәт. Бар.

Ж и д е г ә н. Фермага Лира да барырга булды. Фәүзиягә ярдәм итәргә тели.

Р а м а з а н. Нәрсә, син аны дуңгыз арасына җибәрер идеңме? Әтисе нәрсә әйтер? Иптәш Дускаев...

Җ и д е г ә н. Иптәш Дускаев?! Лираның әтисе?! (*Телефон шалтырый.*)

Р а м а з а н. Җәләев үзе... Иптәш Яхин?! Әйбәт. Шаулатып үстерәбез... Украинадан?.. Кунаклар?.. Рәхим итсеннәр... Кайчан?.. Берәр айдан? Хәл итәсе мәсьәләләр бар? Үзем барырмын. Хушыгыз, иптәш Яхин. (*Жидегәнгә.*) Менә күрдеңме?.. Без үстергән шикәр чөгендере белән танышу өчен украин дуслар киләчәк. Рекорд куябыз, әкәмәт.

Җ и д е г ә н. Шикәр чөгендере, чынлап та, каерылып уңган. Бу — безнең зур уңышыбыз.

Р а м а з а н. Ә син «музыка, сәнгать...» Икенче мәсьәлә — чөгендер культурасы. Икенче мәсьәлә — чүп үләннәренә

каршы көрәш... Рәхим ит, ул синең файдалы эшең... Читтән торып аспирантурада укыйсың... Укы... Галим бул, коткар чүп үләннәреннән. Онытмагыз, бу — колхоз, ә түгел культура министрлыгы. Фермаларга техника кертү башка эш. Минем көн тәртибендә шул мәсьәлә тора. Борчымагыз юк-бар белән!

Җидегән. Борчыдым һәм борчырбыз, иптәш Җәләев. Бу мәсьәләне тормыш хәл итәр. Хушыгыз. (*Чыга.*)

Рамазан. Сагыз булды бит. (*Статуэтканы алып.*) Чибәр, каһәр суккыры! (*Тәрәзәгә карый.*) Кеше-фәлән килеп кермәсен... Әллә Лираның берәр уе булды микән, әкәмәт. Әллә бу чәчәкне дә ул калдырдымы? Юк, мыскыл итәләр болар мине... (*Телефон номеры җыя.*) Фермамы? Фәүзия! Нинди гыжлаган тавыш анда? Курай? Нәрсә анда курай өреп ятасыз? Телевизор? Юк. Булмый. Кураен өрә бирегез. Урманда бушлай үсә. Җәмәйне китер әле. Исерек?! Адәм көлкесе! Ике ягыннан сәнәк белән булса да терәтеп куегыз. Газеттагыча. Җәмәй, синме бу, хәсрәт? Эчүчелеккә каршы көрәш кампаниясе барганда, син нәрсә салып йөрисең? Синең аркада чистый көлкегә калып беттем. Онытгыңмы әллә Нәгыйм ясаган рәсемне? Төшләргә дуңгыз булып керәсең, әкәмәт. Ничә әйттем, эчмә дуңгызлар арасында, эч өйдә рәхәтләнеп, дип. Үзеңә үпкәлә. Сине алырга туры килә. Кая олактырырга инде син каһәр суккырыны. Ярар, пожарныйга җибәрербез. Җәмәй, дим! Ауган, каһәрең. (*Трубканы куя. Ишекне бикли. Статуэтканы алып.*) Коточкыч матур, каһәр суккыры! Их, яшь чаклар! (*Тәрәзәгә карап.*) Хатын-фәлән килеп кермәсен... (*Ишекне тарталар. Каушап кала. Статуэтканы һәм чәчәкне яшерә.*) Мин монда... (*Ача.*)

Миңнулла керә.

Миңнулла. Хуш килдем, яшьтәш Рамазан.

Рамазан. Миңнулла?! Мулла?!

Миңнулла. Куып чыгарганчы йомышымны әйтеп калыйм...

Рамазан. Куып чыгарганчы эт урынына сүгәм әле мин сине, кәмит. Утыр... Юк... утырма...

Миңнулла. Ничава, сүккәндә басып та торырбыз.

Рамазан. Хурлык! Колхозчы чутында йөрисең... Хезмәт минимумың тулмаган.

Миңнулла. Авызында теше беткән — кулында көче беткән, иптәш Рамазан.

Р а м а з а н. Нишләтергә инде син адәм көлкесен. Апак сакалыңа карап әйтәм, Миңнулла, ташла муллалыгыңны, атом заманасында дөнья ямен җибәреп йөрмә.

М и ң н у л л а. Кагылма. Мин сельсовет яклы.

Р а м а з а н. Мәчетнең җимерелгәненә күпме еллар узды, ә син, һаман Ясин чыгып, бичара сабыйларны сөннәткә утыртып тамак туйдырасың. Ничә яшь сиңа, әкәмәт?

М и ң н у л л а. Эш яшьтә түгел.

Р а м а з а н. Үзең әйтәсең, беләктә көч юк, дип... Сине биш тапкыр өйләнгән, диләр, шул дөресме?

М и ң н у л л а. Хатыннарның берсеннән дә уңмадым, Алла бирсә. Берсенең теле бик озын булды. Икенчесенең, Аллага шөкер, бер аягы икенчесеннән ике сантиметрга кыска булды. Өченчесенең...

Р а м а з а н. Җитте, җитте... Серьезный кешене көлдермә, адәм көлкесе. Биш хатын белән яшәп карадым диген, ә? Баш җитми! Мин әле бер хатын белән торып чәчне агарттым. Тагын өйләнергә уйламыйсыңмы?

М и ң н у л л а. Соң, карт көнемдә ялгыз яшәп булмый, яшьтәш Рамазан.

Р а м а з а н. Халыктан оял, ичмасам!

М и ң н у л л а. Китап тыймый, Алла бирсә. Мөхәммәт пәйгамбәрнең дә җиде хатыны булган, диләр.

Р а м а з а н. Яңа китаплар укымыйсың.

М и ң н у л л а. Укымыйм, Алла бирсә, укымыйм.

Р а м а з а н. Лекцияләргә йөрмисең...

М и ң н у л л а. Йөрмим, йөрмим.

Р а м а з а н. Авылдашларыңнан 100 елга артта калгансың.

М и ң н у л л а. Калдык, Алла бирсә, калдык.

Р а м а з а н. Капитализм калдыгы. Кара әле, быел авылда бал уңмады. Сине быел бал суырта, диләр. Кортларың особыймы әллә, әкәмәт?

М и ң н у л л а. Особый, читтән сатып алдым. Кортларым бик уңган, яшьтәш Рамазан.

Р а м а з а н. Үзеңә охшамаган икән. Йә, әйт йомышыңны да...

М и ң н у л л а. Жалоба белән килдем, Рамазан. Таладылар, кыйнадылар!

Р а м а з а н. Кайсы акыллы баш, ни өчен?

М и ң н у л л а. Чистый бозылган икән, хәерсез. Шул... Фәнәвине сулим. Корт умарталарын алды да... Ни умартаны бирми, ни ашлык...

Р а м а з а н. Нәрсәгә кирәк булган аңа умарталар?

М и ң н у л л а. Җиңел генә байыйсы килә кешенең. Җитмәсә, мине дә, Җәмәйне дә бәргәләп чыгарды. Шундый тондырды, имансыз. Берәр чара күр, председатель. Судка бирер ием, бик бирер ием... Менә тәндә әз генә булса да әзе калмаган...

Р а м а з а н. Ярар, чакырырмын, тикшерермен. Беттеме?

М и ң н у л л а. Базарга барып бераз бал сатасы бар. Ат биреп тор әле.

Р а м а з а н. Ат? Сиңа?

М и ң н у л л а. Ат, Алла бирсә, миңа...

Р а м а з а н. Булмый.

М и ң н у л л а. Бушлай булмас. Үзеңә бал кертеп чыгармын.

Р а м а з а н. Маташма!

М и ң н у л л а. Алайса, акча түлим... колхозга...

Р а м а з а н. Колхозга — икенче мәсьәлә... (*Яза.*) Мә, бухгалтерга бир, акчасын түләрсең...

М и ң н у л л а. Хуш, хуш...

Р а м а з а н. Карале, адәм көлкесе, теге изге чишмәгә һаман йөриләрме?

М и ң н у л л а. Чишмәне изге күрүчеләр аз булса да, бар, Алла бирсә. Нишләптер соңгы вакытта безнең авыллар килми. Картларына кадәр клубта. Аллага шөкер, күрше авыллар килгәли. Рәхмәт, яшьтәш Рамазан, күршеләрдә клубларны яптыргансың икән.

Р а м а з а н. Рәхмәт? Миңа?!

М и ң н у л л а. Бу эшең өчен картлар да сиңа рәхмәт укыйлар.

Р а м а з а н. Юк, минем сезнең белән исәп-хисабым юк.

М и ң н у л л а. Исәп-хисап кесәдә, яшьтәш Рамазан. Киттем. Хуш, сау бул. (*Чыга.*)

Р а м а з а н (*телефон трубкасын алып*). Өченче бригадамы? Заһидуллин! Син нәрсә анда, дингә каршы көрәш кампаниясе барган вакытта, клубны ябып бәрәңге базына әйләндердең? Бүгеннән үк клубны ач!

Ф ә н ә в и керә.

Р а м а з а н. Нишләп йөрисең? Комбайның ватылдымы әллә?

Ф ә н ә в и (*йөрәген күрсәтеп*). Менә монда ватылды.

Р а м а з а н. Салдыңмы әллә, әкәмәт?

Ф ә н ә в и. Салып кына төзәтерлек түгел, бөтен тормыш җимерелде.

Р а м а з а н. Әйт, әйдә, яшермә Рамазан абыеңнан.

Ф ә н ә в и. Төне буе йокламадым... Эшкә кул бармый...

Р а м а з а н. Туктале, син нәрсә авылда тавыш чыгарып, кешеләр кыйнап йөрисең?

Ф ә н ә в и. Ачудан.

Р а м а з а н. Кемгә ачуың бар?

Ф ә н ә в и. Кемгә булсын, үземә.

Р а м а з а н. Аңлатып сөйлә. Сиңа нәрсәгә кирәк булды Миңнулла умарталары?

Ф ә н ә в и. Койрык болгамый гына әйткәндә, мин шул Миңнуллалар аркасында Фәүзияне куып чыгардым.

Р а м а з а н (*өстәлгә сугып*). Куып чыгардың? Кеше кыйнавың җитмәгән, Фәүзияне куып чыгардың?! Миңнуллалар гаепләме инде шуңа?

Ф ә н ә в и. Мин әйтәм: корт үрчетик, Фәүзия әйтә: кирәкми миңа кортларың, ди. Кызып киткәнмен. Ни әйткәнемне дә чамаламаганмын. Кайтмый Фәүзия... Гостиницада. Нишләргә инде, Рамазан абый?

Р а м а з а н. Нишләргәме?

Ф ә ү з и я керә. Фәнәви белән карашып алалар. Чыгып китәргә уйлый.

Р а м а з а н. Тукта! Син нәрсә, Лира кебек кунак кызы булдыңмы әллә? Өеңне ташлап, гостиницага күчкәнсең.

Ф ә ү з и я. Күчтем шул!

Р а м а з а н. Сәбәбе?

Ф ә ү з и я. Әнә үзеннән сора.

Ф ә н ә в и. Фәүзия, умарталарны әле генә Миңнуллага илтеп бирдем.

Ф ә ү з и я. Шуның белән эш бетте дип уйлыйсыңмы? Йөрәгеңне корт ашый башлаган синең, Фәнәви.

Ф ә н ә в и. Ә синең йөрәгеңне корт чаккан. Фәүзия, син биек коймалар яратмый идең. Телисең икән, хәзер үк кайтып җимерәм.

Ф ә ү з и я. Койма җимерү бик җиңел ул...

Р а м а з а н. Фәүзия, бар, кайт өеңә, әнә син яратмаган коймаларны җимерәм, ди...

Ф ә ү з и я. Рамазан абый, мин бит сезгә үтенеч белән генә кергән идем...

Р а м а з а н. Әйт, Фәүзия, тыңлый Рамазан абыең. (*Фәнәвигә.*) Бар, чыгып тор.

Ф ә ү з и я. Юк, чыкмасын, ул да ишетсен.

Р а м а з а н. Тыңла!

Ф ә ү з и я. Мин китәргә булдым.

Ф ә н ә в и. Фәүзия!

Р а м а з а н (*Фәнәвигә*). Минем кебек тыныч бул! (*Фәүзиягә.*) Кая?

Ф ә ү з и я. Театр училищесына.

Ф ә н ә в и. Фәүзия! Рамазан абый...

Р а м а з а н. Тузга язмаганны сөйләмә, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Менә яздым да... (*Өстәлгә кәгазь куя.*)

Р а м а з а н (*укып*). Дөрес... язган... Менә — нәтиҗә! Башта ук сиздем... Әйттем...

Ф ә н ә в и. Рамазан абый, җибәрмә!

Р а м а з а н (*яза*). Отказать! Атказанган артистка булам диген, ә? Син болай да атказанган, Фәүзия! Дуңгыз карау алдынгысы буларак, районда берәү син! СССРда берәү булырсың!

Ф ә ү з и я. Укыгач тагын кайтам ич мин. Эштән качып шар сугарга китмим...

Р а м а з а н. Барыбер җибәрмим! Синнән башка (*өстәлгә карап*) ике кулсыз таш курчак булып калыр хәл юк.

Ф ә ү з и я. Иптәш Җәләев... абый... Аңлыйсызмы, минем үзебезнең авылга кайтып артистка буласым килә.

Р а м а з а н. Артистка булмыйсың — бетте-китте! Барыбер синнән Гөлсем Сөләйманова чыкмый.

Ф ә н ә в и. Мин дә шуны әйттем. Тыңламый...

Р а м а з а н. Авыл хуҗалыгы институтына булса, бәлки, уйлап карарга булыр иде әле...

Ф ә ү з и я. Бер мин киткәннән колхоз таркалмый ич.

Ф ә н ә в и. Таркала, җимерелә!

Р а м а з а н. Безне уйламасаң, әнә Фәнәвине жәллә... Аны ташлавың җитмәгән, колхоздан аерылырга йөрисең.

Ф ә ү з и я. Яшьләр үзләре синнән аерылу турында сүз кузгатмагайлары, Рамазан абзый... Йөрәкләрегез металломга әйләнгән сезнең... Хушыгыз, хуҗалар! (*Чыга.*)

Р а м а з а н. Металломга? Ишеттеңме? (*Уйланып.*) Әллә сез мине аңламыйсыз, әллә мин сезне... Йә, әйт, нинди кешеләр сез? Йөрәгегезгә ничәнче размер ачкыч кирәк сезнең? Ну, сине әйтик инде. Пычагыма кирәкме ул сиңа кортлар? Байыйсың килдеме? Ни өчен? Их, авыр сезнең белән коммунизм төзүе! Ни өчен дигәндә, бармагың үзеңә таба кәкре. (*Фәнәвине төрле яктан әйләнеп.*) Кәмит!..

Ф ә н ә в и (*аны үчекләп*). «Кәмит!»

Р а м а з а н. Синең хәл шаярырлык түгел...

Ф ә н ә в и. Борын астында үзеңне мәсхәрә итмәкче булып йөриләр... ә син һаман «...кәмит, кәмит». Печать суккансың, җитмәсә, пьесаларына.

Р а м а з а н. Минеме көлкегә калдыралар, кемнәр?

Ф ә н ә в и. Кем булсын, шул Юлдаш инде.

Р а м а з а н. Ә, Юлдашны әйтәсеңмени? (*Көлә.*) Җәләевне күккә күтәрә ул анда!

Ф ә н ә в и. Күккә күтәрә дә артына тибеп җиргә төшерә. Алты дәфтәр беткәнче синнән көлә.

Р а м а з а н. Алты дәфтәр?! Ул бит миңа бер генә дәфтәр укытты.

Ф ә н ә в и. Ул сине төп башына утырткан. Бер дәфтәрен генә укыткан. Күп кешегә әләгә анда. Мине дә онытмаган, пичәт күз. Миңнуллага кадәр бар.

Р а м а з а н. Минеме төп башына утырткан? Алдама.

Ф ә н ә в и. Менә... Кара. (*Кесәсеннән дәфтәр чыгара.*)

Р а м а з а н. Каян эләктердең?

Ф ә н ә в и. Фәүзия өстәлдә онытып калдырган.

Р а м а з а н (*дәфтәрне актарып*). Бар, эшеңдә бул!

Ф ә н ә в и. Укыгач, кире кайтарып бирерсең.

Р а м а з а н. Карарбыз.

Ф ә н ә в и. Рамазан абый, үтенеп сорыйм, сүзеңдә тор, Фәүзияне җибәрмә! (*Чыга.*)

Р а м а з а н (*дәфтәрне укый*). Кәмиткә әйләндергән бу мине. Менә сиңа Юлдаш. Бик башсыз малай булып чыкты, атасы мәрхүм. Үз кулларым белән печать суктым бит шушыңа, каһәр суккыры. Фамилияне, үземнең үтенүем буенча, Җәләев дип төзәтеп чыккан. Кая олактырырга икән бу дуңгызны. Әһә!.. Дуңгыз фермасына! (*Дәфтәрне өстәл тартмасына бикләп куя.*) Юлдаш!

Ю л д а ш (*теге яктан*). Әү!

Р а м а з а н. Кер әле монда...

Ю л д а ш керә.

Р а м а з а н. Мин синең должностьны күтәрү турында әйткән идем. Исеңдәме?

Ю л д а ш. Онытa алмыйм, иптәш Җәләев.

Р а м а з а н. Егет сүзе бер булыр. Шуннан чыгып, мин ул сүземне бүген тормышка ашырырга булдым.

Ю л д а ш. Ниндирәк эш икән ул, иптәш Җәләев?

Р а м а з а н. Бөтен халык мал продуктларын күбрәк җитештерү өчен көрәшә, ә син микрофон алдында әкиятләр чыгарып утырасың.

Ю л д а ш. Әкият түгел, иптәш Җәләев, әдәби әсәрләр.

Р а м а з а н. Шул инде ул. Исеме генә үзгәртелгән. Маташма, үскәнем. Барыбер синнән Тукай чыкмый. Менә булган, ичмасам, Тукай! Хәзер яшәсә, колхоз председательләрен гел мактап кына язар иде.

Ю л д а ш. Әгәр Тукай хәзерге көндә дә исән булса, сезнең күзне ачырмас иде.

Р а м а з а н. Ярый, үскәнем, телеңә салынма. Тел белән тегермән тартып, онлы булмассың. Нәрсә дидем әле?

Ю л д а ш. Должностьны күтәрү...

Р а м а з а н. Әйе, мин сине, югарыда сөйләгәннәрдән чыгып...

Ю л д а ш. Дуңгыз фермасына җибәрергә булдыгыз.

Р а м а з а н (*аптырап*). Әйе...

Ю л д а ш (*сөенеп*). Шулаймыни? Әй шәп булган! Гел мин уйлаганнарны уйлап йөрисез икән, иптәш Җәләев. Мин бүген генә фермага җибәрүне сорап гариза язган идем! (*Кесәсеннән кәгазь алып өстәлгә куя.*)

Р а м а з а н (*аптырап кала*). Җен икәнсең!

Ю л д а ш. Җен кебек эшләргә исәп, иптәш Җәләев. Бүген нәкъ шул турыда сөйләшәбез. Җидегән абый була, сез дә керегез.

Р а м а з а н. Сөйләшегез, сөйләшегез, бик әйбәт.

Ю л д а ш. Иптәш Җәләев, исегездәме, сез бая миңа төш сөйләгән идегез. Мин дә бер төш күрдем бит, әй!

Р а м а з а н. Сөйләп кара.

Ю л д а ш. Сиңа микрофон куеп йөрим дип радиоузелга чыккач, йоклап кителгән...

Р а м а з а н. Атаң мәрхүм дә аягүрә йоклап йөри иде.

Ю л д а ш. Шуннан, малай, төш күреп ятам. Алдымда безнең клубтагы теге телевизор тора, имеш. Карыйм телевизордан: берзаман, әй, бик сылу бер кыз килеп чыкмасынмы, нишләптер, куллары юк, имеш. Шуннан сез килеп чыгасыз да, аны күреп, куркудан торараташ булып катып каласыз. Теге матур кузгалып куя. Сез, акылыгызга килеп, кача башлыйсыз. Ул йөгерә, сез качасыз һәм чишмәгә барып хәлсезләнеп егыласыз, имеш. Бервакыт, мин сиңа әйтим, кадрда Миңнулла белән сезнең өрәгегез килеп чыга. Куркып калдым инде мин болай булгач...

Р а м а з а н (*сискәнеп, кызыксынып, җөпләп, көлеп тыңлый*). Төш шул инде, мулла белән нинди бәйләнеш булсын минем.

Ю л д а ш. Шуннан, малай, сезме, өрәкме дип әйтим, теге чишмәгә баткансыз да кулларыгызны юып торасыз икән. «Бал белән юам мин аны, яшьтәш Рамазан»,— ди икән Миңнулла. Ә сез, иптәш Җәләев, әйтәсез, имеш: «Мә сиңа ат»,— дисез, имеш. Сиңа зарый-зарый рәхмәт укыйлар, имеш.

Р а м а з а н (*сәгатенә карап*). Җитәр, Юлдаш иптәш..

Ю л д а ш. Шуннан, малай, сезнең янга бик куркынган Фәнәви килеп чыга, имеш... Нишләптер бармагы кәкрәйгән, имеш. Сез, иптәш Җәләев, шул бармакка карадыгыз да: «Төзерсең бу бармак белән коммунизм»,— дисез, имеш.

Р а м а з а н (*борчылып*). Шуннан уянып киттеңме?

Ю л д а ш. Һаман йоклый бирәм... Шуннан, мин сезгә әйтим, Фәнәви әйтә: «Бу бармакның сезгә дә файдасы тияр. Курыкмагыз». Ә сез, иптәш Җәләев, аңа: «Алайса, шул бармагыңа эләктереп, өрәкләр турында язылган бер китап алып кил»,— дисез, имеш...

Р а м а з а н. Уянасыңмы инде, Юлдаш иптәш?

Ю л д а ш. Һаман уянмыйм әле... Алып килә Фәнәви теге китапны да сезгә тапшыра, имеш. Ә сез, иптәш Җәләев, ул китапны (*күрсәтеп*) нәкъ менә шушы өстәл тартмасына охшаган тартмага бикләп куясыз, имеш.

Р а м а з а н (*сискәнеп*). Уяндыңмы инде, каһәр суккыры!

Ю л д а ш. Уяндым. Уянып китсәм...

Р а м а з а н. Уянып китсәң, нәрсә?

Ю л д а ш. Уянып китсәм... телевизор, да, өрәкләр дә юк, мин сиңа теге якта микрофон көйләп маташам, ә син шушы микрофонга сөйлисең, имеш!

Р а м а з а н. Каһәр суккыры! Тыңлап торган! Куйдырмыйм микрофонны! Алып ташла! (*Өстәл янына килеп кул куя.*) Отказать!

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### IV КҮРЕНЕШ

II күренештәге урын. Ф ә н ә в и, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнеп, әрле-бирле йөри.

Д у с к а е в керә.

Д у с к а е в. Сез кем?

Ф ә н ә в и. Урамда берәр башмак күренмәдеме?

Д у с к а е в (*сагаеп*). Нәрсәгә ул? Минем урамда аяк

киемнәре карап йөргәнем юк! Әллә сез теге пьесада уйныйсызмы?

Фәнәви. Уйныйм. Бик!

Дускаев. Кем образында уйныйсыз?

Фәнәви. Сезне уйныйм!

Дускаев. Мин ул пьесаны куярга рөхсәт итмим!

Фәнәви. Кит аннан! Кем буласыз сез?!

Дускаев. Мин сезнең алда отчет бирергә килмәдем.

Фәнәви. Бик усал начальникка охшагансыз. (*Тавыкларга.*) Көш-ш-ш, тилгән алгырлары! Көш! Башмак күренмәде дисез инде?

Дускаев. «Башмагым»ны караганың бармы синең?

Фәнәви. Бүген ике сәгать шуның артыннан чаптым. Һаман юк! Интектем инде эзләп.

Дускаев. Опера театры авылга килми шул. Ә «Шүрәле»не күргәнең бармы?

Фәнәви. Тартканым да бар. Әллә «Шүрәле» папиросы белән сыйлап җибәрәсезме?

Дускаев. Сез нәрсә дуга белән печән чабасыз?

Фәнәви. Печәнен әзерләп куйдым. Җитмәс дип куркып торам. Әллә сатасызмы?

Дускаев. Культура бүлегендә нинди печән булсын?! Димәк, «Шүрәле» балетын белмисез икән?

Фәнәви. Ә... Балет... Бик кирәге бар ие...

Дускаев. Менә... Күрдегезме?.. Ә пианиноны яратасызмы?

Фәнәви. Утын бетсә, тураклап мичкә ягар идем...

Дускаев. Варвар икәнсез! Берәр кино караганың бармы?

Фәнәви. Хәзер йөрмим. Алдыйлар анда. Ә акчаны каерырга беләләр.

Дускаев. Район масштабында синең кебек кешене күргәнем юк. Ә кемгә үреләсең?! Кемнән көләргә җыенасың!.. Дускаевтан. Бүгенге авыл яшьләрен аңламый дип!.. Менә алар — бүгенге яшьләр! Лира кайда?

Фәнәви. Мин аны саклап йөрергә Җидегән түгел. Клубта алар.

Дускаев. Мин аны көтәм. Кайту белән керсен!

Гостиницага кереп китә.

Фәнәви. Көш! Көш! Мурка, кәҗәләнмә! Барысы да качарга гына тора!

Н ә г ы й м керә. Кулында гармун.

Н ә г ы й м. Фәнәви, гармуныңны биреп тор әле.

Ф ә н ә в и. Ә? Гармун? Клубның гармуны юкмыни?

Н ә г ы й м. Тагын бирәү кирәк. Кечкенә генә оркестр төзедек.

Ф ә н ә в и. Миндә әндри казнасы юк.

Н ә г ы й м. Тузанда аунап ята ич. Укасы коелмас.

Ф ә н ә в и. Су салып куйган идем.

Н ә г ы й м. Ике-өч көнгә генә...

Ф ә н ә в и. Башыгыз түгәрәк сезнең. Фәүзияне дә 2—3 көнгә генә дип алдыгыз.

Н ә г ы й м. Фәүзия... бүген...

Ф ә н ә в и. Ул андамы?

Н ә г ы й м. Шундый матур итеп җырлады!.. Тавышы чишмә кебек челтери менә...

Ф ә н ә в и. Ә гармун кем уйнады?

Н ә г ы й м. Юлдаш инде...

Ф ә н ә в и. Ах, пичәт күз... Менә ни өчен ул фермага киткән икән.

Н ә г ы й м. Ул «Янар чәчәк» көен уйнады. Исеңдәме, кайчандыр, әле сез бергә яшәмәгән чакта, икегез сәхнәгә чыккан идегез. Син ул чакта гармун сыздырдың...

Ф ә н ә в и. Әйе шул, бар ие күңелле чаклар... Ә ничек, Фәүзия җырлаган чакта Юлдашка карап куйгалыймы?

Н ә г ы й м. Юк, Юлдаш аңа елмаеп карап ала.

Ф ә н ә в и. Мин аны!.. Фәүзия чынлап елмаймыймы?

Н ә г ы й м. Юк шул. Ә аны һәммәбезнең дә бер генә тапкыр елмайтасы килә. Синнән киткәннән бирле бер генә тапкыр да көлгәне юк аның...

Ф ә н ә в и (*сөенеп*). Чынлапмы? Әз генә булса да йөрәгендә калган икән. Нәгыйм, кара әле, малай, башыма сыймый... Шулкадәр байлыкны: алты почмаклы өйне, күпме малларны ташлап, ничек чыгып китте икән Фәүзия? Үз энә дә алмады...

Н ә г ы й м. Бүген сине уйлап йоклый алмадым, Фәнәви. Кая барасың син?

Ф ә н ә в и. Беркая да бармыйм. Эштән кайтам да йортта йөрим.

Н ә г ы й м. Беркая да бармыйсың шул... Буш вакытыңны ничек үткәрәсең?

Ф ә н ә в и. Буш вакыт турында уйларлыкмы монда...

Башмак кайтмады... Мал ашатасы бар. Ә син минем вакытны алып торасың. Кит әле моннан!

Нәгыйм. Бүген Лира апа скрипка уйнады. Мин дөньямны оныттым. Күз алдыма авылдашларымның киләчәге килеп басты. Менә... барысы да ул киләчәккә барып җиткәннәр... Тик анда Миңнулла, Җәмәйләр генә күренми. Фәнәви, анда син дә юк. Без сине сөйрибез... Син барырга теләмисең... сине биек коймалар уратып алган...

Фәнәви (*борчылып*). Башмак кайтмый да кайтмый. Кая китеп югалды икән?!

Нәгыйм. Фантастик китаплар укып кара син, Фәнәви.

Фәнәви. Укырсың, бар. Бөтен өй таркалып бара.

Нәгыйм. Лира апа кайтмадымы әле?

Фәнәви. Җидегәне белән йөри торгандыр... Әй, Мурка! Дуңгыз чыгып качты, эт сөйрәгере! (*Чыгып йөгерә.*)

Нәгыйм. Җидегәне белән... Юк, ни генә булса да, мин көнләшмәскә тиеш.

Лира кайтып керә. Ул нигәдер күңелсез.

Нәгыйм. Лира апа, мин монда.

Лира. Нәгыйм?..

Нәгыйм. Мин сезгә килмәдем, Фәнәвигә... Лира апа, сез нигә күңелсез? Бүген менә дигән кичә үткәрдегез...

Лира. Әйе, әйе... күңелсез...

Нәгыйм. Лира апа, сезнең кемне булса да яратканыгыз бармы?

Лира. Ә синең, Нәгыйм?

Нәгыйм. Үлеп ратканым бар. Ләкин ул кыз аны белми, һәм яратмый да. Ул башка кешене сөя. Ул яратсын өчен минем дөнья шаулатырлык бер батырлык эшлисем килә.

Лира. Ул кыз кемне ярата соң?

Нәгыйм. Йолдызларга гашыйк. Җидегән йолдызына.

Лира. Әйе... Ләкин ул килмәде... Бәлки, бөтенләй дә килмәс.

Ерактан ялгыз җыр ишетелә.

Лира. Кем ул шулай моңлы итеп җырлый?

Нәгыйм. Авылда мондый тавышны ишеткәнем юк.

Лира. Ул монда килә.

ЯЛГЫЗ ҖЫР

Йөрәгемә нидер җитмәс иде,
Һаваларда тургай булмаса.
Бер дә генә гаҗәп түгел икән,
Җырламаган кеше җырласа.

Лира, Лира, Лира,
Исемең җырлап тора.
Тургай, тургай, тургай...
Янар чәчәкләрне
Ул ярата бугай.

Тургай җырын тыңлый зәңгәр урман,
Тугай буйларында ак томан.
Ул яраткан чәчәкләрне җыеп,
Сөйгән тургаема ашкынам.

Лира, Лира, Лира,
Исемең сайрап тора.
Тургай, тургай, тургай...
Янар чәчәкләрне
Ул ярата бугай.

Лира. Кем ул шулай шашып җырлый?
Нәгыйм. Ул инде яп-якын...

Җидегән керә. Аның кулында чәчәкләр.

Лира (*аптырап, сөенеп, сагынып*). Җидегән?!
Җидегән (*атлыгып*). Лира! (*Бер-берсенә якынаялар.*)
Нәгыйм. Ник минем исемем дә Җидегән түгел икән? (*Чыга.*)
Лира. Сез... сез... җырлый беләсезмени?
Җидегән. Гомеремдә беренче тапкыр.
Лира. Сезнең кулыгызда чәчәкләр...
Җидегән. Бөтен район урманнарын айкап чыктым.
Лира. Сез аларны өйрәнү өчен җыйдыгызмы?
Җидегән. Юк. Мин аларны, Лира, сезнең өчен... Юк, синең өчен җыйдым...
Лира. Сез... син... мин... минем өчен? Сез бит чәчәкләрне яратмый идегез?
Җидегән. Чүп үләннәрен куралмау өчен, чәчәкләрнең матурлыгын тоя белергә кирәк... Менә Лира... Алыгыз... Нәркис, дәлия, лалә, сөмбел... безнең як чәчәкләре...

Лира (*чәчәкләрне алып*). Рәхмәт... мин аларны тәрәзә төбенә куярмын. Мин аларны шиңдермәм... Җидегән, әйтегез әле, теге вакытта миңа ачуландыгыз, әйеме? Сез бүген шуңа килмәдегез. Ә мин сезне кичә беткәнче көттем.

Җидегән. Мин синнән качып йөрдем, Лира. Кичәгә соңга калып килдем. Бүген көне буе диярлек кырда — Фәнәви янында булдым.

Лира. Фәүзиянең газапланганын белсәгез иде сез... Ул Фәнәвине ярата. Кайта да Фәнәви өендә ут сүнгәнче карап тора.

Җидегән. Фәнәви өен билчәннәр урап алган... Ул аларны үзе йолкырга тели, ләкин билчәннәрнең тамыры тирәнгә киткән...

Лира. Мәхәббәт һәрвакыт шулай газаплы, каршылыклы була микән ул?

Җидегән. Сезнең беркайчан да яратканыгыз юкмыни?

Лира. Юк шул.

Җидегән. Ярый, мин китим инде... (*Пауза.*) Мин китим инде...

Лира. Җидегән, туктагыз... Сез шигырь китаплары укыйсызмы?

Җидегән. Укыганым юк иде...

Лира. Ә хәзер?

Җидегән. Соңгы вакытта укымаган шагыйрем юк.

Лира. Тормышыгызда үзгәреш булдымыни?

Җидегән. Булды. Лира, мин туры әйтүне яратам.

Әллә каян гына килдең дә син,
Тыныч йөрәкләрне кузгаттың...
Син клубтан кайтып киткән саен,
Күз карашы белән озаттым.
Кая гына барсам — синең сының,
Урамнарда,
кырда,
болында;
Кабатлармын синең исемеңне
Мәңге-мәңге
барыр юлымда.

Лира. Ой! Кем язган аны?

Җидегән. Юк, бу шигырь түгел! Чын! Аны мин әйтәм! Сиңа! Мин җавап көтәм!

Лира дәшми.

Мин җавап көтәм.

Лира. Миңа салкын булып китте.

Җидегән (*костюмын Лираның кулбашына сала*). Мин җавап көтәм, Лира.

Лира. Җидегән, әйдә, ерак-еракларга китик.

Җидегән. Синең белән дөнья читенә барырга ризамын. (*Гостиница тәрәзәсе ачыла.*)

Дускаев тавышы. Лира!

Лира (*сискәнеп*). Әти! Җидегән, мин хәзер!

Костюмын Җидегәнгә бирергә дә онытып, йөгереп кереп китә.

Җидегән (*Лира киткән якка карап кала. Музыка ишетелә, Җидегән әкрен генә кушыла*).

Китик әйдә ерак болыннарга,
Озатып барсын төнге җил генә.
Сөю вәгъдәләрен ишетегез
Кара урман белән син генә...

Җидегән җырлаган вакытта Рамазан кереп, эскәмиягә утыра да җырны тыңлый башлый.

Рамазан (*җыр тәмамлангач*). Тагын җырла әле...

Җидегән (*борылып*). Сез нишләп монда?

Рамазан. Ничә яшь сиңа?..

Җидегән. Егерме сигез.

Рамазан. Шулайдыр... Нишләп монда күлмәкчән йөрисең?

Җидегән (*костюмы юклыгын сизеп*). Юк икән шул...

Рамазан. Йөрегез, йөрегез, сүз әйтмим.

Җидегән. Рөхсәтегез өчен рәхмәт. Мин Фәнәви янына килдем.

Рамазан. Мин дә Лира янына килмәдем. (*Пауза.*) Парторг булып парторг җырлый башлагач, председательгә сандугач булып сайрарга гына кала.

Җидегән. Сандугач булып сайрамасаң да ярый, әмма сандугачларның сайравына булышырга кирәк.

Рамазан. Клубны гына түгел, авылны кузгаттылар, туган. Күрше колхоз яшьләре урап алды, культураны юлга салгансың, диләр, молодец, диләр. Җан тирләрем чыкты.

Җ и д е г ә н. Бу мактау сезгә аванс булсын.

Р а м а з а н. Галереяны гел ачтык бит, ә?

Җ и д е г ә н. Карадыгызмы?

Р а м а з а н. Бөтен авыл карый, әй! Бүген Каен авылындагы 90 яшьлек кодам ап-ак сакалын җилфердәтеп килгән. «Рамазан кода, клубыгызга кәртинкәләр кайтарткансың икән, барып карыйк әле»,— ди. Хикмәт.

Җ и д е г ә н. Тормыштан артта калмаган икән.

Р а м а з а н. Үзең уйлап кара, туган. Ике ел экономика өйрәндем, бер ел агротехниканы үзләштердем, бер ел двигатель белән җенләндем. Тормыш авыр булды, тормыш!

Җ и д е г ә н. Ул яктан сез алда барасыз. Бик яхшы.

Р а м а з а н. Шуңа шаккатып торам әле, ни арада культура мине куып җиткән дә узып киткән... Венера Милосская диләрме? Казан художнигы аңлатып бирде. Венерадан оялып йөргән идем, хәзер шуның өчен Лирадан, үземнән үзем оялып йөрим. Оялырлык түгел икән ул Венера дигәнең.

Җ и д е г ә н. Оялу сезгә бик килешә. Клубка Миңнулла, Җәмәйләр килмәгәннәрме?

Р а м а з а н. Миңнулла килеп утырган, каһәр суккыры. Кайда диген әле! Күзен чекерәйтеп иң беренче рәттә утыра. «Мин Коръән тыңлап үскән кеше, җыр яратам»,— ди, җитмәсә. Үзе ни эшләми, ни муллалыгын ташламый...

Җ и д е г ә н. Бал сатарга ат биргәч, эшләмәс шул.

Р а м а з а н. Ә? Ат бирдем шул. Колхозга акча түли ич.

Җ и д е г ә н. Ул эшләп тапкан акчасын түләми, хикмәт шунда.

Р а м а з а н. Тәрбияләп бирегез миңа шул каһәр суккыры нәрсәләрне... Җәмәен әйт, Фәнәвиен. Ялгыш юлдан баралар бит. Ялгыш дигәннән, Җидегән туган, утыр әле. Сөйләшик әле бер күзне күзгә терәп. Ярый. Күрше авыл клубларын ачтык. Бик әйбәт кичә дә үткәрдек ди. Башкаларына да акча бүлгәләрмен. Ә теге каһәр суккан Юлдашның пьесасын куйдырмыйк. Кемнәргә тел тидерә бит! Миңа! Нишләргә председательгә? Бюрога барсаң, бюрода кыздыралар, партсобраниедә пешерәләр, тынычланыйм дип өйгә кайтсаң, хатын черелди... Күңел ачарга дип спектакльгә барсаң, тоталар да председательгә ябышалар. Әнә... Җәмәйдән көлегез, Миңнулладан, Фәнәвидән... Ә миннән?

Җ и д е г ә н. Сез үзегез көләсене китерәсез, иптәш Җәләев. Бу бит дусларча, сезгә ярдәм итәргә теләп көлү. Пьесаны барыбер куярлар!

Р а м а з а н. Куйдырмыйм! Районда тавыш куптарам!

Җ и д е г ә н (*сәгатенә карап, борчылып*). Һаман юк... (*Йөренә.*)

Р а м а з а н. Нәрсә юк?

Җ и д е г ә н. Тыныч йокы юк, иптәш Җәләев! (*Борчылып бер як читкә барып утыра.*)

Р а м а з а н. Тыныч йокы бирәсезмени сез! (*Чыкканда Фәнәви очрый.*) Әһә, син икән әле бу.

Ф ә н ә в и. Урамда берәр дуңгыз белән башмак күрмәдеңме, Рамазан абый?

Р а м а з а н (*көлеп*). Бар, Юлдашка әйт, дуңгыз югалды дип, радиодан хәбәр итсен.

Ф ә н ә в и. Соң инде... Халык йоклый...

Р а м а з а н. Дуңгыз эзләргә калдыңмыни инде? Әйт әле, нигә дип байыйсың син?.. (*Җидегән елмая.*)

Ф ә н ә в и. Кеше баеганда мин карап тормам инде. Кеше байый бит.

Р а м а з а н. Кеше, кеше... Кешене беләсеңмени син? Йөрәгең металломга әйләнгән синең!

Ф ә н ә в и. Бу сүзне синең үзеңә дә әйткәннәр ие...

Р а м а з а н. Ә синең Фәүзияң бүген металлга әйләнгән йөрәкләрне эретте.

Ф ә н ә в и. Минем Фәүзиям?..

Р а м а з а н. Безнең Фәүзия дим. Тыңладыңмы?

Ф ә н ә в и. Клубка йөрерлек рәт юк монда.

Р а м а з а н. Бармадың?.. Их син! Фәүзия кебек сандугачның кадерен белмисең! Венера кебек гүзәлнең...

Ф ә н ә в и. Кайсы, теге түбән оч Венераны әйтәсеңме?

Р а м а з а н. Их, темнота, темнота. Әллә син безнең колхозда яшәмисеңме? Бөтенесе белә аны. Венера Милосская...

Ф ә н ә в и. Әллә нишләгәнсең син, Рамазан абый.

Р а м а з а н. Яшьлек кире кайта, энекәш, яшьлек... Ә Фәүзияне укырга җибәрми булмас, ахры... (*Чыгып китә.*)

Ф ә н ә в и (*агач төбенә утыра*). Яшьлек кире кайта... Минем яшьлегем генә кире кайтмый...

Ф ә ү з и я кайтып килә. Ул гостиница ишегенә юнәлә.

Ф ә н ә в и (*Фәүзиянең юлына төшеп*). Фәүзия, уңга борыл!

Ф ә ү з и я. Алай кычкырырга мин синең малың түгел.

Фәнәви. Фәүзия, кайт өебезгә. Саргаеп үләм... Өйнең яме юк... Син генә ямьләгәнсең икән өйне.

Фәүзия. Син бәхетле түгелмени хәзер? Байыйсың... Барысы да җитә...

Фәнәви. Бу караңгы коймалар төрмә шикелле тоела башлады...

Фәүзия. Үзеңне-үзең япкансың...

Фәнәви. Тып-тын... Мал тавышыннан башка берни ишетелми... Төне буе саташам. Чәчәкләр күреп саташам. Кайт, Фәүзия. Оныттыңмыни яшьрәк чакларны... Вәгъдәләр, яратулар төш кенә булып калдымыни?

Фәүзия. Мин сине шул килеш тә яратам, Фәнәви. Ләкин кайта алмыйм. Син үзең безгә кайт! (*Кереп китә башлый.*) Җибәр!

Фәнәви. Җибәрмим!

Фәүзия. Җибәр дим!

Фәнәви. Өйгә кер!

Фәүзия (*кискен*). Фермада да урын бетмәгән. (*Чыгып китә.*)

Фәнәви. Бөтенләйгә китте... (*Башын иеп, капканы ачык калдырып кереп китә.*)

Җидегән, гостиницага якынаеп, борчылып көтә.

Җидегән. Һаман чыкмый. Әллә кире уйладымы? (*Ачык калган капкадан Фәнәвинең өздереп гармун уйнавы ишетелә.*) Аның да йөрәге яна... янсын...

Ут сүнә. Сәхнә әйләнә. Гостиница бүлмәсе. Дускаев ялгызы. Алдында дәфтәр ята.

Дускаев. Бер яктан караганда, дуңгыз караучы малай пьеса язган. Әйбәт. Икенче яктан караганда, конкрет кешеләргә үрелә. Драматург!

Лира керә. Кулында чәчәкләр. Җилкәсендә Җидегәннең костюмы. Костюмны кулына алып, каушап кала.

Лира. Әти... Исәнмесез?

Дускаев. Исәнлек шәптән түгел. Лира, кайда шулай югалып йөрисең?

Лира. Белсәң иде, әти, бүген клубта культура университеты ачтык. Казаннан художник, язучы килде... Ә без сине чакырган идек. (*Үпкәләп.*) Килмәгән булдың...

Дускаев. Килерлекме монда... Көн саен сүгәләр... Аннан соң принципиально килмәдем.

Лира. Артык «принципиаль» булып китәсең, эти.
Дускаев. Сезнең анда... фермада Шекспирмы, Галиәсгар Камалмы пәйда булган, диләр, дөресме?
Лира. Әй бу Рамазан абыйны... Өлгергән дә... Шаярусыз, эти... Менә дигән пьеса...
Дускаев. Режиссер буларак, син шушы уйдырманы (*пьесаны өстәлгә атып бәрә*) хәзерлисең?
Лира. Җаным-тәнем белән алындым, эти. Белсәң иде андагы кызыкларны...
Дускаев. Бик кызык! Алынган мәгълүматларга караганда, бу пьесада этиеңнән дә көләләр.
Лира. Алай фамилия белән түгел инде. Читләтеп.
Дускаев. Бүрегә атып, куянга тидерәсез? Мондый эшне үз кызымнан көтмәдем.
Лира. Эти, син хаксыз. Ул бит синең кайбер кимчелекләреңнән иптәшләрчә көлә. Аларны киләчәктә искә алсын дип...
Дускаев. Эх, Лира, Лирочка. Атаңның абруе синең өчен нуль! Кемнәр белән катнаштың син? Сәнгатьнең ни икәнен белмәүчеләр белән! Һәм башмакны «Башмагым»нан аермаучылар белән! Кем әле теге дуңгыз караучы?
Лира. Алар сәнгатьне бездән ныграк аңлыйлар, эти.
Дускаев. Кыскасы, ул пьесаны куям дисең? Этиеңнән көләм дисең... Принципиально!
Лира (*катгый*). Принципиально!
Дускаев. Күрәм, характерың кире якка үзгәргән.
Лира. Эх, эти! Картайгансың димме... Ә мин сиңа бер шатлыклы сер әйтергә уйлаган идем...
Дускаев. Әйт, кызым, без әле дошман түгел... (*Костюмны карап.*) Тукта, син нәрсә ирләр костюмы киеп куйгансың...
Лира. Әйе, бу — аның костюмы! Эти... ул миннән җавап көтә...
Дускаев (*сикереп торып*). Лира кызым! Кияүгә чыгасың?! Нигә кергәч тә әйтмәдең. Күптән көткән идем. Мин бик шат. Котлыйм!
Лира. Мин аны яратам, эти!
Дускаев. Бәхетле бул, Лира. Район масштабында туй ясыйбыз.
Лира. Кайбер кимчелекләрең булуга карамастан, әйбәт кеше син, эти... Туйга чаклы төзәлерсең...
Дускаев. Ә соң... Кияү кешене кайчан күрсәтәсең?
Лира. Анысы табышмак... (*Серле.*) Мин хәзер... (*Чыга.*)

Д у с к а е в. Менә әйбәт...

Җ и д е г ә н (*уңайсызланып кына керә*). Исәнмесез, иптәш Дускаев?

Д у с к а е в (*рәсми төс алып*). Сез нинди мәсьәлә буенча?

Җ и д е г ә н (*уңайсызланып*). Бик кыен мәсьәлә, иптәш Дускаев.

Д у с к а е в. Беләм. Әйттеләр.

Җ и д е г ә н. Шул инде. Димәк, ризасыз?

Д у с к а е в. Риза. Ләкин кыскартулар белән.

Җ и д е г ә н. Лира исемнәрен дә әйттеме әллә? Кемнәрне кыскартырга!

Д у с к а е в. Мине.

Җ и д е г ә н. Сезне?! Ничек инде? Сез бу эшнең иң төп герое булып иң түрдә утырырга тиешсез.

Д у с к а е в. Җитмәсә, төп герой булып! Кем ул малай? Шекспирмы, классик «Отелло»ны язган?

Җ и д е г ә н. Төшенмим.

Д у с к а е в (*усал*). Сез нәрсә анда миңа каршы кампания оештырып йөрисез?

Җ и д е г ә н. Ачыграк, иптәш Дускаев...

Д у с к а е в. Активта мине хурлап чыктыгыз. Бөтен район буйлап минем данны сатып йөрисез икән.

Җ и д е г ә н. Хурламадым. Кимчелекләрегезне әйттем.

Д у с к а е в. Хәзер ниндидер бер малай, сезнең указкагыз буенча, миннән көлеп пьеса язган.

Җ и д е г ә н. Минем указка буенча түгел, Юлдаш үзе язды.

Д у с к а е в. Һәм сез, идеология өлкәсенең бер ноктасындагы җаваплы кеше, район работнигыннан көлгәнне хуплап торасыз.

Җ и д е г ә н. Республикада сез берәү генә түгел.

Д у с к а е в. Безнең район масштабында берәү генә. Димәк, сез минем бакчага таш атасыз.

Җ и д е г ә н. Зыянга булмас, файдага булыр, иптәш Дускаев.

Д у с к а е в. Сез һаман үз фикерегездә каласызмы?

Җ и д е г ә н. Калам.

Д у с к а е в. Йомышыгызны әйтегез дә мине тынычлыкта калдырыгыз.

Җ и д е г ә н. Сезне күрү өчен генә кергән идем... (*Чыгарга* бара.)

Д у с к а е в. Ә менә минем сезне күрәсем дә килми...

Л и р а керә. Шат.

Л и р а. Йә, дипломатик сөйләшүләр ничек тәмамланды? (*Тынлык.*) Нигә дәшмисез? Әти, кияү буласы кеше ошамадымы әллә?

Д у с к а е в. Кияү?! Шушымыни инде синең яратканың...

Л и р а. Әйе, ул!

Д у с к а е в. Тапкансың икән...

Л и р а. Әти, ни сөйлисең?..

Д у с к а е в. Шушы кеше аркасында мине бүген эшемнән азат иттеләр!

Л и р а. Чынлапмы?

Д у с к а е в (*пьесаны атып бәреп*). Мә пьесаңны, куегыз, әтиеңә соңгы ударны яса! (*Чыга.*)

Л и р а. Әти...

Җ и д е г ә н. Лира... Әйдә, аңлашыйк әле...

Л и р а (*озак икеләнгәннән соң, костюмын Җидегәнгә бирә*). Булмый, Җидегән...

Җидегән, акрын гына атлап, башын иеп чыгып китә. Сәхнә әйләнә. Капкадан, «Янар чәчәк» көен уйнап, Ф ә н ә в и чыга. Гармун тавышы гостиница ягыннан ишетелгән рояль моңнарына кушыла. Фәнәвинең хыялында гармунга кушылып җырлаган Фәүзия күренеп кала.

Ф ә ү з и я җ ы р ы.

Нинди матур озын юлга чыктык,
Янар чәчәк иде юл башы.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булган, яшьлек юлдашым?

Гостиница ишегеннән, костюмын кулына тотып, авыр атлап Җ и д е г ә н чыга да тукталып кала. Фәнәви белән Җидегән бер-берсен күрмиләр.

Ф ә н ә в и (*үткәнне искә төшереп*).

«Менә чәчәк...
Шушы чәчәк кебек,
Балкып, янып торсын киләчәк!»
Мин югалттым янар чәчәгемне,
Күзләр җиткән, эзлим, табалмыйм.
Фәүзия!
Ут сал минем салкын йөрәгемә,
Синнән башка сүнәм, яналмыйм.

Җ и д е г ә н. Калды...

Үз йөрәген җиңә алмады.

Ялгыз егет моңын кем аңласын,—
Кырлар гына,
Кырлар гына аңлый аларны...

Фәнәви (*өй тәрәзәсендәге үрмә гөлгә карап*).

Гөлгә кадәр,
Караңгыдан чыгып,
Фәүзия киткән якка үрләгән.

Җидегән.

Йөрәк, ахры, юкка дөрләгән...

Тынлык.

Мәхәббәтләр! Әгәр чын булсагыз,
Чыгыгыз сез кысан бүлмәдән!

Пәрдә.

## V КҮРЕНЕШ

Чишмә буе. Клубның грим бүлмәсе чишмәгә чыга. Сәхнә читендә умарта.
Миңнулла керә. Тирә-якка каранып тора да чишмә янына килә. Нәгыйм бүлмәдән башын тыгып карый да югала.

Миңнулла. Кеше-фәлән күренми бугай. (*Чишмәдән акча җыя башлый.*) Бер тиен, ике тиен дә өч тиен... Яңадан бер тиен... (*Умартаны күреп ала.*) Бәй, минем умарта түгелме соң бу?

Шул вакыт Миңнулланың өрәге килеп чыга.

Өрәк. Кагылма, бу минем умарта!

Миңнулла (*артка чигенә. Куркып*). Тәүбә әстәгъфирулла! Кем син?!

Өрәк. Синең өрәгең. Гөнаһларыңны санарга килдем.

Миңнулла. Авылда иң гөнаһсыз кеше мин.

Өрәк (*кенәгәсен алып*). Тагын бер гөнаһыңны язып куям,— алдаштың.

Миңнулла (*үз-үзенә*). Бу тавышны ишеткәнем бар кебек... Әһә, миннән көләргә маташалар. (*Өрәккә.*) Туганнан алып бер кәррә дә алдашмаганым... әй... алдашканым юк.

Өрәк. Кайбер әби-бабайлар, бу чишмәне изге күреп, хәер-сәдака ташлыйлар, син, туймас күз, шул тиеннәрне җыясың...

Миңнулла. Шаярма! Бу минем акчалар. Театрга китеп бара идем, коелдылар.

Өрәк (*кенәгәгә карап*). Монда синең 99 гөнаһ бар иде. 100 гә тулды. Хәзер, Алла бирсә дә, бирмәсә дә пунктлап сорау алуга күчәбез. Беренче сорау: син үзеңне действительно мулла дип саныйсыңмы?

Миңнулла. Мулла булсам, чапаным булыр ие... юк ич.

Өрәк. Тәмәке тартасыңмы?

Миңнулла. Тартмаган кая... Имәбез генә...

Өрәк. Хәмер кулланасыңмы?

Миңнулла. Чөмерәбез генә. Бөтен авыл белә.

Өрәк. Син биш хатын алып аергансың. Элекке муллалар да берничә хатын алганнар. Димәк, син мулла?

Миңнулла. Что син! Мулла булсам, биш хатын белән дә бергә торыр ием. Берәм-берәм аерып җибәрдем бит. Бөтен авыл белә.

Өрәк. Кортларыңның эзенә төштек. Кеше базларына кереп, кәрәзләрне талап йөриләр икән.

Миңнулла. Вот чукынганнар! Кайтып колакларын борыйм әле. Мин таламыйм, кортлар.

Өрәк. Сине самогон кайната, diләр. Дөресме?

Миңнулла. Тотылмаган — бур түгел.

Өрәк. Айга очарга кеше эзлиләр, ди. Очмыйсыңмы?

Миңнулла. Айда алтын бар дип сүлиләр, чын микән ул?

Өрәк. Анда да эшләми яшәп булмый.

Миңнулла. Үзегез очыгыз. Җирдә дә чак яшим әле...

Өрәк. Театрга керәсеңме?

Миңнулла. Шунда барам ич... Мулла булсам, театрга йөрер идеммени?.. (*Кереп китә. Нәгыйм парикларын сала.*)

Лира (*көлә-көлә чыгып*). Булдырдың, Нәгыйм! Мин өйрәткәннән дә артык.

Нәгыйм. Миңнулла белән киртә аша гына торабыз бит. Сәхнәгә куярга ясаган умартаны чак алып китмәде, юньсез.

Лира. Хат ташучы да сине таный алмады. Менә сиңа ике хат калдырып китте.

Нәгыйм. Ике хат? Миңа? Берсе Казаннан! (*Ачып укый.*) Ур-ра! Художество училищесыннан! Мине — Нәгыймне киләсе елга кабул итү имтиханнарына чакыралар. Ә икенче хат? Тагын бер ур-ра! Мәскәү, Фәннәр академиясеннән. Тыңла, Лира апа!

Лира. Укып җибәр әле, Нәгыйм.

Нәгыйм (*укый*). Хөрмәтле иптәш Ильясов! Сезнең туган илебезне ярату хисе белән тулы хатыгызны алдык. Безгә шундый эчтәлекле меңнәрчә хатлар килә. Сезгә уңай җавап бирә алмыйбыз. Киләчәктә планеталарга очу өчен махсус хәзерлекләре булган кешеләр генә сайланачак. (*Пауза.*) Их, очып булмады...

Лира. Кайгырма, Нәгыйм.

Нәгыйм. Киләчәктә мин барыбер очармын! Лира апа, икенче хат турында берәүгә дә әйтмә, яме?

Кереп китә.
Лира ялгыз. Җидегән, аны күрмичә, клубка узып бара.

Лира. Җидегән!..

Җидегән (*туктап*). Исәнмесез.

Лира (*сүз табалмый*). Рәхмәт сезгә.

Җидегән. Ни өчен?

Лира. Усал булуыгыз өчен.

Җидегән. Нинди усаллыгым тиде?

Лира. Рамазан абый менә дигән декорацияләр эшләтте. Рояль алып бирде. Сез ярдәм итмәсәгез... Усал булу кирәк шул тормышта.

Җидегән. Сез бит усалларны яратмыйсыз.

Лира. Мин бөтенесен уйладым. Үземне-үзем тиргәдем. Ни генә булса да, син хаклы, Җидегән. Менә минем иң соңгы җавабым: мин усал кешене яратам. Сине!

Җидегән (*бөтенләй үзгәреп*). Лира! Тагын бер әйт!

Лира. Сине яратам! (*Оялып башын ия.*)

Җидегән. Мин хәзер бөтен клубка кычкырам!

Лира. Җүләрләнмә... Бүген уңышлы тәмамланса... (*Якынаялар.*)

Дускаев керә. Ул аларны күрми.

Дускаев. Халык театры шушында ачыламы, иптәшләр?

Лира (*шаярып*). Ярты сәгатьтән ачабыз, иптәш Дускаев.

Д у с к а е в. Синмени бу, Лира?

Л и р а. Әйе, без, эти. (*Җидегәнгә.*) Исәнләш этиебез белән.

Җ и д е г ә н. Исәнмесез, эти?

Д у с к а е в. Беренчедән, мин эти түгел, район газетасы сотрудникы иптәш Дускаев...

Л и р а. Яңа эшегез котлы булсын, эти! (*Җидегәнгә.*) Син дә әйт!

Җ и д е г ә н. Котлы булсын, эти.

Д у с к а е в (*Җидегәнгә*). Икенчедән, мине эзәрлекләүдән кайчан туктыйсыз?

Л и р а. Туктадык инде, эти, әни риза булды.

Д у с к а е в. Ә? Әниең дә шулай димени? Әйдә, арт ишектән озат мине. Район газетасы көзлегеннән карыйк пьесагызны...

Л и р а. Әйдә, эти!

Җ и д е г ә н. Әйдәгез, эти!

Д у с к а е в. Мин эти түгел әле. (*Клубка керәләр.*)

Ф ә н ә в и керә. Кулына гармун тоткан. Эскәмиягә утыра. Грим бүлмәсеннән Ф ә ү з и я чыга. Ул икенче күренештәге киемнәреннән. Уйныйсы ролен өйрәнә.

Җ ы р.

Нинди матур озын юлга чыктык,
Янар чәчәк иде юл башы.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булган, яшьлек юлдашым?
Яшьлек хатирәсен актаргандай,
Дәфтәр битен кичке җил ача.
Еракларда калган тавышыңны
Җил дә алып килми, ичмаса...

(*Шигырь укый.*)

Авырлыклар булса тормышымда,
Алырмын да яшьлек дәфтәрен,
Әйткән сүзләреңне искә төшереп,
«Фәнәви!» дип сиңа дәшәрмен!
Син ризамы?

Ф ә н ә в и (*йомшак кына*). Риза!

Ф ә ү з и я (*сискәнеп*). Фәнәви...

Ф ә н ә в и. Син унҗиде яшеңә кире кайткансың... Фәүзия, анда мин дә бар идем...

Фәүзия. Син дә кайт, Фәнәви.

Фәнәви. Менә мин килдем... Ялгызлыкның бөтен газабын күреп килдем. Нәгыйм гармун сораган иде... Алыгыз...

Фәүзия. Мин синең кайтырыңны йөрәгем белән тойдым, Фәнәви. Миңа да җиңел түгел иде. Бир гармуныңны, тапшырырмын. (*Ала.*)

Фәнәви. Ә мин нишлим хәзер? Яңадан коточкыч тынлыкка кайтыйммы?

Фәүзия. Клубка кер, яме, Фәнәви.

Фәнәви. Үлем белән бер булса да керәм... Беләм, сез миннән көләрсез... Теләсәң нишлә, сине күрмичә түзә алмыйм.

Фәүзия. Клубка гел бергә йөрербез, яме, Фәнәви.

Фәнәви. Йөрербез.

Фәүзия. Син элекке кебек гармун уйнарсың, яме, Фәнәви.

Фәнәви. Уйнармын... Ә син минем өчен... Юк, барысы өчен дә җырларсың...

Фәүзия. Җиләккә барырбыз.

Фәнәви. Урманга, тауларга барырбыз...

Фәүзия. Укырга барырбыз...

Фәнәви. Укырга барырбыз...

Звонок тавышы.

Фәүзия. Башлана. Киттем, Фәнәви. Син дә кер...

Йөгереп чыга.

Фәнәви. Мин сине көтәрмен!..

Грим бүлмәсеннән Рамазан киемендә Юлдаш чыга.

Фәнәви (*шатланып кычкыра*). Рамазан абзый! Фәүзия кайта. Мин дә кайтам!

Юлдаш. Ярый, уйларбыз. Тикшерербез. Карарбыз.

Фәнәви. Йөрәк төзәлә башлады, Рамазан абзый!

Юлдаш. Йөрәк — икенче мәсьәлә, кара аны, комбайның ватылмасын!

Ашыгып Рамазан килеп керә.

Рамазан. Кырда комбайн белән маташып, соңга кала яздым... (*Юлдашны күреп, телсез кала.*) Ә? Син кем? Фәнәви, кем ул?

Ф ә н ә в и (*аптырап калган*). Рамазан абзый...

Ю л д а ш. Иптәш Җәләев, исәнмесез?

Р а м а з а н. Исәнмесез, иптәш...

Ю л д а ш. Җәләев.

Р а м а з а н. Әкәмәт!

Ф ә н ә в и (*бер Юлдашка, бер Рамазанга карап*). Кешеләр ике булып күренә башлады. Шатлыктан бугай!..

Ут сүнә.

Шул ук күренеш. Грим бүлмәсенең ишегенә «Янар чәчәк» дигән афиша электр лампочкалары белән язылган. Җ и д е г ә н белән Н ә г ы й м бүлмәдән чыгалар.

Н ә г ы й м. Спектакль тәмамланып килә. Ә минем киләчәк хыялларым яңа башлана гына.

Җ и д е г ә н. Нинди хыяллар ул, Нәгыйм?

Н ә г ы й м. Мин бүген үзебезнең көчне сиздем. Хыялны тормышка ашырып була икән. Менә... Карагыз. Мин авылымның киләчәк планын сыздым.

Мин Марстан авылыма кайтам,
Авылдашлар күккә чөяләр.
Эзлим Аны...
Ә чәчәкләр миңа:
«Соңладың шул, Нәгыйм»,— дияләр.
Авылым матур. Асфальт. Яна йортлар.

(*Планга күрсәтеп.*)

Монда парк. Яшьлек мәйданы.
Зур мәһабәт сарай. Әнә оркестрдан
Ишетелә тургай сайравы.
Лира апа,
Саумы,
Сезне сагынып
Кайттым, бар галәмне әйләнеп.
Бу кем?
Галим... Сез, Җидегән абый,
Кулыгызда
Янар чәчәкләрнең бәйләме.
Әнә Юлдаш. Ул либретто язган.
Бездә опералар куялар,
Фәүзиябез җырлый,

Аны котлап,
Зур артистлар чәчәк җыялар.
Ә мин — Нәгыйм,
Чиксез йолдызларга күзем текәп,
Җырлыйм «Янар чәчәк» көенә.
Мин яп-ялгыз...
Тик, Җидегән абый,
Сезнең бәхетегезгә сөенәм.

Җидегән. Матур, нигезле хыяллар, Нәгыйм!

Нәгыйм. Без ул хыялны үзебез тормышка ашырырбыз!

Сәхнә ягыннан «Автор!», «Режиссер!», «Художник!» дигән тавышлар, кул чабулар ишетелә.

Җидегән. Сине сәхнәгә чакыралар, Нәгыйм!

Нәгыйм чыга. Бераздан шаулап, көлешеп, Юлдаш, Лира, Фәүзия, Нәгыйм һәм башка яшьләр керәләр. Юлдаш кулында чәчәк бәйләме.

Юлдаш. Юк, иптәшләр, бу чәчәк миңа түгел, ә пьесаны хәзерләүче, халык театрын ачучы Лирага булырга тиеш.

Лира. Сездән башка мин нишли алыр идем. Дуслар, тыңлагыз, мин сезгә зур сөенечемне әйтәм. Без Җидегән белән бүген яңа тормыш башларга сүз куешкан идек. Менә ул минутлар килеп җитте.

Нәгыйм (*талпынып*). Лира апа!..

Юлдаш. Музыка! Иптәш Җәләев алып биргән баян! (*Баян тантана уйный.*) Ниһаять, чәчәкне сезгә тапшырырга җай килде. (*Чәчәкне биреп.*) Бу янар чәчәкләргә кунып, сезнең мәңгелек бәхетегез турында җырлап, тургайлар сайрасын!

Лира. } Җидегән. } Рәхмәт, дуслар!

Ашыгып Дускаев чыга.

Дускаев. Ишек кайда монда?

Юлдаш. Иптәш Дускаев, без, халык театрының артистлары, котлаулар көтәбез.

Дускаев. Котлыйм! Уңыш! Яңалык! Мактап язмыйча булмый. Искә алырмын. Тик кыскартмагансыз икән. Яхшы. Тик район масштабында күрсәтә күрмәгез.

Л и р а. Әти, без бүген Җидегән белән яңа тормыш башлыйбыз, безне котлагыз.

Д у с к а е в. Барыбер сездән котылып булмас! (*Җидегәнгә.*) Исәнмесез?! Калганын район масштабында сөйләшербез.

Бүлмәдән бәрелеп-сугылып М и ң н у л л а чыга.

М и ң н у л л а. Иллә килештереп кыйландыгыз. Бөтен мир алдында мәсхәрә иттеләр. Алла хакы өчен башка күрсәтмәгез. Икенче биш тапкыр өйләнмим, Алла бирсә. Тәүбә! (*Чәчәк тоткан Лираны күреп.*) Нәрсә, әллә никах укыргамы? Кайчан килим?

Н ә г ы й м (*Миңнулла тавышы белән*). Миңнулла, безнең туйда синең катнашың юк!

М и ң н у л л а. Әһе! Синме ул минем өрәкне уйнаучы?

Н ә г ы й м. Ычкын, күршекәем.

М и ң н у л л а. Талыйлар! (*Чыгып кача.*)

Р а м а з а н (*бүлмәдән чыгып, шаярып*). Адәм көлкесенә калдырдыгыз. Юлдаш, дустым, ичмасам, фамилиямне яңадан үзгәртегез. Куярга рөхсәт итәм. Яңадан печать сугыйммы? Ну, өйрәттегез, егетләр! Отчет-сайлау җыелышыннан да болайрак булды.

Ф ә н ә в и бүлмәдән чыга. Халык тынып кала. Ул акрын гына атлап килә. Туктый.

Ф ә ү з и я. Фәнәви, кил! Кыюрак кил безнең арабызга!

Ю л д а ш. Кил, Фәнәви. Курыкма! Тешләмәбез.

Ф ә н ә в и. Фәүзия, син тагын Юлдаш белән басып торасың?

Ф ә ү з и я. Тукран тәүбәсе...

Ф ә н ә в и. Ялгыш кына әйттем.

Ю л д а ш. Бу нинди эш? Мин мәхәббәттә һәрвакыт өченче кеше булып калам. (*Лира янына килә. Нәгыйм аның кулыннан тарта.*) Монда да шул ук хәл...

Ф ә н ә в и (*Фәүзияне кулыннан тотып*). Әйдә, кайтыйк инде.

Ф ә ү з и я. Кара, нишли ул... халык алдында.

Ф ә н ә в и. Бергә кайтыйк инде... Шулай диден ич...

Ф ә ү з и я. Бергә инде, бергә...

Л и р а (*күккә карап*). Карагыз, йолдызлар бүген тагын да яктырак яналар.

Н ә г ы й м. Нәрсә ул йолдыз... әнә Марс... Ул мине көтә.

Р а м а з а н. Бернәрсә дә күрмим, әкәмәт. Әллә яңа йолдыз ясап куйганнармы?

Д у с к а е в. Район масштабыннан чыгып карарга кирәк аны.

Ю л д а ш. Авыл масштабыннан да яхшы күренә, иптәш Дускаев.

Ф ә ү з и я. Әнә бер йолдыз. Ул ерагайган иде... Хәзер якынаеп килә.

Р а м а з а н (*Фәүзиягә карап*). Венера...

Л и р а. Әнә Җидегән йолдыз... Ул шундый якын. (*Җидегән якыная.*)

Барысы бергә «Янар чәчәк» җырын җырлыйлар.

Күкрәгеңә алып кадар чәчәк,
янар чәчәк,
Эзләп тугайларга барырсың,
янар чәчәк,
Син эзләмә аны, үз йөрәгең
янар чәчәк,
Янар чәчәк булып кабынсын,
янар чәчәк,
Яшьлегебез — үзе янар чәчәк,
янар чәчәк,
Тугайлардан аны эзләмә,
янар чәчәк,
Тургайлардан биек күтәрелә,
янар чәчәк,
Сайрый, җырлый, сөя, эзләнә,
янар чәчәк.

П ә р д ә.

*1960—1961*

# Безнең эти мировой*

*Ике пәрдәле комедия*

КАТНАШАЛАР:

Габбас Шәйморзин — 44 яшьтә.
Әнисә — аның хатыны, 42 яшьтә.
Люция — аларның кызлары, 18 яшьтә.
Рева — аларның кызлары, 17 яшьтә.
Мирослав — 18 яшьтә.
Мамалеев Аван Казбекович.
Мин Ханович.
Ким Замович.

1960 елларда Казанда булган вакыйга.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бүлек мөдире Мамалеевның кабинеты.

Мамалеев (*телефоннан сөйләшә*). Шәхсән үзе! Мамалеев! Нинди мәсьәлә? Фатир? Җир астында яшибез? Син аңла, кем, Җамалетдинов абзыкай, хәзергә хәл авыр, килер бер көн, егерме ел үтсә үтәр, синең кебекләр һәммәсе дә җир өстенә менәр! Син аңла: Америка небоскреблары безнең коммунизм корылмалары алдында шырпы кабы кебек кенә калыр! Ун ел көткәнне егерме ел гына көтәрсең, иптәш Җамалетдинов абзый! (*Трубканы куя. Тагын телефон чылтырый.*) Мамалеев! Юк! Фатир юк! Егерме елдан соң булыр, бәлкем?! Син аңла! Без әле 60 нчы елларда гына яшибез! Ә... ә... гафу... иптәш полковник... Шәйморзинны миңа җибәрдегез? Килсен! Һәммәсе уйланылган! Син аңла: чит ил кунагы алдында бөек Ватаныбызның абруен төшермәбез! (*Трубканы куя. Авыз эченнән генә җырлый.*)

Дулкынланып сулар керә
Пароход идәненнән...

---

* 1991 елда К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында һәм Минзәлә татар дәүләт драма театрында куелды.

Эш киеменнән, сакал-мыек баскан Габбас Шәйморзин керә.

Кем кертте? Син аңла: фатир юк! Егерме елдан кил! Кругом марш! Син аңла!

Габбас. Сез мине үзегез чакырттыгыз, иптәш Мамалеев. Мин — Шәйморзин.

Мамалеев (*тора*). Шәйморзин?

Габбас (*үрә катып*). Мин!

Мамалеев (*алдындагы «Личное дело»ны карап*). Шәхсән үзе?

Габбас (*шүрләбрәк*). Мин... үзем...

Мамалеев. Чехословакияне азат итүдә катнашучы Шәйморзин?

Габбас. Нәкъ үзе!

Мамалеев. Беренче Украина фронты?

Габбас. Так точно!

Мамалеев. Командующий?

Габбас. Конев!

Мамалеев. Хәрби комиссариатта булдыгызмы?

Габбас. Булдым.

Мамалеев. Тормыш иптәшегез, балаларыгыз сезнең фронтта кылган батырлыкны беләме?

Габбас. Батырлык дип... бөтен дөньяга күкрәк сугып мактанырлык түгел инде...

Мамалеев. Димәк, гаиләгез белми? Афәрин! Егет икәнсең! Тыйнаклык геройга хас сыйфат!

Габбас. Минем урында һәрбер ир-егет югалып калмастыр дип уйлыйм.

Мамалеев. Һәм дә дөрес! Син аңла: чит ил кунагы нәкъ менә синең шикелле тыйнак та, булдыклы да егеткә килеп ялгышмый. (*Якынаеп, дустанә.*) Хәлең ничек, шәһәребезнең горурлыгы? Син аңла: фатир турында әйтеп торма...

Габбас. Йортларны без үзебез төзибез. Итекченең итеге була димени, иптәш Мамалеев?!

Мамалеев. Менә дөрес! Син аңла: егерме елдан итеге дә, читеге дә булыр!

Габбас. Үзебез генә булмабыз...

Мамалеев. Анысы кечкенә мәсьәлә! Син аңла: без — киләчәк идеаллары белән яшәүче яңа чор кешеләре. Мин, иптәш Шәйморзин, синең кебек фатир сорамаучы аңлы гражданнарны ихтирам итәм, ә андыйлар хәзергесе көндә юк. Инде килеп, төп мәсьәләгә күчик. Син аңла: сине

эзләп, күрергә теләп, юкка гына чит илдән килмиләр. Синең өчен, без кулдан килгәннең барысын да эшләрбез. Хәрби комиссариатта әйткәннәрдер — чит ил хәбәрчесе нәкъ сине күрергә килә!

Габбас. Мин аптырап калдым. Нигә миңа килә? Максаты нидә?

Мамалеев. Аптырама! Син аңла: совет кешесенең иң асыл сыйфатлары именно синдә чагыла. Ни әйтсәң дә, бернигә карышмаучы, алдынгы карашлы эшче, фронтовик... Ул барысын да фотога төшерер, кайткач газеталарына язар...

Габбас. Иптәш Мамалеев, зинһар, коткарыгыз, мине уңайсыз хәлдә калдырмагыз. Мине сайлап ялгышканнар. Минемчә, шәһәребезнең абруе...

Мамалеев. Күтәреләчәк!

Габбас. Юк! Юк! Минем бик күп кимчелекләрем бар: тәмәке тартам, салам, ачуым килгәндә җиде катлы итеп сүгенәм... эчемнән генә булса да...

Мамалеев. Анысы кечкенә мәсьәлә!

Габбас. Бик нервада уйнаса, хатынымны да кыйнап ташлый алам... Аннан соң әле мин...

Мамалеев. Җитте! Син аңла! Менә мин тәмәке тартмыйм, салуын салам анысы, кул бик кычытса да, хатынымны кыйнамыйча түзәм. Ә ул түзә алмый, явыз! Анысы кечкенә мәсьәлә... Ләкин бит мине эзләп килми хәбәрче, нәкъ менә сине, ә, Шәйморзин! Нинди олы җаваплылык, нинди зур хөрмәт!

Габбас. Юк, булмый! Башканы табыгыз. Ул миңа кая... баракка килсенме? Бөтен дөньяга көлкегә калабыз, иптәш Мамалеев! Килсә, егерме елдан килсен!

Мамалеев. Борчылма, Шәйморзин, синең өчен барысы да уйланылган, хәл ителгән! Көзгегә карап җибәр!

Габбас көзге алдына баса.

Рәзве мировой егет шундый мескен кыяфәттә йөрергә тиеш?!

Кнопкага баса. Ярдәмчеләре килеп керә.

Чишендерегез!

Габбасны тиз генә чишендерәләр.

Габбас. Туктагыз, нишлисез сез? Хатын ни әйтер?

Мамалеев. Дөньяви проблемаларны хәл иткәндә, вак мәсьәләләрне онытып торыгыз! Киендерегез!

Тегеләр Габбасны баштанаяк киендерәләр. Хәзер аның өстендә өр-яңа костюм, кара галстуклы ап-ак күлмәк, башында — эшләпә, кулында — япон зонтигы.

Көзгегә! Таныйсыңмы?

Габбас (*көзгегә карап*). Сәлам, хөрмәтле иптәш Шәйморзин!

Мамалеев. Тыңла!

Габбас. Тыңлыйм!

Мамалеев. Син аңла: хәзер сиңа бер мин генә түгел, калабыз гына түгел, ә бөтен мир карап тора! Сизәсеңме син шуны?!

Габбас. Сизәм, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Менә сиңа ярдәмчеләр. Син «Айт!» дигәндә, алар «Тайт!» дип торырлар. Җаның ни тели, алар сиңа барысын да табып бирерләр. Итәк астыннан гына түгел, хәтта җир астыннан да! (*Ярдәмчеләргә.*) Мировой егетебезне һәм дә аның гаиләсен игътибар белән чолгап алыгыз. Беренче чиратта... сөйләшкәнчә... барактан күчерегез...

Габбас. БАрактан?! Рәхмәт, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Рәхмәт әйтергә ашыкмагыз. Син аңла: анысы егерме елдан. Барысы да вакытлыча...

Габбас. Вакытлыча?

Мамалеев. Әйе. (*Пауза.*) Кунак киткәнче.

Габбас. Кунак киткәнче?!

Мамалеев. Син нәрсә?!

Габбас. Үзем...

Мамалеев. Үзең турында уйлама... Төшендеңме? Син аңла: бу — безнең шәһәребезнең, халкыбызның, илебезнең престижы, киләчәге өчен кирәк. Төшендеңме?

Габбас. Төшендем. Киләчәк өчен яңадан эт күрмәгәннәрне дә күрергә ризамын, иптәш Мамалеев!

Мамалеев. Үтәгез!

Ярдәмчеләр чыгалар.

Киттек аэропортка — кадерле кунакны каршы алырга! Минем арттан!

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Иске баракта Габбас Шәйморзиннар бүлмәсе. Арзанлы гади мебель. Диварда — журналдан кисеп алынган фоторәсемнәр.

Рева белән Люция этиләрен каршы алырга әзерләнәләр. Люция өстәл әзерли. Рева радиола янында кайнаша.

Р е в а. Люция!

Л ю ц и я. Ни бар, Рева?

Р е в а. Монысы ничек булыр?

Л ю ц и я. Үзебезчә берәр маршың юкмы?

Р е в а. Әтигә — мировой көй!

Л ю ц и я. Ишек ачылуга — барабыз да кочаклыйбыз!

Р е в а. Кочаклаганчы, ишек янында почетлы каравылга басып, «Геройга дан!» дип кычкырабыз.

Л ю ц и я. Әй лә... арттырма әле... Орден тагып кайтса да бик җиткән.

Р е в а. Әйтте диярсең, этинең күкрәгендә Алтын Йолдыз булыр! Военкоматка юкка гына чакырмыйлар. Хәбәрчеләр дә була дип өстәп язганнар.

Л ю ц и я. Кичә чакыру кәгазе килгәч, сөйләп утырды утыруын... Аны, бер һөҗүмнән соң, Геройга тәкъдим иткәннәр икән. Бомбежка вакытында документлары юкка чыккан... алдамаса...

Р е в а. Әти алдашмый.

Л ю ц и я. Арттыра торган гадәте бар барын. Әй, медаль тагып кайтса да ярый — җиденче медаль!

Р е в а. Әни күпме әйтте үзенә: «Алты медалең булганчы, бер алтын медалең булсын!»— диде.

Көләләр.

Р е в а. Әни үзе ияреп китте.

Л ю ц и я. Әтинең бер дә алып барасы килмәгән иде аны.

Р е в а. Их, Люция! Әгәр дә мин герой кызы дигән дәрәҗәгә ирешсәмме?!

Л ю ц и я. Нишләр идең?

Р е в а. Бәләкәй генә борынымны күккә чөеп, урамнардан «мине күрәсезме?» дигән кебек, малай-шалайларга өстән генә карап узар идем, менә шулай итеп. (*Күрсәтә.*) Кызлар көнләшүдән шартлар иде!

Л ю ц и я. Хыял!

Р е в а. Хыял безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер хыял якын киләчәк!
Шушы шигырьне сөйләп, бәйгедә диплом алган Шәйморзина булам мин!

Л ю ц и я. Мактанчык!

Р е в а. Люция, кил әле, колагыңа гына бер сер әйтәм...

Л ю ц и я. Әйт.

Р е в а. Сатмассыңмы?

Л ю ц и я. Юк.

Р е в а. Аллаһи-билләһи! диген.

Л ю ц и я. Аллаһи-билләһи!

Р е в а. Син Аллага ышанмыйсың. «Честное комсомольское» диген.

Л ю ц и я. Мин комсомолга да ышанмыйм.

Р е в а. Кемгә ышанасың?

Л ю ц и я. Үземә. Әтигә, әнигә. Йә, әйт инде сереңне, Рева, әйт?!

Р е в а. Әнигә әйтмисеңме?

Л ю ц и я. Әйтмим инде, әйтмим. Йә...

Р е в а. Мин кичә эчтем.

Л ю ц и я. Лимонадмы?

Р е в а. Белмәдең.

Л ю ц и я. Коктейль?

Р е в а. Юк. Брудершафт.

Л ю ц и я. Нәрсә ул?

Р е в а. Шуны да белмисеңме? (*Бокалларга су сала.*) Мә, тот! Менә шулай эчтек. Аракы!

Л ю ц и я. Син... аракы!

Р е в а. Тс-с-с!

Л ю ц и я. Кемнәр белән?

Р е в а. Үзебезнең педучилище малайлары белән.

Л ю ц и я. Эчкәч нишләдегез?

Р е в а. Эчеп җибәрүгә, күз алларым яктырып китте. Бөтен тәнем рәхәтлек диңгезенә чумды. Шул халәттән чыгасы килмичә, назлы дулкыннарда тирбәлдем, аннары, мин сиңа әйтим, малайларның мут күзләренә карап, өздереп җырлап җибәрдем:

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем.
Мин сине сөям, чәчәгем,
Мәңгегә сөячәгем! Их!

Л ю ц и я. Аннары?

Р е в а. Аннарымы? Малайларның мине аңламауларына үпкәләп, елап җибәрдем.

Л ю ц и я. Чын сәрхуш кебек сөйлисең!

Р е в а. Аннары киттем биеп, малай, киттем биеп!

Л ю ц и я. Ахыры ничек бетәр моның? Сеңлем, эчмә бүтән, бетәсең бит!

Р е в а. Ахыры болай бетте: самбо алымы белән өч ма-

лайның өчесен өч якка очырдым. Алар мине исерек дип уйладылар. Ә мин аракы урынына су эчкән идем.

Люция. Әй лә, котны алдың. Чынлап эчкәнсең дип курыктым.

Рева. Алла бирсә, чынлап эчкән чаклар да булыр әле.

Люция. Самбо дигәне ярый... Әни әйтмешли, кызларга да бер ярап куяр.

Рева. Әти әйтмешли, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Люция. Егеткә әйләнеп барасың түгелме, җаным? Беләм, әтигә ярарга тырышасың.

Рева. Дөрес! Мин әтине кызганам. Ул мине малай булыр дип көткән. Мин туар алдыннан исемен дә әзерләп куйган: Рево! Их, үзем бер малай алып кайтырдай булам әтиемә!

Люция. Малай алып кайткан чакларың да булыр әле, Алла бирсә, әни әйтмешли...

Рева (*тәрәзәдән карап*). Ура! Әни кайта!

Люция. Үзе генә. Әти юк.

Әнисә керә.

Әнисә. Кызлар!

Люция. Ни булды?

Рева. Әти кайда?

Әнисә. Нишләргә?

Люция. Героймы?

Әнисә. Уф Алла!

Рева. Кремльгә алып киттеләрме әллә?

Әнисә. Ниләр генә эшләргә?

Люция. Черек күлгәме?

Әнисә. Күрәселәр бар икән...

Рева. Әти!

Люция. Әллә сөенечтән йөрәге...

Әнисә. Хәзер үз йөрәгем ярыла...

Люция. Алтын медаль кайда?

Әнисә. Уф... килә!

Люция. Кем?

Рева. Каян? Кемгә?

Әнисә. Безгә! Баракка!

Люция. Нигә? Каян?

Әнисә. Чит илдән?! Хәбәрче!

Люция. Чит илдән?!

Рева. Хәбәрче?!

Л ю ц и я. Булмас!

Р е в а. Ура! Әни, яшьме, картмы?

Л ю ц и я. Егетме? Кызмы?

Р е в а. Негрмы? Эфиопмы?

Ә н и с ә. Кем икәнен дә, каян икәнен дә белмим.

Л ю ц и я. Кайчан килә?

Р е в а. Сәгать ничәдә?

Ә н и с ә. Туктагыз, сөйләргә ирек бирегез... Бардым ияреп Габбас артыннан хәрби комиссариатка. Көтәм коридорда. Берзаман, мин сиңа әйтим, килеп чыкты бу — күзләре ялтырый, куллары калтырый җаныемның. «Бар, өйгә чап, әзерлән, безгә чит илдән хәбәрче килә!» — ди. Ә үзен хөрмәтләп, машинага утыртып, каядыр алып киттеләр. Мин өйгә чаптым.

Л ю ц и я. Башка бер сүз дә әйтмәдемени?

Ә н и с ә. Юк!

Р е в а. Аны бүләкләргә Кремльгә алып киткәннәр!

Ә н и с ә. Ой, кызлар, харап булабыз! Адәм мәсхәрәсенә калабыз! Шушы баракта! Кияргә җүнле күлмәгем дә юк бит, ичмасам!

Л ю ц и я. Ә минем? Мехкомбинатта эшләсәм дә...

Р е в а. Ә минем?

Ә н и с ә. Күпме йорт салып, яшәргә өең булмасын инде?!

Л ю ц и я. Борчылма, әни, менә үзе герой булып кайткач, барысын да бирерләр.

Р е в а. Алла бирсә...

Ә н и с ә. Алла бирәм дип торганда да, бирмәгән шәһәр советы бар бит әле аның. Түрәләрдән калтырап торган ул куркакка кем фатир бирсен?!

Р е в а. Әтигә «Батырлык өчен» медален юкка гына бирмәгәннәр...

Ә н и с ә. Шәхси батырлык өчен бит ул. Үзе өчен генә. Ул батырлыкның безгә бирәр файдасы тидеме? Герой исеме, фактически, миңа тиеш! Габбас Шәйморзин белән егерме елга якын бергә яши алуым өчен. (*Тәрәзәне ача.*) И-и, карагыз инде, кызлар, бөтен дөнья шау чәчәктә!

Л ю ц и я. Әтине каршы алырга әллә берәр бәйләм чәчәк алып керимме?

Р е в а. Мин! Мин алып керәм!

Ә н и с ә. Туктагыз! Кирәкми! Ул башта Алтын медален күрсәтсен!

Р е в а. Ул чәчәкләр ярата. Май җиттеме — тәрәзәне ача да, аккордеонына кушылып, шашып-шашып җырлый...

Л ю ц и я. Май аенда әллә нишли ул. Уйчан, моңсу, эчүдән-ашаудан туктый...

Ә н и с ә. Мәхлукның шул бер җыры бар инде...

Л ю ц и я (*көйләп*). «Каштаннар, каштаннар...»

Ә н и с ә. Онытыгыз әле шуны! Безгә чит илдән кунак килә! Ничек каршыларга? Ничек кунак итәргә? Кайда утыртырга? Нәрсә ашатырга? Йа Алла, буржуйлар алдында хурлыкка калабыз бит... Һинд чәе дә юк! Мәй дә юк... Эчеп бетергән. Социализм дошманнары бот чабып көләрләр инде! Бәет чыгарырлар!

Р е в а. Фельетон язарлар!

Л ю ц и я. Таптым! Әни, бездә аларда булмаган, чит илгә чыгарылмый торган нәрсә бар бит...

Ә н и с ә. Нәрсә ул?

Р е в а. Әтине шаштыра торган...

Л ю ц и я. Әтидән яшереп куйган...

Ә н и с ә. Ә...ә...ә, самогон! Ярамас, кызлар, аны куган өчен, Алла сакласын, шушы алачыгыбыздан да куарлар... Нишләргә?

Р е в а. Их, теге экияттәге кебек, алтын балык йөзеп килсен иде дә: «Җаныгыз ни тели, сорагыз!» — дисен иде икән...

Ә н и с ә. Фәрештәнең «Амин!» дигән чагына туры килсен!

Мамалеевның я р д ә м ч е л ә р е пәйда була.

М и н  Х а н о в и ч. Җаныгыз ни тели?

К и м  З а м о в и ч. Сорагыз!

Р е в а. Әллә сез экияттәге чуртан кушуы буенча эш итәсезме?

М и н  Х а н о в и ч. Мамалеев...

К и м  З а м о в и ч. Кушуы буенча!

М и н  Х а н о в и ч. Затлы кунакны каршы алу өчен сезгә иң беренче чиратта...

К и м  З а м о в и ч. Ни кирәк?

Р е в а. Кәнфит!

Л ю ц и я. Күлмәк!

Ә н и с ә. Һинд чәе!

М и н  Х а н о в и ч. Вакланмагыз! Иң беренче чиратта, сезгә чираттан тыш алынган...

К и м  З а м о в и ч. Өй!.. Кирәк!

Ә н и с ә. Анысына ышанмыйм. Егерме елдан булса булыр...

Мин Ханович. Шундый олы кунак килгәндә, нигә егерме ел көтәргә. Без сезне...
Ким Замович. Егерме ел алга...
Мин Ханович. Киләчәккә күчерәбез!

Машина сигналы.

Ким Замович. Киттек!
Мин Ханович. Минем арттан! Алга!
Әнисә. Туктагыз! Чүмеч булса да алыйм инде...
Рева. Көзгем...
Люция. Тарагым...
Рева. Аккордеон! Әти... (*Ала.*)
Мин Ханович. Берни дә алмыйсыз. Ул шуның өчен дә киләчәк дип атала, анда...
Ким Замович. Юк нәрсә, юк!

Декорация үзгәрә. Кыйммәтле мебель белән җиһазланган яңа йортның бер бүлмәсе пәйда була.

Мин Ханович. Рәхим итегез! Сез егерме елдан алачак өр-яңа өегездә!
Ким Замович. Оҗмах ишекләре ачык: төкле аягыгыз белән!!
Әнисә. Йа Аллам, күрәселәр бар икән!
Рева. Магнитофон!
Люция. Телевизор!
Әнисә. Келәм!
Рева. Сифон!
Мин Ханович. Кер юу машинасы!
Ким Замович. Суыткыч!
Мин Ханович. Ял итү залы!
Люция. Бакча!
Рева. Беседка!
Мин Ханович. Сауна!
Ким Замович. Кирәк икән ванна... ваннасында Анна...
Мин Ханович (*күз кысып*). Аз шаула!
Әнисә. Ярабби, ничә бүлмәле соң бу?
Мин Ханович. Ничә катлы диеп сорагыз.
Әнисә. Мин инде беркатлымын. Ничә катлы соң?
Мин Ханович. Ике катлы!
Әнисә. Бу оҗмахта кем яши соң?
Мин Ханович. Җитәкче работниклар! Алар халкыбызны шундый тормышка күчерү алдыннан озак ел-

лар эксперимент ясап карадылар. Хәзер алар оҗмахның тагын да югарырак фазасына күчтеләр.

Ким Замович. Вакытлыча.

Мин Ханович. Сиксәненче елларда барлык совет кешеләре оҗмахның беренче фазасына аяк басачак.

Ким Замович. Вакытлыча.

Мин Ханович. Ә хәзергә монда яшәү бәхете сезгә эләкте.

Әнисә. Аллаһе Тәгаләнең кодрәте...

Мин Ханович. Безнең партиябез хезмәт ияләренең тормышын ал да гөл итүгә...

Ким Замович. Зур әһәмият бирә. Совет власте елларында...

Әнисә. Эт оясында яшәдек...

Мин Ханович. Тс...с... Бу турыда ләм-мим! Ә тегеләрдә? Чит илдә?

Ким Замович. Эшләр харап анда! Череп таркалган! Төртсәң аварга тора.

Әнисә. Нигә төртмибез соң? Хәл юкмыни?

Мин Ханович. Кунак алдында бу хакта ләм-мим! Бу инструктаж сезнең өчен генә... Тагын шуны белегез, аларда җинаятьчелек елдан-ел арта...

Ким Замович. Урамнар караңгы...

Мин Ханович. Чөнки лампочка, шырпы кебек әйберләрне көндез шәм тотып эзләсәң дә табалмыйсың... Ә сезнең люстрадан күзләр чагыла!

Ким Замович. Аларда бүрек киеп чыксаң, бүрегеңне, тун кисәң, туныңны салдырып китәләр...

Әнисә. Аларда тун бармыни?

Мин Ханович. Миллионерлар турында сүз бара. Ә менә сезнең кебекләр кулларына талон тотып эзләсәләр дә, кибетләрдә кирәк әйбер табалмыйлар.

Әнисә. Нигә махсус магазиннан алмыйлар икән?

Мин Ханович. Бу хакта кунакка ләм-мим! Менә болар, Әнисә ханым, барысы да шуннан инде, үзегез генә белегез дә, телегезне бик озайтмагыз... Хөрмәтле ханым һәм туташлар, хәзер үзегезне «совет кешесе!» дип әйтерлек кыяфәткә кертегез!

Ким Замович. Чишенегез! Салыгыз!

Мин Ханович. Ягъни баштанаяк киенегез! Әнә теге бүлмәдә үзегез теләгән киемне сайлап алыгыз. Кунак үзегездән күзен алмаслык булсын! Сезгә — биш минут вакыт!

Әнисә (*чыгып китәр алдыннан*). Әй, сез!

Ким Замович. Боерыгыз, ханым!

Әнисә. Суыткычны яхшы саклагыз! Бушатмасыннар! (*Чыгалар.*)

Мин Ханович. Кара, кара моны, ничек сөйләшкән була. Әкияттәге балыкчы хатыны диярсең... (*Суыткычны ачып.*) Ким Замович!

Ким Замович. Мин Ханыч!..

Мин Ханович (*бокалларга коньяк салып*).

Без үзебез дөнья җаен
Таба торган егетләр!

Ким Замович. Җае килгән чагында
Каба торган егетләр!

Эчәләр.

Мин Ханович. Оҗмахка да без кертәбез,
Тәмугка да без!

Ким Замович. Үзебез — шайтан... Һәм үзебез
Фәрештә дә без!

Мин Ханович. Сакта торабыз оҗмахның
Ишек төбендә.

Ким Замович (*ишеккә барып*).
Кем ул? Юк! Юк! Сезгә оҗмах —
Әнә тегендә! Ха-ха-ха!

Мин Ханович. Үзебезнең — советский:
Оҗмах, тәмуг та!

Ким Замович. Бер типтереп калыйк әле
Хуҗалар юкта!

Мин Ханович. Ким!

Ким Замович. Мин Ханыч, әйт әле, нигә мине эте-бете кимсетә: тегендә — Мамалеев, монда — болар... Нигә мин — Ким, мин кемнән ким?

Мин Ханович. Исем-фамилияңнең койрыгын мин кисмәдем, Хәким Ни-Замович...

Ким Замович. Син дә бит Мөхәммәтәмин Миңнеханович, Мин Ханыч!

Мин Ханович. И дөрес! На кой чорт безгә, русча не белмес бабаларның дилбегә озынлыгы исемнәре!

Ким Замович. Мин Ханыч! Халык исәнлегенә! Дәүләт исәбенә!

Мин Ханович. Эчмим! Каршы киләм!

Ким Замович. Мин Ханыч, убедительно прошу вас не отказать в моей просьбе! Имзам...

Мин Ханович. Нишләп без халык исәнлегенә эчәргә тиеш? Безнең исәнлек өчен халык эчсен, и баста!

Ким Замович. Мин Ханыч, гениально!

Мин Ханович. Ә беләсеңме ни өчен?

Ким Замович. Мин Ханыч... сездән узып әйтә алмыйм...

Мин Ханович. Халык... бездән башка юк! Без булсак, халык бар, без булмасак...

Ким Замович. Халык юк и булмас та! И баста! Үзебез өчен!

Мин Ханович. То-то!

Ким Замович. Мин Ханыч, убедительно прошу... Гаҗәеп шул матур тавышыгыз белән бер җырлагыз әле... (*Кулына алма ала.*) Теге алманы...

Мин Ханович (*көчәнә*). Бер алманы бишкә бүләек! (*Чыкмый.*) Давай, син!

Ким Замович. Була ул!

Бер алманы бишкә бүлмәем,
Биш алманы үзем ашаем!

Мин Ханович. Афәрин!

Ким Замович. Хан Кимович!

Мин Ханович. Мин? Минме Хан? Хайван!

Ким Замович. Во! Хайван! Менә образлы итеп әйттегез, Мин... Хайванович... әй лә... Мин Ханыч...

Мин Ханович. Айны!

Ким Замович. Сез «хайван» дип дөресен әйтеп биру белән үк айныдым... Рәхмәт... Хан... Хан... Мин Ханыч... Йөрәккә үтәрлек итеп әйттегез!

Хатын-кызлар тавышы.

Мин Ханович. Полундра!

Затлы киенгән-ясанган хатын-кызлар керә. Кигән киемнәре килешми, шунлыктандыр, карачкыга охшап калганнар.

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз, үзегезнең киләчәктә киячәк затлы вә кыйммәтле киемнәрегезне күрсәтеп узыгыз!

Хатын-кызлар сәхнәдән үтәләр.

Мин Ханович. Күлмәк...

Ким Замович. Индийский!

Мин Ханович. Эшләпә...

Ким Замович. Польский!

М и н Х а н о в и ч. Сәгать...
К и м З а м о в и ч. Чистопольский!
М и н Х а н о в и ч. Җилпәзә...
К и м З а м о в и ч. Иранский!
М и н Х а н о в и ч. Джинсы...
К и м З а м о в и ч. Американский!
М и н Х а н о в и ч. Духи...
К и м З а м о в и ч. Французский!
М и н Х а н о в и ч. Фәрештәләр!
К и м З а м о в и ч. Хур кызлары!
Ә н и с ә. Кунак алдында хурга калмасак ярый инде...
М и н Х а н о в и ч. Так точно! Без аларны ничек тотарга өйрәтербез.
Р е в а. Әни, джинсы килешәме? Кунак ошатыр микән?
Ә н и с ә. Курчактан һич ким түгел... Ә мин буржуйлар алдында башымны менә шулай югары тотарга исәп!
Л ю ц и я. Мине күрегез, мине!

Көзге алдында бизәнәләр.

М и н Х а н о в и ч. Хөрмәтле иптәш Шәйморзина, машина сезнең карамакта! Әнә!
Ә н и с ә (*тәрәзәгә карап*). Минеке?
М и н Х а н о в и ч. Сезнеке!
Ә н и с ә. Шул кара машинамы?
М и н Х а н о в и ч. Шул кара машина.
Ә н и с ә. Мин утырырга да хыялланмаган, түрә хатыннары узганда көнләшергә дә базмаган... мин... шуңа утыраймы?
М и н Х а н о в и ч. Һичшиксез!
Ә н и с ә. Мин аңа нигә утырам соң? Әллә кая алып китмәсләрме?
М и н Х а н о в и ч. Борчылмагыз, сезне «ялт!» иттереп китереп куярлар.
Ә н и с ә. Ә мин кая барыйм соң?
М и н Х а н о в и ч. Кая барасыгыз килә?
Ә н и с ә. Әйтергә дә оялам...
М и н Х а н о в и ч. Оялып тормагыз.
Ә н и с ә. Машинага утырып бер шәһәрне әйләнергә дигән хыялым бар иде барын...
М и н Х а н о в и ч. Әйләнегез!
Р е в а. Мин дә!
Л ю ц и я. Мин дә!
М и н Х а н о в и ч. Юк, кызлар, сезгә ярамый!

К и м  З а м о в и ч. Сез монда каласыз.

Ә н и с ә. Минем белән бер җилләнеп килсеннәр әйдә!

М и н  Х а н о в и ч. Мөһим дәүләт эше! Без аларга хәзер инструктаж үткәрәбез.

Р е в а. Мин риза!

Л ю ц и я. Нинди инструктаж?

М и н  Х а н о в и ч. Сыйнфый сизгерлегегезне чамалап карыйбыз.

Р е в а. Мин риза!

Л ю ц и я. Чамалап!

Ә н и с ә. Алайса, минем сизгерлекне дә карагыз.

К и м  З а м о в и ч. Мин Ханович, инструкция бу өлкәдә тәҗрибәсе әзрәк булган яшьрәк кешеләрне күз алдында тота.

Ә н и с ә. Хәерлегә булсын... Кызлар, карагыз аны, мин биргән инструкциядән чыкмагыз! (*Китә.*)

М и н  Х а н о в и ч. Ситуация шундый, кызлар... Абыстай китте. Кая, Ким Замович, фәрештәләр белән бер сайрашып алыйк әле...

К и м  З а м о в и ч. Өстәлгә елышыгыз, сандугачлар!

Рева тиз генә килеп утыра.

Л ю ц и я. Сез... инструкция дидегез...

М и н  Х а н о в и ч. Инструктаж менә шул инде. Ягъни затлы кунак белән өстәл янында ничек утырырга, ничек аңа ярарга?

Люция утыра.

Р е в а. Каян алдыгыз шундый тәмле шоколадны?

К и м  З а м о в и ч (*бокалларга коеп*).

Эчеп җибәр салганны,
Сорама каян алганны! Их!

Р е в а. Кунак шулай җырлаячакмы?

М и н  Х а н о в и ч. Юк! Болай тупас кыланмас. Ул сүзен менә ничек башлар... (*Кулына бокал тотып.*) Ким Замович, теге кунак ничек күтәрткән иде әле?

К и м  З а м о в и ч (*торып*). Мөхтәрәм әфәнделәр һәм сөйкемле туташлар! Мин, бөтен дөньяны әйләнеп чыгып, сездәй совет кызларыннан да гүзәл затларны күрмәдем. Сезнең энҗедәй ак тешләрегез, беленер-беленмәс кенә тибрәнгән ак түшләрегез, аккошныкыдай саф муенnарыгыз хөрмәтенә... Нәрсә? Бер тост!

Мин Ханович. Кызлар, басыгыз, эчегез!
Люция. Мин эчмим.
Рева. Мин дә!
Мин Ханович. Кунак моны үзенең дәүләтен хөрмәт итмәү дип кабул итәчәк. Сезнең тарафтан бу сәяси сукырлык... Ягъни илебезнең абруен төшерү... Ягъни ике дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне какшатырга омтылу...
Рева. Мин эчәм... брудершафт!
Люция. Мин дә... брудершафт!

Кызлар, эчкән булып яшереп кенә, шәрабны түгәләр.

Мин Ханович. Сәяси яктан өлгереп киләсез... Мактыйм!
Рева. Мин исердем.
Люция. Мин дә.
Мин Ханович. Исергәнегезне каян беләсез?
Рева. Җырлыйсым килә!
Люция. Минем дә!
Мин Ханович. Рөхсәт!
Рева (*көйләп*). «Апасыннан матур сеңлесе...»
Люция (*бүлдереп*). «Сеңлесеннән матур апасы...»
Мин Ханович. Ким Замович, сиңа апасы!
Ким Замович. Мин Ханович, сиңа сеңлесе!
Мин Ханович. Инструктаж үткәрү өчен шәп момент! Ким Замович, сез инструктажны апасы белән аерым бүлмәдә үткәрәсез!
Ким Замович. Тыңлыйм, Мин Ханович! Люция иптәш, узыгыз!
Люция. Мин... иптәш түгел!
Ким Замович. Люция, киттек...
Люция. Кермим!
Ким Замович. Мин Ханович?
Мин Ханович. Иптәш Шәйморзина, сез нәрсә, илебезнең абруен төшерергә уйлыйсызмы?
Люция. Юк, уйламыйм!
Ким Замович. Рәхим итегез.

Икенче бүлмәгә чыгалар.

Рева. Йә?
Ким Замович. Нәрсә йә?
Рева. Башладык!

Мин Ханович. Ягъни? Нәрсәне?

Рева. Инструктажны.

Мин Ханович. Ә...ә... ә... Әйе, Рева, әллә, мин әйтәм...

Рева. Юк, мин әйтәм!

Мин Ханович. Әллә... мәйтәм... инструктаж алдыннан бер... нитеп алабызмы?

Рева. Нитеп?

Мин Ханович. Әйе... нитеп... ягъни...

Рева. Сез дә мин уйлаганны уйлыйсыз икән.

Мин Ханович. Мактыйм!

Рева. Әйдә соң...

Мин Ханович. Без башта кыюлык өчен... ниту алдыннан... нитеп алыйк... Брудершафт?

Рева. Нәкъ шулай. (*Рюмкаларга сала.*) Тотыгыз!

Мин Ханович. Яшәсен Рева-люция!

Рева. Ура! (*Эчкән булып, шәрабны түгә.*) Ничек мин моңа кадәр эчмәгәнмен. Искиткеч рәхәт! Эшли башлагач, мин бөтен хезмәт хакымны эчүгә тотачакмын...

Мин Ханович. Нәкъ шулай. Сиксәненче елларның кызлары менә синең кебек кыю булачаклар! Ягъни үзләрен шулай тотачаклар!

Рева. Тотачаклар? Кемнәр тотачак? Без тотканны көтеп тормаячакбыз. Үзебез тотачакбыз! Йә, башлагыз инструктажны, Мин Ханович!

Мин Ханович. Тәк... тәк... син менә бу кәнәфидә тирбәнеп китап укып утырган буласың, янәсе... шулвакыт... яныңа теге без көткән чит ил хәбәрчесе килеп керә. Но, Рева, искәртеп куям: ул ни тели — син шуны эшләргә тиеш! Аңладың? (*Музыка куя.*)

Рева. Мин һәрвакыт әзер!

Мин Ханович (*чыгып китә дә, кыяфәтен үзгәртеп, кире керә*). Чао, мадам!

Рева. Мао!

Мин Ханович. Тукта! Кузгалмагыз! Күкрәгегезне ача төшегез! Тагын... тагын... тагын да! (*Ревага якыная.*) Сездә нинди мәкаль бар әле? «Татар тотып карамыйча ышанмый», шулаймы?! Дөрес әйткәннәр сезнекеләр... (*Кызга үрелә.*) Мадам... мадам...

Рева. Надан! Мин мадам түгел!

Мин Ханович. Тс... с... с... Инструктажны бозмагыз... Хәзер, Рева, диван янынарак утырыгыз. Тәк. Шулай. Әйбәт! Сез кунакка кычкыра күрмәгез! Престиж! Ярамый! (*Кунак булып.*) Гүзәл кыз, сезнең яныгызга утырырга мөмкинме?

Р е в а. Утырыгыз!

М и н Х а н о в и ч. Йомшак кына әйт. «Утырыгыз...» Кунак теләсә теләмәсә дә, утырырлык булсын. Мөмкинме?

Р е в а. Утыра бирегез...

М и н Х а н о в и ч. Әйбәт! Онытма, көнбатышта кызларның гүзәллеген мактап тормыйлар, шундук киемнән тотыналар. О! Бу джинсы сезгә ничек килешә! Сез аны кимәсәгез, тагын да чибәррәк күренер идегез. Тәнегезнең назлылыгын джинсы аркылы да тоеп торам. (*Реваны капшарга тотына.*) О, эфиоп джинсысы! О!

Р е в а. Эфиопиядән кулыгызны алыгыз!

М и н Х а н о в и ч. Ярый... ярый... алайса... Европага күчик.

Кызга үреләә. Реваны екмакчы була. Рева кинәт аны самбо алымы белән атып бәрә. Мин Ханович келәмгә барып төшә. Икенче ишектән Ким Замович та аның янына очып төшә. Алар бер-берсенә аптырап карап торалар.

К и м З а м о в и ч. Хан... мин... Син — Ханович?

М и н Х а н о в и ч. Мин — Ханович... Ә син... Зам?

К и м З а м о в и ч. Ким Замович...

М и н Х а н о в и ч. Рева!

К и м З а м о в и ч. Люция!

М и н Х а н о в и ч. Доложить итегез: инструктаж уңышлы төгәлләндеме?

К и м З а м о в и ч. Сездән калышмаска тырыштык, Мин Ханович!

Л ю ц и я керә.

Л ю ц и я. Шуның белән бетте дәмени?

Ә н и с ә керә.

Ә н и с ә. Әй, дөнья рәхәтләре! Инструктаж? Сез нишләп келәмдә?

М и н Х а н о в и ч. Келәмнең сыйфатын сыныйбыз... (*Тора.*)

К и м З а м о в и ч. Шактый каты! (*Тора.*)

Р е в а. Иптәшләр, шундый уңышлы инструктаждан соң әллә бераз... нитеп алабызмы?

М и н Х а н о в и ч. Юк, юк, юк! Мөһим чаралар вакытында безгә ярамый! (*Югалалар.*)

Машина сигналы ишетелә.

Л ю ц и я (*тәрәзәгә бара*). Килде!
Ә н и с ә. Утырышыгыз!
Р е в а. Машинасыннан төште!
Л ю ц и я. Джентльмен!
Р е в а. Маэстро! Итальяно!
Ә н и с ә. Урыннарыгызга!
Л ю ц и я. Туп-туры безгә килә!
Р е в а. Өебезгә сокланып карап тора...
Ә н и с ә. Уф Алла! Сәяси хатадан саклый күр!
Р е в а. Магнитофон!

Музыка куя. Утырышалар. Ишектә — танымаслык итеп киендерелгән Г а б б а с.

Г а б б а с (*тегеләрне күргәч, аптырап кала*). Чао!
Ә н и с ә. Чего? Кого? Татарчао!
Р е в а. Чао, джентльмен!
Л ю ц и я. Чао, камарадо!
Г а б б а с (*бүлмәне карап йөри, өстәл янына килеп, япманы ачып карый.*) Грандиоз! Грацио!
Ә н и с ә (*артыннан бара*). Биш бүлмәле... лоджи!
Г а б б а с. О, лоджи!
Л ю ц и я. Ванна...
Р е в а. Душ...
Г а б б а с. Кит аннан! Булмас! Валлаһи-билләһи, диегез!

Барысы да аптырап калалар.

Р е в а. Әти?!
Л ю ц и я. Ә без сине...
Ә н и с ә. Шадра шайтан, синмени бу?!
Г а б б а с. Бу мин, кызлар, мин... (*Идәнгә җәелгән келәмгә басарга да кыймыйча, сак кына атлап зур көзге алдына баса.*) Исәнмесез, кадерле Габбас Садыйкович! Ниһаять, сине гомереңдә бер мәртәбә хөрмәтләделәр. Шушы көнгә килеп җиту турында син күпме хыялландың. Кырык дүрт ел гомер итеп, шушы башыңа бер тапкыр эшләпә алып киялмәдең, атаңнан, абыеңнан калган иске бишмәттән, гимнастеркадан, шинельдән башка җүнле кием күрмәдең, күпме адәмнәрне өйле итеп, үзеңә бер куыш салалмадың, гел хыял эчендә яшәдең. Хакың бар идеме адәмчә бер тормыш күрергә? Әллә юкмы? Бар хакың, хөрмәтле иптәш Шәйморзин, бар! Сәлам! Чао!
Л ю ц и я. Әти, чит ил кунагы кайда?

Габбас. Самолет соңлый. Фатирны күрергә дип, тиз генә машинада кайттым. Хәзер китәм.
Рева. Әти, герой булдыңмы?
Габбас. Шул чама.
Рева. Әйттем бит!
Люция. Котлыйм, әти!
Рева. Нинди вакыйга өчен?
Габбас. Чехословакия. 1945.
Люция. Әти, сөйлә!
Рева. Сөйлә!
Габбас. Хәзергә вакыт юк... Шунда... бер һөҗүм өчен инде...
Люция. Нинди һөҗүм?
Рева. Кемгә?
Габбас. Гап-гади бер һөҗүм...
Рева. Әти, тыйнак булып кыланма. Бәлки, син күкрәгең белән дошман амбразурасын каплагансыңдыр?
Габбас. Амбразура түгел түгелен. Тик шул чама... Сез хатын-кыз халкы аңларлык түгел! Катлаулы!
Рева. Берүзең бик күп фашистларны дөмектергәнсеңдер, әти, шулаймы?
Габбас. Юк. Үтергән өчен түгел. Киресенчә.
Люция. Ничек киресенчә? Үтермәгән өченме?
Габбас. Әйе! Әйе! Әллә сез, сугыш дигәч тә, гел үтереп, штык белән кадап, чәнчеп кенә йөриләр дисезме?
Әнисә (*озак карап, күзәтеп торганнан соң*). Габбас!
Габбас (*куркып китә, урә катып*). Тыңлыйм!
Әнисә. Кил әле яныма!
Габбас. Килдем.
Әнисә. Утыр.
Габбас. Утырдым.
Әнисә. Карале күзләремә.
Габбас (*күзләрен читкә алып*). Карадым.
Әнисә. Күзләреңне нигә яшерәсең?
Габбас. Яшермим, менә ич... тутырып карыйм...
Әнисә. Кызлар, сез дә утырыгыз. (*Габбасны урап алып утыралар.*) Әйт хәзер: син героймы, түгелме?
Габбас. Кем ничек карый бит...
Әнисә. Ничек?
Габбас. Мин үземне, мәсәлән, герой итеп тоям.
Әнисә. Тоясың?
Габбас. Тоям... шикелле... сыман...

Ә н и с ә. Алты медалеңне унҗиде ел күреп торам. Алтын медалең кайда?

Г а б б а с. Алтын медаль алмыйча да геройлык күрсәтергә мөмкин әле.

Ә н и с ә. Документ?!

Г а б б а с. Документ?! Әлегә юк...

Ә н и с ә. Кайда?!

Г а б б а с. Батырлык күрсәткән җирдә. Тиздән кайтып җитәр, диделәр.

Ә н и с ә (*Габбасның өстенә бара.*) Шадра шайтан, нинди батырлык кылдың, ә?! Әйтәсеңме, юкмы?!

Уратып алалар.

Г а б б а с (*чыдамлыгы бетеп, сикереп тора*). Сез нигә миннән гестапо сымак сорау аласыз?! Фашистлар кулына эләгеп тә Габбас Шәйморзиннан бер сер алалмадылар! Бәлки, минем кылган батырлыгым хәрби сердер! Бәлки, ул серне үз хатыныңа, балаларыңа әйтергә ярамыйдыр? Килер бер көн: кайчандыр яшерен саналган серләр ачылыр... Бәлки, әле Габбас Шәйморзинны берзаман мировой масштабтагы герой дип сагынып, елап искә алырлар. (*Кычкырудан туктап, әкрен генә.*) Сезгә генә сернең бик кечкенә өлешен ачам: бәлки, минем геройлыкны әлегә халыктан яшерергә кирәк булгандыр? Бәлки, ул бүгенге хәбәрдарлык рамкаларына сыймый торгандыр? Шуңа күрә сез дә минем серемне берәүгә дә, беркемгә дә ачмагыз... Төшендегезме? (*Машина сигналы.*) Мин — аэропортка! Көтегез! Сынатмагыз! Чао! (*Чыга.*)

Ә н и с ә. Тәмам бутады башны, берни дә аңламыйм?!

Р е в а (*табын янына килеп*). Әни, түзәр хәл калмады, ачыктым... (*Шоколад ала.*)

Л ю ц и я (*тартып алып, кире куя*). Читләр өлешенә кермә, бер тамагыңа хуҗа бул!

Ә н и с ә. Гомер буе ачлы-туклы яшәп, күпкә түзгәнне әзгә генә түзегез инде, балалар!

Р е в а. Әни, фокус! (*Өстәлдәге япманы ача.*) Ой!

Л ю ц и я. Әфлисун! Йөзем!

Ә н и с ә. Кара икра, кызыл икра!

Р е в а. Әрмән коньягы!

Ә н и с ә. Оҗмахның...

Л ю ц и я. Беренче фазасы!

Ә н и с ә. Ни өчен Ходай Тәгалә күпләр арасыннан безне генә якын күреп, оҗмахка кертеп куйды икән? Әллә без-

нең гомер буе газап чигеп яшәвебезне күреп кызганды инде... Тәмам хур кызларына әйләндек бит.

Рева (*йөземне кабып*). Телне йотарлык!

Люция. Әбәү, тәмсез! Икра... Тфү!

Әнисә. Кызлар, бер генә локма ризыкка да кагыласы булмагыз! Ул безгә түгел, чит ил кунагына. Соңыннан рәхәтләнеп ашарбыз... калса...

Рева. Калмаса?..

Әнисә. Утырыгыз әле табынга. Репетиция ясап карыйк. Кунак алдында мин сезне үтереп кыстаган булырмын, яме? Ә сез?

Люция. Рәхмәт, ашыйсым килми...

Рева. Мерси! Их бин нихт ессен...

Әнисә. ...дигән булырсыз.

Рева. Ярый, әни.

Люция. Түзәргә тырышырбыз. Сине үзеңне дә кыстыйкмы?

Рева. Кыстыйбыз!

Әнисә. Кыстый күрмәгез, онытып җибәреп, өстәлдәге бөтен ризыкны харап итәрмен. Ходай безнең һәммәбезгә аерым-аерым түземлек бирсен! Аллага шөкер, сезнең авызларыгыз уймак кебек кенә, үземә охшагансыз, балакайлар! (*Табынны ябып куя.*) Кызыктырып тормасын!

Рева (*күреп*). Телефон! Нигә безгә беркем дә шылтыратмый?

Люция. Җүләр, бездә телефон барын кем белә!

Рева. Барак кызлары нишләп яткан була икән, мескеннәр?

Люция. Борчылма, алар да егерме елдан безне куып җитәрләр.

Рева. Ә без ул чакта тагын егерме елга алга киткән булырбыз!

Люция. Кызлар мине күргәч танымаслар да инде.

Кыңгырау тавышы. Үз урыннарына утыралар.

Рәхим итегез!

Мирослав керә. Гади генә киенгән. Иңендә — фотоаппарат.

Мирослав. Исәнмесез!

Тегеләр рәсми тонда, теләмичә генә исәнләшәләр.

Мин ялгыш кермәдемме?

Ә н и с ә. Ни йомыш? Безгә зур кунак киләсе... син аяк астында бик буталып йөрмә инде, энекәш!

М и р о с л а в. Гафу итегез. Бу — Шеймурзин фатирымы?

Ә н и с ә. Дөрес кергәнсез. Узыгыз!

М и р о с л а в. Рәхмәт. Шеймурзин үзе кайда соң?

Ә н и с ә. Мөһим дәүләт эше белән китте.

М и р о с л а в. Сезнең үзегезне кем дип белик?

Ә н и с ә. Без үзебез Шәйморзинның, китапча әйткәндә, тормыш иптәше, искечә әйткәндә, җәмәгате, дөресен әйткәндә, хатыны булабыз.

М и р о с л а в. Шәймурзин өйләнгән кешемени? Уйламаган идем.

Р е в а (*Әнисәнең колагына*). Казан хәбәрчесе...

Ә н и с ә. Ул да уйламаганда өйләнде. Фронттан кайтты да, шушы биш айлык Люция кызым белән тотты да алды. Әмма хатыныннан бик уңды.

М и р о с л а в. Бу кызлар Шеймурзинның балалары? Гаҗәп!

Ә н и с ә. Алар минеке дә!

М и р о с л а в. Гаҗәп! Көтмәгән идем...

Ә н и с ә. Әллә сез минем герой иремне бала тудырырга да сәләтсез дип уйлыйсызмы?

М и р о с л а в. Юк, Шеймурзина ханым, киресенчә...

Ә н и с ә. Ничек киресенчә?

М и р о с л а в. Бу өлкәдә зур уңышларга ирешкән димәкче булам.

Ә н и с ә. Иреште, бик иреште, Аллага шөкер. Без аның белән горурланабыз.

Р е в а. Ул минем малай булуны бик теләгән.

М и р о с л а в. Сез Шеймурзинны теләгенә ирешә алмас дип уйлыйсызмы?

Ә н и с ә. Соң инде... Аның өчен сугышта герой булу гына җитми.

М и р о с л а в. Мин Шеймурзинга ышанычымны югалтмыйм.

Л ю ц и я. Әллә сез безнең әтине беләсезме, иптәш хәбәрче?!

М и р о с л а в. Кызганыч, минем аны күргәнем юк. Әмма бик күрәсем килә. Сез минем шәһәр хәбәрчесе икәнне каян беләсез? Кем дип әйтим...

Р е в а. Рева.

М и р о с л а в. Рева сеңлем...

Л ю ц и я. Люция.

М и р о с л а в. Люция сеңлем...

Ә н и с ә. Әнисә.

М и р о с л а в. Әни... сә? Таныш булыйк: шәһәр газетасының штаттан тыш хәбәрчесе Мирослав.

Ә н и с ә. Сез, иптәш, чит ил кунагы килгәнче, тормыш шартлары белән таныша торыгыз. Менә без шулай яшибез инде! Яхшы яшибез!

М и р о с л а в (*исе китмичә генә карап йөри дә аккордеон янында туктап кала*). О, аккордеон!

Ә н и с ә. Игътибар итмәгез. Иске ул... сугыш трофее... Безнең барысы да өр-яңа! Карагыз! Телефон да бар!

М и р о с л а в. Тотып карарга мөмкинме?

Р е в а. Мөмкин!

М и р о с л а в (*кулына гармунны ала да әкрен генә уйный, аннары җырлый*).

Каштаннар, каштаннар,
Җылы язда бөреләнеп,
Чәчәкләрен ачканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Нурда коенырга теләп,
Зәңгәр күккә ашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Язларың да, назларың да
Йөрәккә тоташканнар.

Җырга Люция белән Рева да кушыла.

Л ю ц и я. Сез әти җырын каян беләсез?

М и р о с л а в. Әти җыры? Юк, бу әтиләр җыры гына түгел, әниләр җыры да.

Ә н и с ә. Табынга игътибар итегез, иптәш! (*Табынның өстен ача.*) Без менә шушылай яшибез инде, энекәш! Җаныбыз ни тели, шуны ашыйбыз, эчәбез! Балда-майда йөзәбез! (*Табынны ябып куя.*) Аллага шөкер, җитмәгән нәрсәбез юк! Блокнотыңа язып куй! Өебез дә стадион кебек!

Машина сигналы ишетелә.

Л ю ц и я. Әти кайта!

Р е в а. Кунакны алып кайта! Әтиебез!

М и р о с л а в. Әтиебез?!

Г а б б а с кайтып керә.

Р е в а. Әти, безгә хәбәрче килде!

Ә н и с ә. Кайда чит ил кунагы?

Г а б б а с. Самолет килгән... Каршыларга өлгермәдем...

М и р о с л а в. Шеймурзин Аббас?

Г а б б а с (*хәвефкә төшеп*). Әйе... мин... Шәйморзин Габбас...

М и р о с л а в. Мин сезне чит илдән Чехословакиядән эзләп килдем...

Р е в а. Чит илдән?

Л ю ц и я. Чехословакиядән?

Ә н и с ә. Эзләп... килдең?

М и р о с л а в. Мин... синең улың... Мирослав. Исәнме, әти?

Габбаска таба атлый. Туктап кала. Барысы да бер мизгелгә хәрәкәтсез басып торалар.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук фатир. Шул ук күренеш. Г а б б а с, Ә н и с ә, Л ю ц и я, Р е в а, М и р о с л а в.

Ә н и с ә. Әти?! Нинди әти?

Р е в а. Ул минем әти!

Л ю ц и я. Ул минем дә әти!

Ә н и с ә. Ул — безнеке!

М и р о с л а в (*уңайсызланып*). Гафу итегез... Бәлки, мин ялгышамдыр...

Ә н и с ә. Ялгышасыз, ялгышасыз... (*Габбаска.*) Нигә катып калдың? Әйт ялгыш килгәнсең дип... (*Габбас дәшми.*) Әйт, Габбас җаным, әйт!

М и р о с л а в. Сез 1945 елның маенда Наход каласын фашистлардан азат итүдә катнаштыгызмы?

Г а б б а с. Катнаштым.

Ә н и с ә. Анда миллион Шәйморзин катнашкан. Шулаймы, Габбасик? Ник дәшмисең? Әллә шулай түгелме?

Г а б б а с. Анысы — хәрби сер.

М и р о с л а в. Сез госпитальдә яттыгызмы?

Ә н и с ә. Ятмады, ятмады!

М и р о с л а в. Яттыгызмы?

Ә н и с ә. Габбас җаным, ятмадың бит?

Г а б б а с. Яттым!

М и р о с л а в. Шунда сезне дәвалаган унсигез яшьлек шәфкать туташын хәтерлисезме?

Ә н и с ә. Юк, юк, хәтерләми! Мин үзем дә шәфкать туташы... миллион кеше дәваладым, тик берсе дә эзләп килми...

М и р о с л а в. Хәтерлисезме, Орлицкий тауларын?!

Г а б б а с. Орлицкий таулары? Наход каласы? (*Ерактан әкрен генә таныш көй ишетелә.*)

М и р о с л а в. Сез әле әнигә менә шундый җыр җырлагансыз. Хәзер аны бөтен шәһәр белә. (*Рева аңа аккордеон суза. Мирослав уйнап җырлый.*)

Каштаннар, каштаннар...

Г а б б а с (*түзә алмыйча кушыла*).

Каштаннар, каштаннар...
Җылы язда бөреләнеп,
Чәчәкләрен ачканнар.

Люция белән Рева да кушыла.

Каштаннар, каштаннар,
Әллә инде минем сыман
Каштаннар да шашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Йөрәк серен ачканнар да
Үкси-үкси качканнар...

Әнисә кызганыч кыяфәттә бер читтә басып тора.

Г а б б а с (*кочагын җәеп, Мирославка таба бара*). Улым! (*Кочаклый.*)

М и р о с л а в. Әти! Мин сине күрү турында гомерем буе хыялландым...

Әнисә кызларын икенче бүлмәгә алып кереп китә.

Г а б б а с. Кичер мине, балам... Мин сине күрермен дип уйламаган да идем. Төшләремә керә идең керүен...

М и р о с л а в. Мин сине төшләремдә зур гәүдәле, озын буйлы баһадир итеп күрә идем.

Г а б б а с. Чәчләрең нәкъ минеке сыман саргылт, йомшак... (*Башыннан сыйпый.*)

М и р о с л а в. Нинди рәхәт... Тагын бер генә чәчләремнән сыйпа, әти. Башкаларны әтиләре иркәләгәндә, мин качып елый идем.

Г а б б а с. Хәзер сине беркем дә кимсетә алмас... Әниең исәнме, Мирослав?

М и р о с л а в. Исән-сау.

Г а б б а с. Сез икегез генә яшисезме?

М и р о с л а в. Без — дүртәү.

Г а б б а с. Тагын кемнәрегез бар?

М и р о с л а в. Тагын бер әти. Тагын бер сеңлем.

Г а б б а с. Ул... бәхетлеме?

М и р о с л а в. Без бәхет турында сөйләшмичә генә яшибез, әти.

Г а б б а с. Әйе, шулайдыр шул...

М и р о с л а в. Әти, син минем әнине чынлап та яраттыңмы?

Г а б б а с. Яратмасам, син булыр идеңмени? Улым...

М и р о с л а в. Син минем дөньяда барлыгымны белдеңме?

Г а б б а с. Мин синең йөрәк тибешеңне тоеп киттем. Юк, мин китмәдем. Мине хәрби часть белән алып киттеләр.

М и р о с л а в. Димәк, син миннән баш тартмыйсың, Шеймурзин?

Г а б б а с. Юк. Үз балаңнан ничек баш тартмак кирәк?!

М и р о с л а в. Димәк, әни сине юкка гына яратмаган, син аның мәхәббәтенә лаек.

Г а б б а с. «Әти!» дип, бөтен дөньяга кычкырып әйтәләсең, улым Мирослав. Сине әниең җибәрдеме, әллә үзең мине эзләп килдеңме?

М и р о с л а в. Мин сине үзем эзләп килдем, әти.

Г а б б а с. Әниең?

М и р о с л а в. Әни миңа унсигез яшь тулуны өзелеп көтте. Бездә шундый гадәт бар: атасыз үскән бала, унсигез яше тулгач, үзенең әтисен эзләп табарга тиеш. Әтисе аны эзләмәсә дә... Үз баласы итеп танымаса да, ул аны гомерендә бер тапкыр булса да күреп китәргә тиеш. Әти, әйт әле, нигә сез, бер-берегезне яраткан ике яшь кеше, кавыша алмадыгыз?

Г а б б а с. Бу сорауга мин үзем дә гомерем буе җавап эзлим. Нигә без кавыша алмадык? Замана, дәүләт кануннары безгә «Ярамый!» диделәр, арабызга тимер пәрдә кордылар. «Ярамый!», «Ярамый!», «Ярамый!» Безнең

мәхәббәтебез шәфкатьсез чор язган кыргый кануннарның корбаны иде. Мине чех кызын ятратканым өчен гаепләделәр, җәзага тарттылар, аңардан баш тартырга мәҗбүр иттеләр.

Мирослав. Син безнең илебезне фашист өереннән азат иткән герой. Ни өчен соң син шул кешелексез кануннардан да дөньяны азат итмәдең?

Габбас. Үзебезнең дәүләт канунарына без икебез дә сукырларча табына идек, Мирослав. Димәк, минем геройлыгым дошманга каршы көрәшкәндә генә күренгән. Мәхәббәт корбаннар сорый!

Мирослав. Юк, әти, миңа синең исән булуың кадерлерәк. Мин әти кешеләрне, нәкъ менә синең кебек итеп, күз алдыма китерә идем.

Габбас. Күз тимәсен, гел үземнең яшь чагыма охшаган егет булып өлгергәнсең! Әнисе! (*Әнисә керә.*) Рева! Люция! (*Керәләр.*) Менә... ир туганыгыз килгән. Мирослав...

Мирослав. Шеймурзин.

Габбас. Мирослав Шәйморзин! (*Тегеләр аптырап карап торалар.*)

Рева (*сөенеп*). Исәнме, абый?

Габбас. Рева сине абыең итеп таныды. Люция?

Люция. Исәнмесез... (*Әнисәгә карый.*) Шәйморзин.

Габбас. Тагын бер кызым туганы итеп таныды. Факт! Әнисе? Әнисә, хәзер эш синдә калды...

Мирослав. Әни?

Әнисә. Мин... Әни... сә!

Габбас. Дөрес! Мирославның да әнисе!

Мирослав. Әни...сә, сезгә Чехословакиядә калган әни... сәдән сәлам!

Габбас. Вәгаләйкем әссәлам!

Әнисә. Габбас, җаным, шулай ук синнән колак кагармын микәнни? Юк, мин сине читләргә бирмим! (*Габбасның кулларыннан тотып.*) Бирмим! Син үзебезнең... советский әти!

Рева. Әни, безнең әти советский гына түгел, безнең әти — мировой!

Габбас (*Әнисәне читкәрәк алып китеп*). Хөрмәтле тормыш иптәшем... Онытма, бу минутларда безгә бөтен дөнья карап тора! Иреңнең генә түгел, илеңнең киләчәге турында да уйла! Мамалеев... (*Ымлап квартираны күрсәтә.*)

Ә н и с ә (*аңлап, уйнап*). Хуш киләсез, төкле аягыгыз белән, чит илләрдән килгән...

Г а б б а с. Балабыз...

Ә н и с ә. Балагыз... (*Габбас ишетелерлек итеп кенә.*) Шадра шайтан, күрсәтермен әле мин сиңа күрмәгәнеңне!

Г а б б а с. Балабыз Мирослав...

Ә н и с ә. Балабыз кебек кадерлебез Мирослав! (*Габбаска.*) «Сине генә яратам», имеш... Иблис! (*Кычкырып.*) Әтисе, чит илләрдән килгән кунакны табынга чакыр! Рәхим итегез, Мирослав! (*Габбаска.*) Кунагың гына китсен, кызган табага бастырам әле мин сине!

М и р о с л а в. Таба дидегезме?.. Аңламадым...

Ә н и с ә. Коммунизмга таба барабыз димәкче идем... Хөрмәтле тормыш иптәшем, сез дә утырыгыз... (*Габбаска.*) Җаныңны алам әле мин синең, егерме ел яшереп йөргәнең өчен!

М и р о с л а в. Җаныңны... Нинди матур сүз!

Ә н и с ә. Без шулай аның белән «җаным-бәгърем» дип кенә сөйләшәбез инде, гаеп итмәссез. (*Табын өстен ачып җибәрә.*) Шушы әтиебез аркасында без менә шул хәлләргә ирештек инде, Мирослав! Аллага шөкер, шәһәр советы безнең хакта бик кайгырта. Тормышыбыз ал да гөл! Социализмның аргы ягына чыгып, аяк салындырып утырабыз. Шушындый зур уңышларга ирештек әтиебез аркасында!

М и р о с л а в. Мин дә үземне киләчәктә яшәгән кебек хис итәм.

Г а б б а с. Дөрес, улым... Фактически без бүген мең дә бер йөз алтмышынчы елларда түгел, туксанынчы елларда яшәп ятабыз! Барлык мәсьәләләр хәл ителгән!

М и р о с л а в. Урамнарыгыз, ишегаллары да чиста булса...

Г а б б а с. Күзләреңә ялгыш күренгәндер, бездә чүп савытлары да юк. Ни өчен дигәндә...

Р е в а. Ташларга чүп юк...

Ә н и с ә. Иске-москы үзебездән дә артмый...

М и р о с л а в. Бараклар да булмаса...

Г а б б а с. Бараклар? Аларда яшәмиләр бит...

Ә н и с ә. Хезмәт ияләре менә шундый хәлдә яшәгән заманнар да булган дип күрсәтү өчен генә саклыйлар аларны...

Р е в а. Безнең ярты шәһәр музей!

Г а б б а с (*бокалларга коеп*). Безгә күрмәгәннәрне күрсәтүче шәһәр советы яшәсен!

Ә н и с ә (*Габбаска*). Күрмәгәннәреңне күрсәтермен әле! Яшәсен Мамалеев!

Ишектә Мамалеев ярдәмчеләре пәйда була.

Мин Ханович (*укый*). Интернациональ максат белән безгә килгән хөрмәтле Мирослав иптәш!

Ким Замович (*укый*). Шәһәр советы сезне безнең калабызга аяк басуыгыз белән...

Мин Ханович. Кайнар котлый!

Ким Замович. Яшәсен безнең халыклар арасындагы корычтай, тимердәй дуслык! (*Чәчәк бәйләме бирәләр.*)

Мирослав. Рәхмәт. Мин бик шат.

Мин Ханович. Кадерле Мирослав... фамилиягезне...

Мирослав. Шеймурзин.

Мин Ханович. Шәйморзин? Шаян кеше икәнсез... Хе-хе-хе...

Ким Замович. Без сезне коммунистик калабыз белән таныштырырбыз.

Мин Ханович. Сез, иптәш Шәйморзин...

Габбас. Кайсы Шәйморзин? Кунакмы?

Мин Ханович. Бутамагыз. Сезнең хакта сүз бара. Ягъни сез үзегезнең шәхси машинагызда...

Габбас. Шәхси? Минем?

Мин Ханович. Үзегезнең шәхси машинагызда барырсыз.

Ким Замович (*пышылдап*). Вакытлыча...

Рева. Ә мин?

Люция. Мин?

Мирослав. Мөмкин булса, мин үземнең әти, әни һәм туганнарым белән бер машинада барыр идем...

Мин Ханович. Әти? Әни? Сез үзегез генә килмәдегезмени?

Ким Замович. Мирослав иптәш юморист...

Мин Ханович. Интернациональ туганлык... аңлашыла...

Мирослав. Миңа үз әтиемне табып бирүегез өчен сезгә бик зур рәхмәт! (*Тегеләр аптырап бер-берсенә карашалар.*) Киттек, әти, туганнар!

Сәхнә караңгылана. Ут яктысында шәүләләр күренә, тавышлар ишетелә.

Габбас. Сез мине кая алып килдегез?

Мин Ханович. Тәмугка!

Ким Замович. Онытма, Шәйморзин, безнең оҗмахыбыз булган кебек, тәмугыбыз да бар.

Габбас. Сез әллә Нәнкир белән Мөнкирме? Мин сезне оҗмахта күргән кебекмен. Анда, ялгышмасам, сез фәрештәләр идегез...

Мин Ханович. Таныдың.

Кирәк булганда — фәрештә,

Ким Замович. Кирәк чакта — шайтан без!

Мин Ханович. Терә, ныклабрак терә диварга!

Ким Замович. Терәдем!

Мин Ханович. Әгәренки булса, җанын ал! Анда чит системага бала үрчетеп йөрмәсен!

Ким Замович. Җавап бир, бәдбәхет, гөнаһ кылу өчен үзебездә мөмкинлек юкмыни?

Габбас. Минем тамчы да гаебем юк. Оҗмахка кире илтегез!

Мин Ханович. Оҗмахка? Ха-ха-ха!

Ким Замович. Гөнаһы юк! Хи-хи-хи...

Мин Ханович. Билетын ал!

Ким Замович. Билетыңны өстәлгә!

Габбас. Мәгез!

Мин Ханович. Әһә, гаебеңне таныйсың?!

Габбас. Мин кем алдында гаепле?

Мин Ханович. Безнең алда.

Габбас. Минем иблисләр белән бернинди дә алыш-бирешем юк.

Мин Ханович. Син безне иблисләр белән тиңлисең?!

Ким Замович. Олы сәяси хата!

Мин Ханович. Ваз кич гөнаһыңнан!

Ким Замович. Тәүбә ит!

Мин Ханович. Җавап бир, син капиталистик системадагы хатын белән эш иттеңме, юкмы?!

Габбас. Мин аны яраттым!

Мин Ханович. Эш иттеңме, юкмы?

Ким Замович. Бала ясадыңмы?

Габбас. Әйе, безнең балабыз бар. Мин аны үз балам итеп таныйм.

Мин Ханович. Баш тарт балаңнан!

Ким Замович. Ваз кич!

Габбас. Ул минем балам!

Мин Ханович. Ах, шулаймы? Тәмугка!

Ким Замович. Тәмуг ишекләре ачык!
Мин Ханович. Яндыр тәмуг утын! Тиз!
Ким Замович. Янмый!
Мин Ханович. Янмый?! Сәбәбе?
Ким Замович. Ягулык юк...
Мин Ханович. Күршеләрдән сорадыңмы?
Ким Замович. Файдасыз. Бөтен системада юк.
Мин Ханович. Шеф, нишләргә боерасыз?

Мамалеев күренә.

Мамалеев. Ягулык тапканчы, хатыны янына озатыгыз. Бәлки, хатыны акылга утыртыр... Киткәнче чукмар белән тагын бер тондырыгыз! (*Габбас кычкыра.*)

Яктыра. Габбас, эшләпәсе белән күзләрен каплап, өйдә кәнәфидә утыра.

Әнисә. Әй, шадра шайтан, ник акырасың? Уян!

Габбас. Мин кайда? Аллага шөкер, синең янга кайтып җиткәнмен икән. Саташып уяндым... Авыр миңа, Әнисә!

Әнисә. Шулай инде... Ике хатын белән яшәү җиңел түгел. Карт иблис! Кара аны, икенче чит ил дип авызыңны ачасы булма! Алла бирсә, аяк та атлатмыйм. Синең әле, кем белә, бәлкем, башка илләрдә дә балаларың бардыр?! Әллә чынлап та шулаймы, җирбит?! Җаныңны алыр идем алуын, тик җаныңны дөнья чибәрләренә өләшеп бетергәнсең... Мәлгунь, кыяфәтсез, адәм гыйбрәте, карачкы... (*Йомшак кына.*) Габбас җаным, ни булды, әллә берәр күңелсез хәбәр бармы?

Габбас. Тегендә... кысалар, имансызлар!

Әнисә. Кемнәр?

Габбас. Мамалеевлар.

Әнисә. Ни диләр?

Габбас. Без сине күпме еллар Алланың кашка тәкәсе урынына тоттык, диләр...

Әнисә. Кашка тәкә? Син? Ни дигән сүз ул?

Габбас. Ялган шөһрәтеңне тудырып гел түрдә йөрттек, диләр. Кадерен бел, диләр. Мине капиталистик илгә барачак делегация составына кертмәкчеләр...

Әнисә. Юк! Юк! Юк!

Габбас. Безнең эшчеләрнең нинди яхшы шартларда яшәве турында сөйләрсең, диләр. Мондый биография белән бара алмыйсың, балаңнан баш тарт, диләр...

Әнисә. Баш тартмасаң?

Габбас. Егерме елдан соң да рәхәт күрсәтмәбез, диләр!

Әнисә. И Алла, бар икән күрәселәр...

Габбас. Синең белән киңәшергә кайтардылар. (*Машина сигналы.*) Анда... көтеп торалар... (*Ишекле-түрле йөри.*) Нишләргә, Әнисә?

Әнисә. Гомереңдә бер тапкыр үз башың белән уйлап хәл ит!

Габбас. Хәл иттем.

Әнисә. Әйт!

Габбас. Миңа бит бер җөмлә әйтү җитә: ул минем... бала... түгел... Шуннан соң без авыр тормыштан котылабыз...

Әнисә. Шулай әйтәсеңме?

Габбас. Синең, балаларның бәхете өчен... кирәк икән...

Әнисә. Габбас, синме бу?

Габбас. Мин.

Әнисә. Юк, бу — син түгел...

Габбас. Бу — мин, Әнисә.

Әнисә. Мирославның әнисен син чынлап яраттыңмы?

Габбас. Чынлап.

Әнисә. Мирославның үз балаң икәнлегенә бер шигең дә юкмы?

Габбас. Юк! Юк! Юк!

Әнисә. Син сугыштан кайткач, биш айлык Люцияне күтәреп, синең өеңә килдем. Син аны да үз кызың кебек яраттың. Аннан Рева туды. Хатын-кыз йөрәге сизә бит: син малай тели идең... Әмма мин сиңа ир бала бүләк итә алмадым. Гаиләбезгә нидер җитмәвен сизеп, синең алдыңда үземне гаепле тоя идем. Аллага шөкер, дөньябыз түгәрәкләнде... малаең...

Габбас. Әнисә, тагын кабатла шул сүзеңне... Малаең, дидеңме?

Әнисә. Малаебызны... дип тә әйтер идем әйтүен...

Габбас. Нидән куркасың, әнисе?

Әнисә. Син герой белән яшәп, үзем дә куркакка әйләнеп беттем инде. Куркам, Габбас!

Габбас. Нидән куркасың?

Әнисә. Мине, безне ташлап, малаең белән бергә чит илгә китеп барсаң?

Габбас. Минме?
Әнисә. Син!
Габбас. Чит илгә?
Әнисә. Чит илгә.
Габбас. Их, Әнисә, миңа да ышанмагач, кемгә ышанырга кала бу дөньяда! Күзләремә сөйкемле булып күренә башладың шушы сүзләреңнән соң!
Әнисә. Шалтырат!
Габбас. Кемгә?
Әнисә. Тегеләргә!
Габбас. Ә... ә... Мамалеевларга?! (*Телефонга.*) Иптәш Мамалеев! Бу — мин, Шәйморзин! Сезнең боерыкны үтәп, хатын белән киңәштем. Малай... минеке! Минеке! Минеке!
Әнисә (*трубканы тартып алып*). Минеке дә! Сәлам белән Шәйморзина!
Габбас. Их-ма! (*Гармунын алып җырлый, Әнисә кушыла.*)

Каштаннар, каштаннар,
Яшьлекнең нәкъ үзе сыман
Ярсуланып ташканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Язларың да, назларың да
Йөрәккә тоташканнар...

Люция белән Рева керә.

Люция (*кайгылы*). Әти!
Габбас. Ни булды?
Рева. Уф, башым!
Люция. Нишләргә?
Габбас. Нәрсә булды?!
Әнисә. Мирослав?!
Габбас. Бәхетсезлек?!
Әнисә. Авария?!
Люция. Аннан да авыррак!
Әнисә. Йа Хода!
Рева. Кем уйлаган шундый бәла килер дип...
Габбас. Улым!.. Әллә?
Әнисә. Мирослав кайда?
Габбас. Ул исәнме?!
Люция. Исәнен исән... әмма...
Габбас. Нәрсә әмма?!
Люция. Ул...

Рева. ...безнеке...
Люция. ...түгел!
Рева. } Безнеке түгел!
Люция. }
Габбас. } Безнеке түгел?!
Әнисә. }
Габбас. Ничек?
Әнисә. Йа Алла, әллә... әллә... шпион булып чыктымы?
Габбас. Юкны сөйләмә!
Әнисә. Кулга алдылармы? Күңелемә килгән иде лә...
Габбас. Яп авызыңны! Люция, Рева, нинди генә авыр хәбәр булса да, әйтегез, күтәрермен...
Люция. Әйтергә тел бармый!
Рева. Мин әле һаман ышанмыйм...
Габбас. Кайда ул үзе? Нинди генә хәлдә калса да, ул минем балам...
Люция. Әнә үзе!

Мирослав керә. Кыяфәте киткән.

Габбас. Мирослав... улым...
Мирослав. Иптәш... Шәйморзин...
Габбас. Иптәш Шәйморзин?! Нигә минем белән шундый рәсми тонда сөйләшәсең? Улым, мин сине аңламыйм...
Мирослав. Мин дә аңламыйм.
Люция. } Без дә аңламыйбыз!
Рева. }
Мирослав. Иптәш Шәйморзин... мин... ялгышканмын...
Габбас. Ялгышкансың?.. Димәк, син мине әтиең итеп танымыйсың?
Мирослав. Кызганыч, әмма мәҗбүрмен.
Габбас. Мәҗбүрсең? Мин, Шәйморзин, Габбас... сиңа ата булырга лаек түгел, димәк?
Мирослав. Шулай дип әйтергә туры килә.
Габбас. Ни өчен? Нигә?
Мирослав. Бөтен фаҗига да шунда шул. Сез — Габбас Шәйморзин. Кыскасы, без: мин дә, сез дә бик нык ялгышканбыз. Анда миңа аңлаттылар!
Габбас. Юк, мин моны аңлаудан баш тартам. Мин бит, мин бит инде Габбас Шәйморзин! Әниеңнең исеме Алена бит?

М и р о с л а в. Әйе, Алена. Анысы туры килә.
Г а б б а с. Шулай булгач! Фамилиясе? Урбанкова?
М и р о с л а в. Урбанкова. Анысы да туры килә. Кызганычка каршы, очраклылык. Бездә андый исем-фамилияләр күп шул.
Г а б б а с. Мин бит, мин Габбас Шәйморзин!
М и р о с л а в. Комиссариатта минем чын әтиемне тапканнар. Ул — Аббаз Шеймурзин. Мин сезгә башта ук әйттем: Аббаз Шеймурзин! (*Телефон чылтырый.*)
Г а б б а с (*трубканы ала*). Шәйморзин Габбас тыңлый. Ә?! Гафу үтенәсез? Мирославның чын атасын таптыгыз?! Аббаз? (*Хәлсезләнеп кәнәфигә утыра.*) Ә ул... чын Аббаз Шеймурзин кайда соң? Мин аның үзен күрмичә торып ышанмыйм!
М и р о с л а в. Минем чын әтием Аббаз Шеймурзин... сугышта алган авыр яраларыннан терелә алмыйча... үлгән.
Г а б б а с. Үлгән? Ничек болай булды соң әле? Ничек болай булды? Син бит... әле генә минем балам идең...
Ә н и с ә. Юк, мин моңа ышанмыйм! Ул баштанаяк минем Габбасыма охшаган! Юк, Габбас, ул синең балаң! Кара инде күзләренә, чәчләренә!
Р е в а. Мирослав... абый... без бөтенләй туганлашкан идек...
Л ю ц и я. Кал бездә... Мирослав... туганым...
Ә н и с ә. Кал, балам...
Г а б б а с. Кал... улым...
М и р о с л а в. Кызганычка каршы, тормыш фактлары — аяусыз. Мин үземнең әтиемне эзләп табарга сүз бирдем. Мин аны эзләп табарга тиеш! Каберен булса да... Рәхмәт сезгә... әтием... әнием... апам... сеңлем... кебек кабул иткән мәрхәмәтле җаннар! Рәхмәт изге күңелле кешеләрне сыендырган шушы ягымлы өйгә! Мин сезне үзебезгә кунакка чакырам, иптәш Шәйморзин... Менә минем визиткам.
Г а б б а с. Әнисә... әнисе...
Ә н и с ә. Үзеңне генә җибәрмим. Мин дә барам!
Р е в а. Мин дә!
Л ю ц и я. Мин дә!
М и р о с л а в. Дүртегез дә килегез! Ә хәзергә... хушыгыз! Мин әтине эзләргә китәм. Хатыны, дүрт баласы белән баракта яшиләр икән.
Г а б б а с. Баракта?..

Р е в а. Мирослав абый, мин дә синең белән барам!

Л ю ц и я. Мин дә!

Ә н и с ә. Барыгыз, кызлар! Аннан соң Мирославны безгә алып кайтыгыз!

М и р о с л а в. Габбас... Садыйкович... хушыгыз...

Габбас Мирославны кочагына ала. Икенче яктан Әнисә килеп кочаклый. Люция белән Рева да аңа елышалар. Үзәк өзгеч бер аваз белән әллә җырлыйлар, әллә елыйлар...

Каштаннар, каштаннар,
Әллә инде минем кебек
Каштаннар да шашканнар.
Каштаннар, каштаннар,
Йөрәк серен ачканнар да
Үкси-үкси качканнар...

Мирославны озаталар. Люция белән Рева да аңа ияреләр.
Тынлык. Габбас бер якка, Әнисә, аңа комачауламас өчен, икенче якка килеп утыра. Музыка дәвам итә.

Г а б б а с. Их, Әнисә, белсәң иде, үкенеч тырный йөрәгемне...

Ә н и с ә (*Габбасның җилкәсенә кулын куя*). Аңлыйм хәлеңне, түз...

Г а б б а с. Үземнең балам дип ышанган хәлдә, ата буларак, мин аны алдадым. Мин аңа менә хәзер, кайтып кергәч, ул серне ачарга җыенган идем...

Ә н и с ә. Нинди сер?

Г а б б а с. Мин аны гына түгел... сезне дә алдадым, Әнисә. Бу оҗмах та вакытлыча гына, чит ил кунагы киткәнче генә.

Ә н и с ә. Вакытлыча? Күңелем сизгән иде шул!

Г а б б а с. Үз балам булмавы ачыклангач, вөҗданым бераз тынычланды кебек.

Ә н и с ә. Габбас, син ни сөйлисең? Безне курчак итеп уйнаттылармыни? Шуңа риза булдыңмы? Син... уен уйнадыңмы? Без бит болай да гомер буе, киләчәк өчен дип, вакытлыча яшәдек, дөресрәге, яшәмәдек. Ә мамалилар без хыялланган, үз кулларыбыз белән төзегән киләчәктә яшәде, яши... Без яшәмәдек.

Г а б б а с. Яшәдек, Әнисә, әмма бер-беребезне, балаларны, киләчәкне алдап яшәгәнбез.

И к е я р д ә м ч е с е н иартеп, М а м а л е е в керә.

Мамалеев (*боерып*). Шәйморзин! (*Габбас кузгалмый.*) Шәйморзин, сиңа әйтәләр!

Габбас (*боерып*). Мамалеев! (*Мамалеев дәшми.*) Мамалеев, сиңа әйтәләр!

Мамалеев (*бүртенеп*). Аван Казбекович...

Габбас. Габбас Садыйкович!

Мамалеев. Ярый, синеңчә булсын...

Габбас. Әй, син!

Мамалеев. Ярый, сезнеңчә булсын, Габбас Садыйкович! Үзегезгә мәгълүм, хәтерлисездер, кайсыдыр ки шушы май аенда, минем рәсми ярдәмчеләрем катнашында сезнең белән килешү төзегән идек. Кайсыдыр ки аның шартлары нигезендә, ягъни мәсәлән, сез, шәһәребезнең һәм дә илебезнең болай да югары булган абруен төшермәү максатыннан чыгып, шушы фатирга вакытлыча, кабатлап әйтәм, вакытлыча күчеп торырга җаваплы йөкләмә алган идегез. Бүгенгесе көндә безгә шул мәгълүм булды, кайсыдыр ки үзебезнең социалистик системадан килгән хөрмәтле кунагыбызның сезнең шәхесегезгә мөнәсәбәте булмавы ачыкланды. Шунлыктан, сез хәзер үк фатирны бушатып, үзегезнең иске баракка китәргә тиешсез! (*Ярдәмчеләренә.*) Мебельләрне Шеймурзин Аббазга, кабатлап әйтәм, Шеймурзин Аббазга вакытлыча бирелгән яңа фатирына күчерегез! (*Ярдәмчеләр үз эшләренә тотыналар.*)

Габбас. Туктагыз! Кагылмагыз!

Әнисә (*куркып*). Габбас, нишлисең?

Габбас. Ә бу костюм, ботинкалар, галстук, эшләпә?

Мамалеев. Әлбәттә, сездә калмый, Шеймурзин Аббазга күчә. Вакытлыча.

Габбас. Ә сезгә билгелеме: Шеймурзин Аббаз сугышта алган авыр яраларыннан дөнья куйган. Ул бу киемнәрне кия алмаячак!

Мамалеев. Анысы әһәмиятле түгел! Аның улы бар.

Габбас. Шуны белегез, әгәр дә Аббаз Шеймурзин исән булса, сезнең шартларга күнеп, карачкыга әйләнмәс иде! Ул сезнең тәкъдимнәрне ишетү белән, эшләпәгезне бер якка (*ыргытып*), костюмыгызны икенче якка (*салып*), бозау муенчагын өченче якка... (*галстугын атып*) бәрер иде! Ул сугыш кырында гына түгел, тыныч чорда да үзенең дошманнарына каршы тигезсез көрәшкә чыгар иде!

Әнисә. Габбас, туфлиләреңне оныттың...

Габбас (*туфлиләрен салып ыргыта*). Җитте! Мин болай да теләсә нинди хаксызлыкка түзеп, куркып, баш иеп яшәдем! Дөресрәге, яшәмәдем! Мин чын Шәйморзин түгел, хәтта карга да курыкмаслык карачкы, сезнең кулыгызда курчак булганмын. Ул Шәйморзинны гамәлдән чыккан дип санагыз! (*Чалбарын да атып бәрә.*)

Әнисә. Майка, трусик үзебезнеке, Габбас. Башкасын хәләл көчебез белән табарбыз!

Мамалеев. Шәйморзин, карагыз аны, дәүләт киемнәре өстеннән көлүегез өчен җавап бирерсез! Ә хәзер бушатыгыз йортны! Бу өй махсус кешеләр өчен салынды, ягъни мәсәлән, престижлы! Син аңла, монда хәзер үзәктән килгән зур кунак керәчәк! Мәсьәлә ачыкмы?

Габбас. Ул монда кермәячәк!

Мамалеев. Керәчәк!

Габбас. Ә сез бу йортны үз куллары белән салган эшче Шәйморзиннан рөхсәт алдыгызмы?

Мамалеев. Акылыңны югалттыңмы? Кемгә каршы килгәнеңне чамалыйсыңмы?!

Габбас. Акылымны югалтсам да, вөҗданымны югалтмам, шулаймы, әнисе?

Әнисә. Шулай, этисе! Үземә дә бераз батырлык керә башлады бугай. Нишлибез, кашка тәкәм, киңәш бир!

Габбас. Тәкәнең мөгезләре дә була аның!

Мамалеев. Саботаж! Авантюризм! Башыгыз белән җавап бирерсез!

Габбас. Киләчәк алдында башыбыз белән генә түгел, җаныбыз белән дә җавап бирәсебез бар. Сезнең дә, безнең дә!

Мамалеев. Ах, сез, вакытлыча булса да киләчәктә яшәүнең кадерен белмәдегез!

Габбас. Без киләчәккә вакытлыча түгел, бөтенләйгә яшәргә барабыз!

Мамалеев. Марш үзегезнең иске барагыгызга! (*Ярдәмчеләргә.*) Алга!

Габбас. Бер адым да артка чикмибез! (*Мебельләрдән баррикада кора. Мин белән Ким һөҗүмгә күчәләр. Габбас белән Әнисәдән кире чигенәләр.*)

Әнисә (*ярдәм итеп*). Бер адым да артка чикмибез! (*Кулына нәрсә эләгә шуны ала.*)

**Машина сигналы ишетелә.**

Мамалеев (*тәрәзәдән карап*). Хуш киләсез, кадерлебез Фердинанд Имамович! Өегез котлы булсын! Рәхим итегез! Рәхим итегез! (*Габбас белән Әнисәгә.*) Бушатыгыз!

Габбас. Монда Киләчәк өчен һәлак булган Шеймурзин Аббазның гаиләсен бөтенләйгә кертмичә торып, бер адым да артка чикмибез! Кабатлап әйтәм: бөтенләйгә!

Рева (*йөгереп керә*). Әти!

Люция (*йөгереп керә*). Әтием!

Габбас. Нәрсә булды?

Люция. Нишләргә?

Рева. Уф, башым!

Габбас. Ни булды?

Әнисә. Мирослав?!

Габбас. Бәхетсезлекме?! Авария?

Мамалеев. Безнең илдә авариянең булуы мөмкин түгел!

Люция. Коточкыч!

Әнисә. Йа Хода!

Рева. Кем уйлаган!

Габбас. Әллә?..

Әнисә. Мирослав кайда? Ул... исәнме?

Люция. Исән!!!

Рева. Ул...

Люция. ...безнеке!!!

Рева.<br>Люция. } Безнеке!!!

Габбас.<br>Әнисә. } Безнеке?!

Габбас. Ничек?

Рева. Аббаз Шеймурзинның өен эзләп таптык. Мәрхүмнең Чехословакиядә булмавы ачыкланды.

Люция. Ни өчендер, гел документларны бутыйлар!

Рева. Ялгыш юлга җибәрергә тырышалар.

Мамалеев. Иптәш Шәйморзин, без сезне мораль бозыклыктан күпме саклап калырга тырыштык! Аңламадыгыз!

Габбас (*усал*). Мин сезне бик яхшы аңладым, Мамалеев! Улым! Кайда ул?!

Мирослав кайтып керә. Йөзе ачык.

М и р о с л а в. Әти! Әни! Туганнарым!

Г а б б а с. Балам!

Ә н и с ә. Улым!

Р е в а. Абыем!

Л ю ц и я. Туганым! (*«Каштаннар» җырын җырлап кочаклашалар.*)

М а м а л е е в (*телефон трубкасын алып*). Иптәш Баркаруллин! Мамалеев сөйли! Хәлләр катлауланды. Операция без теләгәнчә бармый... Нишләргә?

П ә р д ә.

*1989*

# *Куш, Хәйбуш!**

*Ике пәрдәле комедия*

КАТНАШАЛАР:

Сәнифә — элек мәдәният сараенда эшләгән, хәзер — кафеда җырчы, 35 яшьтә.
Талия — элек китапханәдә эшләгән, хәзер кафеда официантка, 27 яшьтә.
Таминдар — элек партия органнарында эшләгән, хәзер цирк директоры, 37 яшьтә.
Шакир — элек циркта клоун, хәзер эшсез, 50 яшьтә.
Тайфур — психотерапевт, 40 яшьтә.
Абдул — элек аспирант, хәзер айныткычта дежур-милиционер, 30 яшьтә.
Хаккый — элек аспирант, хәзер айныткычта врач, 30 яшьтә.
Жан Дустэн — чит ил кешесе.

Вакыйга безнең көннәрдә Казанда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кафе-бар. Бер якта — буфет. Эчке яктарак — эстрада сәхнәсе. Уртада — өстәл, берничә урындык. Диварларда — чит ил артистларының рәсемнәре, шәрә кызлар. Иң күп реклама: хәмер-шәрабка. Чит ил музыкасы бизәлешендә реклама:
«Ханымнар, әфәнделәр! Дөньяның иң гүзәл илләренә ял итәргә, сәяхәткә чакырабыз!»
«Чибәр, яшь кызларны Урта диңгезнең алтын комы, иркә җиле, ягымлы карашы көтә!»
«Круиз Килиманджаро!»
«Шри-Ланкада — могҗизалы җиде төн!»
«Дөньяда иң арзан урыс аракысы: «Асланов!», «Распутин!», «Барселона!», «Хельсинки!», «Париж!»
Талия, өстәлләрне матурлап, салфеткалар куеп йөри.
Сәнифә керә.

Сәнифә. Булды, Талия!
Талия. Әйттем бит! Минем сүз — үтемле! Алдымы?

* 1998 елда Казан татар дәүләт яшьләр театрында куелды.

С ә н и ф ә. Вакытлыча инде.

Т а л и я. Штатка түгелмени?

С ә н и ф ә. Җырчы, биюче штатта каралмаган, кайчан чакырам, шул көнне киләсең, ди.

Т а л и я. Күпмегә килештең?

С ә н и ф ә. Биегән-җырлаган кадәр.

Т а л и я. Әллә ни түгел түгелен.

С ә н и ф ә. Безгә, эштән куылганнарга, ярап тора. Син уңдың. Официантка! Сугасың акчаны!

Т а л и я. Алдамасаң, сугарсың...

С ә н и ф ә. Алдыйсыңмы?

Т а л и я. Дөньясы алдауга корылган. Йә син алдыйсың, йә үзеңне алдыйлар...

С ә н и ф ә. Китапханәдә алдый да, алдана да алмый идең...

Т а л и я. Ярый әле кыскарттылар. Ятар ием тиеннәргә алданып...

С ә н и ф ә. Мәдәният сараенда мин сезне биергә өйрәттем. Хәзер кыргый базар биергә өйрәтә. Менә ничек керергә ул базарга? Керүен бер кереп китсәк, ятар иек ябышып...

Т а л и я. Һәй! Хәзер акыл кирәкми. Аяк белән типтем-кердем. Ишектән кертмәсәләр, тәрәзәне ватып керәм!

С ә н и ф ә. Керерсең, бар... акыл, хәйлә булмаса... Кем мал таба? Аеклар, акыллылар...

Т а л и я. Син эчмисең.

С ә н и ф ә. Бик эчәр ием дә, ярамый, аллергия!

Т а л и я. Мин компаниядә — йөзәм!

С ә н и ф ә. Син батмыйсың!

Т а л и я. Үзем батырам!

С ә н и ф ә. Өстерәп чыгар шунда бер ирне!

Т а л и я. Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә тигән яр булса!

С ә н и ф ә. Ирнең шәбе циркта да, кафеда да, Казанда да, Кабанда да ятмый, матурым!

Т а л и я. Кайда ята?

С ә н и ф ә. Әнә тыңла!

Телевизорда реклама ишетелә: «Диңгез буенда ял итәргә теләсәгез, Казаннан самолет белән рәхим итегез: Төркия. Анталия: 230 доллар! Кипр — 450 доллар! Греция. Солоники. 480 доллар!..»

Т а л и я. Кая инде безгә импортный кияү... Доллар, доллар, доллар...

Сәнифә. Теге миңа биергә йөргән Жаннаны беләсеңме?

Талия. Теге шикәр кебек ап-ак кызмы?

Сәнифә. Әйе, озын борынлы...

Талия. Нишләгән?

Сәнифә. Чыккан.

Талия. Юкка чыкканмы?

Сәнифә. Кияүгә чыккан!

Талия. Уф, шартлыйм!

Сәнифә. Кемгә чыккан дип сора?

Талия. Муллагамы? Попкамы?

Сәнифә. Эфиопка!

Талия. Сенсация! Кияү монда калганмы?

Сәнифә. Ире — миллиардер, үзе белән алып киткән.

Талия. Булдыра безнең кызлар!

Сәнифә. Миргә чыга татар! Бөтен дөнья милләтләренең санын арттыра. Үзе бетсә бетә, әмма арттыра.

Талия. Узды мәхәббәт заманы!

Сәнифә. Хәзер мәхәббәт тә — бизнес! Әнә, тыңла...

Телевизордан диктор: «Европага чыгару өчен 17—24 яшьлек сылу кызларны көтәбез. Адресыбыз...»

Талия. Без ул юл белән бармабыз!

Сәнифә (*көлеп*). Без башка юл белән барырбыз! Татар Казанында күп кайнадык, җитте! Җырлый-җырлый, бии-бии минем арттан!

Икесе дә «Ай җаный, вай җаный»ны бозып җырлыйлар.

Сәнифә. Күпме еллар чыгалмыйча
Яшәдек камалышта.
Әйдә, киттек Европага,
Калмыйк без Мамадышта!
Һай Джони, вай Джони,
Бармыйк без Мамадышка!

Талия. Эте-бете читкә китә,
Этә-төртә мал таба.
Әллә без дә китәбезме
Йә Цейлон, йә Мальтага?
Һай Джони, вай Джони,
Йә Цейлон, йә Мальтага!

С ә н и ф ә. Кызыгып карап торганчы
«Адидас» ыштанына,
Әйдә, чыгыйк без үзебез
Дөнья масштабына!
Һай Джони, вай Джони,
Дөнья масштабына!

Шакир керә. Кызларның җыр-биюен карап тора да үзе дә катнашып китә.

Ш а к и р. Кызлар, бер дә кызыкмагыз
«Адидас» ыштанына,
Шул ук әбиләр ыштаны,
Төймәсе тыштан гына!
Һай җаный, вай җаный,
Шакирның да бар җаны!

С ә н и ф ә. Шакир абый?! Нинди җилләр ташлады монда!

Ш а к и р. Кыргый базар җилләре!

С ә н и ф ә. Әллә сине дә?

Ш а к и р. Җырлап йөрим хәзер
Манный ботка кабып:
«Начальниклар — симез,
Еллар — ябык!»
Алар калҗа каба
Коньяк эчәләр дә,
Җилләр генә исә
Безнең кесәләрдә.
Ошбу җилләр җитсен
Халык массасына,
Сәламемне илтсен
Саклык кассасына!

С ә н и ф ә. Кыскарттылармы?

Ш а к и р. Миннән башкалар барсы да
Малтабар йә эшкуар,
Мине дә эштән кудылар,
Шакир хәзер — җилкуар.

С ә н и ф ә. Утыр, Шакир абый!

Ш а к и р. Рәхмәт, утырттылар инде төп башына!

Т а л и я. Меню! Мерси, мсье Шакир. Француз коньягы? «Наполеон?»

Ш а к и р. «Вермут» булса да ярар ие дә... Сезнең янга эш эзләп килдем, кызлар. Белдерүне укыдым. «Хуш,

Хәйбуш» кафесына швейцар кирәк. Югары белемле булса да ярый, французча белсә, татарча белүнең кирәге юк. Белемем югары, борын — түбән, французча сукалыйм бераз, ләкин татарчаны яхшы белү аяк чалмаса гына инде?!

Сәнифә. Бәхетеңне сынап кара, Шакир абый. Синең кебек мәшһүр клоунны, бәлкем, алыр да?!

Шакир. Тәвәккәлләдем, кызлар. Кайсы ишектән кире чыгарга? Хуш, Хәйбуш! Бисмиллаһи рахман рахим... (*Ишектән эчкә кереп китә.*)

Талия. Милиция!

Абдул керә.

Абдул. Сәнифә апа? Талия? Сез?!

Сәнифә. Без...

Талия. ...идек.

Абдул. Әллә мин ялгыш кердемме? Китапханә, мәдәният сарае монда күчтеме әллә?

Сәнифә. Базар!

Абдул. Кесә бар, карман юк.

Талия. Дәрт бар, дәрман юк.

Сәнифә. Карман бар, доллар юк!

Абдул. Бие, бие, Абдулла,
Биегән кеше бай була!

Сәнифә. Биегән кеше бай булганда...

Абдул. Карт алаша тай була! Сәнифә апа, биеп баемады Абдул!

Сәнифә. Базар биетә, Абдул!

Абдул. Их, кызлар, сезне күргәч, әллә нишлисе килеп китте!

Талия. Салып биримме?

Абдул. Ураза!

Сәнифә. Озаккамы?

Абдул. Капитализмга җитеп, аякларны салындырып утырмыйча капмыйм!

Талия. Фу! Авызыннан американски сигара, «Виски» исе килмәгән егетләрне яратмыйм!

Абдул. Дөнья безнең кулда! Кабарбыз тегесен дә, монысын да! Яратырсың, канәтем, әле Абдул абзаңа йөгереп кияүгә чыгарсың!

Талия. Юк! Милиционерга чыкмыйм.

Абдул. Кемгә чыгасың?

Т а л и я. Миллионерга.

А б д у л. Канәтем, мин ике тапкыр миллионер, ике ай саен миллион алам!

Т а л и я. Сөйләнгән буласың, машинаң да юктыр әле!

А б д у л. «Мерседес!»

С ә н и ф ә. Абдулдан булыр!

А б д у л. Сезне дә утыртырмын бер! Шәһәр уратырмын!

Т а л и я. Булмас. Күргән юк.

А б д у л. Алып кайтам. Польшадан!

С ә н и ф ә. Чит илгә алып чык, Абдул. Польшага булса да...

А б д у л. Карап карарбыз.

С ә н и ф ә. Мин шаярмыйм.

Т а л и я. Мин дә!

А б д у л. Икегезне дә! Бер генә нәрсә кирәк...

С ә н и ф ә.<br>Т а л и я. } Нәрсә?

А б д у л. Доллар!

С ә н и ф ә. Безнең акча ярамыймы?

А б д у л. Поты бер тиен аның дөнья базарында.

Т а л и я. Анысы да юк әле...

С ә н и ф ә. Син нишләп йөрисең әле айныткычыңны ташлап?

А б д у л. План тулмый, анасын сагыныйм! Чыктым берәр чит илдән килгән исерек эләктереп булмасмы дип... Француз наркологы килгән, диләр. Туп-туры Париждан...

С ә н и ф ә. Париждан?! О!

А б д у л. Кесәсе тулы франк инде аның. Ул сезгә керми калмас...

Т а л и я. Керсәме... керсә... миннән ычкыналмас.

С ә н и ф ә. Чит ил белән алай кыланырга ярамый.

А б д у л. Дөрес, аны милиция сакларга тиеш. Яшерен-батырын түгел, безгә эләксә, айлык план — шалт! Барып җиттеме? Кабатлыйм, сезгә керсә...

Т а л и я. Кереп кенә карасын!

С ә н и ф ә. Керә генә күрсен...

А б д у л. Кабатлыйм, сезгә керсә... Эчертегез... юк, юк, тиененә дә кагылмыйсыз. Исертегез, аннары шушы номерга телефоннан — шалт, Абдул! Карагыз аны, француз өчен без үзебез җавап бирәбез! Мин әйткәнчә булсын! Гутбай! (*Чыга.*)

Ишектән Ш а к и р атылып чыга. Кызлар аны күтәреп торгызалар.

С ә н и ф ә. Алдымы?

Ш а к и р. Алды... Котны алды! «Әртисләрнең поты бер тиен!» дип, артка тибеп чыгарды, кабахәт! Бисмилла да әйттем инде югыйсә кергәндә... Дәү әни әйткән ие: «Начальнигың янына кергәндә дүрт тапкыр «бисмилла» дип әйт, нигә дисәң, начальник бүлмәсенең дүрт почмагында дүрт шайтан ятар, «бисмилла» әйтү белән чыгып «сызарлар» дип. Сүзләре бу юлы расланмады: үзе шайтан булып чыкты, ерткыч!

С ә н и ф ә. Тс-с-с... әкрен...

Т а л и я. Үзе ишетмәсен...

Ш а к и р. «Төртмәсәң дә аварга торасың, йолкыш, ди, хәшәрәт!

С ә н и ф ә (*авызын каплап*). Кычкырып әйтмә, Шакир абый!

Т а л и я. Тынычлан, Шакир абый, бар, бар...

Ш а к и р. Кесәңдә акчаң булмаса, тавышы да әкрен чыга шул. Иблис! Кемнәр кулына калдык, кызлар, ә? Әле минем баҗам бар! Ишегалды себерә! Йөз дә утыз кило! Аны беркем дә куалмый! Киттем баҗама! Бирешмәгез, кызлар! Алга, Шакир абый! (*Китә.*)

С ә н и ф ә. Бирешмик, Талия!

Т а л и я. Керсен генә француз, эләктерәм!

С ә н и ф ә. Талия, кагылма французга, минеке!

Т а л и я. Нишләп ул синеке булсын, синең ирең бар.

С ә н и ф ә. Әй, бер мәртәбә чит илгә алып чыгалмагач, шул да ир булдымы! Париж! Гомерлек хыялым! Эйфель башнясы төшләремә килеп керә...

Т а л и я. Әгәр ул миңа караса, нишләрсең?

С ә н и ф ә. Таракан булып төшмәкче буласыңмы? Мин французларның зәвыгын беләм. Алар нечкә билле кызларга карыйлар.

Т а л и я. Ул үзе дә минем кебек юан булса?

С ә н и ф ә. Юан булса да, нечкә булса да, минем хыялыма тимә, Талия!

Т а л и я. Ярар, миңа берәр эфиоп булса да ярар. Ирең булганга гына әйткән идем.

С ә н и ф ә. Һәй, искә төшермә әле шуны! Ул Парижны бар дип тә белми. Күпме ялындым Парижга барыйк дип. Колагына да элми. Аның Финляндиягә барасы килә. Имеш, арзанга төшә. Бүген, мәхлук, йөгереп кайтып кергән: «Киттек Финляндиягә!» — ди. Үзендә циркта булган фин татарлары чакыру җибәргәннәр. Хатын белән

килү мәҗбүри икән. Гаиләгә багышланган корылтай үткәрәләр икән. Мин Финляндиядә булдым. Мин: «Париждан башка беркайда да аяк басмыйм!» — дип, өйдән чыгып киттем.

Т а л и я. Таминдар абый үпкәләп калдымы?

С ә н и ф ә. Ул, бик ачуны китерсәң, алдым-кайттым булыр яшь хатын, дип кычкырып калды.

Т а л и я. Алып та кайтыр!

С ә н и ф ә. Әй, таптың яшь хатын ала торган ир!

Т а л и я. Ә мин барыр идем Финляндиягә!

С ә н и ф ә. Таптың барыр урын! Париж, бары тик Париж!

Француз музыкасы. Телевизор экранында — Тайфур һәм Жан Дустэн.

Т а й ф у р. Мсье Жан Дустэн, мин Сезне Татарстан җирендә сәламлим.

Ж а н. О, сәлам татарларга!

Т а й ф у р. Сез татарча беләсез?

Ж а н. Татар бизнесменнары белән татарча сөйләшәм.

Т а й ф у р. Без бик шат. Димәк, тәрҗемәче кирәкми. Әйтегез әле, Сез Париждан Казанга нинди максат белән килдегез? Хөрмәтле тамашачылар, Жан Дустэн — минем коллега, наркология белгече.

Ж а н. Мин килдем өйрәнергә татарлар ничек эчәләр. Ничек аларны дәвалыйлар. Тайфур әфәнде ничек эшли. Тайфур әфәнде мине өйрәтә, мин аны өйрәтәм. Без аның белән төзибез... татарча ничек әле... договор. Мин белмим татарлар күпме эчәләр, но беләм Татарстанда аракы сатыла күп. Була шундый эчүче, аны булмый дәвалап... татарча ничек... не поддается... Шундый биш кешене Парижга алып китәм...

Т а л и я. Ишеттеңме?

С ә н и ф ә. Тс... с... с!

Т а й ф у р. Үз чиратында коллегабыз биш французны миңа алып киләчәк.

Ж а н. Әйе. Дәваларга татарча.

Т а й ф у р. Безнекеләрне кайчан алып китәргә уйлыйсыз?

Ж а н. Бик тиз.

Т а й ф у р. Ярый. Ә акчаны кем түли?

Ж а н. Түли безнең фирма.

Т а л и я. Сәнифә апа, бушлай!

С ә н и ф ә. Бушлай!

Ж а н. Француз кызыксына татар белән. Эчүче татар бар, беләм. Эчмәүче татар бармы? Күрсәтегез, булса...

Т а й ф у р. Борчылмагыз, коллега. Бөтенләй эчмәүчене табуы авыр булыр булуын, шулай да табарбыз. Минем күршемдә генә эчмәүче ирле-хатынлы күршеләрем бар. Шулар белән бүген үк таныштырырмын...

Ж а н. Мерси. Рәхмәт.

Т а й ф у р. Кемнәрне алып китәргә уйлыйсыз. Ирләрне генәме?

Ж а н. Эчүче кызлар юктыр татарда?

Т а й ф у р. Кызганыч, әмма күп шул.

Ж а н. Алайса, бер хатын-кыз алам...

С ә н и ф ә (*Талияне кочаклап*). Талия, булды!

Т а л и я. Нишлисең, тилердеңме әллә?

С ә н и ф ә. Без китәбез!

Т а л и я. Кая китәбез?

С ә н и ф ә. Мин — Парижга! Син — Финляндиягә!

Т а л и я. Минем бер доллар да юк.

С ә н и ф ә. Минем дә юк. Бушлай китәбез!

Т а л и я. Ничек?

С ә н и ф ә. Ишетмәдеңмени? Тайфур Алтынбаев — минем күршем. Ул французны безгә алып керәчәк.

Т а л и я. Аңламыйм.

С ә н и ф ә. Әрсез, хәйләкәр булмасаң, батасың бу заманда.

Т а л и я. Нишлибез соң?

С ә н и ф ә. Хәзердән үк мин — алкаш, син — Таминдарның хатыны!

Т а л и я. Ә?

С ә н и ф ә (*җыр башлый, Талия аны күтәреп ала*).

Суга салсаң, калкып чыгар
Безгә насыйп яр булса!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Т а м и н д а р Х ә б и б фатиры. Сәнифә өйдә юк. Кич.

Т а м и н д а р (*телефоннан*). Һалло! Кем бу? Тайфур? Безгә кунакка киләсез? Телевизор карамадым. Кем белән? Җан дустың белән? Жан Дустэн? Француз? Нигә безгә? Эчмәүче гаиләгә? Башканы таба алмадым! Юк! Мин әйттем,

эш сәгате бетте. Мин өйдә кабул итмим. Син аны циркка алып бар. Юк, юк! Суыткычта җилләр уйный. Алты ай хезмәт хакы алган юк. Сәнифә кайтмады әле. Эш эзләп йөри. Әллә кайта, әллә юк. Үпкәләштек. Финляндиядән булса, бер хәл, Франциядән — юк! Мин әйттем, көтмим! Сәлам белән Таминдар. (*Трубканы куя.*) Мәхшәр! (*Ишекле-түрле йөри. Ишектә — кыңгырау.*) Теге кайтты... (*Ишек ачарга бара.*)

Шакир. Элекке партия хезмәтчесенә элекке клоуннан сәлам!

Таминдар. Сәламеңне алмыйм, кереп торма. Фу, хәмер исе килә. Сәнифә кайтып керсә, җаныңны алыр!

Шакир. Юк, керәм.

Таминдар. Нишләп йөрисең? Мин сине чакырмадым.

Шакир. Шакир хәзер эшсез клоун. Хуҗасы чакырмаса да килә.

Таминдар. Приказ эленгән. Мин әйттем!

Шакир. Анда сәбәбе әйтелмәгән.

Таминдар. Өстән күрсәтмә килде. Штатны кыскартырга!

Шакир. Хуш, Хәйбуш! Ә нигә клоунны кыскартырга? (*Узарга уйлый.*)

Таминдар. Узып торма. Мин әйттем!

Шакир. Әйтеп бетер. Нигә мине?

Таминдар. Кемне кыскартыйм?

Шакир. Үзеңнән башларга иде.

Таминдар. Миңа бер клоун бик җиткән. Утырып торма! Синең сул колагың бик әйбәт ишетми. Уң колагың белән тыңла! Беренчедән, Степановны кыскартып булмый.

Шакир. Милләтчелектә гаеплиләр.

Таминдар. Мин — интернационалист! Икенчедән, син саласың...

Шакир. Сәхнәдә салган юк бит. Менә минем баҗам бар...

Таминдар. Баҗаңны катыштырма, үзең турында сүз бара. Кайда эчсәң дә, салу — салу инде ул.

Шакир. Өченчедән...

Таминдар. Бизнес заманы! Адәм көлдереп, авыз ерып доллар эшләп булмый. Минем план: дөнья масштабына чыгу. Мин әйттем!

Шакир. Чыгалмыйсың син дөньяга миннән башка! Менә минем баҗам бар...

Таминдар. Чыгам! Юлбарыслар гына исән булсын. Ерткычларга җитәкче булу җиңелрәк, аюны да биергә өйрәтәбез... Эчмиләр, тартмыйлар, ашарга гына сорыйлар. Мәхшәр!

Шакир. Ачтан үтерәсең инде мескеннәрне. Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Хуш, хуш, киттеңме?

Шакир. Миннән җиңел генә котылмакчы буласыңмы? Әйтәсе сүзләрем бар әле.

Таминдар. Ара өзелгән.

Шакир. Мин кунакка чакырылган.

Таминдар. Сине чакырдылармы?

Шакир. Мине! Сәгать җидегә.

Таминдар. Синең кемгә кирәгең бар?

Шакир. Мине хөрмәт итүчеләр бетмәгән шул. Шакир абзаңны бөтен дөнья белә. Мине кем чакырганны беләсеңме?

Таминдар. Беркем дә!

Шакир. Тайфур Алтынбаев шәхсән үзе мине чакырды. Парижның үзеннән килгән доктор чакырырга кушкан. Белдеңме?

Таминдар. Сине Парижда түгел, Казанда да белмиләр. Тайфур кирәк булса, бар, кер үзенә, әнә күршедә... Артыңа тибеп чыгарырлар...

Шакир. Син, энекәш, үзең белән бутама кешене.

Таминдар. Мин сине дөрес куганмын. Аеклыгың турында белешмә алып килсәң, бәлки, уйлап та карармын. Ә хәзер, хуш, хуш, Хәйбуш!

Шакир. Шакир абзаң чакырган җиргә килә, куган җирдән китми. (*Түргә барып утыра.*)

Ишек кыңгыравы.

Әнә кунаклар каршыла!

Тайфур белән Жан Дустэн керә.

Тайфур. Хәерле кич, күрше!

Жан. Исәнмесез?

Шакир. Пардон! Мерси!

Таминдар (*югалып кала*). Мин әйттем...

Ш а к и р. Юк, мин әйттем.

Т а й ф у р. Көтелмәгән визит булмасын өчен, без алдан искәрттек.

Т а м и н д а р. Мин белмәдем...

Т а й ф у р. Жан Дустән әфәнде, таныш булыгыз, минем иң якын күршем, цирк директоры Таминдар Хәбиб! Хәмерне авызына да алмый торган гаиләнең бер әгъзасы, ягъни мәсәлән...

Ж а н. Жан Дустән. Бик шатмын.

Т а й ф у р. Париждан. Нарколог. Минем коллега, ягъни мәсәлән. Рәхим итеп түргә узыгыз. Таминдар әфәнде, эчмәүгә дә карамастан, бик кунакчыл кеше.

Т а м и н д а р. Мин әйттем...

Т а й ф у р. Син әйтсәң әйтәсең инде... Сәнифә кайда?

Т а м и н д а р. Кайтмады әле.

Т а й ф у р. Таминдар әфәнденең сөекле вә сөйкемле хатыны мадам Сәнифә белән дә танышырсыз, ягъни мәсәлән. Утырыгыз.

Ж а н (*утыра*). Рәхмәт.

Ш а к и р. Мерси.

Т а м и н д а р. Аңламадым. Наркологиягә минем гаиләнең ни катнашы бар? Безнең өйдә, үзегез беләсез, коры закон...

Т а й ф у р. Менә, менә! Хөрмәтле кунакны нәкъ әнә шул нәрсә кызыксындыра да. Тәк... ие... Татарларның хәмергә мөнәсәбәтләрен тикшерү өчен, ул Париж кадәр Париждан махсус килгән, ягъни мәсәлән. Ул минем дәвага бирелми торган биш эчкечемне, үз ысулы белән терелтү өчен, Парижга алып китәчәк, ягъни мәсәлән.

Т а м и н д а р. Мин эчкән кеше белән рәттән басып та тора алмыйм, минем моңа ни катнашым бар?

Ж а н. Мсье Таминдар, мине эчмәүче һәм шулай ук эчүче татарлар кызыксындыра. Әгәр алар булса...

Ш а к и р. Менә минем баҗам бар...

Ж а н. Мин бер китапта укыдым, татар хәмердән баш тарткан халык дип...

Ш а к и р. Борын заманда ул, борын заманда...

Ж а н. Фәнни эшем өчен миңа бер мисал кирәк. Эчми торган татарлар!

Т а й ф у р. Иң уңышлы мисал: эчми торган ике татар!

Ш а к и р. Безнең заман геройлары!

Т а й ф у р. Таминдар әфәнде, хөрмәтле коллега алдында

үзегезнең аракы эчмәү тәҗрибәгез белән уртаклашсагыз иде.

Таминдар. Эчмим, бетте-китте!

Тайфур. Конкретно! Эчәсегез килеп тә эчмисезме, әллә...

Таминдар. Эчәсе килә... Коточкыч эчәсе килә... Хатыным...

Жан. О! Бу бик кызык! Хатыныгыз?

Таминдар. Хатынымның да бик эчәсе килә. Әмма...

Жан. Йә, йә?

Шакир. Үзе эчәлмәгәч, ирен дә эчерми! Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Хатында — алкогольгә аллергия!

Жан. Аллергия? Искиткеч кызык!

Таминдар. Кызык түгел, бәхетсезлек! Мәхшәр! Бәйрәм күргән юк! Хәмер исе килгән адәмне дошман күрә!

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Үзара әйткәндә, нормаль тормыш түгел.

Шакир. Бик зур бәхетсезлек. Менә минем баҗам бар...

Тайфур. Хуш, Хәйбуш!.. Инде килеп, кадерле коллега, сезне фәнни объект буларак кызыксындырырлык икенче бер мисал! Таныш булыгыз, Шакир иптәш!

Шакир. Әфәнде!

Тайфур. Әлегә әфәнде түгел! Бик тә принципиаль үҗәт адәм. Сезнең өчен бик һәйбәт субъект, ягъни мәсәлән.

Жан. Хәмергә мөнәсәбәте?

Тайфур. Бик тә уңай.

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Тайфур. Миңа биш тапкыр килеп, биш тапкыр эчүен ташлады. Дәвага бирелмәүче клиентларымның иң көчлесе, ягъни мәсәлән. Иң лаек кандидатым шушы!

Жан. Мин сезне аңладым.

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Тайфур. Шакир иптәш...

Шакир. Әфәнде...

Тайфур. Әлегә әфәнде түгел. Чын әфәнде буласың киләме?

Шакир. Тагын дәваланырга кил димәкче буласыңмы? Хуш, Хәйбуш!

Тайфур. Шәһәрләрнең шәһәре Парижга барып, Эйфель башнясына менеп, дөньясына төкерәсең киләме?

Шакир. Менә минем баҗам бар. Ул төкерсә...

Тайфур. Ул төкерде инде... риза булмады. Менә сиңа

шул мәгълүм булсын, миндә исәптә торучыларның иң зур стажлы ветераны буларак, әгәр Жан әфәнде алса...

Жан. Мин сезгә тапшырдым.

Тайфур. Мин сине Парижга җибәрергә уйлыйм.

Таминдар. Шәп! Мин дә котылырмын!

Шакир. Парижга?

Тайфур. Парижга.

Шакир. Мине? Шакирны?

Тайфур. Сине. Шакирны.

Шакир. Күпме түләргә?

Тайфур. Бушлай.

Жан. Безнең фирма хисабына.

Таминдар. Мәхшәр! Сөенә дә белми!

Тайфур. Шакир әфәнде! Бие! (*Шакирны уратып җырлыйлар, Жан да селкенә.*)

Таминдар. }
Тайфур. }

Безнең урам чокыр-чакыр,
Париж урамы такыр;
Парижларга бару белән
Безне кунакка чакыр.
Ай Шакир, вай Шакир,
Париж урамы такыр.
Парижга баргач та Шакир
Мадам ишеген шакыр;
Без дә анда барыр идек —
Кесә яклары такыр.
Ай Шакир, вай Шакир,
Кесә яклары такыр.
Анда безне дә онытма,
Без калабыз, без — фәкыйрь;
Иптәш булып киткән Шакир
Әфәнде булып кайтыр.
Ай Шакир, вай Шакир,
Әфәнде булып кайтыр.

Таминдар. Хуш, Хәйбуш! Кире кайта күрмә!

Тайфур. Үзеңне Парижда дип уйла!

Шакир. Туктагыз әле, нигә җырлыйсыз, нигә сөенәсез?

Тайфур. Парижга китәсең бит!

Таминдар. Бушлай!

Т а й ф у р. Миндә бирешмәдең... анда, бәлки, юлын табарлар. Жан әфәнде ышандыра. Курыкма, минем белән барасың!

Ш а к и р. Мин бармыйм!

Т а м и н д а р. Парижга?! Бушлай?!

Т а й ф у р. Тәк... ие... Гаҗәп.

Ж а н. Ул бармый? Кызык.

Т а м и н д а р. Мәхшәр! Үзем китәр идем! Нигә генә сәрхуш булмадым...

Т а й ф у р. Кыланма, шаярма.

Ш а к и р. Аек баштан әйтәм. Бармыйм. Менә минем баҗам бар...

Т а й ф у р. Мин аңа әйтеп карадым инде. Баҗаң да үзеңә охшаган. Кәҗәләнә. Салих белән Борис риза.

Ш а к и р. Юк, бармыйм. Хуш, Хәйбуш!

Т а м и н д а р. Безнең татар шул инде, киребеткән нәрсә! Дөнья аренасына чыгарга нинди шәп момент бит, ә! Их, нигә генә сәрхуш булмадым! Синең урында мин булсам... (*Әрле-бирле йөри.*) Үзең турында уйламасаң, милләтең турында уйлар идең. Юк, булмый болар белән!

Т а й ф у р. Сине дәваларга бөтен дөньяның наркологлары алына икән, нигә баш тартырга?

Ж а н. Кызык кеше, кызык.

Т а й ф у р. Бер дә дөнья күрәсең килмимени?

Ш а к и р. Дөньяның мине күрәсе дә килми. Клоун буларак чыгарсагыз, бер хәл.

Т а й ф у р. Клоун һөнәре Жан әфәндегә кагылмый. Соңгы тапкыр сорыйм, бармыйсыңмы?

Ш а к и р. Әгәр ошбу адәм циркттан кумаса, мин аренада җырлар идем, менә болай дип:

Эчәм дисәң суы,
Чәе-мәе бар ич,
Юк, мин бармыйм анда,
Нигә миңа Париж?
Эйфельләрең белән
Дан казанган Париж,
Кызыктырма мине,
Сөембикәм бар ич!
Син дә барма, баҗа,
Син дә барма, Борис,
Казаныбыз бар ич,
Нигә безгә Париж?

Ишек кыңгыравы чылтырый.

Т а м и н д а р. Сәнифә!

Т а й ф у р. Ул!

Т а м и н д а р. Ярый әле эчмәдегез... (*Шакирга.*) Иптәш-әфәнде, сак бул, хәмер исеңне сизсә... Парижга кадәр очарсың!

Ш а к и р. Менә минем бер баҗам бар...

Т а й ф у р. Хөрмәтле коллегам, хәзер мин сине милләтебезнең иң мәдәниятле, тәртипле, тәүфыйклы, эчү-тартуның җан дошманы белән таныштырам. Сәнифә ханым Хәбиб...

С ә н и ф ә керә. Өйдәгеләрнең кемнәр икәнен чамалап ала да исерек хатынны уйный башлый.

С ә н и ф ә. Әй, син! (*Плащын идәнгә атып бәрә.*)

Т а м и н д а р (*аптырап*). Кем? Минме?

С ә н и ф ә. Син кем?

Т а м и н д а р. Таминдар ич.

С ә н и ф ә. Таминдар? Кайсы Таминдар?

Т а м и н д а р. Синең ирең.

С ә н и ф ә. Кайсы ирем?

Т а м и н д а р. Синең ирең бер генә.

С ә н и ф ә. Ни өчен бер генә?

Т а м и н д а р. Сәнифә...

С ә н и ф ә. Нинди Сәнифә ул?! Сәнифә юк хәзер дөньяда! Мин — Сәниф!

Т а м и н д а р. Сәнифә, нишләдең син? Танымыйм...

С ә н и ф ә. Син әле мине танымыйсыңмы? Танытырбыз! Кагылма плащка! Ятсын! Мин әллә башка фатирга кайттыммы? Бутаганмын... (*Чыгарга бара.*)

Т а м и н д а р. Син үз өеңдә. Кер, тынычлан... Әйдә, җаным, ятып тор...

С ә н и ф ә. Синең белән ятарга әллә мине фахишә дип уйлыйсыңмы? Кит! (*Тегеләрне күрә.*) Әйттем бит ялгыш кергәнмен дип... Болар кемнәр?

Т а й ф у р. Исәнме, Сәнифә?

С ә н и ф ә. Исән булмасам, әллә син доктормы?

Т а й ф у р. Әйе. Доктор.

С ә н и ф ә (*Тайфурның галстугына тотына*). Син мине ихтирам итәсеңме, юкмы?

Т а й ф у р. Тәк... ие... ычкындыр, зинһар!

С ә н и ф ә. Ихтирам итәсеңме, юкмы?

Т а й ф у р. Итәм, итәм, Сәнифә ханым... әй... Сәниф!

С ә н и ф ә. Ә монысы кем? Күзләрен җемелдәтеп утыра!

Ш а к и р. Хуш, Хәйбуш!

С ә н и ф ә. Хуш, Хәйбуш? Эштән чыгарылган татар артистымы?

Ш а к и р. Тач өстенә бастың!

С ә н и ф ә. Шакир абый, бәгърем, хуш, Хәйбушем, ник аны әйтми торасың? (*Кочаклый.*) Бүгенге көндә иң яраткан кешем син!

Ш а к и р. Мин әле чүп! Менә минем баҗам бар...

С ә н и ф ә. Үзең булганда, баҗаңның кирәге юк.

Т а м и н д а р. Сәниф... ни бит... бездә зур кунак бар. Синең урында булсам...

С ә н и ф ә. Кунак? Чакырылганмы?

Т а м и н д а р. Чакырылмаган да, татар да түгел.

Т а й ф у р. Таныш булыгыз, Франциядән... Нарколог.

С ә н и ф ә. Наркоман? Менә аларны мин ихтирам итәм.

Ж а н. Юк... юк... Париж. Клиника. Жан Дустән.

С ә н и ф ә. Кайчандыр кемнәрнедер биеткән мадам Сәнифә Хәбиб. Әй, ир!

Т а м и н д а р. Кем? Минме?

С ә н и ф ә. Син кемнең ире соң?

Т а м и н д а р. Синеке.

С ә н и ф ә. Ирем булсаң, тыңла, үтә! Франция кадәр Франциядән затлы кунак килгән. Кайда яртың?

Т а м и н д а р. Үзең беләсең, безнең өйгә хәмер кергәне юк.

С ә н и ф ә. Тап!

Т а м и н д а р. Ярты юк.

С ә н и ф ә. Их, Шакир абзыкаем, болар мине бөтен дөнья масштабында көлкегә калдыралар бит. Коткар, җаным!

Ш а к и р (*куеныннан грелка тартып чыгара*). Шәхси фирма: «Хуш, Хәйбуш!»

С ә н и ф ә. Ярар. «Хуш, Хәйбуш»не эчәбез, безгә барыбер! Тик аяктан гына ексын! Мсье Жан әфәнде. Пардон! Рәхим итегез, өстәлгә. Бонжур! (*Таминдарга.*) Стакан!

Таминдар бокал китерә.

Стакан! Сез дә утырыгыз... Сал, Шакир абый!

Өстәл тирәли утыралар.

Жан (*алдындагы тулы стаканны иснәп*). Бу нәрсә?

Тайфур. Соңгы елларда кулланылышка кергән халык иҗаты әсәре. Сак булыгыз, Жан әфәнде! Тост!

Сәнифә (*чәкешә*). Ля Париж!

Жан (*каба да кире куя*). Ой! Янам!

Шакир (*каплап куя*). Хуш, Париж!

Жан. Исәнме?..

Сәнифә (*Шакирны кочаклап җырлый*).

Стаканның шунсы яхшы —
Мөлдерәп утырганы,
Дус-ишләрнең шунсы яхшы —
Гөлдерәп утырганы!

Хуш, Хәйбуш! (*Таминдарга*). Син минем ирем булсаң, сал, капла. Кабымлыкка — чемечкә! (*Кесәсеннән ала.*) Бүлегез!

Таминдар. Мин әйттем... эчмим!

Сәнифә. Мин әйтәм, эчәсең! (*Көчләп эчерткән булып, үз стаканын түгә.*) Мин хәмернең исеннән исерәм, борчылмагыз, әфәнделәр! Их, Шакир абзыкачкаем, узган икән гомерләрем заяга. Ирләр юкка гына салмый икән. Рәхәтләнеп бер җырлыйк әле, биик әле, Шакир абзыкаем! (*Икесе җырлап-бииләр.*)

Күңелләр тирән булса да,
Кесә яклары сай, буш.
Хуш, Хәйбуш!
Үзеңнең җырың җитмәсә,
Минем җырымны да куш!
Хуш, Хәйбуш!
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде чит илгә,
Хуш, Хәйбуш!
Китмәс идем дә чит илгә,
Үз илемдә читен лә!
Хуш, Хәйбуш!
Китә инде, китә инде.
Китә инде кораблар.
Хуш, Хәйбуш!
Бәлки, бөтенләй кайталмам,
Җаным, бәгърем, карап кал!
Хуш, Хәйбуш!

Сәнифә (*Тайфур алдына барып тезләнә*). Тайфур,

коткар мине! Мин эчүдән тыела алмыйм. Дәвала мине, харап итмә...

Жан. Тайфур әфәнде, әллә без ялгыш кердекме?

Тайфур. Бер минут, коллегам. Тәк... ие. (*Сәнифәгә.*) Бу сезнең нерваларның вакытлыча ычкынуы гына. Стрэсс. Мин сезне бу хәлдә беренче тапкыр күрәм. Шунлыктан сезне сәрхуш дип кабул итә алмыйм.

Сәнифә. Мин әлегә кадәр яшердем. Сиздермәскә тырыштым. Үзегезгә алыгыз.

Тайфур. Берни дә эшли алмыйм. Минем өчен бу — аз.

Сәнифә. Ах, шулаймы? Дәваларга теләмисез? Кыскасы, булдыра алмыйсыз. Хатын-кызны бииздерү авыр шул, мөмкин түгел. Шакир абый, мә акча, бер ярты алып кер!

Шакир. Менә минем бер баҗам бар...

Сәнифә. Баҗаңны да кыстырып кил. Өчәү типтербез!

Таминдар. Сәнифә, ял ит, ятып тор!

Сәнифә. Синең белән ятып шушы көнгә калдым инде. Шакир дус, бир әле каешыңны!

Шакир. Минем баҗам... (*Каешын бирә.*)

Сәнифә. Баҗаңны да күтәреп бәрәм! Мин ирләр белән тигезсез көрәшкә чыгам. (*Каешын тотып.*) Татарчамы, французчамы? Йә, кемнән башлыйбыз? Селяви! Ля Париж? Ля татар? Йөрәгегез булса, чыгыгыз! Таминдар?! Тайфур?!

Кыңгырау чылтырый.

Шакир. Минем баҗам түгел микән? Ярый, хуш, Хәйбуш!

Сәнифә. Шакир абыкаем, тукта. Болар белән булмый! Киттек салырга! Баҗаңны да кереп алабыз! Икебезгә бер баҗа, өчебезгә бер ярты! Үзем сыйлыйм!

Таминдар. Сәнифә, айны...

Сәнифә. Сәлам белән Сәнифә. Исәр җилләр, чыгар кояш, бездән сәлам шул булыр! (*Шакирны кочаклап җырлый.*) Әйдә, шешәдәш дустым, киттек!

Стаканым путалы,
Уң кулыңа тот әле.
Алай бигүк эреләнмә,
Вак-вак итеп йот әле!

Чыгалар. Бүлмә тын кала. Таминдар башын игән. Тайфур белән Жан да дәшми.

Тайфур. Шундый-шундый хәлләр...

Жан. Коллега, ни булды бу?

Тайфур. Үзем дә аңламыйм. Безнең районда эчмәүче бердәнбер гаилә дип йөрсәм...

Ишектә кыңгырау.

Кемдер килә... Без киттек... (*Чыгалар.*)

Таминдар. Нишләргә бу хатын белән? Ничек яшәргә?

Алдында яшь гүзәл кыз Талия басып тора.

Нигә килдегез?

Талия. Мин сезгә икенче хатын булып килдем, Таминдар абый!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Айныткыч. Исерекләрне кабул итү бүлмәсе. Лозунглар эленгән.

«Исеректән исерек туа». *Плутарх*
«Исерү — үзең теләп акылдан язу». *Пифагор*
«Исерек халык белән идарә итү җиңелрәк». *Екатерина II*
«Килеп кермә монда, аек баш,
Исерек булсаң гына аяк бас!»
*Абдул Айнутдинов*

Пәрдә ачылганда ак халатлы Хаккый ялгызы.

Хаккый (*җырлый*).

Париж, Париж,
Гүзәл матур кала.
Халык шунда бара,
Казан озатып кала...

Абдул (*формадан керә*). Хаккый, ура!

Хаккый. Ни булды?

Абдул. Дөнья аренасына чыгабыз!

Хаккый. Ничек?

Абдул. Күрәсеңме?

Хаккый. Нәрсәне?

А б д у л. Кара урамга! Малайлар ташып өлгерә алмыйлар. Исерекләр машинага сыймый. Чират! Бер чакрым!

Х а к к ы й. Ни булган бу халыкка?

А б д у л. Париждан килгән Жан Дустэн бөтен шәһәрне аяктан екты.

Х а к к ы й. Кем соң ул Жан?

А б д у л. Белмәмешкә салышкан буласың. Яшермә, канәтем. Күрдем бит... Жан Дустэн курсларыннан чыкканыңны. «Парижга баргач, үзеңне ничек тотарга?»

Х а к к ы й. Ярар инде. Мин дә сине күрдем. Син салгансың... Тәки ычкындың?

А б д у л. Парижга барам, Хаккый, бармыйча калмыйм!

Х а к к ы й. Мин дә сала башладым. Өмет уятты ул каһәр суккыры!

А б д у л. Бонжур! Үзебез генә белик! Болай булса, Париж безнеке!

Х а к к ы й. Алла бирсә, Париж урамнарыннан бер җырлап узабыз!

> Чакырдым кый, килмәдең кый,
> Җаннарымны кыйдың кый! О' кей, Хаккый!

А б д у л. Утыр урыныңа! Кабул итә башлыйбыз! (*Ишеккә бара.*) Чират тәртибендә кертегез! Кабаланмагыз! Берәмберәм! Француз?! Иң беренче булып кертегез! Кадерле кунакны кабул итегез!

Ж а н (*керә*). Мин кайда?

А б д у л. Рәхим итегез, хөрмәтле кунагыбыз! Сез айныткычта!

Ж а н. Ай-ныт-кыч? Пардон!

А б д у л. Мерси!

Ж а н. Бу нәрсә? Мин беренче тапкыр.

А б д у л. Беренче тапкыр аяк басуыгыз белән котларга рөхсәт итегез, Жан әфәнде. Бу — безнең өчен зур дәрәҗә, Жан әфәнде!

Ж а н. Сез мине беләсез? Ничек?

А б д у л. Телевидение... Аннан соң без сезнең курсларда булдык...

Ж а н. Минем курсларда? Әһә... Парижга бару? Сез алкоголь яратасыз, шулаймы?

А б д у л. Яратам!

Х а к к ы й. Мин аннан башка яши алмыйм.

Ж а н. Мин кайда икәнемне белмим. Налог? Полиция? Ни белән шөгыльләнә бу фирма?

Абдул. Бизнес!

Жан. Бизнес? О! Бизнес нинди?

Абдул. Сезнең кебек үк, исерекләрне дәвалыйбыз.

Жан. Төшенмим.

Абдул. Сез безне дәвалыйсыз, без — сезне.

Жан. Ничек?

Абдул. Безне Парижга алып китәсе төркемгә кертәсез.

Жан. Алкашлар төркеменә? Сез бит полиция!

Абдул. Без монда — полиция. Парижда без — сезнең авыру. Сез хәзер бездә йоклап чыгасыз. Без сезгә йокларга урын тәкъдим итәбез. Рәхим итегез!

Жан. Йокларга? Пардон. Мерси! Бушлай?

Абдул. Бизнес! Чишенегез!

Жан. Сез мине чишендерергә уйлыйсыз?

Хаккый. Кыйммәтле әйберләрегезне, акчаларыгызны тапшырыгыз. Рәхим итегез!

Жан. Юк, юк, мин йокламыйм.

Абдул. Ярый, йокламагыз. Кадерле кунакка хөрмәт! Әмма монда кергән һәрбер клиент акча түли.

Жан. Акча?

Абдул. Бизнес!

Жан. Күпме?

Хаккый. Ун франк!

Абдул. Сез — кунак. Биш франк!

Жан. Мәгез, бизнесмен әфәнделәр, биш франк. Парижга барасыгыз киләме? Күрсәтәм мин сезгә Парижны, күрсәтәм! Инде мине һотельгә илтеп куясыз.

Абдул. Илтәбез, әмма сездән франк алмыйбыз. Бушлай. Әмма безнең икебезне Парижга барасы төркемгә кертәсез.

Жан. Миңа кирәк документ. Булса, алып китәбез.

Абдул. Документ була. Табабыз!

Жан. Бул сау! Рәхмәт.

Абдул. Мерси! Безне онытмагыз. Килгән саен кергәләп йөрегез! Хушыгыз, Жан Дустэн әфәнде! Бонжур, мсье! Егетләр, хөрмәтләп озатыгыз!

Жан Дустэнны озаталар.

Болай булса, «Мерседес»ны Польшадан түгел, Франциядән алып кайтабыз, канәтем! (*Франкны тотып.*) Менә ул җанашым франк! Бизнес шулай башлана. Мая!

Хаккый. Ничек эләктердең бу акуланы?

Абдул. Хәйлә кирәк, хәйлә! Малайларга әйтеп куйдым. Барып алдылар.

Хаккый. Ну, малай, чи мишәрсең икән!

Абдул. Бер-береңне таламыйча бизнес ясап булмый. Без әле, Хаккый канәтем, кыргый базарны үзебезгә иләштерербез. Әйтте диярсең.

Хаккый. Ай-һай, булыр микән?

Абдул. Булмый карасын!

Хаккый. Нишләмәкче буласың?

Абдул. АО «Хуш, Хәйбуш». Хуҗасы — Абдул Айнетдинов!

Хаккый. Ә мин?

Абдул. Син — уң кулым.

Хаккый. Синең белән коммунизмга да, капитализмга да барырга була!

Абдул. Сәрхушләр генә исән булсын! (*Сәхнә артында шау-шу.*) Иптәшләр, чиратка басыгыз!

Хаккый. Генерал!

Абдул. Чит ил кешеләренә, генералларга ташлама ясыйбыз! Генералны чиратсыз! Әйттем бит үзебезнең айныткычны бөтен дөньяга танытабыз дип! Әйдә, генералны үзебез язган «Алкашлар маршы» белән каршылыйбыз!

Атлый-атлый җырлыйлар.

Татарның җене,
Русның чёрты без,
Айныткычыбыз —
Туган йортыбыз!
Салган булсаң да,
Аума син, аума,
Айныткыч алда,
Алга, гел алга!

Маршны генерал формасы кигән, танымаслык итеп грим салган, сакал-мыек ябыштырган Шакир бүлә.

Шакир. Алга, генерал! Кем язды бу маршны? (*Абдулга.*) Син?

Абдул. Без яздык, иптәш...

Шакир. Галиҗәнап генерал! Үрә кат! Кабатла!

Абдул. Без яздык, галиҗәнап генерал!

Шакир. Исемең?

А б д у л. Айнутдинов! Абдул!
Х а к к ы й. Хаккый Фәтхрахманов!
А б д у л. Сорарга рөхсәт итегез!
Ш а к и р. Рөхсәт.
А б д у л. «Хуш, Хәйбуш» айныткычына килеп безне бәхетле иткән генерал, ягъни сез кем буласыз?
Ш а к и р. Генерал Шаке Кәлтрифүнович Буш Хәйбулловский! Исерекләрне айнытырлык марш язуыгыз өчен сез минем исемнән, хуш... ие... медаль белән бүләкләнәсез! Икегезгә бер медаль! Петр патша эчкечеләргә «исерек» дип язылган шушы бер потлы медальне тактырган. Котлыйм, бөркетләр! (*Абдулның муенына тага.*)
А б д у л. Аның тәҗрибәсе зуррак. (*Хаккыйга тага.*)
Ш а к и р. Ошбу медальне айныткычта беренче булып кулланыгыз. Әле генә президентка кереп чыктым. Медальне указ белән раслауны сорап. Моны исереккә таксаң, оялудан шундук салуны ташлар, дидем. «Хәл итәрбез, генерал!» дип вәгъдә бирә калды... Минем люкс бушмы?
А б д у л. Нинди люкс?
Ш а к и р. Нинди булсын, хуш Хәй... Инструкция буенча кабул итегез. (*Утыра.*) Чишендер!

**Абдул папахасын, Хаккый шинелен салдыра. Шакир галифеен үзе сала, трусиктан гына кала.**

Кесәдән акча эзләп тормагыз, сукыр бер тиен дә юк.
Х а к к ы й. Тәнендә эзләр, яралар юк.
А б д у л. Исемегез?
Ш а к и р. Ничек булсын... (*Сакал-мыегын ала.*) Хуш, Хәйбуш!
А б д у л. Шакир абый?!
Х а к к ы й. Син?!
Ш а к и р. Сизгерлек җитми, җегетләр!
А б д у л. Каян синдә мондый форма?
Ш а к и р. Кичә цирк белән исәп-хисапны өздем.
А б д у л. Цирктан киттеңмени?
Ш а к и р. Кудылар. Клоун кирәкми аларга.
Х а к к ы й. Әйбәт булган. Синең тамашачыларың монда киләчәк. Шуннан?
Ш а к и р. Бераз төшереп алгач, хәрбиләр кибетенә кергәнмен дә шушыларны сатып алганмын. Хуш, Хәйбуш! Киткәнмен урам буйлап, үз-үземә команда биреп: «Алга, Шакир абый!» Аннары туган йортка — сезгә килеп кердем... И җегетләр, эчмәс җиреңнән эчәрсең. Ни туган

йорт, ни туган ил юк... Бөтен ил айныткычка әйләнде. Кызык бетте тормышта. Элек әле киләчәккә өмет яшәтә иде. Хуш, Хәйбуш! Генералларга гына әз-мәз хөрмәт калды. Бер кадер күрәсе килгән ие генерал булып...

Абдул. Кереп ят үз урыныңа! Бар, бар, генерал Хуш, Хәйбулловский! (*Төрткәләп озаталар.*)

Хаккый. Ну, малай, шәп урнашып калдык. Әнә Хуш, Хәйбушларны куалар.

Абдул. Ярый әле яшьлек җүләрлеге белән галим булып җитмәдек. Йөрер идек ач пират булып, ачка койрык чәнчеп...

Хаккый. Дөньяның тоткасы милиция! Акча җәлләмиләр!

Абдул. Һәрбер адәмне милиционер яки генерал итмичә торып, тормыш рәтләнмәячәк. Әйтте диярсең!

Тышта шау-шу.

Кем тавышлана анда?

Сәнифә (*килеп керә*). Нахал! Тотма мине!

Абдул. Утыр!

Сәнифә. Утырыгыз!

Абдул. Утырыгыз, зинһар!

Сәнифә. Утырмыйм.

Абдул. Үтенәм, мадам, утырыгызчы!

Сәнифә. Җитәр инде, күп утырттыгыз төп башына. Мин беләм ирләрне.

Абдул. Фамилиягез?

Сәнифә. Минем кем булуымда синең ни эшең бар?

Абдул. Үзегез матур гына кыяфәтле. Кем белән эчтегез?

Сәнифә. Әй эчәбез, эчәбез,
Эчтек бүген, кичә без.
Шакир дуста эчкән идек,
Шунда калган шешәбез!

Хаккый. Чишен!

Сәнифә. Ә? Нәрсә?

Хаккый. Плащыңны гына.

Сәнифә. Юк инде... күп чишендерделәр. Бер көнне урамда пальтомны таладылар. Алкалар, балдаклар юк... сатып эчтем...

Хаккый. Яраланган, кагылган-сугылган урыннарыгыз юкмы, карыйк...

Сәнифә. Минем бөтен җаным яраланган, кагылган-сугылган... (*Бик моңлы итеп җырлап җибәрә.*)

Чит җирләргә киткән кошлар сыман,
Ак болытлар ага еракка.
Үз-үземне тыеп кына торам,
Китәр идем мин дә шул якка.
Ак болытны юлдаш итәр идем,
Хәлләремне алар аңласа,
Шул болытлар белән китәр идем,
Туган-үскән җирләр калмаса.
Баш очымда ак болытлар йөри:
Яңгыр микән, әллә кар микән?
Җанны яралаучы күп дөньяда,
Җанны дәвалаучы бар микән?

Абдул (*таныл*) Сәнифә апа...
Хаккый. Сәнифә апа, сез?
Абдул. Сез... нишләдегез?
Хаккый. Безне җырларга...
Абдул. Биергә өйрәткән... Сәнифә апа. Сез, шәһәрдәге иң айнык кеше, нишләдегез?
Сәнифә. Мин сезне танымыйм. Танырга да теләмим. Элекке Сәнифә апа мин.
Хаккый. Сез дә шул хәлгә төшкәч, безгә ни кала?
Сәнифә. Бу хатын гомерендә бер тапкыр айныткычка эләккән. Урнаштырыгыз аны!
Абдул. Сәнифә апа, әйдәгез, өегезгә илтеп куябыз.
Сәнифә. Мине? Ах, сез миннән җиңел генә котылмакчы буласызмы? Юк, мин монда кунам.
Абдул. Инструкция буенча, сез түләргә тиеш буласыз.
Сәнифә. Миндә акча бер букча! (*Өстәлгә ыргыта.*) Калдык кирәкми! Квитанция! Кунган өчен дә!
Хаккый. Эш урыныгызга кәгазь китәчәк.
Сәнифә. Эш — тю-тю! Кәгазен үземә!

Абдул белән Хаккый бер-берсенә карашып торалар.

Абдул. Ярар, сезнеңчә булсын. Кәгазен чыкканда алырсыз. Әйдәгез! (*Хаккыйга.*) Ля Париж?

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таминдар фатиры.

Таминдар (*телефонда*). Һалло! Кем бу? Дежур милиционер? Абдул Айнутдинов? Студент чакта циркка сәхнә эшчесе итеп алган идем. Хәтерләдем. Сәнифә апа сәлам әйтте? Борчылмаска кушты? Айныткычта? Мәхшәр. (*Әкрен*). Абдул иптәш-әфәнде, ярдәм итегез, өйгә бер кыз басып керде. Коткара күрегез. Килеп куркытсагыз, чыгып китәр иде. Көтәм. (*Номер җыя.*) Тайфур дустым, күршем! Мәхшәр! Бер кыз басып керде. Минемчә, ул ычкынган. Зинһар, килеп, тиешле урынга озат. Минем эш түгел? Коткар, күрше! Син бит доктор. Көтәм. Ул әле кибеткә чыкты. (*Маңгай тирен сөртә.*)

Шакир керә.

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Хуш, хуш... (*Төртеп чыгарырга уйлый.*)

Шакир. Минем партнерша кайтмадымыни әле?

Таминдар. Нинди партнерша?

Шакир. Мин бүген синең хатының белән кундым.

Таминдар. Кундың?

Шакир. Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Сәнифә белән?

Шакир. Кем белән булсын, синең хатының бер генә ич.

Таминдар. Кайда?

Шакир. Айныткычта.

Таминдар. Икегез бергә?

Шакир. Керүен аерым-аерым кергәнбез, аерым бүлмәләрдә йоклаганбыз. «Иртәрәк чыксаң, Таминдарга сәлам әйтә тор»,— диде. Әманәтен үтим.

Таминдар. Шакир әфәнде, утыр әле, киңәшләшик.

Шакир. Минем үземә киңәш кирәк.

Таминдар. Әйт, нишләргә? Миңа бер кыз басып керде.

Шакир. Менә минем бер баҗам бар, ул...

Таминдар. Икенче хатының булып килдем, ди.

Шакир. Үз аягы белән басып кердеме?

Таминдар. Үз аягы белән.

Шакир. Картмы?

Таминдар. Яшь шул.

Шакир. Ямьсезме?

Таминдар. Чибәр шул, каһәр суккыры!

Шакир. Соң?

Таминдар. Минем хәлдә калсаң, нишләр идең?

Шакир. Минме? Мин, энекәш, әйтер идем: Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Минем хатыным бар. Никахлы булмаса да...

Шакир. Исең киткән иске чикмәнгә. Хәзер эте-бете законлы хатын белән яшәп яткан була. Законсыз хатыннан шәбе юк аның, энекәш. Сәнифәне куып чыгарырга ниятлиме әллә? Хуш, Хәйбуш!

Таминдар. Юк шул. Сәнифә апаны ихтирам итәчәкмен ди.

Шакир. Язмыш бүләге бу! Әлбәттә, киләчәктә ул синең үзеңне дә куып чыгарырга мөмкин, мине куып чыгарган кебек, әмма анысы вак мәсьәлә.

Таминдар. Зуррак мәсьәләгә күч.

Шакир. Таминдар, синнән бәхилләшү акчасы алгач, кәефләнеп, генерал киеме сатып алганмын да урамда йөргәнмен. Хуш, Хәйбуш! Кибеттә кире алмыйлар, шуны сатып алмассыңмы?

Таминдар. Кит әле, аның кайгысымы миндә?

Шакир. Ярты бәясенә бирәм.

Таминдар. Нигә кирәк ул миңа?

Шакир. Киттем алайса. Хуш, Хәйбуш! Миннән хатыннарың санынча сәлам!

Таминдар. Тукта, Шакир әфәнде, ярдәм итсәң, шинелеңне алам.

Шакир. Шартың?

Таминдар. Сәнифә кайтып җәнҗал куптарганчы, теге кызны куып чыгарырга ярдәм ит.

Шакир. Хуш?

Таминдар. Син Сәнифәнең яңа гына кайтып төшкән генерал җизнәсе буласың.

Шакир. Хуш.

Таминдар. Бар бүлмәгә кереп киен. Теге кайтып керү белән, зәһәрләнеп чыгарсың. Тыңла, үтә!

Шакир. Алга, Шакир абый! (*Кереп китә.*)

Таминдар. Котылам болай булгач... Таминдарны тиз генә әләктерә алмассыз...

Талия керә. Кулында — сумка.

Т а л и я. Таминдарым, уяндыңмы?
Т а м и н д а р. Йокламадым.
Т а л и я. Сәнифә көндәш кайтмадымы әле?
Т а м и н д а р. Кайтмавын гына теләп тор инде. Кайтса...
Т а л и я. Мин аңардан курыкмыйм, әйбәт апа ул.
Т а м и н д а р. Кайтсамы... кайтса... О... О..!
Т а л и я. Нишләтә?
Т а м и н д а р. Чәчләреңне йолка!
Т а л и я. Шушы кап-кара толымнарымнымы? Ышанмыйм.
Т а м и н д а р. Аның куллары! Тәрәзәдән атып бәрә. Башта сине, аннары мине!
Т а л и я (*җырлап*). Без барыбер бергә булырбыз! Мин Сәнифә апаны андый мәрхәмәтсез итеп күз алдына китерә алмыйм. (*Җырлый-җырлый табын әзерли.*) Мин сине яратам, яратам, барыбер үземә каратам.
Т а м и н д а р. Сәнифәнең бик усал җизнәсе — генерал кайтып төште әле генә. Теге бүлмәдә.
Т а л и я. Шулаймыни? Искиткеч! Кунак итәрбез!
Т а м и н д а р. Сез... кеше өендә нишләргә уйлыйсыз?
Т а л и я. Сәнифә апаны табын әзерләп каршылыйм. Бу вакыйганы билгеләп үтәрбез.
Т а м и н д а р. Нинди вакыйганы?
Т а л и я. Минем сезгә килү бәйрәм түгелмени?
Т а м и н д а р. Кайтып кына керсен... күрсәтер ул сиңа бәйрәмне... миңа да!
Т а л и я. Хәзер без өчебез бер гаилә. Сәнифә апаның алъяпкычы бармы? Әлегә икебезгә бер булыр. (*Алъяпкыч алып бәйли.*)
Т а м и н д а р. Бәлки, «карават та икебезгә бер булыр» диярсез?
Т а л и я. Өчебезгә!
Т а м и н д а р. Талия, сеңел, хур итмә мине хатын алдында, абруемны төшермә!
Т а л и я. Сезнеке күтәреләчәк кенә! Нидән куркасың, Таминдар абый?
Т а м и н д а р. «Ике хатын белән тора» дип, бөтен дөнья шаулар!
Т а л и я. Аның ние бар! Коръән дә каршы килми. Әгәр матди яктан хәле бар икән, хәтта җиде хатын белән яшәргә рөхсәт ителә.
Т а м и н д а р. Бәлки, минем хәлемнән килмидер, каян беләсез?

Т а л и я. Минем хәлемнән килә, Таминдар абый. Нигә безгә бабаларыбыздан үрнәк алмаска?

Т а м и н д а р. Ә Сәнифә?

Т а л и я. Без — ике хатын — янәшә тыныч яшәрбез. Борчылма, сөеклем... (*Янына барып утыра, иркәләмәкче була.*)

Ш а к и р керә. Генерал киемендә.

Ш а к и р. Ни бу? Минем баҗам күз алдымда чит кызлардан иркәләтеп утыра. Хуш... Тор! Үрә кат! (*Икесе дә сикереп торалар.*) Генерал Шаке Кәлтрифунович Бушхәйбуловский! (*Таминдарга.*) Хәзер үк аңлатма яз!

Т а м и н д а р. Телдән әйтергә рөхсәт итегез!

Ш а к и р. Рөхсәт.

Т а м и н д а р. Шушы кыз минем өемә басып керде.

Ш а к и р. Ничек басып керде?

Т а м и н д а р. Икенче хатының булам ди...

Ш а к и р. Шушымы? (*Карап.*) Бик яшь бит бу!

Т а л и я. Үсә-үсә картаям мин, генерал җизни.

Ш а к и р. Минем баҗамнан да — шушы хөрәсәннән дә — җүнлерәк кияү табалмадыңмы, ахмак кыз? Хуш, Хәйбуш!

Т а л и я. Язмышым шулдыр. Генерал җизни, аңлагыз хәлемне, бирегез фатихагызны. Без өчәүләп бик тату яшәрбез.

Ш а к и р. Фатиха бирә алмыйм. Хуш, Хәйбуш! Ычкын! Хуш...

Т а л и я. Җизни, мин сез килүгә бик һәйбәт табын әзерләдем. Рәхим итегез, җизнәкәем! (*Өстәлгә шәраб куя.*)

Ш а к и р (*Таминдарга*). Нәрсә багана кебек катып калдың? Утыр!

Т а м и н д а р. Юк, юк, мин...

Ш а к и р. Утырырга! (*Утырта.*)

Т а л и я (*бокалларга сала*). Тотыгыз, җизни! Мин бик шат!

Ш а к и р. Менә минем баҗам бар — армиягә дә алмадылар. Таминдарның беренче хатыны өчен! (*Эчә.*) Сал! Таминдарның икенче хатыны өчен!

Т а л и я. Димәк, сездән фатиха, җизни?

Ш а к и р (*үзе салып*). Өченче хатыны өчен дә алдан эчеп куйыйк! (*Таминдарга.*) Син бөтенләй җебеп төштең. Ай-һай, ничек яшәр бу ике хатын белән!

Т а л и я. Рәхмәт, генерал җизни!

Шакир. Миннән фатиха! Хуш, Һәйбуш! Ике хатыныңның да рәхәтен күр, баҗа! Алга, Шакир абый! (*Чыга.*)

Талия. Таминдар абый, тагын шундый бер җизни юкмы?

Таминдар (*ачулы*). Мәхшәр! Монысы да бик җиткән!

Талия тәрәзә пәрдәсен төшерә.

Нишлисең син?

Талия. Карап тормасыннар...

Таминдар. Күтәр пәрдәне, әллә ни уйларлар.

Талия. Уйласыннар... Мин синең качып-посып сөя торган сөяркәң түгел, хатының.

Таминдар. Законсыз!

Талия. Законсыз хатының булырга да ризамын. Йөрәк законга буйсынмый. (*Таминдарга якыная.*) Икебезгә генә калырга һич тә ирек бирмиләр...

Таминдар. Ярый... Алай булса әз генә чигенәм. Болай мине хур итмә. Әйдә болай итик, син минем беркем дә белми торган сөяркәм генә бул.

Талия. Сез мине кем дип беләсез? Юк, юк, бары тик хатыныгыз!

Ишектә кыңгырау тавышы.

Үзем ачам. Рәхим итегез!

Абдул. Милиция өлкән лейтенанты Айнутдинов! (*Арты белән басып торган Талиягә карап.*) Хатыныгыз өйдәмени, Таминдар әфәнде?

Таминдар. Өйдә юк шул.

Талия. Өйдә!

Абдул. Хатыныгыз ничектер икенче кешегә охшаган дип әйтимме?

Талия. Әлегә фамилияне үзгәртергә өлгермәдем. Анысы кечкенә мәсьәлә. (*Кулын биреп.*) Талия Хәбиб!

Таминдар. Юк, юк!

Абдул. Сез беренче хатыныгыз белән яшәмисезмени инде? Аңладым, канәтем, алкашка белән яшәгәнче, эчми торган шушы яшьбикә белән яшәвең — мең артык!

Таминдар. Өлкән лейтенант, ышанмагыз, аферистка бу, хатыным өстеннән килде. Мин Сәнифәне аермадым.

Талия. Мин дә Таминдар абыйны да, Сәнифә апаны да яратам. Без бик тату яшәрбез.

Т а м и н д а р. Коткарыгыз! Сәнифә кайтканчы моны куып чыгарыгыз! Протокол төзүне таләп итәм!

А б д у л. Минем ярдәм итүемне теләсәң, сиңа шул киңәшем... Син моны башта исерт, аннары безгә шалтырат, шуннан соң без аны машинага салып, айныткычка, беренче хатының янына илтеп аударырбыз.

Т а м и н д а р. Тукта әле, тукта...

Т а л и я. Туктама, туктама...

А б д у л. Аңла, мин айнык кешене алып китә алмыйм. Бигайбә, инструкцияне боза алмыйм. Хатын алганда, бигрәк тә икенчесен, аеруча сак булу сорала. Пардон! (*Чыга.*)

Т а л и я. Юк, Таминдар абый, безне бернинди көч тә аера алмый хәзер!

Ишектә кыңгырау.

Т а м и н д а р. Дуслар килер, мине азат итәр...

Т а й ф у р керә.

Т а й ф у р (*кулындагы газетаны өстәлгә салып*). Укыдыңмы?

Т а м и н д а р. Берни дә белмим. Каяле... (*Укый.*) «Шәһәребезнең мәгълүм цирк директоры Таминдар Хәбибнең хатыны эчә башлаган. Шуңа җавап итеп, ул икенче хатын алып кайткан. Бу кыю адымны бабаларының гадәтләрен оныткан башка татарларның да күтәреп алуларына шик юк». Мәхшәр! Ялган! Провакация! Мин аны алып кайтмадым. Ул үзе килеп керде! Доктор, карагыз, зинһар...

Т а й ф у р. Шушымы?

Т а м и н д а р. Шушы.

Т а л и я. Исәнмесез, доктор? Сәламәтлегегез ничек?

Т а й ф у р. Рәхмәт. Әйбәт. Тыңлыйм сезне. Нидән зарланасыз?

Т а л и я. Аллага шөкер. Тап-тазамын. Берни дә борчымый.

Т а й ф у р. Хуҗагыз сезнең сәламәтлек өчен борчыла. Без тикшереп карарга булдык. Әлбәттә, үзегез риза булсагыз...

Т а л и я. Мин каршы түгел.

Т а й ф у р. Мин наркология белгече. Шулай да... күрше үтенгәч...

Таминдар. Доктор доктор инде...
Тайфур. Авызыгызны ачыгыз әле, туташ.
Талия. Күпме ачыйм?
Тайфур. Ача алган кадәр.
Талия. Ачтым.
Тайфур. «А!» дип әйтегез.
Талия. А-а-аллага шөкер!
Тайфур. Тешләрегезне күрсәтегез. Тәк... ие...
Талия. Авызым уймак кадәр генә, табиб әфәнде. Барысы да күренмәс.
Тайфур. Күренгәне дә бик җитә. (*Карап.*) Таман гына.
Таминдар. Акылга таманмы?
Тайфур. Үтә матур, үтә зәһәр!
Таминдар. Нинди мәгънәдә?
Тайфур. Тешләгән җирдән өзми куймый бу туташ.
Таминдар. Сез аның баш ягын тикшерегез.
Тайфур (*чүкеч ала*). Тезегезне тез өстенә куегызчы.
Талия. Куйдым.
Таминдар. Мин әйттем... башын...
Тайфур. Комачауламагыз. (*Чүкеч белән Талиянең тез өстенә суга.*)
Талия. Нишлисез?! (*Аягы белән чүкечне бәреп төшерә.*)
Таминдар. Әйттем бит, котырган! Йә, ничек?
Тайфур. Баш куям тезләреңә,
Яшь коям эзләреңә,
Әллә ниләр бирер идем
«Ах!» дигән сүзләреңә»...
дигән җырны ишеткәнегез бармы?
Таминдар. Аның монда ни катнашы бар?
Тайфур. Әнә шул җыр кебек!
Таминдар. Анысын мин үзем дә күреп торам.
Тайфур. Хәзер инде күзләрегезне тутырып, туп-туры менә монда... миңа карагыз. Миңа дим... тәк... ие...
Талия. Карыйм ич.
Тайфур. Карый алмый... Тәк... ие...
Таминдар. Шикле?
Тайфур. Әйтүе дә уңайсыз...
Таминдар. Ниһаять!
Тайфур. Аның күз карашы... коточкыч!
Таминдар. Әйттем бит! (*Телефон трубкасын суза.*) Чакырыгыз!

Т а й ф у р. Күз карашы... коточкыч матур. Башкага карый алмый. Бары тик сиңа гына төбәлгән.

Т а м и н д а р. Сез аның күз карашын түгел, күзләрен карагыз!

Т а й ф у р (*күзләрен карап*). Зәңгәр күк сыман болытсыз, аяз... Тирән күл сыман серле... шомлы...

Т а м и н д а р. Акыл ягы... сай?

Т а й ф у р. Син хаклы. Саерак.

Т а м и н д а р. Әйттем бит!

Т а й ф у р. Әмма...

Т а м и н д а р. Нәрсә әмма?

Т а й ф у р. Акылына караганда хисләре тирәнрәк. Мондый сихри күзләр өчен ханнар ярты патшалыкларын биргәннәр. Котлыйм, гүзәлкәй, сез искиткеч нәфис булу өстенә, сау-сәламәт тә! Киявегез дә үзегезгә лаек.

Т а л и я. Эчмим, тартмыйм, чит ирләр белән йөрмим.

Т а м и н д а р. Лаек түгел! Түгел!

Т а й ф у р. Миңа калса, бу гүзәл кыз икенчегә түгел, беренче хатынлыкка шәп булган.

Т а л и я. Әнә... вакытында алмады бит.

Т а й ф у р. Соң булганчы, уң булсын! Киттем, сәрхушләрем көтәдер. (*Чыга.*)

Т а л и я. Таминдар абый, туганнарыгыздан, дус-ишләрегездән, рәсми органнардан ризалык алдык. Син — минеке!

Т а м и н д а р. Талия, нигә сорамыйсыз, мин сезне яратаммы соң?

Т а л и я. Беренче хатыныгыз яратамы?

Т а м и н д а р. Кем белә аны? Яратадыр...

Т а л и я. Сез аны яратасызмы?

Т а м и н д а р. Кем белә аны. Яратадыр...

Т а л и я. Бер гаиләгә бер ярату бик җиткән. (*Көзге алдына килә.*) Таминдар абый, дөресен әйтегез, мин матур бит, әйеме? Карагыз инде бу гәүдәмне, күп ирләр мине төшләрендә дә күрмиләр. Мине яратмау мөмкин түгел! Әйт инде, матурмы мин?

Т а м и н д а р. Матурлык — туйда кирәк.

Т а л и я. Туйга махсус күлмәк тектем.

Т а м и н д а р. Кайтып кына кермәсен, күрсәтер ул туйны!

Т а л и я. Беренче хатының туйның түрендә — синең уң кулыңда утырыр. Икенчесе... Туйда «Әче!» дип кычкыргач, без ничек үбешербез икән? Әйдә, репетиция ясыйбыз! (*Үпмәкче була.*)

Т а м и н д а р. Җибәр! Кычкырам! Күршеләрне чакырам!

С ә н и ф ә керә. Икесе дә катып калалар. Таминдар битенә буялган иннек табын сөртә.

Мин түгел... ул үзе... (*Ялагайланып.*) Сәнифә, кайттыңмыни?

С ә н и ф ә. Минем ирем бармы, юкмы?

Т а м и н д а р. Бар, Сәнифә, бар!

С ә н и ф ә. Кем ул?

Т а м и н д а р. Мин.

С ә н и ф ә. Булса, нигә ул үзенең хатынын айныткычтан килеп алмый?

Т а м и н д а р. Җибәрми.

С ә н и ф ә. Кем?

Т а м и н д а р. Менә бу?

С ә н и ф ә. Кем бу?

Т а м и н д а р. Үзеннән сора.

Т а л и я. Сәнифә апа, исәнмесез? Тормышыгызны җиңеләйтү нияте белән, мин Таминдар абыйга икенче хатын булып килгән идем.

С ә н и ф ә. Син? Икенче хатын булып?

Т а л и я. Әйе.

Т а м и н д а р. Мин риза түгел. Ул үзе...

С ә н и ф ә. Синнән сорамыйлар! Тик тор! Өйне син җыештырдыңмы?

Т а л и я. Мин. (*Урындыкны өреп*). Утырыгыз.

С ә н и ф ә. Моның... бу мәхлукнең гомергә үтүк күрмәгән чалбарын да син үтүкләдеңме?

Т а л и я. Тишек оегын да ямап, юып куйдым. Ашарга әзер. Өчпочмак. Китеримме? Җаныгыз ни тели? Башта әз генә ял итеп алыгыз. Әллә ваннага кертеп юындырып алыйммы?

С ә н и ф ә. Үтереп баш авырта... махмыр...

Т а л и я. Менә моны кабып җибәрегез, Сәнифә апакаем.

С ә н и ф ә. Икенче хатын алып кайттым диген, ә?! Беренче хатынның баласы юк, диген, ә?!

Т а м и н д а р. Мин алып кайтмадым!

С ә н и ф ә. Тәки алып кайттың, ә? (*Каршына бара.*)

Т а м и н д а р. Сәнифә... җаным... аңла... мин... мин...

С ә н и ф ә. Өйгә бер тәүлек кенә кайтмый тордым... син...

Т а м и н д а р. Сәнифә кадерлем, үтенәм, тавыш чыгарма. Мине теләсә нишләт, аңа кагыла күрмә... кулларың...

Сәнифә. Син әле аны яклап маташасыңмы?

Таминдар. Юк, юк, якламыйм...

Сәнифә. Сеңелем, кил әле монда.

Таминдар. Тия күрмә...

Сәнифә. Чәчләрең озын икән...

Таминдар. Саклан, умыра!

Сәнифә. Кил әле якынрак.

Талия. Мин куркам.

Сәнифә (*кочаклап*). Хыялым тормышка ашты, сеңелем. Иремә икенче хатынлыкка, миңа көндәшкә килеп бик дөрес эшләгәнсең. Күпме көттем... (*Күз яшьләрен сөртә.*) Ул үзе дә яшь хатын алып кайтырга бик теләгән иде. Урамга чыгып бер сызгырсам, йөз хатын йөгереп килә миңа дигән иде. Сызгыруын ишеткәнсеңдер инде, шулаймы?

Талия. Мин сызгырганны да көтеп тормадым, килдем.

Таминдар. Сәнифә, мин бит юри генә әйттем, чынга алдыңмы?

Сәнифә. Минем ирем көчле, сеңелем, шикләнмә, ике хатынны асрарлык!

Талия. Без икебез бер хатын кебек яшәрбез, Сәнифә апа.

Сәнифә. Безнең кебек хатыннарга кәтүк кебек кенә бер ирне карау вак мәсьәлә.

Таминдар. Сәнифә, акылыңа кил, айны!

Талия. Сез мине үз гаиләгезгә кабул иттегез дип аңларга ярыймы?

Сәнифә. Ярый. Тик бер шарт белән! Син картаймыйча торып, Таминдарга өченче хатын алып кайтуны тыябыз. Мактыйм, Таминдар, хатынның...

Талия. Кызның...

Сәнифә. Шәбен тапкансың.

Таминдар. Мин тапмадым. Ул үзе!

Сәнифә. Бигрәкләр дә әйбәт. Хатын-кызны магнит кебек тарту көче бар синдә. Мине дә тарттың бит яшь чакта.

Таминдар. Сәнифә, нишлисең син, нигә көләсең иреңнән! Мин сезне аңладым, сез юри шаяртасыз. Әйт, шулаймы? Син бит эчмәдең? Айныткычка да эләкмәдең?

Сәнифә (*рольдән китеп, «айнып»*). Шаяртуны син үзең башладың: «урамга чыгып сызгырсам...»

Таминдар. Ачуны китергәнгә инде... Ә син?

Сәнифә. Мин шаярырга мәҗбүр булдым.

Таминдар. Ни өчен?

Сәнифә. Минем Парижны күрәсем килә.

Таминдар. Парижның ни катнашы бар?

Сәнифә. Миңа ничек кенә булса да, Парижга барачак сәрхушләр төркеменә эләгергә кирәк, аңладыңмы?

Таминдар. Димәк, син эчкече түгел?!

Сәнифә. Беренче сынауны син уңышлы үттең, Таминдар. Ышандым, син мине яшь чибәр кызларга да алыштырырга җыенмыйсың икән...

Таминдар. Алла сакласын!

Сәнифә. Хәзер икенче сынауны башлыйбыз. Монысында инде синең дә артистлык сәләтең күренергә тиеш. Бу сынаудан мин дә, син дә...

Талия. Мин дә...

Сәнифә. Талия дә отарга тиеш. Бизнес! Шартнамә төзибез!

Таминдар. Аңламыйм.

Сәнифә. Синең Финляндиягә барасың киләме?

Таминдар. Бик килә.

Талия. Минем дә!

Сәнифә. Талиянең дә Финляндиягә барасы килә. Минем анда барасым килми. Бары тик Париж! Төшендеңме?

Таминдар. Юк.

Сәнифә. Мин — Парижга, сез Талия белән — Хельсинкига! Ирле-хатынлы булып. Чөнки сине бары тик хатын белән генә чакыралар.

Таминдар. Талия минем хатыным булып?

Сәнифә. Вакытлыча гына... бөтенләйгә түгел...

Талия (*җырлап*). Син гашыйк бул миңа вакытлыча гына булса да...

Таминдар. Мәхшәр! Нигә аны башта ук әйтмисез? Нигә башны катырасыз?

Сәнифә. Димәк, син риза!

Таминдар. Риза булмаган кая! Син дигәндә мин, Сәнифәм, вакытлыча гына убырлы карчык белән яшәргә дә, дөнья читенә барырга да риза!

Талия (*авызын ерып*). Таминдар абый... (*Кочакламакчы була.*)

Сәнифә. Шартнамә өч нөсхәдә. Рәхим итеп кул куегыз. (*Таминдарга карап.*) Сиңа... Талиягә кагылмаска. (*Талиягә карап.*) Таминдарны Хельсинкидан саф килеш алып кайтырга... Үземә... Исән-сау Париждан кайта алсам, Таминдарга хыянәт итмәскә! Хуш, Хәйбуш!

Өчесе бергә. Хуш, Хәйбуш!

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге кафе-бар. Чит ил музыкасы уйный. Сәнифә белән Талия банкетка өстәл әзерлиләр. Телевизордан соңгы хәбәрләр бирәләр.

Диктор. Француз наркологы Жан Дустэн Гурье әфәнде шушы көннәрдә үзебезнең танылган психотерапевт Тайфур әфәнде Алтынбаев белән бергә, биш якташыбызны, яңа ысул белән дәвалау өчен, Парижга алып китәчәк.

Халык телендә «Хуш, Хәйбуш!» дип исем алган айныткыч, клиентларны кабул итү буенча, беренче урынга чыкты. Болай булгач, дөнья масштабына чыгарга да күп калмады.

Соңгы вакытта цирк тамашасына йөрүчеләрнең саны күпкә кимеде. Моны мәшһүр клоун Шакир Хәйбулловскийның штаттан кыскартылуы белән аңлаталар.

Сәнифә. Ишеттеңме, Талия, кандидатуралар бүген министрлыкта расланa. Шуларның берсе — мин!

Талия. Синең Парижга китүеңне миннән дә нык теләүче башка кеше юктыр, валлаһи!

Сәнифә. Беркем сүз әйтерлек түгел. Документлар тәртиптә!

Талия. Көнләшәм!

Сәнифә. Син дә хыялыңа ирешәсең.

Талия. Минем хыялым — печтик кенә. Берәр бай фин мишәре күз салмас микән?! Һич тә булмаса, үзебезнең Казан татары да ярап куяр иде.

Сәнифә. Миңа да берәр француз әфәндесе күз салмасмәле! Көнбатышта — ирекле мәхәббәт! Парижда торыр өчен берәр байның сөяркәсе булырга да ризамын!

Талия. Кара аны, кайтсаң, миңа косметика алып кайт!

Сәнифә. Кайтмасам да! Сәләви! Париж! Париж! Хыялымда Эйфель манарасына менәм. Түбәсенә күтәреләм дә, бар дөньяны яңгыратып, җырлап җибәрәм:

Эйфель манарасы биек,
Шуңа менәсем килә,
Шунда менеп, түбән карап,
Сезне күрәсем килә!

Талия, Парижга шушы күлмәгемне киеп китсәм, килешер микән?

Т а л и я. Элекке совет кешеләрен гаеп итмәсләр әле. Синең өчен үземнән дә артык сөенәм, җаным. Сөенечтән җырлыйсы килә. Ә синең аякларың биергә әзер торалар.

Тәти күлмәгеңне киеп
Кайларга китеп барыш?

С ә н и ф ә. Дөньядагы иң шөһрәтле
Өч шәһәр эзләп барыш!

Т а л и я. Һәр кеше белә аларны:

С ә н и ф ә. Париж!

Т а л и я. Малмыж, Мамадыш!
Минем нәфес бик бәләкәй,
Түгел байлыктан азмыш.

С ә н и ф ә. Мин барасы юллар ерак,
Кайсына ташлар язмыш?

Т а л и я. Мамадыш? Малмыж?

С ә н и ф ә. Париж!

С ә н и ф ә. Мадемуазель Сәнифә белән мсье Жан Дустэн менә монда утырачак.

Т а л и я. Ә җан дустың?

С ә н и ф ә. Кемне әйтәсең?

Т а л и я. Иребезне.

С ә н и ф ә. Уң ягымда — Жан Дустэн, сул ягымда — җан дустым. Юк, Жан мине ялгыз мадам дип уйласын. Таминдар вакытлыча менә монда утырсын.

Т а л и я. Минем беләнме?

С ә н и ф ә. Минем белән дә түгел, синең белән дә түгел. Син — официантка, йөгереп йөрисең.

Т а л и я. Мин бүгеннән ял алдым. Хельсинки! Син чакырганга гына килдем.

С ә н и ф ә. Әйдә, бер сәгатькә түз инде. Жан Дустэнны сыйлау өчен, Таминдар туйга бүләк иткән балдагымны саттым. Үзенә әйтмә!

Т а л и я. Син дигәндә, аяк идәндә, көндәшем-көндәшкәем.

С ә н и ф ә. Ой, йөрәгем леп-леп килә. Сәгать җиде!

А б д у л белән Х а к к ы й керә. Гади киемнән.

А б д у л. Мадамнарга сәлам!

Х а к к ы й. Ля Париж!

С ә н и ф ә. Сәлам, мсье!

Хаккый. Кунагыбыз кайда?

Сәнифә. Китәбез. Утырыгыз. Сез кунак түгел, хуҗа. Акчагыз түләнгән.

Абдул (*бокалга сала*). Ялган аракы түгелме? Юк. (*Эчә*). Мамадыш! Үзебезнең фирма!

Хаккый (*эчеп*). Мамадыш!

Сәнифә. Париж! Бары тик Париж!

Абдул. Жан Дустэн хөрмәтенә!

Сәнифә. Сабыр итегез, аның хөрмәтенә сөенечле хәбәр китергәч, үзе белән тост күтәрербез!

Таминдар (*керә*). Мәхшәр! Мин әйттем...

Талия. Таминдар абый... Кайчан китәбез?

Таминдар. Беркайчан да!

Сәнифә. Финляндиягә кайчан китәсез?

Таминдар. Тоттырдылар Финляндияне!

Сәнифә. Ничек тоттырдылар?

Таминдар. Кире уйлаганнар!

Сәнифә. Харап кына булгансыз икән.

Талия. Юк, Сәнифә апа, харап булмадык. Безнең тагын бер мөмкинлек бар иде.

Сәнифә. Нинди?

Талия. Фин юлы барып чыкмаса...

Таминдар. Татар юлы.

Сәнифә. Нинди?

Таминдар. Син Парижга барып, французга кияүгә чыгасың...

Талия. Мин үзебездә татарга кияүгә чыгам.

Сәнифә. Кемгә?

Талия. Синең элекке иреңә.

Сәнифә. Уйнапмы?

Таминдар. Уйлап. Без Талия белән уйладык-уйладык та...

Сәнифә. Ә шартнамә?

Таминдар. Шартнамә ул ике яклы гына була ала, дигән карарга килдек.

Талия. Үпкәләмә, Сәнифә апа, син безне үзең мәҗбүр иттең.

Абдул, Хаккый (*чәкешә-чәкешә эчеп, җырлыйлар*).

Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә...

Сәнифә. Әй, бик кирәгегез бар ие! Эйфель манарасына менеп бер җырласам, йөз француз йөгереп килә миңа!

Ш а к и р керә.

Ш а к и р. Сезләргә соңгы сәламем!

С ә н и ф ә. Йөрмә әле монда эч пошырып, безнең кунак көткән чак!

Ш а к и р. Иптәш әфәнделәр, бер генә минутка, сөенечемне әйтергә генә кердем. Сал әле, Талия сеңелем... акчам бар...

А б д у л. Мескен, ул да сүләшкән була...

Х а к к ы й. Аңа тагын сөенеч...

Ш а к и р. Финляндиядән чакыру алдым. Хельсинкига клоуннар ярышына чакырганнар. Үзләре түли.

Т а м и н д а р. Кит аннан, булмаганны!

Ш а к и р. Без дә «әфәнде» булдык! Менә укы!

Т а м и н д а р (*укып*). Мәхшәр! Барасыңмы?

Ш а к и р. Нишләп бармаска? Бушлай бит.

Т а м и н д а р. Париж хәтле Париждан баш тарттың, фингә сөенеп барасың.

Ш а к и р. Анда мин сәрхуш булып барырга тиеш идем. Финнәр талантымны хөрмәтләп чакыралар.

А б д у л. Хуп! Китүең хөрмәтенә берәр тост әйтеп җиффәр!

Ш а к и р (*бокал тотып*). Ярар, әйтәм алайса. Хөрмәтле... әй... милләтле... әй... милләтсез хөрмәттәшләр! Бетмәгән икән әле Шакир Хәйбуловский. Кадерен белүчеләр бар икән... Теге дөньяда ниләр бар икән. Мин дә бер күреп кайтыйм... Хуш, Хәйбуш! Хушыгыз! Сезгә дә уңышлар телим!

Чыга. Сәнифә моңсу җыр башлый, башкалар аңа кушыла:

Күңелләр тирән булса да,
Кесә яклары сай, буш.
Хуш, Хәйбуш!
Үзеңнең җырың җитмәсә,
Безнең җырларны да куш,
Хуш, Хәйбуш!
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде чит илгә,
Хуш, Хәйбуш!
Китмәс идем мин чит илгә,
Яшәү бигрәк читен лә!
Хуш, Хәйбуш!

Сәнифә. Киләләр! Миңа да хәбәр алып киләләр!
Абдул. Миңа да!
Хаккый. Миңа да!
Сәнифә. Миңа да! Париж!

Тайфур керә. Башын игән, борчулы.

Тайфур, Парижга кайчан очабыз?
Абдул. Мин бармы?
Хаккый. Мин?
Сәнифә. Жан Дустэн кайда?
Тайфур. И егетләр, иптәш-әфәнделәр... Париж турында хыялланмагыз да! Без биргән исемлек расланмаган. Жан Дустэнга икенче исемлек биргәннәр.

Һәммәсе хәрәкәтсез кала. Сәнифә һуштан яза, аны күтәреп торгызалар. Ерактан моңсу җыр ишетелә:

Китә инде, китә инде,
Китә инде кораблар,
Хуш, Хәйбуш!
Бәлки, бөтенләй кайталмам,
Тәрәзә ачып карап кал,
Хуш, Хәйбуш.

*1993—1995*

М.ФӘЙЗИНЕ УЙНЫЙБЫЗ

# *Хәлил — Галиябану*

*Мюзикл-юзикл*

КАТНАШАЛАР:

Бәдри — хәлле генә кеше. 50 яшьтә.
Галимә — хатыны. 40та.
Галиябану — кызлары. Бик матур кыз. 17дә.
Хәлил — урта хәлле, матур егет. 21дә.
Исмәгыйль — күп җир биләүче бай егет. 25тә.
Бәдига — яучы булуы белән танылган карчык. 65тә.
Сибгат
Хәмзә
Рәхмәт
Гали
Биктимер
Гөлми
Рабига
Сәгыйдә һ.б. } 16—23 яшьтăге егетлăр, кызлар.
Халык.

Вакыйга Оренбург ягы авылларының берсендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бәдринең ишегалды як өе. Кич.
Урамда «Галиябану» көенә гармун белән җырлап, сызгырып, куллар чабып үткән тавыш ишетелә. Галиябану, чигеп яткан эше кулында көенчә, өстәл янында тыңлап утыра.

Җыр:

Бакчада гөлләр ал икән,
Гөлдә былбыл бар икән,
Кашы кара, буе зифа,
Галиябану, сылуым иркәм,
Кемгә насыйп яр икән?
Үзегез өйдә утырасыз,
Тышка чыккан нурыгыз,
Нурыгызга күз чагыла,

Галиябану, сылуым иркәм,
Яшел пәрдә корыгыз.

Галиябану. Җырлаган идем бу көйне
Багышлап сөйгәнемә.
Исемем кушып җырлыйлар
Үземнең көйләремә.
Гармунда аның уйнавын
Күңелем белән тоям мин.
Сикерепләр чыгар идем,—
Йөрәгемне тыялмыйм.

(*Тәрәзәнең пәрдәсен ачып карый. Шунда ук гармун белән җырлап җибәрәләр.*)

Тәрәзәдән карыйсың,
Карап кемне таныйсың?
Карап күзең талдырганчы,
Галиябану, сылуым иркәм,
Ник чакырып алмыйсың?
Бөдрә-бөдрә, бөдрәсең,
Бөдрә чәчең көйдерәсең...

Галиябану. Кузгатмагыз ярсу йөрәкне,
Әни сизсә, бирер кирәкне.

(*Лампаны сүндерә. Уенчылар җырның яртысында шып туктыйлар.*)

Фәрештәләр сезне юлдаш итсен,
Җырлы юлыгызга гөл сипсен!

(*Әшен алып утыра. Ерактан гына егетләрнең җырлап киткәннәре ишетелә.*)

Без урамнан үтәрбез,
Җырлый-җырлый сиздереп,
Йокың килсә, ятып йокла,
Галиябану, сылуым иркәм,
Уятырбыз сызгырып...

Галимәбану тавышы. Галиябану, сылуым иркәм!

Галиябану эшен өстәлдәге кечкенә сандыкның астына куеп, чыгып китә. Күп тормый Бәдри белән Галимә керәләр.

Бәдри. Ишеттеңме? Ишеттеңме?
Галимә. Бигрәкләр инде харап!
«Галиябану сылуым» диләр!
Бәдри. Җырлыйлар безгә карап!

Кичә Бортас базарында
Тордылар әле сөйләп...
Галимә. Урамда мин дә ишеттем.
Бәдри. «Җырлыйлар сезгә төбәп!»
Галимә. Кашың кыйгач, битең кояш, диләр.
Бәдри. Аргы якның яланы,
Әче була баланы, диләр,
Ай, кояшым, кыйгач кашым,
Тилмертмә бу баланы, диләр.
Аның кашы кыйгачмы?
Башка бер кыз булмасмы?
Галимә. Сызылып киткән, кыйгач та...
Үзем күрдем тугач та.
Бәдри. Миндә генә!
Галимә. Бездә генә!
Бәдри. Сөйкемле кыйгач кашлар!
Бәдри абзаңа егетләр
Сәламнәр бирә башлар!
Җырны ишеткәннән бирле
Янып-көеп уйлыйм гел:
Җырлап узучының берсе
Түгел микән... Исмәгыйль?
Галимә. Юк, Исмәгыйль булмас ла...
Безгә юлын бормас ла.
Бәдри. Чәчләре чәчкә бәйләнсә?
Мәхәббәткә әйләнсә?
Галимә. Үзем дә ишетеп калдым,
Урамнан кайтып килеш,
«Галиябану — минеке! — дип,
Исмәгыйль әйткән, имеш.
Бәдри. Бәракалла, машалла,
Әйт шул сүзне тагы да!
Туры килсен фәрештәнең
«Амин!» дигән чагына!
Исмәгыйльме? Андый затлар
Башка кыз алмас кебек.
Исмәгыйльме? Ул әйткәнен
Эшләми калмас кебек!
Галиябану төн йокламый
Кулъяулык чигә дисең...
Йә, син аны кемгә дисең?
Ник аны эзләмисең?

Галимә өстәл өсләрен актара. Чиккән яулыкны табып алып, шатланып.

Г а л и м ә. Кулъяулыгы...
Б ә д р и. Табылды!
(*Галимәнең кулыннан кулъяулыкны тартып алып.*)
Сөенче, хатын, сөенче!
Ирешәбез теләккә!
Кулъяулыгын чигеп куйган
Исмәгыйльгә бүләккә!
Эшләр пеште болай булгач...
Г а л и м ә. Булмас, юкны сөйләмә!
Б ә д р и. Галимәбану, сылуым иркәм,
Безнең эшләр көйләнә!
Г а л и м ә. Куй аны үз урынына,
Хыялланма, тилермә.
Оят-хурлыкка калырбыз,
Үзе килеп керер дә...
(*Бәдри яулыкны урынына куя да эзләнә*).
Таптым! Егетләр хаты!
Г а л и м ә. И Аллам, чыга күрмәсен
Баланың яманаты!
Б ә д р и. Укы тизрәк, кемнән бу хат?
Г а л и м ә. Мин бит язу танымыйм.
Б ә д р и. Мин үзем дә шул чамада,
Укыр идем аны мин.
Иң ахыргы сүзен кара!
Хәзер китәбез баеп!
Нәрсәгә охшаш?
Г а л и м ә. Тора ул
Кармак кебек тырпаеп.
Б ә д р и. Аллага шөкер! Исмәгыйль!
Шатлан, карчык, бие, көл!
Кил әле, кил кочагыма,
Атлап түгел, биеп кил!
Г а л и м ә. И Ходаем, биргәненә
Мең шөкер вә мең рәхмәт!
Икесен дә бәхетле ит.
Бирче тигез мәхәббәт!
Б ә д р и. Исмәгыйльгә кояш булса,
Г а л и м ә. Башкаларга боз бит ул!
Б ә д р и. Галиябану сылуым иркәм,
Г а л и м ә. Без үстергән кыз бит ул!
Б ә д р и. Әби буласың — алда.
Г а л и м ә. Бабай буласың — алда.
Б ә д р и. Авызың булыр — майда.

Г а л и м ә. Авызың булыр — балда!
Б ә д р и. Егет тә сөя кызны.
Г а л и м ә. Кыз да сөя егетне.
Б ә д р и. Бар дөньяда табалмассың.
Г а л и м ә. Безнең кияү кебекне!
(*Йомшак кына сызгырган тавыш.*)
Б ә д р и. Ишеттеңме?
Г а л и м ә. Сызгыра. Ул.
Б ә д р и. Сизми калмасын тагын.
Г а л и м ә. И Ходаем, хәерле ит!
Б ә д р и. Төкле булсын аягың! (*Чыгалар.*)
Г а л и я б а н у (*кереп, ишекне элә*).

Гарык булдым Исмәгыйльдән.
Тагын язган хат миңа.
Ник аңламый икән инде:
Һәрбер сүзе ят миңа.
Унөч яшьтән бирле, Хәлил,
Йөрәгемдә йөртәмен.
Төн гөленең таң нурында
Ачылуын көтәмен.
Балкып тәрәзә төбемдә
Көтә сине гөлем дә.
Кулъяулыгым чәчәк булып
Җилфердәр таң җилендә.
Тәрәзәне ят кул чиртсә,
Гөлгә кереп качармын,
Күңелемнең саф чәчәген
Сиңа гына ачармын. (*Тагын сызгыру.*)
Сызгыруы бер көй кебек,
Күңел таный Хәлилне.
Әни сизсә — яхшы түгел,
Әллә чыкмый калыйммы?

**Шул вакыт матур тавыш белән сузып кына «Галиябану» көенә җырлаган тавыш ишетелә.**

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә.
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә.

Г а л и я б а н у (*тәрәзә янына килеп җырлый*).

Йөгереп төштем су буена,
Суда кошлар йөзә дип,

Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Җаныем, бәгърем, сылуым иркәм,
Куркам кеше сизәр дип.

Х ә л и л. Урамнардан үткән чакта,
Күзем төшә чарлакка.
Иңбашыңа шәлең салып,
Чыксана инде аулакка.

Г а л и я б а н у. Өй түрендә йөрмә, җаныем,
Ләйсән яуган эзләр бар.
Көн дә саен чыга алмыйм,
Әнкәемнән сүзләр бар.

Х ә л и л. Ал калфакта зәңгәр чук,
Сабыннарга салып сык.
Атаң-анаң йоклаган бит,
Акрын атлап янга чык.

Г а л и я б а н у. Кызып урак урган чакта,
Уч төпләрем тирләр дим.
Күптән атылып чыгар идем,
Әнкәй сизсә, тиргәр, дим.

Х ә л и л (*тәрәзәгә килә*).
Тәрәзәңне ачык куеп,
Кемгә күлмәк кистең син?
Кара кашым, карлыгачым,
Галиябану, сылуым иркәм,
Кем бәхетенә үстең син?

Г а л и я б а н у. Быел, быел дигәнем,
Быелгы ел көйгәнем.
Җаным, бәгърем, сылуым иркәм,
Кулларына гармун тоткан
Егет минем сөйгәнем.

Х ә л и л. Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал,
Сөюләрең чынлап булса,
Тәрәзәдән тартып ал.

(*Галиябану шәле белән капланыбрак кулын бирә, Хәлил бүлмәгә керә. Кулында гармун.*)

Х ә л и л (*Галиябануның кулын тоткан көе*).
Читән аша төшкән чакта,
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Шулкадәрле сагындым.

(*Галиябануны сәкегә тарта. Үзе утыра. Галия утырмый.*)

Җанкай, шәлең атсана,
Кил, алдыма ятсана.
(*Тартып алдына утырта.*)
Сөясеңме, сөймисеңме,
Боргаланмый әйтсәнә.

Галиябану. Аягыңдагы итегең
Болгар икән олтаны.
Сине сөйми кемне сөйим,
Син бит егет солтаны.

Хәлил. Көмеш йөгән кидерткәндә,
Башын чайкый аткаем,
Бит уртаңнан суырып үбәм,
Ачуланма, җанкаем.

Галиябану. Алмагачы иелгән,
Алмалары коелган.
Кичә дә бик каты үптең,
Менә иренем уелган.
(*Хәлил үбә, Галиябану үпкәли.*)

Хәлил. Биек таyга менәмсең,
Болыт килә, күрәмсең?
Үзәкләремне өзәсең,
Елама, Галиям, еламасана,
Бер үпкәннән үлмәссең.

Галиябану (*көлеп җибәрә*). Алдадым. (*Хәлил шатланып китә. Кочаклашып үбешәләр.*)

Хәлил. Козгыннар очмыймы янында?

Галиябану. Курыкмыйм син янда чагында.

Хәлил. Исмәгыйль арага керә бит.

Галиябану. Яратмыйм, ул шуны беләбит.

Хәлил. Уяу бул, күтәреп китмәсен!

Галиябану. Мин мәңге синеке! Көтмәсен.
Әтиләр тисәләр теңкәгә?

Хәлил. Мин яучы җибәрәм иртәгә!

Галиябану. Зинһар җибәрә күр ашыгып.

Хәлил. Бирмәсәләр?

Галиябану. Чыгам ябышып!

Хәлил (*аякка басып, кулын сузып*). Вәгъдәме?

Галиябану (*кулын биреп*). Вәгъдә!
Егет әйтә: кыз булсын,
Кызлар әйтә: үз булсын,
Алдым-бирдем шушы булсын,
Вәгъдә өчен сүз булсын!

Хәлил. Хуш, җаным, мин китәм ышанып.

Галиябану. Мин калам шикләрдән бушанып,
Юлыңа ак җәймә!
(*Хәлил гармун уйнап китә.*)
Ак укага энҗе тездем,
Бер бөртеге калганчы.
Ак теләкләр тели-тели,
Озатканда карап калам
Күз керфегем талганчы.
(*Тәрәзәне яба. Сузып кына әтәч кычкыра.*)

Бәдринең урам як өе. Сәкедә Галимә җеп эрләп утыра.

Бәдри (*өстәл янында*).
Сөенче, карчык!
Кулъяулык очкан!
Галимә. Димәк ки, кызны
Исмәгыйль кочкан!
Бәдри. Егет асылын
Сайлый белгән лә:
Үземә тарткан
Акыл белән дә!
Төялгән капчык,
Җигелгән атым.
Базарга китәм
Хәзер үк, хатын!
Үзеңне инде
Туйларында той!
Аны алып куй!
Моны алып куй!
Туй! Туй! Туй!
Галимә. Мәһәргә ниләр
Салырмын икән?
Бәдри. Бодай сатарга
Базарга китәм.
Галимә. Бүләкләр көтә
Кода-кодагый.
Бергә. Туй! Туй! Туй!
Галимә. Ходаем бирде
Безгә бүләкне.
Бәдри. Затлы да, бай да
Кияү эләкте!
Галимә. Тавыгыңны суй!
Сарыгыңны суй!

Бергә. Туй! Туй! Туй!
Бәдри. Кырма бүрек тә
Киеп кайтырмын.
Галимәбану, сылуым иркәм,
Сызгырып уятырмын!
Риза икәнне
Сиздереп тә куй!
Туй! Туй! Туй!
Бергә. Аны алып куй!
Моны алып куй!
Туй! Туй! Туй!

Чыгалар. Каршыларына Галиябану очрый.

Галимә. Тугансың икән, балакай,
Безне сөендерергә.
Әтиең китә базарга
Сине киендерергә.
Ниләр алып кайтсын сиңа?
Галиябану. Юк, кирәкми...
Галимә. Әйт инде.
Күпме яшереп йөрсәң дә,
Без белдек ниятеңне.
Галиябану. Бер теләгем бар барын да...
Сизде микән эти дә?
Әй... оялам әйтергә...
Галимә. Белдек, сиздек, сылуым иркәм,
Мәхәббәтегез ныклы.
Әтиең дә, әниең дә —
Бирәбез ризалыкны. (*Чыга.*)
Галиябану. Рәхмәт, әни.
Мин нинди бәхетле:
Сизгәннәр, белгәннәр,
Алар да Хәлилне
Яратып йөргәннәр.
Ашкынам, талпынам,
Һай, тизрәк кич җитсен.
Өйдәге шатлыкны
Хәлил дә ишетсен!
Бәхетле иттегез
Сез мине шулкадәр!
Килсәче Хәлилдән
Тизерәк бер хәбәр!

Бәдига керә.

Г а л и я б а н у (*каршына йөгереп бара*).
Әби, миңа килдеңме?
Б ә д и г а. Мин яучы булып килдем.
Икегезнең хәлне дә
Аңлаучы булып килдем.
Г а л и я б а н у. Хәлилдәнме?
Б ә д и г а. Хәлилдән!
Башкага әрәм итмәм.
Аның өчен бик уңай
Җавап алмыйча китмәм.
Г а л и я б а н у. Хәлил миңа ни диде?
Б ә д и г а. Яратам, белсен, диде.
Су буена уенга
Кич белән килсен, диде.
Г а л и я б а н у. Чакырыйм әниемне,
Ризалык алсаң иде.
Әти базарга китә,
Сөйләшеп калсаң иде. (*Чыга.*)
Б ә д ы й г а. Бүреләрне ауларга дип, аучы килер.
Сылу кызны яуларга дип, яучы килер.
Чиртте Хәлил Исмәгыйльнең борынына.
Монда йөрмә, килсәң кире борыл гына.
Аның өчен күп егетләр башын җуяр.
Кем бәхетле — күкрәгенә башын куяр.
Тапты егет уч төбендә тотарлык яр,
Уймакларга салып кына йотарлык яр.
Г а л и м ә (*керә*). Саумы, сәламәтме?
Б ә д и г а. Бәдрине дә күрим.
Г а л и м ә. Үзен базарга дип
Озатырга йөрим.
Б ә д и г а. Сездә бик җаваплы
Изге бер эшем бар.
Бәдрине дә чакыр:
Бик зур йомышым бар! (*Арба тавышы.*)
Г а л и м ә (*тәрәзәне ачып*).
Атасы, кереп китче!
Кунакны күреп китче!
Сатарга бара бодай.
Б ә д и г а. Юлын уң итсен Ходай.
Б ә д р и (*керә*). Ни бар? Юлны бүлмәгез,
Озак тота күрмәгез!

Галимә. Мин үзем хәл итәлмим.
Бәдига. Гаять хәерле бер эш.
Бәдри. Мондый кунак озаткач,
Юлым уңарга тиеш.
Бәдига. Мин юлыңнан бүлдермәм.
Баетырмын, бөлдермәм.
Галимә. Башың белән уйлап бар.
Атың кума камчылап.
Абыстай килгән безгә,
Кызыбызны яучылап.
Бәдига. Яшьләрнең бер-беренә
Вәгъдәләре бар икән.
Галиябану егеткә
Бик тә насыйп яр икән.
Бәдри. Ай, Бәдига абыстай,
Юкка йөрмисең икән.
Син кызга да, безгә дә
Байлык телисең икән.
Галимә. Ай, Бәдига абыстай,
Сүзең алтын-көмештәй.
Кызыбыз — терекөмештәй!
Бәдри. Киявебез — юрга тай!
Галимә. Ай, Бәдига абыстай,
Бәдри. Болай булгач, мин дә бай!
Бәдига. Кызыгыз Галиябану
Галимә. Очарга торган коштай.
Бәдига. Кыз бала булган өйгә
Килеп керсә Бәдига,
Вакыт җиткән дигән сүз
Әзерләнергә туйга!
Яучылаган кызларым
Ал-гөл гомер итәләр.
Кызлы өйләр, көнләшеп,
Бәдиганы көтәләр.
Алма кебек кызларга
Карачкыны димләмим.
Мактасам, белеп мактыйм,
Ялган сүзләр сөйләмим.

Галимә.
Бәдри. } Ай, Бәдига абыстай!

Бәдига. Егет бик уңган егет!

Галимә }
Бәдри. } Ай, Бәдига абыстай!

Бәдига. Авылда иң шәп егет!

Галимә. }
Бәдри. } Ай, Бәдига абыстай!

Бәдига. Бөтен яктан да килгән!
Галимә. Ай егет ул, ай егет!
Булган егет!
Бәдри. Бай егет!
Галимә. Безнең эшләр өметле!
Бәдига. Кызыгыз бик бәхетле!
Галимә. Алда — туйлар хәстәре.
Бәдри. Әрәм итмик вакытны.
Галимә. Егет — кызның акылы.
Бәдри. Кыз — безнең йөрәгебез.
Галимә. Галиябану теләге —
Безнең дә теләгебез!
Бәдри. Йә, тапшырдык Аллага.
Сөйләшербез алда да.
Галимә. Йә, Бәдига абыстай!
Чәй эчик инде кереп.
Бәдига. Юк, ашыгам, егетем
Җавап көтә тилмереп.
Бәдри. Мин дә юлымда булыйм,
Утырып дога кылыйм.

Дога кылалар. Бәдрине озаталар.

Галиябану (*ялгызы*).

Җанымны аңладыгыз.
Хәлилнеке хәзер мин.
Исән йөреп исән кайт,
Әти җаным, кадерлем.
Мин сөймәгән тарафтан
Салкын өреп исмә, җил.
Өметеңне өз инде,
Йөрмә арттан, Исмәгыйль...

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Су буенда таллар янында бер күренеш. Сәхнәнең бер ягында кызлар, бер ягында егетләр утырганнар. Кара-каршы җырлашу бара.

Кызлар. Мичләр тутырып утын яктым,
Чатный-чатный тик янсын,
Уңмаганга без бармыйбыз.
Мыегын сыпырып тик ятсын.
Егетләр. Су буенда таллар бар,
Яфрагында баллар бар,
Яр сөймәгән яшь кызларны
Сөйдерә торган хәлләр бар.
Кызлар. Урамыгыз төз түгел,
Төзәлүе тиз түгел,
Егет үзе ялынмагач,
Ялынучы без түгел.
Егетләр. Сез дә ата баласы,
Без дә ата баласы,
Сөймәгәнгә сөйкәнмибез,
Сөйсәң — ярлар табыласы.

Кызлар, җавап таба алмый, тукталып калалар.

Хәмзә (*үртәп*). Сөймәсәгез сөймәгез!
Гали. Комга терәлде көймәгез!
Биктимер. Уйна, Хәлил, гармуныңны,
Ял итсеннәр бар йөрәкләр,
Түзәлмичә сикереп чыксын
Аккаеннар, тал-тирәкләр!
Хәлил (*бер гармунны кулына тотып, икенче гармунның өстенә утыра*).
Җавабыңны җырлый-җырлый,
Бии-бии тап әле!
Гали. Тузаныңны как әле!
Хәмзә. Әллә кая кереп качкан
Сөйгәнеңне тап әле!

Кул чабып тора. Сибгат кызлар өстенә очып куныл, Рабиганың яулыгын тартып ала, яулык селкеп бии. Кыз туктагач — егет, егет туктагач, кыз биеп, ахырдан кара-каршы биеп китәләр. Биктимер, кызга, егеткә туры китереп, такмаклар әйтеп тора.

Биктимер. Сип, сип суганга,
Тимә безнең туганга,

Безнең туган матур булган,
Зифа буйлы булганга.
Бас, бас күзенә,
Күз тимәсен үзенә,
Яшел чирәм үсеп тора
Аяк баскан эзеңә.
Казаннан килгән егет
Оек-чабата киеп,
Монда килеп, итек киеп,
Нишләп йөрисең биеп?
Һайт! Сип!
Ай-ли, бу Гөлми
Матур баса түгелме,
Тып-тып басып биегәндә,
Өзәләр бит күңелне.
Бас, кызым, Әпипәм,
Син басмасаң, мин басам,
Шундый ямьле су акканда,
Басып калыйк ичмасам.
Биек тауның башыннан
Күренәдер бер авыл,
Җыен яшьләр бергә килгәч,
Менә шулай була ул!
Тыпыр-тыпыр килеп,
Биеп йөрисең икән,
Мин кияүгә китәмен дип,
Көеп йөрисең икән.
Биек тауның башыннан
Күренә пәри шәһәре,
Быел кызларның мәһәре —
Бер падаука бәрәңге,
Һәй ли, һәллә-лә!
Бас, бас күзенә,
Күз тимәсен үзеңә,
Җимер тимер коймасын,
Юл өстенә куймасын.
Как, сук коймасын,
Бәдри абзый тоймасын,
Тоймагае, чәнчелсен,
Юлына күмер чәчелсен!

Биючеләр, туктап, урыннарына утыралар.

Гали. Исмәгыйль нишләп күренми?
Рәхмәт. Язгандыр ул һушыннан.
Хәлил. Ай-һай, бигрәк усал әйттең!
Сибгат. Сыерчыгын очырган.
Гали. Сизәбез ич, сөйгәнеңне
Кочарга ашкынасың.
Сәгыйдә. Сыерчыгыңны козгыннан
Коткарган карчыга син!
Сибгат. Карчыганы зурладың,
Галияне хурладың.
Гөлми. Бүгеннән соң Галиябану
Сандугачка әйләнсен.
Сәгыйдә. Хәлил тизрәк өйләнсен!
Рәхмәт. Чәчләр чәчкә бәйләнсең!
Хәмзә. Уйна, Хәлил, гармуныңны,
Чыгар җаннан бар моңыңны,
Яшьлегеңне, ярсуыңны,
Сөюеңне, шатлыгыңны!
Сибгат. Бәхетлеләр яшәр инде
Бер-берләрен кочып-сөеп.
Рәхмәт. Соңгы тапкыр җырлап калыйк,
Галиябану иркәм, диеп.

Хәлил «Галиябану» көен уйный. Хәмзә белән Рәхмәт парлап җырлыйлар.

Су буенда гөлләр үскән,
Кызлар йөргән төштер бу,
Сөеп алу, сөеп бару,
Галиябану, сылуым иркәм,
Илдә булган эштер бу.
Алмагачның алына
Былбыл кунган талына.
Егете алсын, кызы барсын
Җаны сөйгән ярына.

Шул вакыт Гали кызлар өстенә бака ташлый. Кызлар «Һай!» дип сикерешеп торалар. Күңелле шау-шу.

Сәгыйдә. Абау, бака! (*Болганган арада Хәмзә Рабиганың шәлен тартып ала да, шәлне бөркәнеп, кызлар янына барып утыра. Аннан сикереп тора да кызлар тавышы белән такмак әйтеп биеп китә.*)

Тиратай, тиратай,
Бер кияүгә бир, атай!
Тиратай, тиратай,
Бер кияүгә бир, атай!
(*Шәлне алып, үз тавышы белән.*)
Бер кияүгә бирмәсәң,
Кәләш алып бир, атай!

Хәлил (*гармунын тартып*). Әйдә, җырлатабыз кызларны!
Рәхмәт. Галиябану белән Гөлмине!
Сәгыйдә. Рәхмәт белән Сибгатне!

Сибгат җырлый, аңа Галиябану белән Сәгыйдә кушылалар.

Сибгат. Карлыгач кара, муены ала,
Очып киткәч югала.
Кыз бала дигән газиз бала
Үсеп җиткәч югала.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Китә кызлар яше җиткәч,
Алмадай матур пешкәч,
Ир балалар кайта киткәч,
Кызлар кайтмый бер киткәч.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Күк аргамак, киң күкрәк,
Җиккән сыңар тәртәгә,
Егетләргә һәм кызларга
Илдә булсын мәртәбә.
Ай-ли, Җәмилә,
Шушылай утыру ямьле лә!

Хәлил. Әйдәгез кузгалабыз!

Галиябану сикереп тора.

Гали. Галияне сикерттең.
Рәхмәт. Бу сүзне озак көттең.
Биктимер. Бик асыл кошны чирттең!
Хәлил. Әйдәгез китәбез!
Гали. Туйны кайчан итәбез?
Хәлил. Көне җиткәч, дәшәрбез.

Хәмзә. Гел-гел көтеп яшәрбез.
Сәгыйдә. Киттек, кызлар, көтү кайта!
Галиябану. Чишмәгә төшәсем бар.
Гали. Көнләшәбез, Хәлил, синнән,
Салкын су эчәсең бар.

Яшьләр җырлап китәләр. Сызгыру, кул чабу, төрле кыланышлар.

Алай да безгә нужалай,
Болай да безгә нужа.
Әй-й-й!
Уйнамый да, җырламый да
Яшь гомер ничек уза!
Исмәгыйль (*ялгызы*).
Тирә-якта яман хәбәр йөри.
Оят-хурлык әгәр чын булса.
Минеке дип йөргән сылу кызның
Юлы башка якка борылса!
Юк, ышанмыйм моңа, мин барында
Мондый эшкә бармас беркем дә.
Ул да мине яратырга тиеш!
Галиябану минем иркемдә!
Тик шулай да ялган-гайбәтләрнең
Уртасында калдым әле мин.
Безнең арабызга керер өчен
Башы ике түгел Хәлилнең.

Көянтә-чиләк күтәргән Галиябану сәхнәдән үтә башлый.

Исмәгыйль. Гөлләр үссен, иркәм, юлларыңа!
Галиябану. Бүлмә юлларымны, кит, тотма...
Исмәгыйль. Нигә ашыгасың? Зинһар, тукта.
Бары ике генә минутка.
Галиябану! Сезнең тирәгездә
Оя кора диләр бер козгын.
Расмы шул сүз?
Галиябану. Рас иде дә инде котылдым.
Исмәгыйль. Хәлилдәнме?
Галиябану. Исмәгыйльдән.
Исмәгыйль. Галиябану!
Галиябану. Мин Хәлилгә инде вәгъдә бирдем.
Исмәгыйль. Алданасың!
Галиябану. Алдансам да, сиңа үпкәләмәм.

Исмәгыйль. Син минеке! Бары минеке бул!
Галиябану. Мәңге булмам.
Исмәгыйль. Галиябану җаным, Хәлилдән дә
Артыграк сөям бит сине.
Бар тирә-як аягүрә баса
Ишеткәндә минем исемне!
Бәхетеңне үзең киртәләмә.
Чыга калсаң миннән бүтәнгә,
Туры килер сылу яшьлегеңне
Кайгы белән тәмам итәргә.
Галиябану. Җәберләмә. Мин Хәлилне сөям.
Исмәгыйль. Ах, шулаймы? Ялгыш атлыйсың,
Онытмагыз сезгә Исмәгыйльнең
Гомере буе ачу саклыйсын!
Галиябану. Кит юлымнан, зинһар...
Исмәгыйль. Юк, тиз генә китә алмассың.
Галиябану, аңла, йөрәгемдә
Мәңгелеккә урын алгансың.
Галиябану. Артык тора алмыйм синең янда...
(*Китә башлый.*)
Исмәгыйль. Янган йөрәгемә ук атма.

Галиябануның шәлен тартып ала. Көянтә-чиләкләре җиргә төшә.

Галиябану. Бир шәлемне, сорыйм, туктатма...
Исмәгыйль. Бар кит! Ник китмисең?
Хәлилеңә ашыгасыңмени?
Галиябану. Мине йөдәтүдән файда юк.
Бир шәлемне!
Исмәгыйль (*шәл тоткан кулын бөеренә таянып, «Галиябану» көенә җырлый*).
Җәйгә чыксаң, җилләр өчен
Җәй келәткә урыныңны.
Миннән артык яр тапмассың,
Бик күтәрмә борыныңны.
Галиябану. Рәнҗетмә, бир шәлемне...
Исмәгыйль. Ник китмисең? Бар кит!
Чүплек башындагы өендә
Ярап торыр шәлсез килен дә.
Хәлил (*йөгереп керә*).
Ах, бәдбәхет, кара елан булып,
Кермәк буласыңмы арага?

Г а л и я б а н у. Җаным, бәгърем, коткар, арала.
Х ә л и л (*Исмәгыйль кулыннан шәлне тартып ала*).
Башка бу тирәдә күренмә!
Козгын, сандугачка үрелмә!
(*Галиябануны алып чыга.*)
И с м ә г ы й л ь (*ачу белән карап калып*).
Шушы Хәлилнең кулыннан
Тартып алмасам сине,
Исмәгыйль дип атамагыз
Моннан соң исемемне!

Нык-нык басып чыга. Бераздан Х ә л и л белән Г а л и я б а н у керәләр.

Х ә л и л (*уйнап-җырлап килә*).
Аклы ситса күлмәгемне
Саламын да киямен.
Ярым ятлар белән уртак,
Янамын да көямен.
Г а л и я б а н у. Куркам, хәзер үк Исмәгыйль
Әти-әнигә барыр,
Әти бик аумакай кеше,
Үз ягына аударыр.
Х ә л и л. Син тынычлан әле, Галиябану.
Г а л и я б а н у. Зинһар өчен, табыйк бер юлын.
Х ә л и л. Базарыннан этиең кайтып җитсен,
Сабыр итеп торыйк, былбылым.
Г а л и я б а н у. Әти кайтса...
Ә Исмәгыйль эшне болгатса...
Әтиләрем әгәр айнысалар,
Аның сүзләренә җай булсалар?
Х ә л и л. Көмшәр авылына юл тотарбыз.
Качарбыз да никах укытырбыз.
Г а л и я б а н у. Әгәр мине бикләп куйсалар?
Х ә л и м. Әйт аларга: мин үзем дә
Аңлый башладым, диген,
Борчылмагыз, мин Хәлилне
Инде ташладым, диген.
Мин килермен синең тәрәзәгә,
Төнге урамнардан узарбыз.
Эт тә өрмәс, беркем сизми калыр,
Көмшәр авылына сызарбыз.
Г а л и я б а н у. Ул-бу булып, киләлмичә калсаң?..

Х ә л и л. Таш яуса да килми калмамын.
Г а л и я б а н у. Күңелемне шикле уйлар борчый...
Х ә л и л. Биргән вәгъдәм оныта алмамын.

Читтән гармун тавышы ишетелә.

Г а л и я б а н у. Кемнәр алар? Нигә җыелганнар?
Х ә л и л. Исмәгыйльләр... җырлап үтәләр.
Г а л и я б а н у. Алар безне харап итәләр...

«Галиябану» көенә җырлый башлыйлар.

Җәйнең ямьле көннәрендә
Асыл кошлар кычкыра.
Әллә нинди җебегән авыз
Егет саен кочтыра.

Г а л и я б а н у. Алар безне мыскыл итәләр!

Җ ы р

Сары атым саз буенда,
Җиз камыты муенында.
Алмасам да үкенмимен,
Күп йокладым куенында.

Г а л и я б а н у. Ах, ялган! Ялган! (*Егыла башлаганда, Хәлил тотып кала.*)

Бәдринең бакчасы. Бер читендә сәке. Яңа җыеп куелган чәй урыны. Г а л и м ә поднос сөртә. Б ә д р и сәкедән аягын салындырып читтәрәк утыра. Кич.

Б ә д р и. Байга кыз бирәбез.
Алда — яшьләр туе.
Булам бай кодасы!
Г а л и м ә. Мин бай кодагые!
Акыл-зиһен ягың
Бик чуалып китте.
Б ә д р и. Туйга-мәһәренә
Салыйк икән күпме?
Без дә җүләр түгел,
Кияү белеп торсын.
Г а л и м ә. Туйга — илле булса,
Мәһәренә — йөз сум!!
Б ә д р и. Йөз дә илле сумга

Кыз бирәмме соң мин?
Шундый гүзәл өчен —
Мин мең тәңкә сорыйм!
Сиңа — кәшемир шәл!
Галимә. Кызыбызга — читек!
Бәдри. Тойсын аны кияү
Морза кызы итеп!
Галимә. Кара, кем ул килә...
Үзе — безгә килә!
Бәдри. Әйдә китик, үзе
Кызыбызга килә!

Чыгып барганда, Галимә абынып егыла. Аксый-аксый чыгарга уйлый да туктап кала.

Бәдри. Әйдә, рәхим ит, Исмәгыйль!
Исмәгыйль. Туйлар булсын мөбарәк!
Галимә. Шатлыгыбыз эчкә сыймый.
Бәдри. Сөенәбез бергәләп.
Төкле аякларың белән!
Галимә. Бәхетең белән кил инде!
Исмәгыйль. Риаланма, Бәдри абзый,
Инде бар да беленде!
Галимә. Йә Хода, берни белмибез.
Бәдри. Тиздән туй дип йөрибез!
Исмәгыйль. Син — аңгыра, ә син — җүләр!
Бергәләп киңәшкәнсез:
Сез... сез Галиябануны
Хәлилгә ярәшкәнсез!
Бәдри, Галимә. Хәлил? Кияү? Ни дигән сүз?
Бәдри. Йөрмә юк сүзгә карап.
Галимә. Дошман кергәндер арага.
Исмәгыйль. Алдама күзгә карап!
Бәдри. Нинди Хәлил? Юктыр аны
Уйга да керткәнебез.
Исмәгыйль. Молчать! Хәлил булып чыкты
Кияү дип көткәнегез!
Бәдри. Яулык урнына кызыбыз
Чиккән яулык та бирде.
Исмәгыйль. Яулык дигәнегез күптән
Хәлил кулында инде.
Бәдри. Син дип белеп ялгышканбыз...
Исмәгыйль. Дәшмә! Мерзавец! Куштан!

Димәк, мине икегез дә
Ясарга тели дошман!

Бәдри (*калтырап*).
Бу нинди эш? Кызыкайны
Бар, тиз алып чык монда!

Галимә чыга.

Мин кызымны үстермәдем
Авыл көчекләренә!

Исмәгыйль.
Үзең кара, Бәдри абзый, мин китәм.
Уйлама син: юри генә өркетәм.
Хурга калу миңа үлем белән бер.
Галиябану, бел, минеке барыбер!
Миңа төбәп байтак сүзләр ишеттем,
Мин үземне кимсетелгән хис иттем.
Галияне Хәлилдән тотып калсаң,
Иртәгә үк никах та укыталсаң,
Бәдри абзый шуны бик белеп торсын:
Туй-мәһәрдән башка сиңа — бер мең сум!

Бәдри. Бер мең сум?! Мең тәңкә?!

Исмәгыйль.
Икесенең вәгъдәләрен җимер син,
Шул чагында мең тәңкәгә килерсең! (*Китә.*)

Галимә кызын алып керә.

Галиябану. Мин нигә кирәк булдым?

Галимә. Күңелем тулып китте.
Безнең янда булачак
Киявең булып китте.

Галиябану. Нинди кияү?

Галимә. Исмәгыйль.

Галиябану. Ул нинди кияү булсын...

Бәдри. Сиңа биргәч кияү була,
Җаныңа ия була.

Галиябану. Бирдегез ич инде.

Бәдри. Кемгә?

Галиябану. Кемгә булсын... Хәлилгә.

Бәдри. Без бит уйладык сине
Бирдек дип Исмәгыйльгә.

Галиябану. Төшенмим... Ах, бу ни эш?

Бәдри. Кыскасы, син бер сүзсез
Аңа чыгарга тиеш!
Галимә. Үз эти-әниеңә
Хурлык китермә, кызым.
Исмәгыйлеңә чыксаң,
Бәхетең булыр озын.
Галиябану. Мин аңа бармыйм!
Бәдри. Барырсың!
Галиябану. Ул кансыз ерткыч адәм.
Бәдри. Юкса мин сине, кызыкай...
Галимә. Атаңны тыңла, балам.
Бәдри. Бәдбәхет кыз! Карышсаң,
Миннән яхшылык көтмә.
Галиябану. Сөймим аны, яратмыйм...
Галимә. Картлыкта рисвай итмә!
Бәдри. Мин ни әйтсәм — шул булыр!
Син әлегә минеке!
Галиябану. Үтер, тик аңа бармам!
Мин бары Хәлилнеке!
Бәдри. Ах, шулаймы? Булмыймы?!
Галиябану. Хәлилне генә сөям...

Бәдри гайрәт белән селтәп җибәрә, Галиябану атылып барып төшә.

Галимә. Нишләвең бу, тимә аңа...
Бәдри. Кирәк булганга тиям!

Аны да селтәп ыргыта. Галиябану җирдә яткан көе үкси.

Галиябану (*торып, акрынлап, өстерәлеп кенә барып, бер агачка сөялә*).
Инде нишлим, хәлем аңламагач
Якын дигән кешең — үз атаң.
Килерсеңме, юкмы, әллә инде
Үз-үземне юкка юатам...
Бәдри. Күп уйландың, кызым, шул арада
Килгәнсеңдер инде акылга.
Галиябану. Мин уйладым, үземнеке түгел,
Сезнең бәхетегез хакында.
Күнәм инде... башка чарам юк.
Бәдри. Рәхмәт, кызым, безне аңладың.
Сөрт яшеңне. Әнә үзе килә.
Галимә. Бәхетеңә каршы бармадың.

Исмәгыйль. Исәнме, Галиябану?

Галиябану баш ия, эндәшми.

Бәдри. Насыйп булды, кияү, иртәгә үк
Укытырбыз инде никахны.
Исмәгыйль. Күпме ишетергә туры килде
Исемемә кунган нахакны!
Булды, димәк?
Галимә. Мин дә, атасы да нык аңлаткач,
Ахыр чиктә бала төшенде.
Бәдри. Андый эшне миңа куш инде.
Исмәгыйль. Риза, димәк?
Галимә. Риза инде...
Бәдри. Ризалыкны
Кем бик тели, аны шул ала.
Исмәгыйль. Галиябану туташ, бир кулыңны...
Галимә. Ояла ич, һаман ул бала...
Бәдри. Бир кулыңны, кызым...

Галиябану хәрәкәтсез.

Галиябану (*кулын бирә*). Җаның тыныч булсын.
Исмәгыйль. Менә рәхмәт.
Галимә. Без дә тынычландык, и Алла...
Исмәгыйль. Йә, хуш иттек, киттем бүгенгә.
Галиябану китә күңелдә...
Бәдри. Үзеңә — баш ордык.
Галимә. Аллага тапшырдык!

Бәдринең бакчасы. Төн уртасы. Ай нурларын коя.

Исмәгыйль (*керә*).
Кара төндә нигә килдем монда?
Алай түгел идем мин элек.
Юк, барыбер тынычлана алмыйм,
Төн йоклатмый мине көнчелек.
Имеш, аны Галиябану сөя...
Инде менә сөеп карасын.
Көчле белән юкка көрәшәсең,
Белмисең шул миңа барасын.
(*Тәрәзәдән карап килә.*)
Нишли икән үзе? Йоклый, ахры,
Елый-елый арып бетkәндер,

Бәлки инде бераз тынычланып,
Аны түгел, мине көткәндер.
(*Чыбыклар чытырдый.*)
Берәү килә... Әллә Хәлил инде?
Белмисеңме монда сак барын?
Әгәр кирәк булса, намусымны
Менә моның белән саклармын.

Кесәсеннән револьверын алып, агачларга ышыклана. Як-ягына карана-карана, сакланып кына Хәлил килеп керә.

Хәлил (*сәхнә уртасында туктап*).
Нихәлләр бар икән бу йортта?

Галиябану тәрәзәсенә барып, сузылып карый, сакланып кына тәрәзә чиртә. Тәрәзә ачылмагач җырлый. Исмәгыйль револьверын тоткан-килеш җентекләп карап тора.

Тәрәзәгә егет килгән,
Йоклап ятма, гөлкәем,
Ябышып чыкмый үз-үзеңне
Утка атма, гөлкәем!
(*Тагы чиртә, тәрәзә ачыла.*)
Галиябану. Хәлил, килдеңме?
Хәлил. Бар да мин әйткәнчә булдымы?
Әти-әниләрең тындымы?
Галиябану. Әти-әниләрем уйлаганнар
Мине Исмәгыйльгә бирдем дип.
Хәлил. Соңы ничек бетте?
Галиябану. Чак котылдым
«Инде акылыма килдем» дип...
(*Исмәгыйль нишләргә дә белми.*)
Хәлил. Ат шикелле тизрәк чабып килдем.
Кешеләр дә, ат та алып килдем.
(*Исмәгыйль тыелып кала.*)
Китик алайса, тиз!
(*Галиябану тәрәзәдән төшә, Хәлил күтәреп ала.*)
Галиябану. Куркам, Хәлил, тотылмабыз микән?
Хәлил. Каушама, тиз, атла аягыңны...
Галиябану. Хәерле юл булсын...
Хәлил. Киттек!

Галиябануның биленнән тоткан килеш йөгереп китә башлыйлар. Исмәгыйль, револьверлы кулын кесәсенә тыгып, алларына килеп баса. Болар чигенәләр.

Галиябану (*бик куркып*). Ах!
Хәлил (*курку-ачу катыш*). Ни кирәк сиңа?
Исмәгыйль. Җибәр Галиябануны!
Хәлил. Ник җибәрим мин аны? (*Китмәкче була.*)
Исмәгыйль (*револьверын төзәп*).
Кузгалма!

Галиябану. Һай! (*Куллары белән йөзен ябып, Хәлилнең күкрәгенә каплана.*)

Исмәгыйль. Бир яхшылык белән Галиябануны!
Хәлил. Җибәр безне, барыбер файдасы юк...
Исмәгыйль. Йә Галиябану, йә җаның!
Хәлил. Уйла шуны, мине үтерсәң дә,
Галиябану булмас синеке.
Галиябану. Җәберләмә безне, занһар, җибәр...
Хәлил. Уема да минем керткәнем юк
Сиңа көндәш булу дигәнне.
Беләсең ич вәгъдә бирешкәнне,
Бер-беребезне өзелеп сөйгәнне.
Исмәгыйль. Мин дә сөям, Галиябануга
Әллә юкмы минем үз хакым?!
Кире чигенергә ниятем юк.
Аның белән булыр никахым.
(*Револьверын Хәлилнең маңгаена ук тери.*)
Исмәгыйльнең кулы вәгъдәгезнең
Көле күккә очкач алыныр.
Кит Хәлилдән, ташла, ташла аны!
Галиябану. Мин синеке булмам барыбер!
Исмәгыйль (*Галиябануны көч белән тартып ала*).
Менә хәзер үзең минем кулда.
Хәл ит язмышыңны.
Галиябану. Хәлил җаным, дәш...
Исмәгыйль. Калдырып кит Галиябануны
Яки дөнья белән бәхилләш!

Хәлил кинәт Исмәгыйльнең өстенә очып куна. Исмәгыйль атарга өлгерә алмый кала. Револьверы җиргә төшә. Икәү алыша башлыйлар. Аста калган Хәлил җирдәге револьверны алып өлгерә дә яткан җиреннән өстендәге Исмәгыйльгә төзи.

Хәлил. Тор! Атам!
Исмәгыйль. Шаярма дим минем белән! (*Тора.*)
Хәлил (*револьверны төбәгән килеш, торып*).
Менә хәзер үзең минем кулда.

Синең язмыш белән мин уйныйм.
Тавышланмый-нитми, башың иеп,
Чыгып китәрсең дип мин уйлыйм.

Г а л и я б а н у (*Хәлилгә килеп ябышып*).
Атма, Хәлил, ташла җиргә шуны,
Сүз бирмә син, бирмә алтатарга!

И с м ә г ы й л ь. Күрсәт егетлегең!

Х ә л и л. Хурланам мин
Синең кебек этне атарга!

Револьверны җиргә бәрә. Исмәгыйль револьверга ташлана.

Ал иманың булмаса!

И с м ә г ы й л ь. Китәсеңме, юкмы, яхшы чакта?!

Х ә л и л. Ник китим мин? (*Ике бармагын авызына кабып, әче итеп сызгыра.*)

И с м ә г ы й л ь (*револьверын төзәп*). Ә син шулаймыни?!

Г а л и я б а н у. Исмәгыйль абый, кызган, зинһар!

И с м ә г ы й л ь (*төртеп җибәрә*).
Кит моннан!

Х ә л и л. Ялынма ул эткә!

И с м ә г ы й л ь (*ачуына буылып*).
Мин этме?!

Х ә л и л. Эт син! (*Кесәсеннән пәке чыгарып һөҗүм итә.*)

И с м ә г ы й л ь. Мә, алайса! (*Атып җибәрә. Хәлил чалкан килеп төшә.*)

Сәхнә караңгыланып кала. Галиябануның көйгә охшаган авазына хор кушыла. Яктырганда, сәхнә тулы халык. Галиябану Хәлил гәүдәсе янында.

Х а л ы к. Бу ни хәл? Ни булды? Нишләделәр?

С и б г а т. Кеше үтерделәр.

И с м ә г ы й л ь. Ул үзен-үзе атты!

Х а л ы к. Кемне кем атты? Кем эше бу?

Өй яктан күлмәк-ыштаннан гына Б ә д р и, эчке киемнәрдән Г а л и м ә чыгалар.

Г а л и м ә. Ай Аллам!

Б ә д р и. Бу ни эш? Кемне аттылар?

Х а л ы к. Хәлилне!

Г а л и я б а н у. Хәлилне Исмәгыйль атты.

И с м ә г ы й л ь. Алдама!

Б ә д р и. Ай, эшне бозган, ахры...

Хәмзә. Син аткансың, бәдбәхет!
Исмәгыйль. Мин гаепсез, миңа бәйләнмәгез!
Галимә. Әйдә, Галиябану, өйгә керик.
Бәдри. Тор, кызым, сиңа алай утыру ярамый.
Галиябану. Зинһар, соңгы сулуларында...
Халык. Җаны бармы?
Сибгат. Нидер әйтергә тели...
Галиябану (*Галимәдән ычкынып, Исмәгыйльнең алдына ук басып.*)

Аны мин атмадым диеп,
Әйт күзләремә карап.
Менә шушы җансыз адәм,
Ул итте аны харап!

Исмәгыйль (*Галиябануның күзенә карап калтырап китә.*)

Әйе, мин аттым...

Бәдри. Ах, Исмәгыйль, бик зур хаталык...
Галимә. Кемне кияү диеп атадык...
Кеше үтерүче!
Исмәгыйль.

Әйе, мин үтердем, мин аттым.
Куркытмакчы гына булган идем.
Галиябануны мин бит яраттым.
Мин үкенәм, гаебемне таныйм.
Судның хөкеменә бирелəм.

Аны алып китәләр.

Галимә (*Хәлилгә барып*).
Хәлил углым, хәлең ничек?
Халык. Хәлил, Хәлил,
Шулай булыр диеп кем уйлар...
Моңлы гармуныңны кем уйнар?

Хәлил янына җыелалар.

Хәлил. Үләм... (*Газаплана.*)
Галиябану. Хәлил, китәсең бит...
Галимә. И бичара.
Коткарырга юк шул бер чара.
Хәлил. Галия...бану... (*Кулын суза.*)
Галиябану (*кулын тотып*).
Хәлил! Җаным...

Хәлил (*газапланып күтәрелә.*)

Кил... Үләм...

Галиябану (*Хәлилнең башын кочагына алып, елап*).

Шулай ук аерылабызмыни?!

Хәлил. Галиябану, сылуым иркәм, инде үлсәм дә... үкенмим.

Җан... бирәмен... куе...ның... да... (*Үлә.*)

Хәлилнең соңгы җырын хор күтәреп ала.

Халык. Хуш, Хәлил, мәңгегә...

Галиябану (*Хәлилнең янына тезләнеп*).

Яшь күңелем «инде кавыштык» дип,
Ник бик азга гына сөенде?
Җеназаңда җырлау язган икән
Сиңа багышланган көемне.
Ташламам дип вәгъдә биргән идең,
Җаннарыма гүзәл ямь идең.
Нигә, нигә бергә булалмадык?
Хуш-бәхил бул инде, Хәлилем.

Ерактан скрипкәдә «Галиябану» көе уйнаган аваз ишетелә. Бераздан Галиябану аңа кушылып җырлый.

Ак атласым җитмәде,
Алмас кайчым үтмәде,
Унөч яшьтән бирле сөешеп,
Күзебез күзләрдән китмәде,
Ходаем насыйп итмәде...

(*Елап Хәлилнең өстенә ава.*)

Пәрдә.

# Эчтәлек

## Төрле еллар, җырлы, шигырьле юллар

Йөрәк бүлегендә туган шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 9
«Кузгалмыйча ятам...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
«Күкрәгем эчендә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Ял итмичә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Ел саен, көн саен...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
«Чаптым. Атлап киттем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
«Юк, табиб...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Ята күрше караватта...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Сугыш гарипләре...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Йөрәк, котырма...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Инде бу котсыз заманда...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Картлар арасында иң яше мин...» . . . . . . . . . . . . . . . 15
«Бу дөньяның...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
«Уилар-бозлар йотып...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
«Йөрәк турындагы җырларымны...» . . . . . . . . . . . . . . . 17
«Туйдым икейөзлелектән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Кара багана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Борчак белән Ядрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Тәүге тыныч төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Бер тамчы яшь тамды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Сакмы йокың, Кеше! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Тын океанда, тыныч чорларда . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Ризалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Әйдә, аткаем! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Син яшьтәш тә, замнадаш та... . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Әкияттән аерылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Өч авылдан чыккан өч гали җан . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Дуска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Йокыга талды арып кайткан...» . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Туган җир һәм бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Толымнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
«Яшьтәшләре бар да яуга киткән...» . . . . . . . . . . . . . . 40
Саумы, яшьлек! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Юлларга җыенсам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Табигатем минем ерганактай... . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Аннан бирле күпме печән үсте...» . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Хушыгыз! Мин китәм еракка!..» . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кылганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Эпитафияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
«Диңгезнең ярлары бик ерак...» . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Гүзәллеккә — салават! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Үкенечләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Кыска шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Сибгат Хәким туган нигездә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Киләчәккә аваз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Таныш урманнарым...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Карт тал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

Бакый Урманче күргәзмәсен карагач . . . . . . . . . 59
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Урман кызы Гөлсәрия . . . . . . . . . . . . . . . . 60
«Гадәт-холкым белән...» . . . . . . . . . . . . . . 61
Кемнәр үтәр? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Карадуган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
«Сибелә чәчәк...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
«Әнкәемнең җылы туфрагында...» . . . . . . . . . 65
Туктап уйга калу . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
«Татар бавы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Җәяүле бураннарда . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Якташлар мәҗлесендә . . . . . . . . . . . . . . . 71
«Юл буена чыгып көтәр инде...» . . . . . . . . . 72
Бер кичәдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Җырларым-шигырьләрем . . . . . . . . . . . . . . 74
Хуш, исән бул, Яңавылым! . . . . . . . . . . . . 75
Нигә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Ачыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Зиратлар яныннан узганда. . . . . . . . . . . . . 77
Табиб дустым ядкәре . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Сезнең якта табигать тә башка...» . . . . . . . 79
«Нигә минем баш очымнан...» . . . . . . . . . . . 80
«Фәрештәләр китте...» . . . . . . . . . . . . . . 81
«Ычкынырмын акылдан дип...» . . . . . . . . . . . 82
Яшик әле... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
«Бәла-каза арттан ияреп йөри...» . . . . . . . . 84
«Тормыш бит ул — боксер...» . . . . . . . . . . . 84
«Әйтә алмыйм гомеремнең...» . . . . . . . . . . . 85
«Үзәк өзгеч моңлы тавыш...» . . . . . . . . . . . 85
«Озак яшәгән шагыйрьнең...» . . . . . . . . . . . 86
«Гомерне булмый озайтып...» . . . . . . . . . . . 86
«Бирәү — байый...» . . . . . . . . . . . . . . . . 86
«Гомеремдә күпме буш сүз...» . . . . . . . . . . 87
«Син бит тыңлый белә идең...» . . . . . . . . . . 87
Яши-яши аңладым... . . . . . . . . . . . . . . . 88
Бер җырчыга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Син китсәң... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Багышлаулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
- «Йә, кил әле, Айрат, минем янга...» . . . . . . 90
- Дусларга таян, йөрәк! . . . . . . . . . . . . . 91
- Ялгышасың, Атнабай... . . . . . . . . . . . . . 92
- Кистеләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
- Картлык килсә... . . . . . . . . . . . . . . . 94
- Коткар безне, Ахун! . . . . . . . . . . . . . . 95
- Генералның туган көнендә . . . . . . . . . . . 96
- «Башкорт дуслар...» . . . . . . . . . . . . . . 97
- Кичке урам нигә тып-тын? . . . . . . . . . . . 98
- Матурлык илчесе . . . . . . . . . . . . . . . . 99
- Кем дисәгез... . . . . . . . . . . . . . . . . 100
- Үз тургаегыз . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
- Җәйгә кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
- Җыр дәүләтенең ханы . . . . . . . . . . . . . . 103

Кылы өзелгәннәр көтә шуны... . . . . . . . . . . . . . . 104
Җирнең үзе кебек... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Тупчы Мәхмүт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Сез юклыкны тоям... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Мәңгегә ак булып, пакь булып . . . . . . . . . . . . . 107
Шагыйрьләр яткан изге урында . . . . . . . . . . . . 108
Уян, Мәхмүт, уян... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Күңелләрдән китмәс инде... . . . . . . . . . . . . . . 110
Калдың чишмә юлында... . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Яза алмый каләм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Акчарлак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Безне кемнәр юксыныр?.. . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Син Казанда бүген, дусларыңда... . . . . . . . . . . 115
Маннурның дусларына язган васыяте . . . . . . . . 116
«Көтмәгәндә генә килде ул яз...» . . . . . . . . . . . . 117
«Ахры, мин дә сезнең нәселдәндер...» . . . . . . . . . 118
Тол ханымга бер теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Кара каен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
«Тукталышны узып киткәнмен ич...» . . . . . . . . . 120
Соңгы кар, тәүге яңгыр... . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Роза исемле кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
«Җылы якка озатып калдым...» . . . . . . . . . . . . . 122
«Сәлам сезгә, нәни кызлар...» . . . . . . . . . . . . . . 123
Ак болытны юлдаш итәр идем... . . . . . . . . . . . . 124
«Милләтемнең шигырь бакчасында...» . . . . . . . . 124
Йолдыз булма күгемдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Яңавылым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
«Сизәм ич мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Сара ханым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Без үзебез... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Һәр мизгеле — бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
«Иң кирәкле бер сүземне...» . . . . . . . . . . . . . . . 131
Алмагачлар чәчәк аткан чакларда . . . . . . . . . . 132
Гөлләрдән килеп чыгарсың... . . . . . . . . . . . . . . 133
«Хәсрәтле анадан туганмын...» . . . . . . . . . . . . . 134
Нишләттеләр сине? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
«Әче җил. Күкри, дөберди...» . . . . . . . . . . . . . . 136
«Кайчандыр әбиләр-бабайлар...» . . . . . . . . . . . . 137
«Тукта, җилкәй... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Килдем кырык чакрым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Тау башында җиләклек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Синдә генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Сизәләрдер... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Булгандыр инде... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Соңгы сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
«Җимерүче мәлгуньнәргә каршы...» . . . . . . . . . . 143
«Туруннарым мине укысалар...» . . . . . . . . . . . . 143
Кызлар уйный . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Йорт кызлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
«Ялгышлар да, хаталар да булды...» . . . . . . . . . 145
Кар өстендә чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146

Адашкан аккош баласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Таң кошларын юлдаш итәрмен . . . . . . . . . . . . . . . 148
Кар өстендә тәүге чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Уйга талган чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
«Җитәрлек яшәдем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Күз яшьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Әнием, мин сине ташламам . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Кулъяулык хәтле болыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Күзләремә кергәч... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Күзләрең нигә моңлы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Тукай Сәйдәшне тыңлый . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Кем җиңәр, өстә калыр? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Мине кем аңлар? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Ниһаять! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Без — ир-атлар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Йола . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Бүлешәләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Берләр һәм меңнәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Акча кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Кода белән кодагыйга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Заман егете ни җырлый? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Заман ире ни җырлый? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Имәбез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Замандаш портреты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Бер юллык шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Ике юллык шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Өч юллык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Дүрт юллык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Күчеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Башлы редактор хикәяте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Гали белән сарык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Кыргый базар кочагында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Бер җыр язасы килә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Мин президент булсам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Хатының булса депутат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Бер кыз авызыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Берәүнең изге ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
И сөйкемле шәфкать туташы . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Нәни генә бер явызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Эшкуарлар һәм җилкуарлар . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Рифма өчен язылган шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Васыятьләр әйтеп тормыйм... . . . . . . . . . . . . . . . 183
Яшьлегем минем җитмеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Язылмаган поэма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185

**Хикәяләр**

Мин сездән, авылдашлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Сагыну булган икән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Ачылмаган бер чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Алларыңа тезәр идем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218

**Сәхнә әсәрләре**

Моңлы бала түгел идем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Гашыйклар тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Ерактагы кәккүк авазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Соңгы төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Бәгырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 380
Янар чәчәк. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 416
Безнең эти мировой. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 476
Хуш, Хәйбуш. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 517
Хәлил — Галиябану. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 559

Литературно-художественное издание

Ильдар Юзеев

*(Юзеев Ильдар Гафурович)*

**Избранные произведения
в пяти томах**

Том 4

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, С.Н.Мифтахова, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.12.2002. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы-басма табагы 31,08+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 31,82. Нәшер-хисап табагы 28,78+форз.0,36.
Тиражы 3000. Заказ Б-550.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур.,2.